Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе
Г.Ибраһимов исемендәге
Тел, әдәбият һәм сәнгать институты

# Гаяз Исхакый

# ӘСӘРЛӘР

**УНБИШ ТОМДА**

# 7

Публицистика
(1915–1916)

КАЗАН
ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ
2008
УДК 821.512.145-4
БДК 83.3(2Рос=Тат)
И84

Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең
Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты
Гыйльми советы карары белән басыла.

**Редколлегия:**
*М.Х.Хәсәнов (рәис), З.Р.Вәлиева, К.М.Миңнуллин,
А.Г.Әхмәдуллин, Ф.Г.Галимуллин, Р.Х.Корбанов, Х.Й.Миңнегулов,
Ф.М.Мусин, З.З.Рәмиев, Н.Ш.Хисамов*

**Төзүчеләр:**
*Фатыйма Ибраһимова, Зөфәр Рәмиев, Эльмера Галимҗанова*

**Текстларны әзерләүчеләр:**
*Фатыйма Ибраһимова, Эльмера Галимҗанова*

**Аңлатма һәм искәрмәләрне язучылар:**
*Зөфәр Рәмиев, Эльмера Галимҗанова, Гөлчирә Ханнанова,
Фирдәүсә Кадыйрова*

**Фәнни мөхәррир**
*Зөфәр Рәмиев*

**Исхаков М.Г.**

Әсәрләр: 15 т. / Гаяз Исхакый. — Казан: Татар. кит. нәшр., 1998 —
7 т.: Публицистика. — 2008. — 366 б. — 3000 д. — ISBN 978–5–298–01588–2

Бу томда Гаяз Исхакыйның 1915–1916 елларда язылган публицистик мәкаләләре тупланды.

ISBN 978-5-298-01588-2
© Татарстан китап нәшрияты, 2008
© ТР ФАнең Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты, 2008

*1915*

## КАЗЫЙЛЫК

Хәсәнгата казый истигъфа итү белән яңгы казый мәсьәләсе туды. Кеше төсле, адәм рәтенә керерлек урыннарымыз бик аз булганга, алты мең мәхәлләнең имамнары өчен зурайганда, шул өч казыйның урынын тоту ихтималы гына булганга, казый булырга теләүчеләремез аз булганы юктыр.

Элгәреге заманда казыйлар Казан губернасы муллаларыннан сайланганда, бу безнең өчен зур бер мәсьәлә булып, партияләр тартыша-тартыша торган бер мәсьәлә була иде. Хәзер инде мөфти тәкъдим итеп, министр тасдыйк итү юлы кертелгәч, казыйлыкка бюрократлык исе кертелде, вә казый булу өчен түрә булуда кирәк булган сүз үткәрү, ярау, күңел тулуга зур урын бирелде. Элгәредән казыйларымыз искиткеч булган иде, дия алмыймыз. Халкымыз арасында аларның ришвәтне ничек алулары хикәя булып сөйләнеп йөри, ләкин шул казыйлар голямамызның вәкиле иде. Аның берсе бер нәүбәттә начар булса, шуның урынына яхшыны да сайларга мөмкин иде. Хәзер казый мәсьәләсе тәмам мөфти хәзрәтнең теләве, яратуына тапшырылганга, аның хәрәкәтенә салават әйтеп тора алмый торган казыйларның озак яшәмәүләре күренгәләп торды. Хәзер инде менә тагы шул бу казыйлык урыны буш, имеш. Аның урынына кем чакырылуы матбугатта языла, телләрдә сөйләнә башланды. Сөйләнми хәле юк, бу мәсьәлә — безнең өчен бик зур мәсьәләдер. Казыйларымызның, үзләре кем булса да, урыннары бик олугдыр. Аларның халкымызның рухани тормышына итәчәк тәэсирләре дә шул нисбәттә олугдыр. Шуның өчен шул олуг урынга инсафлы галим, иң тугрысы, иманлы казыйның чакырылуы бик теләнәчәк эштер. Ләкин бит тәҗрибәләремездә инсафлы, ышанычлы, иманлы галимнәремез дә казыйлыкта булгаладылар. Алардан да артык зур хезмәт чыкмады. Күтәрелгән үзгәреш ясалмады.

Чөнки идарәи руханияләремездә эшләр хәзерге юлда барганда [...]

## МӘҮЛЕД БӘЙРӘМЕ

Элгәреге заманда безнең Русия мөселманнары — авылларында яшәгәне дә, шәһәрдә гомерен кичерә торганнары да — үзләренә аерым мәхәлләләр, аерым урамнар ясап, үз гадәтләре, үз юлларына бөркәнеп, сакланып гомер үткәргәндә, безнең халкымыз өчен динен, милләтен югалту куркусы юк иде. Аның тирә-юне, аның кардәш-кабиләсе эчендәге гадәте-горефе надан гына мөселманны үз динендә, үз гадәтендә саклап килергә җитә иде. Шуның өчен ул вакыттагы агайларның наданы да динендә бик ихласлы, бик нык булып, чит халык арасында да үзенең динен саклый ала, үзенең җәмгыятен югалтмый иде. Шуның өстенә чит халык берлән катнашып йөрүләр ул вакытта сату-алу, дөнья кирәге өчен генә булганга, гаилә тормышымыз бөтенләй башка халыкларның гаилә тормышы берлән берегеп, бергәләнеп бармаганга, динемездәге ныклыгымызны югалтырга, милли хәмиятемезне азайтырга урын да юк иде. Ләкин хәзерге хәлдә эшләр башкарды. Мөселманнар, бөтен Русия буена җәелеп, зур шәһәрләрдә генә түгел, кечкенә-кечкенә авылларга кадәр мөселман гаиләләре сатучы, алучы булып таралдылар. Шәһәрдә яши торганнарында, хосусән Петроград, Мәскәү, Варшау кебек зур шәһәрләрдә, төрлесе шәһәрнең төрле почмагында яшәргә мәҗбүр булдылар. Шул таркаулык балаларга вә аларның дини, милли тәрбияләренә бик зур тәэсир итәчәк яңгы бер гамил булып алдымызга килеп басты. Шәһәр балалары хәзер теле чыккач та, үзе кебек татар мөселман балалары берлән бергәләшеп ат-ат, куян куыш уеннары уйный алмый. Татар-мөселман баласы, хәзер гарәфә, кадер кичләрендә әнисенең чабуына тотынып, мулла абзыйларга китап ишетергә, вәгазь тыңларга бара алмый. Татар-мөселман баласы хәзер зур чалмалы, мәһабәт кыяфәтле мулла абзыйны еш-еш өендә күрә алмый. Ул гына да түгел, зур шәһәрләрдәге мөселман баласы бик озакка кадәр азан тавышын ишетә алмый. Менә шулай баланың күңелендә динлелек вә мөселманлык матур мәнзарәләр берлән мәңгелеккә китмәслек булып нығып калачак вакытында да ул мескин тирә-юнендә шул матур мәнзарәләрне таба алмый, дини матур бәйрәмнәр, гадәтләр күрә алмый. Ул гына да түгел, ул тирә-юнендәге башка халык бәйрәмнәрендә аларның балаларының матур киенүләрен, тәмле әйберләр берлән

сыйлануларын күреп, аларның бәйрәмнәре аның күңелендә матур хис калдыра, баладагы иярченлек хисе берлән ул диндә башка балаларның дини гадәтләренә, дини горефләренә иярә башлый. Шулай итеп, аның күңелендә элгәреге әтисе-бабасындагы ныклык кими. Ул дин эшләренә илтифатсыз була. Вә җае тугры килде исә, төрле-төрле гөнаһлы эшләргә чумудан да курыкмый, шуның өчен киләчәк буынны чын мөселман, саф татар иттереп тәрбия итү авырая, зурая, аның өчен тырышырга-тырмашырга, әллә никадәр гайрәт сарыф итәргә мәҗбүрият туа. Мәктәп-мәдрәсәләремезнең вазифалары намазның фарызларын, сөннәтләрен өйрәтүдән узып китеп, мәктәптә балага дини рух, милли хис кертү дигән бер бурыч, зур бурыч йөкләнә. Менә шуны сизеп алып, хәзер дә яхшы мөгаллимнәремез дини бәйрәмнәремездә, олуг кешеләремезнең үлгән вә туган көннәрендә балалар кичәсе ясый башладылар[1] вә шул матур, күркәм ясалган кичәләрдә балаларның күңелендә матур эз, күркәм хис калдырыр өчен берни дә аямадылар. Казанда башланган бу матур эш хәзер бөтен Русиягә җәелде. Русиянең шәһәрләрендә, авылларында Мәүлед бәйрәмнәрендә, Тукай мәрхүм үлгәнгә ел тулган көннәрдә балалар кичәсе ясау бер сөннәт хәленә керде. Казанда былтыр балалар җыеп, (сыеп) җитмәгәнгә, шул бәйрәмне ике көнгә сузарга булдылар. Петербургта былтыр халыкның күплегеннән урын җитмәгәнгә, баланың анасыннан яки хатын кардәшеннән башка берәүгә дә керергә рөхсәт ителмәде. Без Мәскәү кебек мөселман халкының таркау яши торган бер йирендә балаларга шундый матур дини, милли хисне чарлый торган бәйрәм башка йирләргә караганда дүрт-биш мәртәбә артык кирәк булса да, моңганчыга кадәр шул яхшы эш эшләнмәенчә килгән вә шуның хакында, шөбһәсез, үсеп килә торган таркау, фәкыйрь мөселман балаларының бик күбесе дини бер бәйрәм күрүдән вә шуның берлән дин хисен күңеленең иң тирән йирендә саклаудан мәхрүм ителгән. Менә, Аллага шөкер, Мәскәүнең «Хатын-кыз җәмгыяте хәйриясе» шул изге эшкә кереште. 14 гыйнварда, Мәүледен-нәби көнендә балалар өчен (пәйгамбәрләремезнең туган кичәсе 13 гыйнвардыр) әдәби кичә ясарга тотынды[2]. Бу хәерле эшне кулына алганы өчен вә балаларга дини тәрбия кертүдә юлбашчылык иткәне өчен, «Хатын-кыз җәмгыяте хәйриясе»нә рәхмәтләр укымый хәлемез юктыр.

Хатыннарымызның үзләренең вазифалары арасында балалар тәрбиясенә зур урын биреп эшкә башлаулары бик хәерле фал булачагында шөбһәмез юктыр. Шул өстләренә алган эшне матур иттереп булдырып чыгаруны бөтен күңелемез берлән телимез. Ләкин үз тарафымыздан берничә сүз кушмакчы буламыз.

Кичә Татарский мәктәбендә ясалса да, кичәгә Мещанский мәктәбе балалары да чакырылсын иде. Һәм дә мәктәп күрүдән мәхрүм булган мөселман баласына кичәнең ишеге ачык ителсен иде вә аларның да боек, мескин тормышларында шул газиз көн аллы-гөлле матур, якты хис калдырсын иде.

## «СӘЙЯР» ТРУППАСЫ ХАКЫНДА

«Сәйяр» труппасы таралуы хакында гәзитәләрдә шактый хәбәрләр булгалады. Бу күңелсез хәбәр дөрест булса, һәммәмезнең кәефен китәрәчәк бер эш иде. Ләкин төбе «Сәйяр» труппага бигүк дуст булмаган кешеләр тарафыннан чыгарылган вә кечкенә бер эшне зур ителеп, тау кадәре күрсәтелгәне идарәмезгә ачык мәгълүмдер. «Сәйяр» труппаның таралуына дәлил иттереп Җәлал Байкин[1] дигән кешенең вә аның берлән бергә хатыны Сара ханымның[2] да Әстерханга китүләре күрсәтеләдер. Җәлал әфәнденең урыны «Сәйяр» труппада шактый әһәмиятсез булганга вә ул һичбер вакыт эшкә ашарлык бер роль дә уйный алырлык булмаганга, аның чыгуы һичбер төрле әһәмиятне хаиз түгелдер.

Сара ханым үткән ел гына «Сәйяр» труппага килеп кергән булса да, шактый тәрәккъый итеп, ачылып килә торган бер ханымызның «Сәйяр» труппасыннан чыгуы, үзенең тәрәккъыйсы өчен зарарлы булса да, «Сәйяр» труппасының игътибарына тәэсир итәр дәрәҗәдә түгелдер. Шөбһәсез, шул таркауланып йөри торган артист вә артисткаларымызның берләнә төшеп, бер труппа ясый алсалар да, театрымызның тәрәккъыйсенә зур хезмәт булыр иде. Ләкин безнең татарның табигатендәге башбаштаклык йөз тәңкә акчасы булган бер приказчикны хуҗасына рәкыйб иттереп, хуҗа иттереп чыгарганы кебек, артистларымызның да бер-ике, өч рольне шактыйрак уйный башлады исә, «Габдулла Кариев булдым инде» дигән фикергә китерсә, гаҗәп түгелдер. Ләкин әфкяре гомумиямез, матбугатымыз, шул ярылу, шул бүленүнең бик ямьсез эш икәнен белеп, вак-төяк, театрны мыскыллап йөрүче артистларга ярдәмдә булмаска тиештер вә шуның берлән үзенең ныклыгын көчләп булса да шул башбаштаклык ясаучы артистларымызга тыңлатырга тиештер. Халкымыз һәр сәхнәдә чыккан бер кешене артист дип каршы алганга, эшкә иренгән бик күп кешеләр «артистмыз» дип мәйданга атылдылар вә әллә никадәр исемнәрдә «труппалар» тәэсис ителделәр[3]. Боларның труппалары күп вакытта үзеннән һәм үзеннән авылдаш Әхми абзыйның малае берлән пароходта очраган бер асрау кыздан гыйбарәт булса да, оятсызлыкларының иге-чиге булмаган бу якуннар Петербург, Мәскәүләрне дә былчыратуга кадәр килеп җиттеләр. Халыкның шуларга каты торып, шул утын авызларны сәхнәдән куып чыгармаулары аркасында үзләрен чынлап артист

дип уйлый башладылар. Халкымызның бик күбесе «йә инде, мескин, расхудлары бардыр, барыйк инде» дип кызганып сәдака бирүләре — шулар батырайтты... Кәсеп җиңел булганга, әллә никадәр иярченнәр чыкты. Укымаган шәкерт, эш яратмаган приказчик, эш юктан «милләт хадиме» булып йөри торган кызыл авызлар театрга ябыштылар. Шулар менә чын артистларымызга зарар итәләр. Шулар менә, безнең театрымызның кыйммәтен төшенергә хезмәт итеп, милли җинаять ясыйлар. Шулар менә рус халкын, укыган зыялыларымызны театрдан биздерәләр. Аларга ярдәм нинди генә юлда булса да булсын, бу көнге көндә милли дошманга ярдәмдер. Аларны күтәрешү, аларны култыклашу — милли театрымызның тамырын кисүдер вә милли җинаятьтер.

## БЕЗНЕҢ ХӘЛЛӘР

Сугыш[1] Русиянең бөтен халкының әһәмиятене үзенә боруы табигый булган кебек, шул ук Русиянең гражданнары булган без Русия мөселманнарының да шул гомум агышның тәэсиренә бирелүе табигый иде. Шуның өчен, сугыш башлану берлән, бөтен милли, мәдәни, дини мәсьәләләремез онытылды, онытылмаса да, алар бик еракка, тавыш-тыны чыкмый торган күңел сандыкларына бикләтелде. Бөтен дикъкатемез сугышка китте. Бөтен вөҗүдемез, бер зур колак киселеп, сугыш мәйданыннан килә торган хәбәрләрне тыңларга тотынды. Бөтен көчемез, куәтемез сугыш эшләре берлән шөгыльләнергә кереште. Матбугатымыз сугышны язарга, аның вакыйгаларын иҗекләргә бирелде. Халык хезмәтчеләремез сугыш тудырган мәсьәләләр берлән уграшырга, бөтен башка эшләрен онытып, шуңа гына көче-куәте берлән чумды. Ярлыларга иганә җыю, күлмәк-ыштан тегү, тәмәке туплау, кием салым хәзерләү, флаг сату, кызыл тәре сату бөтен барлыгымызны томалады. Һәр йирдә лазарет, тегү урыннары ачылды. Боларның кирәклеген инкяр кыла торган һичбер кеше булмавы да табигыйдер[2]. [...] ыштан тегү никадәр кирәк булса да, флаг сатып, кием җыеп ярдәм итү никадәр лязем булса да, шул эшләрне безнең иң алда тора торган халык хезмәтчеләремез эшләве табигыйме? Гәзитәләремез нишли? Сугыш берлән мәшгуль. Әдәбиятымыз нишли? Сугыш берлән мәшгуль. Җәмәгать хадимнәремез нишли? Сугыш берлән мәшгуль. Депутатларымыз нишли? Сугыш берлән мәшгуль.

Соң, башка кирәкләремезне башкалар эшлиме? Хәер, юк, алар тора. Башка шундый вазифамызга[3] [...]

Менә тагы Дума ачылыр көннәр җитә[4]. Анда безнең әйтәчәк бер сүземез, күтәчәк хезмәтемез юкмы? Уйларга, төшенергә вакыты килмәдеме?[5] [...]

## (МӘСКӘҮ КЕБЕК МӨСЕЛМАНЫ...)

Мәскәү кебек мөселманы төрле йирдән җыелган зур шәһәрдә сезнең язган уңгайсызлыклар булуы табигыйдер. Безнең мөселман халкы кунак сөючән булса да, кунакны хөрмәт итүчән булганга, чакырмаенча килгән кунакка хөрмәтем җитмәс дип куркучан буладыр. Тагы шуның өстенә хатыннарымыз өйне һәрвакыт җыеп торырга өйрәнмәгәнгә, чакырмаган кунак килеп чыкса, хатыннарда «гаебем ачылды» дип курку, кәефе китү хисен тудырадыр. Шул иренә, углына тәэсир итеп, кунакка салкынча йөз күрсәтеләдер. Кунак чакырганда дуст-иш килгән булып, әллә никадәр чыгым ясарга тиеш булганга, чакырылу, кунаклар азаюы да табигыйдер. Шуның өчен дуст-иш үзара сөйләшеп, киңәшеп, атнаның бер буш көненә әле берсенә, әле берсенә баруны гадәт итәргә вә мөмкин кадәр тәкәллефсезчә сыйлашырга тиештер. Шундый мәҗлесләрдә сүз тапмаенча, ашап-эчеп утыруны гына бетерер өчен вә мәҗлескә дустларча сөйләшүне кертер өчен элгәре якынрак, танышрак гаиләләрдән башларга тиештер. Ирләр андый-мондый кирәкмәгән нәрсәләр эчеп, алмашып китмәсен өчен вә мәҗлесләрдә ямьсез сүзләр сөйләмәсен өчен, хатыннар да бергә булырга тиештер. Безнең халыкның мәҗлестә тупас сүз сөйләве, тәмсез телле булуы хатыннарымызның мәҗлесләремезгә катышмауларыннандыр.

Бу мәҗлесләр бара-тора зурайса, киңәйсә, Мәскәүдәге «Шәрекъ клубы»ның[1] нигезе булырга тиештер. Мәҗлестә музыка уйный белүченең булуы, әлбәттә, мәҗлескә матурлык өстенә матурлык кына бирәчәктер.

Эштән арып кайткан егетләргә килсәк, аларның буш вакытларында күңел ачарга теләүләре бик табигыйдер. Һәр яшьнең үзенә күрә теләве, үзенә күрә кирәге була. Балага уенчык уйнау, чабу, йөгерү һава кебек кирәкледер. Вә баланың үсүе, баланың бөтен яктан ныгаюы өчен ляземдер. Сигез-тукызлык яшьлек баланы уйнатмаудан баланың тәрбиясенә, әхвале рухиясенә, сәламәтлегенә зарар гына булган кебек, егерме биш яшьлек егетне, намаз гына уку, тәсбих тартып зекердә утыр, дип көчләү дә шулкадәр зарарлы булып чыгачактыр. Шундый кысынкы гаиләләрнең балаларындагы төрле-төрле табигатькә бик тирес

гөнаһларга чумуы, егетләрнең егетлекләрен онытып, хатын-кыз табигате алып, вакчыл, гайбәтчән булулары моңгарга җитәрлек дәлилдер.

Шуның өчен яшь егетләрнең күңел ачарга, эштән калган вакытларын ямьлек иттереп үткәрергә теләүләренә картларның гөнаһлы эш, бозыклык дип караулары тугры түгелдер. Баланың уен төшенүе, балача булуы никадәр табигый булса, картларның намазда, тәсбихта гомерләрен үткәрүләре никадәр урынлы булса, яшьләр күңел ачарга теләүләре дә шулкадәр урынлы, шулкадәр табигыйдер.

Моңгарга каршы килү ага торган суга каршы килү булганга, кирәкмәгән юлга китүдән башка нәтиҗә бирәчәк түгелдер. Асыл мәсьәлә яшьләргә күңел ачачак урынны ямьле генә, матур гына иттерү, яшь егетләрнең дини вә милли тәрбияләренә зарар итмәслек вә сәламәтлекләрен бозмаслык юлда ясаудыр.

Башка мәдәни халыкларда яшьләрнең үзләренә махсус клублар була. Алар анда тән тәрбиясе өчен гимнастика берлә шөгыльләнәләр. Аның кыйраәтханәсендә үзләре сөйгән гәзитә вә журналларны укыйлар. Зуррак бәйрәмнәрдә кешеләр чакырып дәресләр ясаталар. Музыка, тансы кичәләре ясыйлар. Безнең бит андый урыннарымыз юк. Юк кына түгел, әле ясалуы да бик ерак төсле күренә. Мөселман егетләре, мөселман приказчиклары күбрәк йирләрдә бер-бер мөселман хәрчәүнәсендә берәр бүлмә тотып җыелучан була. Шундый бер-бергә гомер үткәрүчән була. Шунда аларның уйный белә торганнары уйныйлар, сөйлиләр, көләләр. Яшьләрчә кичне үткәрәләр. Ләкин безнең Мәскәүдә андый йир булмаганга, тагы шул үзара җыелышып, әле берсенең өендә, әле берсенең өендә мәҗлесләр генә каладыр.

Тагы егетләр тәрбиясе өчен, аларның кеше алдында үзләрен-үзләре тота белергә өйрәнүләре өчен егетләрнең гаилә эчләренә кабул ителүе дә тиештер. Алар анда үзләренең яшьтәшләре берлән бернәрсә хакында сөйләсәләр, көлсәләр, зурлардан әдәп-инсаф та өйрәнәчәкләрдер вә мәҗлестәге хатын-кыздан тартынырга, йомшак сүзгә, нәзакәткә өйрәнәчәкләрдер. Хәзерге хәлдә егетләремезне шулай Аллага тапшырып калдыру һич ярый торган бер эш түгелдер. Картлар, әтиләр, никадәр, зекердә утыр, тәсбих тарт, дисә дә, алар аны булдыра алмаячаклардыр. Билгакес, аларда ачу килү уянып, шул газиз вакытларын юк эшләр артыннан йөрергә сарыф итәчәкләрдер вә киләчәктә бик ямьсез нәтиҗәләр күрсәтәчәкләрдер.

Гомумән, бай балаларымызның эшсез булуы, «тифкеч» булуының сәбәпләре — аның яшь вакытында гөнаһсыз, матур күңел ача торган уеннар таба алмавыдыр. Күңел ачу яшьләр өчен һава кебек кирәкледер. Аның гөнаһсызы, матуры булмаса, алар аның гөнаһлысы, былчырагы артыннан китүләре ап-ачык мәгълүмдер. Хосусән зур шәһәрләрдә марҗа артыннан чабу, атасының бөтен тапканын өч тиенлек марҗага бетерү — яшьләрнең тәрбиясенә, аларның күңел ачачак йирләренә әһәмият бирмәүдән килгән милли зур гөнаһымыздыр. Шуның өчен Мәскәү кебек мөселманның таркау йирендә, Мәскәү кебек өйләнмәгән егетләрнең күп йирендә шуларга муафикъ гөнаһсыз күңел ачу урыны ясау Мәскәү мөселманнарына важибтыр вә фарыздыр.

**МӘСКӘҮ, 18 ГЫЙНВАР**

Әллә нинди бер мөхәррир: «Бәйрәмнәр — милләтләрнең көзгеседер», — дигән. Көзгедә кешенең бөтен сыйфаты, сыны, торышы күренгән кебек, бәйрәмнәрдә дә бөтен милләтнең, халыкның тормышы-кыйланышының шәүләсе күзгә күренә, ингыйкяс итә. Мәскәүдә үткәрелгән Мәүлед бәйрәмемез Мәскәү мөселманнарының көзгедәге шәүләләрене күз алдымызга китереп бастырды. Халыкның, милләтнең тормышы төрле-төрле булганга, әлбәттә, аның шәүләсе дә, аның көзгедә ингыйкясы да бертөрле генә, бертөсле генә булмый. Аның төрле сыйныфы, төрле бүлеге төрлечә күренә вә җыенын җыеп куюдан Мәскәүнең бөтен мөселманының кыяфәтен, дине вә милли кыяфәтен күз алдымызга бастыра. Бабайлар: «Авызың чалыш булса, көзгегә үпкәләмә», — дигәннәр. Көзгенең хасияте бит чалыш авызны төзәтү түгел, барны барча, бары берлән бергәләп җыеп күрсәтү. Мәскәү көзгесендә дә күзгә ташлана торган берничә авызы чалышларын язмаенча китәргә мөмкин түгелдер.

Бәйрәм мәсҗедләрдә Мәүледен-нәби уку берлән башланды. Мин барган Татарский мәсҗедендә халык шактый күп булса да, Мәскәүнең алдынгы сыйныфы — аңлы бае, фикерле сәүдәгәре, яшь приказчигы, түрәсе, мирзасы юк иде. Икенче мәхәлләнең имамын бу халык байкот астында тотканга, анда да алар бармаганнар иде. Соң, болар шул газиз вакытларда, Мәскәүнең уртасында җәнабе пәйгамбәргә сыгынып, догаларын, ялварышларны күккә ашырганда кайдалар иде?

Бу кыйсем халык Мәскәүнең мәктәбен, мәдрәсәсен, мәсҗеден, «Җәмгыяте хәйрия»сен алып баручы булганга, Мәскәүнең алга, артка баруы бу сыйныф халыкның тормышы, бәхете, сәүдәсе берлән баглы булганга, боларның мәсҗедләренең берсендә хазир булмаулары, була алмаулары күңелсез бер сызык сыза, бөтен бәйрәмгә тулмаганлык, китеклек куша иде. Бу кимчелекнең сәбәбе ни булса булсын, бу Мәскәүнең авызының чалыш йире иде.

Икенче көнне Мещанский мәхәлләсендә вә Ерзиннарның мәктәбендә[1] хатыннар өчен ясалган Мәүледен-нәбине укулар вә кич берлән Әсәдуллаев мәктәбендә[2] балалар кичәсе ясаулар Мәскәү

мөселманнарының йөзләрен агартачак вакытлар булды. Хатыннар шул олуг бәйрәмдә үзләренең рухларын дини хис берлән яңарта алдылар. Алар шул көндә олуг пәйгамбәремезнең җәнабенә башларын иеп сыгына белделәр. Балалар шул көндә тагы зуррак бәйрәм итә алдылар. Алар шул көннең хөрмәтендә гомерләренә күрмәгән балалар кичәсене күрделәр. Шул газиз көннең хөрмәтенә аларның бае, ярлысы, зирәге, аңгырасы бергә-бергә бертигез булдылар. Бергә шигырьләр әйттеләр, бергә мөнәҗәтлар укыдылар. Бергә сөенделәр, шатландылар. Бу мәнзарә Мәскәүдәге Мәүлед бәйрәменең иң матур, иң күңелле мәнзарәсене тәшкил итә иде. Димәк, Мәскәүнең картлары мәсҗедләрдә булындылар, даимән зикер, салават берлән бәйрәмгә кушылдылар. Мәскәүнең хатыннары мәктәпләргә җыелдылар, алар да Мәүледен-нәби тыңладылар, укыдылар. Балалар гөрләп-шаулап бәйрәм иттеләр. Урта халык, сәүдәгәр сыйныфы нишләде?

Болар кая бәйрәм итте, ничек бәйрәмгә кушылды? Бәлки, хосусый өйләрдә Мәүледне каршы алу булгандыр. Бәлки, бер-бер хосусый өйдә Мәүлед укылгандыр. Хәер, улсы да булмады. Хосусый бер өйдә бәйрәм каршылау булса да, монда да җыелган халык студент, курсистка, мөгаллимә, мөгаллим иде. Башка ике сәүдәгәр булса да, болар да иттифакый гына тугры килгән иде. Димәк, шул көндә Мәскәү мөселманнарының иң эшлекле, иң зур бер сыйныфы үги бала кебек читтә калган иде. Дөрест, бу читтә калуның сәбәпләре юк түгел. Болар һәммәсе дә мулла сайлау мәсьәләсенең озаюы, сузылуының нәтиҗәләре. Болар һәммәсе дә муллалар берлә мәхәллә арасында аңлашылмауның тудырган җимешләре иде. Ләкин тәмсез җимешләре иде. Мәскәүнең «Җәмгыяте хәйрия»се дә бәйрәмдә үзен матур иттереп күрсәтә алмады. Бәлки, ул, хатын-кыз җәмгыяте балалар кичәсе ясагач та, вазифамыз бетте дип белгәндер, бәлки, башкачадыр. Аны тикшерү безнең эшемез түгел, ләкин «Җәмгыяте хәйрия» үзенең әгъзаларына кечкенә генә бер Мәүлед көне ясаган булса, догага мохтаҗ шул елда, шул көндә бик күп агай-энемезгә дини хиснең артуына, күңелләр йомшаруына зур хезмәт эшләгән булыр иде. Монда да ни булса да булды, шул китеклек хисе калды.

Менә болар барысы да — бәйрәм көзгесенең күрсәткән авыз чалышлыкларымыздыр. Иншалла, бу чалышлыклар безнең туганнан килгән кимчелекемез түгелдер. Иншалла, бу чалышлыклар кичә «тирес яткан»нан килгән чалышлык кына булып, көн үтү, вакыт кичү берлән төзәлә торган вакытлы хасталык кынадыр. Иншалла, болай түгеллеген без киләсе елга исбат та итә алырмыз, иншалла. Ләкин бу елгы авыз чалышлыкымызны көзге янышнан үткәндә дә күрмәенчә китә алмыймыз. «Авызың чалыш булгач, көзгегә үпкәләмә» дигән сүз дөрест булса да, шул көзгегә үпкәләми дә булдыра алмыймыз.

## ДУМА АЧЫЛДЫ

Сугыш башлангач та, патша хәзрәтләренең әмере буенча июль числосында[1] Дума, җыелып, хөкүмәтнең керткән бөтен ляихәләрен кабул итеп, бер генә мәртәбә мәҗлес ясап, 27 гыйнварга кадәр ябылган иде. Шул билгеләнгән көн җитә башлагач, Думаның комиссияләре эшкә тотындылар. Хосусән бюджет комиссиясе 1915 елгы бөтен росписен карап, Думаның мәҗлесенә хазир итеп куйды. Бюджет комиссияләре элгәреге елларда иң әһәмиятле комиссия булса да, алдан һәрвакытта министрлар вә аларның иптәшләре хазир булып, үз министрлыгы керткән ляихәләрен бәян итү, аларны мөдафәга итү гадәт булып киткән булса да, бу ел комиссиянең эше бигрәк зур булды, һәр көнне бөтен фракцияләрнең кешеләре тәдкыйкларын сөйләделәр. Һәр көн төрле-төрле министрлар җаваплар бирделәр, бәяннар ясадылар. Вә һәр мәсьәлә хакында мәгълүм бер фикергә киленеп, бюджетны хәзерләп җиткерделәр.

Думаның бу җыелышы да дүрт-биш көн генә дәвам итәчәк булганга, мәҗлестә фәлсәфә сатып утырырга вакыт булмаячак, шуның өчен һәр партия үзенең әйтеп калачак сүзен әйтер өчен фракцияләрнең вәкилләре берлән Дума президиумы арасында килешү булды вә һәр фракция бер-ике генә хатиб чыгарырга разый булды.

Алты айлык Думасыз торган чакта, Русия тормышында, әлбәттә, әйтеләчәк бик күп сүз җыелгандыр. Сөйләнәчәк, хөкүмәтнең дикъкатен җәлеп иттерәчәк бик күп яңгы эшләр тугандыр. Шөбһәсез, кыска-кыска гына булса да, Дума әгъзалары боларга тиеп-тиеп китәрләр вә хөкүмәт әрбабының дикъкатен җәлеп итәрләр. Кичерә торган айларымыз, көннәремез фәүкылгадә айлар, көннәр булганга, шөбһәсез, хөкүмәтнең дә халык вәкилләре берлән сөйләшәчәк, киңәш итешәчәк мәсьәләләре күбәйгәндер.

Сугыш тудырган кирәк-яраклары бик күп булганга, хөкүмәтнең дә халык вәкилләре берлән бергә-бергә эшли торган эшләренең исәбе-саны бик арткандыр.

Безнең мөселман депутатларымыз, моңганчы кадәр комиссия мәҗлесләрендә сөйләгәннәре мәгълүм булмаса да, әлбәттә, эшкә катышканнардыр. Алар да, әлбәттә, шул тансык мәҗлескә үзләренең милләтенең, сайлаган милләтенең теләгәнен әйтергә омтылып тора торганнардыр.

Безнең үземезгә генә [караган], безнең мөселман булуымыздан гына килгән мәсьәләләр дә иксез-чиксез күптер.

Боларның йөздән берсе, шөбһәсез, сугыш сафларына җитәрлек дәрәҗәдә имамнар күндерү вә мөселман гаскәрен башка гаскәрдән аерым күмү, юллар өчен тикшерү[2] [...] барысы да сугыш тудырган мәсьәләләр булганга, шөбһәсез, шул кыска мәҗлесләрдә каралырга вә хөкүмәткә шуларның әһәмиятләрен аңлатырга тиештер. Моннан да әһәмият ягыннан ким түгел — тагы яралы гаскәрләремезгә ярдәмне бер кулга, бер идарәгә китерү өчен бер җәмгыять, бер организация булдырырга тырышу вә шул организацияне мөселманлыкка тирес галәмәтләрдән саф итеп мәйданга чыгарырга иҗтиһад итүдер. Болар менә һәммәсе дә сугыш тудырган мәсьәләләр булганга вә болар аркасында, кирәк, хөкүмәткә вә кирәк, сугыштан зарарланганнарга, файдадан башка бер нәтиҗә булмаячак булганга, шуларны аңлату, урынында сөйләү — мөселман депутатларымызның вазифасы, ватаны, мәмләкәте, халкы алдындагы бурычыдыр.

Менә шуның өчен депутатларымыз, саннары никадәр аз булса да[3], үзләре егерме биш-утыз миллион халыкның вәкилләре икәнен онытмаенча хөкүмәт әрбабы вә Дума алдында шул мәсьәләләрне күрсәтсәләр, бик зур хезмәт иткән булырлар вә вазифаларыны үтәгән булырлар иде.

Сугышның күтәргән мәсьәләләренең икенчесе, безнең өчен шулай ук әһәмиятлесе — соңгы сугыш берлән бергә мәйданга килгән үз арамыздан инсафсыз адәмнәремезнең хөкүмәт алдында, ышанычлы халкымыз алдында игътибарлы кешеләремезне хөкүмәткә ят күрсәтер өчен бөтен милләт өстенә тап ябуларыдыр. Казанда мондый инсафсызлар шул дәрәҗә күбәйгән ки, Казанның гомерендә сәясәт берлән утрашмаган уңган сәүдәгәреннән Садыйк Галикәев, Сөләйман Аитов, Мөхәммәтҗан Кәримовларда вә үзенең иске фикерлелеге берлән мәшһүр Исмәгыйль Үтәмешевта ясалган тентүләр[4] инсафсыз доносчыларның ни дәрәҗәдә ялганчы икәнен күрсәтергә җитәчәктер. Бу мәсьәләдә, халкымыз арасыннан чыккан чүп-чарның сүзенә карап шундый игътибарлы сәүдәгәрләремезне борчу һәм дә ифтиралар берлән борчу, шөбһәсез, сугыш тудырган мәсьәлә булганга, депутатларымызның хөкүмәт әрбабы алдында шул эшнең асылын ачулары ляземдер.

Әдәпсез кешеләрнең «төреккә акча җыя» дигән сүзен хәзер бер кәсеп итеп, сату-алудагы конкурентлардан котылыр өчен яисә башка берәр төрле үч алу өчен коралланган доносларының хакыйкатене ачу ватан вә милләт файдасы ягыннан да фарыздыр. Югыйсә бу әдәпсез, инсафсыз адәмчекләр хөкүмәт берлән халкымыз арасында аңлашылмауларга сәбәп булу ихтималы булганга, никадәр элек аларның пәрдәләре ачылса, шулкадәр файдалы булачактыр.

Менә шул кечкенә-кечкенә эшләрне депутатларымыздан көтеп каламыз. Вә алар шул фәүкылгадә бервакытта үзләренең бурычларын үти алсалар иде, дип догада буламыз. Вакыт әһәмиятле икәнен аңлаган депутатларымыз, иншалла, шул әһәмиятле вакытның тудырган мәсьәләләре дә шул дәрәҗә зур, шул дәрәҗә кирәкле икәнен хәтерләреннән чыгармаенча, вазифаларының башында булырлар. Ватан, милләт алардан шуны көтә.

## КАРС МӨСЕЛМАННАРЫ

Карс тирәләрендә сугыш астында калган мөселман халкының хәле ни дәрәҗә авыр икәнлеге берничә мәртәбә гәзитәмездә язылган Карс губернаторының рәсми кәгазьләреннән мәгълүмдер.

Карс вилаятендәге мөселманнар сугыш астында калганга, боларның бик күбесенең өйләре, йортлары сугыштагы мәҗбүрият берлән ватылачагы табигый иде. Мондый вакыйга Польшада да булды. Киләчәк дошман гаскәренә сыгыначак урын калмасын өчен, чыккан йирдәге өйләр, биналарны вату бу сугышта гадәт хөкеменә керде. Шуның өчен бөтен Польшада, Галициядә әллә никадәр авыллар, шәһәрләр җимерелеп беткән кебек, сугыш астындагы Карс вилаятендәге авылларның да җимерелүе вә ватылуы ышанмаслык эш түгелдер. Ләкин бу сафта сугышка башка халыклар арасында да дошманлык булганга, мөселман халкыннан үч алу нияте берлән гөнаһсыз мөселманнарның үтерелүләре, йирле халыкның кораллы төркемнәре мөселман авылларын талаулары Карс губернаторының рәсми приказлары берлән мәгълүмдер. Менә шул хәлләр Кавказда, хосусән Карс, Батум вилаятьләрендә меңнәр, ун меңнәр мөселман гаиләләрен йортсыз-йирсез калдырды. Меңнәр, ун меңнәр балаларны атасыз-анасыз, арка таяначак ярдәмчесез калдырды. Шуның аркасында шул йирдәге мөселманнарда ачлык-мохтаҗлык чигенә җитте. Без дә гәзитәмездә шул мескиннәргә ярдәм тиешлеге хакында өч-дүрт номердан бирле яза килсәк тә, Казан, Оренбург гәзитәләре шуларга озын-озын мәкаләләр багышласалар да, мәгаттәәссеф, безнең Идел буе мөселманнарыннан шул ерактагы туган кардәшләренә, ерактагы бәхетсез мөселман агай-энеләренә ярдәм кулы сузылганы күрелмәде, ишетелмәде. Мәгаттәәссеф, бу көнгә кадәр Мәскәүдә шул хакта бертөрле дә тәшәббес булмады. Бәлки, халыкның бер кыйсеме хөкүмәткә хилаф эш булмасын дип шөбһәләнгәннәрдер. Бәлки, бер кыйсеме арамыздагы иксез-чиксез әдәпсез доносчыларга тагы бер доноска материал бирү булмасын дип курыкканнардыр. Бу мәсьәлә Русиянең эчендәге, Русиянең үз тәбәгасы Русиянең шул зур сугышына ярты миллионнан артык гаскәре берлән кушылган Русия мөселманнары хакында булганга,

һичбер куркынылачак урын юктыр. Болар һәммәсе дә законлы эшләр вә хөкүмәтнең үзенең зур түрәләренең (Карс губернаторының мөселманнарга телеграмнары) үтенүе буенча башланган эшләр. Аңгарга башка Кавказ мөселманнарыннан, бакулы, ганҗәле, иранлы мөселманнар, Тифлискә һәйәтләр күндереп, рәсми тарызда ярдәм җыярга рөхсәт тә алганнардыр. Бакуның «Җәмгыяте хәйрия»сендә иганә дәфтәре дә ачып эшкә керешкәннәрдер. Шуның өчен бу изге эштә һәр мөселман шәһәрнең мөмкин кадәр ярдәмгә килүе тиеш булган кебек, мөселманнарның «Җәмгыяте хәйрия»ләренең дә сәерче булып калмаулары ляземдер. Әлбәттә, һәр йирдә дә мөселман үзенең кардәшләре алдындагы шул бурычын үтәүдән тартынмаган кебек, һәр йирдәге мөселман җәмәгать хадимнәре дә шәһәрләрдәге, авыллардагы «Җәмгыяте хәйрия»ләре дә шул изге эшкә ярдәмгә катыштырырга тырышачактыр. Бу шулай булырга тиештер. Һәм шулай булачактыр. Ләкин кирәк, җәмгыятьләрнең мәҗлесләреннән шул мәсьәләне үткәрер өчен, кирәк, акча җыеп җибәрер өчен шактый вакыт үтәчәк булганга, без үз тарафымыздан Петроградтагы бөтен «Җәмгыяте хәйрия»ләр җыелышының сайлап калдырган комитетына шул мәсьәләдә зур бер бурыч йөкләмәкче буламыз. Комитетның кулында шактый гына зур акчалар булырга кирәк. Хәзердә кулында булмаса да, ышанычлы кулларда булырга кирәк. Шул суммадан комитет, үзеннән-үзе генә хәл итеп, биш-ун мең сум гына ярдәм ясаса, бик урынлы бер эш эшләгән булыр иде, вә бөтен мөселман дөньясы матбугаты рәхмәт укып каршы алыр иде. Комитетның кулындагы акчалар Карс вилаятендәге зарарланганнар өчен җыелмаган булса да, шул сәдаканы бирүчеләр, иншалла, шул хәерле юлга тотуга ачуланмаслар вә эч күңелләреннән рәхмәт тә укырлар иде. Шуның өчен Петроградтагы комитеттан шул мәсьәләгә әһәмият берлән карап, шул эштә халыкның теләве берлән бергә-бергә булуларын бик үтенер идек.

Мәскәүгә килсәк, Мәскәү кебек ике «Җәмгыяте хәйрия»се, Мәскәү кебек берничә йөз яшь сәүдәгәре, Мәскәү кебек берничә йөз мөселман студенты, курсисткасы булган шәһәргә шул ачы күз яше алдында тик яту, шул ачлык-ялангачлык мәнзарәсе алдында сәерче булып тору — кичерелмәслек гөнаһтыр. Шуның өчен бөтен Мәскәү мөселманнарының тизрәк шәфкать кулын сузуларын көтәмез. Вә тизрәк шул мескиннәргә — бер локмә кабарга мохтаҗ булган мәзлум мөселманнарга ярдәмгә йитешерләр дип өмид итәмез вә бу изге эштә Мәскәүнең ханымнары да үзләренең хезмәтләрен, гайрәтләрен кызганмаслар дип ышанамыз. Вә шуларның йимешләрен күрүне ашыгып көтәмез.

**БЕЗНЕҢ ХӘЛЛӘР**

Тарих көпчәгенең әйләнүе алдымызда нинди генә мәсьәлә ачмасын, тормышымызның барышы алдымызда нинди генә милли, дини, мәдәни сөальләр куймасын, һәммәсенең дә җавабы бер замиргә кайта. Һәммәсенең дә милли бертөсле булып каплана.

Матбугатымыз, халкымыз алдында җәмгыятьләр съезды ясау мәсьәләсе килеп басты. Матбугат язды, халык укыды. Гакыллы башлар гакыл сатты. Шуннан соң һәммәсе дә үзенең вазифасын үтәде кебек хис итте дә башка эшкә тотынды. Матбугатка яңгы мәсьәләләр туды, укучыга яңгы сүзләр табылды, фәлсәфә сатып, сагыз чәйнәп йөрүчеләргә яңгы фаразлар башка килде. Җәмгыятьләрнең ясаган комитеты да зур лазарет ясарга карар чыгарды.

Шул озын хезмәттән соң бар да арыды да хәл җыярга тотынды. Татар тарихы тагы кечкенә генә иттереп көпчәген селкетте. Тагы берәр дини мәсьәлә — казыйлык мәсьәләсе туды. Тагы язылды, тагы укылды, тагы сөйләнде, тагы тыныш куелды, тагы «хәл җыю» башланды...

Татар тарихының тагы бер бите ачылды, канлы күз яшьле бер мәнзарә күренде. Русиянең бер читендәге туганнарымыз, кардәшләремез, диндәшләремез ач-ялангач, йортсыз-йирсез, мәзлум көенчә күз алдымызга басты. Тагы язарга керештек, тагы сөйләргә тотындык, тагы фәлсәфә чәйнәшергә башладык. Менә озакламас тагы шул куркынычлы мәнзарәне онытырмыз, тагы яңгы бер мәсьәлә туганча хәл җыярмыз. Тагы яңгы эш килеп чыккач та, «менә шул инде иң әһәмиятле мәсьәлә» дигән кебек каршы алырмыз. Тагы сагыз чәйнәрмез-чәйнәрмез дә, эчемез пошар да, туярмыз да ташлармыз. Тагы яңгы мәсьәләне, яңгы бер эшне күтәргә тотынырмыз. Тагы аңгарга ябырылып, бөтен көчемез, куәтемез берлән ябышырмыз да тагы ашап туйган үрдәк кебек яныннан борылып китәрмез. «Җәмгыяте хәйрия»ләр киңәшенең юлда калуы, казыйлык мәсьәләсенең бер нәтиҗәгә ирешмәенчә туктавы[1], Карс мөселманнары хәленең бертөрле адәм гакыллы юлга куела алмавы[2] — болар барысы да иттифакый гына бер эшләр түгел. Мәгаттәәссеф, болар менә шулай тугры килгәндә, менә шулай уңмаенча калган гына түгел. Болар — безнең бөтен эшемез, бөтен хәлемезнең килеше барышыннан туган табигый бетешләремез, бөтен уемыз, бөтен төшенчәмез, бөтен мантыйкымызның тудырган нәтиҗәләре, бөтен тирә-юнемездәге эшләремез, кыланышларымызның үстергән йимешләре. Шуның өчен бу бәхетсезлекләрдә бер тарафтан караганда беркем дә гаепле түгел.

Җәмәгать хадиме булган кеше гаепле түгел, чөнки аны мохите тиен кебек — бер агач башыннан икенче агач башына сикереп йөри торган иттереп тәрбия иткән; матбугат гаепле түгел, чөнки аны укучылар көннән-көн яңгы мәсьәләләр чыгарып торырга, яңгы ласкутлар сатарга мәҗбүр иткән, иске сагызны әле авызның бер ягына, әле бер ягына әйләндереп чәйнәргә өйрәнгән.

Укучы, уйлаучы, әфкяре гомумия гаепле түгел, чөнки аны милләт хадимнәремез, матбугатымыз эшкә җитди иттереп, эш итеп карарга өйрәтмәгән. Ул укучы алдында хәлфә, йитәкче була алмаган гына түгел, ул аның кәефен китәрер өчен, аның хөббе нәфесен кытыклар өчен клоунлык вазифасын иткән...

Беркемдә, бернидә гаеп юк. Һәммәсе үз урынында, үз вазифасында.

Икенче яктан караганда, һәммәсе гаепле: җәмәгать хадимнәре, матбугат, әфкяре гомумия, халык — һәммәсе гаепле һәм дә һичбер төрле кичерерлек түгел дәрәҗәдә гаепле. Җәмәгать хадимнәре үзләре үзләренең дәрәҗәләрен белмәгән өчен, үзләренең халык алдына куя торган мәсьәләләрен җитди иттереп аңлап бетмәенчә, үзләренең нишләргә теләгәннәрен күреп җитмәенчә эш башлаганнары өчен, үзләренең кая таба бара торган, кайдан килә торган юлларын белмәгән өчен гаепле. Үзләренең иптәшләре, юлдашлары кемнәр икәнен аера алмаган өчен уңга, сулга борылганда чикләре кая икәнен кистерә алмаган өчен, үзләренең дөрест дигәннәрендә нык торырлык иманнары булмаган өчен гаепле. Алар мәсләкләре юклыкта гаепле. Матбугат үзенең вазифасы йитәкче булуда икәнен белмәгән өчен, үзенең бурычы халыкның алдыннан мәдәният нуры күрсәтеп бару икәнен белмәгән өчен, үзенең бурычы җил кайдан килсә, шунда аумаенча, туп-тугры иттереп алган кыйбланамәсе берлән бармаган өчен гаепле. Үзенең гайбәтче карчык түгел икәнен аңламаенча, үзенең эшсезләрне җуатыр өчен уенчык түгел икәнен аңламавы өчен гаепле, төпсезлектә, мәсләксезлектә гаепле.

Әфкяре гомумия үзенең бурычы җәмәгать хадимнәренең вә матбугатның алып бара торган эшендә койрык булып, аны боручы икәнен белмәүдә, яхшы берлән начарны, файдалы берлән зарарлыны аерырлык дәрәҗәгә җитмәүдә гаепле.

Әфкяре гомумия шарлатан берлән чын хезмәтчене, лыгырдау берлән чын сүзне, җил иләү берлән чын эшне аермауда гаепле.

Халык шул эшләргә тамга сала белмәүдә үзенең вөҗдан тавышын шул кешеләргә тәэсир иттерә алмауда гаепле.

Менә шуның өчен, менә шул бөтен иҗтимагый, мәдәни, милли, дини гамилләремез һәммәсе дә зәһәрләнгән өчен, без нинди генә эш башласак та очлый алмыймыз. Нинди генә фикерне мәйданга суксак та, аның бисмиллясыннан үтә алмыймыз. Нинди генә план корсак та, шуның нигезен корыр өчен иске бинаны ватудан уза алмыймыз. Һәм дә уза да алмаячакмыз... Шуның өчен киләчәктә тарих көпчәкләре әйләнгәндә тагы шул лыгырдап калмас өчен, тагы шул тиен кебек бер мәсьәләдән сикереп, икенчесенә кунып йөремәс өчен бөтен мәдәни, милли хәрәкәтнең үзәген пакьләргә, сафларга тиештер.

Бөтен мәдәни эшләремезнең нигезен үзгәртеп, төплелек, җитдилек, мәсләклелек ташларына бинаны куярга тиештер. Һәм дә һичбер вакыт әрәм итмәенчә эшләргә тиештер. Юл бер генәдер. Юл шул гынадыр. Шуннан башка юл да юктыр. Шуннан башка эш тә мөмкин түгелдер. Шуның өчен тарихның зур имтиханнары алдында торганымызны хәтерләп, тарихның алдында бер милләт булып яшәргә хакымыз бармы-юкмы, имтиханына керергә вакыт җитәчәкен уйлап, тәһарәткә керешергә тиештер.

Тәяммем берлән башларга ярамаганын белеп, алдан тәһарәтләнергә, казасы, кәффарәте булмаячагын аңлап, вакытында акланырга, пакьләнергә тиештер.

## МӘСКӘҮ, 8 ФЕВРАЛЬ

Бүген Мәскәү «Җәмгыяте хәйрия»сенең еллык җыелышы булачактыр. Бүгенге мәҗлестә Мәскәү «Җәмгыяте хәйрия»сенең идарәсе (правлениесе) үткән елда булган эшләр хакында үзен сайлаган кешеләр алдында хисап тотачак, бу көн «Җәмгыяте хәйрия»нең әгъзалары киләчәк ел өчен нинди изге эшләр эшләү тиешлеге хакында бер-берсе берлән сөйләшәчәк, бер-берсе берлән киңәш итешәчәктер. Бүген Мәскәү мөселман «Җәмгыяте хәйрия»сенең әгъзалары киләчәк елда эшләнеләчәк вә эшләнергә тиеш булган изге эшләрен берәм-берәм санап, шуларны тотарга идарәгә әмер бирәчәктер. Бу көн үк шул әгъзалар үзләре теләгән хәер эшләрне эшләр өчен, кемнең кулыннан киләчәген төшенеп, шул җәмәгать бурычын үтәр өчен идарәгә алты әгъза да сайлаячактыр. Киләсе елда «Җәмгыяте хәйрия»нең эшләячәк эшләре һәммәсе дә бу көнге җыелышның карары берлән генә эшләнәчәк булганга, бу көнге җыелышымызның «Җәмгыяте хәйрия»нең эшләве-эшләмәве, файдалы юлдан баруы-бармавы өчен бик зур әһәмияте бар. «Җәмгыяте хәйрия»нең киләчәк елдагы бөтен эшләре өчен мәсьүл бу көнге җыелыштагы әгъзалар булганга, алар алдында бик зур җәмәгать бурычы торадыр. Изгелек җәмгыятенең бөтен эше изгелек юлында булган

кебек, анда хезмәт итүчеләр дә һәммәсе дә савап өчен генә эшләгәнгә, идарә әгъзаларымызны сайлаганда, мөмкин кадәр шул савапны күбрәк итәргә тырышучыларга вә үземезнең мөселман җәмәгатемезгә күбрәк ярдәмгә ашыгырга торучыларга күзне сала төшәргә тиештер. Җәмәгать хезмәтене фи сәбил Алла армый-талмый эшләргә хәзерләрне сайларга тиештер. Шөбһәсез, сайлау вакытында һәр әгъза үзенең вөҗданы алдында мәсъүл икәнен хәтереннән чыгармаенча, кодалык-кодагыйлык, дустлыкны, дошманлыкны онытып, җәмәгать хезмәте ягыннан гына карап шарга сузылырга тиештер. Иншалла, «Җәмгыяте хәйрия» әгъзалары кирәк, шул киләсе елның эшләячәк эшләрен уйлашканда вә кирәк, шул эшләрне эшләп дөньяга чыгаручыларны сайлаганда, үзләренең аңлы, белемле икәнлекләрен вә җәмәгать эшенең кая таба барырга тиеш икәнен күреп торганнарны күрсәтерләр.

Мәскәү «Җәмгыяте хәйрия»сенең башлануына шактый күп вакыт үткән булса да, әле бит җәмгыятьнең эшкә башлавы бик яңгыдыр. Шуның өчен аның бу көнгә кадәр иткән хезмәтләре никадәр кирәкле вә зур булса, киләчәктәге хезмәтләре тагы киңрәк, тагы зуррак булуы тиештер. Бу көнге көндә «Җәмгыяте хәйрия» бер мәктәп, бер кыйраәтханә, бер лазарет тәрбия итеп килә. Ул Мәскәүдәге фәкыйрь мөселманнарның күмелүләренә, аларның көн кичерүләренә зур ярдәм итә. Болар һәммәсе дә бик зур һәм дә бик кирәкле эшләрдер. Үлгән фәкыйрь мөселманны күмү бөтен Мәскәү мөселманы өстенә фарыз булган кебек, фәкыйрь картлар, карчыкларга ярдәм итү дә — боларның бурычыдыр. Болар һәммәсе дә изге эшләр, саваплы эшләрдер. Ләкин киләчәк елның эшләре эчендә без үз тарафымыздан тагы да саваплы эшләрне күбәйтүне мәслихәт табамыз.

Мәскәүдә егерме-утыз мең мөселман бар. Мәскәү зур булганга, болар шәһәрнең төрле почмагына таралганнар. Боларның фәкыйрьрәкләре, көнлек хезмәт берлән яши торганнары балаларын-чагаларын ерак йирләргә мәктәпкә җибәреп йөртә алмыйлар, киемнәре булмый. Вагон вә трамвайга акчалары җитми, шуның өчен бу мөселман балаларының бик күбесе үзенең укый торган газиз бала вакытыны урамда уздыра. Дин, диният, әдәп вә инсаф өйрәнә алмый. Русларның урам малайлары берлән бергә булып, алардан үрнәк алып, бозылып чыга. Болар бер генә, ун гына булмаганга, боларның саннары көннән-көн артып торганга, «Җәмгыяте хәйрия» эшче мөселманнар күп йирләргә кечкенә-кечкенә генә мәктәпләр ачса иде. Безнең мөселман агай-эне никадәр фәкыйрь булса да, баласын-чагасын укытырга омтылып торганга, шөбһәсез, «Җәмгыяте хәйрия»гә шул тирәдәге йирле мөселманнар һәрвакыт ярдәмгә килер иде. Вә «Җәмгыяте хәйрия» кечкенә-кечкенә генә сумалар берлән елына өч-дүрт йөз сум акча чыгарып, йөзәр мөселман баласыны дини әдәп өйрәтеп, бик зур хезмәт иткән булыр иде. «Җәмгыяте хәйрия»нең ачылуыннан максуд мөселман халкының мәгънәви ихтыяҗларына ярдәмгә йитешү булганга, җәмгыять әгъзалары шул изге эшкә чын ихласлары берлән тырышсалар иде.

Икенче теләвемез — «Җәмгыяте хәйрия»нең үткән елгы мәҗлесендә һөнәр мәктәбе ачу хакында бер карар чыгарылган вә шуңгарга каратып шактый зур гына сума да билгеләнгән икән. «Җәмгыяте хәйрия»нең идарәсе, сугыш булу сәбәпле, шул карарны дөньяга тудыра алмады вә шуның өчен шул суманы җәмгыятьнең фәүкылгадә җыелышында пансион ачарга тотарга рөхсәт бирде. Мәскәү кебек эшче мөселман күп йирдә мөселман балаларының һөнәргә өйрәнүе, өйрәтелүе, шөбһәсез, бик кирәкле эштер. Саваплы булуга башка бөтен мөселман халкы өчен файдалыдыр. Шуның өчен җәмгыять шул һөнәр мәктәбе мәсьәләсен дә яңадан кабартып, шуны эшләүне дә ашыктырса иде.

Өченче — җәмгыятьнең чыгышлары арасында укучыларымызга (ибтидаи мәктәпләрдәге фәкыйрь балаларга башка) ярдәм маддәсе бөтенләй юк. Бәлки, Мәскәүдә укый торган төрле мәктәпләрдәге мөселман шәкертләремез, мөселман студентлар, курсисткалары бик байлардыр, һичбер төрле ярдәмгә мохтаҗ түгелдер, алай булса, шатланудан бүтән эш калмый. Фәкать мохтаҗларына бирмәү гадәт ителгән булса, шөбһәсез, «Җәмгыяте хәйрия»нең зур кимчелегедер. Мәскәү кебек тормыш кыйммәт шәһәрдә урта сыйныф халыктан чыккан шул укучыларымыз ярдәмгә мохтаҗ булулары бик табигыйдер.

Петроград «Җәмгыяте хәйрия»се шул укучыларның уку хакын түләүгә һәр елны берничә мең сум акча сарыф итә. Оренбургта укучыларга «Ярдәм җәмгыяте» дигән аерым бер җәмгыять эш күрә. Бөтен шәһәрләрнең «Җәмгыяте хәйрия»ләре шул юлда бик күп мәсъраф тота.

Мәскәүнең генә шуннан аерылып калуы, шөбһәсез, гайре табигый бер эш булганга, төзәтелергә, ислях ителергә тиештер.

Ахырдан, җәмгыятьнең әгъзалары шул мәҗлестәге сүзләр, планнарга өстән генә карамаенча, шуларны тикшерүне үзләренең милли бурычы санап һәрбер эшкә тавыш биргәндә, аңлап бирергә тырышса, вә бер фикергә кушылганда, каршы торганда, вөҗданнарының кушуына карап кына хәрәкәт итсәләр иде. Мәскәү өчен шул зур эштә, әлбәттә, Мәскәүнең могтәбәр мөселманнары барысы да хәзер булырлар дип ышанганга, аларны «килсәңез лә» дип чакырып торуны үзләре өчен түбәнчелеккә санаганга, шул могтәбәр әфәнделәрдән чын ихлас берлән эшләүләрен генә үтенәмез.

## МӨСЕЛМАННАРНЫҢ ХӘЛЕ ВӘ ДЕПУТАТЛАРЫМЫЗ

Петроград гәзитәләрендә Кавказның грузин депутатларыннан Чихәнкилинең[1] хәрбия министры[2] берлән Кавказдагы сугыштан җәберләнгән мөселманнар хакында мөзакәрә итүе язылды. Бу көнге «Русское слово»дан шул ук грузин депутат әфәнденең шул ук мөселманнарның җәберләнүе хакында баш министр Горемыкин[3] җәнаблары берлән мосахәбәсе, баш министрның шул эшкә дикъкать берлән карап, Чихәнкили җәнабларына шул мөселманнарның җәберләнүе хакында гаскәри мәэмүрләргә аерым доклад ясавын тәүсыя иткәне гәзитәмезнең хәбәр кыйсемендә бар[4]. Хәрбия министры да шул эшкә дикъкать итәчәген вә үзенең кул астындагы түрәләренә көчләүләргә юл калдырмау хакында әмер бирәчәген сөйләгән. Кирәк, хәрбия министрыбызның вә кирәк, баш министр Горемыкин җәнабларының шул мескин мөселманнарның хәлләренә дикъкать итүләре, әлбәттә, нәтиҗәсез калмаячактыр. Кавказда сугыш астындагы йирләрдә мөселманнарны көчләүне бетерәчәктер. Ләкин мәсьәләнең икенче бер тарафы бар. Ник шул мөселманнарның җәберләнүе хакында Чихәнкили министрларга барып, шул мөселманнарны яклап йөри? Ник шул эшне безнең Петроградтагы мөселман депутатларымыз эшләми? Ник шул йитмеш-сиксән авыл мөселманнарының зарларын алар ишетеп, хөкүмәт даирәләренә йиткезми?

Әллә шул мәгълүматны безнең мөселман депутатлары җыя алмаганнар да, депутат Чихәнкили генә җыя алганмы? Мәгаттәәссеф итә аламыз, Кавказ мөселманнарының зарарлануы хакында мәгълүматлары бар кешеләр элгәре Петроградта мөселман депутатларына мөрәҗәгать иткәннәр, алардан җүнле сүз, өмидле эш күрмәгәч, Чихәнкилигә киткәннәр. Чихәнкили безнең мөселман депутатларымыздан мөселманракмы, ул әллә безнең мөселман депутатлардан инсанлыракмы? Анысы безгә мәгълүм түгел. Ләкин бөтен Русия мөселманнары Чихәнкили җәнабларының шул хезмәтенә чын күңелдән рәхмәт әйтәчәктер, әйтергә тиештер.

Бу бер мәсьәлә. Икенче бер мәсьәлә: Батумда мөселманнар Грузия экзархына мөрәҗәгать итеп, үзләренә химая итүләрен телиләр... (Гәзитәмезнең 71 нче номерында хәбәр кыйсемендә бар[5].) Аның олуг дәрәҗәсенә сыгыналар. Экзарх җәнаблары да кабул итә. Мөселманнарны химаясенә ала. Соң, грузиннарга караганда биш мәртәбә артык булган Кавказ мөселманы мөфтисе шәйхелисламы юкмыни? Ник ул мөселманнар, үзләренең рухани башлыкларыннан баш тартып, грузин экзархына сыгыналар?

Ник Кавказ мөселманнарының начар хәлләрене хөкүмәт даирәләренә белгертергә теләгән кешеләр, безнең үз депутатларымыздан, үз җир мөселманнарымыздан читкә китеп, грузин депутатыннан үтенәләр? Боларның арасында гам бер сәбәп юкмы? Булса, ул кая?

Бу бит беренче мәсьәлә түгел. Үткән елны бөтен фракцияне читтә калдырып, Дагъстан мөселманнары националист Ковалевскийга мөрәҗәгать иткәннәр[6] вә ул аларның хакларын сакларга тырышкан өчен, шул мескин мөселманнар рус депутатына үзләре алдында иң кыйммәтле булган Коръән газыймны бүләк итеп биргәннәр иде.

Бу ел шул Карс мәсьәләсе әллә кайчан язылса да, «Вольный экономический общество»да[7] шул хакта тагы ук рус депутаты Соколов җәнаблары бик озын доклад укыса да, ник соң безнекеләр шуңгарга әһәмият бирмәгәннәр иде. Хәзер ник бирмиләр? Моның җавабы кайда? Кемдә?

## БУ КӨННЕҢ БУРЫЧЛАРЫ

Карс мөселманнарының хәлләре бөтен Русия мөселманнарының күзләре алдына зур-зур мәсьәләләр бастырды. Боларның иң беренчесе — Русиядәге мөселманнар никадәр күп булсалар да, Русиядәге мөселманнар һәрвакытта, без утыз миллионлы халык, без Швейцария, Голландия, Бельгиянең өчесенең халкыннан да зур бер милләт, Норвегия, Швейцария, Даниянең өстенә Финляндияне кушканда да безнең санымызга җитә алмыйлар диеп мактанып йөрсәләр дә, шул утыз миллионлы халыкның үзенә мөнасиб бер куәи мәгънәвиясе юклыгы исбат ителде. Шул тавышлар, шул сүзләрнең бушбугазлык кына икәнлеге ап-ачык күренде. Бер миллионга саны җитмәгән Русия әрмәни халкы Төркия, Ираннан качкан йөз меңәр әрмәнлеләрне химая итәргә, ашатырга-эчертергә куәтләре җиткәндә, бер миллионлы грузин халкы үзенең эчке эшеннән бушаган куәтен безгә, мөселманнарга, өмәгә биреп торганда (Чихәнкилинең министрлар берлә мөзакәрәсе, Грузия экзархының мөселманнарны химаясе), без, утыз миллионлы мөселманнар — сугыш сафына алты йөз, җиде йөз мең гаскәр чыгарган мөселманнар, бер эш эшли алмадык, арамызда утызар-кырыгар миллионлы капиталистларымыз[1] булдыгы хәлдә, меңнәр, йөз меңнәр урта

дәрәҗәдәге сәүдәгәрләремез[2] бөтен Русияне туйдырдыгы хәлдә, без җәберләнгән, золым ителгән җитмеш-сиксән мөселман авылларына гына да ярдәмгә җитешә алмадык. Бу — бер.

Халкымызның күңелендә шул мескин көчләтелгәннәргә каршы зур шәфкать кайнаса да, милләтнең теләген бергә җыеп, бергә укмаштырып чыгарырлык куәтемез, көчемез булмады. Зыялыларымыз, алдагыларымыз шул зур милләтнең, шул зур халыкның иксез-чиксез шәфкатеннән бер ярдәм сандыгы да ясый алмады. Бу — икенче. Бу кимчелек — зыялыларымызның, алдынгыларымызның кимчелеге һәм дә гафу кылынмаслык кимчелеге. Сугыш башланганга алты ай үтте. Карс вакыйгасы чыкканга өченче ай китте. Без һаман бер хәрәкәт ясый алмадык. Меңәр-меңәр Карс мөселманнары ачлыкта, мохтаҗлыкта калды[3][...].

Дөрест, һәр шәһәрнең олугысы-кечесе күлмәк-ыштан тегәргә кереште. Олугысы-кечесе бер-ике пар күлмәк хәзерләү берлән милләте, ватаны алдындагы бурычы тәмам булды дип ышанды. Кайгы артты, ярдәм урыннары күбәйде. Нишләргә белмәс дәрәҗәгә җитте. Менә шул вакытта Петербургтагы җәмгыятьләр съездының[4] кабул иткән уставы хөкүмәт тарафыннан тасдыйк ителде. Ягъни җәрәхәтлеләргә, сугыштан зарар күргәннәргә ярдәмне бергә укмашырга, бергә җыярга, ул таркау эшне бергә алып барырга рөхсәт бирелде. Бирелде генә түгел, һәр йирдә, һәр авылда, шәһәрдә рәсми ярдәм җәмгыятьләре ясар өчен йирле мәэмүрләрдән рөхсәт кирәкмәгәне белдерелде. Инде эшләргә калды. Хәзерге көннең беренче вазифасы һәр йирдә ярдәм комитетлары ясап эшкә тотыну вә һәм дә шул ярдәмне элек ихтыяҗымыз күп йиргә тоту, иң каты булган авыруымызны даруларга сарыф итүдер.

Төрле шәһәрдәге йирле халыкның вазифасы шул ярдәм комитетлары ясау-эшләү булса, матбугатның вазифасы — шул эшне кая таба бору юлларын эзләү вә нинди авыруларымыз, хасталарымызның даруга, дәвалауга иң мохтаҗ урыннарын күрсәтүдер.

Петербургтагы комитетымызның[5] вазифасы — шуларның тавышыны ишетеп, халыкның теләвене фәгалияткә чыгарудыр.

Безнеңчә, иң беренче бурычымыз — хәзер шул сугыштан зарарланганнарга ярдәмне бер кулга алып, шуны зурлыгымызга мөнасиб дәрәҗәдә киң иттереп һәм дә андагы ихтыяҗга карап эш итүдер.

Карс вилаятендә җимерелгән йитмеш-сиксән авылда ятим балалар, тол хатыннарның саннары бик зурдыр. Боларның карга басып, суыкка катып үлмәгәннәрене тәрбия итү, шул мескиннәргә елы йирдә ашаячак икмәк бирү — мөселманнарның бурычы вә вазифасыдыр. Дини, милли ватаны вазифасыдыр.

Шуның өчен андагы фәкыйрь, мохтаҗ ятимнәрне йирләштерү, урынлаштыру Петроград комитетының беренче эше булырга тиештер. Шундагы ихтыяҗны белер өчен Петроград комитеты, беренче уларак, акчалар, әйберләр берлән бер һәйәт күндерергә вә шул һәйәт арасына мөселман депутатларымыздан берничә кешенең керүе, мотлакан, ляземдер, тиештер. Шуның өчен Петроградтагы комитет, вакыт үткәрмәенчә, шул эшне булдырыр өчен фракциямез берлән мөзакәрәгә керергә тиештер. Фракциямез дә, шул эшкә зур әһәмият биреп, комитетның теләвен, халкымызның теләвен булдырырга ашыгырга тиештер. Бу көнге комитетның бурычы — менә шул һәйәтне тәшкил итүдер. Фракциямезнең бу көнге бурычы — ул һәйәтнең эчендә булуны үз вазифасы икәнен белеп, шуның уртасында булудыр. Халкымызның вазифасы — шул эш Петроградтан ясалып, тәэсис ителеп җитсә, ярдәмгә кул сузудыр.

## ҖАВАПЛАРЫМ

Язуларыма хәтере калган әфәнделәрнең тәнкыйтьләренә җавап язу гадәтем булмаганга күрә, «Вакыт» гәзитәсендә чыккан Ибраһим абзый Акчурин җәнабларының «Исмәгыйль бәк вә Зөһрә ханым Гаспринскийлар» дигән фельетоннарыма[1] ачык хатын[2] җавапсыз калдырган булсам да, «Сөембикә»нең 7 нче номерында шул ук мәсьәләне Мәхбүбҗамал ханым Акчурина кузгатканга[3], җаваплашырга мәҗбүрият хис иттем.

«Исмәгыйль бәк вә Зөһрә ханым Гаспринский» исеме берлән язган фельетоннарым берничә кешенең кәефенә китмәячәге мәгълүм булса да, бүгенге көндә һәммәбезнең иң кадерле хиссиятемез берлән сөелгән каһарманнарымызның тормыш юлында нинди мәгънәсез, кирәксез уңайсызлыклар күргәнлекләрен язмаенча китә алмадым. Вә шул ике мөхтәрәм затның мөнәсәбәтләре хакында, аларның юлларына сугылган киртәләр, золымнар ясау хакында күзсез булып үтә алмадым. Хакыйкать ни булса — шуны яздым. Ямьсез буяуларын сыегайтыбрак шул ямьсезлекне ясау, шул ике олугымызга каршы җинаять кылуда иштиракь иткән кешеләрне кызганыбрак, өстәнрәк киттем. Шуның өчен киләчәктә бу ике затның тәрҗемәи хәлләренең тәфсыйлатын язарга теләүчеләрдән минем шул фельетоннарымда авыр мәнзарәләрнең калдырылганын белдереп китәм вә, дөресене белү тиеш булса, шул ямьсез эшләрне мәйданга чыгару кирәклеге табылса, шуның тәфсыйлатын Зөябашы[4] тирәсендәге вакыйгада иштиракь

итмәгән кешеләрдән, Гаспринскийны кыйнатыр өчен фабриканың свистогын бирдереп, эшчеләрне җыймаган даирәләрдән эзләүне вә шул вакыйгаларның җанлы шаһиды булып калган, бүгенге көндә исән, тешсез Гайнүш абыстайны онытмауларын тәүсыя итәм.

Җыйган мәгълүматым, алган фактларыма киленсә, фельетоннарымда язылган бөтен вакыйгалар, фактлар иң вагыннан алып иң кечкенәсенә кадәр тугрыдыр, дөрестер. Боларның әсасларында, нигезләрендә, төпләрендә һичбер төрле хыял-мыял юктыр. Вакыйгаларның айларында, көннәрендә аерым ачык әйтә алмаган урыннарым булса да, боларның һичберсе минем төп фикеремне үзгәртерлек, фельетоннарымның үзәген бозарлык түгелдер. Мәсәлән, Ибраһим абзый Акчурин минем фельетоннарымнан «Гаспринский, 1881 елда Ибраһим абзыйны табып, мәсьәләне аңлата» дигән җөмләнең уртасына, «табып» дигән сүзгә бер зур сөаль галәмәте куя да: «Бу бөтенләй ялгыш, Мәкәрҗәдә Гаспринский бу турыда минем берлән бер сүз сөйләмәде», — ди вә шулар артыннан ук үзе: «Мәкәрҗәдән борынмы яки соңмы Исмәгыйль бәк миңа үзенең Зөһрәне соравын сөйләсә дә, аның ул уена минем иштиракь итүем-итмәвем Гаяз әфәнде Исхакыйга һәм «бик якыннан күргән кеше»гә мәҗһүлдер», — ди. Димәк, мин Мәкәрҗәдә диюемдә хата иткән булу ихтималым бар икән. Гаспринскийның Ибраһим абзыйга шул сүзне Мәкәрҗәдә түгел, Нижний ягында сөйләве яисә Мәкәрҗәдә булса, флаг күтәрелмәс борын яисә флаг төшкәч булу ихтималы бар икән. Ләкин соң шул эш вакыйганы үзгәртәме? Әсасны бетерәме?

Зөһрә ханымның кыланышы-йөреше, киеме-салымы хакындагы сүзләрем һәммәсе дә аның якыннарыннан алынган, тәдкыйк ителгән тугры сүзләр, дөрес уйлардыр. Шуның өчен, Мәхбүбҗамал ханым Акчуринаның «Сөембикә» журналындагы «Зөһрә ханымның кечкенә кыз чагыннан алып буй кыз булган вакытына кадәр аның кием-салымына бик әһәмият бирелә. Туташлар зарафәт ягына мәел итсәләр дә , мөхтәрәм язучы әфәндегә әйләнеп-тулганып, тагы шул ук кием-салым илә баш ватуы охшап җитми» дигән, миңа биргән дәресе өчен рәхмәт әйтсәм дә, «фәзаилешшөһүр»че[5] абыстайларга ярар өчен «Зөһрә ханым* аягына ак киез ката кия иде, чәчләре сүтелгән, тузылган, балагы салынган, өстенә алачадан күлмәк кебек иттереп бер капчык кигән иде» дия алмавым шикелле, тарихка җинаять итеп, шул Зөһрә ханымның булдыклыкларын, уңганлыкларын, нәфислек сөюләрен дә яшереп калдыра алмау өчен гафу итәрләр дип уйлыйм. Шуның кебек үк Зөһрә ханымның матурлыгы, Зөһрә ханымның тирә-юньгә зур тәэсир итүе, ирләрне мәфтүн итәр дәрәҗәдә назик, зифа булуы хакында, русларның да аңгарга изһаре мәхәббәт итүләре хакында язуларым тугры, дөрестер, вакыйгалардыр. Шуның өчен шул ук ханымның: «Бу сүзләрне язып, мөхәррир әфәнде иң элек үзенең тәрбияле гаиләдән улган гыйффәтле ханымнар, туташлар илә таныш түгел идекене ап-ачык әйтеп бирә», — дип, минем Петроград, Мәскәү, Казандагы йөзгә якын таныш туташ-курсисткаларга, бөтен татар дөньясындагы берничә йөз таныш татар мөгаллимәләренә, берничә мең таныш татар ханымнарына «Сез гыйффәтсез!» дип былчырак ыргыту никадәр урынсыз булса да, минем фельетонымдагы бер әсасны ды һичбер төрле какшатмыйдыр, бозмыйдыр.

Исмәгыйль бәк җәнабларын үзем ун ел мөддәтендә күз берлән күреп таныдым, таныштым. Аның җәмәгать эшләрендә мәсләкләрен, юлларын өйрәндем, аның берлән моназарә дә кылыштым. Мәсләк низагы да ясадым[6]. Тел вә сәясәт мәсьәләләрендә аның берлән һәр вакытта аерым-аерым нокталарда тордым. Шулай булса да, минем аны хәлфә итеп олуглавым, аның мине шәкерте итеп якын итүе кимемәде. Мин Исмәгыйль бәк җәнаблары берлә төрле-төрле җирләрдә хосусый бик күп очраштым, үзендә берничә мәртәбәләр кунак булдым, аның холкы, табигате хакында шактый күп тәҗрибә ясый алдым. Зөһрә ханым берлән танышуымның иң беренчесе Бакчасарайда Зынҗырлы мәдрәсәсендә укыган Садри әфәнде Максудовта булды. Ул минем иптәшем, аркадашым булганга, минем күңелемдә Зөһрә ханым хакында бик матур бер хыял уятты. Зөһрә ханымның якын кардәше Йосыф бәк Акчурин минем шул хыялыма әллә никадәр азык бирде. Шул Зөһрә ханымны — минем башымдагы Зөһрә ханымны үстерде, киңәйтте, олыгайтты. Ләкин болар һәммәсе дә Зөһрә ханымның Исмәгыйль бәккә иптәш булуы соңында вә иптәш булырлыгы хакындагы сүзләр булганга, аның яшьлеге, аның кияүгә чыгуы хакында тәфсыйлатлы мәгълүматым юк иде. Бу ел Гаспринский җәнабларының вафат хәбәре мин Мәскәүдә вакытта Хәсән абзый Акчуринның[7] квартирына алынган телеграмнан беленгәч тә, шул өйдә кунактагы Фатыйма ханым Шакулова[8] җәнаблары «Исмәгыйль бәк үлде, олуг кеше иде. Ләкин аның олуглыгы хакында язылганда, Зөһрәнең олуглыгы турысында да онытылмас иде» мәлендә бер сүз әйтте. Вә миңа аларның мөнәсәбәтләре хакында язарга, булмаса, мәгълүмат бирергә вәгъдә бирде. Матәм үтеп, мин Мәскәүгә күчеп килгәч, шул ук Акчуриннар өендә Фатыйма ханым Шакулова миңа мәгълүмат бирде. Мин, кулыма кәгазь тотып, шуларны берәм-берәм яздым. Мәҗлестәге Зөһрә ханым Акчурина (Хәсән абзый хатыны) бәгъзе моназарәләрне тутырды, бәгъзе бер мәгълүматларны күбәйтте. Шул мәгълүматым белән язарга керештем. Шөбһәм булса, барып вә телефон берлән шул ук Фатыйма ханымнан, ул киткәч, Зөһрә ханымнан справкалар ясадым. Кирәк, Фатыйма ханым Шакулова җәнабларына, кирәк, Зөһрә ханым Акчурина җәнабларына ышанычым Ибраһим абзыйдан ким булмаганга вә Ибраһим абзыйның шул эшкә кире

торганлыгы элгәредән мәгълүм булганга, мәгълүматны битараф җирдән җыюны мәслихәт таптым. Шуның өчен Ибраһим абзый Акчуринның хәтере калуы хак булса да, минем фельетонымдагы Ибраһим абзыйның «Коромысловкага барма да, йөрмә дә, тапмассың да» дигән сүзе дөрестер. Ибраһим абзыйның шул кияүләү мәсьәләсендә Гаспринскийлар ягында булынмавы гәзитәмездә басылган Гаспринскийларның метрический справкалары берлән исбат ителмештер.

Шуның өчен Ибраһим абзыйның мәрхүм Гаспринскийларның хамисы булган булып, матбугатка чыгып, үзен-үзе йолар өчен календарь артыннан җыйган иске рус мәкальләрен тәрҗемә итеп, миңа һөҗүмнәре, дәрес бирүләре урынсыздыр, Ибраһим абзыйның шанына муафикъ түгел кечкенәлектер, ваклыктыр, үз кадерен үзе белмәүдер.

«Сөембикә»дә «вөҗданы күтәрә алмаенча» язган Мәхбүбҗамал ханымга бер нәрсәне тәнкыйтькә керешүдән элек шуны укып чыгуын, язылмаган сүзләрне кыстырмаенча, әйтелмәгән уйларны «әйтте» димәенчә, барны барча гына алып эш итүен үтенер идем. Мин кай җиремдә Зөһрә ханымны «үзен-үзе тота белми иде» дидем? Кай җиремдә «Зөһрә ханым үзенә халык арасында мәхәббәт изһар итүчеләргә буйсына иде» дидем?..

Шул тез чүгүчеләргә, мәхәббәт изһар итүчеләргә йөзләренә чабарга көче җитмәс идемени дигән сөальгә аптыраудан башка җавабым юк. Җыйган мәгълүматымда Зөһрә ханымның сугышчан, талашчанлыгы хакында бер сүз дә булмаганга, аның назик табигате пароходта да сугышып йөрү дәрәҗәсенә кадәр төшермәс иде дип ышанам.

Зөһрә ханымның куәте, көче кулының ныклыгында түгел иде, аны зур иткән, аны көнләткән хасыятьләрдә, аның оста кычкырышуы-талашуында түгел иде. Ул зур бер мәгънәви куәткә хуҗа, ул искиткеч бер җазибәлелеккә, хәйран калырлык бер матурлыкка малик иде. Менә шул куәтләре, көчләре аның алдында вак-төяк чүп-чарларны гына түгел, әллә нинди фабрикант малайларын гына түгел, татарның иң олуг кешесе Исмәгыйльне дә тез чүктерде. Менә аның шул олуглыгы хәзер, бүгенге көндә аның мөкаддәс кабере алдында бөтен татар зыялыларын, көнче түгел бөтен татар хатыннарын тез чүктерә һәм чүктерәчәк. Чөнки ул каһарман бер милләтче татар булган кебек, ул чын бер татар хатыны, тулы татар хатыны иде.

Иң соңыннан гына, Мәхбүбҗамал ханымның озын сүзләренә, мөхакәмәләренә катышмаенча гына бер-ике генә сүз әйтим: Зөһрә ханымнар, Исмәгыйль бәк кебек олуглар янына барганда, аларны үлчәргә тотынганда, үзеңнең авылыңдагы аршының берлән үлчәп, шуңгарга сыймаса, «юк, алай ярамый, бүгенгә кадәр күрелгәне, ишетелгәне юктыр» дип, Вильһельм[9] тонында хөкемнәр чыгару килешеп бетә микән? Сезнең авылда чәй суына барганда сөйләнмәсә, бәлки, башка җирдә сөйләнгәндер. Сездә булмаса, күрше авылыгызда, бәлки, бардыр. Дөнья бит шактый гына зур. Дөньяның морале, дөньяның әхлагы да иске «Фәзаилешшөһүр»ләргә генә кереп бетмәгән кебек, матурлык, нәфасәт хакындагы уйлар да иске әбиләрнең мәкальләре берлән генә чикләнеп бетмәгәндер. Сезнең кебек хатын-кыз дөньясыннан чыккан язучылардан без ир язучыларның да көтә торган зур өмидләремез, сезнең безгә каршы зур бурычларыгыз бар. Аның иң зурысы: сездән башка да матбугат галәмендә хөкем сөрә торган гайбәт базарына сезнең яңа гайбәтләр китереп чыгармавыгыз, мәдрәсәдә кылны кырыкка ярган шәкертләремез: «Сәлмидән морад Сөләйман, Сөләйманнан морад Давыд, Давыдтан морад аның Тимере», — дип казынып, тибенеп торганда, сезнең кебек хатын-кыз арасыннан чыккан язучыларның кычытмаган җирне казуларына нә халкымызның, нә матбугатымызның ихтыяҗы бардыр. Тормышымызга хатын-кызымызның тәэсиренең азлыгы никадәр үземезне тупаслаткан булса, матбугатымызда хатын-кызымызның иштиракь итмәве дә шулкадәр матбугатымызны дорфа ясавында шөбһә юктыр. Шуның өчен язучы хатыннарымыз үзләренең дикъкатьләрен шул йомшартуга, нечкәртүгә, тормышымызга нәфасәт кертергә, хис-нәфасәтне назикләтергә хезмәт итәргә тиештер.

Алардан шуны көтәбез. Аларның бурычлары шул.

## ИСТАНБУЛ ВӘ БУГАЗЛАР

Думаның соңгы өч көнлек мәҗлесендә хариҗия министры Сазонов[1], Төркия берлән бу сугышта бугазлар һәм дә Истанбул мәсьәләсен бөтенләй Русия файдасына тиешенчә хәл ителмәенчә уртада калдырмаячакмыз, дигән иде. Шуның соңында сөйләгән төрле партияләрнең депутатлары да шул хакта һәммәсе дә Истанбулны вә бугазларны Русиягә кушуның кирәклегене кат-кат тәкрар иткәннәр иде. Русиянең ашлык сәүдәсе Истанбул вә Чанак кальга бугазлары аша йөргәнгә, бугазларны кулда итү Русиядә яңгы гына туган мәсьәлә түгелдер.

Мәшһүр Петр Великийның Кара диңгездә флот ясап, Төркия берлән сугышка хәзерләнүләренең төп замире шул Истанбулга вә бугазларга кайта иде.

54 нче елда башланган Кырым сугышы[2] да шул бугазларны кулда итү, Истанбулга хуҗа булу уе берлән башланган иде. 77 нче елның сугышында[3] Истанбул вә бугазлар мәсьәләсе беренче урында торган иде вә Айя Суфиянең манараларына крест тагу [уе] русларның бик күбесенә зур дәрт, гайрәт биргән иде.

Бу сугыш башлангач, шул мәсьәлә тагы русларның әфкяре гомумиясендә Истанбулга хуҗа булу, Айя Суфия мәсҗеден кәлисәгә күчерү уе бик күп сөйләнгәнлеге язылды.

Сату-алу ягыннан һәм дә сугыш ягыннан да Истанбул вә бугазларның Русия кулына күчүенең кирәклеге хакында бик күп дәлилләр китерелде. Истанбул вә бугазлар Русиянең кулына керсә, Русия тугрыдан-тугры Бәхре сәфидкә[4] юл ачып, үзе теләгәнчә үзенең ашлыгын Аурупага кертәчәктер. Бугазлар кулда ителсә, Русия бик нык саклана торган Чанак кальга бугазы берлән бикләнә торган Мәрмәрә диңгезендә вә аннан соң шундый ук куәтле Истанбул бугазы берлән бикләнә торган Кара диңгездә сугыш көймәләрен сакларга урын алып, Бәхре сәфидтә диңгез ягыннан иң көчле мәмләкәтләр берлән ярышырлык хәлгә киләчәктер. Шул хәл корыда җиңелми торган зур Русияне диңгездә бик куркынычлы диңгез куәтенә дә ия ясаячактыр вә дөньяда Русиядән зур, Русиядән көчле бер мәмләкәт калдырмаячактыр.

Бөтен дөньяның зур мәмләкәтләре ул вакытта Русиягә караганда зәгыйфь, көчсез булып калачактыр. Русия дөньяның бөтен сәясәтендә үз сүзен йөртәчәктер.

Менә бугазларның шулкадәр зур әһәмиятле булуы, Истанбулның дөньяның бизмәненең уртасында торуы бугазларны, Истанбулны алу мәсьәләсен авырайта килде. Англия һичбер вакыт Русия тарафыннан Истанбул алынуга разый булмады. Германия, Австрия, Франция һәрвакыт шул мәсьәләдә Төркиянең хуҗалыкын саклап килде. Ләкин хәзер менә сугыш башлангач, Англия белән Франция безнең иттифакчымыз булгач, бугазлар вә Истанбул Русиягә бирелергә иттифакчыларымыз разый дигән уй таралды. Рус әфкяре гомумиясе Истанбул бугазларын алу өчен үзенең тырышуын иттифакчыларга ярдәм итү, гомум дошманны җиңәр өчен кирәкле бер эш итеп йөртте. Ләкин хариҗия министрымызның сүзенә каршы Англия парламентында бирелгән запроста вә Англия хариҗия министрының җавабында «Без Русия өчен бугазлардан үтүнең ачык булу кирәк икәнен тасдыйк итсәк тә, Русия хариҗия нәзыйренең сүзләреннән Истанбулны кулда итәмез дигән мәгънәне күрмимез» дип ясаган нәзакәтеннән рус матбугаты шөбһәгә төште. Вә соңгы вакытларда Чанак кальга бугазын инглиз вә француз флоты тарафыннан ярылып үтелергә тырышуы вә шуның аркасында Истанбулны кулга эләктерергә маташуы да төрле моталәгаләргә сәбәп булды. Хәзер рус, инглиз гәзитәләренең зурлары шул хакта озын-озын мәкаләләр язганның соңында бу мәсьәләдә Англия берлән Русия арасында фикердә аңлашылмау юклыгы мәгълүм булды вә Истанбулны, бугазларны бүлешүнең әле вакыты кермәгәнлеге беленде.

Истанбулны алу ике тарафтан мөмкиндер. Берсе — Кара диңгез ягыннан, берсе — Мәрмәрә диңгезе тарафыннан. Кара диңгез ягыннан Истанбулны алыр өчен коры җир гаскәре куәтле булу гына җитмидер. Кара диңгездәге флот та, төрек флотына караганда күп дәрәҗә көчле булып, Кара диңгездә хуҗа булырга тиеш вә теләгән урынына гаскәр төшерерлек куәтле булырга тиештер.

## МИЛЛИ УКУ ЙОРТЛАРЫМЫЗ

Гәзитәләремездә язылган, арамызда сөйләнгән сүзләрнең иң күбесе мәктәпләремез, мәдрәсәләремез хакында икәнендә шөбһә юктыр.

Атадан, бабадан килгән мәдрәсәләремез, мәктәпләремез, мәгаттәәссеф, бу көнгә кадәре бер рәткә кертелгәне юктыр. Болар һәммәсе — закон кашында мәсҗед янындагы мәктәпләр, имамнарның дин укытыр өчен ачкан мәдрәсәләредер. Боларның нә закон каршында мәгълүм бер программалары бар, нә идарәи руханиямез тарафыннан эшләтелгән бер тәгълиматы, тәнзыйматы бардыр.

Элек һәр мәдрәсә үзенчә аерым-аерым идарәдә, һәр мәдрәсә үзенчә аерым бер программада бара иде. Шуның өчен кайбер мәдрәсәләремез «Һәфтияк-шәриф» берлән «Фәзаилешшөһүр»дән үтә алмый, кайберләрендә имамнар, хатиблар мөдәррисләр йитешә иде.

Мәдрәсәләрнең программасызлыгы, тәгълиматсызлыгында зарар бик күп булса да, моның файдасы да шактый зур иде. Уңган, дәртле мөдәррисләремез үзләре теләгәнчә мәдрәсәләрен зурайталар, үзләре теләгәнчә программаларын киңәйтеп, мулла, мөдәррисләргә дәресханәләр ясыйлар, тирә-яктагы бөтен авылларга муллалар чыгарып, мөәзиннәр җиткереп торалар иде.

Тормыш боерыгы берлән ул мәдрәсәләр эчләрен үзгәртте. Шул бер исемнән, бер бинадан ике гыйлем йорты аерым-аерымга бүленде, берсе балалар укытыр өчен мәктәп, икенчесе муллалар, хатиблар, мөдәррисләр, мөгаллимнәр чыгарыр өчен мәдрәсәгә әверелде.

Авыл халкының унар, унбишәр ел мәптеккә йөреп, «Кунут» догасы берлән «Колһуаллаһ» өйрәнеп[1] чыгарга вакыты йитми башлады. Аның йире-суы тарайды. Торыш-йөреше бәһаләнде. Ул теләр-теләмәс унсигез яшьлек углын ун ел эчендә өйрәнеп йитмәгән әт-тәхыятьтән аерып, күмер казырга[2] җибәрергә мәҗбүр булды. Тормыштагы шул үзгәреш мәктәп-мәдрәсәгә дә тәэсирсез кала алмады. Уку шул юлда булса, ун-биш-уналтыга кадәр җиде-сигез ел укыган авыл баласы өстән генә дә динен танып, язу язар, укырлык булмаса, фабрикка, завод, шәһәр тормышы астында халкымызның дине, тәрбиясе бер-ике буында тәмамән бетәчәге мәгълүм булды. Укытуны рәтләргә юл эзләнергә тотынды. Уку фәне әллә кайчан табып чыгарган аз укытып күп булдыру кабул ителде. Халкымыз шуны ысуле җәдид дип кабул итеп, мәктәпләремез шул юлга куелды. Шундый аз вакытта күп белер өчен, укытканда иң кирәклесен кирәкледән алдан тотып укыта белер өчен элгәреге сукыр суфилар, карт мөәзиннәр, сугыштан зәгыйфь калып кайткан солдатлар ярамый башлады.

Укытучыларны хәзерләр өчен мәдрәсәләремезгә яңгы фәннәр кертү лязем булды. Мәдрәсәләрнең халкымызның тарихы кая барганын күрерлек күзе ачыклары, уку юлындагы шул мәҗбүри үзгәрешне күреп, тарихның кушкан ягына борылдылар. Мәдрәсәләренә укыту юлын рәтләрлек фәннәр керттеләр. Мәдрәсәләренә мөгаллимгә кирәкле дәресләр арттырдылар. Мәдрәсәләренең вазифаларын киңәйттеләр. Авылга мөгаллим чыгара башладылар, тормышның шул теләгән тутыруда мәдрәсәләремезнең программасы үзгәрде. Анда яңгы фәннәр кертелде, моңганчы ишетелмәгән тарих, җәгърафия, голүме риязыя, голүме табигыягә урын бирелде. Аның берлән генә бетмәде, мәдрәсәдә яңгы бер гамил килеп чыкты. Унҗиде, унсигез еллык авыл малаен күмер казырга куган тормыш мулла малаена да утыз биш, кырыкка кадәр мәдрәсәдә «Җамигъ әр-рәмуз»ның кырыйларына язылган хашияләрен укып, китап моталәга кылып ятарга ирек бирми башлады. Тормыш аны да кысты. Ул да тизрәк укыйсын укып чыгып, мулламы шунда, мөәзинме, мөгаллимме булырга, үзенең тормышын үзе күтәргә мәҗбүр булды. Шуның өчен мәдрәсәнең уку-укыту эшләре тәртипкә салынырга, анда да вакытның кыйммәтен үлчәргә мәҗбүрият хис ителде. Мәдрәсәләр да ислях ителде. Аларның да укулары-укытуларына элгәреге заманда бабайлар алдында күренмәгән яңгылыклар кертелде. «Дин саклау, динле булу» дигән уй халкымызның башына, канына сеңеп калганга вә тарих бабай аны һәрвакыт шул уйда торырга, шул фикер янында бөтен көчен-куәтен сарыф итәргә мәҗбүр иткәнгә, ул тирә-юньнән килә торган бозыклыктан куркып коты очты вә, шул динлелеген саклар өчен, үзе аңламаенча гына бөтен дөнья тарихында дини гадәт сакчысы булып килгән хатыннарына күз төшерде. Яңгы тормыштагы үзгәрешләр арасында дини гадәтне сакларлык иттереп укый, тәрбия итела торган мәктәпләре, мәдрәсәләре юклыгы беленгәч тә, халык, беркем кушмаенча, беркем әйтмәенчә, кызларын укытырга кереште.

Шул фикерне тудырган гамилләр бөтен татар дөньясында бер булганга, бөтен Татарстан бердән башлады. Биш-ун ел үтмәде, абызтайларга, сукыр карчыкларга сабакка йөри торган авыл кызлары киң һавалы, пакь мәктәпләрдә укыткан мөгаллимәләргә йөрергә тотынды. Авыл хатыны булуның бурычлары хәзер урак уру арасында әллә нидә бер намаз укып алу гына булмаганга, үзгәргән тормыш алардан да үзләренә ирләрен багларлык, биләрлек, балалары күмер заводына яшьтән китсә дә, рус булып кайтмаслык тәрбия итә белерлек өйрәнү, белү сораганга, монда да уку-укыту киңәйде. Менә шулай итеп, биш-ун ел эчендә бөтен уку мәнзарәләремез үзгәрде, алар сипләнде, яңгарды. Кечкенә баланың үсүе, зураюы никадәр табигый булса, мәктәп-мәдрәсәмезнең дә үсүе, күбәюе шулкадәр табигыйдер. Халык үзе яшәгәч, аның мәктәбе, мәдрәсәсе, әдәбияты, матбугатының яшәве, үсүе, зураюы, киңәюе — мәгълүм мантыйкый бер эштер. Баланың яше зурайган саен, аның киеменең үзгәрүе, элгәреге кечкенә вакыттагы биләүсәсе унике-унөчтә балага ярамавы, унике-унөчтәге чагындагы казакие, күлмәге егет булып җиткәч кияргә тар булуы никадәр табигый булса, халыкларның уку-өйрәнү эшләрен алып бара торган даирәләр, мөәссәсәләренең дә халыкның үсүе, зураюына карап үзгәрүе шулкадәр табигыйдер. Аның үлчәүләре, бизмәннәренең алышынуы да тиешледер, ляземдер[3]. [...]

Менә шул мәсьәләләрне бертөрле хәл итәр өчен, шул мәсьәләләрне бертөрле законный юлга куяр өчен, былтыр депутатларымыз мөгаллим вә мөгаллимәләр хакында кечкенә генә законопроект керткәннәр иде. Ләкин сугыш булу берлән тукталып калды. Аның урынына безнең катнашымыздан башка күбрәк поляларның иҗтиһады аркасында хосусый мәктәпләр хакында закон эшләнеп чыкты. Дума, Советтан үтеп, патша хәзрәтләре тарафыннан тасдыйк ителеп, хөкүмәтнең законнар игълан итела торган рәсми мәҗмугасында 117 нче номер берлән басылып игълан ителде. Шул закон буенча һәр йирдә, авылда, шәһәрдә хосусый мәктәпләр ачу өчен бу көнгә кадәр кылынып килгән бик күп кысынкылыклар бетерелде. Мәктәп ачуда явочный порядок әсаси иттереп кабул ителде. Менә шул закон буенча һәркемгә, һәр җәмгыятькә теләсә генә нинди телдә укытырга рөхсәттер. Фәкать шул законда күрсәтелгән шартларны гына ригая итү, ягъни мөгаллимнең укытырга хакы булуы өчен, Русия тарихы русча укылу, рус теле дәрес итү кебек без әллә кайчан эшләп килә торган уңгайлыкларны гына тутыру шарттыр.

Менә хәзер инде законнан файдаланып, безнең Уфада ачылырга карар ителгән дарелмөгаллимин, дарелмөгаллиматымыз законлы юллардан хәрәкәткә тотынсын иде. Шул законнан файдаланып, Казанда ачылырга карар ителгән вә ике йөз мең сум акча җыйный алган кызлар гимназиясе[4] дә эшкә башласа иде. Урта мәктәпләргә рөхсәт алыр өчен попечительгә генә прошение бирү җиткәнгә, әлбәттә, шуларны андагы үз түрәләре берлән генә дә эшләп булыр иде. Вә аннан зуррак даирәләргә үтәргә — мәгариф назыйренә җитәргә тиеш булса да, Петроградта ачык йөз берлән каршы алыныр иде[5]. [...]

Монда һичбер төрле шөбһә юктыр. Ләкин без, үземез «алма пеш, авызыма төш» дип торганга, бер эшне дә булдыра алмыймыз. Һичбер эшне вөҗүдкә чыгара алмыймыз.

Уфаның дарелмөгаллимин, дарелмөгаллимат комиссиясе нишләде, нишли? Хәзер шул закон чыккач, яңгы мәгариф назыйре алышынгач[6], нинди хәрәкәт ясады? Казанның гимназиясе нишләде, ни хәрәкәт ясады?

Һич!

Мөгаллим, мөгаллимәләремезнең хәлләрен төзәтү өчен, уку-укыту эшемезне саглам казыкка бәйләр өчен шуннан башларга кирәктер. Шуны эшләргә алынган кешеләр эшли башларга тиештер. Юл законлыдыр, юл ачыктыр.

## СӘЯСӘТ ЙӨРЕШЕ

Соңгы атналарда сугышның яңгы сәхифәләре ачылды. Аларга әле тарихныңниләр язачагы мәгълүм булмаса да, шул яңгы битләрнең ачылуы гына да бик күп уйлар, сүзләр тудырды. Битараф дәүләтләрнең бик күбесенең мәнфәгатьләренә бәрелешеп, аларның төрлесендә төрле тарафка маилләр уятты.

Вакыйгаларның беренчесе — француз, инглиз флотының Чанак кальга бугазын туктамаудан ике атнадан бирле тупка тотуы. Икенчесе Франция белән Ингелтерәнең Германия белән Австриягә блокада игълан итүләре, ягъни Германия берлән Австриянең чит мәмләкәтләр берлән бөтен килеш китүен бетерәмез дип белдерүләре вә шул мәмләкәтләр арасында битараф дәүләтләрнең көймәләрен дә тотарга карар бирүләредер.

Беренче мәсьәлә, ягъни Чанак кальга бугазын үтәргә тырышу Италия, хосусән Балкан хөкүмәтләренең мәнфәгатьләренә бик якыннан бәрелгәнгә, боларның һәммәсе дә зур мәсьәлә уятты. Халыклары, хөкүмәтләре алдында тагы бер мәртәбә «Безгә дә сугышырга тиеш түгелме? Тиеш булса, кемнәр яклы булырга?» дигән уйны икенче, өченче мәртәбә мөхакәмәгә куйдырды. Бөтен матбугат хәзер шул мәсьәлә берлән мәшгуль, Румыния, Болгария, Юнанстан хәзер битарафлыкның иң читендә торалар. Румыния халкының бу сугыштан көткән зур өмидләре бар. Ул да — Румыниянең күрше мәмләкәтләрендә, хосусән Австриядә калган иске румын йирләрен үзләренә кушу. Алар шул зураюны мөмкин кадәр үз халыкларына җиңелчәрәк, мөмкин кадәр кан түкмәенчә, ышанмаенчарак булсын өчен форсат саклап яталар иде, ягъни битараф торалар иде.

Максудлары — үзләренә тиешле булган өлешне алырга вакыт җиткән чакта мөмкин кадәр көчле булып калу вә, куркытып, бүлешүгә катышу иде. Румыннар шуңгарга хәзерләнәләр, ике як берлән дә йөзек яшереш уены уйнап җиңгән яклы булырга торалар иде.

Бугазларны тупка тоту, аны ярып үтәргә теләү Румыния алдында тагы бер мәсьәлә тудырды. Ул да — бугазның кем кулында калуы. Румыниянең диңгезе Кара диңгез генә булганга, аның чит мәмләкәтләр берлән сәүдәсенең иң зурысы бугазлар ашадыр. Ул үзенең ашлыгын, керосинын шул юлдан бик күп иттереп Мисырга чыгара, Италиягә бирә иде. Аның шактый күп пароходлары, шул юл берлән чыгып-кереп, Төркиянең Яфадагы шәһәрләре арасында алыш-биреш йөртә иде. Төркия берлән аерым сату могаһәдәләре булганга, Румыниянең сатуына бугазларның төрек кулында булуы зарар итми иде. Хәзер шул бугазлар, төрекләр кулыннан чыгып, икенче бер кулларга күчсә, Румыния үзенең Кара диңгезендә бикләнеп калмыймы, Румыниянең сату-алуы икенче бер мәмләкәтләрнең кәефенә табигъ иттерелмиме дигән мәсьәлә туды. Румыния өчен бу мәсьәлә чит мәмләкәт мәсьәләсе булганга, әфкяре гомумия тагы кайнады, ташыды, тагы хөкүмәт, үзенең битарафлыгыннан чыгарга вакыт җитмәдеме дип, хәзерлекләр күрергә кереште, парламенттан кирәк вакытында осадный положение игълан итәргә рөхсәт алды. Румыниянең бөтен сәясиләре хәзер шул мәсьәлә берлән мәшгуль булган кебек, сугыш даирәләре дә сугышка хәзерләнүләре берлән мәшгульдерләр.

Бугазлар мәсьәләсенең очы килеп йиткән мәмләкәтнең икенчесе — Юнанстандыр. Греклар да, искедән бирле Истанбулны үз кулларына кертеп, яңгыдан Бизанс мәмләкәтен тудыру хыяллары берлән яшиләр вә шуңгарга форсат көтәләр иде[1]. Грекларның, кирәк, мәдәниятләре вә, кирәк, көчләре, куәтләре мондый зур планнарны тудырырга ирек бирмәсә дә, алар шул татлы уйлардан аерылмыйлар иде. Менә хәзер Чанак

кальга бугазын ярып кичүгә тырышу шул мәсьәләне бу көнге көн мәсьәләсе иттерде. Грекларда ике фикер туды. Берсе — инглизләр, французлар белән берләшеп, аларга ярдәм итешеп, шуның өчен үзләренә Истанбулны сорау; икенчесе — аларның Истанбулны грекларга бирмәүләренә ышанып, шуларга дошман вазгыятьтә булу. Бу ике фикернең дә үзенең иярченнәре күп булганга, бу мәсьәләдә кай яклы булу да Юнанстан өчен бик зур эш булганга, анда да зур-зур низаглар булды. Хөкүмәт, король берлән бергәләшеп, өч-дүрт мәртәбә киңәшләр ясады. Инглизләр, французларның Чанак кальга бугазын корыдан үтәр өчен ике корпус гаскәр биреңез, диюләре вә шуңгарга каршы Анатолийдән йирләр вәгъдә итүләре мөзакәрә ителде.

Гәзитәләргә караганда, баш министр Винизилус[2], иэтиляфчылар белән берләшеп, Төркиягә игълане хәреб кылу тарафында булынды, бәгъзе министрлар берлән король битарафлыкны саклау ягында торды. Ахырдан бер фикергә килә алмадылар да, Винизилус, грекларга Төркия берлән Беренче сугышны хәзерләгән, Икенче Балкан сугышын очлап чыгарган[3] Винизилус истигъфа итте, министрлыкны ташлады. Әлегә әле Юнанстандагы мәсьәлә шуның берлән капланды. Ләкин Винизилусның үзенең иярченнәре шактый күп булганга, король Константин үзе немес булганга, король тарафдарлары берлән Винизилус тарафдарлары арасында зур-зур низаглар, фетнәләр булуы да ерак түгелдер.

Өченче дәрәҗәдә Болгария тора. Болгария бер ягы берлән Кара диңгезгә чыкса да, аның Варна, Бургаз портлары сату-алу өчен иң эшлекле юллары булса да, соңгы сугышта ул тар гына юл берлән Аталар диңгезенә[4] чыкканга вә анда начар гына булса да Дәдәагач лиманы[5] Болгария кулында булганга, өстән караганда аның сату-алуы өчен бугазларның башка кулларга күчүенең зур тәэсире булмаска тиеш иде. Ләкин Болгариянең Дәдәагач лиманының, бердән, рәтләнеп эшләнеп бетмәгән булуы, икенчедән, аның анда флоты булмавы һәм дә күршесендәге греклар берлән дуст булмавы аркасында шул йирләрне сакларга көче җитмәве Болгария алдында бугазлар мәсьәләсенең әһәмиятен бик зурайтадыр. Ул да шул мәсьәләнең ничек булса да хәл ителүенә сәерче генә булып кала алмаячактыр. Болгариянең сугыштан көткән өмидләренең иң зурысы серблар, грекларга киткән Македонияне кире кайтарып алу вә Румыниянең көчләп алган Дубруҗаны тагы үзенеке итү булганга, аның урыны, бер яктан, бик хәтәрле, бер яктан, бик әһәмиятледер. Румыния кай тараф берлән сугышка керешсә дә, Болгариянең ары яктан килеп кермәвенә имин була алмыйдыр. Греклар, кай тараф белән берләшеп сугышка керсәләр дә, Болгариянең артларына төшүеннән котыла алмыйлар. Шуның аркасында Балкандагы кечкенә мәмләкәтләр әле ул яклы, әле бу яклы булган булып киләләр вә һичбер якка чынлап кушылып китә алмыйлар. Бу икеләнү сәясәтендә шул мәмләкәтләрнең сарайларының тәэсире юк түгелдер. Юнанстан, Болгария, Румыниянең корольләре — өчесе дә немеслердер. Һәм дә күптән түгел генә Германиядән килгән бу корольләр үзләренең төп йортлары берлән үзләренең галякаларын һич кисмәгәннәрдер. Кыз алышу, кыз бирешү, угыл өйләндерү, туй итү һаман немес принцлары берлән була килгәндер. Шуның өчен бу мәмләкәтләрнең сарайлары вә аның тирә-юньнәре эчләреннән немесләргә дусча карамаулары мөмкин түгелдер. Вә шуларның тәэсирләре аркасында сәясәт тә шулай саллана-саллана барадыр.

Бугазлар мәсьәләсенең шактый зур тәэсир иткән мәмләкәтнең зурысы — Италиядер. Италиянең әмәле — Бәхре сәфидтә иң көчле мәмләкәт булудыр. Шуның өчен ул Траблисны алды. Шуның өчен Аталар диңгезендәге төрекләрдән алган унике атауны, солых шартлары буенча кайтарылырга тиеш булса да, бирмәенчә килә. Аның өчен дә Истанбулда зур бер мәмләкәтнең йирләшүе, бугазларның зур бер мәмләкәткә бирелүе уңгайлы эш түгелдер. Аның да планнарын, фаразларын җимерәчәктер. Шуның өчен Италиянең битарафлыгы да бик уңгайсыз бер хәлдәдер. Сугышның барышы, үзенең вазгыятен саклау аны да сугышка катышырга мәҗбүр итү ихтималы бик якындыр.

Англия берлән Франциянең Германия вә Австриягә һичбер төрле сәүдә көймәсе кертмәскә карар бирүләре вә шуны булдырырга тырышулары икенче тараф мәмләкәтләрнең кәефен җибәрде. Бу эш сугыш башланганнан бирле Германия берлән сатуларын әллә ничә мәртәбә арттырган Швеция, Дания, Голландия халыкларына бик уңгайсыз булды. Шул сугыш вакытларында Германиянең үз пароходлары чыгып йөри алмаудан файдаланып, бу мәмләкәтләрнең сәүдәгәрләре Германия товарын үзләре аша икенче мәмләкәтләргә чыгарып, Германиягә кирәк нәрсәләрне тагы үзләре аша кертеп, ваттырып сату итәләр иде. Хәзер шуңгарга киртә куелды. Франция, Англиянең флоты Германия якасына туктарга рөхсәт бирми. Пароходларның малларын конфисковать итмәсә дә, кире кайтарып җибәрә. Моңгардан иң зарар күргән мәмләкәт Америка булды. Америка, сугыш башлангач та, «убыр китте, урыны калды» мәкаленчә эшкә керешкән иде. Ул сугыша торган мәмләкәтнең һәммәсенә ашамак-эчмәк әйберләрен генә түгел, сугыш кирәк-яракларын да сата иде. Германиягә бик күп ашлык, мамык кертә, үткәрә алса, бакыр да ычкындыра иде. Франция берлән Ингелтерәнең шул карары аларның бик эчләрен пошырды. Шул мәсьәлә хакында сәясиләр арасында сөйләшү башланды.

Ләкин мәсьәләнең ничек бетәчәге мәгълүм түгел. Шундый ике зур вакыйга алдында хәзер бөтен битараф дәүләтләр аптырап калдылар. Әле берсе дә катгый бер карарга килә алмаса да, әле берсе дә, мин

бу яклы, дип, сугышка катыша алмаса да, озакламаенча сугышчылар арасында бер-ике мәмләкәтнең тагы кушылуы бик көтеләдер. Вә соңгы атналар сугыш тарихының бик әһәмиятле сәхифәләрен ачачактыр дип уйланыладыр.

## КАРС МӨСЕЛМАННАРЫ

Карс мөселманнарына ярдәм эше бөтен Идел буе мөселманнары арасында юлга куелып килә. Оренбургта, Казанда да рәсми ярдәм җыярга рөхсәт алдылар. Аерым комитетлар ясап эшкә керештеләр. Әстерханда шул мескиннәргә ярдәм тәшәббесе берлән театр куярга хәзерлеккә тотындылар. Кечкенә-кечкенә шәһәрләр дә, азмы-күпме җыеп, төрлесе төрле юл берлән шул мескиннәргә күндерделәр. Авыллар да буш калмады: үзенең якынына, кардәш-кабиләсеннән әллә никадәр гаскәр озаткан авыллар да ярдәм кулын сузды. Гәзитәләрдә бертуктамаенча әле бер имам әфәнденең җыйган акчасы, әле бер мөгаллимә ханымның шәкертләреннән туплаган сумасы җибәрелүе, тапшырылуы язылып тора. Димәк, шул изге эштә бөтен Идел буе мөселманы хәлле хәленчә катышты[1]. Бае, фәкыйре, укучысы, укытучысы көчләнелгән кардәшенең күз яшен сөртергә кулыны сузды.

Бөтен Русия мөселманы шул мескин гарипләрнең кайгысы үз хәсрәте икәнен, аның бәхетсезлеге үз бәхетсезлеге икәнен эш берлән күрсәтте. Бәлки, аның биргәне бик аздыр. Бәлки, аның күндергәне җәрәхәтне төзәтү түгел, аны юарга да җитәрлек түгелдер. Бәлки, анда ач-мохтаҗ мөселманнарны туйдырыр өчен, андагы йортсыз-йирсез, киемсез-салымсыз кардәшләрнең сусавын бетерер өчен шуңгарга караганда тагы йөз мәртәбә артык ярдәм итәргә тиештер.

Шулайдыр. Ләкин шул кечкенә генә ярдәмемез дә, шул өф итәргә җитмәгән сәдакаларымыз да җәберләнгән, боеккан ятим балаларның, тол хатыннарның күңелендә шатлык уятачактыр. Аларның курыккан, коты очкан күңелләренең бер почмагында гына кечкенә генә булса да өмид уятачактыр. Алар янган, көйгән бәгырьләре берлән үзләренең ялгыз түгеллеген, үзләре шул суык, салкын Кавказ тау араларында никадәр ташландык кебек күренсәләр дә, еракта булсалар да, аларның туганнары, аларның кардәшләре бар икәнен сизәчәкләрдер. Егълый-егълый шешеп беткән күзләре берлән шул туганнарын, кардәшләрен күрмәсәләр дә, йөрәкләре шуларның барлыгын хис итәчәктер. Шуларның нинди авыр чакта да үзләрен ялгыз калдырмауларын онытмаячаклардыр вә безнең өстебезгә шундый казаи илаһи килсә, ярдәм кулларын сузуны үзләренең бурычы саячаклардыр. Моңганчыга кадәр иткән хезмәтемез менә шулкадәр. Ләкин хезмәтне тәмам итәр өчен тагы бик зур гайрәт, бик зур тырышлык итәргә вә шул башланган эшне тәмамларга тиештер. Шулкадәр казаи бәла арасында әллә никадәр бала-чага атасыз-анасыз, кардәш-кабиләсез калуы, әлбәттә, һәркемгә мәгълүмдер. Мондый балалар, әлбәттә, бер генә түгел, ун гына түгел, йөз генә дә түгелдер. Менә шул ятимнәргә ярдәмгә җитешү — тагы ук безнең бурычымыздыр. Ләкин андагы хәлне белеп булмаганга, күпме бала барын аерып әйтеп булмаганга, безгә шунда, мотлакан, бер һәйәт җибәрү тиештер, фарыздыр. Ул һәйәтне күндерү дә аерым-аерым шәһәр өчен, аерым-аерым «Җәмгыяте хәйрия»ләр өчен, аерым-аерым ярдәм комитетлары өчен мөмкин түгел дәрәҗәсендә авырдыр. Шуның өчен шул мәсьәләне бөтенемез иттифак итеп, Петербургтагы рөхсәт ителгән комитетка тапшырырга тиештер. Вә шул комитеттан да мөмкин кадәр тизрәк Кавказда шул һәйәтне күндерүне ашыктырырга тиештер. Һәйәтнең хәле, мәүкыйгы нык булсын өчен, араларында бер-ике депутат булуы лязем булганга, комитет фракциямез берлән сүзгә керешергә, вакыт үткәрмәенчә мөзакәрәгә тотынырга тиештер.

Комитетның бу көнге вазифасы менә шул. Анда барган һәйәт шундагы ихтыяҗның чамасын белеп кайтса, шуңгарга карап эш итә башлармыз, андагы һәйәт тәрбиясез калган балаларны тәхминән генә хисаплап кайтса, шуларның тәрбиясенә юл эзләрмез вә, иншалла, Идел буе мөселманнарының юмартлыгы аркасында меңләп-меңләп мөселман баласын мөселман рухында тәрбия итә алыр идек. Меңләп-меңләп баланы мөселман авылларына, мөселман шәһәрләренә йирләштерә алыр идек.

Шуны да әйтеп китәсем килә: шул ярдәмчеләр арасында шәһәрләр генә түгел, авыллар да, утарлар да бик күп зикер ителде, бик күп гәзитәләргә исемнәре язылды. Шуның арасында мин бер мәртәбә дә Семипалат дигән бер шәһәрнең исемен яисә Семипалатлы фәлән әфәнде дигән бер фамилияне күрмәдем, укымадым. Ул шәһәрдә бит элгәре утыз-кырык мең мөселман, ун-унбиш мәсҗед, зур-зур байлар бар иде. Әллә сугыш чыккач, шунда бер мөселман да калмадымы? Әллә шуның бөтен халкы, Карс мөселманнары кебек, бер казага очрадылармы? Ул гына да түгел, мин Төркестаннан, Бохарасыннан, Сәмәркандыннан, Хивасыннан, Ташкентыннан шул ярдәмчеләр арасына кушылганнарны һичбер ишетмәдем, Төркестанның алты-җиде миллион мөселманы арасында шул кызганычларны, шул ятимнәрне аярлык шәфкать булмавына, әлбәттә, ышанмыйм.

Һәр көнне кебек, яралы гаскәрләр файдасына, Кызыл Крест файдасына театрлар уйнап, ахшамнар ясап йөргән әфәнделәрнең медаль алыр өчен, «спасибо» ишетер өчен генә йөргәннәрдер дигәнгә ышанасым

килми. Алар тегесен дә савап өчен йөргән кебек, Карс мөселманнарына ярдәмдә дә савап өчен йөрерләр. Моңганчыга кадәр ара ераклыктан гына ярдәмгә кулларын суза алмасалар алмаганнардыр. Гәзитәләрне аз укыганга гына дөньяның хәленнән, әхваленнән хәбәрдар булмаганга, шулай соңга калганнардыр.

Мәскәүнең үзенә килсәк, монда да бер тарафтан шактый зур хәрәкәт булса да, укучылар, яшьләр шул мескиннәр файдасына театр куярга дип маташып йөрсәләр дә вә юмарт мөселманнары кулдан килгәнчә ярдәмне җибәреп торсалар да, «Җәмгыяте хәйрия», мәгаттәәссеф, соңганчы бер эш эшли алганы юктыр. Бөтен шәһәрләрдә рөхсәт алынып бетсә дә, Мәскәү «Җәмгыяте хәйрия»се шул сүзне сөйли башлауның тиздән кырыгы җитсә дә, эш ләм-мим кадәр алга киткәне юктыр. Эш булып чыгар өчен бер генә дә ихтимал артканы юктыр. Шуның өчен театрларын, ярдәм ахшамнарын шуңгарга бәйләнгән даирәләрдә бер эш эшли алмаенча калу ихтималлары бик якындыр, «Җәмгыяте хәйрия» идарәсенә шул эшкә бераз дикъкатьлерәк маташуы, шул эшне башлаганда да, артыннан йөрегәндә дә чынлабрак тырышуы бик матлубтыр. Соңганчыга кадәр килгән алпан-тилпән йөртүне бетерергә, чынлап ярдәм юлына керешергә вакыттыр.

## БАБАЙЛАР ТУПРАГЫ

Бу көнге гәзитәләремездә Кырым мөселманнарының күчеп китә торган немеслардән тугыз йөз дисәтинә йир алулары хәбәр ителеп языладыр.

Кырымда немес колонистларының кулында әллә ничә мең, бәлки, әллә ничә ун мең дисәтинә йирләр булганга вә боларның иң күбесе безнең бабаларымыздан йирләре булганга, аз гына булса, шул хәләл малымызның үземезгә кайта башлавына шатланмый хәлемез юктыр. Шул тугыз йөз дисәтинәне алган агай-энемезнең кулы җиңгел булсын иде дә меңәр-меңәр дисәтинә йирләремез үземезгә кайтарылсын иде. Кырымдагы йирләрнең иң зур бүлеге элгәре безнең татар кулында иде. Ләкин бик күбесе шул дөньяның оҗмахындагы йирләрнең кадерен белмәгәнгә, башкортлар кебек юк бәһагә сатып бетерде. Кайбере, Төркиягә һиҗрәт итеп, җиреннән-суыннан җөда булды. Киткән йирләрнең иң күбесе Әби патша заманасында утыртылган колонист немесләргә вә аларның яхшы тормышларын ишетеп, кызыгып, үзе теләп күчкән төрле халыкның кулына кергән иде.

Хәзер немесләрнең йир-суны биләүләре хакында кысынкылыклы закон чыккач вә немес колонияләренә хөкүмәт даирәләрендә әминият беткәч, алар күпләп-күпләп йир-су, мал-туар сатарга вә бөтен мал-мөлкәтне бетерергә керештеләр. Безнең татарлардан һиҗрәт вакытларында ничек бушлай алып калган булсалар, хәзер үзләре дә шулай ярты бушлай сатарга тотындылар. Менә хәзер безнең Кырымдагы агай-энемез шул форсаттан файдалана белсәләр иде, бабаларының дөнья кадерен белмәгәннән иткән хаталарын бабалары яба белсәләр иде. Бу форсат Кырым татарларына йирле-сулы булып калыр өчен актыккы форсаттыр вә бу форсатны югалтсалар, үз йирләренә үз илләрендә мәңге коллыкта, хезмәтчелектә калачактыр. Шул мәсьәләне чынлап аңлап, шул мәсьәләне Кырымдагы матбугатымыз чынлап, җентекләп халыкка чәйнәп бирсә иде, вә Кырымның зыялылары шул юлда халыкка юлбашчысы булса иде.

Кырымда немесләрнең сатыла торган йирләре бик күп булганга, вә немесләрнең салган йортлары, йирләре, корган утарлары бик пөхтә иттереп эшләнеп, иген игүләре соңгы систем машиналар берлә эшләнә торган булганга, аларның утарларын алыр өчен Кырым татарлары гына түгел, Идел буеның мөселманнары да катышса, бердән, бик зур файда итәчәкләрдер. Икенчедән, һәйбәт итеп ашлык чәчәргә, бакча үстерүгә өйрәнәчәкләрдер. Шуның өчен Идел буендагы мөселманнарның да шул Кырымдагы немесләрнең йирләренә дикъкать итүләрен үтенер идек. Көче йиткәне берлән шунда йир-су алуны мәслихәт итәр идек. Элгәреге вакытындагы дисәтинәсе дүрт-биш йөз сумга йөргән йирләрне хәзер немесләр йөзәр сумга саталар. Өчәр меңгә алган машиналарын бишәр йөзгә кадәр бирәләр икән. Гайрәтле, уңган егетләремез, шул тарафка чыгып, шул эшләрнең артыннан йөрсә, кирәк, үзләре өчен вә, кирәк, мөселман йиренең мөселманга кайтуы өчен әллә никадәр хезмәт итәчәктер. Бездә шундый йир-су ала торган банкларымыз булмаганга, яһүдиләрнеке кебек фәкыйрьләргә ярдәм берлән йир алып бирә торган җәмгыятьләремез булмаганга, бу эшне дә берәм-сәрәм эшләргә тугры киләчәктер вә бу эштә дә уңган байларымыз ярдәменә сыгынырга мәҗбүр булыначактыр.

Идел буеның әллә кайларга, чүплек башларына, сазлык араларына җәйләүләргә чыга торган байлары шунда кечкенә-кечкенә бакчалар, йирләр алсалар, үзләре вә балалары өчен нинди матур күңел ачарлык эш эшләячәкләрдер.

Иң соңыннан әйтәчәк сүземез Кырымда вәкыф эшләрен карауч даирәләргәдер. Һәркемгә мәгълүм, Кырымдагы мөселманнарның вәкыфларына хәзерге көндә бер миллионга якын саф акчасы бардыр.

Бу вәкыфларның багышланулары шундагы мөселман халкының дини вә дөньяви файдасы өчендер. Шулай булгач, шул зур сумманы кечкенә процентлы банкларда яткырганчы, шуңгарга шул нимесләрнең йирләрен, бакчаларны алсалар, файдамыз күбрәк булмас идемени? Вәкыф идарәсе шул йирләре тотуны үзенә мәслихәт тапмаса, шуларны йирле мөселманнарга вакыты берлән сатканда, файдасыннан матди, мөселманнарны йирле итүдә мәгънәви зур-зур файдалар итмәс идемени? Кырымдагы вәкыфларның хуҗасы хисап ителгән Кырым мөфтилеге шул мәсьәләгә дикъкать итте микән? Вә шул Духовный правлениенең әгъзалары шул форсаттан файдалану юлын күзәтteләр микән?

Юлы тугры килгәндә, шуны дә әйтеп китик: нимес колонияләре бер Кырымда гына түгел, алар Саратов, Самар, Уфа, Оренбург губерналарында бик күп иде. Монда да алар алдап-йолдап алган мөселман йирләренә, башкорт туфрагына утырганнар иде. Монда да алар шәһәрләр кебек авыллар мәйданга китергәннәр. Сөтле сыерлар, күп йонлы сарыклар, йөзәр пот тарта торган атлар җиткергәннәр иде.

Хәзер менә алар да бик күп йирдә китәләр. Бик күп йирдә йирләрен-суларын саталар. Күрше-тирә мөселманнары шуларның да йирләрен читләргә җибәрмәсәләр иде. Шундагы иске бабаларның урыннарына яңгы казык каксалар иде.

Тупрак көннән-көн кадерләнәчәк, көннән-көн кысылачагы игътибарга алынып, монда да шул форсаттан файдалансалар иде[1].

Хосусый бер мәктүбтә Архангельдан язалар: «Безнең Архангель шәһәрендә зурысы, кечкенәсе йөз егермеләп мөселман магазины бар. Боларның бик күбесенең сәүдәсе — ашау-эчү әйберләре, бакалейный маллар белән шәһәремездәге фрукта, мивә сәүдәсе бөтенләй мөселман кулында. Кырымнан, Төркестаннан, чит мәмләкәтләрдән мөселман сәүдәгәрләре әллә никадәр мивә китертәләр. Ишмаметовлар кебек зурлары Кырымда, Ташкентта бакчалар алып та эшләтәләр. Ләкин уртачаларымызның мивә сату-алуы һаман шул өченче, дүртенче куллардандыр. Гәзитәңездә Кырымда нимесләрнең йирләре сатылу хакында язылды. Шул йирләр бакчалы, бостанлы йирләрме? Әллә ашлык чәчә торган кырлы, яланлы йирме? Һәм дә йир-су алганда укмашып, бер-бер ширкәт итеп буламы?.. Шул йирләрне алышырга бер-бер банк ярдәм итәме?[2] [...]

Кырымның мивәсе Төркестан мивәсеннән алда йөргәнгә һәм дә безгә Кырымнан мивә китертү җиңелрәк, якынрак булганга, безнең уртача сатучыларымызга шунда бакчалар булу бик файдалы булыр иде.

Шуларга җавап язсаңыз ла».

Кырымда нимесләр кулындагы тупракның саны өч йөз мең дисәтинә чамасындадыр. Боларның зур утарлары берлән күп йирлеләре булган кебек, кечкенә-кечкенә дүрт-биш дисәтинәле кыр йирләре дә бик күптер. Боларның йир кәсепләренең күбрәге ашлык чәчү булса да, бакчачылары да, бостанчылары да бик күптер. Боларда бер фирма йирдән бертөрле генә иттереп файдаланмый. Ул ашлык чәчә торган йиренә иген чәчә, бакча утыртырга яраклыларына бакча ясый, бостанга муафигын бостанга аера. Тәмәке үсәчәк йирләргә тәмәке чәчә. Шуның өстенә шул фирмаларда төрле җенестән төрле-төрле хайваннар асрап, иң кыйммәтле, иң файдалы аяклы мал асрый. Ләкин бу нимесләрнең һәммәсе дә йирләрне сатмый һәм дә сатарга мәҗбүр түгел. 82 нче елдан соң Германиядән килгәннәре генә сата. Алай булса да, Кырымда нимесләр тарафыннан сатыла торган йир-суның исәбе-хисабы юк. Бәһаләренә килгәндә, Кырымда гадәттә йир бик кыйммәт булганга, бакчалар, бостаннар йирнең урта хисабы берлән дисәтинәсе мең сум чамасында йөргәнгә, хәзерге көндә шул ук йирләрне 150 сумнан 200 сумга кадәр алып була, вә шуның өстенә фирмалардагы мал-туар, эшләү кораллары да ярты бәһасенә рәхәтләнеп-рәхәтләнеп сатылып торалар.

Боларның күбесендә бостан да, бакча да бар һәм дә эшләнеп беткән, өлгергән көенчә бар. Сатыла торган йирләр шулкадәр һәйбәт эшләнгән, бу көн акчаңны бирсәң, иртәгә бөтен өй җиһазлары, бөтен кирәге-ярагы берлән үз кулыңа күчереп, кереп хуҗа булган кебек, өченче көнне үк шул милектән файдалана башлый аласың. Шуларны алырга бер-бер банкның ярдәм итүе хакында аерым мәгълүматымыз юк. Шулай булса да, Урта Русиядә хәзер йортны, бар йир-суны залог салырга мөмкин булган кебек, әлбәттә, анда да мөмкин. Укмашып алу хакында законда һичбер төрле кысынкылык юк. Теләгән кадәр кешеләр, сәүдәгәрләр, бергә укмашыңыз да алыңыз[3]. [...]

Шуның өчен ул якка таянуны ташлап, үз башыңызга эш итү мәслихәттер. Сезнең кебек чабата берлән ыштырдан килеп, егерме-егерме биш ел эчендә зур-зур магазиннар иясе була алган, сәүдә галәмендә шулкадәр зур игътибар казана алган, иң шимальдәге мәсҗеднең манараларын күккә күтәргән иҗтиһадлы, тырыш Архангель мөселманнары, сез аңгарга мохтаҗ түгелсез[4]. [...]

Үзеңез эшләңез. Кырым үзенең шул җәннәт бакчалары берлән сезнең кебек армый-талмый торган инсафлы сәүдәгәрләргә, эшлекле кешеләргә мохтаҗдыр. Бакча вә бостаннарын идарә итәр өчен кеше, ышанычлы, эшлекле кеше табу Кырымда бик җиңгелдер. Кырым агай-энемез, Аллага шөкер,

бабайларымыздан килгән тугрылыкны, иминлекне тәмамы берлән саклап килгәнгә, аларны ширкәткә кушу яисә бакча башы ясау бик уңгайдыр. Кыскасы гына, Кырымдагы бакчалар, бостаннар — сезнең кебек уңган сәүдәгәрләргә, акча хисабын белә торган, малның кадерен таный торган сатучыларга мәңгелек бер хәзинәдер һәм дә көннән-көн кыйммәте, бәһасе арта торган хәзинәдер. Арыган чакта балаңыз-чагаңызга мая җыяр өчен, үзеңезгә буш вакытыңызны рәхәттә үткәрер өчен Алла тарафыннан бирелгән дөнья оҗмахыдыр. Ләкин җитди бер эшеңез булса, эшкә тиздән башларга вә язып, сөйләп тормаенча, урынына барып, күз берлән күреп эшне эшләргә тиештер. Чөнки андагы йирләр бик кадерле, бәһале булганга, бездән дә уңган халыкларның кешеләре күптән инде алып торалар. Вә иң яхшы йирләрне берәм-берәм чүпләп торалар. Шуның өчен озак сөйләп торсаңыз, без барганда анда туйның дөмберенә очрамас өчен, тиздән юлына керешергә тиештер.

## ИКЕНЧЕ АДЫМ

Карс мөселманнарына ярдәм эше икенче бер адым атлады. Ул да Карс мөселманнарына ярдәм итәр өчен, Баку «Җәмгыяте хәйрия»сенең тырышуы буенча, Кавказның «Гомумярдәм җәмгыяте»нә ике мөселман вәкиленең кабул ителүе. Икенчесе — Карс мөселманнарына матди вә тыйбби ярдәм өчен аерым һәйәт җибәрергә рөхсәт бирелүедер (гәзитәмездәге хәбәрләр кыйсемендә)[1]. Бу рөхсәт аркасында ярдәм мәсьәләсе мәгълүм бер интизамга куелачактыр. Вә ярдәм итү үземезнең мөселманнарның кулына тапшырылачактыр.

Баку мөселманнарына үзләре карап ярдәм итәргә, үзләре кирәкле тапкан урынга тотарга ирек бирелде. Хәзер бурычымыз — шул изге эшне мөмкин кадәр тулы, мөмкин кадәр киң иттереп эшләү, булдыра алдыгымыз чикле бөтен мохтаҗлыкларны бетерергә тырышудыр. Өе җимерелгән, ватылган, ашамагы-эчмәге таланган, караучы ирсез, сакчы атасыз калган тол хатыннар, ятим балалар арасында авыруның төрле-төрлеләренең күплеге табигыйдер. Болар арасында йогышлы чирләрдән дә тиф кебекләренең булуы бик мөмкиндер. Шуның өчен анда бер тыйбби һәйәт күндерергә тырышу бик муафикъ, бик мәслихәттер. Мәскәүдәге Карс мөселманнарына ярдәм итә торган даирәләргә Баку «Җәмгыяте хәйрия»сенең рәисеннән, медиклардан никадәр студент, курсистка бара алуы хакында сорап телеграм алынды. Алты студент барачаклары белдерелеп җавап күнderelде вә берничә курсистканың да, һәйәт тәшкил итеп бетсә, барырга разый булачаклары мәгълүм булды. Димәк, шул тыйбби һәйәт, иң дөресте, санитарный отрядның хәзерләнү юлына керешелде. Иншалла, Урта Русия мөселманнарының матди вә мәгънәви ярдәмнәре аркасында Бакуның шул карсларга ярдәм һәйәте шул эшне булдырып мәйданга чыгарыр. Бу рөхсәт алынгач, тагы яңгы бер вазифа, халкымызның тагы бер бурычы арта. Ул да шунда атасыз-анасыз калган балалар-чагаларны мөселман иттереп тәрбия итәргә, үстерергә юл эзләү.

Бу мәсьәлә — акча берлән фәкыйрьләргә ярдәмнән тагы зуррак, тагы әһәмиятлерәк мәсьәләдер. Шундагы балаларның тәрбиясез калуы вә күп вакытта мөселман түгел кулларга алынуы гәзитәмездә берничә мәртәбә язылган кебек, бу номерымызда да «Икъбал» гәзитәсеннән күчерелеп бер мәктүб басыладыр[2]. Шуларның җыенысыннан алынган бер мәгълүмат, шулар тирәсендә туган бер тойгы булса, ул да шундагы меңләп-меңләп ятим мөселман балаларымызның чит кулларга китүенең ачылыгы, шул мескиннәрнең аталары-аналары, йортлары, йирләреннән аерылуга башка, милләтләре, диннәреннән дә чыгарга мәҗбүр булуларыдыр. Тәрбия итүчеләре, караучылары юкка шундагы сестраларның вә төрле йомшак күңелле рус итәргә яратучыларның кулларына сыгынуларыдыр.

Менә шул авыр мәнзарәләрне бетерер өчен, шул мескин мөселман балаларын мөселман рухында тәрбия итеп, мөселманча үстерер өчен, без моннан элгәреге бер номерымызда шуларның саны-хисабын белер өчен, шунда бер һәйәт җибәрелүне мәслихәт күргән идек. Шул һәйәт җибәрүне Петроградтагы бөтен җәмгыятьләрнең комитетыннан көткән идек. Шул һәйәт андагы ихтыяҗны белгәннең соңында андагы ятимнәрнең саны гадиден чамалаганның соңында монда бер карарга килеп, шуларның ярдәмнәрен кулга алырмыз дигән идек. Хәзерге көндә шул һәйәтне җибәрү Баку «Җәмгыяте хәйрия»сенең кулына алынганга, безнең ул вакыттагы теләгемезнең бер кыйсеме үтәлгән була. Ләкин без һаман әле шул Баку һәйәтенең эше зуррак булсын өчен, аның йирле түрәләр алдында мәгънәви бәһасе кыйммәтлерәк булсын өчен, берничә депутатның да шул һәйәт арасында булуын лязем дип беләмез. Бу фикерне әллә кайчаннан бирле алга сугып, мәкаләләремездә язып килсәк тә вә шул фикерне булдыруны без Петроградтагы комитеттан көтсәк тә, хәзер дә Баку җәмгыяте рәсми эшкә тотына алгач, шул вазифаны үтәүне аңгардан да көтәмез. Петербургтагы комитеттан да, шул бакулыларга ярдәм итәр өчен, фракциямез берлә сөйләшеп мөзакәрәгә керүне бик урынлы, вакытлы табамыз. Хәзерге көндә Карс мөселманнарына ярдәмнең баскычы

Бакудагы җәмгыятьнең җибәрә торган һәйәтенә матди вә мәгънәви ярдәм итү, Петроградтагы комитет шул бакулылар берлән бик якында торып, аларның эшләрен үзенең эше иттереп ярдәм кулын сузудыр. Фракциямез, шул Бакудагы комитетның чакыруын да көтмәенчә, үз тарафыннан берничә депутат җибәрергә хәзерлеген белдерү вә шуңгарга кешеләр хәзерләүдер. Әгәр тырышып-тырмашып хәзер шул һәйәтне андагы мәэмүр алдына кыйммәте мәгънәвиясе булырлык иттереп җибәрә алсак, бердән, шундагы ихтыяҗның ни дәрәҗәдә икәнен үлчәп кайта алыр идек. Икенчедән, бәлки, шундагы хөкүмәт мәэмүрләрен борчып тора торган мөселман авылларының таланмаганын саклар өчен гаскәрләр берлән каравыллар куеп торуның сәбәпләрен аңлата алыр идек. Шуның аркасында кирәкмәгән шул мәшәкатьне хөкүмәт мәэмүрләре өстеннән төшереп, аларга ярдәм дә итә алыр идек. Бу вазифаны үти алсак, халкымыз өстендә яңгы бер бурыч йөкләнәдер. Ул да — шундагы ятим балаларны тәрбия итү. Буңа кадәр булдыра алган кадәре Баку мөселманнары шул вазифаны азлап-азлап үтәп киләләр иде. Ләкин ятим бик күп булганга, аларның куллары да җитеп йитмәгәнгә, күбесе анда-монда әвәрә булып кала иде.

Хәзер дә шулай булмасын өчен ике генә юл бар: берсе — шуларны тәрбиягә итәрлек приютлар, ятимханәләр ачу, икенчесе — гаилә-гаилә шуларны бүлеп алу. Ятимханәләр ачу безнең мөселманда әле бик яңгы булганга, андагы ихтыяҗга җитәрлек ятимханәләр булдырыр өчен бик күп акча кирәк булганга, без хәзер шул балаларны гаиләләргә таратуны мәслихәт вә уңгай табамыз.

Кавказда, Идел буенда аз дигәндә дүрт-биш миллион мөселман гаиләсе бар. Боларга, әлбәттә, биш-ун мең ятимне генә йирләштерү авыр бер мәсьәлә түгелдер. Шуның өчен хәзер дә гәзитәләр аркылы кешенең күпме бала ала беләчәге, кемнең кыз баланы, кемнең ир баланы алырга нияте барлыгы беленсә вә шулар бергә җыелса, балаларны йирләштерү дә бик зур бер уңгайлык булган булыр иде. Шул мөселман балаларыннан берәрне яисә берничәне тәрбия итәргә яисә үзенә бала итәргә теләүчеләр табылса, без шуларны гәзитәмездә игълан итә барыр идек вә һәм дә шуларның исемнәрен, фамилияләрен, адресларын Баку «Җәмгыяте хәйриясе»нә җибәреп торыр идек*.

Балаларга киленсә, монда ятим калган балаларның иң күбесе лаз (рус гәзитәләре анчаз дип йөртәләр) балалары, ягъни грузиннан мөселман булган халыкларның балалары вә бер кыйсеме саф төрек балаларыдыр. Андагы төрекләр, лазлар табигатьләре, тәрбияләре буенча шул тирә халкының иң алдагылары хисап ителәләр. Болар — намус, пакьлек өчен җаннарын аямый торган, эшлекле, тырыш пакь мөселманнардыр. Кыяфәтләре, төсләре берлән дә дөньяның беренче дәрәҗәдә матур, эре халыкларыннан танылалар. Тәрбиядә уңгайсызлыктан куркылмасын өчен, ахырдан балаларның аталары-аналары табылып кайтарылганда уңгайсызлык тумасын өчен шуны да әйтергә кирәк: бу халыкның һәммәсе сөнни мәзһәбендә булганга, безнең Идел буе мөселманнары өчен монда да авырлык булмаячактыр.

Бу көнге гәзитәмездәге кебек вакыйгалар күбәймәсен өчен, Идел буе мөселманнарының саф күңелләре шул ятимнәрнең күз яшьләрен сөртергә, шул өшегән, каткан ятим балаларның күңелләрен ислам тәрбиясе берлән елытырга ашыгу тиештер.

Бу — безнең милли, дини бурычымыздыр. Бу — безнең ватанымыз алдындагы вазифамыздыр.

## ГАБДУЛЛА КАРИЕВ

Бүген Казанда мәшһүр артистымыз Габдулла Кариевның бенефисы булачактыр. Габдулла Кариев, сигез елдан бирле кышын-җәен белмәенчә, көзен-язын аермаенча, театрымызда эшләп килгәнгә арыган. Ул татарның амбар өчен ясалган бинасында театр сәхнәсе куйдырыр өчен маташа-маташа суык тидергән, хасталанган, тамагын бетергән. Докторлар аңгарга шактый озак хәл җыярга кушалар, шактый күп вакытта да сәхнәдә уйнамаска мәслихәт итәләр.

Ул бүген үзенең тудырган сәхнәсендә, үзенең юктан бар иткән «Сәйяр» труппасының уртасында, Казан шәһәрендә саубуллаша. Габдулла Кариевның талантын үстергәндә бик күп ярдәм иткән, Габдулла Кариевның татар дөньясында беренче труппасын тудыруга мохит биргән Казан, Габдулла Кариевка сәхнәне калдырып китәрлек авыру бүләк иткән Казан, бүген үзенең зурлыгы, кечкенәлеге, елысы, суыгы берлән аның алдында башын иеп тора.

Бүген Казан үзенең гаебен Кариевның шәхесе алдында гына түгел, зур бер милли көчемезгә каршы ителгән милли гаебен икърар итеп гафу тели. Ләкин Кариевның шул хәлендә сигез ел бербуйдан туктамаенча, ачлыкны, мохтаҗлыкны искә алмаенча, шималь буйларыннан җәяүләп йөреп, татар театрын тудырырга иткән хезмәтләрендә арка таяначак көчләр таба алмауда, арыганда җитәкләячәк, сөяленәчәк милли көчләр булмауда бер Казан гына гаепмеме? Юк, бу гаеп — бөтен татар дөньясының гаебе, бу гаеп — бөтен татар дөньясының үзенең тудырган җәүһәрләрен тәкъдир итә белмәүнең фаҗигасе.

Әллә кайдан чыккан бер шәкерт Алла тарафыннан биргән бер көч берлән театр ясыйм дип эшкә керешә. Артист юк, театр юк, аңлаучы юк. Иң авыры — шуларны булдырырга кирәк булган матди барлык та юк. Юк кына түгел, аның кирәклеген аңлаучы да юк. Аңларга тиеш булган сыйныф — укыганнарымыз, зыялыларымыз — бик олугланган булып, «безнең татардан берни булмый» дигән булып көлемсерәп карыйлар. Мөмкин кадәр зарар итәргә, театрның дәрәҗәсен киметергә тырышалар. Габдулла шул «юклар» арасында калмый, ул шуларга каршы «бар, бар, менә татар бар, менә мин бар» дип кычкыра вә, шул юклыкларын каплар өчен, бетмәс-төкәнмәс гайрәт берлән театр тудырырга керешә. Габдулланың шул «мин бар» дигән азанын ишетеп, аның янына театр тудырырга теләүче әхлаклы егетләр, каһарман кызлар җыелалар. Алар, үзләренең декорацияләрен, үзләренең гримнәрен букчаларына төяп, җәяүләп, татар дөньясы юлына китәләр, сәергә чыгалар, «Сәйяр» труппа ясыйлар. Мең бәла берлән шәһәрләремездә театрлар куялар. Бәла берлән рөхсәт алалар, донос ясамасыннар өчен, муллаларга, кущтаннарга барып ялыналар, ялваралар. Билетләрен йөреп-йөреп үзләре саталар. Габдулла шулар арасында иң күп эшли. Ул рөхсәткә үзе йөри. Йирле куштаннар берлән сәясәтне үзе йөртә. Репетицияләрдә үзе иң авыр рольне үзе ала. Шулай иттереп, уеннар уйныйлар гына түгел, көннән-көн уйнауларын тәрәкъкый иттерәләр. Боларның мәшәкатьләрендә, боларның эштән чыгып эшләгән чакларында сәерче яисә дошман ук булып торган татар бае, татар зыялысы «күңел ачар» өчен боларны карарга, йөрергә тәнәззел итә башлый. Ул аларны Мәкәрҗәдә самокатта куюларына бераз кашын-күзен җимерә. Ләкин шуны тотар өчен дә шул артистларның көндезен кинематограф күрсәтеп, идәннәрен үзләре юып, Нижний русларыннан җыйган акчасы берлән шул бай балаларына сәдакадан татар театры уйнаганын уйлый да алмый. Аңгарга каршы кул да суза алмый. Габдулла үзенең артистлары берлән тырыша-тырмаша үзеннән-үзе тудырырга маташа. Арый, туктый, йөди, йончый, эшне ташламый... Ул авырый, хәзер иптәшләре, дустлары көчләнеп аны хәл җыярга җибәрәләр, сигез елда шул дәрәҗәгә китергән татар театрын тәмам театр иттереп бетерер өчен хәл җыярга җибәрәләр.

Аны Казан озата. Казан гына түгел, бөтен татар дөньясы озата. Тиз кайтсын да башлаган эшне тәмамласын, диеп озаталар.

Габдулланың татар театрына иткән хезмәте безгә «Сәйяр» труппа ясап бирү генә түгелдер. Кырык корамадан бер труппа ясау никадәр авыр булса да, монда Габдулланың иткән хезмәте бик зур булса да, иң зур милли хезмәте безнең театрымызга милли рухны бирүдә вә милли типлар ясаудадыр. Аның ясаган типлары моңганчыга кадәр татар дөньясында һичбер күрелгәне юкка аларга кыйммәт бирүдән без гаҗизмыз.

Без Габдулла әфәнденең тизлек берлән савыгып, үзе сөйгән театрның башына яңгыдан кайтуын көтәмез. Үсеп килә торган театрымызда Габдулла Кариевның тагы яңгы-яңгы типлар тудырырга көч бирүен Алладан сорыймыз.

Сау булыңыз, Габдулла әфәнде.

## ӨЧ МӘСЬӘЛӘ

Сугыш аркасында килеп чыккан кизүдә ике мәсьәләмез бар иде. Боларның берсе — Петроградтагы җәмгыятьләр съездының карары[1] берлән бөтен Русия мөселманнарының шанына муафикъ сугыш сафына күчмә хастаханә җибәрү. Икенчесе — Карс вилаятендә көчләнелгән мөселманнарга ярдәм эшен рәткә кую иде. Бу көнге көндә шуларга тагы бер яңгы мәсьәлә килеп кушылды. Ул да — Кырымдагы кардәшләремезнең хатын-кызларының төрек тәбәгасы булып киткән мөһаҗир Кырым татарларына кияүгә чыкканнарының хәле. Беренче мәсьәлә хөкүмәт тарафыннан рөхсәт бирелгәч тә, Петроградта вакытлы мөселман комитеты тәэсис итеп эшкә кереште. Ягъни һәртөрле кирәкле, яраклы кәгазьләрне хәзерләп, үзенә акча берлән ярдәм итәчәк җәмгыятьләргә мөрәҗәгать итте, идарәи руханияләремез аша мәсҗедләрдә акча туплату юлына керде. Йирле комитетлар ясарга чакырып бәяннамәләр җибәрде. Хәзер һәр йирдә халык шул мәсьәлә тирәсендә сөйләнә, уйлана.

Съездны ясаттырган сәбәпләрнең берсе безнең Русия мөселманының ватан юлында итә торган иксез-чиксез ярдәмен бергә укмаштырып, бернәрсә иттереп, рус халкына вә хөкүмәтемезгә күрсәтү иде. Шуның өчен шул изге эшкә ислам төсе бирәсемез килү, аерым бер байрак астында эшләргә теләвемез дә табигый иде вә шул гомумхалыкның теләвен съездда кабул итеп «ля иллаһә иллә аллаһ вә Мөхәммәд Рәсүлуллаһ» дип язылган айлы байракны галәмәт иттереп кабул иткән иде. Русиянең төрле ягындагы мөселман халкы да шул күчмә хастаханә мөселман исеменнән була дип ярдәмгә хәзерләнә иде. Хәзер әле менә устав тасдыйк ителсә дә, төрле җәмгыятьләрдән вә башка мөселман даирәләреннән акча сорау башланса да, шул күчмә хастаханәнең мөселман кыяфәтендә булуы хакында бернәрсә дә мәгълүм түгел. Вакытлы комитет матбугатка съездның кабул иткән карарыннан бәгъзе маддәләрен хөкүмәтнең үзгәрткәнен сөйләсә дә (мәсәлән, Кавказда сугыштан зарар күргәннәргә ярдәм), шул ук эшнең ничек эшләнүе, элгәреге кебек

күчмә хастаханәме ясалуы, әллә башкача бер эш эшләнүеме һәм дә аерым бер мөселман байрагы астындамы, әллә башка бер төрлеме икәнен ачык әйтә алмый. Комитетның игъланында: «Съезд кабул иткән хосусый галәмәткә рөхсәт алу берлән мәшгульдер», — дигәнгә башка бернәрсә юктыр. Шуның өчен вакытлы комитетның ясап чыгарырга теләгәне шул эшне Русия мөселманнарының съездлары кабул иткән рәвештәме, түгелме икәнен белмимез. Халык арасында «бу мәсьәләдә төп фикердән бик күп читкә кителгән, вакытлы комитет аерым мөселман галәмәте кабул итүдән ваз кичеп, Кызыл Тәре җәмгыяте астына керергә булган» дигән хәбәрләр йөри. Болар, иншалла, дөрест түгелдер. Вакытлы комитет съездның карарын үзгәртергә хакы булмаганга, андый әсаста үзгәреш булса, әлбәттә, кирәк, матбугат аша вә кирәк, аерым бәяннар аша белдермәенчә булмас иде. Менә шул мәсьәлә, хәзер шундый томаннар берлән капланып торганга, халыкта һаман төрле фикер уятып, нишләргә белдермәенчә, аптыратып тотадыр. Шул эшнең эш булып чыгуы өчен вә шул эштә мөмкин кадәр күп җәмгыятьләр вә җәмәгать хезмәтендәге даирәләр катнашсын өчен вакытлы комитет шул мәсьәләне ачарга тиештер вә йирле «Җәмгыяте хәйрия»ләр алдында вә мөселман дөньясы алдында шул мөгаммәне бетерергә тиештер. Без вакытлы комитетның шул хакта ап-ачык бәянын көтеп торган кебек, бик күп шәһәрләрдәге җәмгыятьләр дә шуны көтеп, шөгъбәләр ачуның шуңгарга баглап кичектерүендә шөбһәмез юктыр. Шуның өчен, эш тиз эшләнсен өчен, җәмгыять эше җәмәгать белән җәмәгать теләгәнчә булсын өчен, йөзек яшереп уйнамаенча ап-ачык сөйләргә, әйтергә тиештер.

Икенче мәсьәлә: Карс мөселманнарына ярдәм үз юлында шактый гына күңелле бара. Вакытлы комитетның уставыннан хөкүмәт бу маддәне төшереп калдырганга вә вакытлы комитет тугрыдан-тугры катыша алмавы мәгълүм булды вә ярдәм эше Баку «Җәмгыяте хәйрия»се янында тәэсис ителгән шөгъбәгә тупланды. Хәзердә бөтен Русиядән агып килә торган ярдәмнәр шунда таба юлланыладыр. Бакулылар, шул эшне мөмкин кадәр теләгәнчәрәк итәр өчен үзләре тарафыннан һәйәт җибәрергә рөхсәт алдылар вә Кавказның миллият аермаенча качучыларга ярдәм җәмгыятенә ике мөселман вәкил кабул иттерә алдылар. Хәзер Баку «Җәмгыяте хәйрия»се шунда җибәреләчәк һәйәт янында санитарный бер отряд җибәрүне оештыру берлән мәшгульдер. Баку «Җәмгыяте хәйрия»се рәисенең Мәскәү укучыларына телеграмын вә укучыларның барырга разый булуларыны гәзитәмездә язган идек[2]. Шул мәсьәлә хәзер менә Петроград укучылары алдында мөзакәрә ителгәнен вә анда барырга разыйларның күплеген мәгалмәмнүнияять белдек. Башка шәһәрләрдә, әлбәттә, шул мәсьәлә мәйданга куелгандыр. Аннан да шул мәсьәләдә укучыларымыз бигрәк табибә, талибәләремез кулларыннан килгән кадәр ярдәмгә хәзерләрдер. Бу эштә укучыларымызның ярдәм кулларыны сузулары, үзләренең туганнарыны шундый мохтаҗ вакытларында хәтерләреннән чыгармаулары — милли вә мәдәни бурычлары булган кебек, ватаннары вә бөтен инсаният алдындагы да вазифаларыдыр. Иншалла, безнең укучыларымыз шул мәдәнилек имтиханында, әгъла дәрәҗәдә булмаса да, яхшы дәрәҗәсен тота алырлар, иншалла.

Матди ярдәмгә килгәндә, мондый эшләр бик күңелле бара. Русиянең бөтен тарафында ярдәм җыярга рөхсәтләр алына, бөтен шәһәрләрдә театрлар, концертлар, әдәбият кичәләре ясала. Бөтен авыллардан ярдәм туплана, бөтен көчләремез, куәтләремез бергәләшеп-берләшеп шул ятимнәргә, шул мескиннәргә шәфкатьле кулын суза.

Казандагы мөселман театры шулар файдасына ике мең сигез йөз сум бирде[3].

Оренбургта махсус комитет ясалды, эшкә дә кереште вә кыска гына мөддәттә биш мең сум иганә җыйды. Уфа театрыннан бер мең сум ярдәм алынды.

Петроградта 27 мартта зур бер вечер ясалачак. Кружок берлән махсус бер көндә ярдәм җыяр өчен һәм дә шул мөселманнарның хәлләренә күрсәтерлек лекцияләр укытырлык өчен рөхсәт алырга тәшәббес ителә (хосусый мәгълүматымызга караганда, рөхсәт бирелүе бик якын икән). Димәк, анда да зур-зур хәрәкәтләр эшләнә. Анда да шул ихтыяҗга җитешергә тырышылына.

Безнең Мәскәүнең генә хәле үзенә муафикъ дәрәҗәдә булмады. Карс мөселманнары мәсьәләсе чыккач, берничә мәртәбәләр мөзакәрәләр булды.

Кружок берлән җыйналу фикере булып та, махсус бер көндә халыкны мәсҗедләргә чакырып иганә җыю фикере алга атылды, вә аннан соң берәр театр ясап ярдәмгә җитешергә дә карар бирелде. Карар бирелде... Әмма... шул карарны эшләп бирергә күктән фәрештәләр төшмәде... Чит шәһәрләрдән кешеләр килеп эшләп бирмәде. Шуның өчен шул «карар» карардан үтмәде. «Җәмгыяте хәйрия» рөхсәт алыр өчен идарә әгъзасыннан берсенә тапшырды. Ул да прошениесене бирде дә шуның берлән бөтен эше бетте. Театр ясыймыз, дип йөрүче даирәләр дә сөйләделәр-сөйләделәр дә әллә кая югалдылар.

Шул эшләр тәмам беттеме? Әллә йоклап кына ятамы? Анысы безгә мәгълүм түгел. Шулай да Мәскәү «Җәмгыяте хәйрия»се шул мәсьәләдә, ичмасам, Мишә заводындагы мөселманнардан да артта калмаса иде! дип догада буламыз.

Өченче мәсьәлә: Кырым татарларының хатыннары мәсьәләсе. Кырымда бервакытны муллаларның аздыруы берлән бик күп кырымлылар Төркиягә һиҗрәт иткәннәр. Аларның йирләрен бушлай алыр өчен, шундагы төрле гакыллы башлар шул һиҗрәткә бик күп ярдәм иткәннәр. Ләкин күчкән кырымлылар, һава ярамаганнан бик тиз авырый башлагач, өйләренә борылып кайтканнар, йир беткән, йорт сатылган булса да, мәшәкатьләнә, маташа торгач, тагы оя корганнар.

Ләкин кайткан вакытта болар үзләре берлә бергә төрек тәзкирәсе (паспорты да) алып кайтканнар. Бу паспорт берлән һичбер төрле эшләре булмаган. Бөтен низагларын рус мәхкәмәләрендә күргәннәр. Көчләнүләрендә Русия мәэмүрләренә мөрәҗәгать иткәннәр.

Шуларның балалары, җитеп өйләнергә вакыт җиткәч, шундагы күрше-фәләннән кызлар алганнар. Кыз бирүче ага да, кыз алучы кода да: «Тукта, без бит икемез — ике мәмләкәт кешесе, Әхмәт — төрек тәбәгасы, Фатыйма — Русия тәбәгасы, монда без хокук, дәүләт законына гаид бер мәсьәлә дә тудырмыймызмы?» — дия уйламаганнар, уйлый да алмаганнар. Аларга шул Әхмәт һаман шул күрше Әхмәт булып калган, Фатыйма һаман күрше Фатыйма.

Төркия сугышы башлангач, яңгы мәнзарә туган. Фатыйманың агасын сугышка алып киткәннәр. Алар ватанны сакларга хөдүдләргә җибәрелгәннәр. Фатыйманың ирен, күрше Әхмәтне, «син — төрек» дип, Кырымнан сөргәннәр. Фатыйма аптырауда калган. Тагы үзенең әтисе, әнисе, кардәше, кабиләсе янына сыгынган, менә тагы яңгы әмер: төрек тәбәгасы хатыннарын Кырымнан сөрергә. Фатыйма инде нишли? Ул тел белми. Ул Кырымда гына яшәгән... Ул эш белми...

## ТУКАЙ МӘРХҮМ

Озакламаенча мәрхүм Габдулла Тукайның вафатына ике ел туладыр. Үткән елны шул көнне бөтен Идел буеның мәктәбе-мәдрәсәсе зур бер матәм көне ясады. Үткән ел шул көнне Идел буеның бөтен аңлысы, зыялысы үзенең тойгысын, төшенчәсен сөйләп-җырлап бирүче бер әгъзасының юклыгын, үзенең уен-фикерен шигъри бер җепкә тезеп бирүче милли шагыйренең арасыннан киткәнлеген бик нык хис итте. Ул да шул көнне матәм тотты. Ул да шул көнне зур бер милли кайгы көне икәнен сизенде, пошынды, кайгырды. Идел буе дөньясының хәзрәте, мулласы да, бик озакка кадәр бөтен милли эшләрен гөнаһ дип карый торган имамы да, бөтен изгелекләр, бөтен олуглыклар искедә генә булган, бөтен зур кешеләр кадимдә генә яшәгән дип игътикад иткән мөдәррисләре дә шәһәрнең мәктәпләрендә, мәдрәсәләрендә, китапханәләрендә падишаһлык сөргән Тукай алдында, авылының мөгаллиме, мөгаллимәсе, шәкерте алдында гына түгел, авылның урамына да тәэсир иткән Тукай алдында башын имәенчә булдыра алмады. Ул да Тукай мәрхүмнең рухына дога кылды. Ул да Тукай мәрхүмгә багышлап мәчетләрдә хәтем әйтте.

Бу ел да, әлбәттә, шулай булачактыр. Бу елда да авылында, шәһәрендә, мәктәбендә, мәдрәсәсендә Тукай кичәләре ясалачактыр. Бу ел да шул мәрхүм шагыйрьнең тәрҗемәи хәлләре, иткән хезмәтләре саналачактыр. Бу ел да аның менгән урынының зурлыгы, биеклеге күрсәтеләчәктер. Бу шулай булырга тиештер. Шулай булачактыр.

Бер быел гына түгел, еллар, ун еллар, йөз еллар шулай барачактыр, шулай китәчәктер. Бу — табигыйдер, бу — мантыйкыйдыр. Бу — Тукайның олуглыгына, иткән хезмәтенең зурлыгына мөнасибтыр. Көннең-көнендә матур милли бер шигырь багышлый торган сигез еллык хәятында[1] күрмәгән кадерне, ихтирамны Тукай мәрхүм үзенең мәрхүм булуы берлән бердән алды[2]. Авыр тартышлы тормышта — төчесеннән битәр ачысы күп, матурыннан битәр ямьсезе күп тормышта ирешә алмаган дәрәҗәгә Тукай бердән иреште. Аның дусты-дошманы, аның барлыгына сукыр күз берлән караучы милләте бердән күзләнде. Милли тормышындагы шул зур зыягның сәбәпчесе үзе икәнен хис итеп, үзенең вөҗдан тавышын басар өчен: «Яшә, Тукай, яшә, Тукай!» — дип кычкырырга кереште.

Тукайның мәктәп, китап аша бөтен Идел буеның тамырына җәелә торган, җәелгән шигырьләре, милли моңнары шул кычкырыш-бакырыш берлән иң тупас колакларга да ишетелде. Көннән-көн Тукай мәрхүмнең тәэсире тирәнәя барган кебек, көннән-көн Тукай мәрхүмнең милли рухы бөтен татар яшьләренең җанын, рухын ашлый барган кебек, көн үткән саен аның кыйммәте дә күтәреләчәктер. Аның татар милләтенә хезмәте, әйтеп калдырган байлыгы меңнәр, йөзәр меңнәр мәртәбә артачактыр. Аның су чишмәсенең төптән бәреп чыга торган тамыры өзелсә дә, аның су буйларымызда җырлап агуы бетәчәк түгелдер. Аның төптән килми, артмый торган шигырь хәзинәсе алган саен кимеми торган, алган саен саклана торган милли зәмзәм коесына әвереләчәктер. Шул зәмзәм коесының тирәсендә бик күп еллар, йөз елларга кадәр сусаганлыкларын бастырырга теләүчеләр булачаклар. Суга теләнергә, пакьләнергә теләгәннәр пакь су табачаклар. Авырулы күзенә сөртү нияте берлән килгәннәр күз авыруыннан дару табачаклар. Үзләрен-үзләре ничек олыгайтырга, шөһрәт чыгарырга юл тапмаенча йөри торган, үз урынын

таба алмаган дан сөючеләр дә ул зәмзәм коесын былчыратып, шөһрәт чыгарган гаребкә иткән хезмәтен иттерәчәкләрдер.

Тукайның зурлыгы алдында бөтен кечкенәләр, бөтен ваклар мыж киләчәкләр. Бөтен хәшәрәтләр, аның төрле тарафында төрле төстә җыелып, «Без Тукай берлән икәү» дигән хассиятьне калдырыр өчен әллә никадәр маташачаклар. Берсе: «Шәкертем Тукайга әйттем», — дип йөриячәк. Берсе: «Без Тукай дус берлән кочаклашып, табигатьне карап ләззәтләнә идек». Берсе: «Мин, Тукай килгәч, син бит, Габдулла, миннән азрак сабак укымадың, менә минем фәлән мәкаләмне укы әле, фәлән китабымны моталәга ит әле, дип әйттем», — дип мактаначактыр. Бу — табигый бер эштер. Авыл сабан туенда батыр калган егетнең кодасы-кодачасы күбәйгән кебек, тормыш тартышында да шундый ихтирамны алган кешенең дусты, хәлфәсе, туганы, җан дусты күбәячәге дә билгеледер. Тукай да шулай булачактыр. Аның хакында дөрес-ялган әллә никадәр сүз сөйләнеләчәк. Әллә никадәр юллар язылачактыр. Ләкин шул сүзләр, шул язулар арасында көнче кешеләргә язык булырлык бик күп материал табылса да, шуларның начар тәэсире мәктәбемезгә керергә тиеш түгелдер вә сыйныф балаларымызның күңелендәге матур, пакь шагыйрь Тукай дигән идеалны былчыратмаска, керләтмәскә тиештер. Бу вазифа бөтенләй мөгаллимәләр вә мөгаллимнәрнең өстенә йөкләнелгән милли бурыч булганга, алар шул мәсьәләдә бик сак булырга тиештер. Тукайның вафатына ике ел тулу берлән ясалачак мәктәпләрдәге Тукай кичәләрендә балаларның күңелләрендә иң матур хис уяндыра торган, иң пакь бизәкләр берлән бизи торган сүзләр, шигырьләр укылырга тиештер.

Тукай безнең яңгы, мәдәни, милли тормышымызның иң зур нигезе булганга, аның тазалыгы, аның пакьлеге баланың күңелендә бик нык утырырга тиештер. Аның олуглыгы, аның бөеклеге безнең милләтемезнең бөеклеге, олуглыгы белән мөнасиб булганга, ул үзенең олуглыгы кадәр пәрдәсен ачарга тиештер. Шуны булдыру, шуларны эшләп баланың күңеленә сеңдерү — мөгаллимәләр вә мөгаллимнәрнең бурычыдыр. Милли-мәдәни вазифадыр.

## РУСИЯ МӨСЕЛМАННАРЫ*

Без, Русиянең күп кабиләле мөселманнары, үзенең уннан тугыз составында бер төрки-татар кабиләсенә керүче һәм аңлашылмый торган тарихи сәбәпләр нәтиҗәсендә Татар бугазыннан алып Мурманга кадәр булган империянең бөтен чиксез киңлекләренә таралган мөселманнар, гаҗәп хәлдә.

Әмма мәрхәмәтсез тәкъдир бездә милли үзаң тәрбияләде һәм, шунысы гаҗәп, гасырлар дәвамында чиктән тыш нык үзсаклау көчен үстерде. Шуңа күрә мәдәнияте безнекеннән югарырак дәрәҗәдә булган халык арасында яшибезме, әллә мәдәни үсеше түбәнрәк дәрәҗәдәге кабиләләр белән бәйләнештә булабызмы, хисләр белдерүдә һәм кабул итүдәге психологик үзенчәлекләрне һәм фикер йөртүдәге үзгәлекләрне саклап, һәр җирдә һәм һәркайда үзебезгә тугрылыклы булып калабыз. Музыка сәнгатебез, җырларыбыз Иран шигъриятенең күпгасырлык кысрыклавына бирешмәде. Туган телебез мөселман дөньясында мәдәни һәм дини яктан зур әһәмияткә ия булган, бай гарәп теле алдында да артка чигенмәде. Үзләштерүче славян мәдәнияте йогынтысы астында да үз холкыбыз үзгәрешсез калды. Күзгә күренми торган, әмма каты рәвештә гасырлар дәвамында барган халыкларның көрәшендә без җиңелмәс булдык: көрәш безне бердәм ясады, бердәмлек киләчәккә өмет тудырды, иҗади башлангычка азык бирде. XX гасырга аяк басканда, без җыйнак милли-мәдәни берәмлек буларак чыгыш ясыйбыз, ә гасыр башының каршылыклы җәмгыяви омтылышлар мәйданында исә тирән милли үзаң һәм барлык матди һәм әхлакый атрибутларга ия булган милләт буларак калкып чыктык.

Искереп беткән укыту ысулы белән эшләүче мәктәпләребезне башлангыч дөньяви училищеларга, схоластик мәдрәсәләребезне рухани семинарияләргә һәм укытучылар институтларына үзгәртеп, соңгы унбиш елда педагогия өлкәсендә эшләргә туры килгән реформалар чын мәгънәсендә тарихи батырлык булып торалар. Сыйфат һәм сан ягыннан үсеш алган һәм күпчелек Аурупа халыкларындагы кебек әһәмияткә ия булган беллетристик һәм фәнни-педагогик әдәбият өлкәсендәге казанышларыбыз милли иҗади эшләрнең мөһимлесе булып тора.

Милли театр оештыру, милли типлар эшләү, зур талантлар тәрбияләү, музыка сәнгатен милли опера дәрәҗәсенә үстерү милли-мәдәни иҗат эшенең өстәмә чагылышы булып тора. Әлеге эшне башкаруда гаять зур киеренкелектәге көч таләп ителүен, читтән бернинди дә, һәм матди, һәм рухи ярдәм булмавын искә алсак, яңа башлангычларны булдыру өчен иске ныклы нигезләрне җимерергә туры килүен, бюрократиянең һәлакәткә китерүче салкын кулы белән кадими руханиларыбызның берлектә даими эш итүен игътибарга алсак, җитди, эндәшмәүчән, карусыз төрки-татар халкының эчке дөньясында нинди бетмәс-төкәнмәс көчләрнең яшеренеп ятуы билгеле булыр.

Бу мәдәни эш хәзер дә башкарыла һәм элеккечә киеренкелек белән алып барыла. Мөселман массаларының тормышы ару-талусыз, икеләнүсез, эчке каршылыктан башка көчле ташкын булып ага, һәм аның юлындагы бар нәрсә шулкадәр яңа, тормышчан һәм гүзәл. Үз тарихында берничә тапкырлар кабатланганча, рус җәмгыяте әйләнә-тирәсендә барган хәлләргә игътибар бирми калдырды, дәүләт эшләрендә җитди катнашучы булган күпгасырлык күршесендәге эчке үзгәрешләрне абайламый калды. Кызганычка каршы, бу вакытка кадәр мөселманнар турындагы иске күзаллаулар кулланышта, хәзергәчә безне Екатерина патшаның иске аршыны белән үлчәүдән, кулланылыштан чыккан ассигнацияләр белән бәяләүдән туктамадылар. Көтелмәгән зур аңлашылмаучылык, каршылыкларга китереп чыгарырга сәләтле, кыйммәтләребезгә булган үтә гаделсез мөнәсәбәт, безнең фикеребезчә, рус матбугатының безгә карата нормаль булмаган, зәгыйфь игътибар күрсәтүендә күмелеп ята. Безнең белән башлыча миссионерлар һәм Көнчыгыш белгечләре кызыксына. Аларның беренчеләре профессияләре белән бәйлелектән безнең нәрсә эшләвебезгә һәм иҗат итүебезгә объектив мөнәсәбәт белдерә алмыйлар, махсус миссионер һәм уң тарафлы матбугат битләрендә безнең яшәешебезне чагылдырып, үзләренең объектив вөҗданнары мөмкинлек биргән дәрәҗәдә хакыйкатьтән ераклашалар. Археологик фикер йөртергә генә сәләтле икенчеләре мәдәни иҗат уңышларына 300 елдан да иртәрәк лаеклы дәрәҗәдә бәя бирә алмый, ә объектив критерияле, нормаль фикер йөртүче (акыллы) рус интеллигенциясе беркайчан да безгә килмәде, дуслык та, дошманлык та белдермәде. Үз халкы эчендә эш белән күмелгән аз санлы зыялыларыбыз исә рус җәмгыятенә беренче булып килә алмый иде. Бер яктан, төрки-мөселман дәшмәүне алдан ук уйлап, кулай күрә иде, икенче яктан, тышкы сәбәпләр басымы астында. Әмма хәзер рус җәмгыяте фикере каршына чиратка милли проблемалар куелганда, мөселман интеллигенциясе үз халкының төп өлеше буларак, читтән карап торучы булып кала алмый һәм үзенең зәгыйфь көчләрен туплап, рус җәмгыятен төрки-мөселманнарның милли-мәдәни омтылышлары һәм өметләре белән таныштыруда кулдан килгән кадәр катнашырга, шулай ук үзара аңлашу, килешү һәм ихтирам нигезендә Империянең төрле халыклары арасында дустанә мөнәсәбәтләр үстерүдә булышлык күрсәтергә тиеш.

## МӨФТИЛЕК МӘСЬӘЛӘСЕ ӘТРАФЫНДА

Соңгы вакытларда рус һәм мөселман матбугатында яңгы гына Оренбург мөфтилегенә тәгаен ителгән Баязидов хакында һәм аның тәгаен ителүенә мөселманнарның карашы тугрысында бик күп хәбәрләр чыгып тора. Күптән түгел генә «Уфимская жизнь» гәзитәсендә Сабир мулла Хәсәновның[1] бер мәктүбе басылып чыкты. Ул: «Могтәдил мөселманнар яңа мөфтилекнең куелуына шатланалар, тәрәкъкыйпәрвәрләр генә моннан разый түгел», — ди. Халкымызның сәгадәтен алга баруда дип белдегемнән, мин дә үземне шул тәрәкъкыйпәрвәрләр җөмләсеннән санамый хәлем юк. Минем болай саналырга хакым барлыгына мулла Хәсәнов та бәхәс итмәс дип уйлыйм. Шуның өчен мин шул тәрәкъкыйпәрвәрләр исеменнән сөйләүне үз өстемә алырга батырчылык кылам һәм Хәсәнов белән башка «могтәдил» мөселманнарга әйтәмен ки, без Баязидовның мөфтилеккә тәгаен ителүенә шатланмыймыз гына түгел, бик нык кайгырамыз. «Могтәдил» мөселманнарның шатлануына Баязидовның нинди иҗтимагый сыйфатлары сәбәп булгандыр, мин анысын белмим. Ләкин безнең кайгыруымызга сәбәп булган нәрсәләр бик билгеле, аларны яшерергә мин тиешле дип уйламыйм.

Мөфтилек башында торучының халык арасында йитәрлек игътибарлы, нөфүзле, иҗтимагый абруе саф һәм үзенә ышаныч казана алырлык булуы тиеш дигән әсаска каршы килүче, шаять, булмаса кирәк.

Хәятның мәгънәви көчкә генә бирелә торган якларын идарә кылырга чакырылган кеше — мөфтилек башлыгы, халык аңарга ышанмаган вакытта һәм ул, үзе халык белән мәгънәви мөнәсәбәттә булынмаганда, үз өстенә салынган вазифаны камилли алмый.

Баязидовның мөфтилеккә куелуына шул югарыда сөйләнгән әсаслар ноктаи нәзарыннан караган вакытта, безнең кайгыруымызның сәбәбе тәмам аңлашылачактыр.

Баязидов Русия мөселманнары арасында һичбер игътибарлы кеше түгел. Соңгы ун ел эчендә мөселманнарның шулкадәр киң мәдәни вә иҗтимагый хәрәкәтләре, һәммәсе аны бер якта калдырып китүе моңа зур дәлилдер.

Ул бу эшләрдә бөтенләй бер як читтә калды. Бу хәрәкәт дәверендә дөньяга килгән мөәссәсәләр, мөселманнар тарафыннан ясалган төрле съездлар, киңәш мәҗлесләре, комитетлар, мәгариф җәмгыятьләре, хәйрат мөәссәсәләре вә башкалар үзләренең йитәкчеләре арасында түгел, хәтта гади әгъзалары арасында да Баязидовны күрмәделәр.

Мәдәни көче аз булган халыкның мәдәни хәрәкәтләренең башында Аурупа тәрбиясе күргән шундый кешенең күренмәве йә аның бик басынкылыгыннан яки аның тәмам игътибары юклыгыннан гына булырга

мөмкин. Бу эштә, тәэссефкә каршы, икенче тәфсиргә генә муафәкать итәргә тугры килә, чөнки аның юашлыгы хакында сөйләшергә мөмкин түгел. Үзенең билгеле юлына халыкны тартуга вә юлбашчылык кылырга тырышканлыгын татар телендә гаксы әл-хәрәкәтче — кирегә сөрә торган «Нур» гәзитәсен чыгару белән ачык күрсәтте[2]. Шулай ук «Сыйрател-мөстәкыйм» исемле бер партия тәэсис итеп[3], мөселманнар арасында «чын руслар союзы»на охшашлы бер иттифак ясарга тырышуы белән үзенең мәсләген ачык итеп мәйданга куйды. Бу ике эшне вөҗүдкә чыгарырга маташуы мөселманнар тарафыннан каршылыктан башка һичнәрсәгә очрамыйча сүнеп калган икән, анысын Баязидовның юашлыгыннан күреп булмый. Баязидовның игътибары юклыгының төбен мөселманнарның артык нәзбереклегеннән күрмичә, ялгыз Баязидовның иҗтимагый симасыннан гына эзләргә кирәк. Аның кем икәнлеге түбәндәге фактлардан ачык күренә. Мәсәлән, Мәхкәмәи шәргыянең[4] сөальләренә җавап биргәндә, ул иң артта калган руханилар фикерен яклап, ачыктан-ачыкка мөселман мәктәп-мәдрәсәләренә фән кертүгә каршы фикер бәян итте. Инородец исеме белән йөртелә торган халыкларга, шул җөмләдән үзенең диндәшләре булган мөселманнарга да һәртөрле кысулар чыктыгы хәлдә, һичбер тартынмыйча, иң гаксы әл-хәрәкәтче бюрократлар белән һәрвакытта якын мөнәсәбәттә булынды. Шундый танышлыклар вә шундый мөнәсәбәтләр, әлбәттә, кешегә вазифалар йөкли. Баязидов әфәндегә дә белгән мәгълүматларын биргәләргә тугры килә иде. Мөселманнар белән булган мөнәсәбәте аркасында ул мәгълүматларны алу аңгар авыр түгел иде. Моның нәтиҗәсендә күбрәк вакытта гаепсез көйгә ук хосусый затлар, хәтта матбугат органнары җәзаландылар.

Оренбург мөфтилегенең башы итеп Баязидовның куелуына минем чыннан кайгыруымның сәбәбен аңлау өчен шул сөйләгәннәр йитсә кирәк. Хәсәнов кул астындагы «могтәдил» мөселманнарның бу чаклы ашыгып күрсәткән шатлыклары, йомшак кына әйткәндә, гаҗәп бер эштер. Мөселманнар гына түгел, аларның чын дуслары булган башка милләт әһелләре дә, югарыда сөйләнгән хәлләрне белгәннән соң, бу шатлыкка кушыла алмаслар дип уйлыйм.

**БЕР ИЗАХ**

Язмышның золымыннан котылып, үзе теләгән ак-пакь дөньяга тырышып йөргәндә, Гыйффәт туташ үзенең туган авылы, кардәш-кабиләсе берлән тулган Әҗедә — һәрвакытта дүрт-биш йөз ак якалы ирләре, корсетның төрле-төрле модаларын белгән ике-өч йөз ханымнары булган Әҗедә һичбер төрле ярдәмче таба алмаенча, үзенә паспорт алышыр өчен дә волостька барышучы иптәшкә дә аптырап йөргәндә вә янындагы иптәше, ярдәмчесе Сәлимә туташ чит кеше булып, Әҗенең бөтен халкының шул милли җинаять алдында сәерче булып карап торган чагында коралсыз калганга, биш меңле мөселман эчендә ялгыз калган Гыйффәт туташ, юридически ярдәм сорап, «Вакыт» гәзитәсендә юристымызга мөраҗәгать итте, һәм гайн заманда ук хатлар, телеграммалар белән бәгъзе юристларымыз вә ярдәмче булырдай затларымыз чакырылдылар да, Алланың ярдәме берлән, биш мең мөселманнарның сәерче булып торган җинаятенә каршы русларның саф күңелләре чыдамады, князь Гагаринның ярдәме аркасында татар хатын дөньясындагы беренче шагыйрәмезгә игътибар бирелеп, аның каләменнән, муеныннан чылбыр алынды. Халыкны күрә торган судебный следовательләрнең инсафы берлән ике туташымызга караклыктагы ифтира, бөһтан, ялганлыгы беленеп, «икәүләп урлау» хакындагы судебный эшләре бетерелде.

Гыйффәт туташка паспорт бирелеп, ул укыр өчен, үзен киң дөньяга ачык күз берлән чыгарга хәзерләр өчен Мәскәүгә килде.

Мәскәүнең аңлылары тәкъдирнең язмышыннан золым күргән беренче шагыйрәмез Гыйффәт туташка дустлык кулларын суздылар. Аны урнаштырдылар. Аның тормышын тәэмин итәр өчен эш, көч таптылар. Хәзер, Аллага шөкер, Гыйффәт туташ үзен аңлаган дустлары арасында үзен-үзе яктырту, мәгълүмат тутыру юлында тырышып ята. Бөтен кирәк-ярагында хәзер ярдәм итешергә дуст-ише хәзер. Аның өеннән чыкканда матди хәле начар булса да, кирәк, шигырьләреннән килгән гонорар берлән, кирәк, дуст-ишнең җитәкче булуы аркасында табылган хосусый дәресләр белән бер дәрәҗәдә хәяты тәэмин ителде вә, аны кызганып, авылларда унбиш-егерме тиенләп җыелган сәдакаларга, әлхәмделилля, ихтыяҗ бетте вә, бетмәсә дә, Гыйффәт туташ авыл мөәзиннәренә рәкыйб булып, ул юлда сәдака җыюны кабул итәрлек дәрәҗәдә вак түгел, шуның өчен «Гыйффәт туташка ярдәм» дип, ун-унбиш тиен сәдакалар җыеп, гәзитә битләрендә шагыйрәмезнең исемен өстерәтеп йөртмәүләрен бик үтенәмез.

Моңгарчы килгән акчаларның һәммәсен Гыйффәт туташ җибәргән кешеләренә кире кайтара барды. Моннан соң да аны шундый кирәкмәгән хезмәттән коткару өчен шул борчуны бетерүне үтенәмез.

Үземнән шуны да әйтим: бер халыкның арасыннан бер шагыйрь, бер рәссам, бер артист, бер музыкант, бер галим чыкса, вә шул кеше хәл-әхваленең китеше берлән матди вә мәгънәви ярдәмгә мохтаҗ булса, шөбһәсез, милләт, милләтнең аңлылары аңгарга ярдәмгә йитешергә тиештер, фарыздыр.

Ләкин андый ярдәмнәр һичбер вакыт нечкә күңелле бер рәссамны хурландыру, ваксыту юлында булмаска тиештер.

Шагыйрьнең, мөхәррирнең, рәссамның, артистның фидияче мөәзин түгел икәнен аңларга вакыт йитте.

Яңгы чыккан һәрбер төрле милли байлыкларны иске үлчәүләр берлән үлчәп булмаганны, иске сәдака, савап чирләре белән яңгы милли байлык тудыручыларны чамалау аларны тәхкыйрь, мыскыл итү икәнен аңларга вакыт итте.

Шуның өчен язмышның кидешеннән әллә никадәр золым күргән Гыйффәт туташны милләтнең аңлылары рәнҗетмәүләре, сәдакалар белән аның баскан шагыйрьләр көрсисене ваксытмаулары, Гыйффәт туташның шәхесенә хөрмәттә, татар әдәбиятына хөрмәттә бурычларыдыр, үтәргә тиеш бурычлардыр.

## * * * (ИДЕЛ БУЕ МАТБУГАТЫНЫҢ...)

Идел буе матбугатының яше унберенчегә китә торган тарихи көннәрдә чыгарырга муафикъ булынган «Сүз» гәзитәсе фәүкылгадә хәлләр арасында мәйданга киләдер.

Унҗиденче ай дәвам иттереп киленгән канлы зур сугыш[1] укучыларымыз арасында дәрьялар кадәр күз яшьләре түктерергә сәбәп булган кебек, милли вә дини хәятымыздагы теләнелмәгән үзгәрешләр дә динне, милләтне сөйгән һәр татар баласының бәгырьләренә кара каннар берлән тутырган көннәрдер. Татар углы ватан мөхафәзәсендә баһадирча бурычын үтәп торганда, аның артында калган үз йортында, Идел буенда дини вә милли фәүкылгадә [illegible]!

Ватанымыз, дәүләтемез эчендәге, тыштагы эшләрен үтәүдә Русиядә яши торган бөтен халыкларның милли, сәяси организацияләре, русларның саф күңелләре берлән бергәләшеп, берләшеп ватанына, дәүләтенә, үз милләтенә хезмәттә бергә булганда, безнең бердәнбер легальный организацияләремез дә, мөселман фракциямез дә һичбер төрле эшкә катнашмаенча, үзенең барлыгын Дума хәятыннан сызды вә шуның аркасында милли, дини ихтыяҗларымызның иң кечкенәсе генә дә, иң кичектерергә ярамый торганы гына да мәйдане мөзакәрәгә куела алмады.

Егерме биш-утыз миллионлы Русия исламы телсез-тешсез кебек рус галәме, Русия әфкяре гомумиясе алдында мумия булып катты да калды.

Милли, дини хәятымыздагы шул күңелсез фактлар никадәр кайгылы булса да, шулар аркасында милли, дини теләүләремезгә никадәр зур киртәләр куелса да, әлбәттә, боларның һичберсе дә безнең милли, дини бурычымызны өстемездән төшермәде, билгакес, бөтен көчемез, куәтемезне җыеп, үземезнең милли, дини ихтыяҗларымызны булдыру юлында тырышуны лязем, фарыз итте.

Шуның аркасында татарның милли көчләренең иң зәгыйфе, иң яше булган татар матбугатына төшәчәк бурычның никадәр авыр, никадәр мөшкел икәнен тәҗрибәләр берлән белсәк тә, шундый тарихи көннәрдә Русия исламының хәят мәсьәләләре тарих имтиханына куелганда, вазифамыз башында булмауны вөҗдане миллиямез, намусы динимез кабул итмәде. Ходайсызлар, милли кяферләр падишаһлык сөрә торган татар хәятында ак-пакь эшне алып бару никадәр авыр икәнен белсәк тә, бөек Алланың олуг көченә сыгынып, ватык каләмемез, сынык күңелемез берлән бурычымызга тотындык.

Алла могыйнеңез булсын!

## КИЗҮДӘГЕ МӘСЬӘЛӘЛӘРЕМЕЗ

### I

Моннан унбиш еллар элек Казанның мөселман мәхәлләләренең кечкенә генә бер мәхәлләсенең кыска гына бер урамында, тәбәнәк кенә бер өйнең тар гына фатирында, пөхтә генә бер өстәл янына дүрт-биш кешелек кенә чәй мәҗлесе хәзерләнгән иде. Зыяфәт Оренбургтан килгән фикердәш, мәсләктән бер яшь татар берлән утырышыр өчен корылган вә Казан яшьләренең һәммәсе дә самовар янына тупланган иде.

Татарның шул вакыттагы тормышыннан разый булмаган, татарга әллә нәрсә ясарга төшенгән, татарны әллә нинди яңгы, нык бер халык итәргә хыял иткән бөтен көчләр, куәтләр берсе дә калмаенча җыелган иде. Ләкин шуларның һәммәсе дә нәни генә бер баланың бәләкәй генә кулындагы гөнаһсыз бармаклары саныннан — гадид ягыннан артык булмаса да, көч ягыннан да кечкенә баланың бармакларыннан куәтле

күренмәсә дә, уйлар, теләүләрнең яңгылыгы, аклыгы ягыннан да мәгъсум баланың тапсыз күңеленнән керсез иде.

Мәҗлес никадәр кечкенә булса да, сүзләр зурдан иде. Уйлар җирләрдән йөреп бетереп, күкләргә кадәр оча иде. Татарның укуы, укытуы, мәктәп-мәдрәсәсе, идарәи руханиясе, әдәбияты, матбугаты инәсеннән җебенә кадәр төшенелә, мөхакәмә ителә, юллар эзләнә, маяклар утыртыла иде. Һәммәсенең башында «халкыңа хезмәт итү» фикере ак-саф көенчә нурлана, һәммәсенең сүзендә шул пакьлек ялтырый, һәммәсенең йөзендә шул мәсләк аклыгыннан нур балкый, иман нуры ялтырый иде.

Монда сүз күп булса да, уй төрлечә акса да, мәсьәләләр кызык булса да, әфкяр һаман бер иде, нәтиҗә һаман шул иде: халыкка хезмәт итү, халыкны уяту, халыкны милләт ясау.

Булачак мөгаллиме, булачак мөхәррире, булачак җәмәгать хезмәтчесе асыл максатта мөттәфикъ иде. Тугры иттереп танылган юлда бергә иде. Озын-озын бәхәсләр, могарәзәләр булса да, боларның һичберсе мөхәррирнең әдәптән өсткә чыгарырга теләве өчен, мөгаллимнең җәмәгать хезмәтчесенә ярар өчен ителми. Мөгаллим, әдипнең фикеренә кушылса, аны якласын дип эшләми. Җәмәгать хадиме мөхәрриргә иштиракь итсә, гәзитәдә күтәрсен, мактый төшсен дип эшләми иде. Һәммәсе дә хаклык өчен, тугрылык өчен эшли, һәммәсе дә халкына файда булсын өчен дөрест дип уйлаган фикеренең хаталыгын икърар итә — һәммәсе икенчесе ясаган могарәзәне дустлыктан, иптәшлектән дип күз чытмаенча каршы ала. Ихласлы тыңлый, гайрәтле тартыша, фикеренең тугрылыгына ышандымы, хатасын икърар итә иде. Берсе оста иттереп үткән мәҗлестәге бер иптәш аның хатасыннан көлгәндә, үзе дә бергә көлешә, шул мәҗлестәге мохалифнең матур иттереп тәгъбир итүенә эченнән шатланып сөенә, аңгар кыйммәтен тәкъдир итә иде. Чөнки боларның теләкләре һаман әле теләк кенә булып күктә, хыялда гына яшәгәнгә, чөнки боларның уйлары эш булып дөньяның тупас урамнарыннан, пычрак чатларыннан өстерәлмәгәнгә, чөнки боларның шул ак-пакь фикерләре җиргә төшеп, татар тормышына кереп, шуның кысынкы ишекләреннән, кечкенә тәрәзәләреннән кереп-чыгып йөрмәгәнгә, төнлә берлән генә дошман күзеннән качар, күрмәгәндә генә үтәр өчен төндәктән, кече морҗа ашасыннан төшкәндә корымга, көлгә буялырга мәҗбүр булмаганга, су кебек сафлыгын, сөт кебек аклыгын, фәрештә кебек пакьлеген югалтмаган иде. Чөнки ул бөек уйлар, ул зур төшенчәләр — татар тормышының хәрчәүнәсеннән үткәндә, сасы куй мае исе сеңдермәгән, татарның мәдрәсәсеннән үткәндә, әчелеккә басып былчыранмаган, татарның кибетенең шүрлеге астында ятып керләнмәгән, татарның мирзасының өй алдында әвәләнеп яткан буяуларга буялмаган иде. Чөнки ул әле үзенең алмаз кебек балкуын, үзенең иман кебек күңелне нурландыруын бетермәгән иде.

Әле дә хәтеремдә, сәгатьләр үтә-үтә китәргә вакыт җиткәч, сөйли-сөйли кичләр үткәч, арамыздан берсе: «Менә хәзерге мәҗлестә тагы фәлән кеше, фәлән кеше килгән булса иде дә без, шулай сөйләшеп, мөхакәмә итеп торган өйнең түшәме җимерелеп төшеп, барымыз да үлсә идек, татарның милли, гыйльми хәяты егерме биш елга соңга калыр иде», — диде. Ул шул сүзне көлә-көлә әйтте, без шул сүзне көлә-көлә тыңладык, көлә-көлә «алай ук түгел лә» дип бәхәс иттек. Көлә-көлә «ул чын да хакыйкатьтән ерак түгел» дип куйдык. Инде аңгарга унбиш ел тулды. Бик күп айлар үтте. Бик күп сулар кичте.

Татар тормышыннан бик күп уйлар, фикерләр тәгәрәп-тәгәрәп, мәтәлеп-мәтәлеп үтте. Бик күп үзгәрешләр булды. Кул берлән тотылмый, күз белән күрелми торган яңгылык туды. Колак берлән күп ишетелми торган, борын берлән иснәлми торган бик барлар юк булды. Татар тормышы кызулап-кызулап тарих битләрендә тәгәрәргә, әле тауга бәрелеп, әле суга төшеп, әле чирәм өстенә кереп тәгәрәргә тотынды.

Татар тормышының йомшак кырыйлары, чыгып тора торган почмаклары юлындагы каты ташларга бәрелеп кырылды, татар тормышының чокырлары-чакырлары үтә барган юлында очраган сазны, чүпне, былчыракны да эләктереп, үзе берлән бергә алып китте. Шулай итеп, ул элгәреге кытыршылыкларын бетергәләп ялтырый төште...

Икенче яктан, сөякләре, тамырлары арасына юлдагы төрле чүп-чардан, зәһәрле агулар, хасталыкларның микробларын үз янына җыйды. Хәзер әле шул былчыраклар татар тормышының тәненең өстенә генә кунып, шуны былчыратып, ямьсезләндереп кенә торсалар да, шуның асыл матдәсен тутыктырып черетер өчен вә шуның ашасыннан үзәгенә үтәр өчен һәр көнне кимерәләр, җимерәләр, татар тормышының тышына ягылган, читтән килгән йогышлы авырулар да үзенең микробларын күбәйтеп, аның эченә керергә, йөрәгенә җитәргә вә шулай итеп бөтен канын зәһәрләргә, рухын агуларга маташалар. Инде ул мәҗлес иткәнгә унбиш ел үтте. Унбиш ел эчендә безгә идеал булып күренгән бик күп нәрсәләр, гади булып китеп, тормышымызга кереп китте. Без ул мәҗлестә уйларга хәтеремезгә килмәгән, килә алмаган әллә никадәр манигъләр, дошманнар туды. Ул вакытта күңелле иде, кызык иде. Мәсьәлә бер генә иде. Көч бер генә иде, бертөрле генә иде. Дошман да бер генә иде. Мәсьәләләрнең хәле дә бертөрле генә иде. Сәгадәткә ирешә торган юл да бер генә иде. Ул да — халыкны гыйлем, мәгариф юлына кертү, халыкны укытып, тәгассыб, наданлыктан коткарып, Аурупа мәдәнияте йимешләре бакчасына илтеп кертү иде.

Шуның юлы һәммәмезгә мәгълүм иде, ул да ысуле җәдид мәктәпләре күбәйтү, мәдрәсәләрдә тәгассыбны бетерерлек гыйлем, фәннәр кертү иде.

Ул вакытта дошман да бер генә иде. Ул да наданлык иде, халыкның наданлыгы иде. Халыкның наданлыгыннан килгән муллаларның наданлыгы, аларның наданлыгыннан килгән тәгассыбы иде. Безгә, шундагы биш кешегә дә, шул мәҗлескә чит шәһәрләрдә торып килә алмый калган биш кешегә дә шул идеал, шул гая гая иде. Шул дошман дошман иде. Мәҗлестәге биш кешене дә, килә алмаган биш кешене дә шул ак тормыш өчен тартышу җанландырган, рухландырган иде.

Унымызны да шул хаклыкның дошманнарына каршы тору фикере бер кеше кебек итеп, бер көч иттереп беркеткән, ныгыткан иде. Инде аңгарга унбиш ел үтте. Аннан бирле ысуле җәдид мәсьәләсе хәл ителде. Мәктәп мәсьәләсе кизүдән чыкты. Безнең фән кертәмез, гыйлем тудырамыз дигән мәдрәсәмез җимерелде дә бетте. Һичбер төрле хәят галәмәте күрсәтмәенчә үлде дә калды. Ул вакытта безнең хыялымызга китерә алмаган татар матбугаты дигән гамил туды да, үсте дә, ун елны да үткәрде. Татарның тәмам үз әгъзасы булып, үз хәрчәүнәсенә кереп, үз гайбәте эченә батып, үз хәйләсе, үз ваклыгына чумып, үзенең бөтен милли чирләрен ияртеп, кәкре аяклы, буш корсаклы, тавык гайрәтле булып, сабан туйларына барырлык малай булып, үзе кебек чалыш аяклы, зәгыйфь малайлар берлән перәннектән генә көрәшерлек булып, канителле кәләпүш киеп урамга чыкты. Аның җәмәгать хадимнәре хәзер ун гына түгел, йөзгә, берничә йөзгә җитте. Җәмгыятьләре, клублар, сәяси партияләре, озын өстәл янына җыелып, чәй янына утыртып, милли ашларга башка, сохари, бисквитлар ашый торган, иртәдән алып кичкә кадәр сөйли торган, бөтен мәгънәсез уйлар, фикерләрне көйли торган, баш авыртып, арып беткәч, курка-курка өенә кайтып, безне дә милләткә хезмәт итми дисәләр инде. Алла боларга ләгънәт итсен, дия торган ярма тегермәне, истимна урыннары булды.

Тагы тормыш элгәреге кебек, унбиш ел элекке кебек беркатлылыгын, берлелеген югалтты. Ул катланды, төрләнде. Хәл ителәчәк мәсьәләләр күбәйде, зурайды, киңәйде, тирәнәйде, барылачак юллар кырыкка аерылды. Сукмаклар сугылды. Болар бер кушылды, бер аерылды. Тартыша торган көчләр унга узылды, дустлар төрләнде. Алдакчысы булды, хәйләлесе туды, тугрысы чыкты, дошман хәйләләнде.

Дошман дуст, иптәш киеменә киенде, дошман, иптәш, дуст бара торган юлга кереп, «мин бергә, мин бергә» дип, йоклаганны көтәр өчен бергәләште. Мәсьәлә киңәйде, аның ботаклары күбәйде. Хәле дә бик төрлегә әверелде.

Шуның өчен унбиш ел элгәреге бер мәҗлес җиткән мәсьәләләргә җилд-җилд китаплар язарга, гәзитә тулысы мәкалә язарга мәҗбүрият туды вә шул мәҗбүриятнең кушуы буенча укучыларны шул чуалдыкта адаштырмас өчен мәкаләләр язу нияте табылды вә шуны тутырырга тотынылды.

**II**

Мәдәният тарихының гаҗәп бер кануны бар: ул да һәр мәсләк, һәр фикер туган вакытында, яшь чагында үзенең янына шул мәсләккә баштан аягына кадәр ышанган кешеләрне генә туплый. Һәр яңгы мәсләк, яңгы мәзһәб үзенең тарафына җыелган әгъзаларына искиткеч бер зур мәгънәви куәт бирә, аларны батырлык белән бизәкли.

Хәзрәти Гайсә галәйһиссәламнең хәвариюнын[1] алыңыз: бу унике әүлия баштан аягына кадәр хәзрәти Гайсә галәйһиссәламнең мөкатдәс фикерләре берлән ашланган түгел идеме?

Хәзрәти Мөхәммәд галәйһиссәлам янына тупланган сәхабәләрнең мөҗаһир әнсарилары Алла юлында бөтен дөньяларын оныткан, пәйгамбәре боерыгы өчен утта янмый, суда батмый торган каһарманнар түгел идеме?

Соңгы заманнардагы дини исляхәттәге Лютерның[2] бер уч иптәшләре, Аурупадагы фикер алышыну, сәясәт яңгару вакытындагы Жан Жак Руссо[3], Монтескьеләрнең[4] иптәшләре, Русия тарихында каһарманлык берлән шөһрәт тоткан һәммәсе дә шул канунга табигъләр иде. Һәммәсе дә, саннары берлән никадәр аз булсалар да, мәгънәви көчләре берлән шулкадәр куәтлеләр иде. Үзләренең дөрест дигән дини әсасларын сөйләүдә, фәлсәфи кагыйдәләрен таратуда арыслан кебек батырлар, шул уйларны аңлатуда күзләрне камаштырырлык ялтыравыклы куәткә маликлар иде. Ул гына да түгел, икенче бер фикер, икенче бер мәсләк берлән очрашканда, башка бер дин, гадәт ягыннан үткәндә таштан, тимердән катылар, икенче мәсләкләрнең сүзен, уен ишеткәндә ике колакка да саңгыраулардыр. Шуның өстенә яңгы мәсләк тарафдарлары һәрвакытта, һәр йирдә бер-берсе берлән мәгънәви көч берлән бик нык бәйләнгәнгә, аларда шәхсият-фәлән катгыян юкка, җыенысы бергә җыен җепләрдән эшләнгән аркан кебек, фәүкылгадә көчле булалар.

Хәвариюн, әсхабе кирам дин юлында үзләренең шәхси тормышларын, гаиләләрен, көн күрү мәнфәгатьләрен оныткан кебек, соңгы заманнардагы сәяси фиркалар — гыйльми үзгәрешләрнең әрбабы да мәсләкләре угырында бөтен тирә-юньнәрдән ваз кичкән кешеләрдер.

Хәвариюн, әсхабе кирам халыкның сәгадәте юлында үзләренең фидаи хезмәтләре өчен никадәр хөрмәтле булсалар, бу мәсләкләрнең әгъзалары да шулкадәр үк каһарманнар — батырлардыр, хөрмәтлеләрдер. Үзләренә нисбәтән шулкадәр үк адәм баласына хезмәт иткән затлардыр. Бөтен мәдәният тарихында гам булган шул әсас Төркиянең таркау вилаятьләреннән бер Юнанстан[5] ясар өчен тәэсис ителгән өч-дүрт грекның гизле җәмгыятендә, Рум иленнән мөстәкыйль Болгарстан ясар өчен оешкан Болгар кәмитәчеләрендә[6], Төркияне бүлеп алып калыр өчен мәйданга атылган төрек фидаиләрендә дә хөкемне йөрткән кебек, безнең Идел буе мөселманнарының да халкын коткарырга, халкы тын сулыш алсын өчен кояшка таба тәрәзә тишүчеләренә дә гамдыр.

Алар да шул фикер, мәсләк янында берләшеп, бергәләшеп, бер көч ясыйлар. Алар да, саннары азга карамаенча, ул вакыттагы гаммәнең дин зирәһлесе берлә коралlануына карамаенча, аларга һөҗүм ясыйлар. Берсе артыннан берсе гаммәнең сугыш сафларын кулларына төшерәләр. Гаммәнең ныгыган калалары булган мәсҗед-мәдрәсәдә хиссиятләрен киметәләр иде вә шуның аркасында диннәр таралган вакыттагы тизлек берлән мәсләкләрен тараталар иде.

Ләкин тарих, мәдәниятнең тагы икенче бер кануны да бар. Ул канун буенча һәр үскән яңгы фикер, һәр мәсләк, теләсә, ул тәгълим дине булсын, теләсә, фәлсәфи игътикад булсын, теләсә, икътисади, иҗтимагый, сәяси бер мәсләкнең хәрәкәте булсын, киңәя башлагач, үсә башлагач, аның әгъзалары элгәреге бергә бәйлануларын бетерәләр. Аның янына урынлашкан баһадирлар элгәреге гайрәтләрен киметәләр. Ул гына да түгел, шул мәсләк, шул фикер, үзе дөньяда йөри-йөри, төрле фикерләр, мәсләкләр берлән бәрелешә-бәрелешә, үзенең катылыгын югалталар. Акрын гына чит диннәр, дошман мәсләкләрдән гадәтләр, йолалар кабул итәләр. Бик күп вакытта шул дин, шул мәсләкнең әсасын аңламаган бер халык, бер кавем арасына төшеп, шуларның гадәтләре, йолалары арасында тоз күленә төшкән ишәк кебек эреп тә китәләр вә күп вакытта аннан да бернәрсә алып, үзенең төп йортыннан килгән бәгъзе бер әсасларны калдырып, яңгы бер уйдырма, яңгы бер «качыр»лар мәйданга китерәләр. Мәсәлән, исламиятнең әсасына мохалиф булган мистицизм(суфилык)ның таралуы — мистицизмга баткан фарсы мәдәнияте берлән очрашканнан килгән исламият өстендәге бер гөмбәдер. Мәдәният тарихының икенче кагыйдәсенең биргән йимешедер.

Шул кануннар берлән коралланып караганда, татар мәдәни хәрәкәте юлга чыкканда, татар мәдәниятчеләре татар тормышына кереп киткәндә, боларның үз мәсләкләрен саф иттереп алып барулары мөмкин идеме? Татарның элгәреге мәдәният каһарманнары — Насыйрилар, Мәрҗаниләр, Исмәгыйль бәкләрнең[7] эшләрен алып баручылар — алар кебек нык саглям булуы мөмкин идеме? Бу сөальләргә җавап бирер өчен ул вакыттагы татар тормышының мәдәни-гыйльми хәятын күздән кичерү, ул вакыттагы татар тормышындагы җанлы әгъзаларны санап карау җитәчәктер.

Болар — сәүдәгәрләр, руханилар, мирзалардыр вә боларга тән булып хезмәт иткән вә боларны ашатып-эчертеп торган игенче халыктыр. Боларның сәүдәгәр халкы татарда үзгәрү, алышыну уе туган чакта сүзендә тора торган, алдашмаенча сата ала торган, биргән вәгъдәсеннән кайтмас өчен никадәр зур булса, матди зарарны күтәрергә разый, аз йә сәүдәгәрлектән хөкемгә эләкмәсәң, ничек тә алдарга ярый дигән лозунгны алдына алган рус сәүдәгәр тибының вагына алышкан вакытында тугры киләмез.

Шәрекъ тугрылыгыны югалткан, Гаребнең эшлеклелеген таба алмаган бу кыйсем халыкны әхлак җәһәтеннән бик түшенке, фисык-фәсадның колы, куркак итеп очратамыз.

Руханиларны да озак вакытлар халыкны бабалары динендә саклап килә-килә арып беткән муллаларның мәхдүмнәре итеп күрәмез вә аларда да бабайларындагы динендә салат, дин әхкяменә күз йомып ышанудан бик күп дәрәҗәдә түбән, гадәт-йолалар ягыннан мөселман булса да, эченнән мөәлләфәтел-колүб* көенчә очратамыз. Өченче сыйныф — мирзаларның хәле тагы пәришан. Алар үзләренең мөселман икәнлекләрен аталары, аналары үлгәндә генә беләләр. Алар үзләренең татар икәнлекләрен дәрәҗә күтәрелер алдында кара сызык сызылгач кына тоялар. Ләкин һәр икесендә дә мөселманлыгы өчен дә, татар булганы өчен дә эче пошып, ачуы килеп, үзенең күбрәк эш итә торган рус мирзалары, хөкүмәт түрәләре арасында динене, милләтене яшерергә маташа иде. Аның мулла кушкан исеме Гали булса да, ул аны инде аны Александрга алыштырган. Аның атасы Сөләйман булса да, ул аны инде күптән Савельевич та ясап алган. Аңарда дини тәгассыб үзенең бәгъзе бер юллары берлән калган булса да, миллияттән эз дә, сүз дә юк. Бик йомшак иттереп тәгъбир иткәндә, мөселман — урыс. Авыл халкы — икенче халык. Болар гыйлем, мәгарифтән бик ерак булганга, динендә никадәр нык булса да, гадәтендә, йоласында, киемендә-салымында, ерында, көендә миллиятне бик нык мөхафәзә итү фикере, уе, гакылы берлән һичбер нәрсәне оештырып чыгарлык түгел.

Менә шул мохиттә мәйданга чыккан татар мәдәниятчеләре, менә шул дүрт бүлек халыкның уртасыннан туган татар милләтчеләре тап-таза бер көч булып үсә ала идеме? Шул тирә-юньдә үскән җәмәгать хезмәтчесе шул дүрт бүлек халыкның авыруыннан, чиреннән өстә тора ала идеме?

Авыруы булса, аның шул хасталыгы үсүенә манигъ булмый идеме?

Бу сөальләргә җавапны киләсе мәкаләдә озайта төшәрмез[8].

## III

Шул дүрт бүлек халык арасында туган, шул дүрт халыкның эчендә үскән, шул дүрт бүлек халыкның яхшылыгыннан яхшылык, начарлыгыннан усаллык, шул дүрт бүлек халыкның тазалыгыннан ныклык, хасталыгыннан авыру алган татар халкының баласы, татар милләтенең халыклар сабан туена көрәшер өчен чыккан үз егете нинди куәт, нинди көч берлән чыгуын белер өчен татар тормышындагы гаилә хәятына, Идел буендагы татарлар арасында хатын-кызның урынына күз ташлау вә шуны тәхлил итү ляземдер.

Чөнки татар хатыны ана булып, татар хатыны хатын, иптәш булып, татар хатыны бала булып, дүрт бүлекнең дүртесенә дә бик зур роль уйнаган бер әгъзасыдыр. Дүртесенең дә холыкта, гадәтнең, әхлакның куелуында, эшләнүендә иң зур көчтер. Чөнки хатын-кыз дүрт бүлекнең телен, шивәсен, ерын, көен, гадәтен, йоласын, киемен-салымын, иске әкиятләрен, табышмакларын саклауда вә шуларны буыннан буынга күчерүдә иң зур гамилдер. Шуның өчен татар хатынының татар тормышындагы хакыйкый (фактически) урынын тәгаен итү, аның тормышымызга ясаган тәэсиренең үлчәвен белү ляземдер.

Иске заманаларда төрек-татар хатыны үзенең сәяси-иҗтимагый тормышымызда ирләр берлән бер дәрәҗәдә булмаса да, бик зур иде, олуг иде. Болгар падишаһысына килгән гарәп һәйәтләрен, сәйяхларын язганда, падишаһ вә олугларның мәҗлесләрен сөйләгәндә, хатыннарның мәҗлестә хазир булуларын язалар. «Беренче хатын», «икенче хатын» дип йөртәләр. Руслар берлән татарларның мөнәсәбәтләрен язганда, сугышларын сөйләгәндә татар хатыннарына әллә никадәр урын бүләләр. Аларга бер көч иттереп карыйлар. Чынлап та, төрек-татарда хатыннар бер көч иде.

Милли хәятны бәйләүдә зур бер җеп иде. Ана мөкатдәс иде. Ана хөрмәте берлән ант ителә. Дошманны иң зур мыскыл итәсе килсә, ул анасы берлә сүгелә* иде.

Хатын иптәш иде, юлдаш иде. Гаилә хәяты, ир берлән хатынның мөнәсәбәте мөкатдәс иде. Дуст та, дошман да күзен салырга ярамый торган, ут та яндырмый, җил дә, су да ашамый торган өйнең нигезе иде. Гаилә ясау иске дә, яңгы да тормышның иң җитди бер адымы, ике якка да күп бурыч йөкләтә торган адымы иде. Һәм дә бөтен халкы, ыругы алдында, ыруглар бурычы ала торган яшь егет алдында, аның ыругы, халкы алдында мәгълүм хак бирә торган иҗтимагый бер эш иде. Шуның өчен безнең телдә «хатын алу — өйләнү» тәгъбир ителә. Ягъни өйле булу, өй ясау. Буйдаклык өйсезлеккә мокабил иттереп йөртелә иде. Буйдак теләсә кая китәргә, теләсә кая барырга хакы булса да, өйләнгән егетнең ул хакы кими, аның өстенә өй тәрбиясе бурычы йөкләнә иде.

Димәк, бездә өйләнү, өй тәэсис итү аерым бер тормыш ясау мәгънәсендә истигъмаль ителә вә шулай булып та чыга иде. Ир кәсеп итә. Мал ясый, хатын шул табылганны тота, өйне тәрбия итә, эчке ягыннан идарә итә иде. Кием-салым хәзерләү, аның төсе, буе, модасына игътибар итү, бәйрәмнәрдә аш-су пешерү, килем-төшем алдында ил гадәтеннән артта калмаенча кунак сыйлау, бала-чаганы искедән алып килгән гадәт-йола берлән тәрбия итү, аларга халыкның әхлак кагыйдәләрен сеңдерү, күптән өстерәлеп килә торган җыр-көйләрдә аларның тойгыларын симертү ананың — хатынның бурычы иде, өйләнүдән килгән ил алдындагы бурычы иде. Ул шул бурычны угыллары, кызларыннан «яңгы өй»ләр тудыру бурычын үзе аңламаенча да, аңлап та эшләп килә иде. Менә шул ана, менә шул хатынның киләчәк буынны тәрбияләүдәге ролен аңлар өчен, татар хатынының әхлакый кыйммәтен белү ляземдер. Татар хатынының татар иле каршысындагы бурычын үтәүдәге уңганлыгының бизмәнен карау ляземдер. Татар хатыны гаилә ясап, ашатып-эчертеп, киендереп, бала тудыруда гына түгел, шул «яңгы өй»не нык нигезгә куюда, шул буйдак татар егетенең рухына тәэсис итеп, аны «өйләндерү»дә, өйгә ияләштерүдә нинди куәтләргә малик иде? Татар хатыны бала-чагасын үстереп, үзе аңлаган бер тормышка хәзерләүдә нинди мәгънәви көчкә ия иде?

Бу мәсьәләне ачыграк аңлар өчен, Идел буе мөселманнарын икегә бүлмәенчә хәл юктыр. Буның берсе — татар, берсе — мишәрләрдер*. Тел ягыннан бер булган бу ике бүлек халыкны әхвале рухияләре ягыннан ике төрлелеген, гомум ил тормышында ике төрле роль уйнавын икърар итми хәл юктыр. Татарларның киләчәк тормышына итә торган тәэсирләренең урыннары башка-башка икәнен әйтеп китмәенчә мөмкин түгелдер**. Казан татар хатыны, кызлык яшьләренә җиткәч тә, киләчәктәге «өй»нең бер әгъзасы иттереп үстерелә. Ул шул яңгы булачак «өй» өчен җиһаз хәзерли. Ата-анасы өендә пансионда гына тора торган кеше, кунак кына кебек хис итә. Үзенең күрмәгән-белмәгән тормышына омтыла гына түгел, хәзерләнә. Ул

«өй»нең туена, төшеменә, бәйрәменә, салымына киемнәр, җиһазлар, кирәк-яраклар хәзерли. Кияүгә бирелдеме, атасы-анасы йортыннан тәмам бизә. Киткән вакытта җиңгәсе, тутасы берлән кырылышып әйберләр төйи, ачык ала, яшерен ала. («Киткән кыздан тукмак та кача» дигән мәкаль бу хакта чыккандыр.) Иренең өенә барып төштеме, анда аның каенанасы, каенсеңлесе, килендәше булса, ул, мотлакан, аерым чыгуны төшенергә тотына, сугыша-кырылыша, егълаша, сөя-көя, маллы, товарлы, сөтле йорттан чыга да үзенә «өй» кора. «Ач карыным, тыныч башым» дип, кечкенә бурага, йир асты өенә нигез сала. Чыны — аерым тора башлый, эшли, тырыша, «өй» ясый, йорт тудыра. Чөнки аның күңелендә «Миңлениса сыеры», «Миңлениса түтәле», «Миңленисаларның мәҗлес көне» дигән сүзне ишетәсе, күрәсе килү урынлашкан. Шуның өчен ул бай йортны да ташлый, шуның өчен ул аз эшләми, тук тамаклы тормышны да ач, фәкыйрь хәятка алыштыра. Чөнки үзеннән-үзе бернәрсә тудырырга, яңгы йорт тудырырга уйлый, уйлый түгел, аңламаенча, шул яңгы йорт тудырырга омтыла.

Шул йорт туа башлады. Ул, шуның капкасы Миңлесылуның капкасыннан ким булмасын өчен, келәте Фәхриҗамалларның келәтеннән начар булмасын өчен, йокысын, тынычлыгын бетереп эшли. Аш-су арасында күрше-фәләннән фәкыйрь күренмәс өчен төнен, кичен утыра, ягъни Казан татар хатыны өй тудыру, «яңгы өй» ясау идеясенә кол булып хезмәт итә. Ул гына түгел, ул шул идеягә үзенең күптән түгел генә буйдак булган ирен хезмәт иттерә.

Яңгы гына ата-анасы йортында, бай ата-анасы йортында үскән, аз хезмәт берлән җиңгел тормышка хуҗа булган егеткә «синең, бу синең рәхәтең шул кечкенә өйдә» дигән фикерне башына суга. Бәлки, шул мәгълүм идеалга таба омтылу, шул юлдагы тартышу Казан татар хатынының кулына күбрәк корал да биргәндер. Бәлки, тормыштагы төрле бөгелү-сыгылулар аның тәнен-җанын сыгылырга-бөгелергә өйрәткәндер. Аның ирен өйгә бәйләү өчен ясалган әллә никадәр юллары бар. Дөрестен әйтсәк, тозаклары бар. Ул киенә-бизәнә белә. Ул, иренә уңгай булсын өчен, тәмле ашлар пешерә белә. Иренә ярар өчен ачык көлә белә. Көлә, сөйли, ерлый. Иң ныгы — ул иренә чәер кебек ябыша. Аңгарга «син кайда — мин шунда, без кайда — йорт шунда» дигән фикерне суга вә шуны эше, кылынышы берлән исбат итә. Ире кая китсә: «Әни ни эшләр икән? Ата казны сагынырмын», — дип тормый, букчасын ала да чыга да утыра. Менә шуның өчен Казан татары тормыш кушып Сибириянең тайгасына барып керсә дә, шимальнең тундрасына барып басса да, Миңленисасын исенә төшерә.

Өст-башы начарланса да, Миңлениса искә төшә. Ашыйсы-эчәсе килсә дә, Миңлениса төшә. Шуның өчен, аз гына күз ачтымы, Миңленисаны китерү уе берлән ашланып эшләргә тотына вә беренче имкянда Миңленисаны чакыра. Миңлениса ят йир дип тормый, аңгарга ире бар йирдә ят йир юк. Ул килә. Кызыл башлы сөлгесен элә, шакмаклы ашъяулыгын җәя. Үзенең әнисеннән өйрәнгән пәрәмәчен, коймагын, лапшасын пешерә.

Өй кора, яңгы өй кора. Тирә-юньдәге халыкның гадәтенә, йоласына карамаенча өй кора. Өенә искедән алып килгән бөтен гадәтләрен тутырып, тирә-юне русмы, чувашмы, башкортмы, төрекме, ул «татар йорты» ясый.

Аның гадәте, йоласы берлән торырга тотына. Тирә-күршедәге халыкның гадәте, йоласына өйрәнү генә түгел, аларга үзе тәэсир итәргә маташа. Аларга «менә чын тормыш бу — безнең тормыш, ул тормыш, ашның асылы — пәрәмәч, бәйрәмнең чыны — Корбан бәйрәме, киемнең матуры — итәкле күлмәк» дигән уйны тарата. Үзенә-үзе «мәдәни бер учак» дип карый. Бала-чагасы шул рухта үсә.

Мишәр хатыны бөтенләй икенче әхвале рухиядә тәрбия ителгән: иң әүвәл аның балалыгында матур әбиләр хикәяләре, матур иске мәнзарәләр юк. Аның тарихы берлән хәзерге тормыш арасында әллә нинди ят-чит нәрсәләр кереп утырган. Ул үзенең иске тарихыннан, иске байлыгыннан йә мукшы берлән аерылган, рус халкы берлән киселгән. Үзенең хикәяләреннән, әкиятләреннән, көйләреннән, ерларыннан чит көйләр, чит көчләр белән читкә төртелгән. Тарихы әллә кая еракта гына, пәрдә артында гына калган...

Хәзерге тормыш элгәреге бабайларның бабасының бабалары тормышның агышы булып бара алмаган, әллә кай бер йирдә шул тормышка тирес салынган, буа аны буа алды, буа артында булган. Ул хәзер буа артында гына яши. Чит кеше булган буаның канунынннан төшкән су берлән генә канәгатьләнә. Шуннан ара-тирә ычкынып киткән балыкларны гына күрә. Буа астында җыелган төрле-төрле балыкларны көн дә, көн дә күргәнгә, менә чын су хуҗасы шул балыклар дип таный. Балыкны тегеләй генә йөри торган, түшен кояшта ялтыратып китәр өчен генә яратылган хайван дип исәпли. Аныңча, йирнең асылы — шул буа арты. Йортның чыны — шул буа тирәсе. Тормышның төбе — шул буа арты тормышы.

**IV**

Әнә шул татарның тормышының буасы артында, татар тормышының тарихы агымыннан читкә кагылып яшәеш мишәр хатынын арка таяначыксыз калдырган. Мишәр хатыны* үзенең йолаларында,

гадәтләрендә, көендә, җырында арттагы таза, нык тарих диварларына таяна алмаганга, ул үзенең эченнән һәрвакыт көчсезлек хис иткән. Үзенең көченә ышану нык булмаган. Үзенең «үз»леген мөкатдәс итеп танырлык вә шул «үз»леген мөкатдәс иттереп тирә-юненә танытырлык куәте булмаган. Ул әллә нидән куркып калганга, тормышының артында әбиләрнең нишләгәнен күреп тора алмаганга, киләчәк буынга бирергә дигән «әбиләр мирасы» аңарда бик аз булган. Иң уңгайсызлыгы, шул мирасның азлыгы, шул ярлылык, шул фәкыйрьлек аның рухына бик начар тәэсир иткән. Ул: «Менә мин моны телим! Менә мин шулай торуны телим, менә бу хак тормыш! Менә бу чын гадәт!» — дигән гадәтләре, йолалары аның күз алдында булмаганга, ул анда барырга да белмәенчә, монда китәргә дә белмәенчә аптырап калган.

Аның әбиләреннән калган әкиятләре, кыйссалары, җырлары, берсе артыннан берсе рус җыры, рус көе берлән җиңелә-җиңелә, халыкның яшь буынына җан азыгы булу көчен югалткан.

Шул көйләр, җырлар берлә бергә акрын гына тел кителә башлаган. Аның китекләре, сыныклары урынына рус сүзләре кергән, аларның тәләффызлары, әйтелүләре татар авызына килеп йитмәгәнгә, чын татар сүзләре, чын әбиләре, бабайларның сүзләре җуан иттереп, йә кирәкмәгәнгә озын иттереп, йә кәкре-бөкре иттереп, шул ят сүзләргә ияртелеп, татар теленең үзенә махсус булган көен, аһәнкесен бозган. Тел тупасланган. Шул телдәге җырлар да, дорфаланып, татар баласының йөрәгенең яшерен почмакларына барып җитә алмаган. Шуның аркасында мишәр халкы тормышында, рухани азык базарында ачлык башланган. Ул ачлыкны бетерер өчен читтән китерелгән муллалар яисә үзеннән булса да читкә җибәрелеп рухани азык төяп кайткан муллалар, бохари тәрбиясе берлән дини бәгъзе бер фәлсәфәләр, суфилыклар алып кайтсалар да, халыкның, гади мишәр халкының милли кимчелекләрен күрә дә алмаганнар, аңлый да алмаганнар. Алар шул өзелеп калган чит халык арасында диңгездәге атауда яши торган мишәр халкының иң зур ихтыяҗы: үз йорты, үз иле берлән мөнәсәбәт ясау, үзенең тарихи буасы артындагы тормышын, иске милли тормыш берлән тоташтыру, бәйләү икәнен аңламаганнар. Алар шул дини хезмәтләрен итсәләр дә, милли хезмәттә, мишәр халкының иң мохтаҗ булган телен саклауда, җырын, көен, гадәтен, йоласын югалтуда һичбер төрле файда китерә алмаганнар. Менә шул милли фәкыйрьлек, милли бөлеклек арасында үскән мишәр кызы, хатыны бөек булып үсми хәле бармы? Шул көйсез, җырсыз, тарихсыз тормышта хатын булган мишәр кызының рухы дорфаланмый, уе, тойгысы тупасланмый хәле бармы?

Шуның өстенә аның кием-салым модасының агуында да милли агымнан читкә төшеп калуы, үзеннән-үзе бер мода агымы ясарга куәте җитмәве тагы хәлен мөшкелләтә, аның тормышының матурлыкларын киметергә мәҗбүр итә түгелме?

Менә шул милли түгеллекләр, шул милли фәкыйрьлекләр арасында үскән гаиләгә хатын булып кергән мишәр хатыны роль уйный алачак, нинди юлга таба гаиләне, баланы алып барачак?

Ул үзеннән-үзе бер кеше иттереп, үзеннән-үзен милли тормышның бер әгъзасы итеп хис итә алмаганга, ул иске тормышның җимерекләре янына сыгыла, сыена гына. Ул кияүгә чыкса, Әхмәткә, Мөхәммәткә, Гайсәгә, Мусага чыгып, аның берлән бергә «яңгы өй» ясау фикеренә таба ихтыярсыз омтыла алмый, омтылмый. Ул «иске өй» каената, каенананың өенә яңгы бер әгъза булып, яңгы килмешәк булып кына керә. Ул, үзендә көч хис итмәгәнгә, иренә «яңгы өй» ясау фикерен суга алмый, аны шул якка бора алмый. Аның кайгысын уртаклашыр өчен, аның шатлыгын берләшер өчен ул ире берлән бергә Сибириягә, Төркестанга, Финляндиягә бара алмый. Бара алмый гына түгел, барырга тели дә алмый, теләргә тиеш тә дип белми. Ул чынargaн Әхмәтханга кияүгә чыкса да, аның иптәше, тормыш иптәше икәненнән битәр, Батый абызтайның киленлеген, Әхмүш абзыйның комганына су сала торган асрау икәнен ныграк хис итә вә шуларга ярар өчен үзенең иң күп көчен, куәтен сарыф итә.

Шул киленлек вазифасын үтәгәндә, иренә каршы булган бурычын, баласына каршы булган вазифасын тәмам оныта. Ирен гаилә җылысы берлән җылытырга аның вакыты калмый. Баласына гаиләсе тормышын сөйдерергә көче җитми. Аның баласы да, шул таза анадан, таза атадан үскән баласы да җисмәи никадәр таза булып үссә дә, шулкадәр ач булып мәйданга чыга. Менә шул рухаи ач мишәр баласы, үзенең тирә-юньдәге юклыкны күргәч тә, үзенең туган илендәге рухани фәкыйрьлекне сизгәч тә, ул шуннан котылыр өчен читкә атыла. Зур бер куәт берлән атыла.

Үз иленнән чыкты исә, үзенең туган су буеннан китте исә, ул бердән күзен ачып, бөтен шул юклыктан котылыр өчен чит тормышның эченә атыла. Ач бүренең көтүгә атылуы кебек, күзен йомып ыргытыла. Аннан җаны азык эзли. Аннан тормышын мәгънәләтә торган фикерләр, мәсләкләр эзли, артындагы тормышы һичбер төрле аны бәйләп тота алмаганга, аның мәркәздән атылуында бик еракка китмәсен дип, милли җеп тотып тора алмаганга, ул башыннан аягына кадәр чит тормышның эченә чума. Аның күз карашының бөтен милли кимчелекләрдән пакь булуы, аның үткен, зирәк булуы, аның тәне таза булу аркасында батыр булуы аңгарга бик тиз рус галәмендә киң юл ача. Ул сәүдә эшендә сату-алуның хикмәтләрен сизеп алып, базарның хәйләле юлларыннан үтә-үтә бик югарыга менә. Ул Русиянең

мәгънәвиять дөньясына кереп китсә, аннан иң югарыгы фикерләргә таба омтыла. Ул, гомумән, тормышында иң югары баскычларга таба очарга тырыша вә шул хәрәкәтләрендә бик зур хөрлек күрсәтә.

Кыскасы гына, мишәр гаиләсе гаилә хәятында иң кирәкле булган консерваторлыктан мәхрүм булганга, үзенең баласын-чагасын тәмам хөр итеп рус дөньясына очырта да җибәрә.

Мишәр гаиләсе үзенең баласын-чагасын өенә кызыктырып кайтарырлык куәткә малик булмаганга, чит тормыштан алган мәгълүмат, ямь-тәм берлән иске тормышына сипләргә угылларын-кызларын куша алмый вә, шулай итеп, үзенең милли тормышының үсүенә ярдәм итә алмый. Ул искене бетерә генә. Искене сипли алмый. Ул искене сүгә генә, яңгыны, «үзенеке яңгыны» ясый, тудыра алмый. Ул русларның калдыкларына гына канәгатьләнә бара.

Казан татары гаиләсе — консерватор. Ул һичбер яңгыны кабул итмәскә тырыша, русның барлыгын күрмәскә маташа. Үзенеке түгел нәрсәне кабул итсә, ул, мотлакан, үз киеменә киендереп кертә. Русның музыкасын сөя. Ул аңгарга татарның рухын сугып татарландыра. Такмак куша.

Аның гадәтен яратса, мотлакан, бер йиренә үзенең бер мөгезен чыгара, татар исе сибә, татар буявы буйый, чөнки аның хатыны милли, мәдәни бер көч булганга, аның борыны татар исен сизгәнгә, аның күзе татар төсен таныганга, аның «үзлек» фикере һәр батыр нәрсәне тәнкыйть берлән карарга көч биргәнгә, ул тормышын сипли генә. Ул иске бинаны ватмаенча аны буйый, аны зурайта, аны киңәйтә. Ул йотылуга каршы теше-тырнагы берлә тора. Ул руслашуга мәдәни җинаять дип карый.

Менә шул ике бүлек халыктан чыккан җәмәгать хезмәтчеләре дә, шөбһәсез, өйләреннән, йортларыннан алган күз карашлары берлән мәйданга атылалар. Казан татарлары тормышны сипләргә тотыналар. Акрынлап кына, ваклап кына мәктәп партасын бу ел бер карыш, киләсе елга бер карыш үстереп, дүрт-биш елда кирәгенә җиткерәләр. Хәрчәүнәдә «ике дә өчне» алып сөйләнә-сөйләнә генә җәмгыять эшләрен тирәнәйтәләр.

Рус мәктәпләренә кәләпүш, калфагы берлән генә йөреп, аннан алган мәгълүматны да кәләпүшкә сыярмы, калфакка кечкенә булмасмы дип кенә карыйлар.

Мишәр җәмәгать хадиме тәмам хөр булып мәйданга чыга, мәсьәләне төптән үзгәртергә тотына. Аныңча, мәдрәсә исляхы, идарәи рухания исляхы вә башкалары тәмам яңгыдан булырга тиеш. Яңгы нигезенә корылырга тиеш.

Менә шул консерваторлык психологиясендә чыккан татар җәмәгать хезмәтчеләре берлән радикализм фикерен ташучы мишәр җәмәгать хезмәтчеләре арасында рухани тартышу бара. Шул ике көчнең тартышуы аркасында татарның милли, мәдәни хәрәкәте икесеннән дә кирәкле-кирәкмәс кушымталар алып, урта йирдән хәрәкәт итеп ята.

**V**

Менә шул ата-анадан туган татар углы алдында, менә шул мохиттә үскән татар хезмәтчесе алдында бердән татар милләте алдындагы томанлы пәрдә күтәрелде. Бердән татар тормышы үзенең авырулары, җанындагы, рухындагы хасталыклары, эч пошулары, куркаклыклары берлән бергә алга килеп басты.

Татар углы уйланырга, төшенергә, бу уникедән берсе юк милләт берлән ни эшләргә, кырык тугыз авыруның илле бере берлән сырхауланган бу халыкны ничек терелтергә, җаны-тәне ачлыктан корыган бу милләтне ничек ашатырга, тазартырга дип ис җыярга өлгермәде, тарих тарафыннан йә ислях, йә бетәсез дигән кыска ультиматум бирелде. Татар углы анда сугылды, монда сугылды, үзенең милли тормышының дин диварына сыгынмакчы булды. Халыкның көн күрү якларына, икътисади хәле астына посмакчы булды. Милләтнең сәяси хокукларына арка терәп сөйләмәкче булды. Милли байлыкларын калкан тотып тартышмакчы булды. Бердән шуларның һәммәсен сәфәрбәрлек хәленә китереп, мәйданга чыкмакчы, үзенең торырга хакы барлыгын исбат итәр өчен хәят мәйданына чыкмакчы булды. Нигә генә тотынмасын, һәммәсе көчсез, дин дивары — йөзләр, меңнәр еллар халкын саклап килгән икенче халыкның икътисади, сәяси, мәдәни тормышыннан аерып килгән дин дивары искергән, җимерелгән. Аның ярыкларыннан күрше халыкларның фикерләре, мәдәниятләре, гадәтләре, йолалары кереп тора. Ул гына да түгел, шул дин диварын саклаучылар, голямалар үзләре каравылда торырлык дәрәҗәдән үткәннәр, алга таба карарга тугры килмәгәнгә, алга күз ташлауны онытканнар. Ул гына да түгел, аларның күзләре гадәткә хилаф булып, маңлайга түгел, баш артына куелган. Алар шул күзләр берлән ислам дөньясының үткән шәүкәтләрен, үткәргән хәлләрен, кичергән фетнәләрен күреп торалар.

Шул күзнең гайре табигыйлеге аларның күзләреннән үлчәү куәсен, ераклык-якынлыкны үлчәү куәсен алган. Алар һаман әле мең ел элек булып үткән хәвариҗләр килмәсен дип куркып, алар берлән моназарәгә хәзерләнәләр. Сөякләре череп бетеп, көл булган рәвафизлар берлән тартышыр өчен күптән сәяси кыйммәте беткән шигыйлек, могтәзиләлек кебек исламның сәяси агымнары берлән кычкырышыр өчен тырмашалар,

маташалар. Шул хыялдагы дошманлык берлән саташып, алар хәзерге халыкны, мәхәлләне онытканнар. Аның ыңгырашына каршы моннан мең ел элек сәяси лозунг булган «зу галәл-әмамин, аллаһумә мин исгидин әс-сәһидин»* дигән сүзләрен генә мыгыр-мыгыр укыганнар. Аңлашылмаган телдә укыйлар да укыйлар.

Халыкның бөтен авыруын, хастасын истинҗа мәсьәләләре берлән генә хәл ителә дип уйлыйлар. Татар углын шул дин сакчыларының банкротлык мәнзарәсе коточкыч бер хәлгә китерде. Ул, артына-алдына карамаенча: «Дин эшләренә ислях!» — дип кычкыра. Дин хисенең мыскыллануы, дини авыртуы иксез-чиксез зур булганга, ул моны табигый тел берлән генә әйтми. Ул, каравыл кычкырган кебек: «Дини эшләрдә ислях!» — дип кычкыра.

Шул тавыш, җан ачысы берлән кычкырган шул тавыш бөтен татар дөньясында хәрәкәт уята, дин сакчылары арасында зур бер шау-шу кубара. Аларны төрлегә бүлдерә. Алар арасында күзнең маңлайда булуы хакыйкатьме, артта булуы хакыйкатьме дигән фәлсәфи моназарә ача. Вә шул тавыш-кычкырышта бу кыйсем халыкның рухы бик фәкыйрь икәнлеге мәгълүм булып, бөтен халык алдына динле генә түгел, милли дә эш булып килеп баса.

Сыйрыф дини булган мәсьәләләргә дини-сәяси, милли булганнары да бергә кушылып, хәлен көтеп мәйданга атыла. Дини эшләр берлән генә капланып, шулар берлән генә халыкның ачлыгын, сусавын, авыруын, хасталыгын бетерә алмаганны күргәч, татар углы халыкның көнкүрешенә, икътисади диварына күз сала. Монда да бер бади — элгәреге сату-алудагы байлык беткән, авылдагы мал-туар, йир-су муллыгы әллә кая киткән... Ул гына да түгел, татар сәүдәгәре, тугрылык берлән шөһрәт тоткан татар сәүдәгәре урынына иелә-сыгыла, хөкемгә эләкмәсә, атасын да алдый торган, ресторанда күргән рус малайларының кыланышларын идеал иттереп, аларга таба омтылуны сәгадәт саяган, тормышы буе марҗа куучы татар егетенә очрый.

Авылның элгәреге атлы-тунлы Әхмәтҗаны, Мөхәммәтҗаны күмер казырга баручы дворник, кучер булучы Әхмүшкә әйләнгән. Монда да халыкның тамагын туйдырырлык, милләтнең җаны өшүен бетерерлек җылы юк. Менә татар углы алдында тагы икътисади мәсьәләләр туа, туа гына түгел, хәзер хәл итмәсә, ачка үләм, дип, ишекне шакылдата.

Үзенең милли байлыгына, әдәбиятына, шигыренә, театрына, матбугатына, фәненә ябышмакчы була. Шуларның шүрлегенә кулын суза, ләкин анда да бум-бушлык табып, аннан да килә торган суыклыкны, юклыкны күреп, милли матбугат тудыру, милли әдәбият ясау, милли театр, милли музыка йитештерү дигән яңгы бурыч күз алдына куна. Мәктәбе, мәдрәсәсеннән йөри, эзли, һәммәсе җимерек, һәммәсе ватык... Һәммәсен эшләргә, һәммәсен тудырырга дигән тагы мәсьәлә алга куела.

Татар углы, үзенең сәяси хокукларына ышыкланып, шуннан ныгаеп, шул кирәк-яракларын карар өчен, эшләр өчен арка таяначак була. Анда да бутышникның сыбызгысына башка, казыйның керле чалмасына башка бернәрсә таба алмый.

Татар углы, шул уникенең берсе юк хәят тартышуы мәйданында милли тормыш ясар өчен, тарих бабай тарафыннан чакырылган татар углы аптырап кала. Киләчәк кышның якынлыгын сизсә дә, шул искене бетерүче, иске бабайлар мирасын әрәм итүчеләргә шулкадәр ачуы килә, тетмәсен тетәр өчен, дошманын эзләргә тотына. Шул эзләгәндә кемне күрсә, шуңгарга ташлана, кемне очратса, шул дошман кебек тоела. Дини эшләрне ислях итәргә диючеләргә милләтчеләр дошман кебек сизелә. Милләтчеләргә икътисадчылар иң зарарлы кебек тоела. Икътисадчысына иң шарлатаны сәясиләр кебек сизелә. Бер-берсенә тешләре-тырнаклары берлән ябышалар, чәчләрен, сакалларын йолкышалар, аякларын, кулларын сындырырга керешәләр. Озак итеп сугышалар, кычкырышалар, хурлашалар, канга батышалар. Арыйлар, талалар, җәрәхәтләнәләр. Шул аңлашмау, тартышуны карар өчен, шул кычкырышларда утка май салыр өчен яңгы бер кыйсем халык туа, ул да — циркларга барып йөреп, көрәшүчеләрне чагыштырып, искеләр вә муллаларга йөреп, ат узыштыручыларны көрәштереп тәрбия ителгән ак якалы егетләр, үземезнең шул халык көчләремезнең тартышуыннан үзенә театр мәнзарәсе иттергән хулиганнар, милли кяферләр... Болар, тартышу басыла башласа, куыштырып җибәрер өчен әле бер якны, әле бер якны көчләгән булалар. Әле берсен, әле берсен әтәчләндерәләр. Халык хезмәтчеләренең мәсләк тартышуларын Испаниядәге үгез сугыштыру уены кебек бер фәхеш күрсәтергә маташалар. Ләкин кыш якынлаша бара...

Милли кием-салымның кирәклеге, милли ашамак-эчмәкнең ихтыяҗы зурайганнан-зурая бара. Тагы ук теге татар угылларына, бер-берсе берлән талаша-кычкырыша арып беткән татар хезмәтчеләренә өй ясау, ашамак-эчмәк хәзерләү бурычы килеп төшә. Битләрендәге каннарын сөртеп-сөртеп эшләргә, тудырырга тотыналар. Татар өе, татар йорты ясарга керешәләр. Халык өчен ашамак-эчмәк үстерергә маташалар. Күптән түгел генә таш ярып, күз чыгарып сугышканын онытмаганга, өй салыр өчен агач китергәндә очрашсалар, күчәрләрен юри бәрдереп китәләр. Милли өй буяганда кара-каршы килешсәләр, арулыгын, пакьлеген карамаенча, бер-берсенә пумала белән лач иттерәләр. Милли түтәлләр утыртканда, милли

бакчалар рәтләгәндә тырнашалар, тибешәләр, ләкин көн үткән саен, болар эшнең тәменә кереп киткәнгә, көн үткән саен, кышның якынлыгы сизелә килгәнгә, бу хәлләр шулай онытыла киләләр. Көн үткән саен кышка кадәр өйне, милли өйне мичле ясар өчен көне-төне тырышырга кирәк булганга, алар үз халкын «күрше»нең сәндерәсендә, анда урын булмаса, сыерлы, сарыклы, дуңгызлы хайван абзарында калдырырга тугры килмәсен дип тырышалар.

Алар шул өйдә торганда, кышның көннәре, төннәре озын икәнен белгәнгә, халык ачлыктан, мохтаҗлыктан чыгып, күршенең тәрәзәсе төбенә барып, «Христа ради!» димәсен өчен, милли кырда, милли түтәлдә, милли бакчада көне-төне казыналар.

Милли хулиганнарның «теге бит сине ямьсез, диде, теге бит сине динсез, диде» кебек гайбәтләрен дә ишетергә вакытлары калмаенча, милли кяферләрнең: «Шул дамы эш булды. Ичмасам, Иван Иваныч эшләгән! Ул тәрәзәләре, дисәң, чын пыяла, җиһазмы, дисәң, английский, ягулы нимечский, безнең монда нәрсә? Торырга урыны юк. Спальнясы аерым булмаса, ат узыштырып кайткач, юынырга ваннасы, киң бүлмәсе, мин йә думаю Иван Иванычтан алырмын, ведь миндә бала-чага воспитаниесе бар», — дигән булып гакыл сатуларга карамый, ул бөтен көчен, куәтен сәфәрбәрлек хәленә китергән дә эшли, казына.

Озын кышта роскошь берлән торырлык иттереп корырга вакыты, көче җитмәгәнне белсә дә, катып үлмәслек җылы, ачка үлмәслек черемәгән азык хәзерләү уе берлән бөреләнеп ята.

Хәзер аның бурычы шул икәнен белгәнгә, ул теге сыйрыф дини мәсьәләләрне, милли мәсьәләләрне дә, икътисади мәсьәләләрне дә, сәясиләрен дә икенче дәрәҗәгә калдырган. Аларның бәрелешләрен дә читкә калдырып, өй корырга, куыш, милли куыш ясарга гына бөтен дикъкатен борган.

Бәлки, милли хулиганнар, милли кяферләр җиңгәрләр дә, аның яртысы эшләнеп калыр, бәлки, шулар тагы бер һөҗүм ясарлар да, өй хәзер булгач, утын китерер өчен атын урларлар, бәлки, ашамак-эчмәк хәзерләнеп җиткәч тә, йортка ут төртеп яндырырлар.

Ләкин татарның хезмәтчеләре бу көнге, бу елгы көзге бурычын үтәми хәле бармы? Аның кышка әзерләнергә бөтен көчен сарыф итми мөмкинме?

## VI

Менә шул өйне ясар өчен 5 нче елда Мәкәрҗәнең беренче съездында[9] актык. Монда Идел буе татарының гына түгел, Кырымның, Кавказның да бәгъзе бер көчләре, халык тормышын ясаудагы инженерлары бар иде. Берничә көн дәвам иткән хосусый мәҗлесләрдән соң, хөкүмәт даирәләреннән ачыктан-ачык җыелышып сөйләшергә рөхсәт ала алмагач, Ока иделе өстендә пароходта беренче съездны ясарга карар бирдек.

Кечкенә мәҗлесләрдә халык арасында бик күп фикер акканлыгы, бик күп өй эшләнеп бетеп, мәгълүм төс алмаенча әле бер тарафка, әле бер тарафка бәрелеп йөргәне күренде. Халкыбызның аңлылары, зыялылары арасында эшләнеп беткән сәяси фикерләр, икътисади, иҗтимагый мәсләкләрнең бик таркаулыгы күзгә ташланды, вә шул мәҗлесләргә мәгълүм бер программа берлән килгән көчле группаның булмавы бөтен әфкяр агышын, өй тартышуын мәсләк низагысыннан шәхси кычкырышларга таба борды.

Мәҗлескә хазир булганнардан мәгълүм программасы бар кешеләрнең шөбхәсез берсе «иттифакчы»лар таифәсе[10] иде. Икенчесе Идел буенда кыска гына гомер яшәсә дә, Идел буенда беренче сәяси партиялек байрагын күтәргән* «хөрриятче»ләр[11] иде.

«Иттифакчы»лар таифәсенең теләге, хәзергә әле сәяси үзгәрешләрне алга куймаенча, мәгълүм юлдан барырга, планнар эшләп бетермәенчә, бөтен Русия мөселманнарын бер кулга җыеп, бер юлдан алып бару вә шуның идарәсене махсус ясалган «Олуглар комитеты»на тапшыру иде. «Хөрриятче»ләр фикеренчә, вакытның кизүдәге мәсьәләсе сәяси хокукларны мөзакәрә итеп, шуны алу юлын кору иде. Бу ике фирканең эш программаларында, бәлки, аерма зур да булмагандыр. Ләкин ул вакытлардагы иҗтимагый иҗекләүләр бик тупас булганча, читтән караганда болар бер-берсенә каршы чарпыша торган фиркаләр булып кабул ителгәннәр иде. Хосусән ике фирканең барырга теләгән юлларының башкалыгы, тактикаларының аерымлыгы боларны бөтенләй ике төрле агым итеп танытткан иде.

«Иттифакчы»лар таифәсенең уенча, хәзерге мөселманнарның тактикалары лояльный булып күренеп, үземезнең хәлемездән разый булмасак та, шуны үзгәртү юлында «аңлату»дан чыкмау иде, ягъни аларча «аңлата белсәк», «аңлатсак», безнең бөтен хәлемез ал да, гөл дә булмаса да, бик күп ислях ителәчәк иде.

«Хөрриятче»ләр фикеренчә, үземезнең җитешмәгән бөтен йирләремезне тутырыр өчен үземез тырышу, үземезнең хокукымызны алу өчен үземез тартышу, аңлатып кына түгел, бер көч булып тартышу лязем иде вә, шул тартышуда үземез генә җиңү ихтималымыз булмаганга, русларның безгә программалары якын булган фиркаләре берлән бергә булу лязем иде. Кыскасы гына, әүвәлге фирка пассивный, ягъни барына разый булу, икенче фирка активный, ягъни юкны бар итү ягында иде.

Менә шул фиркаләр арасында бик күп халык, бер мәсьәләдә «иттифакчы»ларга, бер мәсьәләдә «хөрриятче»ләргә кушылып, шул ике агымны бер тоташтыра, бер бүлә, ике арадан низагның үзәген оныттыра иде. Вә бер бүлек шундагы бөтен иҗаби мәсьәләләрне һичбер төрле аңлап җитә алмаенча, сәлби мәсьәләләрне генә алга сөрә. Мөфтине төшерүне, казыйны үзгәртүне бик зурга куя иде.

Менә шул иҗтимагый ботка эченнән арынып чыгар өчен озын мөзакәрәләр, аңлашулар, самими көрешүләр лязем иде. Вә шуннан соң мөмкин кадәр ике фиркане дә, якынлаштыра торган хаттел-хәрәкәт тәгаен итү тиеш иде.

Пароходтагы съездымызның тарихымызда шул эшне үтәячәк иде. Ләкин эш барышындагы кешеләрнең, хосусән Рәшид казыйның[12] вә аның мөритләренең мәсьәләне киңләп аңлый алмауларыннан вә шундагы көчләрнең киләчәк өчен кыйммәтләрен тәкъдир итәрлек күзләре кыскалыгыннан мәсьәлә шәрекъчә хәл ителмәкче булды. Вә шулай итеп, аңлашу урынына ике арада зур бер аңлашылмау, ике арага бик ямьсез тирән бер чокыр казылды. Хосусән мәҗлестә иртә берлән мәгълүм урында сәгать унда пароход китәчәк итеп игълан ителсә дә, «иттифакчы»лар, «хөрриятче»ләрне калдырыр өчен махсус дәгъвәтнамә чыгарып, сәгать тукызга халыкны чакырттылар. Вә кызулап-кызулап, тегеләр килгәнчә, пароходта китеп бардылар.

Шуның өчен үзенең олугларының сүзенә инанмауны гакылына да кертмәгән «хөрриятче»ләр, ул вакытча әйтелгәндә, яшьләр, алдатылып, су буенда калдырылдылар.

Шуның аркасында Русиянең иҗтимагый хәрәкәтенең беренче адымына алдау кушылды, вә шуның аркасында ике арада булган вә булачак мөнәсәбәт намуссызлык юлына төртелде. Русия мөселманының иҗтимагый хәятның башында әйтелгән шул милли җинаятьтәге иблис ялчылары үзләренең максатларына да ирештеләр. Шул тарихи көннән игътибарә ике арада зур гауга, низаг кубарга сәбәп булдылар. Зур пароходны куып җиткән кечкенә пароходтагы яшьләргә каршы ителгән мөгамәлә, аларны сүзгә кушылсалар, мөзакәрәгә катышсалар, шәһәрдән утыз-кырык чакрым йирдә Идел кырыена чыгарып ташлыймыз, дип куркытулар бөтен мөнәсәбәтне зәһәрләмәенчә булмады. Вә мәҗлестә мәҗбүрән телсез ителгән «хөрриятче»ләр алдында кабул ителгән теләүләрнең исеме «Бөтен Русия исламының иттифакы» дип аталса да*, шундагы бөтен хазир булганнарга алдау икәнлеген күрсәтеп торды, вә шул иттифак эше, башкортлардагы ямьсез кызга бирелә торган «Сылу» исеме кебек, тарихның көлүе булды да һичбер вакытта түгел бөтен Русия мөселманың, комитет әгъзаларының да иттифакы була алмаенча калды.

Шуннан соңгы булган бөтен сәяси кычкырышларымыз, бөтен фирка низагларымыз шул тарихи хатага буялып китеп барды вә шул мәҗлестә кабул ителгән теләүләрнең һичберсе, фәгалиятькә чыга алмаенча, «суга алмаган зур күтәргән» булды да калды.

Бу көнге көндәге әфкяре гомумиямездәге чуалулар, аңлашылмаулар, бу көнге көндәге җәмәгать хезмәтчеләре аркасында самимиятнең юклыгы, аларның бик күбесенең алган юлы төрле-төрле былчыраклардан пакь булмавының мәгънәви сәбәпләренең берсе, шөбһәсез, шул беренче «Иттифак»ның нифак чишмәсеннән ага башлавыннандыр. Шуннан соңгы кубарылган мәсьәләләрдә иң беренче күзгә ташланган эш «иттифакчы»ларның бер-берсен аңламавы булды. Исмәгыйль бәк[13] Рәшид казыйны аңламады, Рәшид казый Галимәрдән бәкне[14] аңламады, халык берсен дә аңламады. Боларны җанландыра торган мәсләк тә, берлек дигән зур бер көч булмаганга, болар арпа камыры кебек таралды да китте.

Икенче, «иттифакчы»ларның күтәргән мәсьәләләре бик күп булганга, шуларны алып барырлык, эш иттереп чыгарырлык көч юкка, аларның бик күп эшләрендә бергә булачак яшьләр көченә дошман күзе берлән караганга, шул сүзләрдән катгыян бер нәтиҗә чыкмады вә шуннан соң озакламаенча башланган хөррият көннәрендә «Мөселман иттифакы» мәгънәви вә матди һичбер төрле роль уйнамады, уйный алмады. Ул гына да түгел, Казандагы хөррият көннәрендәге карагруһларның «Хөррият кирәкми» дигән нәмаишларына катнашудан мөселман голямасы алып кала алмады вә, шулай итеп, шул тарихи көннәрдә мөселманнарның йөзләренә кан ягылды.

Хөррияттән соң киткән мәсьәләләрдә аңлашылмауның бер зур сәбәбе, шөбһәсез, шундагы көчләрнең тәрбиясенең төрле-төрле булуы булды. Җәмәгать эшенә катышканнарның зур бер кыйсеме үзләренең мәгълүматларын, тәрбияләрен Шәрекъта алган затлар иде. Икенче берсе Русия мәктәпләрендә укыган кешеләр иде. Шәрекъ шәкертләренең төшенчәләре бик киң булса да, мәсьәләләрнең һичберсендә мәгълүм куелмаган әсаслар иде. Аларның уйлары Шәрекънең матур күге, зөмбед кебек диңгезе арасында уйланылганга, бик күбесе хыял дәрәҗәсеннән индерелмәгән вә тормышка татбикъның ысулы уйланылмаган иде. Ул гына да түгел, болар үзләренең хезмәт итәчәк халыкларының Идел буе татарымы, бөтен Русия мөселманымы, әллә бөтен дөнья мөселманымы икәнен аерып бетермәгәннәр иде. Башта мәсьәләне Идел буеның мөфтилегеннән[15] алып китәләр иде дә, бара-бара, Мисырның дини исляхиятенә[16], Габделхәмитнең золымына[17] итеп төртәләр иде.

Үзгәреләчәк мәсьәлә хакында да мәгълүм күз карашы юк иде. Диннән әллә нинди тәгассыбларны алып ыргытырга тиеш. Җамалетдин әл-Әфгани[18] әйткәнчә, ислам тәрәкъкыйга манигъ түгел, мәктәпне ана телендә ясарга кирәк. Башкортның йирен-суын саттырмаска кирәк, мулланы волостной судта хөкем иттермәскә кирәк. Телдә, әмәлдә, фикердә берлек кирәк...

Шул чуалчык теләкләргә таба бу халыкның барырга тиеш тапкан юлы да һичбер төрле эшләнелмәгән, аңгарга һичбер кем тарафыннан тәҗрибәле кул берлән маяклар кагылмаган иде. Властьта да фәкать бер тел иде. Шуның өчен, кайда булса, шунда болар, матур иттереп, Шәрекътагы матур сүзләрне бизәкләп, «тәрәкъкый», «милләт-фәлән» дип фәлсәфәне саталар иде. Иң уңгайсызы шул иде: бу кыйсем халык Шәрекънең мәдәнияте черегән вакытта чыгарылган моральне сеңдереп кайтулары вә шуның аркасында мәсләк, сәбат кебек һичбер хакыйкатьне кабул итмәүләре, могаризләр белән тартышуда бөтен интригаларны коралланулары иде. Бу бүлек халык шул вакыттагы уянып килә торган татар сәүдәгәрендәге дини әхлак дигән фикергә таба үзен хезмәтче итеп танытканга, Шәрекъ шәкертләренең халык арасында игътибары зур, сәяси көче нык иде.

Икенче бүлек халык — Русия мәктәпләренең шәкертләре. Болар Русиядәге үзгәреш алдындагы сәяси тәрбияне күргәнгә, рус әдәбияты аша шул вакыттагы икътисади уйлауны, тарихи вакыйгаларны матди ноктаи нәзардан карауны кабул иткәннәр иде. Болар, һәрбер мәсьәләне хәл итәргә тырышканда, аның икътисади, матди ягын җентекләргә өйрәнеп, мәгънәви көчләрдән булган дин, миллият хисен икенче дәрәҗәгә куйганнар иде. Болар тарихи вакыйгаларда иң көчле гамил итеп халыкның икътисади, сәяси хәленең үзгәрешен танyганга, табигый, шул мәсьәләләрне беренче дәрәҗәгә сөрәләр иде.

Дини мәсьәләләрнең теләгәнчә баруы, милли мәсьәләләрнең үсүе, киңәюе сәяси-икътисади хәлләрнең йимешләре иттереп кенә йөрткәнгә, динне, милләтне дөнья өчен хезмәтче иттерергә тырышалар иде.

Менә шул ноктада алар Шәрекъ шәкертләре берлән һичбер төрле аңлашылмаенча, туктаусыз низагта торалар вә халыкның дингә ихтирам хисеннән файдалана белгән Шәрекъ шәкертләренең осталыгы аркасында динсезлек сыйфаты берлән сыйфатланалар иде. Шуның аркасында болай да бик зәгыйфь булган көчләре берлән халыкка, халыкның зур кыйсеменә таяна алмыйлар иде. Ул гына да түгел, бу кыйсем халык, Идел буенда туса, Идел буеның ихтыяҗын алга сөрә, Кырым булса, Кырым халкының, Кавказда булса, Кавказ мөселманнарының җитешмәүләрен тотып, баягы бер байрак астына кертелгән «Бөтенрусия мөселманы иттифакы»на[19] төрлеләндерү, хаталандыру куша иде.

Читтәге мөселманнарның хәле берлән уграшуны хәтерләренә дә китермәенчә, «Японияне мөселман итәмез» дип йөртүчеләрдән, табигый, көләләр иде. Менә шул аермалар, менә шул үзгәлекләр, хәзер безгә бик кечкенә кебек күренсә дә, ун ел элек бик зурлар иде. Шул вакыттагы хәлләр өчен зур тәэсир итәрлек көчлеләр иде. Беренче хатаның йимеше булган ышанышмау кушылгач, боларның арасында һичбер төрле кул сузып җитмәслек чокыр казыла, халыкны икегә бүлә торгач, халыкның хезмәтчеләренең бик күбесен бер-берсе берлән тартышырга бора торган яңгы мәйданнар, яңгы сугыш сафлары ача иде.

Алтынчы, җиденче, сигезенче еллардагы «иттифакчы»лар, «таңчы»лар, «уралчы»лар[20] булып чыккан берничә бүлекне тудырган көчләр, шөбһәсез, менә шул без сөйләгән гамилләр иде.

## VII

Гади халыкның тарихка, тарихи вакыйгаларга үзенә башка нәзары бар. Ул караш буенча, бер халыкның тормышы менә шулай табигый итеп агып барганда, әллә нинди харикылгадә көчле бер батыр туадыр да, кысылып килгән милләтне мәхкүмияттән чыгарып, үзенә баш иттереп куя. Әхлакан бозылып беткән бер халык бик тирән иттереп фисык-фәсадка чумган чагында, нур кебек ялтырый торган бер әүлия килеп чыга да шундагы халыкны вәгазь берләме, башка куәт берләнме җиңеп, шул әүлияның үзеннән аз гына ким дәрәҗәдә пакь иттереп куя.

Бу кыйсем халык, бу фәүкылгадә көч күктән иңәме, йирдән туамы — анысын да уйлап тормый, ул чыга да золымны мәхү итә, караңгылыкны яктырта, фәкыйрьлекне бетерә. Кайдан чыга, ничек туа — аның анда эше юк. Шуның өчен аның күз алдында тарих аның бербуйдан агып бара торган, мәгълүм кануннар буенча хәрәкәтләнә торган халыклар, милләтләрнең үткәндә вә хәзердә кылган эшләрнең итогысы, якүнесенең җыентыгы түгел, аларча, тарих — милләтнең тормышы өстеннән сикереп йөри торган, адәм баласының башыннан очып йөри торган «бәхет», «бәхетсезлек» кошы.

Ул кош күп вакытны тик тора, ул вакытта халык та тик тора. Аның да тарихы алга да, артка да бармый, хәрәкәтләнми. Кайвакытта ул «кара бәхет» булып халыкның янына куна. Халык иңгери, сыкрый, җәфа чигә, тагы «бәхет» килә дә тагы күк йөзе ачылып китә. Халык кәефләнә, рәхәтләнә, иллә ниһая шулай китә, ягъни бу халыкча тарих өзелеп-өзелеп бара торган, халыкның тормышында аерым-аерым күрелә торган ак

бәхетле, кара бәхетле көннәрдән гыйбарәттер. Шуның өчен аның тарихында еллар, гасырлар юк, аның уе тарихның калдырган шадралар, кытыршылары буйлап кына ага.

Мамай заманында, Туктамыш вакытында[21], урыс алган чагында, пәйгамбәр заманасында[22], сәхабә кирам чагында[23], мөҗтәһидләр бар вакытта менә болар барысы да шул халыкның тарихи төшенчәләренең тәсбих төймәләре.

Менә шул караш бөтен халык арасында бик таралган нәзар булганга, безнең заманда да һаман әле бик күп кеше тормышның үзгәрешенә, тарихның аңлавына шул күздән карый. Шуның өчен бездә дә «17 октябрь килде, хөррияте әдъян, хөррияте каләм туды» дигән җөмләләр авыздан-авызга сөйләнә, шуның өчен бездә дә әле 17 октябрь Манифесты[24] бөтен милли-мәдәни хәрәкәтемезнең баш тудыручысы, үстерүчесе иттереп карала. Ләкин тарих вә голуме иҗтимагыя голямасы алдында мондый тарихны сикертеп җибәрә торган фәүкылгадә көчле баһадирлар, алмаз кебек пакь әүлиялар юктыр. Тарихның алышуы аларның әллә кайдан килеп чыгуларына багланып тора торган иттифакый бер сикереш түгелдер.

Боларча тарихта мәгълүм затларның рольләре инкяр ителмәсә дә, аларның күктән иңүләре, җир астыннан килеп чыгулары катгыян кабул ителмидер. Андый затлар кирәк, әүлиялар, кирәк, баһадирлар булып мәйданга атылсын, шул халыкның үз теләгенең мөҗәссәме иттереп кенә каралдылар.

Шуның өчен бу тарих голямасы алдында 17 октябрь кебек тарихи көннәр — халыкның эчендәге алышынуны ясаучы гамил булмаенча, халыкның эчендә ясалган, эшләнелгән үзгәрешләрнең өстеннән пәрдә ачылган көн генәдер. Шуннан соң күрелгән эшләр һичберсе 16 октябрьнең кичәсендә туа башлап, 17сендә үсеп беткән эшләр булмаенча, әллә никадәр элек караңгы бер төндә туган, озын мөддәт үскән эшләрдер. Аларча, 17 октябрьдән соң ачыктан-ачык мәйданга чыккан сәяси фиркаләрнең шуннан элек тә хәятлары булырга тиештер.

Аларча, шунда чыккан фиркаләрнең 17 октябрьгә кадәр дә таянып килгән аерым бүлекләре, шул фиркаләрне үстерә торган аерым әхвале рухияләре булырга тиештер. Менә шул ноктадан караганда, безнең сәяси-иҗтимагый хәятымызда үземезгә күрә роль уйнаган шул «иттифакчы»лар, «таңчы»лар[25], «уралчы»ларны үстерә торган гамилләр бар идеме? Шуларның килеп чыгулары иттифакый гына бер эш түгел идеме? Һичкем инкяр итмәсә кирәк, унтугызынчы гасырның ахырында безнең Идел буе татарының тормышында зур бер хәрәкәт башланды (ысуле җәдид низагысы, муллалар сүгелүе, мәдрәсәләр забастовкасы, кием-салым гаугасы шул хәрәкәтләрнең дорфача тышка чыгуы иде).

Менә шул эчтәге зур хәрәкәтнең гамәли, психологический факторының иң зурысы, шөбһәсез, халыкның «тормышның хатирәлелекне эченнән сизенүе» иде. Менә шул «хатирәлелекне сизү» аны уйга төшергән иде, аны уйлый-уйлый, тормыш сипләнмәенчә ярамый дигән фикергә китергән иде.

Димәк, бу вакыттагы безнең татарның хәрәкәте, үзенең хәятын саклар өчен ясаган мөдафәгасе, бу вакыттагы татар тормышында үзгәрешләренең төбе борьба за существование иде.

Милли хәятны саклау өчен читтән көч алып сипләмәенчә мөмкин түгеллекне аңлы сыйныф һәммәсе иштиракь итсә дә, шуны кайдан алу, никадәр алу хакында фикерләр бик төрле иде.

Бер кыйсем халык, сипләнәчәк материал бабаларымызның кабереннән алынырга тиеш, алар да Бохарада, Багдадта моннан мең генә ел элек үлгәннәр, көрәк, балта алыйк та, шуларның каберләрен казып, шундагы ләхет такталары берлән йортымызның җимереген турайтыйк, шундагы кәфен бүзләре берлән сүтегемезне ямыйк, диләр иде. Бу халык тузу, искерү дигән нәрсәне аңламый торган бер кыйсем булганга, шул көлке фикергә каршы килгән һәммә кешегә дошман булып мәйданга атылалар. Мантыйксыз-нисез мәсьәләне чуалталар иде.

Болар безнең милли хәятымызның консерваторлары, искелекне саклаучылары иде. Ләкин аның кай йирендә яхшысы, кай йирендә начар, черегәне икәнен күрерлек күзләре булмаганга, болар шул иске тормышның һәммәсен кочаклап, «шул гына хак тормыш, моңгарга башка һәммәсе батыйль» диючеләр иде. Боларча, бер фирка булу, партия тәшкил итү яңгылык булганга, бу кыйсем халык шул тарихи көннәрдә мәгълүм бер бүлек булып чыга алмады. Соңгы елларда үзләренә махсус бер орган берлән «Дин вә мәгыйшәт»[26] берләшкән кебек кылынсалар да һәм дә, редакциядән файдаланып, сагыя вә доnoслар берлән фикер дошманнарына каршы бик зур фисык-фәсад, золым ясасалар да, болар халкымызның таза тәне өстенә чыккан Иран, бохари чыуаны булдылар да калдылар. Вә халкымызның эчке хәрәкәтенә, мәдәни агышына һичбер төрле тәэсир ясамадылар. Киләчәктә дә бер партиянең төбе булырлык яраклылык күрсәтә алмадылар.

Икенчесе — менә шул кыйсем халыкның кысуын, шул бүлек халыкның мантыйксызлыгын, кыска күзлелеген үзләренең өстләрендә хис иткәннәр. Болар — унтугызынчы гасырымызның ахырында йитешкән мәдрәсә шәкертләремез. Һәм дә шул тормыш үзгәрүендәге һәртөрле дулкыннарны бергә үткәргән, милли тормышның һәрбер елышуында бергә булган аңлы яшьләребездер. Болар үзләренең тәрбияләре ягыннан русларның радикаль фикерлеләреннән дәрес алганга, төрекләрнең, гарәпләрнең

исляхчыларыннан мәгълүмат җыйганга, бөтен фикерләре, уйлары берлән яңгаруга ашкынучылардыр. Боларның әхвале рухияләрендә шул иске тормышымызның кысынкылыгына каршы булган дошманлык хисе иң зур роль уйнаганга, болар — татар тормышының протестчыларыдыр. Болар — татар тормышының реакциясенә каршы туган реакциянең йимешләредер.

Нинди генә эшкә тотынсалар да, баягы кыйсем — консерваторлар — боларга каршы чыкканга, мәктәп, мәдрәсә исляхында киртә салганда, өстенә-башына киенгәндә кяфер дип кычкырганга, һәр мәдәни хәрәкәтенә аяк чалганга, боларның үзләренең беренче лозунгларыны «Бетсен искеләр!» дип кычкырулары табигыйдер вә шул юлда иң беренче милли бурыч шуларны бетерү дип тырышулары, тартышулары — боларның иң самими хәрәкәтләредер.

Менә шул искелеккә протест әсасында унтугызынчы гасырның ахырында яшьләр берләшәләр. Иң әүвәл җимерү, иске тормышны җимерү өчен вә шул юлда көчне берләштерү өчен «Шәкертлек» исемендә махсус бер җәмгыять[27] янында оешалар.

Тугыз йөзенче еллардагы бу халыкның «мөфти төшерәмез» дигән хәрәкәте вә шул хактагы Русиянең бик күп шәһәрләре тарафыннан җибәрелгән мәктүбләре, бәяннамәләре — боларның җәмәгать эшендәге беренче адымнарыдыр.

Егерменче гасырның башындагы Казанда чыккан «Тәрәкъкый»* журналлары[28] — бу бүлек халыкның беренче органыдыр. Ләкин озак вакыт үтми, «Шәкертлек»нең җимерү программасы тар кебек тоела. Аның эчендә хәрәкәт башлана. Мисырдан килгән дини реформалар берлән Русиянең әдәбиятыннан, матбугатыннан килгән сәяси-иҗтимагый үзгәрү уйлары шунда керә башлый. Озын-озын кычкырышлар туа, икътисади, иҗтимагый мәсьәләләр мәйданга чыга.

Ерактан гына килә торган русларның радикализм фикерләре берлән Аурупаның социализмысы шунда килеп бәрелә. Боларның икесендә дә бу татар яшьләре үзе яратмаган бөтен искелекләрне себереп түгүне күргәч, менә монда безнең теләүләрне әллә кайчан формулага кертеп куелган икән дип, шуларга якынлашалар. Шуларның фәлсәфәләре берлән танышып, шуларның әдәбияты, матбугаты берлән тәрбияләнергә тотыналар. Үзләренең радикальный фикерләренә шунда бик күп арка таяначак мәгълүмат алалар. Һәрнәрсәгә икътисади күз берлән карап төшенергә өйрәнәләр.

Ләкин тагы монда да искелеккә барып төртеләләр: берсе — русларның народниклар агышы, икенчесе — читтән килгән марксизм агышы.

Татар яшьләренең моңганчы килгән көчләре шул ике юл чатында аптырап кала. Тегендәме? Мондамы?

Шул сөальгә җавап өчен тагы озын-озын бәхәсләр, моназарәләр, тагы ике уртада аңлашу башлана.

Ләкин тормыш үзе боларны тагы бүлеп җибәрә.

Татар мәдрәсәсендә тәрбия ителгән татарның ганганәсендә, татар тарихында нык нигезләр күргәннәре, народникларга таба мәел итеп, «таңчы»лар булып мәйданга чыгалар. Үзләренең программаларына социализмны язсалар да, народниклардагы миллияткә биреләчәк урын марксизмга караганда үзрәк, якынрак иттереп хис ителә.

Марксизмдагы кырт кисүләре, алардагы милли, дини гамилләргә тарих калдыклары дип караулар боларның эчләрендә яшеренеп яткан миллилекләрне кытыклый, эчләрен пошыра. Шулай итеп, алар да татарның милли социализмысының фиркасе булып мәйданга атылалар вә «миллилекне» үзләренең программаларының бер ноктасы итеп алып баралар.

Татар тормышының агышында күңелгә утырырлык берни күрмәгән яшьләр, татар тормышының бөтен китүен башыннан алып ахырына кадәр үзгәртергә кирәк дип ышанганнары (боларның күбесе мәдрәсә күрмәгән затлар иде), тормышның бөтен ясалуын башка нигезгә куярга тиеш дигән фикергә киләләр. Бөтен мәдәни тартышуларның гамилләре, икътисади мәнфәгатьләргә дигән фәлсәфәне кабул итеп, марксизмга кушылалар вә татар тормышының бер кыйсемендә эшче халкында шул фикерне тазартыр өчен «уралчы»лар булып мәйданга чыгалар.

**VIII**

Шул ике арада татар тормышының сул канатыннан бара торган протестчылар берлән консерваторлар арасында бер буш йир, бер урталык кала. Менә шул урталыкны «иттифакчы»лар тудыралар. Ләкин бушлыкның бик киң булуы һәм сул ягындагы чиге суллар тарафыннан гына куелган мәсләк баганалары берлән генә аерылуы шул ике арадагы хөдүдне саклар өчен куелган гаскәрнең фәкать суллар (оланнары) угланнары булуы сулларның урталыкка таба җыелуларына манигъ була алмыйдыр. Шуның аркасында суллар берлән урталык арасындагы сызык, акрын-акрын бетеп, керделе-чыктылы бер ызан була да каладыр. Урталыкның уң тарафында чиге мәсьәләсе тагы мөшкел. Мондагы фирка, фикер, мәсләк чикләре бервакытта да сызылмаганга, бу якта хөдүд күчмә халыкның өлкә чиге кебек була да тора.

Яз була башласа, консерваторлар, ишәкләренә атланып, елыныр өчен урталыкка киләләр. Кыш була башласа, «урталык» сыгыныр өчен консерваторлыкларга баралар. Хосусән ике фирканең дә чиктәшләренең тәрбиясе бер булганга, болар, берсеннән-берсенә күчеп йөри-йөри, ике арадагы начар читәннәрне бөтенләй җимереп бетерәләр. Менә шул чикнең начар саклануы «уртаклык»ның хәлен бик «иттифакый» нәрсә итеп куя. «Уртаклык»ның арка терәп таяначак көчләре әле уңга таба, әле сулга таба шуып йөргәнгә, аның өстенә утырырга теләгән «Мөселман иттифакы»ның хәлен вә шуларга таянып эш итәргә маташкан мөселман фракциясенең аяк астын тайгакка әйләндерә, аның гакыллыгын бетерә.

Әүвәлге заманаларда «Мөселман иттифакы»ның кемнәр тарафыннан булса да кабул ителгән бер программасы бар чагында, «Мөселман иттифакы»ның сәяси өлкәсе кая чикле барганын күреп торырлык озын күзле Йосыфлары[29] бар чагында, уң тарафта менә моннан үтәргә ярамый дип кадалган чик базары янында каравылчы Исмәгыйль бәк бар чагында, «Мөселман иттифакы» урынында нык утырган бер партия булып җитмәсә дә, хәзерге кебек уң ягыннан күтәрсәң — сулга ага, сул ягыннан салам кыстырсаң, уңга авыша торган кесәл хәлендә түгел иде.

Менә шул вакытта «Мөселман иттифакы» уң тарафтагы чигендә «сәяси хокукларны теләүче тәрәкъкыйпәрвәрләр фиркасе» дигән вывескасы аяк астына тапталмаган чакта, «Мөселман иттифакы» татар тормышында сәяси вә мәдәни бер гамил иде.

Ул үзенең аз булса да бер каравылчылары берлән мәсләк алыштыру, чиктән чыгу, киртә сикерүне бик җиңелгә санаган халыкка каләме берлән генә булса да, «кыйбла» шуннан узмый, уңга тагы борыла төшсәк, намаз намаз булмый дип, Тимер Казык йолдызлык вазифасын итә иде. Ләкин «Иттифак»ның шул уң тарафтагы иң куркынычлы чигенә каравылга баскан солдатлары үзләре теләп кенә шунда торганга, алар китсә, тагы шунда кеше куярга кирәк дигән фикер урталыкта аңланып йитмәгәнгә, Йосыфлар, Гаспринскийлар китү берлән урталыкның чиге буш калды. Аның теге вывескасы элгәреге асылынып торса да, кайбер вакытта шуның астына җыелып, бала-чага «кунак-кунак», «кода-кодачалык» курчагы уйнаса да, өстенә язылганына игътибар бетте.

Әфьюн берлән исергән мулла берлән кочаклашып килә торган рус арасында дуңгыз, аракы сатып йөрүче рестораторлар килеп кергәндә «урталык» — әфьюн, аракы зарарлы, халык арасына кертергә ярамый, милләт кибә, бетә, дуңгыз ите симез булса да, шәригатемездә хәрам, милләтемездә мәкруһ дия алмады. Шуларга каршы «чибәр егет, юлыңда бул» дип озата алмады. Урталыктагы «Иттифак» шул мәсьәләдә үзенең мәсләк ягыннан, әхлак ягыннан банкротлыгын игълан итте. «Иттифак» фирка уларак хәятын бетерде. «Иттифак» сәяси, мәдәни бер оешу уларак яшәешенә хатимә чикте.

Бу ник болай булды? Ни өчен «Мөселман иттифакы» үз эчендә шулкадәр күп миллионлы халык арасында кечкенә генә «Мөселман иттифакы» яши, үсә алмады?

Урамдагы хәбәрләргә караганда, яшьләр каршы килде, фәлән әфәнде сөймәде, фәлән кеше яратмады. Ләкин тарихи вакыйгалар хакындагы безнең нәзарымыздан, әлбәттә, бу сүзләр гайбәттән башка бернәрсә түгелдер. Бер партиянең, бер фирканең бер милләт эчендә яши белүе-белмәвенең сәбәпләре тагы тирәнрәк, тагы олуграктыр. Шуның өчен шундый сүзләр ишетергә бик тугры килсә дә, тарихи вакыйгаларны иҗекләгәндә аларга кыйммәт бирергә ярамыйдыр.

Соң, нәрсә сәбәпләре?

Бик күп.

Берсе — шөбһәсез, иң зурысы «Мөселман иттифакы» сәяси партия булып яшәрлек Русия мөселманнары арасында зәмин юк иде. Аның зур, киң иттереп күтәргән байрагын алып барырлык көч юк иде. Бу байракны күтәргәндә зурлыгына, киңлегенә карап безне белмәгән русларның бер гөруһысы исе дә киткәндер, безнең көчемезнең мөҗәссәме дип күрсәтелгән шул байракка ышанып, сәяси хата да ясагандыр. Анысы башка.

Ләкин ул вакытта сәяси «Мөселман иттифакы»н алып барырлык көч юк иде. Хосусән ике тарафтан уңнар, суллар аерылып чыккач, байракны күтәреп кенә тору да бик мөшкел иде.

Икенче — «Мөселман иттифакы»ның ныгыган мәркәзе — мәсләк, әхлак кагыйдәләре берлән бергә береккән үзәге юк иде.

Аның әгъзалары арасыннан бер кыйсем халык шул идеягә хезмәтне үзенең гаяи әмәле итеп алмаган иде.

Шуның өчен ул әгъзалар «Мөселман иттифакы» байрагыннан файдаланырга яратсалар да, Думага сайлауларда, сайлануларда вә башка шәхси эшләрендә «Мөселман иттифакы»ның вәкиле итеп күренергә сөйсәләр дә, үз тарафыннан аңгарга хезмәт итүче, бер заэләгә хезмәт итүче бик аз иде. Башлап йөргән Йосыфлары киткәч — юк та иде.

«Мөселман иттифакы»ның кайгысын, үзенең хәсрәтен, шатлыгын, үзенең бәйрәмен итә торган бер гөруһның юклыгы «Мөселман иттифакы» берлән бергә яшәп, бергә үсеп баручы бер кыйсемнең юклыгы «Мөселман иттифакы»н җансыз тән кебек итеп куя иде. Аны рухсызландыра, аны суыкландыра иде.

Хосусән шуның кассасында акча булганда, тирә-юнендә мыжгылдап йөрүче «иттифакчы»ларның актыккы күздән балны алып бетергәч тә бердән югалулары «Иттифак»ның мәгънәви кыйммәтен төшерә иде. Халык алдында аның хезмәтчеләре хакында наемщиклар хакындагы туарга мөмкин фикерләр, уйларны тудыра иде.

Шуның аркасында арттан килә торган, үсә торган яшь буынга сәяси бер үрнәк булып та тора алмый иде. Картлары сафтан чыкканда, яшьләрдән яңгы көчләр берлән кирәген тутыра алмый иде.

Өченче — «Мөселман иттифакы»ның әгъзаларының бик үк иттифакый кешеләрдән булуы иде. Бая әйткәнчә, моның уңнан да, сулдан да үз тарафыннан саклана торган каравылы булмаганга, ике яктан да җимереп төшкән ярны «безнеке» дип кабул итә торганга, әгъзалар мәсләк-уй җәһәтеннән кырык корамадан гыйбарәт иде.

«Мөселман иттифакы»на керер өчен куелган үлчәү мөселман булу һәм дә, икенче иттереп, мөселманнарның иттифак берлән торуларын күңеленнән генә теләү җиткәнгә, моның даирәсенә сыймаган мөселман юк иде. Шуның өчен моның эчендә мәгълүм тәртип, мәгълүм дисциплина ясау мөмкин түгел иде.

Дүртенчесе — «Мөселман иттифакы»на программа төзегәндә, аңгарга сәяси рәң бирү хатасы иде. Бөтен мөселманнарны, кадет партиясенең бозаулары иттереп, кече абзардан олуг абзарга «Һайт, түкә!» дип сөрүнең вакытсызлыгы иде.

Читтән торып карaганда, бу программа сәяси бер хата, сәяси балалык, сабыйлык иде.

Менә шул балалык уены уйнаганда, милләтемезнең истикъбале, идеалы берлән балача мөгамәлә ителгәндә, киләчәгемез өчен иҗтимагый, сәяси хаталар ясалганда, татар тормышының сул канаты «таңчы»лар, «уралчы»лар гына шул хатаны тәмамы берлән күрә алганнар иде.

Алар гына, шул вакытта халыкның наданлыгыннан, сәяси тәрбия күрмәвенән файдаланып, бер «Иттифак», бер «Мөселман иттифакы» ясыймыз дип йөргән затларның хыяллары, шәкерт фаразлары берлән көрәшергә тиешлеген аңлаганнар иде. Алар гына шул милли, мәдәни бурычны үтәргә тотынганнар иде. Алар гына «Иттифак»ка мохалиф фирка булып мәйданга чыкканнар иде. Ләкин зәмин сул канатның файдасына түгел иде. Халык, кысыла-кысыла йөдәп беткәнгә, йончыганга, кайдан гына өн килсә, шунда хазир иде. Кайдан гына «монда хәляс» диелсә, шунда барачак иде. Тагы шуның өстенә «Иттифак»ының башында кемнәр дә мохалифләре кемнәр?

Исмәгыйль бәк, Галимәрдән бәк, Йосыф Акчура углы. Ул гына да түгел, әллә никадәр мирзалар — түбәтәйле мирзалар.

Дөрест, алар түбәтәйне 17 октябрьнең таңында гына киделәр. Дөрест, алар шул көннәрдә генә Савелий Алексеевичтан Сөләйман Әхмәтҗан углына, Константин Павловичтан Хөсәен Вәли углына әверелделәр. Алай булса да, әверелделәр.

Алар, мирза кешеләр, белми эшләми торганнардыр. Әле дә сөяк сындырып, бик озак каралып йөрделәр, «Иттифак» диләр, ясыйк инде, «Мөселман иттифакы» булсын инде, йәңез, хәзрәтләр, фатиха, «Мөселман иттифакы» булсын, амин, Аллаһы әкбәр!

«Мөселман иттифакы» булды.

Шул обыватель ноктаи нәзарына «Мөселман иттифакы»н шау-шу чыгармау дип аңлаган халыкка ничек иттереп «Иттифак»ның төбе череклекен аңлатырга мөмкин иде? Ничек иттереп «Иттифак» партиясенә каршы килгән кешеләр үзләренең каршы булуларын, мохалифлекләрен мәсләктән, «Иттифак»ның мөмкин түгеллеген күргән-белгәннән икәнен аңлата алалар?

Ничек «Иттифак ясыймыз» дигән сүз «көлдән ботка пешерәмез» дигән хата икәнен күрсәтә алалар?

Тагы «Иттифак»ның артында шулкадәр милли авторитетлар торганда, япь-яшь кешеләр, матбугат мәйданына чыгып килә торган мөхәррирләр шул авыр милли бурычны үти алалар идеме? Менә шул хәлгә башка сул канатның үзендәге икелек тә тәэсирсез калмады.

6 нчы елда Мәкәрҗә съездына[30] җыелган халык «Мөселман иттифакы»ның программасыны мөзакарә итәчәк булса да, мөнтәкыйд сыйфаты берлән дә шунда «уралчы»лар килмәделәр вә шул мәҗлесләрдә йөрүне, сөйләүне файдасыз табып, шул зур съездга эш ягыннан булмаса да, фикер ягыннан бик күп хезмәт иткән съездга катышмадылар (шунысы гаҗәп, шул вакытлардагы съездга иштирак иткән «таңчы»ларның мәсләктәшләре — народниклар, Думага да байкот ясап, беренче сайлауларга катнашмаганнар иде. Съездга иштиракь итмәгән «уралчы»ларның мәсләктәшләре, марксистлары да сайлауларга, мәҗлесләргә әһәмият биреп, Думага да катышканнар иде). Вә шундагы фикер, мәсләк тартышуында халкымызга «булачак»ны, «мөмкин»не, «хыял»дан аерып бирүдә «таңчы»ларны ялгыз калдырдылар.

Ул вакытка кадәр Беренче Дума булып таралган иде инде.

Безнең халык та аз-маз сайлау-фәләнне күргән иде. Бер генә булса да тәҗрибә алган иде. Шуның өчен шул съезд бөтенләй үк ят булачак түгел иде.

Съездда да былтыр пароходка утырып качып киткән яшелләрдән дә ычкынырга җиңел түгел иде. Чөнки «таңчылык» хәзер мәгълүм бер урын тоткан организация булып җиткән, аның әгъзалары танылган, аның органы «Таң» таралган бер гәзитә[31] булган иде. Шуның өчен ачу комиссиясендә «иттифакчы»лар берлән «таңчы»ларның вәкилләре бергә утыралар иде.

«Таңчы»ларда — былтыр гына тагуннан качкан кебек кагылган «таңчы»лар да — шул мәҗлестә бер хокуклы әгъза булып эшлиләр иде.

Ләкин ачу мәҗлесендә тагы аңлашылмау кузгалды. Рәшид казый рөхсәт алганда, «Халкымыз арасында тарала торган безнең шәригатькә мохалиф социализм, анархизм фикере берлән тартышыр өчен съезд ачамыз» дигән маддәне тыккан.

«Иттифакчы»лар үзләре дә бу сүздән разый түгел. Бу сүзләр — аларның да руслар берлән катнашып йөргәннәренә уңайсыз бер тәгъбир. Шуның өчен бу программа берлән җыелган съездда утырышу кадет танышлары бар кешеләргә, «иттифакчы»ларга күңелсез.

Карагруһларда гына әйтелә «анархия», «социализм берлән көрәшү» байрагы берлән эшкә керешү авыр.

Тагы озын сүзләр, озын мөзакәрәләр, кычкырышлар.

Ләкин бу юлы «таңчы»лар берлән «иттифакчы»лар арасында түгел, «иттифакчы»лар берлән «иттифакчы»лар арасында.

Рәшид казый үпкәләгән, аны карагруһ дигәннәр.

Галимәрдән бәк союзының лозунгысы берлән ясалачак съездга кермим, дигән.

Тагы әллә ниләр, әллә ниләр.

Акчура углы берлән «таңчы»лар берьюлы ике араны килештереп йөри. Үпкәләрне язарга анда бара, монда чаба, җалына, җалбара. Съезд ачылырга була.

Ләкин съезд программасы хакындагы хаталыкны Рәшид казый үз өстенә алырга булып, съезд үзе теләгәнчә программа ясарга булып ачылырга була.

Җыеламыз, җыелалар.

Зал тулган, халык улый, гөжли, Нижнийның иң зур залы шыгрым тулган, Русиянең бөтен тарафыннан җыелган мөселманнарның саны җиде-сигез йөз.

Ачу комиссиясенең докладчигы сыйфаты берлән Мәхмүтфуад әфәнде Туктаров, съезд ачылуга кадәр ниләр булганы берлән халыкны таныштырып, Рәшид казыйның программасындагы сүздән кайтканлыгын белдереп, съездны ача. Президиум сайлана. Съезд эшкә керешә.

## IX

Мәҗлес «халыкны оештыру» лозунгысы берлән эшкә керешә. Әрәм булып ята торган таркау көчләрне бергә оештыру уе съездның ун канатын да, сул канатын да бергә җыя. Шул таркау көчләрне бергә туплап, милли ихтыяҗларны тутырыр өчен эшләргә теләү ике тарафны да бер ноктага таба бора. Съездның башында лозунгы иттерелгән таркау көчләрне «оештыру» съезддагы иттифакый җыелган төрле агым кешеләрен бергә беркеттерә торган бер гамил була.

Ләкин съездны бер ноктага таба бора алган «халыкны оештыру» лозунгысы ике тарафтан ике төрле аңлашыла вә шуның аркасында берлеккә сәбәп булган ук гамил ике тарафның аерылуына гамил була.

«Иттифакчы»лар аңлавынча, халыкны оештыру лязем. Русиядә 25–30 миллион мөселман бар. Болар Русиянең сәяси тормышында һичбер төрле роль уйнамыйлар. Мәмләкәтнең идарәсенә һичбер төрле тәэсир ясый алмыйлар. Ул гына да түгел, сарих үзләренең генә булган эшләренең дә үз мәнфәгатьләре файдасына хәл ителүенә һичбер төрле тәэсир итә алмыйлар. Болар буш көч булып торалар.

Мәмләкәтнең идарәсе 17 октябрь Манифесты берлән халыкның тәэсире астына бирелде. Думадан үтмәенчә бер закон да чыкмаячагын игълан ителде. Димәк, Русиянең дахили эшләренең агымы Думадагы көчле партияләрнең ихтыярына күчте. «Без Русия мөселманнары никадәр күп булсак та, Думада, әлбәттә, күпчелек ясый алу ихтималымыз юк. Шуның өчен Думада көчле булуы ихтимал тотылган вә теләкләре берлән безнең мөселманга чит булмаган сәяси бер партиягә кушылырга кирәк. Ул партия дә — кадетлар партиясе. Шуның өчен мөселманнарны оештыручы нокта, мөселманнарны бер көч итүче гамил кадетларның сәяси программалары булырга тиеш. Шуның өчен кадетларның сәяси программаларын кабул итеп, һәммә мөселманны шул программа астына җыйыйк. Уңы, сулы, бае, ярлысы — һәммәсе шунда берләшсен! «Мөселман иттифакы» дигән партия һәммәсенең үз партиясе булсын!»

«Таңчы»лар «халыкны оештыру» гамилен бөтенләй башка ноктада таптылар. Аларча Русиянең төрле почмакларына таралган, төрле гадәт-йола астында яши торган мөселманнарны дөньяның килеше берлән берсе бай, берсе фәкыйрь, берсе мирза, берсе хезмәтче, берсе мулла, берсе мужик булган мөселманнарны берләштерә торган нокта бер генә: ул да — фәкать милли, дини мәсьәләләр. Төркестан сыртының, дала кыргызының, Касыйм мишәренең, азәрбайҗан татарының — җыенысының җитмәгән йире — дини, милли ихтыяҗларыдыр.

Мәктәп-мәдрәсә мәсьәләсе Кырымда да, Казанда да, Ташкентта да, Тифлистә дә бер дәрәҗә исляхка мохтаҗ. Идарәи рухания эшләре, вәкыфларның чуалчыклыгы Идел буенда да, кыргыз даласында да, Кавказ таулары буенда да, Сыр-Дәрья якларында да бертөрле исляхны көтә.

Шуның өчен «Мөселман иттифакы» Русиянең төрле почмакларына таралган мөселманнарны милли, дини юлда бер көчкә җыя торган мәдәни җәмгыять булырга кирәк, мәдәни бер иттифак булдырырга кирәк. «Мөселман иттифакы»ның әгъзалары арасында иҗтимагый хәлләре берлән бик төрле булган бөтен мөселман керә алсын өчен, «Мөселман иттифакы»на үзенең сәяси фикере уңдарак, сулдарак булган мөселманнар да булына алсын өчен, аның сәяси программасы булмаска тиеш, ягъни «Мөселман иттифакы»на кергән кешеләр, үзләренең сәяси фикерендә хөр булып, теләсәләр, кадетларга кушылырга тиеш, теләсәләр, трудовикларга, теләсәләр, октябристларга кушылырга ихтыярлы булырга тиеш. Ләкин сәяси программа беркем өчен дә «фәлән партиянең» дияргә мәҗбүр булмаска тиеш.

Менә шул карашлардагы ихтиляф: «Мөселман иттифакы»на бер тарафның «сәяси оешу» дип карарга теләве, икенче тарафның «мәдәни оешу гына» дип карарга маташуы шул киләчәк мәсьәләләргә тәэсир ясады, бөтен мәсьәләләрдә мәҗлесне икегә бүлде вә ике тактиканы бербуйдан тартыштырды. Шул мәҗлестә үк «иттифакчы»лар, «таңчы»лар дигән ике агым туды.

«Иттифакчы»лар, үзләренең ноктаи нәзарларын тормышка татбикъ итәр өчен: «Бөтен мөселманнар кадетларның мәркәз комитетлары берлән якын тора торган сәяси бер мәркәз комитетка ияреге кирәк вә, бөтен мөселман булган шәһәрләрдә йирле мөселман комитетлары ясап, йирле кадетлар берлән бергә хәрәкәт итәргә кирәк, сәяси тартышуда кадетлар берлән бер байракны мөхафәзә итәргә кирәк», — диделәр.

«Таңчы»лар: «Бөтен мөселманнарның мәдәни эшләрен алып барыр өчен мәгълүм бер мәркәз комитетка табигъ итәргә кирәк. Шул мәркәз комитет бөтен Русиягә таралган мөселманнарның гам булган мәдәни эшләрендә юлбашчы булырга тиеш.

Бөтен мөселманнарның гам булган ихтыяҗларын бергә оештырып, бер кулдан эшләргә тырышырга тиеш. Шул комитет бөтен мәдәни эшләремезнең учагы булырга тиеш. Мәктәп-мәдрәсәнең исляхы өчен лязем дәрес китаплары хәзерләү аның кулында булырга тиеш. Халыкның агаруы өчен лязем булган фәнни китаплар хәзерләү комитетының кулында булырга тиеш. Халыкны гыйлем-һөнәргә алыштырыр өчен кирәкле җәмгыятьләр ясау, аларга рәһбәрлек итү комитетның вазифасы булырга тиеш.

Туып килә торган әдәбиятымызның тәрәкъкыйсенә лязем булган шартларны тудыру аның бурычы булырга тиештер».

Ваклап әйткәндә, «Мөселман иттифакы»ның бөтен Русия мөселманнарының гыйльми ихтыяҗына хезмәт итәрлек нәшер җәмгыятьләре, үзенең китап складлары, үзенең кыйраәтханәләре, үзенең китапханәләре булырга тиеш. «Мөселман комитеты» туып килә торган һәр яшь көчне милли-мәдәни хезмәткә кушар өчен аның милли-мәдәни эшләр берлән алып барудагы программасы гына түгел, тәрҗемәханәләре, курслары, дәресханәләре булырга тиеш. Кыскасы гына, «Мөселман комитеты» гыйльми эшләремезнең һәммәсен үз кулына җыйган гыйльми бер мөселман мәркәзе хезмәтен итәргә тиеш. Шуның өчен мөселман күп йирләрдә ясалган йирле комитетлар шундагы мәктәпләрнең матди-мәгънәви ягын үз кулына алырга тиеш. Шундагы укучы яшьләрне мәгълүм юлдан алып барыр өчен аларга рәһбәр булырга тиеш.

Мөселман арасында туып килә торган театрны үстерүне, мөселман дөньясында хәрам итеп игълан ителү берлән былчырак йирләргә качарга мәҗбүр булган музыканы үз химаясенә алырга тиеш.

Ул гына да түгел, нә мәркәз комитетымыз, нә җирле комитетлар һичбер төрле сәясәт берлән маташмаска тиеш, нә кадетлар берлән, нә башкалар берлән комитет уларак мөнәсәбәттә булмаска тиеш.

Сайлауларда да, сәяси мәйданга чыгаруларда да һәркем, хөр булып, үзенә якын күргән партия берлән бергә хәрәкәт итәргә тиештер.

Менә шул ике ноктаи нәзар съезд буенча халыкны икегә аерып килде. Менә шул ике ноктаи нәзар, һичбер вакытта бер-берсенә кушыла алмаенча, Мәкәрҗә съездында «иттифакчы»лар, «таңчы»лар дигән бер-берсе берлән тартыша торган ике партиянең барлыгын тасдыйк итте.

Хәзер инде, ун ел үткәннең соңында, бәлки, ике карашның кайсы дөрестрәк икәнен аңларга юл ачыла төшкәндер. Бәлки, партия низагларында булуы табигый булган бәрелешүләр, кырылышулар хәзер онытыла төшкәндер дә бер тарафтан карарга мөмкиндер.

Минемчә, мөмкин. Һәм дә хәзер дә шул вакыттагы хатаны ап-ачык итеп күрсәтергә дә мөмкиндер. Киләчәктә шундый хаталар тәкрарланмасын өчен ачып бирү ляземдер.

Уйларга, төшенергә уңгай булсын өчен бераз хыял диңгезенә чумыйк: фаразан, шул съезддагы бөтен кешеләр «иттифакчы»ларның платформаларын кабул иттеләр ди. «Таңчы»лар да үзләренең сәяси фикерләреннән кайттылар, уңнар шул кадет программасын үзләренә муафикъ күрделәр. «Мөселман иттифакы» дигән бер партияне ясарга карар бирделәр. Ул гына түгел, ясадылар ди. Көчле бер мәркәз комитет тудырдылар. Мөселман булган һәр шәһәрдә йирле комитетлар сайладылар, «Мөселман иттифакы»ның клубларын мәйданга китерделәр ди. Кадетлар берлән һәрвакыт бер сүздә булып, һәр сайлауда бергә хәрәкәт итеп, бик күп кадет Думага җибәрделәр ди. Шул мәркәз комитет, кадетларга таянып, мөселманнарның хәлләре хакында бик күп сүзләр сөйләделәр, нотыклар ирад иттеләр ди.

Нәтиҗә шуннан ни туар иде ди. Бер-бер проект, мөселманнарның теләгән тутырырлык законопроект эшләнеп чыгар иде, диме?

Мөселманнарның хокукый хәлләре ислях ителер идеме ди?

Хәзер Беренче Дума вакытларын, Икенче Дума хәлләрен күздән кичерәмез, боларның икесендә дә күпчелек кадетларда иде. Мөселман фракциясе кадетлар берлән бергә иде.

Димәк, мөселманнарның йирле сәяси фикерләренең вәкилләре Думада күпчелек берлән иде. Шуннан ни чыкты?

Күзгә күренгән — нәрсә?

Һич!

Ник? Мөселманнар кадетларга хилаф партияләргә кереп закон үткәргәндә, күпчелекне бозмаганнардыр бит? Юк, юк... ник соң?

Чөнки Дума үзе бернәрсә тудыра алмады. Чөнки аңгарга ирек бирмәделәр, чөнки Дума таратылды...

Өченче Дума җыелганда, сайлау законы үзгәртелде, мөселманнар аз кертелде[32]. Үз хакларын мөхафәзә итәрлек дәрәҗәдән иңдерелде.

Болары һәммәсе дөрест? Ләкин ник Дума таратылганда Дума тарафында булган күпчелекле кадетлар моңгарга разый булдылар?

Чөнки кадетлар Думада күпчелек казанган булсалар да, илдә — Русиядә — таяначак көчләре юк иде. Чөнки ул сүзгә оста кешеләрне үз байрагы астына җыя алган булса да, Русиядә аның байрагы өчен тартышучы көч бик зәгыйфь иде. Чөнки кадетларның зур байракларын күтәреп барырлык мәдәни көчләр русларның үзләрендә хәзер түгел иде.

Мөселманнарның сайлау хакларын биш мәртәбә киметкән «Өченче июнь законы»на мөселманнар ләммим димәенчә разый булдылар.

Ник?

Чөнки мөселманнар, никадәр күп булсалар да, үзләренең сәяси мәнфәгатьләрен аңлар дәрәҗәгә килмәгәннәр иде.

Чөнки мөселманнарның сәяси хокуклары, арка таянырлык мәдәни мөәссәсәләре ясалмаган иде.

Чөнки мөселманнарның мәдәни көче нык түгел иде. Сәяси көчсез иде.

Ул гына да түгел:

Дума да таралмаган булсын, Беренче Дума биш елын бетергән булсын, Икенче Дума әле һаман гомер сөрә торган булсын. Шул вакытта «Мөселман иттифакы» үзенең программасын тутыра алачак идеме? Юк иде. Катгыян, юк иде.

«Мөселман иттифакы» үзенең Икенче Мәкәрҗә съездында[33] ук үзенең бөтен көчен мәдәни тарафка борырга карар ясарга мәҗбүр булачак иде.

Йирле кешеләрнең җитмәве, депутатларның наданлыгы, җәмәгать хезмәтчеләренең үз вазифаларын аңламаулары «Мөселман иттифакы» партиясен мәдәни бер җәмгыятькә әверелергә мәҗбүр итәчәк, әверелмәсә, бетәргә мәҗбүр итәчәк иде.

## X

Минем бу сүзләрем бәгъзе бер кешеләргә алдан хәбәр бирү кебек кенә тоелу ихтималы бардыр. Бәгъзе бер кешеләрнең «Дума бит үзе теләгәнчә яшәп карамады, кадетлар үзләре теләгәнчә күпчелекләреннән файда итә алмадылар. Шуның өчен Беренче, Икенче Думалар дәвам иткән булса да, «Мөселман иттифакы»ның сәяси партия булып хәяти банкрот булачак иде дигән дәгъвасы асылсыздыр, «коры дәгъва гынадыр» кебек могарәзәләр итү ихтималы бардыр.

Ләкин шул Беренче, Икенче Дума яшәсә дә, «Мөселман иттифакы»ның сәяси партия уларак яши алмавына җитәрлек дәлилләр тормышымызда юкмы? Минемчә, бар һәм дә сукырга күренерлек дәрәҗә ачыклары бар.

Думалар дәвам итте. Русиянең хәяты иркенчәрәк булды ди. Русиядә борынлап килә торган яшь милли көчләргә аяк чалынуы булмады, ди. Без, мөселманнар да, үземезнең сәяси фикерләремезне (ягъни кадет программасын) теләгәнчә татбикъ итә алу имкянына малик булдык ди.

Ләкин шул хактан файдалана белү өчен дә, әлбәттә, үз көчләремез булуы лязем икәне инкяр ителмәс. Ул вакытта да безнең ихтыяҗларымызны нинди генә булсын, сәяси булсын, иҗтимагый булсын, безнең өчен шул ук кадетлар эшләп биреп, авызымызга чәйнәп салу булмаячагына беркем дә каршы килмәс, ягъни шул вакыттагы эшләремезнең һәммәсенең дә эшләнеп фәгалиятькә чыгуы безнең кәгазьдәге хакымызга мөнасиб дәрәҗәдә түгел, үземезнең билфигыль көчемездгә мотабикъ дәрәҗәдә генә булуын һәркем тасдыйк итәр.

Голуме иҗтимагыядәге хокук — көчнең күләгәсе генәдер. Көчнең зурлыгы-кечкенәлеге берлән хокукның зураю, кечкенәләнүе мөтәнасибтыр. Көче булмаган кыйсемнең, сыйныфның хокукы кәгазьгә никадәр зур булса да, фигыльдә, эштә һичтер диган бәдиһиләрдән дә хәлемез мөстәсна булып калмас иде. Шуның өчен көчемез нисбәтендә генә хокукларымыздан файдалана беленер иде. Шул көчемез сәяси зур байракны алып барырга түгел, күтәреп торырга да йитмәс иде.

Монда тагы бу да фараз гына: «бәлки, җитәр иде» дияргә мөмкин. Ләкин моны сүз итеп әйтергә генә мөмкин. Чөнки ул вакытта көчнең булмавы хәзер мәгълүм бер хакыйкать, факт!

Чөнки көч һичбер вакытта югалмый. Көч һичбер вакытта мәгъдүм булып китми, китә алмый. Бара торган юлында аңгарга каршы киртә салынса, ул икенче йирдән юл ала. Бер йирдән капланса, икенче йирдә төртеп чыга. Чөнки көч диган куәт тик торуның тәмам киресе булганга, ул барлыгын белдерми калмый, кала алмый.

Хәзер безнең ун елгы хәлемезгә борылып карыйк: шундагы сәяси көчләремез — «Мөселман иттифакы»н сәяси партия итәргә йөргән көчләремезне кыска гына бер тәфтиштән үткәрик. Анда ни бар? Күпме сәясәт пирләремез «Мөселман иттифакы» программасы янында утырып торалар? Әле алар үзләренең байракларын мөхафәзә иткәндә, солдатның байрагын мөхафәзә иткәндәге кебек, каһарманлык күрсәткәндә дә шул байрак янын мөкатдәс бер кабер ясаганнармы?

«Юк!» дими хәлемез юк бит!

Шулай булса, шул сәясәт пирләремез көчләрен сәясәттә эшләтә алмагач, мәдәни, гыйльми, әдәби юлларга күчкәннәрме? Көчләрен анда эшләткәннәрме?

Ун ел элгәре «Мөселман иттифакы» партиясенең тирәсендәге эшләрне берәм-берәм күңелегездән кичереңез! Габдулла Буби берлән Садри әфәнде Максудига башкаларын[34] эзләсәңез, хәтереңездән таба алмыйсыз түгелме?..

Чөнки болар орлык сачеп, җил булса да, булмаса да, үзләренең үлчәүләрен югалтмый торган көчләр түгелләр иде. Чөнки болар сәясәт җиле берлән тормыш өстенә аккан кибәкләр генә иде. Җил беткәннең соңында да йиргә ашыгып төшәчәкләр түгел иде, чөнки аларда йирлелек, йиргә мәнсүблек, йир тарту бик зәгыйфь иде.

Шуның өчен сәясәт җиленнән соң көн елы булса да, суык булса да, кибәкләр кибәк булып калачак, бөртек-бөртек булып ындыр табагына төшәчәк иде. Һәм дә төште...

Шуның өчен тарих көрәге берлән замана йилендә шул милли көчләр соралганның соңында ындырда тагын да бик аз калган бөртекне күреп, безнең теге вакытта саламы биеклегенә куануымыз яңлыш булган икән! Ашлыгымызның башагы сыек булган икән! Ул вакытта саламын күреп, менә бу ашлык иске бурычымызны түләргә дә җитә, киләчәк өчен дә кала дип ышануымыз хата икән түгелме?

Шуның өчен без шул вакытта ук бар ашлык берлән угылларымызны өйләндерү, кызларымызны бирүне күңелгә кертмәенчә, йиремезне төзәтү өчен яңгы сукалар, бөртеге эре чыга торган яңгы орлыклар алырга гына тиеш түгел идеме?

Шулай иде. Менә шул кыска гына тарихи тәҗрибәгә таянып әйтә аламыз: ул вакыттагы шау-шуга карап зур сәяси партия ясарга маташу халыкның көчен аңламаудан килгән хата иде. Күршеләрнең зурлыгына кызыкканнан килгән балалык иде.

Ул гына да түгел, эш эшләргә өйрәнмәгән бер кыйсем халыкның зур эш эшләгән кебек күренер өчен ясаган хатасы, бәлки, ихтыярсыздыр, милли хатасы иде. Хәзер инде тагы фараз диңгезенә рәхим итеңез!

Мәкәрҗә съезды «Мөселман иттифакы» «бөтен Русия мөселманнарын милли, дини, мәдәни мәсьәләләрдә берләшә торган мәдәни бер җәмгыятьләр диган әсасны кабул итте» ди. Һәр мөселман кадет программасына гына сәяси вә икътисади әсас дип кабул итүе лязем диган маддәне бөтенләй хәтереннән чыгарып, сәяси платформаны ачык калдырды ди. Шул вакытта ни булачак иде? Табигый, шул җәмгыятьнең теләген вөҗүдкә чыгарыр өчен сайланган комитеты шул теләкләрне гәүдәләндерергә, тормышында үстерергә тотыныр иде түгелме?

Бөтен мөселманның мәдәни ихтыяҗларын булдырырга керешер иде түгелме? Үзенең милли көчләренең иң зурысын шул мәдәни кырга борыр иде түгелме?

Әйе, шулай, шуның өчен мәркәз комитет мәдәни ихтыяҗымызның программасын мөзакәрә итәчәк иде түгелме?

Аның нәрсәдән гыйбарәт булачагын без хәзер ун ел үткәннең соңында ап-ачык әйтә алабыз.

Аның беренчесе — мәктәпләр мәсьәләсе, икенчесе — мәдрәсә мәсьәләсе, өченчесе — идарәи руханияләремез, имамнарымыз, мөәзиннәремезнең хәле, мәхәллә берлән мөнәсәбәте, дүртенчесе — әдәбиятымыз, матбугатымыз, музыкамыз, театрымыз илә ахириһи түгелме?..

Шул вакытта Русиянең бөтен почмагында мәктәпләрнең исляхка мохтаҗ икәнлеге тасдыйк ителгәндә, шул мәктәп мәсьәләләремезне бер юлга куярлык көч бар идеме?

Кавказдан, Кырымнан, Идел буеннан шул милли мәктәпнең программасын, тәрбиясе юлын билгеләрлек куәтләр бар идеме? Шул ун ел эчендә таркау көчләр берлән Идел буенда гына ибтидаи тәгълимне рәтләргә әллә никадәр көч сарыф кылынганны игътибарга алсак, «бар иде» дими хәлемез юк.

Бар иде. Димәк, мәгънәви көчемез шул вакытта мәктәп мәсьәләсен әсаслы иттереп хәл итәргә җитәрлек иде.

Укытырга мөгаллимнәремез, мөгаллимәләремез, кыйраәт китаплары хәзерләргә педагогларымыз хакындагы сөальгә «бар иде» дип җавап бирә аламыз түгелме?

Шулай булса, ни кала?

Бәлки, без бик һәйбәт итеп тырышып эшләгән программамызны татбикъ итәргә мөгаллим әфәндегә тоттыра алсак, аңарга укытыр өчен фәлән китаплар лязем дип күрсәтешсәк, шул мәктәпне алып барырга матди көчемез булмагандыр.

Бу да бар иде.

Идел буенда гына биш меңгә якын мәктәпнең милләт акчасыннан гына үтәлеп килүе шул хактагы шөбһәне бетерә түгелме? Шулай булса, безнең баш комитетымыздагы мәктәп комиссиясенең кулында матди, мәгънәви көч җитәрлек булганда, аның эше нигә генә терәләчәк иде?

Бер яктан, халыкның аңына, икенче яктан, хөкүмәтнең дахили сәясәтенә. Ләкин ул вакытта боларның икесе дә безгә мөсагыйд иде. Шуның өчен мәктәп комиссиясе чынлап эшкә керешсә, шөбһәсез, милли мәктәпнең тәрбиясе, программасы хакындагы уйны татбикъ итә алачак иде вә шуның аркасында бу таркау мәктәпләремезне мәгълүм системага кую имкяны туачак иде. Шуның аркасында мәктәпләремездә мәгълүм бер тәрбия бирү ысулы фәгалияткә чыгарылачак иде. Шуның хакында мәктәпнең укытуында, тәрбиясендә мөгаллим берлән баланың мөнәсәбәтендә, аналар белән мөгаллимнәрнең мөнәсәбәтендәге хәзерге гайре табигыйлек бетмәсә дә, бетәргә якынлашачак иде.

Мәктәп эшләренең эченә мәгълүм берлек кереп тә, мәктәпнең торышы, барышы иттифакый мөгаллимнең яхшылыгына, иттифакый мулланың тәрәккыйпәрвәр булуына, иттифакый авыл байгурасының укытуны яратуына, иттифакый мәхәллә халкының мөгаллимне яратуына, яратмавына баглы булмас иде. Мәктәпнең тәрәккый тәдәннисендә балаларның тәрбиясендәге шул «иттифакыйлык» бөтенләй үк бетмәсә дә, алтмыш процент кимер иде. Шуның аркасында милли тормышымызның иң зур нигезе булган мәктәпләремез киләчәгемезнең өмид бавы булган яшь көчләремезнең тәрбиясе әминиятле юлга куелыр иде.

Менә шул аяк баскан йирнең ныклыгы мөгаллим, мөгаллимәләрнең әхвале рухиясенә тәэсир итәр, мәсканне үзен ныгытыр иде. Ул гына да түгел, мәктәп комиссиясенең шул планын татбикъ итәргә тотынганда, әлбәттә, иң зур манигъләр булып мәйданга чыгачак шивә мәсьәләсе эш аркасында җиңелчәрәк хәл ителер иде. Шунда баш күтәрүе табигый булган Казан вә гайре Кавказ, Кырым шивәләре арасындагы ихтиляф уңгайрак бер сатых өстенә куела белер иде.

Иң зурысы — шөбһәсез, шул мәктәп тирәсендә Русия мөселманнарының бик күп матди-мәгънәви көчләрен җыя белүдер.

Мәктәп исляхы фикере ул вакытта һәркем өчен аңланган лозунг булганга, моның янында шактый зур матди көч җыярга мөмкин булачак иде. Уфадагы мөфти мәҗлесендәге дарелмөгаллимин сумасы, Казандагы Романов гаиләсе солтанәтенең өч йөз ел тулу мөнәсәбәте берлән эшләнәчәк гимназия мәсьәләсе моңгарга дәлил булса кирәк. Шуның өчен шул комиссия табигый тәрәккый иткәндә хәзер инде ун ел үткәч, полякларның школьная матсалары кебек биш-алты мең мәктәпне карый торган бер гыйльми җәмгыяте булыр иде. Шул гыйльми урыннарымызны туйдырыр өчен кыйраәт китаплары хәзерли торган, дәрес китаплары татбикъ итә торган зур гыйльми җәмгыятемез булыр иде. Шуларны йөзәр мең сум — тәңкәлек сата белә торган зур китап складымыз булыр иде. Шул эшкә идея ноктаи нәзары кушылганга, китапларымызның таратылуы, укылуы, хәзерге нисбәттән аз гына да утыз процент артыр иде. Ул гына да түгел, беренче елларда ук мөгаллим,

мөгаллимәләргә ихтыяҗ бик зурлыгы хис ителгәнгә, дарелмөгаллимин, дарелмөгаллимат мәйданга килгән булыр иде. Ләкин миңа болар һәммәсе дә «иде», «иде» ... Ул «иде»ләр бик күп инде.

Менә шул ун ел вакыт үткән бит! Ник сезнең теләгәннәреңезнең берсе дә вөҗүдкә чыкмаган, диячәкләр. Вә шул могарәзә дөрест кебек тә тоелачактыр. Ләкин моңгарга җавапны бераз калдырып торыйк. Әле дә шул мөселман җәмгыятенең мәдрәсәләр мәсьәләсенә күчик әле.

## МИЛЛИ ЙИТЕШСЕЗЛЕКЕМЕЗ

27 декабрьдә бөтен Русиянең халык театры ясау, халык театры тудыру юлында тырышучыларның Мәскәүдә съездлары ачылды. Съездның 5 гыйнварга кадәр дәвам итәчәк мәҗлесләре өчен Мәскәүнең төрле гыйльми, мәдәни, сәнагый җәмгыятьләре урыннар хәзерләгәннәр, Русиянең төрле почмагыннан җыелган шулкадәрле кунакларга үзләренең биналарының залларын, бүлмәләрен ачканнар.

Шул гомум эштә ярдәмләшер өчен, бергә булыр өчен, бергә хәрәкәт итәр өчен съездны ясарга тырышкан бюрога вәкилләр күндергәннәр. Матди вә мәгънәви ярдәмләшкәннәр вә шул авыр йөкне күптән бирле өстерәп китерә-китерә бу көнге көнгә җиткергәннәр. Съездга иштиракь итү хакы халыкка театр ясау, халыкка театр тудыру эшендә ярдәм иткән һәртөрле җәмгыятьләргә, театрда уйнаучы артист-артисткаларга, сәхнәне оештыручы, театр китаплары язучыларга — һәммәсенә гам иттерелгәнгә, съездга өч йөздән артык әгъза җыелган. Боларның төрлесе Русиянең төрле почмагыннан булган кебек, боларның арасында Русиянең киң өлкәләрене тутырган аерым-аерым һәр милләтнең театр вәкилләре берлән туладыр.

Яһүдине әйтмә дә инде, монда әрмәне, грузины, латышы, эстоны, полягы — һәммәсе үзенең театрына мөнәсәбәт дәрәҗәсендә вәкилләр күндергән. Һәммәсе үзенең халкының театры нинди авыр юллардан үткәнен сөйләргә, үзенең халкын мәгънәви тәрбиядә үз театрының нинди чокырлар-чакырлардан үтәргә мәҗбүр иткәнен әйтергә, аңлатырга, бөтен Русиядән җыелган театр хезмәтчеләре алдында аһын-зарын күрсәтергә килгәннәр.

Безнең татар театры да бик кыска гомерле булса да, съезд ачылганда, аның яше дә әле уннан үтмәгән булса да, татар театры да үз халкының тормышында, милли тормышында гына түгел, гаилә тормышында да, мәгънәви үзгәрешләрдә дә шактый зур урын тотканга, аның да халкы алдында иткән хезмәте бөтен Русиянең халкы алдында мәдәни хезмәт булганга, аның да бу көнге көнгә кадәр килгән гомере, үткән юллары кагылмалы, салулы булганга, татар театрының да аһы-зары мәйданга куелырга тиеш иде. Халык театры ясаучылар арасында аның тавышы, ыңгырашуы ишетелергә тиеш иде. Хосусән татар театрының ун еллык гомерендә үткәргән авырлыклары, аның үтәргә тиеш булган юлындагы көфер почмагыннан[1] да, час чатыннан[2] да, байлар мәйданыннан да алган яралары, җәрәхәтләре ачылырга, гомум алдында ачылырга тиеш иде, вә шул яралар, җәрәхәтләрдән ага торган каннар берлән, түгелгән йөз сулары берлән татар театрын ачлы-туклы өстерәп бара торган артисты, артисткасы, татар театрының милли каһарманнары үзенең сәхнә иптәшләре, башка милләт артист, артисткалары берлән бергә булырга тиеш иде. Татарның драматурглары — Камалы, Әмирханы, Исхакые[3] — шунда бергә булырга, шунда бер татар театры фракциясе ясарга тиеш иде.

Мәскәүнең «Җәмгыяте хәйрия»се уставы сыйдырмаса да, киләчәк мөсафирларга «Хуш килдеңез!» диярлек дәрәҗәдә генә милли аңлы буласы иде. Мәскәүнең хатын-кыз җәмгыяте татар хатын-кызының бу көнге хакын алуда иң зур гамил булган театрчыларның «Рәхим итсәңез лә!» дияр дәрәҗәдә генә көчле буласы иде. Мәскәүнең Русия мөселманнарының тормышын, әдәбиятын өйрәнә торган җәмгыяте кадерле кунакларга юлбашчысы булырлык дәрәҗәдә генә үскән, балигъ булган буласы иде... иде, иде, бик күп «иде».

Менә шул «иде»ләр, мәгаттәәссеф, берсе дә булмады. Зур съездның ачылуына кадәр татар сәхнәчеләреннән нә бер кеше килде, нә бер доклад бирелде... Ул гына да түгел, съездга котлау телеграмнары арасында нә бер труппадан, нә бер аерым артисттан, нә Татарстанның төрле почмагына таралган төрле-төрле театр түгәрәкләреннән, музыка сөючеләреннән бер сүз, бер телеграм, бер котлау булды!

Моның берлән без татар театрын өстери-өстери муеннары шиңгән, җилкәләре төшкән татар сәхнәчеләренең битләренә бәрмимез. Без татар артисткасы, артистының, татар драматургысының хәзерге вазифасы башында, милли бурычы алдында тора алмавының сәбәпләрен белмимез түгел, татар сәхнәчесе үзенең шул милли эшендә дүрт яктан чолганган дошманнар арасыннан үтә барганда, татарның шундый милли эшләренә ярдәм кулы сузарга тиеш булган бүлеге — яшь байларымызның иң күбесе милли кяферләр, атасыннан калганны бетерә алмаенча аптырап йөри торган кабак тастымалы булганга, әлбәттә, алар үзләренең бөтен көчләрен, куәтләрен иң кечкенә хәят тартышуына, тамак туйдыруга бирергә

мәҗбүрләрдер. Әлбәттә, көн дә көн дә ишек төбеннән китми торган ачлык бәласе, иртәгесе театрга да кием-салым йитештерү мәшәкате аларны югары караудан да мәхрүм итә. Аларны көндәлек тормышның чүп-чары изәдер, ватадыр, тормышның эбере-чебере, аякка бәрелеп, күзгә сугылып, аларны чын хезмәттән, татар сәхнәсен тәрәкъкый иттерү, татар сәхнәсенең йөзен-күзен күрсәтү бурычыннан аерып, аларны мәгъзүр итәдер. Ләкин шул ук мәгъзүрлек аларны, рус вә башка милләт сәхнәчеләренә арка таянудан мәхрүм итеп, тагы көчсезләндерәдер.

Буласы эш булды. Үземезнең әллә никадәр зур гайрәт берлән эшләнгән милли сәхнәмезнең аз гынасын да русларга, башкаларга күрсәтеп: «Менә без дә бар... без дә эшлимез, безнең дә милли тормышка, халык булып яшәргә хакымыз бар», — дигән сүзне әйтә алмадык. Үземезнең шактый зур кыйммәт булган труппаларымыз, үземезгә нисбәттә яхшы артистларымыз, артисткаларымыз булса да, сәхнәмездә шактый зур урын тота торган драматургларымыз булса да, «берни юк!» дигән хиссият калдырдык. Бәлки, әле беренче мәҗлесләрдәге гөнаһның кәффарәтен, казасын кылырмыз, бәлки әле, аннан-моннан берәр кеше килеп, татар театры исеменнән бернәрсә сөйләнер, бәлки, театрлары, опералары, музыкалары берлән безгә — Идел буе татарларына караганда бик күп алда торган Кавказ кардәшләремез ярдәмгә йитешер.

Бәлки, килә алмаган сәхнәчеләр, телеграмнар, котлаулар берлән үзләренең ник булмауларын белдереп, ерактан гына булса да үзләренең теләкләрен күрсәтерләр.

Бәлки, монда, Мәскәүдә, берничә кеше табылып, шул милли бурычны үтәргә ярдәм итешер.

Ләкин бу көнге көндә әле үземезнең театрдагы «безлекемезне», «барлыкымызны» күрсәтә алмадык, алмадык.

*1916*

## МИЛЛИ МАТБУГАТ БӘЙРӘМЕ

1905 елда Казанда Октябрь көннәре[1] әле башланып өлгермәгән иде. Йосыф әфәнде[2] тарафыннан бер мәҗлескә чакырылдым. Казанның ул вакытның язучыларыннан хисап ителгән кешеләрнең һәммәсе дә мәҗлестә хазир иде. Йосыф Акчурин, Һади Максуди[3], Фуад Туктаров[4], Борһан Шәрәфкә[5] башка хәзер язучылар җөмләсеннән чыккан Фәсих учитель Мөхетдинов[6] берлән Шакир абзый Таһиров[7] та бар иде. Утырышып бетү берлән Сәедгәрәй мирза Алкин[8] да килде.

Мәҗлес ачылып мөзакәрә башланды. Сәедгәрәй мирза Алкинга Казан шәһәрендә «Казан мөхбире» исемендәге татарча телдә вә шуның тәрҗемәсен русчада «Казанск. вестник» исемендә гәзитә[9] чыгарырга рөхсәт бирелгән.

Менә шул гәзитәне ничек кую өчен, шул эшне ничек алып бару өчен безне рәсмән Алкин, гайре рәсми Йосыф әфәнде киңәшкә чакырган. Казанда гына түгел, бөтен Идел буенда беренче булган бу мәҗлестә милли татар гәзитәсен тәэсис итү мәҗлесендә хазир булуымызны без, бәлки, үземезнең шул вакытта тарихымызның алышынуы уенында иштиракь итүче артистлар икәнемезне аңламаганмыз. Шул юлларны язып торучы мин моннан ун ел соң, Идел буеннан бик күп читтә, Русиянең икътисади, мәгънәви мәркәзендә шул мәҗлестән соң башланган хәлләргә каратып язачагымны, әлбәттә, уйламаганмын да, күңелемә дә китермәгәнмен.

Әйе, менә шул тарихи көнгә шактый күптән инде — ун ел тулып үтте. Әйе, шул мәҗлестән соң башланып киткән татар матбугатының кыска тормышында төрле җирләрдә комедиясе, драмасы, фаҗигасе уйналды.

Шул көндә бергә җыелып, бер гәзитә чыгарырга уйлаган бу бер уч кешедән бер кыйсеме бөтенләй читкә сугылды, бер бүлеге татар матбугатына дошман вазгыять алды, язучы булып калганнары, төрлесе төрлегә бүленеп, матбугаттагы төрле әфкяр, төрле мәсләкнең җитәкчесе булды. Татар матбугатының беренче пәрдәсендә иттифакый гына беренче роль биргән Сәедгәрәй мирза «Казан мөхбире»н, алучылары биш меңгә җиткән бер гәзитәне иттифакый гына тугры килгән бер ресторан мәҗлесендә иттифакый гына тугры килгән бер кешегә сатты да гәзитә галәменнән чыкты, чын хезмәтчеләрнең эшләрен бәрбад итеп, Мөхәммәтҗан Сәйдәшевкә гәзитәне тапшырды[10]. «Казан мөхбире» аңгырый-шыңгырый авырып үлде.

Шул мәҗлестәге беренче номердагы баш мәкаләне язуны иттифакый гына өстенә алган Фәсих абзый Мөхетдинов, матбугатның унынчы елына кадәр беренче мәкаләне язып өлгертә алмаенча, татар матбугатының идеалыннан бик ерак булган бер мәнсабка керде.

Шул вакытта тәгълиме ибтиданың таралуында шактый зур хезмәтче булган Шакир абзый Таһиров җәнаблары картайды, матбугаттан читкә китте.

Шул мәҗлестә рәсми секретарь булган Йосыф әфәнде «Төрек йорты» мөәссисе[11] булып, башка мохиттә эшкә тотынды. Һади әфәнде «Йолдыз» гәзитәсе тәэсис итеп башка чыкты. Мин [һәм] Фуад әфәнде, үземезгә аерым бер юл тотып, «Таң йолдызы» гәзитәсе тәэсис итеп, татар агымында яңгы булган «таңчылык» мәслекенә кучтек. Борһан әфәнде, хәзерге «Вакыт»ның «Вакыт» булуына бик күп гайрәт, бик күп ихлас сарыф итеп, вак-төяк интригага җиңелеп, «хөр мөхәррир» булып калды.

Шул мәҗлестә хазир булмаган бик күп кешеләр, Казанның үзендә вә чит шәһәрләрдә матбугат агымына кереп китеп, аның суында йөзә башладылар. Йә су астына, йә суга каршы актылар... яисә татар тормышының бер ягыннан икенче ягына гайбәт хәбәрләре күчереп, «актарма»лык ролен үтәделәр.

Казандагы беренче «Казан мөхбире» урынына Казанның үзендә генә унлап исемдә гәзитәләр чыккан кебек, Казан түгел шәһәрләренең дә иң күбесендә мөселман халкының зурлыгы-кечкенәлегенә нисбәтән бер вә берничә гәзитәләр, журналлар булып үтте[12]. Матбугат галәменә сәүдәгәре, мулласы, булган бае катышып йөреп, әйләнә-селкенә кайсысы иләк астына төште, кайсысы өстенә өелеп, алып ыргытылды. Тормышның матбугатны әйләнүендә, замананың әһле каләмне тирбәтүендә матбугатка йомшак тотынган, матбугат дөньясына эш юктан гына кергән бөтен әфәнделәр урынлы-урынына утыртылды. Тормышның агышыннан килеп чыккан яңгы мәсләкләр туды, искеләре үзгәрде, сипләнде, яңгы кешеләр каләмгә ябышты.

Һәр җанлы әгъзада булуы табигый булган хәрәкәт-үсү, үзгәрү матбугат галәмендә тәмамы берлән хөкемен йөртте.

Татар матбугаты туды, үсте, үлде, күмелде. Тагы туды, тагы үсте. Уникенең берсе юкта мәйданга чыккан татар матбугаты ун ел эчендә иң әүвәл матбугатта язучылар, үзенә махсус язучылар, гәзитә язучылары тудырды. Татар матбугаты үзе үсә-үсә мәдрәсә тәрбиясе күргән шул шәкертләрне үстерде. Татар матбугаты үзе, киңәя-киңәя, шул «кәшфез-зөнүн шәкерт»нең[13] мәгълүматларын киңәйтеп, аларны мөхәррир иттереп, карашларын киңәйтте. Татар матбугаты сугыла-бәрелә, йөри-йөри ышкыланды, шомарды. Аның теле баеды, истыйляхатлары күбәйде, үзенә махсус гәзитә теле дигән яңгы бер тел тудырды. Шуны аннан-моннан сүзләр алып оештырып, урлаштырып сүзләндерде. Татар матбугаты ун еллык гомерендә татарның өенә-йортына керде. Татарның шәһәрендә генә түгел, авылында да зур урын тотты.

Татар матбугаты татарның гомуми мәсьәләләрен караганда, әфкяре гомумиянең иң көчле гамиле булып алды. Татар матбугаты, ун ел эчендә үзенең халкына нисбәтән тәрәкъкый итеп, үзенең халкының төрле бүлегенең тәрҗемане әфкяре булып алды. Татар тормышында гражданлык хакы казанды.

Менә шул ун еллык тормыш үткәргән татар матбугаты тирә-юнендәге суыкларга карап та корымады. Туңгакка карап та катмады, тайгакка карап та егылып, башын ярмады. Табигый вә соңгый — булган һәртөрле уңгайсызларны бөгелә-сыгыла үтәргә тугры килгәнгә, әлбәттә, тулы-симез булып, башы-күзе матур көенчә сөннәт туена хәзерләнә алмады.

Балалык вакытында була торган зыяндаш, чәчәк авыруларын бик күп үткәрергә тугры килгәнгә, шадра гына, куркак кына булса да, тазарырга истигъдадлы булып туйга хәзерләнде.

Хәзер аның сөннәт туе. Ул, яңгы милли киемнәргә киендерелеп, үзенең милли исләрен сөртенеп, шул сөннәт мәҗлесенә чыгарга хәзерләнгән. Аның атасы-анасы, аның дуст-ише аны ничек каршы алачагы, аның шулкадәр авырлык арасында ун ел үткәргән гомеренең халкы, милләте алдында кадере, кыйммәте ни дәрәҗәдә булачагы, әлбәттә, шул туе мәҗлесендә күреләчәк, шул гомуммәҗлестәге догалардан, теләкләрдән, бүләкләрдән-салаклардан мәгълүм булачак. Ләкин ул шул авыр көннәр, озын төннәр үткәргән матбугат — суык кышлар, сазлы былчыраклы көзләр кичергән матбугат — халыкның һәрбер эшендә, милләтнең һәрбер ихтыяҗында көче-куәте берлән тартышкан матбугат күңеленнән куркып, шул туйны имтихан кебек итеп каршы ала. Вә иртәгәне дерелдәп: «Ни була, милләт нинди тамга сала?» — дип каушап көтеп тора.

Ителгән хезмәтләр тәкъдир ителерме? Бозылган каннар, ватылган нерваларның кыйммәте куелырмы? Агарган сакаллар, коелган чәчләр, югалтылган саулыклар, бүләк итеп алынган хасталыклар, чирләр үлчәнерме? Бирелгән шәһитләрнең корбаннары бизмәнгә салынырмы дип көтеп тора!

Киләчәктәге тагы зуррак, тагы мәсьүлиятлерәк эшләр алдында батыраер өчен, ныгыр өчен, туган иленнән, йортыннан, җиреннән мәгънәви көч алыр өчен өмидләнеп, Идел буена моңаеп-моңаеп карый!

Өмидле иттереп күзен тегеп көтә-көтә карый.

Милләт тә нинди авыр хәлне үткәрсә дә, кирәк, эчтәге уңгайсызлыклар, кирәк, сугыштан туган авырлыклар күңелне бәйрәмгә күтәрмәсә дә, ул да үз баласы — матбугатка каршы мәхәббәт биләми, йомшаклык берлән, ана шәфкате берлән сыйпамый-сыламый сыендырмый хәле бармы?

Әнә милләтнең бабалары өмидле чыккан угылларына яшьлеген котларга хәзерләнеп яталар, аның ябык кыяфәте, аның фәкыйрь, ярлы кием-салымы аларның аналык хисләрен мыскыл иткәндә, шуны тазартырга егет булып үсүендә, чит халыкларның матбугаты берлән үлчәшүендә ким булмасын өчен киендереп-бизәндереп яталар. Әнә аның анасы — милләт хатыны — үзенең кечкенә, зәгыйфь кенә баласыннан әллә никадәр илтифат күргән, ире җәберләсә дә, тормыш кысса да, кечкенә башы берлән химаяче булып чыккан, шул баланың туена — шул ана хакын балалыктан аңлаган матбугатның туена күзеннән яшен чыгарып рәхмәт укырга, кулыннан килгән һәрнәрсәсен корбан итәргә, калтыраган куллары берлән гөл чәчәкләре сибәргә хәзер тора.

Татарның яшьләре, татар матбугатының — яшь татар матбугатының шәкертләре, үзенең кеше булуында, үзенең кеше төсле күзен ачып дөньяга карый белүендә башыннан аягына кадәр татар матбугатына бурычлы булган яшьләре, шәһәрләрдә, авылларда дөркем-дөркем җыелганнар, очраган бер-берсен тәбриклиләр, күпләп-күпләп, берәмләп-берәмләп телеграмнарга чабалар, идарәләргә телеграммалар, тәбрикләр яудыралар...

Шәһәрләрнең, авылларның «Җәмгыяте хәйрия»ләрендә, нәшре мәгариф җәмгыятьләрендә матбугат кичәләре ясаганнар, Исмәгыйль бабайның[14] мәрхүм рухына, матбугат юлында шәһит булган Тукай мәрхүмнең җанының рәхәтлегенә Коръәннәр укыйлар, догалар кылалар, теләкләр җибәрәләр.

Каләмнең ертыгын, ярыгын ямар өчен, матбугат әһеленең авыр көннәрендә ярдәменә йитешер өчен ясалачак матбугат фондына акчалар тәгаен итәләр, зур-зур байларымыз татар матбугатында исемен калдырыр өчен ашыгалар... Үзләре исеменнән, аталары исеменнән матбугат исеменә стипендияләр ачалар...

Әһле матбугатка җиңгеллек булсын өчен, аларның мәгънәви йөкләрен бүлешер өчен зур китапханәләр тәэсис итәргә акчалар билгеләп, милли әдәбиятымызның тарихы саклансын, милли матбугатымызның бер юлы да югалмасын өчен милли музейханәләргә биналар салдыралар...

Бөтен татар дөньясы үзенең милли матбугатының сөннәт туена, ун миллионлы Идел буе мөселманы үзенең чын баласының шул дини дә туена зур гайрәтләр, зур энергияләр сарыф итеп, йөзләр, меңнәр сумнар акчалар, маллар сарыф итеп хәзерләнәләр.

Кадерле атаның, ананың бердәнбер углының сөннәт туена Әстерхан нугае ни дәрәҗәдә игътибар берлән хәзерләнсә, бөтен милләт үз матбугатының шул туена шулкадәр әһәмият берлән хәзерләнәдер. Чөнки без — милләт булган, чөнки без үземезнең баламыз, үземезнең мәдәни баламыз — матбугатның тәрбиясе генә түгел, бәйрәмендә күңелен ачу, авыр көнендә күңелен күтәрү дә безнең бурычымыз икәнен белер дәрәҗәгә җиткән ата-ана булганмыз.

Үземезнең тарихларда шаулап тора торган баһадир бабаларымызның көчле-таза, әхлакка нык аналарымызның чын бабалары булып үсеп җитеп, бала тәрбиясенең фарыз икәнен, мөкатдәс икәнен аңлаган татар кавеме булганбыз.

Әлбәттә, шулай итәчәкмез.

Чөнки бу көн татар матбугаты — ун еллык гомерен үткәргән татар матбугаты бүген имтиханга керсә, үзенең киләчәктә яшәргә хакы бармы-юкмылыгын исбат итәр өчен милләте алдында имтиханга керсә, бу көнге милләт тә, татар милләте дә тормыш имтиханына керәдер. Ул да тарих алдында, үзенең күршеләре алдында үзенең балигъ булганын күрсәтү, үзенең дусты берлән дошманын аерыр дәрәҗәдә гакыллы икәнен, халкының бөтен эшләрен дә үзе алып барыр дәрәҗәгә җиткәнен күрсәтерлек там хаклы гражданлык имтиханына керәдер.

Бу көнге көн дә матбугатның имтихан көне булса, бу көнге көн — милләтнең дә имтиханы, мәдәни имтихан көнедер. Без, әһле каләм булганга, яшь матбугатымызның шул имтиханын бишкә тотуын көтеп калган кебек, без, милләт углы булганга, халкымызның шул мәдәнилек имтиханын тотуда да шаны муафикъ дәрәҗәдә алыр дип өмидләнеп торамыз. Мөселман вә татар өмиде берлән өмидләнеп көтәмез.

## ПЕТРОГРАД ТАТАР ГӘЗИТӘЛӘРЕ

Петроград, Мәскәү кебек мөселман галәменнән читтәге шәһәрләрдә чыккан вакытлы матбугатны язудан элек, шундый матбугатның чыгуы өчен иң беренче шарт булган ислам хоруфатлы матбагалар хакында мәгълүмат бирелүе ляземдер. Петроград, Мәскәү кебек шәһәрләрдә боларның тәэсисләре гәзитә-журналны вөҗүдкә китерүдән кечкенә эш түгелдер.

Петроградта беренче уларак мөселман хоруфатлы матбаганы Кырым татарларыннан Ильяс мирза Бораганский тәэсис итте[1].

Петроград университетының төрек теле [*бер-ике сүз укылмый*] булган Ильяс мирза Бораганский — [*бер-ике сүз укылмый*] оста хаттат булуга башка [*бер сүз укылмый*] басылу, тагын матурлату, мөселман китапларына нәфасәт бирү уе берлән эш башлаган кешедер. Хоруфаттагы стильне күрә торган, китаптагы нәфасәт берлән тупаслыкны аера торган аның күзе Казанда басылган һәрбер китапны күргән саен мыскыллана, аның хисе нәфасәте тәхкыйрь ителә иде. Шул дорфалыклар, хаталарны чит милләт халкы көлеп караганда, Ильяс мирзаның милли хисе хурлана, аның бабаларыннан агып килгән һавалы каны кайный иде. Менә шул Русия исламнарының хоруфатында булган тәнасыбсызлыкны бетерер өчен, Русия мөселманнарындагы басылган китаплардагы тупаслык, дорфалыктан котылыр өчен вә басылган китаплар ашасыннан аз гына булса да нәфасәт тойгысы уятыр өчен, ул бердәнбер юл тапты. Ул да Русия исламнарына кирәгенчә хәрефләр кисеп вә шуларны ислам матбагалары арасында таратып вә шул хәрефләр берлән үзенең бөтен хисе, нәфасәтен кушып, китаплар бастырып, матбугаттагы нәфасәткә үрнәкләр бирү иде. Шул ният берлән Ильяс мирза үзенә матбага ясау уена төште. Үзенә аерым хәрефләр кисте, үзенә аерым типография ясады вә, шул милли эшне эшләгәндә, Русиянең мөселман галәменең матди көченә таяначак булып эшләде. Ләкин, мәгаттәэссеф, Ильяс мирзаның фикерен аңлаучы руслар булса да, татар галәменнән берәү дә, беркем дә кул суза алмады. Ильяс мирзаның бастырган нәфис «Мишкят»е[2], зур вә кечкенә кулдагы Коръәннәре күп тарала алмадымы, иярченнәр таба алмадымы — мөселман матбугатында нәфасәт артуга тәэсир итә алмады.

Ильяс мирзаның матбага эше вә матур, нәфис китаплар нәшер итүе үз җилкәсенә генә ятканга, ул никадәр нәфасәтнең гашыйкы булса да, нәфис китаплар нәшер итәргә кирәкле матди ярдәм булмаганга вә шуның аркасында аның тарафыннан таратылган әсәрләр күбәеп, бөтен Русия дөньясына җәелә алмаганга, аның каһарманонә хезмәте сәмәрәсез калды яисә бик аз сәмәрә бирде. Ләкин Ильяс мирзаның матбагасының икенче зур бер хезмәте тиде: шул матбаганың булуы аркасында Рәшид казый Петроградта «Миръат»лар нәшер итә башлады[3] вә шул эш аркасында, укучы татар дөньясына беренче уларак, вакытлы матбугат ничек булырга тиешлеге хакында күзгә күрсәтеп мисал булу хезмәтен итте.

«Миръат»лар, безнең мәсьәләләремез бик күп вакытта, халкымызның укуга сусаган чагында чыкканга, бик сөелеп укылды вә бик күп йиргә таралды. Ул вакыттагы татар галәмендә күп шау-шуга сәбәп булды. Хосусән аның мөфти сүгү хакындагы мәкаләләре[4] бик күп иярченнәр дә тудырды.

Татар дөньясында беренче булып чыккан Петроградның «Нур» гәзитәсендә Ильяс мирза Бораганскийның матбагасы булуы аркасында гына мәйданга килә алды. Аның башлануы, дәвамы шул матбагада булды.

Петроградның ахуны Гатаулла Баязидов тарафыннан чыгарылган «Нур» гәзитәсе[5], 1905 елда чыкканга, ул беренче татар гәзитәсе булуы өчен әүвәлдә [*бер-ике сүз танылмый*] татар дөньсы язучыларының бик күбесе иштиракь итеп, шул гәзитәнең сәхифәләрендә милли аһларын, зарларын ачмакчы булдылар. Ләкин гәзитә, үзенең беренче татар гәзитәсе булудан килгән мәнфәгатен аңлап йитеп, шул эшне тәрәккъый иттерү юлына керешә алмады.

Икенчедән, тәгаен итәчәк мәсләкендә шул вакытта милләт булып яшәргә теләп мәйданга атылган татар әфкяре гомумиясенең теләве берлән бергә агу тиеш икәнен аңлый алмады.

Өченчедән, Русиядә булган сәяси үзгәрешләр вакытында татар милләтенең хокуклы бер халык булып яшәргә теләүдән килгән хокук низагысын ачык күз берлән карый алмады. Таң йолдызы иттереп токкан фонаре, халкының йөрәгендә яна торган иман нуры булмаенча, вак-төяк департаментлардагы мөселманга дошман кечкенә түрәләрнең нәсихәте булганга, бөтен мәдәни, милли, сәяси эшләрдә мөселманнарның күплегенә каршы килде.

Дүртенчедән, Русия мөселманнарының киләчәге вә киләчәктәге сәгадәте хакындагы уе-фикере үз тирә-юнендә җыелган лакейлар, официантлар, дворникларның төшенчәсе-уе булганга, Русия исламнарының истикъбален чын лакей булуда, итагатьле официант булуда күргәзергә тырышып, мәсләкән лакейлар гәзитәсе булып калды.

«Нур» гәзитәсенең идарә дигән нәрсәсе һичбер булмаганга, язучысы да юкка, ул һичбер вакытта гәзитә кыяфәтенә керә алмады. Хөкүмәт даирәләреннән бирелгән игъланнарны басар өчен, әле айда бер, әле ике атнада бер чыгып килсә дә, 14 нче елда кара көчләргә бирелә торган сумадан өлеш чыгарылмаганга, Сафа әфәнде Баязидов дәвам иттерә алмады. Гәзитә рәсми ябылмаса да, халыкның бойкоты астында өшеп-туңып, бөрешеп катты.

14 нче елдагы «Нур»ны зурайтып җибәрү, аны көндәлек итү хыялы да кара көчләргә генә арка терәп башланганга, шул вакыттагы татар әфкяре гомумиясене лакейлык психологиясенә җибәрер өчен ясарга тырышылган «Сыйрател-мөстәкыйм» союзы да Идел буе мөселманнарының гомуми бойкот ясаулары аркасында кара бер тап кына булып калды. Хәзер «Нур» гәзитәсе бар да түгел, юк та түгел[6].

Петроградта икенче гәзитә «Өлфәт» булды[7]. Бу гәзитә 5–6 нчы еллардагы дини ислях ясарга теләгән кешеләрнең тәрҗемане әфкяре булып мәйданга чыкты. Русиядәге хәл-әхваль, Русия мөселманнары арасындагы хәрәкәтләр бик җанлы булганга, «Өлфәт»тәге Рәшид казыйның кызу мәкаләләре, Муса әфәнденең гыйльми тәдкыйкатьләре[8] бик тиз дикъкатьне җәлеп итеп, «Өлфәт» иң күп таралган гәзитәләр арасына керде. Дини, милли мәсьәләләр, сәяси, икътисади агымнар бергә җыелып йөргән чакта, беренче дәрәҗәдәге мәсьәләләр берлән унбишенче дәрәҗәдәгеләренә тамга, үлчәү куелмаган вакытта, «Өлфәт»нең үлчәү бизмәненнән бик ерак булган мәкаләләре үзенең сәяси, мәдәни, милли тормышындагы кысынкылыклардан туеп бетеп иреккә чыгарга бик тырышкан [*бер юл ертылган, укып булмый*] вә шуның өчен иксез-чиксез хыял диңгезендә йөзгән Идел буе укучыларының рухларына бик муафикъ иде. Аларның иҗтимагый-милли эшләргә өйрәнмәгән башларына, аларның татарның бөтен тулмаганнарын, кимчелекләрен Җәбраил фәрештә китереп тоттырыр дигән төшенчәләренә үлчәүнең зурлыгы, күтәрелгән мәсьәләләрнең муллыгы берлән дә бик мөнасиб иде.

«Өлфәт» гәзитәсенең укучысы күп булу ягыннан матди җәһәте тәэмин ителергә тиеш булса да, акчасызлыктан тукталды. Кечкенә генә матбагасы бик юкка гына сатылып әрәм ителде.

Өченче гәзитә Икенче Дума вакытында чыгарылган «Дума» гәзитәсе[9] иде.

Бу гәзитә Думадагы мөселман фракциясенең сул канатлары әгъзалары тарафыннан чыгарыла иде. Гәзитә, кыска гына вакыт дәвам итеп, хөкүмәт тарафыннан ябылды, вә мөхәррире Кәлимулла Хәсәнов шундагы мәкаләләр өчен крепостьта утырып чыкты.

Дүртенче гәзитә — «Ил»* гәзитәсе. Фракция янында күптән гәзитәнең кирәклеге хис ителгәнгә, берничә мәртәбә тәшәббес ителгән булса да, нәтиҗәсез калган иде. Бу юлы шул уйны тудырыр өчен Гаяз әфәнде Исхакый башлагач, Муса әфәнде Бигиев кушылгач, фракциянең бәгъзе әгъзалары да кушылып эшли башлаган иде. Ләкин гәзитәгә рөхсәт алынып китәр-китмәс чакта, Петроградка килгән Садри әфәнде Максудиның хосусый тырышуы аркасында фракция әгъзалары аерылып чыгып, Исмәгыйль әфәнде Леманов исеменнән «Милләт» исемле гәзитәгә[10] рөхсәт алганнар иде вә шуның аркасында гәзитәсез торган Петроград бердән ике гәзитәле булган иде.

«Ил» гәзитәсенең матбагасы юклыгы, көтмәгән авырлыкларга очраганга, гәзитә атнага берлектән үтә алмаенча, 14 нче елның ахырында Мәскәүгә күчкән иде.

«Милләт» гәзитәсенең нашире Дума әгъзасы Ибнеәмин әфәнде Әхтәмов берлән Сәлимгәрәй мирза Җантурин, мөхәррире фракциянең секретаре Исмәгыйль әфәнде Леманов иде.

Гәзитә, журнал төсендә чыгып, фракциянең тәрҗемане әфкяре иде. Ләкин чыгуларында һичбер төрле интизам булмаганга, мәкаләләрендә һичбер төрле күзгә ташланылачак мәсьәләләр уятылмаганга, кулланган теле нә Идел буе, нә кырым, нә азәрбайҗан шивәсенә тугры килмәгәнгә, тын гына үлде дә китте.

Фракциянең шактый сумасын ашаса да, мөәссәсәләрнең татар әфкяре гомумиясен идарә итәмез дигән уйларының төбе хата икәнлеген, мөәссәсәләре мирза булсалар да, акчалы булсалар да, матбугат эчендә хөрмәт, кадер казаныр өчен яза белү дә кирәк икәнен исбат итәр өчен җанлы дәлил булды да күздән югалды.

Петербург Петроград улганнан бирле[11] анда татар гәзитәсе, журналы чыкмады, чыга алмады.

## МАТБУГАТ БӘЙРӘМЕ МӨНӘСӘБӘТЕ БЕРЛӘ

Икенче гыйнварда идарәмезгә Казанның гәзитә вә журналларының баш мөхәррирләре имза иткән кыска гына бер мәктүб килде. Мәктүб Казан гәзитә вә журналларының 5 гыйнвар көнен милли матбугатымызның ун еллык бәйрәме көненә боруга карарларын белдертә вә безне дә иштиракькә чакыра иде.

Вакыт бик аз булганга, соңгы елларда татар тормышында туган көчләрнең иң зурысы булган матбугатның ун еллык үсүен күздән кичерер өчен хәзерләнү һич мөмкин булмаганга, без Казан иптәшләремезнең бу хәрәкәтләрен туйдан соң дөмбергә булган шул мәҗлескә дә вакытында дәгъвәтнамә җибәрә алмауларын яки җибәрмәүләрен фәүкылгадә бер хәйранлык берлән каршы алдык. Мәктүбне берничә мәртәбә укыгач та, чынмы, уенмы икәненә төшенә алмаенча, Оренбург, Уфа гәзитәләренең идарәләренә җаваплы телеграм биреп бәян сорадык. Уемызча, безгә килгән мәктүбнең гайне ул идарәләргә дә җибәрелгән булырга тиеш. Аларда күптән шуңгарга хәзерләнү башланган булырга тиеш иде. Тагы безнең хөсне занымыз яңлыш чыкты. «Тормыш» идарәсеннән 4 гыйнварның кичендә, сезнең телеграмыңыздан соң катышабыз дигән мәелдә, «Вакыт»тан 5 гыйнварда, фикрән катышсак та, программасын белмимез, дигән мәгънәдә җаваплар алдык. Шул аңлашылмау аркасында номер хәзерләнүләргә дә кирәк булганга вә Мәскәүдә шул бәйрәмнең эшләренә дә хезмәт, гайрәт сарыф итәргә кирәк булганга аптырап калдык.

Татар матбугатына гаид уникенең берсе юк. Мәскәүдә мең бәла берлән номер хәзерләдек. Мең бәла берлән шул көнге ясалачак мәҗлесне оештырдык. Соңга калып матбугат бәйрәмендә бурычымызны үтәмәенчә калмыйк дип, курка-курка, матбугат иптәшләремезгә тәбрик телеграммалары, котлаулар җибәрдек вә, шул көнгә бөтен хезмәтчеләремезне эштән бушатып, бәйрәмнәргә керештек.

Күңелемездән үземезнең шулкадәр соң белүемез аркасында Казандагы кебек тантаналы мәҗлес, Оренбургтагы кебек әдәбият бәйрәмен хәтердә калдыра торган зур вакыйгалы утырыш, Уфадагы кебек бөтен милли хәятымызда таныш булыр дәрәҗәдә эшләтелгән зур тәшәббесләргә иштиракь итә алмавымызга, Мәскәүдәге көчләрне шул милли эш янына җыяр дәрәҗәдә вакытымыз булмауга вөҗданән газапланып, бәйрәмне, мәҗлесне үткәрдек.

Оят булса да әйтеп китик: безнең гәзитәмез дә татар матбугатында шактый урын тотканга, безнең язучыларымыз да татар матбугатының бисмиллядан бу көнгә кадәр матбугат уртасында эшләп килгәнгә[1], бөтен Русия татары дөньясыннан телеграмнар, тәбрикләр дә көттек. Инде шактый вакыт үтте. Бөтен татар матбугатының 7 гыйнварда чыккан номерлары хәзер һәммәсе идарәмезгә килеп җитте. Һәммәсен күздән кичердек. «Вакыт» гәзитәсендә матбугат юбилейсы хакында «Сүз»нең телеграмына башка кыска бер хәбәр генә кертелгән[2], «Тәрҗеман»да ләм-мим дип бер сүз язылмаган*. Кавказ гәзитәләрендә безнең тәбрикемез берлән соңга калган дәгъвәт кенә басылган. Казан гәзитәләре вә «Тормыш» кына, махсус ук булмаса да, берничә мәкаләне шул мәсьәләгә багышлаганнар[4]. Мәҗлесләрнең, утырышларның хисапларын без күрмәдекме, мәҗлесләр озаеп китеп, әрбабе каләм бик соңга калып язарга өлгермәдеме, 7 гыйнварда чыккан номерларына бернәрсә дә кертелмәгән. Безнең дуст-ишемез юкмы, безнең матбугат галәмендә урынымыз бик кечкенәме, һичбер шәһәрдән, һичбер җәмгыятьтән телеграм, тәбрик алмадык (идарәләр берлән алышканнар, әлбәттә, монда керми). Шул күңелсезлек[кә], матбугатка — шулкадәр авырлык берлән ун яшенә җиткән матбугатка — үзенең халкының, үзенең аңлы халкының бу кадәр салкын кан берлән каравына эчемез пошты, күңел рәнҗеде. Ләкин уйлый-уйлый торганның соңында шул хата үземездә, үз матбугатымызда, шул гөнаһ бөтен матбугат әһелендә икәнлеге фикеренә килдек.

Матбугат галәме татар тормышында никадәр зур урын тотса да, матбугат татарның бөтен мәдәни, милли эшләрендә никадәр авырлыклар күреп алга таба атласа да, мәгаттәәссеф, матбугат әһеле үзе-үзенең шул хезмәтендә вак-төяк мәсьәләләрдән үтә алмаган, мәгаттәәссеф, матбугат әһеленең бик күбесе үзенең шәхси файдасы берлән гомуми мәсьәләне аера алыр дәрәҗәдә үсә алмаган. Мөфтилек мәсьәләсендә күрелгән бу хакыйкать тагы бер мәртәбә исбат ителде, мөфтилек мәсьәләсендә берничә гәзитәнең генә милли мәсьәләләрне киң иттереп аңлар дәрәҗәдә мания величиядән азат түгел икәнлеге күренде.

Матбугат мәсьәләсендә Казан гәзитә вә журналларының идарәләре гомуми эшләргә карауларына бик түбәндә икәнлекләре, матбугат бәйрәме кебек зур мәсьәләдә бер сүзгә килерлек, бергә хәрәкәт итәрлек, иң зурысы — шул эшне эш иттереп, милли эш иттереп карарлык хәлгә килмәгәнлекләре беленде.

Матбугатның үзенең ун елында матди-мәгънәви генә түгел, үзенең бер көч булу ягыннан да һичбер төрле матди вә мәгънәви организациягә табигъ түгеллеге беленде. Матбугат әһеле арасында да, мәгаттәәссеф, башбаштаклык, падишаһлык сөрүе, матбугат әрбабының күбесе арасында да үз эшенә җитди карамау табигый булып киткәнлеге күрелде.

Шуның өчен матбугат үз туенда мактаулы кыз кебек күңелсез хәлгә төшеп оялды. Инде шул йөз кызаруны өстемезгә алыйк та, моннан соңгы булачак гомуми эшләрдә бергәрәк хәрәкәт итәр өчен, мәсләк аермасы булмаганда, минем сул аягым ничек куша дигән кагыйдәне арамыздан бетерер өчен, ун елдан бирле халыкка дәрес-сабак өйрәтеп тора торган матбугат әһелен үземез организовать итик. Үземез үз арамызда йөретер өчен әхлакый-иҗтимагый кагыйдәләр ясыйк, шуларны матбугат тормышына татбикь итүнең юлларын хәзерләү, матбугат әһеленең махсус җәмгыятьтә берләшүе, махсус кагыйдәләрне үзе өчен дә, рәфикы өчен дә, рәкыйбе өчен дә бер көчтәлеген тасдыйк итү берлән генә булачактыр вә шуның өчен әһле матбугатка күрешеп, үз хәлен кайгыртышу, үзенең эчтәлеге тормышына кагыйдәләр, кануннар кую — унберенче яшькә киткән татар матбугатының беренче иҗтимагый бурычыдыр.

Бу оятлы имтиханнан соң матбугат әһеле шуны аңларга тиештер вә шуны җитди иттереп мөзакәрә итәргә, «двадцать одно» мәҗлесләрендә генә түгел, махсус ясалган утырышларда мөзакәрә итеп булдырырга тиештер. Без тарафымыздан кечкенә генә булса да әһле матбугатның рәсми бер киңәш мәҗлесен ясауны мәслихәт күрәмез. Шуны булдырыр өчен хөкүмәт даирәләренә мөрәҗәгатькә вакыт җитте дип уйлыймыз вә бөтен бурычны да матбугат бәйрәмендәге гөнаһларның кәффарәте өчен Казан матбугат әһеле башларга тиеш дип ышанамыз.

## [ХАЛЫК ТЕАТРЫ СЪЕЗДЫНДА МӨХТӘРӘМ ГАЯЗ ӘФӘНДЕ ТАРАФЫННАН БИРЕЛГӘН ДОКЛАД]

Татар театры татар тормышының көлкеле ягыннан алынган уеннардан башланды[1]. Бу уеннар мәдрәсәләрдә хозур вә кампания көннәрендә мәдрәсә шәкертләре тарафыннан уйнала иде. Мәүзугларын татар муллаларының, аларның мәхәллә халкы, мәхәллә эшләре берлән мөгамәләләренә керешле хәл вә вакыйгалардан көлүдән гыйбарәт булып, сәнгать, әдәбият ноктасыннан чыгарып ясаган әйберләр иде.

Тугыз йөз сиксәненче елларда театр китапларын әдәби рәткә салу тәҗрибәсе[2] ясалса да, муаффәкыять казана алмаган иде. Шулай да бу вакытларда татар театры китапларында милли фаҗига күренешләре язылган драмалар да ара-тирә күренә башлады. Ләкин татар халкының тормыш вә тирә-якка карашлары бик беркатлы булганга, бигрәк тә театрны аңларлык дәрәҗәдә хәзерлек булмаганга, халык татар яшьләренең — саннары бик аз, мәгънәви көчләре бик чикле булган яшьләрнең — милли театрга нигез салу тәшәббесләрен аңламады; милли театрның үз тормышындагы кыйммәтен тәкъдир итә алмады.

Ниһаять, унтугызынчы гасырның ахырларында Русиядәге сәяси үзгәрешләр һәм ислам галәмендә хәрәкәткә китергән уйгану дәвере Волга буе татарларына да тәэсирен итте. Аларда да әлегәчә күрелмәгән фикер вә карашларда үзгәреш тудырды, әлегәчә кыйммәтен тәкъдир итә алмаган нәрсәләргә дикъкатьләрен җәлеп итте.

Татарларда да, үзләренә күрә генә булса да, бер-бер артлы иҗтимагый, мәдәни, милли хокукларына керешле мәсьәләләр баш күтәрде, үз телләрендә гәзитәләр мәйданга килде. Мәдәният, мәгариф юлында эшләүче җәмәгать хадимнәре заһир була башлады, җәмгыятьләр тәэсис ителде.

Менә шул арада, шул елларда азмы-күпме милли әдәбият, милли музыка, милли театр халык арасында үзенә тиешле урынны ишгаль итәргә башлады. Халыкның аңлырак кыйсемендә тарафдарлар тапты. Шул мәгънәви үзгәрешләр эчендә тугыз йөз алтынчы елда Казан һәм Уфада татар зыялылары, татар мөгаллимнәре, татар мөхәррирләре тарафыннан төзелгән татар спектакльләре куела башлады[3].

Беренче куелган әсәрләр татарларның үз тормышларыннан алып язылган яки җәнүб төрекләренең театр китапларыннан икътибас ителгән әсәрләр иде.

Ул чагында гомумхалык арасында күбрәк уйналган пьесалар Гаяз әфәнденең «Өч хатын берлән тормыш» исемле әсәре[4], Г.Камалның «Бәхетсез егет» һәм төрекләрнең «Кызганыч бала»сы була иде.

Сәхнәдә уйнаучыларның берсе дә уйнар өчен махсус җитештерелгән затлар түгел иде. Хатын-кыз рольләрен уйнаучылар күп вакытта егетләр була иде.

Бара торгач, берничә татар гимназисткалары сәхнәгә чыгарга җәсарәт иттеләр.

Татар театрының мәйданга чыгуы халыкның күпсанлы надан кыйсеме арасында шау-шу тудырды. Казанда беренче татар театры куелачагы афишада игълан ителеп өлгермәде, кара фикерле татарлар тарафыннан һөҗүмнәр башланды. Шәһәрнең муллалары, атаклы хаҗи абзыйлары җирле хөкүмәт мәэмүрләренә, бу эшләр шәригатькә хилаф, театр уеннары халыкта, гаиләләрдә бозыклык, әхлаксызлык таралуга сәбәп була дип, татар театры уйнауга рөхсәт ителмәвен үтенеп мөрәҗәгатьләр иттеләр, жалобалар яудырдылар. Моның берлән генә калмады, театрга каршы кара көч[5] истигъмаль итәргә керештеләр.

Шуңгар күрә, беренче театр уйналганда, коралланган татар яшьләре артист вә артисткаларны урамда озатуга[6], шулай ук театр ишек төбендә коралланып каравыл торырга мәҗбүр булдылар. Чөнки кара халыкның, театр бинасына басып кереп, сәерчеләр һәм уйнаучыларга һөҗүм итүләре ихтимал иде.

Икенче яктан, муллалар бертуктамый мәсҗедләрдә театрның зарарына дин исеменнән ләгънәтләр яудыралар. Тәмуг берлән, кяферлек берлән, хатыннары талак, балалары хәрам булу берлән куркыталар иде. Кыскасы, театр хакында хыялга да килмәгән ялганнар, төһмәтләр берлән халыкның башын катыралар иде.

Бу күңелсез хәлләргә, кара халык тарафыннан яудырылган нәфрәтләргә карамыйча, халыкта милли театрны күрүгә һәвәс артканнан-артты. Беренче кат уйналган театр бинасы сәерчеләр берлән шыгрым тулды.

Шул беренче мәртәбәдән соң милли театр яңгыр соңында үскән гөмбә кебек һәр җирдә үсүендә дәвам итте. Театр һәвәскәрләре татарларның мәркәз шәһәрләрнең һәммәсендә табылды.

Мөселманлы шәһәрләрнең барысында да, зуррак авылларда, мөселманы күп заводлар театр уйнаучылар, түгәрәкләр тәэсис ителде. Бөтен Русиядә милли сәхнәнең өстендә пәрдә күтәрелде.

Татар театрының шулай үсүе, зураюы табигый юлында бара алмады. Аңгарга каршы, аның тәрәккыесенә дошман көчләр туды. Бердән, төрле җирләрнең түрәләре шөбһәле күз белән карап уңгайсызлыклар ясадылар. Татарча уйнарга драматический цензор[7] тарафыннан рөхсәт алынган пьесалар өчен русча тәрҗемәсен сорап йөдәттеләр. Һичбер сәбәпсез генә мөэзиннең кушмавы өчен рөхсәт бирмәделәр.

Икенчедән, эчтәге, татар тормышының уртасындагы аңлашылмаулар төрле манигълар тудырды. Яңгы бер пьеса язылып чыктымы, татар халкы арасында «Бу кем тормышыннан?» дигән сөаль китте. Вә һәрвакытта йә бер бай, йә бер мулла: «Бу минем тормыш, бу минем гаиләм», — дип, китапны үз өстенә

алып, китап хакында донослар, кылавызлар башлады. Вә шул китапны сәхнәгә чыгармас өчен бөтен түрәләрнең бусагаларын таптап бетерде. Русия тормышында зур роль уйный торган васиталар берлән күп вакытта теләгәненә муафикъ булды.

Татар пьесаларының бик күбе шундый киртәләр арасында сәхнәне күрә алмады.

Шулай булса да, тартыша, көчләшә булса да, татар театры татар тормышында гражданлык хакын алды. Ул шәһәргә генә түгел, авылга да керде. Мәктәпне үзенең иптәше ясап, һәр бәйрәмнәрдә аның сыйныф бүлмәләрен сәхнәгә әйләндерә башлады.

Ләкин драматический цензура татар театрына каршы бик зур уңгайсызлыклар тудырды. Татарлар арасында театрның тәрәккыесенә тормозлар ясады. Бу кадәр күпмиллионлы Русия татарлары өчен Петроградта матбугат эшләре баш управлениесендә бер генә драматический цензор торадыр. Бу цензорга татар театр китапларын карау хакында һичбер устав бирелмәгән. Цензор ничек теләсә шулай карап, үз ноктаи нәзарына муафикъ хөкем чыгара. Бу «ноктаи нәзар»ның нидән гыйбарәт икәне татар халкына бик мәгълүм. Ул да — Русиядә рус әдәбияты, рус театры булып торган сурәттә, татар әдәбияты, татар театры дигән нәрсәнең үзе юк һәм лөзүме юк.

Шуңгар күрә цензор карамагына бирелгән татар пьесалары өчәр елгача цензорда яталар. Соңыннан йә рөхсәт ителә, йә һичбер сәбәбен-нисен әйтмичә, күрсәтмичә кире кайтарылалар.

Хәлбуки татарның милли, мәдәни яшәве өчен, театрының яшәве-үсүенә ихтыяҗы җанлы халыкның һава, суга ихтыяҗы берлән бер дәрәҗәдә булганга, бу гайре табигыйлек зур уңгайсызлыкларга сәбәп буладыр.

Соңгы җиде-сигез елларда татарларда махсус җитешкән артист вә артисткаларыбыз мәйданга килде һәм сәхнәбез өчен алтмышка якын милли тормыштан алынып язылган пьесаларыбыз вөҗүдкә чыкты.

Дөрест, әле татарның милли театрының бинасы юк. Татар артистлары әлегә үзләренә аерым, гадәттән тыш бер хәят берлән яшәп киләләр. Алар чын-чыннан күчмә халыкка охшыйлар. Бер шәһәргә киләләр дә берничә спектакль биргәч, тагы икенче җиргә күчәләр. Мәгъруф «Сәйяр» труппасына[8] «Сәйяр — Гизгеч» дип аталу бу сәбәптәндер.

Шулай да Казан вә Оренбургта татар театры труппасы урынлашып тора.

Татар театрының үз халык тормышында күрсәткән тәэсирләренә килсәк, әлбәттә, татарның иҗтимагый-әдәби хәятында зур роль уйнавын инкяр итәргә мөмкин түгел.

Мәсәлән, хатын-кыз мәсьәләсендә татар театры мөһим мәсьәләләрне гамәли рәвештә чишеп мәйданга куйды. Чөнки драма рәвешендә язылган татар пьесалары һавадан, зыядан мәхрүм дүрт дивар арасында яшәп килгән татар хатын-кызы тормышыннан алынып язылалар. Бу пьесаларда татар хатынының да иреккә чыгуга омтылуы хәбәрләнгән, изелгән тормышка протест ителүе тасвир ителә, вә хатын-кызларыбызның иҗтимагый, мәдәни хәятта тотарга тиешле булган урыны күрсәтеләдер.

Шуңгар күрә үзләрен тоткынлыктан азат итү юлында көрәшүче каһарман артистларга каршы татар хатыны миннәтдар.

Татар театры татар мәдәни хәятында мөһим гамәлләрдән булганга, халык яклы рус зыялыларының да дикъкать вә игътибарларын җәлеп итәргә, аларның хөсне илтифатларына хакы бардыр.

Әйтәчәк сүзнең кыскасы, татар театры бер мәдәни милләт театры дәрәҗәсенә җитәр өчен, иң әүвәл, әлбәттә, бөтен Русиядәге хокукый үзгәрешләргә баглыдыр; икенчедән, татар театры юридически бер җәмгыять хәленә керә алсын өчен, җәмгыятьләр хакындагы 4 март правиласына[9] тәфсир итеп бирелгән циркуляр буенча, мөселманнарның җәмгыятьләргә оешуы хакындагы кысынкылыклар бетерелергә тиеш; өченче, театрга куелу өчен махсус драматический цензура дигән диван бетерелгәнчә, шуның эше ислях ителергә тиештер; дүртенче, татар теленә Русиядәге бөтен телләр берлән бер хак бирелеп, татар теленең бөтен кысынкылыклардан хөр ителүе ляземдер.

## МӘСКӘҮ, 20 ГЫЙНВАР

Гәзитәмезнең бу номерына дәрҗ ителгән студент Сәгыйд әфәнденең «милли оешу» хакындагы фикере[1] искерми торган бер авыруымызны уятадыр. Ул да — нинди генә эш башланмасын, шул эшне алып барыр өчен ахырына кадәр көчнең җитмәве һәм төрле тарафта эшләнә торган милли-мәдәни эшләрнең бер-берсе берлән багланып бер эздән бармавыдыр. Безнең милли-мәдәни ихтыяҗларымыз күп булганга, болар һәрвакытта төрле тарафта татар тормышының өстенә чыгып торалар.

Кайвакытларда бик зур дулкыннар күтәрелеп, бөтен татар әфкяре гомумиясенең дикъкатен җәлеп итәләр: мөфтилек, идарәи рухания исляхы, мәктәпме, школамы мәсьәләсеме, фракциясенең сәясәте вә башкалар.

Кайвакытта татар тормышы өстендә шадралар гына чыгарып, кечкенә-кечкенә тавышлар гына куптаралар. Йирле земстволарга сайлаулар, җәмгыятьләрнең эшләре вә башкалар кебек, кирәк, зурлары, кирәк, кечкенәләре булсын, уятылган мәсьәләләрнең һичберсе хәл ителә алмыйлар, сөйләнәләр-сөйләнәләр

дә кизүдән чыгалар, модадан үтәләр. Тормыш эчендәге дулкыннар да үзләренең көчләрен тагы берникадәргә чикле эчләренә яшерәләр. Мәсьәлә һичбер төрле хәл ителмәенчә, янынан үтәргә мөмкин түгел хәлгә керсә, төрле урынында төрле төстә хәл ителеп, милли берлегемезнең буявын көчсезләндерәләр*. Төрле вакытта төрлечә борып, аларның үсүләре, тәрәкъкый ителүләрендәге галяканы, мантыйкыйлыкны саклый алмыйлар. Милли үсүгә, милли тәрәкъкыйгә башбаштаклык зәһәрен сугаралар. Менә шул таркаулыкның тудырган уңгайсызлыклары, әлбәттә, көннән-көн күзгә ташлана барачактыр. Көннән-көн безнең хәзерге мәдәни, милли, сәяси эшләремезне бутаячактыр. Вакыт үткән саен киләчәкемезнең юлын төрлеләндереп, бөтен эшемез, идеалымызны буталгыч бер хәлгә китерәчәктер. Башбаштаклыкны коточкыч дахили дошман итеп арамызга утыртачактыр.

Шул хәзерге тарихи вакытларда яшәгәнемезне аңлаган көчләр, хәзерге вакытта ясалган кечкенә генә бер хаталар бик зур милли уңгайсызлыклар тудырачагын күреп торган куәтләр, милли даирәләр, шул депутатларның кырык тырнагы арасына кермәс өчен, милли оешуга омтылырга тиеш иде.

Шул милли даирәләрдәге аңлы затлар, шул мәсьәләнең иң әһәмиятле эш икәнен белеп, милли алга китүемезнең, сәяси вә мәдәни эшләремездә өмидле нәтиҗә көтүемезнең беренче шарты, милли хәятымызның иманы иттереп карарга вә булдырырга тиеш иде. Ләкин, мәгаттәәссеф, шуны әле эшли алмыймыз. Сәбәпләре, әлбәттә, бик күптер. Ләкин факт факт көенчә кала.

Без әле һаман арпа камыры кебек, оешмаган көенчә селкенеп ятамыз. Шуның хакында үземезнең зур милли көчемездән халкымызның файдасы өчен энергия, гайрәт ала алмыймыз.

Бәхетле халыкларда милләтнең тарихи көпчәге әйләнә башлаган чакларда эш башында торыр өчен кечкенә булса да саф, пакь, идейный бер милли гөруһ мәйданда була. Вә шул идейный төркем, үзенең ышанган мәсләге берлән халкын җыеп, аның барырлык мәгънәви көче булып (мәсәлән, Япониянең, Финляндиянең XIX гасыр ахырындагы интеллигенциясе кебек) каһарманәнә эше берлән халкын мәгълүм тарихи юлга төртеп җибәрә.

Халыкның эчтәге көче хәрәкәткә килеп эшләргә башлагач, бу гөруһның халык күзендә игътибары, кыйммәте зур булганга, бөтен кечкенә көчләр беренчеләр салган сукмакны киңәйтергә тотыналар вә шул кечкенә милли эшне көчләндереп, табигый юлы берлән үстереп, олуг тарих юлына, бөтен халыкларның тартыша торган мәдәни хәят мәйданына алып чыгалар. Һәм дә эчтән ныгыган көенчә тышкы көчләр, чит көчләр дошман булып каршы алса да, сытылып китмәслек булып чыгалар.

Менә мондый «милли оешу» һәм дә югарыдан түбәнгә таба милли оешу бик бәхетле халыкларга гына тугры килә. Эчендә бик-бик күп көчләр сакланып яткан яшь халыкларда гына була ала. Менә бездә дә шул мәсьәлә мөмкин кебек иде, безнең дә эчемездә табигый булган берлек бар кебек иде.

Шуның өчен бездә дә шул «югарыдан оешу» булыр кебек, хәерле нәтиҗә бирер кебек иде. Без дә үземезнең сәяси агышымызда, үземезнең мәдәни үсүемездә бер үзәктән барырмыз кебек иде. Мәгаттәәссеф, бу эш без теләгәнчә чыкмады. Мәгаттәәссеф, халкымызның эчендәге берлеге читтән кысылып кына ясалганлыгы, читтән тарттырган кыршау берлән генә берләндерелгәне мәгълүм булды. Безне кыскан кыршау шартларга өлгермәде, без кырык тарафка чәчрәп киттек. Кырык якта «Мин генә!» дигән лозунг берлән эшкә тотындык вә шул «Мин генә!»ләр вакыт узган саен күбәя-күбәя, элгәре шәһәрләрдә генә «Мин генә!»ләр башланды. Аннан соң мөселман күбрәк һәммә авылларга таралды. Хәзер инде «Мин генә!» дигән олуглар берлән Русия мөселманнарының бөтен авылы, бөтен мәхәлләсе тулган.

Менә шул «Мин генә!»лек, «мин-минлек» — бу көнге көндә безнең иң зур иҗтимагый авыруымыздыр. Менә шул «мания величия» хасталыгы — бөтен эшемезгә зарар итә торган, тормышымыздагы иң зур гамилдер. Әлбәттә, эш башындагы «олуглар»ымызның да куәи мәгънәвияләре кечкенәлеге, аларның да мәгълүм бер идея берлән янмаулары, мәгълүм бер мәсләкне үзләренең иманнары ясамаенча, бик гакыллы булган булып мәнфәгать кушулары шул банкротлыкка сәбәп булгандыр. Ни булса да булган, бу берлек банкротлыгы — хәзер булган бер эштер.

Шуның өчен киләчәктәге тормыш дулкыны килгәндә юылып ыргытыласымыз килмәсә, икенче төрле «берләшү» юлын карамаенча мөмкин түгелдер. Ул да — «түбәннән берләшү», халыкның яшәгән урынында, күплекле шәһәрләрендә, авылларында, милләтнең төрле икътисади бүлекләрендә аерым-аерым укыган пакь халкымызның күбрәк көчен сарыф итеп, шуны милли бер кальга хәленә китерүдер. Шуның өчен милли көчләремезне хәзерге көндә югарыдан берләшү фикеренә корбан итмәенчә, һәр шәһәр, өязнең мәдәни юлына тотарга тиештер. Оренбург үзенең земствосындагы милли хезмәткә иманлы бер кешене чакырырга вә шуңгарга ярдәм итешүне иң зур мәсьәлә санарга тиештер. Уфасы үзенең мәктәп эшләрен рәтләвенә бөтен дикъкатен сарыф итәргә тиештер. Казаны тагы шулай, болар артыннан, әлбәттә, төрле авыллардагы төрле милли җәмгыятьләр, милли көчләр, иң әүвәл үз вазифалары аяк баскан урыннарын ныгайту икәнен сизенеп, шуңгарга тотынырга тиештер.

Менә шул төрле йирләрдәге җәмгыятьләр, милли даирәләрдән табигый үсешкән көчләр генә киңәя-киңәя шуларны берләштерү юлына керергә тиештер. «Түбәннән оешу» да халыкның үзенең аңы, дәрте, гайрәте берлән эш ителәчәк булганга, шул оешу мәйданга килгәндә, шөбһәсез, югарыгы даирәләремездәге затларымыз да хәзерге кебек елак булмаенча, чын эшлекле кешеләр булачаклардыр.

«Түбәннән оешу» башланганда, йирле халыкның оешкан каны, акрынлап-акрынлап языла килеп, җәмәгать эше халыкның үзе эше булып калачактыр. Бу көнге көндә җәмәгать эшенә «эшсезләр эше» дип, «кәчемәгән йирне кашу» дигән ялган фикер дә бетәчәктер. Шуның өчен без бөтен Русиягә таралган саф, пакь көчләргә утырган урыннарында милли оячыклар ясауны хәзерге тарихи көннәрнең фарызы дип беләмез вә киләчәгемезнең өмиден шул яшь көчләрнең саф эшләренә иманлы, мәсләкле булуына гына баглый аламыз. Вә шуның өчен үземезнең югарыдагы милли даирәләремезне күздә тотсак та, бөтен гайрәт, бөтен энергияне шуларга сарыф итү дип урынсыз дип беләмез.

Ителәчәк гайрәтләр, матди ярдәмнәр нәтиҗәсез калмаса да, алар йирле көчләрне зәгыйфьләндерү юлында булмаска тиеш дип уйлыймыз.

## «ЙОЛДЫЗ» ЮБИЛЕЙСЫ

«Йолдыз»* гәзитәсенә ун тулды. 16 гыйнварда шул бәйрәмне «Йолдыз» идарәсе махсус номер[1] чыгарып укучылары белән бүлеште. Шул номерда «Йолдыз»ның мөхәррирләре үзләренең иткән хезмәтләре хакында, хисапмы диим, бер нәрсә бирде. Кайберсе шул көндә «Йолдыз» һәйәте тәхририясен, хосусән Һади әфәндене, бөтен милләт исеменнән булмаса да, күпчелек исеменнән тәбрик тә итте.

«Йолдыз»ның ай хакындагы мөхәррирләреннән Садыйк хәзрәт әл-Иманколый җәнаблары шулкадәр тәэсирләнде булырга кирәк, ул, үзенең «Каванинел-җимаг»** китабындагы мөтәхассыйслыгын да онытып җибәреп, «Йолдыз»га багышлап шигырь дә язды.[2] Шуның берлән, әлбәттә, шул хәзрәт таланты ни дәрәҗә киң икәнлеген күрсәтеп, дустларын сөендергән кебек, «Йолдыз»ның шигырь, әдәбиятка да ни дәрәҗәдә хезмәт иткәнен, сәнаиге нәфисәне никадәр нечкә, назик аңлавын эш берлән күрсәтте. Ләкин шунысы гаҗәп, «Йолдыз»ның язучылары үзләре хакында язган мәкаләләрендә «Йолдыз», ун ел могтәдил милли мәсләктә дәвам итеп, Русия мөселманнары эчендә җиде-сигез мең укучы тапты» дисәләр дә, «Йолдыз»да язучы мөхәррирләрнең исемнәрен санаганда, Русиядә бөтен әһле каләмне зикер итеп, шул цифрны 220 гә җиткерсәләр дә, шул бәйрәм номерында Һади әфәнде, борадәре Садри әфәнде, борадәре Сәләхетдин әфәнде, «Йолдыз» язучыларыннан Ибраһимколый, Шәһит Әхмәдиев, Хөҗҗәтел-Хәким Мәхмүдов, мөгаллим Фатих Сәйфи әфәнделәрнең каләмнәреннән башка бернәрсә дә күренмәде вә җиде-сигез мең укучы тарафыннан вәкяләтәнме, үзеннән генәме, Чистайның бер приказчигы берлән Әҗенең карагруһысыннан Шәриф мулла, беркемгә дә мәгълүм түгел Госманов һәм Гатиев[тан] башка кеше табылмады***. Татарның милли хезмәтләрен тәкъдир итә белүче аңлыларыбызның хатасымы диик, аңлап эшләгән эшләреме диик, күзгә ташланырлык беркем тарафыннан («Вакыт» берлән «Тәрҗеман»нан башка)[3] бер тәбрик, бер котлау җибәрелмәде. Гыйльми, әдәби бер төркем тарафыннан һичбер төрле тәкъдир ителгәне күрсәтелмәде. Ул гына түгел, каләм юлында хезмәт иткән мөхәррирләр тарафыннан җылы сүз, дустча әйткән бер фикер, иптәшчә бер кул кысу очрамады. Бу иттифакый тугры килгән хата гына булдымы? Әллә милләтнең аңлы кыйсеме шул ун ел яшәгән «Йолдыз»ның яшәвендә, үсүендә сөенерлек бер нокта тапмадымы? Әллә халыкның алдан бара торган бер бүлеге «Йолдыз»ны — мәгълүм «Йолдыз»ны ун елга кадәр яшәтергә җитәрлек тирә-юньнең шулкадәр озак арчыла белмәвенә эче пошты да, кайгырды да матәм тоттымы?

Унъеллык бәйрәмен беренче мәртәбә итә торган Идел буе матбугатының беренче юбилейсындагы шул суыклык, шөбһәсез, тәхлил итмәенчә кителәчәк бер вакыйга түгелдер.

Имеш, бер кеше (мәсәлән, Һади әфәнде) биш-алты яшьтән гәзитә чыгару уе берлән мәшгуль булсын (Һади әфәнде үз мәкаләсендә шулай ди). Имеш, бер кеше бала вакытыннан ук илһам берлән «Йолдыз» дигән исемне байрак итеп алсын да, шул байракны тормышының мәдрәсәсеннән, ысуле җәдиденнән, мөдәррислегеннән, экстренныйлыгыннан өстерәп чыгарып, билфигыль «Йолдыз» итсен, имеш тә, шуны сәяси, иҗтимагый, икътисади авырлыклардан курыкмаенча, ун ел бербуйдан, «суллык» мода булганда да, мөдәббиранә алып барып, миллиятне мөдафәгада фидаи булсын, имеш тә, шул фикергә иштиракь итүче, шул байракны бергә күтәрешеп баручы ике йөз дә егерме мөхәррир язучы җыйсын, имеш тә, җиде-сигез меңлек бер кавемга минбәр булып, шул халыкны тугры «милли» юлдан өстерәп барсын, имеш тә, туктап бәйрәм итәргә уйлагач, тагы шул Ибраһимколый, тагы Садыйк Иманколый, тагы агай-эне берлән генә калсын, имеш!

Бу урында, Һади әфәнде урынында, чынлап та үзенең мәсләге, үзенең идеалы өчен генә яши торган бер кеше булса, аның шул озын тартышудан соңгы бәйрәме шул хәлдә үтсә, ул кеше үзенең иткән хезмәте, бетергән гайрәте һичбер төрле мәгънәви файдага китмәгәнен күрсә, шөбһәсез, шул идея банкротлыгын күтәрә алмас иде, шөбһәсез, ул кеше янып-көеп үләр иде. Яки аһ-ваһ итеп, йөткереп бетәр иде.

Ләкин Һади әфәнде җәнабларының ул хәлдә түгеллеге хакында укучыларны тәэмин итә алганга, шул күңелсезлекнең сәбәбен башка тарафыннан эзләү түгелме? Минемчә, лязем. Укучыларга, әфкяре гомумиягә шул суыклыкның сәбәбен белү лязем.

Әле «Йолдыз»ның бәйрәме — «Йолдыз»ның унъеллык «милли хезмәте»нең бәйрәме шулай үтте, шулай үтәргә тиеш булганга, шулай үтте. Чөнки «Йолдыз» ун ел яшәсә дә, ун ел эчендә бик күп кәгазьләрне каралап чыгарса да, бик күп фикерләрне бутап-бутап маташса да, «Йолдыз» үзенә дуслар, үзенә мәсләктәшләр таба алмады. Чөнки «Йолдыз» үзе дустлык карасына манылып язмаенча, осталык, яра вә каралары берлән языла, мөдарә каләме берлән төзәтелә иде.

Чөнки «Йолдыз»дан ап-пак нур сибелмәенчә, күзнең эчен пошыра торган пәри утлары гына тарала иде. Мәсләктәшләр җыя алмады. «Йолдызчы» ясый алмады. Чөнки «Йолдыз»ның мәсләге юк иде, «Йолдыз»ның алган юлы, туры дип ышанган фикере, болай итәргә ярамый, дип яратмаган уе юк иде.

Ул боларның һәммәсеннән дә «мөдәббиранә» кичә иде. Шуның өчен татар тормышы алдына таң яктысы туарга торганда, «Йолдыз»ның мәсләктәшләре дә, исемнәрен саклап, «мөдәббиранә» «Йолдыз»ның бәйрәменә катышмадылар. Шуның өчен «Йолдыз»ны укучылар «Йолдыз»ның милли хезмәтен, могтәдил мәсләген сөючеләр дә Һади әфәндедә өйрәнгән «сөясәтчә» белмәмешкә салынып калдылар. Шуның берлән бу халык лисане халь берлән «Йолдыз»ның бүгенге унъеллык юбилейсы бәйрәме түгел, «Йолдыз»ның җеназасы икәнен күрсәттеләр.

Соң, чынлап та, «Йолдыз» шулай каршы алынырга тиеш идеме?

«Йолдыз» соң гәзитә буларак нәрсә?

Иң әүвәл гәзитә дигән нәрсә безнең кебек матбугаты яңгы туган чакта, мотлакан, бер фикер, бер мәсләкнең нашире булырга тиеш; мотлакан, зурмы, кечкенәме, бер гөруһ, бер төркем халыкның тәрҗемане әфкяре булырга тиеш.

Мотлакан, мәгълүм бер фикерне алып бару да билгеләнгән эзе булырга хаттел-хәрәкәте тәгаен әйтелгән булырга тиеш.

Мотлакан, гәзитәнең кайдан чыгарга ярамавы хакында җиңнәренә баганалар — мораль, мәсләк баганалары утыртылган булырга тиеш.

Һади әфәнде, үзенең әйтүенә караганда, ул кечкенә чактан ук «гәзитәләрне вәкаигы яумия языла торган урактан гыйбарәт икәнен» аңлаган икән.

Шуның өчен «Йолдыз»га әллә ничә мәртәбә рөхсәт сорауларында ул шул «вәкаигы яумия»нең рапортын татарча язарга дип рөхсәт сораган вә шул рөхсәтне ала алгач, шул «вәкаигы яумия»не язып чыгара башлаган. Һади әфәнденең бәйрәм номерындагы дустлары, ишләре, шәкертләренең сүзенә караганда, шул рапортта сүзләрен әдәби татар телендә һәм дә дөрес имля берлән яза килгән.

Гәзитәгә, шулай итеп, тормышның протоколы дип карагач, табигый, Һади әфәнде, шул мәсьәләләрне язганда, аның дөрестлегенә әһәмият бирергә кирәк иде түгелме? Ләкин Һади әфәнде, кечкенә вакытында «кушуч» берлән «йушкы»ның төбен эзләгәндә үк этисеннән куркып калганга, әллә кемнәрнең кәефе китмәсен өчен анда сыгылып, монда бөгелеп язып килгән.

«Йолдыз»га кергән бөтен мөхәррирләрне шул эскәнҗә астыннан үткәргән. «Йолдыз» янына килгән һәрбер кешенең «үзлеген» бетереп, аны «Йолдыз»ның агымында борылып-борылып ага торган йомычка ясаган вә шуның аркасында «Йолдыз»да һәйәте тәхририя дигән әсасны бөтенләй бетереп, кечкенә Һадичыклар, Мөтәһадилар тудырган вә шуның аркасында гәзитәнең мәгънә үсүен мәңгегә кисеп куйган.

Гәзитәнең кайдан үтәргә ярамый, кайдан кичәргә ярамый дигән кагыйдәләре булмаганга, ул унъеллык дәвамында, гәзитәнең мөхәррирләре әйткәнчә, махсус имлясын алып баруга башка бер эз, бер якты юл калдыра алмаган.

Менә чын гәзитә булыр өчен кирәкле шартларның берсе дә табылмаганга, «Йолдыз», үзенчә аерым бер тормыш белән яшәп ун ел гомер үткәргән, шул вакыттагы Русиядәге реакциядән файдаланып, шул вакыттагы татар арасындагы башбаштаклыктан файдаланып, халыкның аңламавына, наданлыгына таянып, ул ун ел дәвам иткән. Ләкин гәзитә булып түгел, әллә нәрсә булып, «вәкаигы яумия» булып, «чуалчыкаты сәясия», тагы белмим ни булып торганлыгын, ләкин шул торуы өчен, шул осталыклар, шул мәсләксезлекләр генә җитмәгәнгә, гәзитә дигән нәрсәне алып барырга зур бер матди көч кирәк булганга, «Йолдыз» шул якны ничек хасил итә алган?

«Йолдыз»ның дәвамын кем тәэмин иткән? Шөбһәсез, монда без Һади әфәнденең бик оста сәүдәгәр, бик гакыллы мәнфәгатьпарәсен күреп, хәйран калмый хәлебез юктыр.

Һади әфәнде, мәдрәсә шәкерте генә булса да[4], бик күп сәүдәгәрләр аңлап җитә алмаган «базар»ның әхвале рухиясен аңлый, үзенең «товары» «Йолдыз»ның ниндирәк даирәләрдә үтә алачагын эзли. Билгеле, төн никадәр караңгы булса, «Йолдыз» шулкадәр ялтырый кебек күренәчәк. Шуның өчен Һади әфәнденең иң кара, иң караңгы бүлекләремезгә таба күзен боруы табигый түгелме? Шуның өчен Һади әфәнде авылның кара якларына, авылның Сәет Баттал, Салсал хикәясе[5] укып тәрбия алган мөәзиннәренә күзен сала. Шуларның теләкләренә теләк иттереп, шуларның Салсал хикәясендәге өйрәнгән фикер агышына якын тарызда язарга тотына. Сәет Батталдагы кебек, шаккатырулар берлән мөәзиннәрне кызыктыра... Сәет Батталдагы кебек күз ачып күз йомганчы Англиягә барып килеп, Америка берлән Англия мөнәсәбәтен хәл итә.

Салсалдагы кебек гөруһ-гөруһ кяферләрне мөселман итә. Сәет Батталдагы кебек өч көн эчендә гарәпчәне белә торган, дүрт көн эчендә Мопассанны аңлый торган дәрес китаплары хакында тәгърифләр яза, шул мөәзин янына надан мулласын да катыштырыр өчен программаны киңәйтеп ай вә гошер зәкятләрен кертә.

Мөәзиннәр, надан муллалар, иске фикерле сатучыларга элгәреге уйлары, элгәреге төшенчәләренә башка яңа бер авырлык сукмас өчен, аларны куркытмас өчен, һичбер мәсьәләне ачык иттереп куймый; бер мөштәринең яисә бер гөруһ укучының кәефе китмәс өчен, бер фикерне дә катгый иттереп әйтми. Үзенең сакланачак мәсләк колгасы юкка, каршы тотачак иман калканы юкка, ул бер фикер өчен дә кызуланып тартышмый, кычкырышмый; тисәләр, бәрелсәләр дә, «безнең урамга килерсең әле» дип мыгыр-мыгыр итә дә читкә китә. Ләкин ялгыш бер туры килгәндә, мотлакан, аягының гына бер очын чалырга дип көпчәккә таяк тыгарга булып китә. Кечкенә вакыттагы куркып калуы хөрриятен бетергәнгә, укучылары арасында кәефе китүче булмасын дигән каулгә* табыну ихтыярын алганга, ул аяк чалганда да кешедән чалдырырга маташа. Үзенә туры килсә, тагы ялгыш икән кебек кенә кылана.

Шулай иттереп, «Йолдыз» үзе куркак, үзе мораи, үзе икейөзле, үзе чуалчык булып, яңа замананың диюләр хикәясе кебек бернәрсә булып яши. Фидия өчен кычкырыша, талаша, зәкят, гошер өчен донос ясаша торган, иске дә түгел, яңа да түгел, аңлы да түгел, аңламый да түгел бер бүлек халыкның тәрҗемане әфкяре була да, шуның морале, шуның күз карашы берлән төзәленеп тора. Шуның «вәкаигы яумия»сен яза да тора. Ләкин шунсын инкяр итәргә ярамый, шуларны махсус бер имляда язып тора[6].

Чын гәзитә укый алмаган бер сыйныфны, шөбһәсез, кызыктырып укырга өйрәтә. Шөбһәсез, шул кыйсем халыкка яңа бер уй бирмәсә дә, бер фикер чаткысыны, тугры бер хакыйкатьнең авырлыгын салмаса да, үз тирә-юнендәге чуалып йөри торган фәлсәфәсене, сәясәтне җәмәгать башмагы кебек әйләндереп йөретә.

Гомумән караганда, «Йолдыз» татар арасында бер кыйсем халыкны укырга өйрәтеп, гәзитәнең гомумләшүенә хезмәт итеп файда китерә. Гәзитә укудан читтә калачак бер бүлек халыкны гәзитә дөньясына өстерәп кертеп, бөтен татар матбугатының укучысының даирәсен киңәйтә.

Ләкин мәгънәви яктан караганда, «Йолдыз» татарның милли фикеренең алга баруында, табигый юлыннан алга баруында бик зур җинаять ясагандыр. Иң әүвәл «Йолдыз» ап-ачык ителеп әйтеләчәк хакыйкатьләрне имеш-мимешләр берлән бутап, ачык сүзгә мохтаҗ укучысының мантыйкын бутагандыр. Икенчедән, «Йолдыз»ның бу хата, бу туры дип алып бара торган юлы юкка, аның бүген хатарак булуы ихтималы бар дигәне, иртәгә дөрес булу ихтималы имеш берлән бетерелгәнгә, гомумән, укучылары арасында ялган берлән дөрест, хата берлән ялгыш арасындагы чикнең бетүенә сәбәп булгандыр.

Өченчедән, ун ел бербуйдан «Йолдыз»ның бөтен язуларында мәсләксезлек, милли, сәяси, иҗтимагый моральләрне аяк астына таптау өстерәлеп килгәнгә, «Йолдыз» мәсләксезлекне мәсләк итә торган милли хулиганлыкның тууына мәгънәви ата булгандыр. Үзенең вак гайбәте, вак интригасы, вак доносы, вак фәлсәфәсе, вак яхшылыгы берлән шул милли хулиганнарның үсүенә сөт, җим биреп, ана булгандыр.

Дүртенчедән, «Йолдыз» иң законлы эшләрдә хөкүмәтнең һичбер төрле даирәсе тарафыннан кысылырга уйлатылмаган мәсьәләләрдә бик ерактан күргән булып, болай да куркак халыкны куркытырга, «законный микән, фәлән микән» дип котын очырырга өйрәткәндер вә, шул зәһәрне тамчы-тамчы тамыза-тамыза, укучылардагы гражданлык хисен тавык йөрәклегенә кадәр иңдерергә сәбәп булгандыр.

Менә шул шөбһәсез зарарлы эшләрне «Йолдыз» көпә-көндез ап-ачык иттереп эшли алгандыр.

Менә шул зәһәрләрне «Йолдыз» тирә-юнендәге әллә никадәр гәзитәләр, журналларның тәнкыйде арасында эшли алгандыр. Әфкяре гомумиянең ак, пакь кыйсеменең каршы торуына карамаенча, шул мәсләксезлек җимешен үстергәндер, тараткандыр. Шуның өчен «Йолдыз»ның ун ел тулу мөнәсәбәте берлән ясаган бәйрәмендә халык өчен дә шатланырлык зур бер нокта бардыр. Әүвәлдә, «Йолдыз»га башка татар гәзитәләре юк вакытта, хөкүмәтемез тарафыннан рөхсәт бирелмәенчә торып, аның зәһәреннән шул вакытта безне саклап калуыдыр.

Шул вакытта, аңгарга каршы бер сүз әйтергә мөмкин булмаган чакта, безнең бөтен халкымызның фикере агышына зәһәр җибәрергә Һади әфәндегә монополия бирелмәведер. Бу шатлык милли көчләр өчен, киләчәккә өмидләре бар көчләре өчен, татар тормышының соңгы ун елыннан үткәргән вакыйгаларының иң

сөенeләчәге, иң зурысылыгында минем шөбһәм юктыр. Шуның өчен бүгенге көндә мин дә бәйрәм итеп, «Йолдыз»ның ун гына ел яшәгәненә шатлыгымны изһар итеп, татарның иҗтимагый вә сәяси, милли тормышыннан шундый органнарны яшәтә торган гамәлләрнең тиздән бетүен Алладан сорап калам.

«Йолдыз» гәзитәсенең татар матбугаты юк вакытта рөхсәте бирелмәве хата икәнен хөкүмәт даирәләре хәзер аңладылар булырга кирәк. «Йолдыз» таралуына җиңеллек итәр өчен карагруһ гәзитәләренә генә бирелә торган почтадагы очсыз тарифаны* татар гәзитәләреннән фәкать Һади әфәнденең «Йолдыз»ына гына биреләдер. Вә шуның хакында «Йолдыз»ның матди тарифы хөкүмәт тарафыннан ясалган зур бер ярдәмгә таянып барадыр.

## МӘДӘНИ ЭШЛӘРЕМЕЗ

Гәзитәләрнең язуына караганда, Оренбург вилаять земствосы, Уфа вилаять земствосына мөрәҗәгать итеп, земстводан ярдәм ала беләчәк. Мөселман мәктәпләренең программасын тикшерер өчен, махсус бер программа ясар өчен бер киңәш мәҗлесе ясауны башларга үтенгән. Уфа земствосы, бу эшне әле карап бетермәгән булса да, шул тәшәббесне үз өстенә алачак икән.

Мөселманнарның ибтидаи мәктәп эшләре һәр йирдә бик чуалчык булганга, әлбәттә, бу мәҗлескә башка губерна мөселманнары да чакырылырга тиештер.

Шунда эшләнгән программа бөтен Идел буе мөселманнарына ярарлык булып чыксын өчен, халык шуны үз теләге дип карасын өчен, әлбәттә, мәктәп эшләрендә ихтисасы булган мөгаллимнәремез, педагогларымыз чакырылырга тиештер. Аларның тавышларына зур әһәмият бирелеп, ибтидаи тәгълимнең нигезе таза йиргә куелырга тиештер.

Ләкин бу сүзләр сөйләнеп йөри торган төче хыяллардан үтсен өчен, уку-укыту, мәктәп ясау эшләренең мөтәхассыйслары докладлар хәзерләргә, кирәге булса, гомумҗыелышка кадәр кечкенә бер киңәш мәҗлесе ясап алырга тиештер.

Ибтидаи тәгълим мәсьәләмез хәзерге көндә баһадирча тырышып укытучы мөгаллим, мөгаллимәләрнең иҗтиһады, мәхәлләдәге бер-ике тәрәккъыйпәрвәр мөселманнарның һиммәтенә генә бәйланып тору баскычыннан үтәргә тора. Тормышның кушуы аны үсәргә, нигезен ныграк йиргә салырга мәҗбүр итә. Шуның өчен мәктәп хәзер иттифакый тугры килгән мөгаллимнең иттифакый китүе берлән үзгәрә торган программасын да әсаслы бер юлга куярга тиештер. Шуның өчен мәктәпнең Әхмәтҗан абзыйның кәефе өчен үзгәрми торган, мулла абзыйның мәслихәт тапмавы берлән арттырылмый-киметелми торган төпле программасы булырга тиештер.

Программаны ясау, бездә гадәт булган кебек, дәрес тәртипләрен, китап исемнәрен, укыту вакытларын язып чыгу гына түгелдер. Программа төзү дигән нәрсә — киләчәктә мәктәпнең тәрбиясе, укытылуы, рухы нинди юлдан барырлыгы хакында Коръән аятьләре кебек катгый кагыйдәләр астына бөтен мәктәп эшен сугудыр. Шуның өчен бу программа эше — милләтемезнең киләчәгенең рухы, җанылыр. Шул программаны кирәгенчә эшләп бетерү — мәктәп эшемезнең яртысыдыр. Шуңгарга күрә, кирәк, Уфа земствосының, кирәк, Оренбург земстволарының шул эшкә дикъкать итүләренә бик сөенеп карап, бөтен гыйльми көчемез берлән шул эшне яшәрлек, үсәрлек итәргә тырышу ляземдер, форсаттыр. Гомумән, земстволарның безнең мәктәпләремезгә, кыйраәтханәләремезгә бирә килгән ярдәмнәрен тотуда бик саклык берлән мөгамәлә кылып, земство алдында шул кечкенә генә сумаларның сәмәрәсе бик зур икәнен эш берлән күрсәтү киләчәгемез өчен бик тиештер. Шул даирәләрдәге ышануны казану халкымызны агартудагы өмидемезнең без теләгәнчә чыгуына хәерле фал булачактыр.

Оренбург вилаять земский собраниесенең карамагына бик күп докладлар арасында губернаның мөселманнары арасында мәгариф тарату хакындагы берничә доклад та бардыр.

Бу докладлар, иншалла, безгә файдалы рәвештә хәл ителәчәктер. Ләкин Оренбург губернаторы Орск земствосының мөселманнарны агартуга дигән унсигез меңнән өч мәктәпне генә тасдыйк итүе, үзенең мәҗлесне ачкандагы нотыгында Чиләбе земствосының чиркәү школларына акча бирмәвенә разый түгеллеген вә мөселман мәктәпләренә акча бирүне кирәкле тапмаенча күрсәтеп сөйләгән сүзләре Оренбург земствосындагы мөселман мәгарифен шактый уңгайсыз хәлгә куядыр.

Оренбург вилаятендәге мөселманнар, хәзерге көндә губерна халкының өчтән бер өлеше булган кебек, мәгариф ягыннан иң мохтаҗ булган халыктыр. Боларның мәктәпләре, хәзинәдән ярдәм алмаганга, үземезнең идарәи руханиямез тарафыннан да вә башка җәмгыятьләремез тарафыннан да ярдәм ала алмыйдыр. Болар һәммәсе дә шундагы фәкыйрь халыкның тырмашуы берлән генә барадыр. Шуның өчен мондагы мөселманнарның үзләреннән земский сбор дип җыелып алына торган сумадан йөз дә икесенең генә үз мәктәпләрен алып баруга тотуны күрәселәре килүе табигый булырга тиеш иде вә шул хаклы

ярдәмне һәм дә наданлыктан сусаган мөселманнарга бирәр тамчы гына тамызыла торган шул ярдәмне беркем дә артык күрмәскә тиеш иде. Ләкин губернатор җәнаблары ни өчендер шул эшләргә сәясәт катыштырып, чеп-чи мәдәни эшкә сәяси рәң бирәдер. Мөселман мәктәбе берлән чиркәү школасыны бер-берсенә рәкыйб итеп куядыр.

Без үз мәктәпләремезне моңганчыга кадәр һичбер төрле сәяси партиянең коралы итмәдек вә шул мәктәпләрдән гыйлем агаруга башка һичбер төрле сәяси фикер таратмадык вә киләчәктә дә таратмаячакмыз. Чөнки без сәясәт берлән агару-агартуны, мәктәпне бутап йөрткән халыкларның сәясәтләре бәрбад, мәктәпләре пәришан икәнен күргәнемез бар вә киләчәктә дә шулай булачагына ышанырлык фәнни тәрбиядән мәгълүматымыз бардыр. Шуның өчен Оренбург земствосының халкын агарту юлындагы хезмәтенә «бусы — мөселман», «бусы — түгел» дип аерма куелмавын бик ихлас берлән көтәмез. Хосусән аталары сугыш сафларында да баһадирча сугышып яткан башкорт балаларының мөселман булганлыклары өчен генә укудан мәхрүм иттерелүе ватан файдасы ягыннан да кирәкле бер эш түгелдер.

Шул көннәрдә Оренбургта Әхмәт бай мәрхүм вәкыфының мөтәвәллиләренең еллык мәҗлесләре була[1]. Бу мәҗлестә Әхмәт бай мәрхүмнең васыятен тутыруны өстләренә алган мөселманнар үзләренең үткән елда шул эш тугрысында нишләгәнлекләре хакында хисап бирәләр. Киләчәк ел өчен нишләячәкләре хакында планнарын тасдыйк итәләр.

Әле гәзитәләрдә, кирәк, хисаплары, кирәк, эшләячәк эшләре язылып чыкмаганга, цифрларга таянып сүз сөйләү бик авырдыр.

Ләкин цифрсыз гына, моннан, ерактан карап кына бәгъзе бер фикерләр йөртергә ярамас кебек күренми.

Мәрхүм Әхмәт байның вәкыфы буенча «Хөсәения» мәдрәсәсе тәрбия ителә[2]. Анда ике йөз-өч йөз шәкерт дәрес ала иде.

Мәдрәсәнең куелуындагы низам вә интизам булмаудан, мөдәррис әфәнденең эш башында торырлыгы булмавыннан егерме ел дәвам иткән бу мәдрәсәдән чыккан затларның саны Уфаның Сабирҗан әфәнде Шәмигуловның магазиныннан чыккан артистларымыздан[3] бик күп ким булса да, бала-чагага аң кергәнчә укырлык бер йир булып тора иде.

Ләкин былтыргы елда мәдрәсә тәмамән ябылды. Әлбәттә, үзеннән-үзе генә түгел. Зур-зур сәбәпләр берлән ябылды. Ләкин ябылды, ачылуы хакында бер эш эшләндеме-юкмы — анысы безгә мәгълүм түгел, ләкин ачылмады.

Менә шул матдәсендә мәрхүм Әхмәт байның рухы шатланырлык эш, әлбәттә, булмады.

Әхмәт байның вәкыфыннан алтмыш авылдагы ибтидаи мәктәпләрнең мөгаллимнәренә мәгаш бирелеп килә иде. Шул мәгашне алып, алтмыш мөселман мәхәлләсендә алтмыш мөгаллим аз дигәндә өч мең гөнаһсыз мөселман баласын укытып, күңелен нурландырып килә иде.

Олуг бәйрәм көннәрендә шул өч мең гөнаһсыз балалар мәрхүм Әхмәт байның рухының тынычлыгына дога кылалар иде. Үткән ел, менә бу ел шул мөгаллимнәр вазифаларын ала алмадылар. Үткән ел да, бу ел да шул өч мең мөселман баласы укытуның савабы Әхмәт байга бара алмады.

Әлбәттә, моның сәбәпләре бардыр. Әллә кая йорт сатылмагандыр... Әллә кемнән акча алынмагандыр... Бәлки, башка эш эшләнмәгәндер, анысын мин белмим. Ләкин алтмыш мөгаллимнең вазифасы ике ел бирелмәде. Өчәр меңләп балалар ике ел укытылмады, мин шуны беләм.

Бу җыелышта мөтәвәллиләр киләчәктәге хәлләр хакында уйлаячаклар һәм дә яңгы әгъзалар сайлаячаклар, имеш. Алары — үз эшләре. Ләкин киләчәктә дә шулай барачак булса, мөтәвәллиләрнең яңгысын сайлап торуның лөзүме бармы? Шулар гына эшне алып бара алмыймы?

Әхмәт бай дигәч, Мәхмүт бай да искә төшми хәле юк. Мәрхүм ул да агасы кебек үк гыйлем юлына кереп китмәгән булса да, шуның өчен зур бер мәдрәсә салдырып, шуны ышанычлы мөдәррис кулына тапшыра алмаса да, ул да бик зур вәкыф калдырган иде. Ул да шул тирәдәге, хосусән Каргалыдагы мөселман мәдрәсәләренең хәлләрен хәтеренә төшереп, аларны карарга Швейцариянең бер кантоны кадәр бер утарны вәкыф иткән иде. Ул мәсьәләгә инде өч-дүрт ел вакыт үтсә дә, әле ул вәкыф тасдыйк иттерелеп беткәне юк иде. Мәхмүт бай мәрхүмнең мирасыннан угыллары файдалансалар да, үзенең рухы әле файдалана алганы юк иде, вә шул соңаю Оренбург, Каргалы мөселманнары арасында төрле-төрле хәбәрләр дә чыгарган иде. Хәзер шул вәкыфны тасдыйк иттерү юлына керелгәнен мәгалмәмнүният хәбәр алдык.

Шундый уңган елда, сәүдә эшенең шулкадәр кызу елында аталарының рухын тынычландырыр өчен вакыт табуларына балаларына рәхмәт укымаслык түгелдер. Иншалла, озакламаенча шул вәкыф та, тасдыйк ителеп, бөтен эшкә керешергә мөмкин булыр. Ләкин бу тасдыйкның да бик озак сузылмавы, әлбәттә, мәрхүм бай балаларының үзләренең теләге булганга, әһле матбугатның да күңелен тынычландырачак бер эш булганга, тиздән бетүен көтәмез вә Мәхмүт байга гөрләп савап баруны балалары ашыктырыр дип ышанамыз.

## «ИЛ» НАШИРЕНЕҢ МӨРӘҖӘГАТЕ

«Ил» гәзитәсе былтыр тукталып калгач, бик күп агентларымыз, алыш-биреш иткән кешеләремез хисапларын бетермәделәр. Төрлеләренә төрлечә мөрәҗәгатьләр булса да, бу көнге көнгә кадәр «Ил» гәзитәсенең ил өстендә алачагы мең дә дүрт йөз сумнан артыктыр.

«Ил»нең нашире булуым өчен аның бурычларын түләргә миңа тугры килгәнгә, «Ил»гә бирәчәкләре бар әфәнделәр, ханымнардан бурычларны үтәүләрен бик үтенеп сорыймын. Акча, переводлар башка гәзитәләр берлән буталмаенча, үз исемемә җибәрелергә тиештер.

«Ил» гәзитәсенең нашире Мөхәммәдгаяз әл-Исхакый. «Москва, Мещеринское подворье, № 84. М.Гаязу Исхакову» дип язылырга тиештер.

## МӘСКӘҮ, 27 ГЫЙНВАР

25 гыйнварда имза ителгән падишаһ хәзрәтенең Дума вә Советны чакыру хакындагы Указы игълан ителде.

Падишаһ хәзрәтенең фәрманы буенча, Дума да, Совет та[1] 9 февральдә ачылырга тиештер. Думаның, Советның мәҗлесләре никадәргә сузылу хакында Указда бер мөддәттә күрсәтелмәгәндер. Шуның өчен гәзитәләрдә Дума бюджет карар өчен кыска вакытка гына чакырыла дигән хәбәрләр дөрест үк булып чыкмады.

Думаның чакырылуыннан элек баш министрлык урыныннан Горемыкинның истигъфа итеп[2], яңгы баш министр Штрюмер[3] җәнабларының куелуы Дума даирәсендә, рус әфкяре гомумиясендә шактый күп хәбәрләр тараткан иде. Кайберләре бу яңгы тәгаен дахили сәясәтемезнең тагы уңга таба агуына сәбәп булачак дигәннәр иде вә шуның өчен Думаның җыелуын да тагы кичектерелүен көткәннәр иде.

Хәзер бик зур сабырсызлык берлән Русиянең әфкяре гомумиясе яңгы баш министрның программасын көтеп торадыр. Яңгы баш министр Дума даирәләрендә һәм дә матбугатта уң түрә дип танылган булса да, ватанымызның хәле мөляхәзәгә алынып, Думадагы күпчелеккә каршы килмәс дип көтеләдер һәм дә соңгы вакытларда баш министрның үзенең бәгъзе хәрәкәтләре шуны аңлатадыр.

Гәзитәләрнең язуына күрә, Дума рәисе Родзянко Петроградка килгәч тә, Штрюмер җәнаблары аны зиярәт иткән вә үзенең Дума берлән хәрәкәт итәргә теләвен бәян иткән. Хәзердә Родзянко ашасыннан шул бергә хәрәкәтнең юлын тәгаенләү өчен баш министр зур фракцияләрнең лидерлары берлән дә мөзакәрәгә керешмәкче була икән. Баш министрның мөляхәзәләрен белдерер өчен, сәһшәнбә көн 26 гыйнварда Дума рәисенең кабинетында фракция яшьләренең киңәшләре булачактыр. Шул мәҗлестә Родзянко депутатларны Штрюмер җәнабларның фикере берлән таныштырачактыр. Шуннан соң һәр фракция, үзенең әгъзалары берлән киңәшләшеп, хаттел-хәрәкәтләре хакында мәгълүм караш ясалачактыр. Димәк, шул араларда Думаның бөтен фракцияләрендә зур, әһәмиятле мөзакәрәләр барачактыр.

Думадагы «тәрәккъыйпәрвәр блок» та хәятын күрсәтә башлаячактыр. Штрюмерның баш министрлыкка менүен сөенеп каршы алган уң депутатлар, «тәрәккъыйпәрвәр блок»ка каршы торыр өчен, «кара блок»[4] ясамакчы булалар вә Думада уң фракцияләрне берләштереп, хөкүмәткә арка таяначак булырга тырышалар. Ләкин Думаның иң зур күпчелеге «тәрәккъыйпәрвәр блок» ягында булганга, калганнар арасындагы социал-демократлар, трудовиклар, мөселманнар «кара блок»ка катышу ихтималлары юкка, «кара блок»ның зур көчкә малик булу ихтималы юктыр.

Шуның өчен Штрюмер җәнабларының «Дума берлән бергә хәрәкәт итәргә телим» дигән фикере хәятка татбикъ ителә алса, «тәрәккъыйпәрвәр блок»ка авышу булмый хәле юктыр.

Дума ачылуы якынлашкач, безнең мөселман фракциясенең хәле тагы авыраядыр. Бердән, үзенең сәяси программасын тәгаен итү мәсьәләсе алдына килеп басадыр. Икенчедән, безнең үземезгә гаид бик күп мәсьәләләремезне Дума минбәренә нинди тарызда алып чыгу эше мәйданга куелачактыр. Кирәк, хаттел-хәрәкәт тәгаен итү, Думадагы нинди фракцияләр берлән бергәрәк хәрәкәт итүне рәтләү, кыскасы гына, гади обывательлектән чыгып, сәяси тормыш берлән яши башлау, кирәк, кизүдәге мәсьәләләремезгә ничек итеп беренчелек, икенчелек, өченчелек номерлары сугу — һәммәсе бик зур эшләрдер. Шуның өчен, әлбәттә, фракциямезнең Котлыкай мирзаның мәктүбенә[5] илтифат ителеп, берникадәр җәмәгать хадиме җыелышса, уңгайрак булыр иде. Шул кешеләрнең киңәше берлән, бәлки, бюро ясау да мөмкин булыр иде. Бәлки, Дума янында җанлы бер оячык ясалып, үземезнең эшләремездә мөрәҗәгать итә беләчәк «милли адрес»ымыз булыр иде.

## МАТБУГАТ, ЯҺҮДЛӘР ВӘ БЕЗ

Петроградта чыга торган «Новое время» гәзитәсе бик күп еллардан бирле хөкүмәтнең ярым рәсми гәзитәсе булып килә иде. Гәзитә, элгәре бик кечкенәдән башланып, үсә-үсә генә, хәзерге Русиянең иң зур гәзитәләре арасына менеп җиткән иде. «Новое время» гәзитәсене тәэсис итүче, үстерүче ярлы бер мөхәррир Алексей Суворин иде[1]. Суворин, Русиянең интеллигенциясе гомумән хөкүмәткә инанмау рухында яшәп килгәндә вә, шул юлда язып, эшләп килгәндә, шулар арасыннан ук мәйданга чыккандыр. Шактый яхшы язучы, авыл учителе Суворин гәзитәнең койрыгын суга каршы түгел, су агымына таба борган да киткәндер.

Әлбәттә, ул бу эшне сөйләшмәенчә, уйлашмаенча гына түгел, шул вакыттагы хөкүмәт даирәләре берлән киңәшләшеп, сатулашып эшләгәндер.

Шул эш өчен матди ярдәм алганмы-юкмы — анысын, әлбәттә, без белмимез. Ләкин «Новое время»нең шуннан соң хөкүмәтнең химаясе астына керүен һәркем ачык белә. Шуннан соң хәзинәнең бөтен игъланнары «Новое время»гә бирелә башлаган (моннан килгән файда елына бер ике йөз мең сумнардан ким түгел) вә бөтен хөкүмәтнең рәсми даирәләре «Новое время» гәзитәсен ала башлаган.

Һәм дә хөкүмәтнең бөтен хәрәкәте хакында «Новое время»гә вакытында әйтелә килгәнгә, ул хөкүмәтнең унга, сулга барышын күрсәтә торган кыйбланамә булып алган. Шуның аркасында чит мәмләкәтләрдә «Новое время»нең кыйммәте арткан.

Әгәр Алексей Суворин шул эшләргә өстән генә караса, бу ярдәмнәр берлән генә әллә кая бара алмас иде. Ләкин Суворин, «Новое время»нең мөндәриҗәсе ягыннан да яхшы булуына бик зур әһәмият биреп, бик күп акча, гайрәт сарыф иткән.

Гәзитәгә файдага башка нәрсә китерми торган игълан эшен бик нигезле, йирле куеп, Петроградның бөтен кухаркаларын үз астына җыйган. Шуның берлән бергә «Новое время» фәнни, әдәби, гыйльми китаплар нәшер итәргә керешкән, зур бер нәшрият мәйданга китереп, зур китап складлары ясаган вә зур шәһәрләрнең һәммәсендә дә үзенең китап магазиннарын урынлаштырган, берничә төрле журналның да нәшерен үз өстенә алган. Менә шулай итеп, сынык каләм берлән, үткен баш берлән, сыгыла-бөгелә белә торган вөҗдан берлән эшкә керешкән Суворин Русиянең иң зур гәзитәсенең хакыйкый нашире, Русиянең беренче дәрәҗәдә зур вә бай китапханәсенең хуҗасы булып алган. Шулар аркасында Русиянең әфкяренә тәэсирен бик юксәлткән кебек, байлыгын да берничә миллионга җиткергән.

«Новое время»гә, кирәк, Русиядә, кирәк, Аурупада Русия хөкүмәтенең фикеренә хезмәт итә торган зур орган дигән фикерне утырткан.

Озын еллар язып килеп, «Новое время»нең үзен дә тәгаен иткән. Ул да — дахили сәясәттә «Әмереңез!» дип тору вә эчтәлеге бөтен начарлыкларны гайре русларга, хосусән яһүдиләргә аударып, эчтә «чын руслык» сәясәт йөртү, тышкы сәясәттә «аңлы националист» булып, Русиянең мәнфәгате өчен тырышу вә Русиянең олуглыгы, бөеклеге өчен кардәш славян халыкларын табигъ булган мәмләкәтләреннән аерып алып, Русиянең олуглыгына хезмәт иттерү.

Русиянең аңлы интеллигенциясе Русиянең истикъбале дахили эшләрне исляхта дип ышанган гөруһ булганга, алар һичбер вакытта да Суворин гәзитәсен яратмаганнар вә аңгарга бик шөбһәле күз берлән караганнар. Ләкин Суворин үзе кебек фикердәшләр табып алганга, гәзитәнең матди ягы яхшы куелганга, алар илтифат итмәенчә бара биргән.

«Новое время» гайре русларга хокук бирү мәсьәләсендә һәрвакытта тискәре торган. Хосусән яһүд мәсьәләсендә һичбер вакыт Русиянең яхшы күңелләре берлән бергә булмаган.

Менә шул гәзитә, менә шул китапханәләр хуҗасы Суворин үләр алдыннан, гәзитәсе, журналлары, китап эше үзе куйган юлдан барсын өчен, «Новое время» дигән бер товарищество ясый. Шундагы гәзитәнең кыйммәтен сигез йөз пайга бүлеп, һәр пае бишәр мең сумнан хисаплана. Аларны бергә язышкан, хезмәт иткәннәрнең күбесенә бушлай бирә. Бик күбесен угыллары, кызлары, туруннарына яздыра. Ләкин алай гына эш бетмәгәнгә, гәзитәне карт язучылардан, карт эшлеклеләрдән тотып бер совет ясый да шуңгарга идарәне тапшыра, үзе үлә.

Гәзитә дәвам итә. Китап эше дә бара. Ул гына түгел, Петроградта «Вечерное время» дигән кичке гәзитә дә чыгарыла башлый.

Менә шулай эш үз юлында бара кебек торганда, үткән елның декабрь ахырларында «Новое время»нең совет мәҗлесендә зур скандал чыга. Суворинның үзе барда аерылып чыккан углы Алексей Суворин («Русь» гәзитәсене тәэсис иткән вә шунда мөселман отделе дә алып барган иде)[2], совет мәҗлесенә килеп, зур скандал күтәрә. Луарвир берлән шундагы көзге, тәрәзәләрне ватып, политсә китерергә мәҗбүр итә. Шулай итеп, «скандал» дигән мәсьәләне мәйданга куймакчы була. Ләкин тагы агай-эне арасында ызгышу төсендә генә гәзитәләргә чыга.

Хәзер менә Алексей Суворин шул эш хакында махсус бер китап язып чыгарган. Аның китабына караганда, карт Суворин угыллары — «Новое время»нең редакторы Михаил, «Вечерное время»нең

редакторы Борис — яһүд банкирларына гәзитәләрен сатканнар. Алар 15 нче елның гыйнварында «Новое время»нең бөтен эшен яһүд банкирлары берлән үзләреннән мөрәккәб малия һәйәтенә 16 нчы елга кадәр тапшырырга мокавәлә язышканнар. Шул мокавәлә буенча яһүд банкирларының кешеләре Домкин советка әгъза итеп сайланган. Шул мокавәлә буенча «Новое время»нең идарәсендә рәислек яһүд банкирларының вәкилләренә бирелергә тиеш ителгән вә шул мокавәлә буенча Суворин балаларына бөтен пайщиклар мәҗлесендә ярты табыш бирелергә вәгъдә ителгән, шул мокавәлә буенча бөтен эшне үз кулларына алыр өчен яһүд банкирлары «Новое время»нең пайларын сатып алырга тотынганнар. 16 нчы ел башына кадәр үзләре тарафында күпчелек ясар өчен (дүрт йөздән артык пай лязем) алар Михаил Сувориннан 53 пай, Борис Сувориннан 73 паен алганнар вә, башкалардан берәм-сәрәм җыеп, банкирлар кулына 232 пайны керткәннәр! Шуннан соң төрле юллар берлән куркытып, «Новое время» бөлә дигән хәбәр таратып, Суворинның бала-чагасыннан пайлар алырга маташканнар. Суворинның кызы Анастасия Суворинаның 89 паен сатып алмаенча, шул пайдан килә торган табыш хакын гына һәр елны 36 мең тәңкә биреп тору вәгъдәсе берлән үзләренә алганнар. Михаилга редакторлыгы өчен жалуниесен арттырып, елына 48 мең сумга, Борисныкын 30 мең сумга үстергәннәр. Менә шулай «Новое время»не акрынлап яһүдләр үз кулларына төшерергә бөтен планын корганнар.

---

Шул эшкә разый булмаенча, Алексей Суворин иң әүвәл кардәшләренә үгет биргән, сүз аңлата алмагач, ахырдан зур тавыш чыгарып, рус әфкяре гомумиясенең дикъкатен җәлеп итмәкче вә «Новое время»нең дустларын уятмакчы булган.

Шул ният берлән скандал ясаган, шул ният берлән менә аерым китап чыгарып тараткан. Шул ният берлән агай-энесе берлән судлашмакчы була.

Шул ният берлән рус әфкяре гомумиясенә каршы: «Әфәнделәр, мин яһүд милләтенә дошман түгел, мин шул гайре рус милләтләренең бер хокуклы булуы өчен тырыша торган кеше, ләкин Петроградта бердәнбер рус гәзитәсе булган «Новое время» атамның корган юлыннан чыгып, яһүдиләрнең барабаны астында биюенә разый түгел. Мин яһүд банкирларының үз фикерләрен рус әфкяре гомумиясе иттереп күрсәтергә теләүләренә разый түгел. Бу мәмләкәтнең мәнфәгате ягыннан да зарарлы. «Новое время»не коткарыңыз! Әле дә Петроградтагы «Речь», «Дон», «Биржевые ведомости», «Голос» гәзитәләре — яһүд гәзитәләредер. «Новое время» генә рус гәзитәсе булып калсын», — ди.

Бу мәсьәләдә Алексей Суворин хаклымы, түгелме? Анысында безнең эшемез юк. Ләкин «Новое время»нең яһүд банкирлары кулына төшүе дөрест булса гаҗәпкә калмаслык, яһүдләрнең уңганлыгына искитмәслек түгелдер.

Кайдан боларның гайрәтләре җитә, кайдан бу кадәр акча табалар?

«Новое время»не кулга төшерер өчен берничә миллион акча кирәктер, «Речь», «Дон» вә башкаларны алып барыр өчен тагы йөз меңнәр кирәктер.

Әле аның берлән генә дә бетми бит. Җәнүбтәге иң зур гәзитә «Киевская мысль», «Одессовские новости» гәзитәләре дә аларныкы бит. Һәртөрле зуррак шәһәрләрдәге бик күп төрле гәзитәләр дә, журналлар да алар кулы берлән, алар акчасы берлән чыгарыла бит!

Бу акча кайдан табыла? Ничек шул акча кызганылмый? Әллә бик күп файда итеп зур табышлар алалармы?

Хәер!

Бу гәзитәләрнең барысы да булмаса да, иң күбесе әле акча ашый. Иң күбесе әле һәр елны яһүд байларының йөзәр меңен, бәлки, миллионын кимереп тора. Ләкин гәзитәләр ябылмый, бара, көчәя, зурая.

Соң, күп табыш та китермәгәч, акчаны шулкадәр сөя торган яһүд сатучысы ник соң шулкадәр акча сарыф итә?.. Ул безнең татар бае кадәр дә икътисадны белмимени?..

Мәсьәләнең иң нечкә йире менә шунда.

Яһүд сәүдәгәре ул икегә өч файда алып, өч тиен янда калдырырга эшен кормаган. Яһүд сәүдәгәре бу көн кесәдә калган биш тиенне файдага санауга эшне утыртмаган. Аның күз карашы киң. Ул бу көн эш иткәндә, иртәгене генә түгел, моннан ун ел алдагыны күрә. Ул хәзер Мәскәүдә эш иткәндә, бөтен Русиядәге хәлне күздән кичерә, ул үзе генә әйбер сатканда, яһүд булудан килгән уңгайсызлыгын уйлаганда, Русиядәге бөтен яһүднең хәлен күз алдына китерә.

Ул киң итеп сәүдәгә карый. Шуның Русиядә алга китүенә киртә булып торган яһүднең хокуксызлыгына[3] үзенең моның Исаакның хокуксызлыгы гына дип карамаенча, үзе өчен генә тырышмый, бөтен яһүд өстеннән хокуксызлыкны бетерер өчен тырыша, бергә тырыша. Аерым-аерым расход тотканча, бергәләп тота. Бергәләп Русиянең әфкяре гомумиясен үз файдасына бора. Русиянең матбугаты ашасыннан

«яһүд мәсьәләсе», «яһүд мәсьәләсе» дип, дүрт-биш миллионлы халыкның эшен Русиядәге иң әһәмиятле мәсьәлә, Русиянең хәят-мәмат мәсьәләсе итеп куя. Үзе куя алмаса, рус мөхәррирләреннән куйдыра. Акчага сатылганын акчага ала — менә сиңа 30 мең, менә сиңа 48 мең. Шул матбугат аркасында хокук мәсьәләсен генә хәл итми, үзенең банкирларына кирәкле әллә никадәр сәүдә эшләрен үткәрә. Мәслихәт иттереп язып, тимер юлына имтияз ала. Бик кирәкле иттереп күрсәтеп, бер мәмләкәт мокавәләләрен үзгәртә.

Эшләтә, үз мәнфәгатенә һәммә көчне эшләтә. Бейлис мәсьәләсен[4] генә хәтерләңез! Нишләделәр? Бөтен Русия гәзитәләре генә түгел, бөтен дөнья гәзитәләре айлар буе шуны «иң әһәмиятле мәсьәлә» дип язып тормадымы? Болар һәммәсе дә һәр йирдә яһүд кулы, яһүд акчасы барга эшләндеме? Инде хәзер безнең хәлемезне алыңыз!

Русиядә руслардан соң күплектә беренче милләт.

Русиядә хокуклар җитмәү, гыйлем, мәгариф юклыкта иң беренче милләт.

Ләкин безнең хакта бер айлык бөтен Русия гәзитәсен актарып чыксаңыз, бернәрсә табарсызмы?

Юк.

Ник?

Рус матбугаты безгә әһәмият бирми.

Ник бирми?

Чөнки бирдерә белмимез!

Чөнки хокукымызны саклар өчен гайрәт кирәк булган чакта, тавык йөрәк булып качамыз.

Хокукымызны мөхафәзә итәр өчен акча кирәк булганда, миллионерларымыз хәерче кебек мескин кыяфәт аламыз.

Шуның өчен Русиядә элгәре дә, хәзер дә яһүд халкы хакында әллә никадәр язылса, шулар файдасы өчен әллә никадәр көчләр, гыйльми, фәнни затлар хезмәт итсә, алар шул хезмәткә лаеклар. Чөнки аларга ул хезмәтчеләрне эшләтер өчен һәммәсе әллә никадәр мал, көч сарыф иткәннәр, итәчәкләр. Хәзерге хәлдә безнең хакымызда бер сәяси ир, бер журналист, бер фән галиме кыл кыймылдатмаса, безнең шанымызга муафикъ бер эш эшли! Чөнки без аның ватык каләмен генә алырлык та йитәкчелек итмәгәнмез, итмәячәкмез!

Яһүд сәүдәгәре бөтен гомерен яһүд галәйһенә хезмәт иткән миллионнар сум тора торган «Новое время»не сатып ала.

Күрәләтә зарар итәчәк, миллионнар зарар итәчәк эшкә катыша. Башына бәла ала.

Без киң Русиянең бөтенләендә, ике пайтәхетнең берсендә иң кирәкле мәсьәләләремезне хәбәр итеп кенә язарлык бер тылмач тота алмыймыз.

Чөнки яһүд акчаның кадерен белми, исрафчан, «ахмак».

Чөнки без — икмәкнең кадагы ничә тиен икәнен, исраф хәрам икәнен ана сөте берлән сизгән «гакыллы» баш!

## «ЙОЛДЫЗ»НЫҢ «МИЛЛИЛЕГЕ»

«Йолдыз» гәзитәсенең башы Һади әфәнде Максуди «Йолдыз»ның ун еллык юбилейсы мөнәсәбәте берлән язган мәкаләмә[1] «Таңчы»га җавап» гонванында мәкалә язган[2]. Һади әфәнденең үзен-үзе аклар, «Йолдыз»ны күккә күтәрер өчен язган бу мәкаләсе, укучылар алдында минем дәгъва иткән «Йолдыз»ның мәсләксезлеген, мораилеген, ваклыгын исбат итәр өчен аяклы дәлил булган кебек, тагы минем әйтергә онытып калдырган «Йолдыз»ның бер сыйфаты барлыгын да ачып бирәдер. Ул да — алдакчылыктыр.

Һади әфәнде үз кулы берлән язган мәкаләсендә «Йолдыз»да яшеренеп калган бер начар сыйфатын менә ничек иттереп ача: «Таң» вә «Тавыш» заманнарында[3] болар «Йолдыз»га милли дип бәйләнә иделәр. Алар ул вакытта мода йиле белән искәнлекләреннән, миллияткә бик каршы иделәр».

Иң әүвәл шуны әйтик: мин үзем, минем иптәшләрем һичбер вакыт «Йолдыз»ны милли гәзитә дигәнемез юк. Һичбер вакытта «Йолдыз»ның милли гаяга хезмәт итә торган бер орган булуына ышанганымыз юк. Сүзләремездә, фикер йөртүемездә «милли» дигән сүзне «Йолдыз» хакында истигъмаль иткәнемез юк, итмәячәкмез. Итсәк, «милли хулиганнар», «милли кяферләр» дигән сүзләрдәге кебек татарның үз эченнән туган мәгънәсендә истигъмаль итәмез, итәчәкмез. Шуның өчен «Таң», «Тавыш» вакытларында да «Йолдыз»ны сөймәвемез, көлүемез булса, ул да — «Йолдыз»ның милли гаягә хезмәт итүеннән түгел, билгакес, «Йолдыз»ның самимиятьсезлекеннән, мәсләксезлекеннән көлү иде. Ул да һичбер төрле Һади вә Мөтәһади әфәнделәргә ачудан, кәеф китүдән түгел, мәсләки аермадан, татар хәрәкәтенең яшь вакытында шундый мәсләксез — җил кайдан килде, шунда ава торган органнарның зарарлылыгын милли аң берлән сизүемездән иде.

Икенче Һади әфәнденең (хәзер «Ил» берлән «Сүз» хакында) һәрвакытта әдәпсез рәвештә «бер-ике гәзитәгә бәйләнә торалар» дигән сүзе башыннан ахырына кадәр хатадыр. «Ил» гәзитәсенең ике ел дәвамында, «Сүз»нең беренче елында шул ике гәзитәнең дә һичбер номерасында һичбер гәзитә вә журналга бәйләнү булмады. Шул өч ел эчендә бу гәзитәләр чыгып килә торган милли матбугатымызның һичберсе белән кычкырышмады.

«Йолдыз» хакында язылган мәкаләдә дә һичбер төрле кычкырышу булмаенча, «Йолдыз»ның урынын билгеләүдер вә шул «Йолдыз»га үземезнең мәсләк ягыннан биргән тамгамызны сугудыр.

Билгакес, менә шул өч ел эчендә «Йолдыз» «Вакыт»[4] берлән талашты, шул өч ел эчендә «Йолдыз» «Идел»[5] берлән сугышты, менә шул өч ел эчендә «Йолдыз» «Тәрҗеман»[6] берлән кычкырышты, менә шул өч ел эчендә «Йолдыз» «Тормыш»[7] берлән эләгеште.

Шуның өчен, кирәк, безнең элгәреге гәзитәләремез хакында, кирәк, хәзергеләре хакында «әдәпсезчә бәйләнәләр» дигән Һади әфәнденең бу сүзе һичбер төрле әсаска бина ителмәгән, ялганларга өйрәнгән бер гәзитәнең кизүдәге ялганы гынадыр.

Һади әфәнде мәкаләсендә: «Гаяз әфәнде, «Йолдыз», вак интригалар, вак доносլар берлән мәшгуль булды, — ди. — Моңгар дәлил ни икән?» — дип сөаль бирә вә миннән җавап сорый.

Һади әфәнденең дәрте почмаклансын, языйм:

7 нче елда Казанда «Тавыш» дигән гәзитә чыга иде. Шул гәзитәнең нашире Хөсәен әфәнде Әбүзәров иде, редакторы Габдулла әфәнде Биккинин иде. Редактор авырый башлагач, идарә редактор алыштыру хакында законнар юлынча гариза биргән иде. Ул кәгазь әйләнеп чыкканчы, редактор вафат иткән. Хөсәен әфәнде үзе өйдә булмаганга, идарәдәге әфәнделәр, редактор үлгәнне белмәенчә, «Тавыш»ның номерын әүвәлге редактор имзасы берлән чыгарганнар.

Икенче көнне «Йолдыз» гәзитәсендә (ул вакытта гәзитә атналык кына, Һади әфәнде үзе генә яза иде) «Тавыш» гәзитәсенең мөхәррире үлгәннең соңында да гәзитә чыгаруында дәвам итә, фәлән көнне вафат иткән иде, гәзитәнең номерасы фәлән көнне чыкты» дип язып чыгарды[8]. Шуннан соң «Тавыш» гәзитәсен яптылар. Идарәсен тентеделәр. Шул номерны чыгаручыны эзләп, идарәдәге хезмәтчеләрне тотып алып киттеләр. Аның берлән эш белмәгәнгә, гәзитәнең нашире Хөсәен әфәнде Әбүзәров берлән гәзитә басыла торган Кәримовлар матбагасының мөдирен судка бирделәр.

Суд Хөсәен әфәндегә дә, мөдир әфәндегә дә берничә ел төрмә яисә ссылка була торган статья буенча озак эшне йөреттеләр.

Кәримовлар типографиясенең мөдире вафат булып[9] котылып калды.

Хөсәен әфәнде Әбүзәров бик зур мәшәкатьләр берлән үзенең шул вакытта Казанда булмаганлыгын исбат итә алды.

Унынчы елда булган аның судебный палатада каралган эшендә судебный палата Хөсәен әфәндене гаепсез тапты.

Менә бу бер донос!

«Йолдыз» казып чыгарган бер донос.

Икенче, Петербургта чыга торган «Ил» гәзитәсендә «Татарга» дигән бер шигырь басылды. Шул шигырь өчен «Ил»нең 7 нче номерасы конфисковать ителде. Мөхәррир сыйфаты берлән мин судка биреледем. Шигырьдә «Мәннаф» дигән имза булса да, ул кешенең кем икәнлекен әйтеп, аны да судка тарттыру яисә аның кемлеге хакында мәгълүмат бирмәенчә, бөтен мәсъүлиятне үз өстемә генә алу минем ихтыярымда иде. Мин икенчесен кабул иттем.

«Гәзитәдә мәсъүл мөхәррир — мин, шигырь хакындагы мәсъүлият миңа төшә, «Мәннаф» дигән псевдонимны белмим», — дидем.

Шулай итеп, 129 нчы статья буенча тикшерү минем хакымда гына башланды.

Шул чакта «Йолдыз» «Мәннаф дигән кеше Троицк шәһәрендә бүрекчедер, фәләндер-фәләндер» дип бер нәрсә язып чыгарды. Гөнаһсыз кеше хакында шөбһә уятып, аның гаеплелеге, судка бирелүе хакында тикшерү китте.

Менә бу ике. Икенче донос.

«Йолдыз»ның өченче доносы хакында, мәгаттәәссеф, хәзергә әйтә алмыйм.

Ләкин анысындагы золым беренче, икенчеләренә караганда тагы зур, тагы күбрәк даирәгә иде.

Иншалла, бу цифрлар әле моның берлән генә бетми торгандыр.

Ләкин милли матбугатның шул авыр көннәрендә ителгән доносլар, шул милли җинаятьләр дә «Йолдыз»ның никадәр «милли орган» икәнен күрсәтергә дәлилле булса кирәк.

«Йолдыз»ның үзенең генә бөтен татар гәзитәләре арасында, ялгызы гына аерылып, карагруһ гәзитәләргә махсус почтовой тариф берлән җибәрелүе хакындагы маддәсе, Һади әфәнде сылап-сыйпап әйткәнчә, кечкенә түгелдер.

Шул тарифка ни өчен Мәскәүнең «Русские ведомости»[10], «Русское слово»[11], Петербургның «Речь»[12], «Дон»[13] вә бүтән тәрәкъкыйпәрвәр гәзитәләре керә алмаган да, ничек иттереп «Земщина»[14], «Колокол», «Русское Знамя»[15] гәзитәләре генә керә алды икән?

Моның бер сәбәбе бар түгелме?

Әлбәттә, бар.

Менә шул сәбәп буенча утыз елдан артык дәвам итә торган «Тәрҗеман», иң күп тарала торган «Вакыт», «Кояш», «Тормыш», «Ил», «Сүз» гәзитәләре вә Кавказның бөтен мөселман гәзитәләре шул тарифка керә алмаганда, Һади әфәнденең «Йолдыз»ы гына ничек кергән икән?

Менә моның сәбәпләре «Йолдыз»ның «миллияте» берлән карагруһ партияләрнең гайре русларга карашлары арасында берлек барлыгыннан түгелме?

Иң соңыннан «Йолдыз»ның ун еллык мәҗлесендәге бер-ике ел элек Казанда булган Камали бутышник юбилейсыннан алынып ясалган программасы вә шундагы миссионер Җузи әфәнденең[16] «Йолдыз»ны, Һади әфәндене мактавы «Йолдыз»ның нәрсә икәнен сукырга да күрсәтә торган дәлилләр түгелме?

Менә «Йолдыз»ның шундый «милли хезмәтләр»ен без элгәредән белеп торганга, ул хезмәтләрнең Казанда йитештергән хулиганлык йимешләрен күреп торганга, киләчәктә Аллаһы Тәгалә хәзрәтләре «Йолдыз»ның «шундый хезмәтләре»ннән бөтен әһле исламны сакласын иде дип, кулымызны күтәрдек.

Фикеремезнең аңлашылуы-аңлашылмавы — халкымызның аңыннандыр.

Догабызның кабул булуы-булмавы — Алланың үзеннәндер.

## МӨСЕЛМАН ФРАКЦИЯСЕНДӘ КИҢӘШ МӘҖЛЕСЕ

Вакытның әһәмиятлелеген сизеп, Думадагы мөселман фракциямезнең[1] хәле авырлыгын хисапка алып, фракциямез рәисе Котлыкай мирзаның[2] дәгъвәтенә җитдирәк карау көтелергә тиеш иде. Тормышымызның хәленең теләсә ничек баруы, теләсә кая таба агуына сәерче булып карап тора алмаган даирәләрнең чынлап катышуы, мәгънәви мәсьүлиять хис итеп катышуы тиешле иде. Ләкин әллә ни булды, без аңламаган сәбәпләрдән киңәш мәҗлесләре вакытның әһәмиятенә мөнасиб дәрәҗәдә зур була алмадылар.

Сәбәпләре, әлбәттә, күптер. Бик күп кешеләр «Юллар начар булды. Киңәш уңгайсыз вакытка тугры килде, киләм дисәң дә килеп булмады, китәр өчен дә уңгайсызлыгы куркытты», — дип җаваплар язалар.

Бик күбесе: «Вакытым булмады, бушрак вакытта булса, бик барыр идек», — диләр. Кайберләре: «Рөхсәт алынып ясалса, мәслихәт булмас идеме?» — дигән сөальләр бирәләр. Иң зур бер кыйсеме: «Без сезнең карарга разый», — дип, алдан ук кушылып куялар.

Бу гөруһ халыкның үз-үзен гомум эштән читкә алып калдырыр өчен китергән дәлилләре, үзләре алдында бик нык булса да, гомумноктаи нәзардан караганда, һичбер төрле кыйммәтне хаиз түгелләрдер. Иң әүвәл юлның авырлыгы никадәр дөрест булса да, шул юл берлән бит Петербургка көненә берничә дистә мең кешеләр килеп, төрле халык җәмгыятьләренә берничә йөз кешеләр өзелмәенчә вилаятьләрдән агып торалар.

Безнең киңәшкә килгән затларымызга да аерым-аерым поездлар бирелмәде, кысылды-пысылды гына килделәр. Мәҗлескә әһәмият биргәннәре дә, вакытлары бик күпкә нишләргә белмәенчә аптырап калганнан, үз шәһәрләрендәге гайбәттән, вак-төяк эшләрдән вакытлары буш калгач, шул бушлыкны киңәш берлән тутырыр өчен генә ашыкмады.

Рөхсәт алыну-алынмавы, уңгайсызлыгы да һәммә кеше өчен бер дәрәҗәдер. Бөтен фракцияләр, бөтен милли организацияләр шундый киңәшләрне үзләре теләгән вакытта ясап килүләре мәгълүм булганга, хөкүмәт тарафыннан «Ясамагыз!» дигән әмер булмаганда, рөхсәт алу эше «гакыллы баш» кадәр зур түгелдер.

«Сезнең карарыңызга разый» дип читтә тору, читкә кысылу, посу, җәмәгать эше ягыннан караганда бик күңелсез вакыйгадыр һәм дә киләчәккә өмидле булган даирәләрдән чыкса, зур хатадыр. Бездә әле җәмгыять эшләрен эшләүчеләр белән шул эштә мәнфәгате булмаган ике бүлек халык берсе «сез», берсе «без» булып аерылганы юк һәм аерылмаска тиештер. Җәмәгать эшләренең алга китүе, халык файдасына таба тугры баруы өчен һәрбер җәмәгать эшенә һәр гөруһ халыкның «үз эшем», «үз эшемез», «безнең эшемез» дип каравы вә шул эшкә, вакыты буш булганда гына түгел, һәрвакытта, һәр чакта уңгайлы-уңгайсыз һәр хәлдә катышуы ляземдер. Үз эше иттереп эшләве, матди вә мәгънәви көчен аямаенча эшләве фарыздыр.

Хосусән хәзерге вакытта Русиянең алдында бик зур мәсьәләләр торганда, Русиянең хәятында булачак бөтен үзгәрешләр безгә дә һичбер төрле тәэсире булмаенча калу ихтималы булмаганда, шул эштә безгә дә,

үземезнең көчемезне бер ноктагарак җыеп, үземезнең теләгемез буенча катышырга, рәтләү, төзәтүгә катышырга тиештер.

Киңәш мәҗлесләре, халкымызның шул мәсьәләне аңлап җитмәгәнме дим, шул киңәшләрдән зур өмид көтмәгәнме, күрсәтте: халык бик салкын канлылык берлән каршы алды. Киңәшләрнең көне мәгълүм булса да, әүвәлге мәҗлесләргә Уфа, Мәскәү вәкилләренә башка беркем дә килә алмады. Икенче көннәрдә Казаннан бер зат килде. Берәр атна, ун көн көн үткәч, Троицкидан һәм кыргыз кардәшләремездән берничә затлар тәшриф иттеләр. Шулай итеп, мәҗлесләр, хатын-кыз ашы кебек, башы да мәгълүм түгел, ахыры да мәгълүм түгел бер хәл алды. Беттемелеге дә, бетмәдемелеге дә күренми торган сузылган боламык булды да калды. Киңәшләр арасында матбугат әһелен күрер өчен зур әһәмият бирелгән булса да, «Тормыш» гәзитәсеннән Закир әфәнде Кадыйри[3], «Сүз»дән миңа башка беркем дә килмәде. Казан гәзитәләре үзләренең Петроград мөхбирләренә вәкаләт кәгазьләрен йибәрсәләр дә, матбугатның урыны сыеклыгын бу гына тутыра алмады. «Вакыт»тан беркем дә булмады. Кырым, Кавказ гәзитәләреннән дә бер кеше дә килмәде, китмәде.

Ләкин фракциянең кузгаткан мәсьәләләре бик әһәмиятле булган кебек, киләчәк кешеләрнең үзләре кузгатачак мәсьәләләре өчен киң бер юл калдырылган иде.

Халык күп булмау аркасында ул төр мәсьәләләр әлегә бик аз ачылды. Фракциянең куюы буенча Думадагы баш министрның декларациясенә фракциянең җавабы мөзакәрә ителде вә шул декларациянең әсаслары хакында сүзләр алышынды, киңәшләр ителде.

Икенче булып фракциянең блок белән мөнәсәбәте мәсьәләсе куелды. Шуңгардан килеп чыккан фракциянең Думадагы башка гайре рус милләтләренең вәкилләре берлән мөнәсәбәте каралды.

Өченче, Думадагы мөселман фракцияләрнең сәяси платформасы, сәяси урыны, мәйданы мөзакәрәгә куелды.

Дүртенче, фракциядә бюроның кирәклеге вә аның даими булу-булмавы вә бюро ясалуы сөйләнелде. Бу маддәләрнең берсе-берсе генә дә бик зур милли — иҗтимагый мәсьәләләремезгә барып төртелгәнгә, әлбәттә, бик күп сүзләр, җитди мөзакәрәләр уятылды, карарлар чыгарылды.

Шул мөзакәрә һәм карарлар белән таныштыру бик күп вакыт алачак булганга, аларны киләчәк мәкаләләргә калдырамыз, тоз табар идек тә, коймак пешерер өчен утын гына табарга калыр иде дигән фәлсәфәне авыл куштаны кебек сатты. Халыкны ялыктырды.

## МӨСЕЛМАН ФРАКЦИЯСЕНДӘ КИҢӘШ МӘҖЛЕСЛӘРЕ

Беренче мәҗлес 3 февральдә булды. Фракциянең рәисе Котлыкай мирза кыска гына нотык берлән киңәшкә куелачак мәсьәләләрне санап чыкты вә беренче иттереп хөкүмәтнең декларациясенә[1] җавап уларак, мөселман фракциясенең бәяннамәсен мөзакәрәгә кую матлублыгын аңлатты.

Мәҗлестә депутатларымыздан Котлыкай мирза Тәфкилев, Ибнеәмин әфәнде Әхтәмов, Йосыф әфәнде Җәгъфәрев, Гайса мирза Еникиевләр хазир иделәр.

Депутатлар арасында Гайса мирза, мөзакәрә хакында әллә нәрсә әйтергә теләсә дә вә шактый күп вакытны алса да, ни фикер бәян иткәне мәгълүм булмады.

Хазирун шул хакта кыска-кыска гына сөйләп декларациягә җавапны карарга тотындылар. Ибнеәмин әфәнде докладчик сыйфаты берлән хазирунны бәяннамәнең нигезе берлән таныштырды. Шуннан соң нинди мәсьәләләр өстәлергә тиешлеге күтәрелде. Читтән килгән затлар да, халкымызның йөдәгән, йончыган мәсьәләләре бик күп булганга, мәҗлес бик сузылды. Декларациягә кертер өчен төзелгән маддәләр бик озайды. Шуннан соң фракция әһеле [тарафыннан] мөселман фракциясенең бу бәяннамәсе мөселманнарның теләүләренең мәтене генә булырга тиеш, аларга шәрех иттереп һәр министрның сметасы каралганда, аерым нотыклар да сөйләнерләр дә диелде. Шуннан соң мәтенгә үзәк тутыру китте. Иң әүвәл мөфтилек мәсьәләсе куелды.

Халкымызның иң зур күпчелегенә каршы килеп, халкымыз алдында сәлби тарафтан гына танылган кешенең мөфти иттереп куелуы хөкүмәтнең «халык берлән хөкүмәт берләшергә тиеш» дигән лозунгысына хилаф, шуның өчен мөфти тәгаен иттерүдә эшләнелгән хөкүмәтне иһмаль итүләр, алдаулар дахилия назыйрының сметасыны карауга калдырып торылса да, шул хакта протестымызны әйтү лязем, диелде һәм, шул фикер кабул ителеп, Баязидов[2] вә компаниясенең эшләгән эшләренең документлары фракциягә тапшырылды.

Икенче мәсьәлә уларак, Уфа губернасындагы епископ Андрейның[3] вә башка миссионерларның мөселманнарны тәхкыйрь итә торган мәсьәләләре, лазаретларда мөселман солдатларга татарча басылган

Инҗил таратулар сөйләнелде, Петроградның берничә лазаретыннан алынган татарча Инҗилләр, Мәскәүнең бәгъзе бер лазаретларында мөселман солдатлардан киртә сикертер өчен эшләнгән эшләр хакындагы хатлар, материаллар каралды. Болар хакында кыска гына әйтеп алып, озын иттереп сөйләү сугыш назыйрының сметасы каралганчыга калдырылды.

Аннан соң мәсьәлә милли тормышымыздагы уңгайсызлыкларга күчте.

Болар арасында, әлбәттә, беренче урынны земстволарда мөселман халкын агарту эшенә хөкүмәт түрәләренең аяк чалулары иң зур мәсьәлә булды. Орск земствосының тәгаен иткән акчасын Оренбург губернаторының тасдыйк итмәве сөйләнелде. Аңгарга Пермь губернасындагы земство акчасыннан мөселманнарның милли эшләренә губернаторның каршы килүе кушылды. Вятка губернаторының берничә елдан бирле мөселманнарны агарту өчен земствоның аз гына булса да ярдәм итәргә теләвенә разый булмавы сөйләнелде. Ахырдан Вятка земствосының мөселманнарны агартыр өчен дигән суманы тасдыйк итмәве, законлы түгел дип губернатор өстеннән Сенатка биргән жалобасы нәтиҗәсез калдырылуы изах ителде. Хазирунның фикеренчә, боларның һәммәсе дә сәхраи кәбирдә суга сусаган юлчы кебек, Русиянең уртасында гыйлемгә сусаган мөселман халкына үзләренең земствога түләгән акчаларыннан йөздән берен генә дә үз укуларына тотылырга рөхсәт ителмәве хәзерге көндә мөселманнар берлән хөкүмәт арасында дустлык югалуга сәбәп булачак итеп табылды вә, шуның хакында декларациягә кертергә мәслихәт табылып, гомумән, бу мәсьәләгә әһәмият бирергә тиешле табылды. Аннан соң төрле йирдәге төрле йирле түрәләрнең мөселман эшләренә тискәре караулары сөйләнелде. Әстерхандагы мөселманнарның бөтен гыйльми, мәдәни эшләре фәхешханә сахибе берәүнең монополиясенә бирелгәнлеге ачылды вә шул хактагы кирәкле материаллар берлән Думада сөйләү лязем табылды.

Декларация мәсьәләсе мөзакәрә кылынганда, читкә китеп, бик күп сүз сөйләнде, мөгаллимнәремез, мөгаллимәләремезнең хокуксызлыгы мәсьәләсе уянды. Фронтта җитәрлек дәрәҗәдә гаскәри имамнарның булмавы сөйләнде.

Шуларның һәммәсен алып, кыска гына мәтен тарызында декларация хәзерләүне фракция әгъзалары өстләренә алдылар вә, тәмам булгач, бер мәртәбә укып чыгарга вәгъдә иттеләр. (Думада Тәфкилев тарафыннан укылган мәгълүм декларация.) Ләкин монда сөйләнгән сүзләр, эшләнгән теләкләр һәммәсе дә мәмләкәтнең дахили эшләренә генә гаид булганга, хариҗи сәясәт хакында берәр сүз әйтү лязем түгелме дигән бер мәсьәлә туды. Моңганчыга кадәр фракциямез тормышында һичбер мәртәбә дә сәясәт хакында сүз сөйләнмәгәнгә, бу яңгы мәсьәлә тагы бик күп фикер, уй уятты. Мөселманнарның бара торган сәяси юллары оппозиция берлән бергә булганга, хариҗи сәясәт хакында аерым сүз сөйләүнең лөзүме күрелмәде. Фәкать мөселманнарның дини, милли хисләрен рәнҗетерлек сүзләр Дума минбәреннән әйтелсә, җавапсыз калдырмау тиешлелек кенә әйтелеп үтте.

Декларациянең ахыры, бөтен мөселманның теләге дип, дахили сәясәттә «тәрәккъыйпәрвәр блок»ның[4] теләве берлән бергә булуга башка, мөселманнар үзләренең генә теләге иттереп, дин вә миллият аермасыннан килгән бөтен кысынкылыкларны бетерергә, бер диннән икенче дингә күчү хакында закон эшләп чыгарырга, кыргызлар, Төркестанның бөтен мөселманнарының Дума сайлау хакларыны бетергән, Идел буе вә Кавказ мөселманнарының шул сайлау хакларын бик күп киметкән 3 июнь правиласын[5] үзгәртергә дигән теләкләре берлән бетерелде.

Мәҗлестә Уфа депутаты Байтирәков[6], Самар депутаты Миңлегалиев[7], Дагъстан депутаты Далгат[8] әфәнделәр юк иделәр. Мәҗлес бик озакка тартылып соң бетте.

«Тәрәккъыйпәрвәр блок»ка мөнәсәбәт хакындагы мөзакәрә киләсе мәҗлескә калдырылды.

---

2 нче мәҗлеснең беренче мәсьәләсе мөселман фракциясенең «тәрәккъыйпәрвәр блок»ка мөнәсәбәте булды. Һәркемгә мәгълүм, үткән сессиядә Думаның кадетлардан башлап националистларга кадәр җыелган алты фракциясе, бер теләү тирәсендә берләшеп, вакытлы гына булса да бер оешу, бер иттифак ясаганнар иде.

Бу иттифак тәмамән берлек, берләшү булмаганга, һәммә фракция вакытның бик әһәмиятлелеген сизеп, үзләренең булдырырга тиеш тапкан бик күп мәсьәләләрен артка калдырып торырга разыйлашканнар иде. Алты фракциянең дә, хәзерге тарихи вакытта кичектерелергә ярамый торган дип, алтысы да ышанган ун маддә тирәсендә оешканнар вә, шулай итеп, Думада бик зур күпчелек ясап, Думаның бөтен эшен үз кулына алганнар иде. Бу алты фракциянең оешуы хәзер дә «тәрәккъыйпәрвәр блок» дип йөртеләдер. Менә шул «тәрәккъыйпәрвәр блок»ның берләшкән мөһим нокталарыннан берсе хөкүмәт халыкның ышанычын казанган затлардан булсын дигән лозунгы иде.

Горемыкин кабинеты шул маддәне һичбер төрле кабул ителерлек тапмагач, көзгә Дума сессиясе таралган иде.

Менә шул «тәрәккъыйпәрвәр блок»ның уртасында безнең мөселман фракциямезнең бергә бара торган юлдашлары кадетлар, прогрессистлар булса да, безнең мөселман фракциямез шул алты фракция эченә җиденче булып та керә алмаган иде вә шул «тәрәккъыйпәрвәр блок»ның ун маддәлек программасына вә шул программаның тәфсиренә мөселманнар хакында бер сүз дә әйтелмәгән вә мөселманнарның һичбер төрле кичектерергә ярамый дигән бер теләүләре дә кертелмәгән иде.

«Тәрәккъыйпәрвәр блок» ясалып беткәч тә, озакламаенча Думаның таралып китүе дә безнең мөселман фракциямезнең блокка каршы урыны тәгаен ителә алмауга сәбәп булды. Инде блок ясалган чакта депутатларымызның да бик азының гына Петроградта булуы эзсез калмагандыр, блок үзенең мөселман фракциясенә зур бер көч дип карамавы, әлбәттә, роль уйнамаенча булмагандыр. Ләкин факт шул: мөселман фракциясе блоктан тышта калган иде, яисә читтә калдырылган иде.

Шул мәсьәлә, ягъни безнең фракциямезнең Думада нык урыны юклыгы безнең фракциямезнең халкымызның зурлыгы, мәмләкәтне алып баруда сарыф иткән бик күп көченә мөнасиб дәрәҗәдә мәгънәви кыйммәте юклыгы бөтен әфкяре гомумиямезне галәянгә китергән иде. Дума хакында озын-озын сүзләр, гәзитә мәкаләләре дә бәхәсләргә сәбәп булган иде. Садри әфәнденең фракцияне блокка кермәүдә гаепләп язулары[9], депутат Йосыф бәк Җәгъфәревнең фракция әгъзаларының ни эшләгәннәрен белдергән бәяннамәләре[10] һәркемгә мәгълүмдер вә шул хакта бөтен гәзитәләрдә язылган мәкалә, мөхакәмәләр дә хәтерләрендәдер. Менә бу көнге мәҗлес шул чуалчыкны, шул аңлашмауны хәл итәчәк иде.

Рәис әфәнде мәҗлеснең үзеге нәрсә икәнен сөйләгәч тә, Садри әфәнде үз карашын бәян итте.

Анынча, Думада шундай зур бер «сәяси оешу» бар икән. Аның программасына ун маддә күрсәтелгән мәсьәлә кертелгән икән, бу ун маддә безнең мөселманнарның да хәятларына зур тәэсир итәчәк булганга, мотлакан, фракциянең блокка кушылуы лязем иде, күпне көтеп торганчы азны алу тиеш иде. Блок берлә җитди сөйләшкәндә, мөселманнарның бөтен кирәкләрен кабул итеп бетермәсәләр дә, бәгъзе берләрен программага өстәргә разый булырлар иде. Шуның өчен мин мөселман фракциясенең блокка катышмавын хата дип уйлыйм, шуны, мотлакан, төзәтергә лязем, диде [Садри әфәнде].

Аңгарга җавап итеп һәм дә вакыйганы аңлатыр өчен депутат Йосыф Җәгъфәрев бәянатта булынды.

Җәгъфәревнең сүзенә караганда, блок ясалган чакта Думада Гайса мирзадан[11] башка беркем дә булмаган. Блокның мәҗлесләре элгәреге Дума рәисе Родзянконың[12] кабинетында булган. Андагы ике мәҗлестә Җәгъфәрев җәнаблары мөселман фракциясенең вәкиле булып утырган, мөселман фракциясе исеменнән сүз сөйләнгән. Өченче мәҗлескә чакырырмыз дигән булсалар да, Җәгъфәревкә дәгъвәт кылмәгән. Думаның карарында вә гәзитәләрдә «блок ясала икән» дигән хәбәр чыккан, шул арада өченче мәҗлес тә булган. Ләкин ул мәҗлес хосусый бер кешенең өендә, совет әгъзасы профессор Максим Ковалевскийның[13] ханәсендә ясалган. Вә мәҗлескә Җәгъфәрев чакырылмаган.

Җәгъфәрев кадетлар, прогрессист депутатлар арасына мөселман фракциясенең чакырылмавы хакындагы сәбәпләрен сорашып, белешеп йөргәндә, блокның программасы да игълан ителгән. Анда мөселманнарның теләвеннән бер сүз дә, бер маддә дә кертелмәгәнгә, мөселман фракциясе үзеннән генә шуларның ясаган программаларына разый булып барып керүне уңгайсыз тапкан. Үзенең шунда керүен блок программасына — мөселман теләвенә илтифат ителмәгән блок программасына разыйлык булып чыгачак дип читтә калган.

Җәгъфәревтән соң шул вакытта Петроградта булган Гайса мирза да сүз алып мәсьәләне ача төшмәкче булды.

Бик озын иттереп, блок шулай булса, блок тегеләй булса, без менә шулай дисәк, кадетларга китереп янтыктан төртсәк, прогрессистларга «вәт бит, без мөселман» дип бармак селкетсәк, октябристларның салпы ягына салам кыстырсак, директор департаментка барып, «Иван Иваныч, дело не в том» дип аңлатсак, шул булыр иде кебек тоелган кебек булганнан була түгелме, диде.

Кыскасы гына, он гына юк, күршедән май сорап алыр идек тә, аннан-моннан сөт, тоз табар идек тә, коймак пешерер өчен утын гына табарга калыр иде, дигән фәлсәфәне авыл куштаны кебек сатты. Халыкны ялыктырды, башны авырттырды. Мәсьәлә хакында бер генә дә яңгы сүз, яңгы факт, яңгы фикер әйтмәде.

Хәзерге хәлдә блок мәсьәләсе ни дәрәҗәдәлеге соралды. Фракция рәисе: «Без хәзер әле блок берлән мөзакәрә итәмез, шул сөйләшү, аңлашу беткәне юк. Үземезнең блокка керүемез өчен шарт итеп гайре рус милләтләргә хокук кысынкылыгы бетсен, дигән маддәне кабул лязем дип беләмез вә шул юлда сөйләшәмез», — диде.

Гайре рус милләтләргә хокук кысынкылыгы бетерелү маддәсе шактый яңгы бер мәсьәлә тудырды. Ул да — көзге сессиядә фракциямезнең рәисе Котлыкай мирза Тәфкилевнең гайре рус депутатларның оешы (блокы) исеменнән чыгып декларация укуыдыр. Садри әфәнде, аның артыннан Закир әл-Кадыйри әфәнде[14]

мөселман депутатларның бу эшләренә оясына сыймаган тычканның койрыгына себерке тагып керүе кебек карадылар. Үз эшемез эшләмәенчә ятканда, үз эшләремезне эшләргә көчемез булмаганда, яһүдиләргә өмәгә йөрү сыман хәрәкәт, диделәр. Мөселман депутатларның башка милләте мәхкүмә депутатлары, ягъни латыш, эстон, яһүд, поляк, малорус, грузин, әрмән депутатлары, мөнәсәбәте белән ничек булуы мәсьәләсе аерым бер мәсьәлә булып мәйданга чыкты.

Мәҗлестәге бер кыйсем халык фикеренчә, без, мөселманнар, үземезнең Думадагы эшемездә үземез генә кайгыртырга кирәк, үземезнең эшләремезне, үземезнең ихтыяҗларымызны гына тотырырга маташырга кирәк. Шул юлда ничек мөмкин — шулай эшләргә кирәк, хөкүмәт даирәләренә дә аңлатырга кирәк, рус депутатлары белән дә сөйләшергә кирәк, хасыйлән, без үземезнең бөтен эшемезне эшләгәндә, без гайре рус дигән киң, гам флагны күтәрмәенчә, «без — мөселман» дигән байракны күтәрергә тиеш, диделәр.

Бу фикерләрнең тарафдарлары Садри әфәнде берлән Закир әфәнде булдылар.

Икенче бүлек һәм дә зур бер бүлек: Думадагы безнең вазгыятемез мәгълүм чикләр куелган даирә эчендә булырга тиеш, Думадагы депутатларымызның хезмәтләре андагы оппозициядәге фракцияләр берлән бергә булырга һәм парламент ысулынча булырга тиеш, департаментларга[15] барып бусага таптаулар, сыгынулар, кыянулар депутатларның шәэненә муафикъ түгел.

Тагы мөселман депутатларның хәрәкәтләре һәр мәсьәләдә оппозиция берлән бергә булырга тиеш. Чөнки хокуклары иң кысылган Русиядә бер халык булса, ул да — без. Бинаән галәйһи безнең хәзерге идарәгә разый булуымыз һич мөмкин түгел. Оппозиция берлән бергә булганда да, без алар берлән табигый юлдашлар түгел. Хәзер, алар хөкүмәткә тәнкыйтьче булып караганда, без алар берлән бергә. Тормышлар үзгәреп китеп, шул ук оппозициянең үз эченнән хөкүмәт чыкса, ул хөкүмәт тә безнең теләгәннәремезне тартышмаенча бирмәячәктер. Ул вакытта да без оппозициядә булып калачакмыз. Безнең берлән бергә шул вакытта да бөтен гайре рус депутатлар калачактыр, чөнки аларның да, безнең дә гам булган «бөтен милләтләр мөсави булсын» дигән идеалымыз әле Русиядә бик озакка кадәр идеал булып торудан чыкмаячактыр. Шуңгарга күрә Думадагы гайре рус милләтләрнең вәкилләре — безнең мөселман фракциясенең табигый юлдашыдыр, Русиядәге бөтен гайре рус милләтләрнең хокуклы булуы — латышына, яһүденә, грузинына, полягына, мөселманына бер эштер, һәммәсенә дә үз эштер.

Бу бүлек халык фракция әгъзаларының гайре рус милләтләрнең депутатлары берлән бергә булуын бик муафикъ, кирәкле бер хәрәкәт тапты вә, шул сәясәтне мөселманнарның табигый сәясәте булды дип, тамга салды. Мәсьәлә бик озайды. Шуннан фракция рәисе Котлыкай мирза бәгъзе бер изахат бирде.

Аның сүзенчә, мөселман депутатлары, үзләренең көчсез җилкәләренә яһүд, латыш, эстон вә гайреләрне мендереп утыртып, аларны өстерәп бармыйлар. Билгакес, гайре рус милләтләргә хокуклы булуда башка халыкларның бөтен мәгънәви көчләре безнең мөселманга караганда әллә никадәр күп гайрәт сарыф итәләр.

Декларация укуда да Котлыкай мирзаның чыгып укуы мөселманнарның башка халыкларны үз химаяләре астына алудан түгел, фәкать гайре рус депутатлар арасында Тәфкилев җәнаблары иң карт депутат булудан гына!

Аннан соң, блок үзенең декларациясендә мөселманнар хакында бер сүз дә әйтмәгәч, әлбәттә, мөселман фракциясенә үз теләвен әйтү лязем иде. Шул вазифаны үтәгәндә, җыен гайре рус милләтләр, аерым-аерым бер сүзне сөйләп торганча, бергә оешып әйтүне мәслихәт таптылар. Ялгыздан чыгып сөйләгәндә дә, мөселман фракциясе шул ук бөтен милләтләргә мөсавәт, диндә кысынкылыкны бетерүне теләр иде.

Шуның өчен гайре русларның катышуыннан мөселман фракциясе һичбер маддәдә оттырмады, билгакес, шул байрак астына яһүд, латыш, малорус, грузин вә башкаларны җыеп, урынын ныгытты гына!

Шул мәсьәләләрнең ваклары, тәфсыйлатлы мөзакәрә ителгәндә, тагы яңгы бер мәсьәлә туды. Ул да — депутат кем, мөселман депутаты кем вәкиле, мөселман депутаты мөселман халкының вәкилеме, әллә ходатае, адвокатымы?

Мөфтилек мәсьәләсендә фракциягә килгән бик күп телеграмнар, хатлар, мөрәҗәгатьләрдә бер кыйсем халык, мәсәлән, Баязидовны урынсыз кеше дип төшерер өчен тырышуны кушалар.

Икенче берсе, Сафаны мөфти иткән өчен хөкүмәткә рәхмәт укыңыз, урыны ныгаюына тырышыңыз, диләр.

Өченче бер кыйсеме әүвәлге төшерергә дигәннәренә дә, урыны ныгысы, дигән мөрәҗәгатьләренә дә кулны куеп, мәсьәләне чуалталар. Шулай булгач, мөселман депутаты кем соң, кемнең вәкиле? Русия татарлары арасында — унбиш ел эчендә биш мең ибтидаи мәктәп ислях иткән Русия татарлары арасында — тәгълиме ибтидаи таралуы өчен елына миллион сумнар ярдәмнәр иткән, матбугатлы, әдәбиятлы халык Русия мөселманнарының аурупалы мөселман гасырынча хәят тартышуына хәзерләнгән татар булуын кыйсем халыкның вәкилләреме?

Әллә бөтен рәхәт, тынычлык искедә генә иде, һәр яңгылык хәрам дигән муллалар берлән, үзенең русча белүеннән яисә бер-бер мөнәсәбәт тотуыннан файдаланып, үз мәнфәгатенә халыкның киләчәген, миллиятен, динен йә аңлап, йә аңламаенча корбан итә торган бер кыйсем куштаннарның сайланганымы?

Хазирунның иң күп бүлеге — мөселман фракциясенең депутатлары, Русия мөселманнарының аңлы кыйсеменең тәрҗемане әфкяре. Иске фикердәге картлар, шуларның салпы ягына салам кыстырып фетнә чыгаручы муллалар булса да, Русия мөселманнарын карагруһлы фикердә дип хөкүмәткә якын күренер өчен бөтен гыйльми, мәдәни, милли эшләремезгә аяк чалучылар, доносчылар, сагыячеләр булып торса да, бу кыйсем халык — милләтнең чүбе-чарыдыр. Милләтнең алышуы вакытында була торган, иске тормышыннан чыгып, яңгы тормышка таба керүендәге сыныклары, ертыклары, сәләмәләредер.

Башка халыкларның мәдәният тарихларында булган бу кыйсем чүп-чар булмавы, тирес черегәндә, янганда шуның сасысы чыкмавы мөмкин түгелдер. Шуның өчен ул вакытлы, иттифакый бүлеккә әһәмият бирмәскә лязем диелсә дә, башка могарәзәләр-фәләннәр булынганга, мөселман фракциясенең гомуми хаттел-хәрәкәте, аның сәяси юлы, платформасы хакында киңәшү тиеш күрелде.

Вакыт бик соң булганга, өченче мәҗлескә мөселман фракциясенең хаттел-хәрәкәтен, тәгаен платформасыны билгеләү маддәсе кертелде.

## МӨСЕЛМАН ФРАКЦИЯСЕНДӘ ӨЧЕНЧЕ КИҢӘШ МӘҖЛЕСЕ

Мәҗлестә Кырымнан, Кавказдан берничә яңгы затлар бар. Әүвәлге мәҗлесләрдәге кебек Котлыкай мирза Тәфкилев рәислек итә.

Мәҗлеснең беренче мәсьәләсе — мөселман фракциясенең платформасыны билгеләү, мөселман фракциясенең хаттел-хәрәкәтен яңгыдан күздән кичерү.

Шул мәсьәләнең кирәклеген мин алга сөргәнгә, рәис әфәнде миңа фикеремне ачып бирергә куша. Мин түбәндәгечә бәянда булынам: элгәреге мөселман фракциясе «Мөселман иттифакы» дигән партиянең бер кисәге санала иде. Мөселман фракциясе «Мөселман иттифакы»ның программасыны Дума ашасыннан тормышка үткәрә торган көче иде. Ул вакыт мөселман фракциясе янында бергә комитет[1] утыра иде вә мөселман фракциясе берлән бергә эшләшергә тырыша иде.

Читләрдәге мөселман иттифакчыларының йирле өяздәгеләре фракциягә ярдәмдә булып даими мөнәсәбәттә торалар иде. Дөньяның алышынуы берлән «Мөселман иттифакы» үзенең урынын саклый алмады. Ул бетте. Аның партия хәлендә яшәешенә хатимә чигелде. «Мөселман иттифакы» партиясенең милли хезмәтен сөйләү, аның алган юлын тәнкыйть итәргә монда теләмим. Фәкать шуны гына әйтеп китәм: «Мөселман иттифакы»ның иң зур хезмәте аның күтәргән байрагындагы мәшрутиятьчелеге булып, ул шул мәшрутиять байрагын бөтен мөселман исеменнән күтәрү берлән сәяси тәрбия күрмәгән, башбаштаклыкны сөюче мөселман халкын уңга таба хәрәкәттән аерып кала алды. Шул мәшрутиять байрагын бөтен мөселманның теләге дип төшендерә, аңлата алудан — чинга, медальгә, «молодец, князь!» дигән вак рәхмәтләргә эреп китә торган, сәяси тәрбиядән мәхрүм милләтнең истикъбале, милли агышы кебек фикерләрне аңлаудан түбән бер кыйсемен мөселман исеменнән карагруһ теләүләре берлән чыгудан тыеп кала алды вә, шулай итеп, мөселманнарның Русиядәге сәяси урыннары мәшрутиятьчеләр берлән генә икәнлеген ап-ачык тәгаен итте. Рус әфкяре гомумиясенә шул фикерне илка итә алды. Менә «Мөселман иттифакы» партиясенең шул хезмәте, мөселман теләкләренең уң ягыннан чик була белүе — зур бер тарихи хезмәттер. Ләкин хәзер шул уңнан чикне саклаучы юкка, илдә дә уңга таба мәел туды. Фракциядә дә шуның ингыйкясе булырга тиеш. Фракция, бәлки, мөселман фракциясе уларак уңлашмагандыр. Ләкин аерым-аерым депутатлары уңлашканнар[2]. Үткән сайлаулардагы Казанның сайлаучыларының күбесе «Безгә депутат булган кеше «үтенүче» булсын» дигән лозунгыны күтәрүләре вә шуның аркасында кара көчләр берлән бергәләшсәләр дә, бер мөселман депутаты үткәрә алмаулары, Оренбургта сайлауларда, «вакытчы»ларны кызылга санап, Гайса мирзаны үткәрергә тырышулары[3] — шул юлдагы эшләрдер. Хосусән соңгы көннәрдәге мөфтилек мәсьәләсендә чыккан дәрәҗәгә, медальгә кызыгучыларның бертуктамаенча киртә сикереп торулары, хәзерге көндә «Сыйрател-мөстәкыйм союзы»ның яңгыдан ныклап вөҗүдкә чыгар өчен тырышып ятуындагы («Исламе мәгариф» гәзитәсе[4]) бер кыйсем халыкның үлпән-сүлпән селкенеп торуы — шул уңлашуга мәел барлыкның зур дәлилләредер. Шуның өчен фракциянең хаттел-хәрәкәте ачык ителеп тәгаен ителмәсә, аның әгъзалары һәр мәсьәләдә мәгълүм мәсләк белән эш итәрлек ачык чөй баганалары сызылмаса, аларның аяк астлары һәрвакыт хәрәкәтләнеп торачактыр. Аларның эшләгән эшләрендә берлек, мәгълүм система булмаячактыр. Фракциягә керер өчен мәгълүм сәяси мөэмин бәяләр кабул итү шарт ителмәсә, аның әгъзалары арасында бер туктамаенча низаг булып, куәт, гайрәт, эчке тартышка китәчәктер. Шуның өчен хәзер мәгълүм бер программа ясарга вакыт, заман мөсагыйд булмаганга, мин мөселман фракциясенең уңнан-сулдан чикләре сызылуны лязем табам. Бигрәк

тә уңнан һөҗүм куәтле булганга, ул тарафка мәшрутиятьчеләр дигән байракны тагы күтәреп, уңнар берлән чик чокырын тагы казырга кирәкле табам. Шулай ителсә, мөселман фракциясе мәшрутиятьлеләрнең парламент көчләре дип танылса, мөселманнарның үзләре дә ап-ачык бер мәшрутиятьле группа алдында калдырылыр иде. Мөселман фракциясе үзе дә парламент ысулына тәмамән хилаф булган интенданствога «Минем җонны сатышырга ярдәм итеңез, фәлән ахунга алтын медаль алып бирергә тырышыңыз!», «Матбугатның тавышына әһәмият бирмәңез!» дигән кебек мөрәҗәгатьләр алдында кулы ачык, җавабы мәгълүм булыр иде.

Кыскасы гына, мин хәзер фракциянең хаттел-хәрәкәтендә уң тарафтан, мотлакан, мәшрутиятьчеләр дигән байракны яңгы буяуларын буяп күтәрүне лязем табам.

Мәсьәләнең куелуына каршы Садри әфәнде могарәзә итте. Аныңча, «Мөселман иттифакы» бар инде, аның программасы эшләнгән, шул юлдан барырга кирәк.

Муса әфәнде[5] дә: «Бездәге хәзерге эшләрдәге чуалчыклар гыйззәте нәфесемез юклыктан килгән хасталыклар гына. «Иттифак»ның программасы бар», — диде.

Закир әфәнде Кадыйри «Сыйрател-мөстәкыйм»нәрнең һөҗүмнәрен алга китереп, минем теләүне куәтләде.

Котлыкай мирза: «Фракциядә мәсләк ягыннан шундый уңгайсызлыклар була, — диде. — Мөселман фракциясенә керер өчен мәгълүм мәсләки шартның куелмавы бик уңгайсызлана иде», — диде. Мәсьәлә дә бердән ике сатыхка куелып китте. Бер кыйсем халык, «Мөселман иттифакы»ның программасына һөҗүм башланды», — дип, төрле юллар берлән шуны сакларга тотындылар. Икенче кыйсем халык: «Монда «Мөселман иттифакы» программасы мөзакәрә ителми. Хәзерге әһәмиятле вакытта уң тарафтан килә торган милли дошманга каршы кальга гына куела», — диде. Сүз фәүкылгадә озайды. Кечкенә генә бер кыйсем халык, Садри әфәнде[6], ахырга таба Закир әл-Кадыйри әфәнде бөтен көчләре берлән «Иттифак» программасына сарылдылар.

Исмәгыйль әфәнде Леманов[7], уңга каршы мәшрутият баганасын утыртуга каршы килмәенчә: «Киләсе сайлауларда депутатлар иттифакый гына үтмәсен өчен, махсус бер сәяси фикернең тарафдарлары үтсен өчен тырышырга кирәк. Думада мөселман фракциясе, ул вакытта иттифакый үткән Миңлегалиевләрдән[8] тормаенча, бер фикер, бер уйда оешмадан гыйбарәт булыр», — диде. Сәлимгәрәй мирза Җантурин[9], бу мөзакәрәләрне «Иттифак» программасын тикшерү дип карамаенча: «Менә бу сөйләшүләр уңнан килә торган афәткә каршы берләшү генәдер, милли көчләрне бергә җыю гынадыр. Шуның өчен уңнан мәшрутиять чиге сызу ягындамын», — диде. Сүз озаеп киткәч, Котлыкай мирза: «Без бөтенләй программасыз түгел. Эчке эшләремездә үземезнең кануннарымыз бар», — дип, фракциянең Өченче Думада ясаган эш программасын игълан итте. Эш программасы бөтен хазирунны канәгать хасил иттерде.

Рәис әфәнденең: «Шул эш программасын кабул итәсезме?» — диюенә бөтен кеше «разый» дип җавап бирде. Шул мәсьәлә бетте хисап ителеп, мин бюро кору мәсьәләсен көткән идем. Ләкин Садри әфәнде: «Бу эш программасы Өченче Думада «Мөселман иттифакы»ның программасыннан сыгып алынган иде. Моны кабул итү «Мөселман иттифакы»ның программасын кабул итү булды, бәс, безнең киңәшемез фракциянең программасы «Мөселман иттифакы»ның программасы дип кабул ителде», — диде. Шул шәкертчә ясалган Шәрекъ сәясәте ябылган мәсьәләне тагы кабартып җибәрде. Ибнеәмин әфәнде Әхтәмов[10], мәсьәләгә изах биреп: «Әгәр шундагы хазир булган кешеләр, «Мөселман иттифакы» программасының бөтен маддәләре мөселман депутатларына мәҗбүри булсын, дисәләр, мин ул фикер берлән килешә алмыйм. Мин «Мөселман иттифакы»ның дини, милли мәсьәләләрендә генә башка иптәшләрем берлән бер фикердә. Минем сәяси фикерем «Мөселман иттифакы»на язылмый», — диде.

Аның артыннан мин «Мөселман иттифакы»ның программасын контрабанда берлән үткәрергә тырышуга протест ясадым.

Үзем өчен «Мөселман иттифакы»ның теләкләре минем сәяси, милли, дини теләкләремнең иң кечкенәсе — минимумы булып кына кабул ителәчәген аңлаттым.

Шакир әфәнде Мөхәммәдьяров[11], Кәрим Сәгыйть әфәнде[12] минем фикеремне изах иттеләр. Тагы моназарә китте. Ахырдан өч төрле формула тавышка куелды. Берсе Садри әфәнде тарафыннан кертелде.

Беренчесе: киңәш мәҗлесе мөселман фракциясе өчен программа иттереп, «Мөселман иттифакы партиясе»нең программасын кабул итте.

Икенчесе: минем тарафымнан кертелгән киңәш мәҗлесе мөселман фракциясе өчен «Мөселман иттифакы партиясе»нең программасын уң тарафтан куелган чик дип кабул итте.

Өченчесе: Кәрим Сәгыйть әфәнде тарафыннан кертелгән киңәш мәҗлесе мөселман фракциясен уңнар берлән тартышыр өчен ясалган милли организацияләремездән суллар һәм урта партияләрнең иттифакый блогы дип кабул ителде.

Садри әфәнде формуласына алты гына кеше тавыш бирде.

Минем формулама каршы уналты кеше тавыш биргәнгә, «Мөселман иттифакы партиясе»нең программасы мөселман фракциясе өчен уң тарафка каршы куелган чиктер дигән теләү мәҗлес тарафыннан кабул ителде.

Кәрим Сәгыйть әфәнде шул икенче формулага разый булганга, ул үзенең формуласын кайтарып алды.

Бюро хакындагы сүзләргә бик аз вакыт калганга, дүртенче мәҗлескә калдырырга тугры килде. Алай да мәҗлестә, бюро хакындагы әсаслар бераз сөйләнеп, Сәлимгәрәй Җантурин, Гайса мирза Еникеев, Шакир Мөхәммәдъяров, Гаяз Исхаковтан мөрәккәб бер комиссиягә бюро хакында доклад ясарга тапшырылды.

## КИҢӘШ МӘҖЛЕСЕ

Дүртенче мәҗлестә Троицк вәкиле имам Габдерахман әфәнде Рәхманкулов[1], кыргыз җәмәгать хадимнәреннән Икенче Дума әгъзасы Бүкәйханов[2], «Казак» гәзитәсе мөхәррирләреннән Байтурсунов[3] һәм дә урта казакълыктан бер әфәнде[4] бар иде.

Мәҗлес ачылгач та, «Бюро төзү» комиссиясенең доклады тыңланды. Комиссиясенең докладчигы сыйфаты берлән Сәлимгәрәй мирза Җантурин сүз алды һәм дә түбәндәгечә фикерен ачты: «Үткән мәҗлестәге хазируннарның бюро төзү лязем дигән карарларына карап вә Дума әгъзаларының Думада кирәгенчә хезмәт итеп барыр өчен фракция читтән килгән көчләргә мохтаҗ дигән фикерен алга тотып, без бюро хакында уйлаштык. Безнеңчә, мөселман эшләрен Думада кирәгенчә алып барыр өчен, мотлакан, фракциягә эштәшчеләр кирәк. Фракциянең үз көче берлән генә Думадан үтә торган мөселман мәнфәгатьләрен мөхафәзә итәргә генә түгел, шуларны күздән үткәреп, җентекләп торырга да көче җитәрлек түгел, бәлки, Думадагы әллә никадәр комиссияләрдә эш итәрлек итү лязем. Думаның гомуми мәҗлесләрендә булыну тиеш. Думадан бик күп үтә торган закон ляихәләрен карап чыгу тиеш. Думадагы фракцияләрнең һәрбер хәрәкәтен җентекләп тору тиеш. Хөкүмәтнең мөселманнарга йөртелә торган һәрбер әмерләрен, фәрманнарын, хәрәкәтләрен тәхлил итеп тору тиеш. Моңгарга башка илемездәге хәлләр дә шома гына бармаганга, аннан да бер туктамаенча зарланулар, үтенүләр явып торганга, аларга да ярдәм кулы сузу тиеш.

Шуның өстенә тагы мөселман тормышында һичбер төрле кичектерүне кабил түгел берничә ляихәләремезне дә хәзерләү лязем.

Бу йөкнең никадәр зур икәнен аңлаган һәркемгә күренеп тора. Шул зур милли йөкне өстерәр өчен өч-дүрттән узмаган депутатларымызның саны һичбер төрле җитү ихтималы юктыр. Аларның көчләре, сәгатьләре мәхдүд булганга, шул депутатлар өстенә генә бөтен эшне ташлау хатадыр. Думадагы бөтен фракцияләр, хәтта иң зурлары да, читтән көчләр китереп эшләтергә мәҗбүрләрдер. Шуның өчен мөселман фракциясенең хезмәте халкымыз теләгәнчә барсын дисәк, мотлакан, фракциягә ярдәмгә итешер өчен бюро тәэсис итү ляземдер.

Без бюро ясауда әсасән менә шул фикергә килдек.

Бюро, аз дигәндә, дүрт кешедән мөрәккәб булырга тиеш. Бюро әгъзалары, фракциядәге депутатларымыз берлән бергә утырышып, закон проектлар хәзерләү дәрәҗәдә мәгълүмат, тәҗрибә сахибләре булырга тиеш (юристлар булуы матлуб). Бюро әгъзаларының хезмәт мөддәтләре бер елдан ким булмаска тиеш. Бюро әгъзалары, мөселман фракциясенә иптәш булып килеп, фракциядә уянган мәсьәләләрнең һәммәсенә дә иштиракь итәргә тиеш.

Бюро әгъзаларының мәгънәви хокуклары Дума әгъзаларыныкы берлән бер дәрәҗәдә булынырга тиеш.

Бюроны тәэсис итүдә, бюрога әгъзалар табуда ике төрле юл мөзакәрә ителде. Берсе — фракциянең үз чакыруы берлән Русиягә таралган эшлекле мөселманнарны җыю. Икенчесе — зур шәһәрләрдән Казан, Уфа, Оренбург, Троицк, Мәскәү вә башкалардан бюрога яраклы бер кешенең вәкил иттереп җибәрелүе.

Фракция үзе чакырганда, халык күзе алдында уңгайсызлык булмасын өчен, «фракция үзе теләгәннәрне генә чакырды» дигән шөбһәне уятуны фракция әгъзаларымыз теләмәгәнгә, без дә шәһәрләрдән сайлап җибәрү ысулында туктадык. Ләкин шул ысулда безнең алдымызда тагы бер уңгайсызлык килеп басты. Ул да — бер-бер шәһәрдән мөселманнарның күпчелекле бер урыннан үзләренчә бик олуг булган кешеләрен җибәреп, ул әфәнденең бюро хезмәтенә тәмамән ярамау ихтималы. Мәсәлән, Әстерхан төрле көчләрдән куркып, арага кертергә шикле булган бер учительне җибәрә. Каргалы «анда дин эшләренә фракциядә зуррак әһәмият бирергә тиеш» дип, хөрмәтле бер хәзрәтне, ләкин ляихә төзү эшләре берлән һичбер яктан таныш түгел мулланы, мөәзинен җибәрә.

Шул уңгайсызлыктан котылыр өчен, без, комиссия әгъзалары, хәзерге киңәш мәҗлесе тарафыннан бюрода булуы тиеш табылган затларның исемнәре тәртип ителсен вә шул затларның килүләре матлуб иттереп күрсәтелеп, сезләрдән халыкка мөрәҗәгать ителсен, дидек.

Бюроның малия ягында комиссия менә нинди фикергә килде.

Бюроның дүрт әгъзасының хәя тәэминнәре депутатлар вазифасыннан ким булмаска тиеш. Шул затларның эшләячәк эшләрендә, хезмәтләре үрчемле булсын өчен, укыган яшьләрдән, студент, курсисткалардан мәгълүм мәгашка ялланган могавиннәр булырга тиеш.

Фракция берлән бюро арасындагы галяканы йөртә торган вазифага алынган секретаре булырга тиеш. Фракция берлән бюроның фатир һәм дә канцеляриясе булырга тиеш.

Шулай идарә итәргә егерме биш, утыз мең чамасында еллык расхуд кирәк. Шул акчаны, әлбәттә, халыктан җыеп алу лязем. Ләкин шул мәсьәләнең малия эшен башкаруны фракциягә тапшыру мәслихәт күрелмәде. Чөнки фракция болай да бик күп эш берлән күмелгәнгә, аның вакыты юктыр. Икенчедән, фракция берлән бюро әгъзалары арасында мәгаш алу, мәгаш бирү мөнәсәбәте ике арага суыклык төшерү ихтималы юк түгел. Шуның өчен бюрога вәкил җибәрүдә Уфа мөселманнарының башлап күрсәткәннәре үрнәккә тотылырга мәслихәт табылды. Ул да — һәрбер зур мөселман шәһәре үз тарафыннан хәяты тәэмин ителгән бер вәкил җибәрә вә шуның могавине өчен, канцелярия расходы өчен мәгълүм сума тәгаен итә. Мәсәлән, Казан, Оренбург берәр кешене шулай күндерәләр (Уфа вәкиле хәяты тәэмин ителеп, анда тора инде). Мөселман фракциясе эше бөтен Русия мөселманнарының эше булганга, әлбәттә, моңгарга кечкенәрәк шәһәрләр, авыллар да катышырга тиеш. Алардан киләчәк сумалар берлән фракция өчен булуы лязем күрелгән дүрттән артык әгъзаларны чакырырга тотылырга тиештер. Менә безнең комиссиянең бюро хакындагы күрсәткән планы».

Сәлимгәрәй мирзадан соң мин Сәлимгәрәй мирзаның хәтереннән чыгып калган бер маддәне тутырдым. Ул да — әгәр мөмкин булса, бюрода Төркестан, Кыргыз, Кавказ эшләренә махсус аерым-аерым бюрочыклар ясалса иде, вә шул мөселманнарның мәсьәләләре шул бюрочыкларга җыелса иде, вә шул бюрочыкларның башларында вәкил булып кыргыз кардәшләремезнең дә үз вәкилләре, төркестанлыкта Төркестан вәкилләре, Кавказныкында Кавказ вәкиле утырса иде.

Комиссиянең доклады шактый зур мөзакәрәләр уятты. Хазируннан берсе (белмим, Габдерахман әфәнде, белмим, Шакир әфәнде[5]) бюрога шактый зур сума күрсәтә: «Бу суманы халыктан алырга кирәк. Безнең халык җәмәгать эше эшләргә өйрәнмәгән. Моңганчы эшләгән җәмәгать эшләремез һәммәсе дә эшләүчеләр тарафыннан «садака» ителеп эшләнеп килде. Татарның иң зур бае да җәмәгать эшен эшләшүдә үзенең бурычы бар дип, татарның һичбер даирәсе дә җәмәгать эшен үземез эшләргә тиеш дип эшләми, шул юлда өстенә төшкән йөкне һичбер төрле күтәрми. Билгакес, әллә кемнәрнең эшләгәннәрен яратмаган булып сөйләп йөри. Аннан соң бездә җәмәгать эше кадәр бәһасез нәрсә юк. Татар фикере буенча, укучылар өч-дүрт тәңкәгә университет бетерергә тиеш, егерме-утыз тәңкәгә җәмәгать эше артыннан йөрүчеләр шул мөселман эшен эшләп бетерергә тиеш.

Халыктан егерме биш, утыз мең сумалар акча алынса, гади халык шуннан бик зур нәтиҗәләр көтәчәк. Аның бөтен ихтыяҗлары шуның берлән тәмам үтәлергә тиеш дип карап, күзгә ташланырлык бер эш күренмәсә: «Әй, юкка әрәм иттек, егерме биш мең сум бит ашадылар җәмәгать малын, безнең писарь Иван Ивановичка егерме тәңкә биреп, прошение яздырсак, анда шәп була иде диюләр бик күп булыр», — диде.

Шул сүзләргә каршы халыкның үз мәнфәгатен аңлатмаган чагында андый күңелсезлекләр булмый хәле юк. Татар халкының, мәгаттәэссеф, аңлы дигән кыйсеме әле җәмәгать эше матди вә мәгънәви яктан үз вазифасы-бурычы икәнен белә алганы юк. Ул әле һаман читтән килә торган көч моның акчасын, көчен сарыф иттермәенчә эшли торган әүлиямы, фәрештәме көченә ышанып, сүз көтеп ята. Ләкин аның аңлаганын көтеп торырга хәзер вакыт мөсәгыйд түгел. Бүредән курыккан кеше урманга бармыйдыр, ди. Мөселман җәмәгать эшендәге кешеләргә алай бик назик, тиз үпкәләүчән булырга ярамый. Шул акчаны халыктан алырга тиеш, халык бирергә тиеш. Мадам ки эшнең эшләнүе шул кечкенә сумага баглы, киләчәк буыннарга тәэсире булачак. Шул зур эшне уртада калдырырга ярамый, диелде.

Бер әфәнде: «Ник менә Кавказдан акча табу юлы каралмаган, ник Төркестаннан, ник кыргызлардан алыну юлы каралмаган?» — диде. Бу мәсьәлә тагы яңгы сүзләргә юл ачты.

Мөзакәрәләрдән моңганчыга кадәр гомумән фракция эшләрен алып баруның матди йөге Идел буе мөселманнарының җилкәсенә генә төшкәнлеге, Кавказ мөселманнарында дәүләте зур кешеләр бик күп булса да, болар арасында, ингамиянә күрә, медаль, чин, мактау бирелми торган милли эшләргә бирергә ихласы бар кешеләр бик азлыгы сөйләнелде.

Мәҗлес, комиссиянең фикеренә кушылып, докладта күрсәтелгән әсасларда бюро ясауны лязем тапты вә шул хактагы киңәш мәҗлесенең биргән карарын халыкка белгертер өчен киңәш мәҗлесе рәисе Котлыкай мирзага тапшырды.

Хазируннар шул бюроны булдырырга ярдәм итәргә сүз бирештеләр. Моннан соң элгәреге мәҗлесләрдә ачык калган «тәрәкъкыйпәрвәр блок»[6] мәсьәләсе килеп басты. Бу мәҗлестә Котлыкай мирза: «Мин блок рәисе Сидловский[7] берлән күрешеп сөйләштем. Сидловский, аерым милләтләрнең теләкләрен блокның үз

программасына кертә алмыймыз, дип рәсми әйтте», — диде. Шул мәсьәлә вакытында озын моназарәләр китте.

Блокның мөселманнарның теләгенә әһәмият бирмәвен халыкка ачыграк күрсәтү лязем түгелме дигән бер мәсьәлә туды. Бер кыйсем халык мөселманнарның үзләренең тормышларына иң кирәкле булган бер мәсьәлә хакында, мәсәлән, идарәи руханиянең исляхы, мөфтилек сайланып куелуы хакында бер ляихә кертеп, блокның пәрдәсен ачарга кирәк, блок шул мәсьәләдә безнең теләмемезгә ярдәм итсә, тавыш бирсә, бик яхшы, бирмәсә, безнең теләкләремезгә дошманлык вазгыятен алса, халык күрсен, диелде.

Шуннан блокның гайре милләтләрнең теләкләренә каршы нинди вазгыять алуын күрсәтер өчен депутат Җәгъфәрев[8]: «Трудовая группа» Дума ачылгач ук, Русиядәге милләтләр арасында хокукта мөсавәт булсын дигән ләйхә кертмәкче булган иде. Думага кертеләчәк ляихәләргә утыз депутатның имзасы лязем булганга, шул өстенә трудовиклар, социал-демократлар, мөселманнар вә гайре рус депутатлар берлән генә утызга җитмәгәнгә, кадетлар вә прогрессистлардан бәгъзеләренең имзалары алынган иде. Блок үзенең әгъзаларының шул ляихәгә имза куюлары кирәкмәгән эш тапты да, блок әгъзалары имзаларын алдылар да ляихәне кертү бер атнага — читтән килә торган оппозиция депутатлары килүгә кадәр кичекте», — диде.

Шул бәяннан соң мин: «Хәзер инде, мәсәлән, без бюро ясасак, шул бюро бик тырышып эшләп, үземезгә кирәкле ляихә өлгертсә, шуны Думадан үткәрергә имкян бармы һәм дә шул ляихә кертер өчен генә дә утыз имзаны таба алмаенча аптырап калмыймызмы?» — дигән сөаль бирдем. Фракция әгъзаларының җавабына күрә, без хәзер дә суллардан һәм дә Караулов группасыннан[9] утыз имза таба аламыз. Ләкин бөтен закон проектларының үтүе хәзер, мотлакан, блокның ихтыярында гына. Чөнки күпчелек аларда. Бәгъзе берсен блокта фракцияләрнең фикерләрен булдыру ихтималы булмаганын үткәреп булыр иде.

Троицк имамы Габдерахман әфәнде: «Без хәзер блокта булсак, безнең мөселманнарның бөтен теләкләрен блок күтәрешер идеме?» — дигән сөаль бирде.

Аңгарга каршы бирелгән җавапта, блокка кермәвемезнең бер сәбәбе гайре рус милләтләргә мөсавәт маддәсе принцип уларак кабул итмәү булганга, әлбәттә, шәһәрләр, земстволарга сайланулар, мәктәпләремезне ислях хакындагы ляихәләремез блокның националист әгъзаларын кол аеру ихтималы булганга, аларны үткәрмәсләр иде, диелде.

Имам әфәнде: «Алай булса, безнең халыкта «блокка керсәк бар да була иде, блокка керми иткән хатадан бер эшемез дә эшләнми», — дигән фикер дөрест түгел. Мадам ки безнең иң кечкенә ихтыяҗларымызны да күзгә алмаган блокка фракциянең кермәве савап дип аңлыйм», — диде.

Бүкәйханов җәнаблары: «Фракция, блокка керсә дә, аягын-кулын бәйләгән булыр иде. Хәзер эшләргә чит көч килә, эшләве үз ихтыярында, блокка кермәскә тиеш», — диде.

Садри әфәнде[10] блок берлән тагы сөйләшү ляземлеген алга куйды.

Озын сүздән соң ике төрле формула тавышка куелды.

Берсе: блокның хәзерге программасына гына разый булып, мөселман фракциясе блокка керсенме?

Зур бер күпчелек: «Кермәсен», — дип тавыш бирде.

Икенчесе: блокның программасына үз теләкләремезне кертер өчен мөзакәрәләр ясалсынмы?

Монысына күпчелек: «Милли, дини мәсьәләләремездән мәгълүм теләүләрнең тиземен кабул итүе принцип итеп мөзакәрә ясалсын», — диде.

Шуннан соң Гайса мирза Еникиев өченче предложение кертмәкче булды. Аныңча, «Мөселман иттифакы» блокка кермәскә дә тиеш, чыкмаска да тиеш. Блокка дуст та булмаска тиеш, дошман да булмаска тиеш. Блоктан башта да тормаска тиеш, аның берлән агып та китмәскә тиеш. Аннан сулда [да] булмаска тиеш, уңда да булмаска тиеш. Өсттә дә булмаска тиеш, астта да. Хасыйле, игътикад китапларында «Аллаһе Тәгалә хәзрәтләренең нинди сыйфатлары булса, шуларның барысы берлән дә мөселман фракциясе сыйфатланган булырга тиеш» формуласы аңлашылмаса да, үзенең фикерен ачык иттереп әйтү киләчәктәге үзенең сәясәтенә уңгайсызлык килер төсле булганга, әллә ниләр сөйләп, йөз яшереш уены сызылды. Мәҗлестә тагы бик күп мәсьәләләр булса да, бик күп вакытны ашады. Рәис әфәнде йомшаклык итеп, аны кырт итеп кисә алмады. Бик күп вакыт әрәмгә китеп, халык ярма тегермәне әйләнүдән бик ялыгып беткәч кенә, мөфтилек мәсьәләсе мөзакәрәгә куелды.

Мәсьәлә: иң әүвәл безнең Идел буе мөселманнарына үзләре теләмәгән бер шәхесне мөфти ителеп куелуы[11]. Аның ничек мөфтилек урынына менәр өчен эшләгән хәрәкәтләре рус вә татар гәзитәләрендә язылды. Матбугатка чыкмаганы хакында тагы материаллар бар. Соңгы көннәрдә булган бәгъзе бер арестларны шул мөфтилек мәсьәләсенең бер йимеше дип сөйләнелә. Фракция шул хакта допрос ясамыймы, диелде. Котлыкай мирза, җавап биреп, «Мөфтилек мәсьәләсе хакында фракциядә материал күп, ул хакта тәшәббестә булыну хакында фракция әгъзалары арасында ихтиляф юк. Фракция бу мәсьәләдә кулыннан килгәнне эшләячәк. Ләкин әле хәзер запрос ясаумы, башкача кузгатумы мәсьәләсе хакында ачык җавап бирә алмыйм. Арестларның мөфтилек берлән мөнәсәбәте булса, мәсьәлә башка төс ала. Бездә рус

депутатлары да рухани бер мәнсабны донос урыны ясарга разый түгелләр» мәалендә җавап бирде. Шуннан соң мәсьәлә икегә бүленеп китте. Берсе — идарәи руханиямезне ислях хакындагы ляихәне тиз өлгертеп, кирәк, булган идарәи руханиямездә, кирәк, булачакларында (мәсәлән, кыргызларда) мөфтилек мәнсуби сайлау берлән булсын дигән принципны кабул иттерү.

Бу мәсьәләне ашыктыру ляземлеген Кырым вәкилләре дә сөйләделәр. Аларда да мөфтилек мәсьәләсе, бездәге Баязидов мәсьәләсе кебек үк булмаса да, шулай булырга хәзерләнеп тора. Шуның өчен мөфти мөселманнардан сайлансын дигән бөтен мөселманнарның теләген тизрәк закон хәленә китерелсә иде. Шуның аркасында төрле департаментлардагы мөселманнарның әмәлен, гарызын сатып көн күрүче сатлык писарьләргә пакь рухани мәнсабларны былчыратырга юлны каплыйсы иде, диелде.

Икенче — хәзерге Идел буенда мөфти булып утыртылган Баязидов хакында.

Моның хакында киңәш мәҗлесендә сүз бик озайды. Аларны язып утыру стратегически яктан мәслихәт булмаганга ябык калдырыла. Ләкин арада Баязидов калсын инде дигән бер зат та булынмады вә фракция катгыян шул мәсьәләне Дума минбәреннән ачарга булуын вәгъдә итте.

Мәҗлес шуның берлән тәмам булды*. Киңәш мәҗлесләре бетте итеп игълан ителде.

## МӘСКӘҮ, 26 ФЕВРАЛЬ

Якшәмбе көн[1] Әсәдуллаев бинасының залында Мәскәү «Җәмгыяте хәйрия»сенең еллык мәҗлесе булып үтте. Шәрекъ ысулында зиннәтләнгән мөселманнарның үзләренең залында үз эшләрен караулары никадәр күңелле, шатлыклы эш икәнен сөйләп торасы да юк инде. Бинаның мәһабәтлеге, залның зурлыгы безнең мәдәни юлга керүенә ун ел гына тулган татарларны гына түгел, ике йөз ел элек башлаган полякларны, русларны да һаваландырмаслык түгелдер. Без дә эчемездән һаваланып, шундый зур бинамызның булуына кәефләнеп, мәҗлес ачып, мәҗлес дәвам иттердек. Ләкин шул бинаның эчендә сөйләгән сүзләр, беренче мәртәбә татар исеменә итеп эшләнгән мәдәни эшләр бинаның газамәтенә, залның биеклегенә нисбәтән бик кечкенә булды. Иң күп сөйләнгән сүз кыйраәтханәне — Мәскәү кыйраәтханәсен алып барырга бирелгән акча исраф булмасын, тотылган расхуд үзенең капиталына җитәрлек табыш бирми калмасын даирәләрендә йөреде. Бөек милли әмәл берлән салынган олуг залда, мәгаттәәссеф, Мәскәү мөселманнарының бердәнбер китапханәсенең китап алуына алты йөз сумлык акча тәгаенләүне күпсенгән вак фикерләр сөйләнде. Мәгаттәәссеф, олуг бинада олуг мәҗлестә шундый кечкенә бер тиен, ике тиенлек файда мәсьәләсе мәҗлеснең кадерен югалтты. Мәскәү мөселманнары һәммәсе дә сәүдәгәрләр булгач, әлбәттә, һәрбер эшкә табыш-ярыш ягыннан караулары табигыйдер. Бу һичбер төрле тәнкыйть ителерлек сыйфат түгелдер. Ләкин кешеләрнең зур әмәлләр алдында шәхси мөнәсәбәтләрен онытып җибәреп, бәгъзе матур хәрәкәтләр ясаулары да яшьлек, тазалыкны күрсәтә торган табигый сыйфат кынадыр. Кирәк булганда, бик аек булган булып, бер тиен, ике тиен берлән сатулашу, үзенә-үзе ышанмау — картлык-зәгыйфьлек галәмәтедер. Кешенең акчага сак булуы никадәр табигый булса да, кыз катына кергән бер егетнең зәүкъ-сафа вакытында бертуктамаенча кесәсен капшап, «кәләшем сыпырмасын» дип янчыгын саклавы — ваклыктыр, пислектер.

Шуның өчен, шул матур залга кияү кебек бизәнеп, ясанып беренче мәртәбәләр кергәндә, милли юлга йөз меңнәр сарыф иткән Шәмси аганың[2] рухы «кесәмә керәләр» дигән куркуны оныттырган булса, нинди матур, нинди күңелле булыр иде.

Менә шул ваклыклар, куркулар, табигый, күңелгә «Шул зур бинадан кирәгенчә файдалана беләалырсызмы?» дигән куркуларны төшерде. «Җәмгыяте хәйрия»нең хисабы вакытында бик күп әгъзаларның үзләренең милли вазифаларын үтәмәүләре, «Бу зур мәктәп бинасы, бу зур зиннәтле зал буш булып калмасмы? Шул зур мәктәп, шул зур зал эчендәге мәдәни бушлык мәрхүм Шәмси аганың рухына үзенең суык сыкравын җибәреп тормасмы?» дигән икеләнү күңелдән китмәде.

Алла бирсен дә шул шөбһәләнү вөҗүдкә чыкмасын, мәктәп шауласын, залның эче милли, мәдәни эшләремез берлән шыгрым тулсын. Ләкин менә бу дога элгәреге заманда, әүлиялар, шәехләр күп вакытында, бәлки, бу доганың кабул булуы өчен ихлас берлән җинане Барига кул күтәрү генә җиткәндер. Әллә кайдан төрле фәрештәләр, пәриләр килеп таулар-ташларны актаргандыр, мөселманның теләген тутыргандыр.

Ләкин хәзерге гөнаһлы гасырда мөселманның догасы кабул булсын өчен, мөселманның теләген Аллаһы Тәгалә булдырсын өчен, мотлакан, кемнәр дә булса эшләргә тиештер. Арымаенча, талмаенча, матди, мәгънәви көчен аямаенча эшләргә тиештер. Мөселманның юлына тискәре чыга торган һәртөрле базар-чокырларны курыкмаенча үтеп эшләргә тиештер.

Менә Мәскәүдә, мәгаттәәссеф, шул эшче элемент өлгермәгән. Мәгаттәәссеф, шул эшчән халык өлгерергә юл да куймаган. Мәгаттәәссеф, Мәскәүдә җәмәгать исеме Син, Мин, Әмин Дәмин, Мөхәммәт

Әмин эшләү берлән генә була дигән аксиома әле канга сеңмәгән. Мәскәүнең, тарихи Мәскәү мөселманын шул садака алуның хурлыгын аңлатырлык итеп тәрбия итмәгән. Аның бае-ярлысы «садака» алып килгән.

Мәрхүм Ерзин[3] Мәскәү мөселманнарына садакадан мәсҗед салдырган, аны садакадан елыткан. Мәрхүм Әсәдуллаев аларга садакадан мәктәп салдырган. Анда укыткан.

Әле тап-таза, исән Мәскәү җәмагать карты Хөсәен хаҗи Байбиков «Җәмгыяте хәйрия»гә өйрәтер өчен аларны садакадан җыеп сыйлаган вә һакәза, вә һакәза.

Менә шуларның барысы да Мәскәү мөселманнарында — баенда, ярлысында файда иткән елында, зарар иткән чагында бер психологический сызык сызган, ул да — Мәскәү мөселманына әллә кемнәр матди, мәгънәви эшләр эшләргә тиеш, тиеш кенә түгел, әллә кемнәр аның дини, милли ихтыяҗларын үтәргә тиеш. Ул әллә кемнәрнең бурычлары, Мәскәү мөселманнары алдындагы бурычлары.

Менә шул ноктадан караганга, әллә кемнең килеп эшләвен көтеп торганга, Мәскәүдә булуы фарыз дәрәҗәсендәге эшләр клуб «күңел»дә тора.

Менә шул ноктадан эшне йөрткәнгә, шул Әсәдуллаев бинасы мәктәбе кылга гына эленеп тора. Шул ук әллә кемгә терәлеп торганга, Мәскәүдә һичбер төрле мәдәни эш эшләнми. Һичбер төрле мәдәни хәрәкәт Мәскәү мөселманнары тарафыннан башланылмый, эшләнелми.

Алар көтәләр.

Алланың рәхмәтен, Җәбраил фәрештәнең килеп эшләвен, Яхъя мулла пәриләре[4] дошманнарын җиңүен, мөселман җеннәре Мәскәү мөселманнарының йөзләренә ак китерерлек хәрәкәтләр ясауларын көтәләр. Бик ихлас берлән алар эшләгән эшне кабул итәргә хәзерләнеп көтәләр. Тагы садака алырга кулларын сузып көтәләр.

Изге көчләр, килеңез!..

## «ЙОЛДЫЗ»ГА СОҢГЫ ҖАВАП

«Йолдыз» гәзитәсенең унъеллык юбилейсына каратып язган фельетоныма[1] «Йолдыз» тарафыннан контр һөҗүмнәр ачылды. Һади әфәнде Максуди, үзенең бөтен көчен бер йиргә җыеп, минем өстемә ташланды[2]. Бөтен әтрафтан урыным, халкым алдында тоткан вазгыятем «Йолдыз»ның бөтен коралларыннан һөҗүменә мәгъруз калды.

«Йолдыз» үзенең атлый, җәяүле, ачыктан һөҗүм итә, гизле көенчә удар ясый торган бөтен гаскәрен сәфәрбәрлеккә китерде. Тугрыдан мәкалә язды. Кечкенә фельетон белән астан керде[3]. Фәнни тәхлилат ясап, шул мәсьәләнең төп ягыннан сәбәпләрен тикшерде. Минем икътисади хәлләремне иҗекләде.

Укучыларга «Әһә, Һади әфәнде нинди һөҗүм башлады, ядрәләр берлән күмде бит, менә тик тору кирәк иде» дигән тойгыны калдырырга тырышты. Шуның саясендә минем «Йолдыз» милли хулиганнар тудыручы, вак донослар ясаучы, очсыз тарифа берлән файдалана белер дәрәҗәдә әминият казанган» дигән тамгаларымны оныттырырга маташты, тырышты, шау-шу күтәрде, тузан очырды.

Минем әдәби әсәрләремнең элгәре китапчылар тарафыннан бастырылып, соңгы елларда нәшерләрен үз өстемә алуым[4], минем унсигез елдан бирле каләм берлән эшләп килсәм дә, Һади әфәнде кебек, үземнең ишәгем, үземнең фәйтуным булып устроиться итә алмавым, тагы, белмим, ниләр-ниләр минем йөземә гаеп итеп бәрелде, ыргытылды.

Тузан куптарып, «Йолдыз»ның йөзендәге ачылган караны каплар өчен ясалган шул маневрларга пәкъ эчтән көеп, вөҗданән чыдый алмау төсен бирер өчен, үзенең «кычкырыш осталары» — ике йөз егерме «Йолдыз» мөхәррирен ярдәмгә чакырды[5]. Шул ике йөз егерме кешенең намусларын мөхафәзә байрагын күтәрде.

«Сүз»нең «Йолдыз»га суккан кара тамгасын «бу безгә генә түгел, «Йолдыз»га гына түгел, бу безгә, барымызга да — «Вакыт»ка, «Тормыш»ка, «Кояш»ка, «Тәрҗеман»га, «Казан мөхбире»нә — һәммәмезгә дә дип күрсәтмәкче булды. Ягъни һәммә милли органнарга, космополитларның дошманлыклары дип, милли гәзитәләремезнең ак күләгәсе астында кара йөзен яшермәкче булды.

Ләкин шул һөҗүмнәр, шул маневралар тагы мескин «Йолдыз»ның бөтен вазгыятен ачып кына бирде.

Ике йөз унтугыз мөхәррирнең намусын сакларга чыккан «Йолдыз»ның баһадиры саламнан ясаган кылычы берлән селкенеп торганда, артында җиңеләйтелгән тарифа берлән почтага җибәрер өчен, «Йолдыз» номерлары төялгән «Йолдыз» ишәгеннән башка матбугатта үзенә бер иптәшне күрә алмады (билгакес, ике йөз унтугыз «Йолдыз» мөхәрриренең сигезенчесе, тугызынчы иттерелеп күрсәтелгән мөәррих Зәки Вәлиди берлән мөнәкъкыйд Нәҗип Гасрыйның[6] минем ноктаи нәзарым берлән тәмамән бер фикердә икәнлекләрен күрсәтә торган мәкалә вә мәктүбләре идарәмездә сакланадыр).

Нә хәзерге милли гәзитәләремез «Йолдыз»ны каралту — безне каралту, «Йолдыз»ның җил кайдан өрә, шунда таба китүе — ул безнең «милли барышымыз» дип «Сүз»гә каршы чыкмадылар, нә иске гәзитәләрнең язучылары, мохлисләре «Йолдыз»ның бәйрәмендәге Камали бутышник юбилейсыннан алынган тәртибаты «Йолдыз»ның юбилейсында сөйләнгән мактауларның нинди милли урамнардан алынып китерелгәнлекләре хакындагы сүзләремезгә «бу да безне тәхкыйрь ителгән, безнең намусымызны таптау» дип мәйданга атылмадылыр. Чөнки һәммәсе, һәммә милли гәзитәләр, һәммә милли кешеләр, бу мәсьәләдә төрле сәбәпләрдән фикерләрен ачык әйтә алмасалар да, безнең берлән бергә иделәр. Чөнки боларның һәммәсенең дә «Йолдыз» вилласында ясалган милли хулиганлык алдында күңелләре сыкраган, милли намуслары тәхкыйрь ителгән иде.

Менә шуның өчен «Йолдыз»ның минем хосусый тормышым, минем әдәби хезмәтем, гәзитә вә журналлар төзүдә иткән мәшәкатьләрем, Себергә җибәрелүләремә[7], төрле-төрле мәальдә, төрле тормыштан хикәяләр язуыма ясаган һөҗүмнәре вә минем берлән шул мәсьәләдә бер фикердә икәнлегене ап-ачык әйтеп мәйданга чыккан Мәхмүтфуад әфәнденең яшенең ничәдә булу хакындагы фал ачулары — һәммәсе дә буш куык булды да калды.

«Йолдыз»ның күтәргән тузанын беренче милли йил себереп ыргыткач та, кулын йомарлап, тешләрен шыкырдатып торучы «Йолдыз»ның бөтен сәфәрбәрлек хәленә китерелгән кораллы гаскәре башы-аягы берлән күренде. Болар Һади әфәнде Максуди, без — «Сүз» берлән моназарә кылышканда дигән гонванын күтәрү өчен, батып үзенең сөйләгән сүзләрен ачыктан язарга ышанмаган, үзенең эшләгән эшләре кулын пычратудан әмин булмаган «Йолдыз» чүпрәге астына сыгынучы «йолдызчы» әфәнделәрнең өчесеннән гыйбарәт[8] булды да калды.

«Йолдыз»ның үз дәгъвасынча, мәсләгендә иштиракь иткән затларның ике йөз унҗидесе милли гәзитәнең мәгънәви хәле шулкадәр авыр чагында читтә торды да калды.

Шул шаудан соң «Йолдыз» гәзитәсенә минем куйган тамгам кырылдымы? Минем фельетоныма күрсәтелгән «Йолдыз»ның гаепләре, ичмасам, берсе генә дә юылдымы?

Вак доносчы дигән гаепләвемне Һади әфәнде үзе икърар итте түгелме? Дөрест, ул минем сүземне тәфсир итте, иҗекләде. Без алай дип әйтмәгән идек, имлясы башкача иде, диде. Үзеңез дә оныткансыз, «Тавыш» мөхәррире Габдулла түгел, Гариф Биккинин иде, диде[9].

Ләкин бит гыйбарәнең бер булмавы берлән асыл мәсьәлә дә үзгәрми.

Шул доносның «Йолдыз»да булуын бит Һади әфәнде үзе икърар итте.

Шуннан соң Хөсәен Әбүзәров һәм дә Кәримов типографиясенең мөдире учитель Габделмәннан әфәнде хакында судка бирелгәнлекләрен[10] тәкзиб итә алмады. Чөнки болар — фактлардыр. Судтагы кәгазьләрдә ничек иттереп «Тавыш» хакында гаепләнү башланганы ап-ачык язылган фактлардыр.

Тагы «Йолдыз»ның 1601 номерындагы «Йолдызчы» имзасы берлән язылган фельетонындагы минем сәяси фикерем хакында жирный хәреф берлән әллә кемнең дикъкатен җәлеп итәргә маташуы[11] көчсез хәрифнең вак доноска тотынуы түгелме?

Тарифа[12] хакындагы минем гаепләвем дә икърар ителде.

Һади әфәнде: «Юк, безнең гәзитәмез «Вакыт», «Тәрҗеман», «Кояш», «Тормыш», «Сүз» гәзитәләре кебек нормальный почтовой тарифа түли», — дия алмады.

Ул үзенең Петроградка баруында, мөхтәрәм Молчанов берлән сөйләшеп[13], «Йолдыз»ны җиңел тарифага күчертә алуын икърар итте. Минем әйткәнем дә шул иде.

Моны мин хөкүмәт тарафыннан субсидия алу дип әйтмәдем. Ләкин «Тәрҗеман», «Вакыт», «Тормыш», «Казан мөхбире», «Азат халык», «Азат», «Ил», «Сүз», «Икъбаль», «Иршад», «Хәят», «Икъдам», «Ачык сүз» гәзитәләренең һәммәсен дә почтовой тарифага керткәндә, русларның тәрәккыйпәрвәр гәзитәләре «Русские ведомости», «Русское слово», «Речь», «Дон» гәзитәләренә ияртеп йөртеп нормальный тарифа (елына бер сум егерме тиен) алалар да «Йолдыз»ны «Новое время» язучыларыннан хөрмәтле Молчановның чыгарган гәзитәсе «Петербург» алардан ким түгел, хөрмәтле доктор Дубровинның чыгарган «Русское Знамя»сы вә башка карагруһлар гәзитәләре[14] берлән бергә тиңләштереп очсыз тарифага кертәләр.

Моның зур бер сәбәбе булырга кирәк түгелме?

Шуның сәбәпләре «Йолдыз»ның юбилейсында сөйләнелгән нотыклар, «Йолдыз» зыяфәтенә чакырылган кунакларның спискасы берлән беленә төшмиме?

Тагы шул сүзне озайтып торганчы, ник соң Һади әфәнде, «Йолдыз» менә бер әбүнәдән фәлән кадәрле тиен түли дип кырт кисми?

Онытылмасын әле, Закаспийский область төрекмәннәре арасына «Вакыт», «Тормыш», «Тәрҗеман» вә башка татар гәзитәләре кертелмәгәндә, ни өчен «Йолдыз» гәзитәсе генә тоткарсыз керә ала иде? Моның да сәбәбе бар түгелме?

«Йолдыз» баһадирларының күтәргән тузаннары минем «Йолдыз» өстенә ыргыткан бер генә гаепне дә арулап бирмәгәнгә, мин һаман әүвәлге фикердә калам.

Һаман Алладан «Йолдыз» кебек «милли органнар»ның дәвамына мәсагыйд булган мохитне пакьләргә дигән догамны кулымны төшермәенчә кылам. Татарның бөтен ак-пакь кыйсеме шул догада, минем берлән бергә дип, мәгънән, батыраеп кылам.

## КЫРЫМ РУХАНИ ИДАРӘСЕНДӘ МӘКТӘП-МӘДРӘСӘ МӘСЬӘЛӘСЕ

Безнең Русия мөселманнарының мәдәни мәсьәләләренең иң авыры мәктәп-мәдрәсә мәсьәләсе икәне мәгълүмдер. Шул мәктәп-мәдрәсә эшләре берлән Идел буе татарлары — без унбиш елдан бирле уграшамыз. Ислях, димез, тәртип, программа, димез, дәрес китаплары сайлау, имля мәсьәләсене хәл итү, димез, шулар хакында гәзитә вә журналларымызда моназарәләр ачамыз, комиссияләремездә эшлимез. Мөгаллимнәр җәмгыятенең 6 нчы елдагы булган Казандагы съездында мәктәпләр өчен бер программа да кабул иткән идек. Аннан соң төрле шәһәрләрдә, төрле мөселман җыелган урыннарда бер генә түгел, әллә ничәшәр киңәшләр булып үтте, һәммәсендә дә төрлечә карарлар кабул ителде. Ләкин уку-укыту эшен юлга салырга муафикъ булынылмады.

Үткән ел, Уфа земствосының чакыруы буенча, егерме биш-утыз кешеле мөтәхассыйсларның кыйраәт китаплары сайлау, имля эшләү хакында киңәшләре булды. Шундагы мөтәхассыйслар земствоның ибтидаи мәктәпләре өчен кирәкле китапларны сайлап, бөтен мөгаллим-мөгаллимәләргә үрнәк күрсәттеләр.

Шул көннәрдә Оренбург земствосының мөрәҗәгате берлән Уфа земствосы мөселман мәктәпләренә гам бер программа төзер өчен вилаятьләрендә мөселман булган земстволардан мөселман мөтәхассыйс вәкилләр чакырып, зур бер съезд ясый дигән хәбәрләр язылды вә шул эшнең фагыйлиятькә чыгуы хөкүмәтнең рөхсәтенә генә баглылыгы беленде. Иншалла, җәйгә шул съезд булып, Идел буе мөселманнарының ибтидаи тәгълимнәренә яраклы бер программа ясап бирер.

Бу мәктәп-мәдрәсә мәсьәләсе Кавказ кардәшләремездә бик кызу дәверен кичерде. Анда да мәктәп-мәдрәсәнең хәле пәришан икәнлеге игътибарга алынып, Тифлистә учительләр, мөгаллимнәр, җәмәгать хезмәтчеләренең съезды бу ел гына булып алды, вә Кавказ наместнигының кушуы буенча хәзер мәктәп-мәдрәсәләргә программа эшләнә башлады.

Ничек булып чыгар?

Кавказ мөселманнарының дини, милли ихтыяҗларын үтәрлек булырмы?

Безнең Идел буена үрнәккә алырлык булырмы? Киләчәк күрсәтер.

Хәзер инде кизү Кырымга килеп җитте.

Безнең Идел буенда мәктәп-мәдрәсә исляхы фикере кырымлы, бакчасарайлы Исмәгыйль баба Гаспринскийның исеме берлән баглы булганга, Кырымдагы мәктәп-мәдрәсә исляхы хәзер кизүгә куелды, дигән сүз гаҗәбрәк тоелыр.

Безнең Идел буе халкына мәктәп-мәдрәсә исляхы иң әүвәл Кырымда беткәч кенә, Исмәгыйль баба безгә дә нурын җәйде кебек аңлана иде. Ләкин бу — хата. «Һичкем иле́ндә пәйгамбәр булмый» дигән мәкаль Исмәгыйль бәк хакында да дөрест чыкты. Идел буенда мәктәп-мәдрәсә исляхының бабасы дип танылган Исмәгыйль баба — Идел буенда биш мең ибтидаи мәктәп ачылуга мәгънәви остаз булган Исмәгыйль баба — үлмәс борын, Кырымда рәтләп танылмады. Җеназасы күтәрелмәс борын, Бакчасарайның яры астында бөтен Русия мөселманнарының мәдәни остазлары ятканы бөтен ислам галәмендә сизелсә дә, Кырымда беленмәде. Шуның өчен аның мәктәп-мәдрәсә исляхы дигән фикере бөтен Идел буена, Кавказга, Төркестанга, Мисыр, Һиндкә, Иранга тәэсир йөртсә дә, Кырым мөстәсна булып калды. Мәхәлләсендә Зынҗырлы мәдрәсәсе генә дә аның уе, фикере берлән файдалана алмады.

Менә моннан утыз ел элек мәктәп-мәдрәсә исляхы дигән, Кырымнан киң Русиягә сәяхәткә чыгарып җибәрелгән фикер Кырымга әйләнеп кайтты. Айның кояш әтрафында ясаган дәвере кадәр вакыт үткәреп, бер дәвер ясап кайтты. Бу Кырым егете чит илләрдә йөри-йөри үзгәргәнме, әллә ул егет Кырымнан киткәндә Кырымның агалары, мирзалары, какилары, голямалары, әһелиясе йокыда булганда, төсен-битен күрми калганнармы — аны яңгы кеше итеп каршы алдылар.

«Ислях әфәнде» килгән!

Ишек кага!

Сәлам бирә...

Боерсаңыз!

Кырымның Духовное управлениесе шул яңгы кунакны каршыларга 23 февральгә галиләрен, мирзаларын, агаларын чакырды. Шул яңгы кунак моннан элек Кырымның Бакчасарай шәһәреннән, кыя

астыннан чыгып киткән Исмәгыйль бәк Гаспринскийның тумасы Кырымның үз углы икәнен ул хәтеренә дә китермәде. Күңел өчен генә дә шул «Ислях әфәнде» мәҗлесенә Исмәгыйль бабаның «Тәрҗеман»ыннан карарга гына да кеше чакырмады.

Мәсьәлә анда түгел. Исмәгыйль баба төрек-татар милләтенә иткән хезмәтен «мине онытмаңыз» дип эшләде, «Ислях» дигән углы үз йортына, үз иленә кайткач, үзе мәрхүм булгач булса да кайткач, әлбәттә, аның җаны рәхәтләнәчәк, сөенәчәк, кабереннән торып, зур күзләре берлән Кырым мәктәп-мәдрәсәләренә «бакышлар» җибәрәчәк.

Ләкин бит ул Кырым Духовное управлениесенә яңгы туган булып килеп кергән «Ислях әфәнде» утыз ел элек, тугач та, безнең Идел буена очып килгән иде. Ул бездә үскән иде, һавада очып йөри торган хәлдән чыгып, бездә гәүдәләшкән иде, бездә балигъ булган иде. Аның Кырымга хәзер тәпи-тәпи барып кергән аяклары бездә ныгыган иде. Шуның өчен Кырым зыялыларының, мирзалары, агаларының, голямаларының шул «Ислях әфәнде»нең бабасын инкяр итүләренә безнең кәефемез китәргә хакымыз бар.

Кырым мәктәп-мәдрәсә исляхы мәсьәләсе мөзакәрә ителгәндә, шул исляхның бабасы Исмәгыйль бәкнең икенче углы «Тәрҗеман»ның мәҗлескә чакырылмавына... [*Бер абзац бозылган, өстенә кәгазь ябыштырылган. Укып булмый.*]

Исмәгыйль баба онытылса да, ислях керде. 23 ендә утызлап мөселман алдында мәктәп-мәдрәсә исляхы мөзакәрә ителде.

Ибтидаи мәктәпләр юк авылда да яңгыларны ачарга, барларын ислях итәргә, бөтен мәктәпләргә бер программа кабул итәргә карар чыгарылды.

Аның берлән генә калмады, мәдрәсә мәсьәләсенә дә тиелде. Аның «Гавамил» укыла торган пустханәләре[1] уку йорты булырга тиеш табылып, аларны да милләт, дин мөхафәзәсе өчен кирәкле хезмәтләр итәргә чакырылды.

Голяма, мирзалар, агаларның киңәшләрендә мөдәррисләр, мөгаллимнәр чыгарыр өчен ибтидаи мәдрәсә (дөресте, дарелмөгаллиматлар), имамнар, хатиблар чыгарыр өчен мәдрәсәи рөшдиләр, казыйлар, мөдәррисләр чыгарыр өчен мәдрәсәи галиләр дигән өч кыйсемгә бүленергә мәслихәт ителде. Шул бүлекләрнең һәммәсендә дүртәр ел укып, унике елда тәмам итәргә карар ителде.

Программасына фөнүне җәдидә кертү, русчаны гимназияләрдәге кадәр укыту да кабул ителде.

Бу кабуллар принцип уларак кына булганга, шуларны эшләп бетерер өчен махсус комиссия сайланылды. Аның берлән генә дә калмады, мәктәп-мәдрәсәләрне карар өчен калдырылган вәкыф мәсьәләсе мөзакәрәдән үтте. Шул вәкыфтан кирәгенчә файдалана белүне тикшерү өчен үзенә махсус вәкыф комиссиясе аерылды. Әлбәттә, әле бу мәҗлестә бер эш тә пешмәде. Без, Идел буйлары, андый мәҗлесләр берлән билфигыль хезмәт арасында ничә вә ничә еллар үтәргә лязем икәнен тәҗрибәләр берлән белгәнгә, Кырымда мәктәп-мәдрәсә мәсьәләсе ислях ителде дип кабул итмимез. Алай да шул киңәшләре берлән Кырымда мәктәп-мәдрәсә мәсьәләсенең исляхы башланды дип сөенүдән тыела алмыймыз.

Әлбәттә, бу принцип уларак кабул ителгән әсаслар тормышка татбикъ ителгәнчә бик күп сулар агачак, бик күп көннәр, айлар, еллар үтәчәк. Ләкин бер кергән ислях уе Кырымнан кире китмәячәктер. Кырымда мәктәп-мәдрәсә исляхының матди ягы безнең Идел буеның хәленнән уңгайрак. Кырымда мәктәп-мәдрәсә, мәсҗед өчен калдырган бик күп вәкыфлар бар.

Боларның йире генә 63 нче елга кадәр 250 мең дисәтинә иде. Кырымлылар Төркиягә һиҗрәт иткәнгә вә башка тәртипсезлекләрдән бу вәкыфлар бик азайды. Хуҗалык итәргә тиеш булган идарәи руханияләре бер эш эшләмәгәнгә, вәкыф йирләрнең бик күбе тар-мар килде. Муллалардан сатып алган булып немесләр утырды. Дачалар салынды, ахырга таба вәкыф комиссиясе дигән бер комиссиянең кулына хөкүмәт тарафыннан тапшырылды. Ләкин вәкыф комиссиясенең дә шул вәкыфтан мәктәп-мәдрәсәгә тоткан еллык сумасы үзенең түрәләренең еллык жалунияләреннән аздыр.

Сугыш башлангач та, вәкыф комиссиясе лазарет ачарга Красный Крестка[2] туксан мең сум акча бирде (Вакытлы мөселман комитетына да бирергә булган кебек иде, бирүе мәгълүм булмады).

Шуның өчен вәкыф эшләре ислях ителсә, Кырым кардәшләремезнең мәктәп-мәдрәсә мәсърафлары тәэмин ителгән булачактыр.

Киңәш мәҗлесләре йирле губернаторның рөхсәте берлән эшләнде. Рәислек иткән казый әфәнденең сөйләвенчә, шунда кабул ителгән программалар, губернатор аша мәгариф назыйрына җибәрелеп, тасдыйк ителәчәк, имеш. Әлбәттә, бу тасдыйк мәсьәләсе ул кадәр тиз һәм дә министр тарафыннан болай да бүгенгенгә иртәлек эш түгелдер. Һәм дә Думадан читтә тасдыйк ителүе дә шөбһәледер. Тугрысы, кырымлыларның шул әсаслары мәгариф нәзарәтендә материал булып, мәктәп-мәдрәсә хакында закон эшләнгәндә, мөселман фикеренең нәмунәсе булып торачактыр. Яисә мөселман фракциясенең ляихәсе каралганда, мәгариф назыйрының портфелендә җавап изахка кирәкле фикер булып торачактыр.

Шуның өчен ясалган комиссияләр, шул мәктәп-мәдрәсә исляхы өчен кабул ителгән принципларны тәфсилләгәндә, бик уйлап, тормышка татбикъ ителә алуларын төшенеп, эшкә керешергә тиешләр. Хәзерге хәлемездә катгыян фәгалияткә чыгара алу ихтималымыз булмаган маддәләр кертелмәскә тиештер.

Мәдрәсәләрдә русча гимназия программасы сыйдырган кадәр укытылсын дигән теләү дога уларак кабул ителсә дә, эшләп чыгарыр өчен була торган эш түгелдер. Чөнки шул теләүне тудырыр өчен мәдрәсәләрдә түгел, бер мәдрәсәдә генә дә русчадан гимназия дәресләренә мөгаллимлек итәрлек хәзер кешеләремез юктыр. Тиздән булачак та түгелдер.

Тагы принцип уларак дини мәдрәсәләремездә ни өчен русча дәресләрнең гимназия программасы сыйдырган кадәр улуы кирәк?

Безнең голямамыз өчен русча белү, русча фәнни, дини әдәбияттан файдалана белер дәрәҗәдә русчасы лязем икәнен тасдыйк итсәк тә, гимназия программасы кадәр русча укытуның лөзүме бар диеп уйламыймыз. Билгакес, моның катгыян дини мәдрәсәмездә кирәге юк, дип игътикад итәмез.

Дини мәдрәсәмезнең киләчәк программасының нигезенә дини, фәнни мәсьәләләр куелып, русча тел фәкать мәгълүмат җыяр өчен корал иттереп куелырга тиеш дип ышанамыз. Әлбәттә, комиссиянең әһле гыйлеме дә, карар берлән билфигыль эш арасында ничә мең фәрсәх мәсафә барны белгән затлары, фән-тәрбия мөтәхассыйслары безнең кадәр генә белә торганнардыр.

[Комиссия әгъзалары] «Ислях әфәнде»не күргәч тә, бердән «кып-кызыл» булып китеп, мәдрәсәләремезнең тарихи ганганәләреннән азат булган киңәштәге затларның бу карарлары, озын төшенчә фикер берлән түгел, хис берлән исляхка гыйшыктан эшләнгән эшләр икәнен белә торганнардыр.

Шул ислях принципларын тормышка татбикъ ителерлек эшләнүен Кырым зыялыларыннан көтәмез. Кардәшчә дога кылып көтәмез.

## * * * (ТАГЫ «СЫЙРАТЕЛ-МӨСТӘКЫЙМ» БАШ КҮТӘРДЕ...)

Тагы «Сыйрател-мөстәкыйм» баш күтәрде. Тагы милләтнең нәфрәтен казанган кара көчләр үзләренең кара уйларын татбикъка вакытны мөсәгыйд таптылар. Тагы милләтнең җаны, рухы, бөтен мөкатдәс идеаллары бер хәтәрле хәлгә килде.

Бу көн, иртәгә аның ныгып бетмәгән мәдәни сафлары һөҗүмгә мәгърүз калачактыр. Бу көн, иртәгә аның берегеп бетмәгән милли көчләре читке кара көчләргә арка таянган монафикълар тарафыннан мәйдане хәребка чакырылачактыр. Бу көн, иртәгә милләтнең бөтен тамырларына агу йибәреп, аны зәһәрләү башланачактыр.

Унбиш-егерме елдан бирле бөтен милләтнең каһарман көчләре берлән тәрбияләнеп килгән, бөтен милләтнең пакьләренең аклыгы берлән сафлыгы сакланып килгән милли мәдәниятнең аклыгы, пакьлеге берлән мөнтазам тартышу башланачактыр.

Аның үзегенә агулар — аның табигый үсүендәге эчке көчен бетерер өчен Алланың биргән һәр көнендә тамчы-тамчы агу тамызыла башланачактыр.

«Сыйрател-мөстәкыйм» тагы туа.

«Сыйрател-мөстәкыйм»дәге ходайсызлар тагы милли кяферлекләрене таратырга тотыналар. «Сыйрател-мөстәкыйм» янына җыелган бөтен ходайсызлар тагы милли хисемезне былчыратырга, милли намусымызны аяк астына таптарга тотыналар.

Хәлемез хәтәрдә!

Бөтен милли көчемез хәтәрдә!

«Сыйрател-мөстәкыйм» тагы туа...

Ул бу юлы матди мәнфәгатьләргә бөтен мазыйсы, киләчәген сата торган яшь көчләрнең, сатылып алынган фәхешнең йимеше, милли фәхеш баласы булып мәйданга килә.

Ул фәхеш баласылыгын яшерер өчен матур ат берлән «Ислам вә мәгариф» исеме берлән мәйданга чыга.

Элгәреге битен-йөзен яшерер өчен, үзенең төп атасы департаментлар, Байрашовларны оныттырыр өчен, моңганчы пычрак хезмәтләрдә булмаган кешеләрнең аркасына таянып, татар дөньясына чыга.

Элгәреге тактикасыннан зарар иткәнен күреп, бәүлис [полиция] юлы белән хәрәкәт итәргә булып чыга.

«Сыйрател-мөстәкыйм» яңадан мәйдане мөбарәзәгә чыга...

Яшь көчләр берлән ачыктан-ачык, баһадирларча сугышыр өчен түгел, итәк астыннан хәрәкәт итеп, бөтен милли эшләремезгә аяк чалырга булып чыга.

«Сыйрател-мөстәкыйм» ислам, мәгариф пәрдәсенә өретелеп, моңганчы исемнәрен былчыратмаган кешеләрнең хиссиятләренә таянып, үзенең милли мәдәниятемез берлән көрәшен авыз иттермәкче булып, милли легализация булып чыга.

«Сыйрател-мөстәкыйм» милли хулиганлыкның мәркәзе булып, акрын-акрын бөтен көчләрне эчендә эретергә ниятләнеп мәйданга чыга.

Шул хезмәтендә арка таяначак чит кара көчләрнең матди ярдәмнәренә тәмамы белән ышанып эшкә тотына.

Беренче зәһәр тамчы тамачак урынның — Петроградның яшьләре, мөселман укучылары шул милли хәтәрне сизенеп, алдан вазгыятьләрен игълан итәләр.

Алдан ук шул милли фәхеш баласына игълане нәфрәт итеп куялар.

Әлбәттә, бөтен Русиянең мөселманнары, бөтен Идел буеның аңлы зыялылары Петроград департаментларыннан чыккан шул шәйтан таягының яктысы саф мөселманны алдар өчен, юлдан яздырыр өчен дошман көчләр тарафыннан ясалган икәнен белерләр.

Әлбәттә.

Шул шәйтан таягын сабикы садыйк дип күрсәтергә тырышканнарның мазыйлары нинди булса да, хәзерге көндә шәйтанга, иблискә ялчы булмаганлыкларын хис итәрләр, итәргә тиешләр, гакыллары берлән булмаса, җаннары, иманнары берлән хис итәргә тиешләр.

Бөтен көче, гайрәте берлән шул былчырак куллардан үзенең мөкатдәс мәдәниятен, милли хәятының өмиден зәһәрләндертмәскә тиешләр.

Киләчәгенә иманы өчен — бер милләт булып яшәвенә иманы өчен шул ходайсыз кулларны этәргә, ыргытырга тиешләр һәм итәчәкләр.

Чөнки аның мазыйсының мөкатдәс нокталарын мыскыл итәләр. Чөнки аның киләчәгенең иң зур өмиден, милли хәяткa булган өмиден зәһәрлиләр.

Чөнки аның милли иманын урларга, караңгыда килеп, төнлә урларга, дуст дигән булып, ышандырып, әминият казанып урларга хәзерләнәләр.

Чөнки аның кайнар йөрәге, көннән-көн кызу тибә торган милли йөрәге урынына лакей, официант йөрәге куярга маташалар.

Киләчәктә аны мескин, зәгыйфь, куркак, пис итәр өчен бөтен яшь каннарын зәһәрләргә дип ау коралар.

Милли хәятымыз хәтәрдә!

Киләчәккә өмидемез хәтәрдә!

Чөнки бердәнбер байлыгымыз булган милли мәдәниятемез, чөнки бердәнбер арка таянычымыз булган милли намусымыз, чөнки караңгы төндә бердәнбер яктыртучы фонаремез булган милли өмидемез, чөнки суык көннәрдә бердәнбер елытучымыз булган милли иманымыз һөҗүмгә мәгърүз...

Хәйләле, дәссасле чит көчләрдән агу-зәһәр алган дошманның һөҗүменә мәгърүз...

Хәлемез хәтәрле...

Актык милли байлыгымызны, кечкенә мәдәниятемезне йимерергә тырышалар. Актык арка таяначак милли өмидемезне кырып-себереп түгәргә тырышалар, тырмашалар.

Идел буеның авылында, шәһәрендә, кырында, басуында, болынында, яланында ялтырый торган милли нурларымызны, милли иман йолдызларымызны караңгы болыт берлән капламакчы булалар. Киләчәгемезне, нурлы таңы ачылып килә торган милли таңымызны шәйтан падишаһлыгы кебек караңгылыкка батырырга, чумдырырга уйлыйлар.

Бөтен өмидлеләр, бөтен милли иманлылар, аңлаңыз, сезнең һәммәңезнең иң мөкатдәс өмидеңез дошманның зарбәсенә мәгърүз...

Онытмаңыз! Дошман тарафыннан күтәрелгән авыр чүкеч һәммәмезнең милли йөрәгемезгә сугар өчен, милли атәшемезне читләргә чәчрәтеп, бердән сүндерер өчен эшләнә.

Шул алдакчыларның кыланышларына, фәрештә пәрдәсенә төрелергә маташа торган шул шәйтаннарның хәйләләренә алданмаңыз!

Үзеңезнең хисеңез, милли тойгыңыз кушканча, милли өмидеңез янында урын тотыңыз!

Милли иманыңызны, милли өмидеңезне киләчәктә милләт булып яшәргә дигән милли игътикадыңызны, милли җаныңызны саклаңыз.

Хәл — хәтәрдә...

Аек булыңыз!

Тәнемез, тамырымызны ашый торган хулиганлык йөрәгемезгә, милли йөрәгемезгә барып җитәдер.

Аны да ашап, аны да чүп итәргә маташадыр.

Ныкланыңыз!

Шул дошманнарга, шул милли кяферләргә бөтен мәгънәви көчеңезне каршы куеңыз.

Үземезнең мөкатдәс милли байрагымызга, үземезнең милли иманымызга каршы торган шул пычрак кулларга «җигел» дигән батыр боерыкны биреңез!

Милли кяферләр, милли хулиганнар, үзләренең мазыйларын саткан, үзләренең киләчәкләрен шәйтанга рәһенгә салган ходайсызлар, туктаңыз!

Менә безнең чигемез! Нинди генә байрак күтәрсәңез дә, моннан үтә алмыйсыз.

Менә безнең чигемез!

Монда иман бар...

Монда Аллага, монда халыкка, монда изгелеккә иман бар...

Иске милли кяферләр, яңгы милли хулиганнар, карт вә яшь ходайсызлар, җигел! Маташма!

Монда синең хәйләң дә, синең кара көчең дә, синең хәрам акчаң да йөрми торган иман бар. Синең зарбәләреңдә ватылмый, чәчелми торган иман бар...

Җигел, мәлгунь!

## ТАГЫ «СЫЙРАТЕЛ-МӨСТӘКЫЙМ»

«Сыйрател-мөстәкыймче»ләр тарафыннан «Ислам вә мәгариф» дигән орган чыгарырга хәзерләнү тагы әфкяре гомумияне галәянга китерә. Ни дип аңлыларымыз шуны суык канлылык берлән генә каршы алмыйлар.

— Чыга икән, чыга шул. «Ислам вә мәгариф» исемендә булып чыгамы? Әллә «Сыйрател-мөстәкыйм» исемендә килеп утырамы? Әллә бер дә уйланмаган яңгы бер исемдә мәйданга киләме?

Әллә иске «Нур» гына җанландырыламы?..

Монда нинди искиткечлек бар?

Менә башка гәзитәләр, журналлар чыга бит, ник соң шуның янында тавыш күтәрелми?

«Тәрҗеман» гәзитәсе 33 ел чыгып килә, «Вакыт» 10 ел чыкты, яңгы гәзитәләрдән «Тормыш» былтыр гына чыкты, «Сүз» быел гына мәйданга килде, боларның берсе дә бит мондый шау-шу куптармаган иде.

Ник соң «Сыйрател-мөстәкыйм» генә, «Ислам вә мәгариф» кенә шулкадәр тавыш чыгара?

— Сезнең гәзитә чыгарырга, үз фикерегезне таратырга хакыңыз булган шикелле үк, сез әллә Сафа мулланың[1], Фатих Байрашовның[2], Хаҗи Теләшинең[3] фикерләрен таратыр өчен үз органнарын чыгарырга хакларын инкяр итми торгансыз?

«Вакыт» гәзитәсенең үз фикерен таратыр өчен борадәран Кәримовларның наширлекләренә, «Тормыш»ның Гыйбадулла Госмановның һиммәтенә таянып баруында бит сез бер гаеп тә күрмисездер.

Хаҗи Теләшинең үз фикердәшләреннән матди ярдәм алуына, Фатих Байрашовларның үз юмарт дустларына кулларын сузуларына ник ул кадәр кыек карыйсыз дигән сөальләр килә түгелме?

Шул ук сөальләрне Фатих Байрашовның бөтен татар матбугатына, татар әфкяре гомумиясенә бирү ихтималы бар түгелме?

Аннан соң ни дип әллә нинди Гыйсьмәтиләр, Нәүрузилар «Ислам вә мәгариф»кә кергәннәр, керәләр икән[4], дип шау-шу чыгарасыз? Һәрвакыт гәзитә идарәләренә бер кешенең керүе, чыгуы табигый түгелме? Галиәсгар Гафури «Кояш»ка кергән иде[5]. Галимҗан Ибраһимов «Аң»га кергән иде[6]. Хәзер кайсысы чыкты, кайсысы яза.

Шуннан бит беркем дә бер мәсьәлә ясамаган иде. Ник соң хәзер генә тавышланасыз?

Аннан соң Муса әфәнде «Әманәт» матбагасында «Ислам вә мәгариф»не басарга рөхсәт биргән икән яисә бирмәгән дип, нинди мәсьәлә тудырасыз? Муса әфәнденең матбагасы булса, ул үзенә файдалы эш бирсәләр алыр, файдасыз булса алмас түгелме?

Харитонов матбагасында «Алла бер» дигән исламны тәхкыйрь иткән брошюра басылуга протест ясамадыгыз бит!» дияргә хаклары бар түгелме?

Тагы иң соңыннан болар һәммәсе бит «гаептән хәбәр бирү». Бәлки, Байрашовның чыгарачак гәзитәсе бик файдалы орган булыр. Бәлки, аңгарга матди ярдәм итә торган даирәләр фәкать мөселманны сөюдән генә яшерен мөселман булып, руслар күрмәгәндә истинҗа кылырга яратуыннан гына бирә торгандыр.

Бәлки, шул гәзитәгә керергә разый булган кешеләр бик яхшы ният берлән «сыйрател-мөстәкыймче»ләрне үзләрен алдап, шул эштән мөселманга файда итәр өчен хәйлә генә эшли торганнардыр!

Болар әле беленеп йитмәгән, фактлар әле кулда юк. Алай кызуланырга ярамый... Арттырып җибәрәсез, димәсләрме?

Шул фикер бик күп кешегә дөрес тә, гакыллы да, төпле дә кебек тоелмасмы?

Тоелыр...

Менә безне галәянга китергән нәрсә дә шул нокта да!

Әфкяре гомумиямезнең аңлы кыйсемен куркыткан маддә дә шул.

Көтик әле, фактлар булганча сабыр итик әле, дидетерлек итеп «Сыйрател-мөстәкыйм»нең эшен куя белүдә...

Менә шул әхвале рухиядә икеләнүне тудырыр өчен әлегә кадәр паграк кешеләрне мөхәррирлеккә чакыралар, шул әле яхшы булмасмы дигән өмидне тудырыр өчен алар үзләренең «Нур» матбагалары була торып, Муса әфәнденең «Иманәт»ендә бастырырга маташалар.

Матбага, матбугат дигән сүзләрне урта халык аерып бетермәгәннән файдаланып, «Муса әфәнделәр чыгаралар» фикерне тудырыр өчен, бик зур матди корбаннар ясап та, «Иманәт»кә керергә тырышалар.

Үзләре, килеп чыккач та, «Сыйрател-мөстәкыйм» союзы чыккандагы кебек, халык бердән сугып измәсен өчен, халык арасына — үзләренә, эчтән дошман булган мөселман халкы арасына күз буявы маневрлары эшләп, халыкның хәрәкәтен төрлеләндерергә, андагы берлекне бетерергә тырышалар.

Менә шул мәсьәләне күреп торган кешеләр, шуларның оста маневрларына корбан булмас өчен, халыкның күзен ачарга тиешме?

Әллә ул: «Тукта әле, әле дә факт булсын», — дип торсынмы?

Бер кешене үтерергә дип, ул эчәчәк самавырга агу салып торган җинаятьчене күргән кеше: «Әй, әфәнде, сине үтерергә дип агу салалар!» — дип кычкырырга тиешме?

Әллә ул: «Әле бит факт кулда юк, ул әфәнде чәйне эчсен әле. Бәлки, агу ул кадәр күп тә түгелдер. Бәлки, тәэсир итмәс... Аннан бит әле белеп булмый: ул әфәнде үлсә дә, ахирәт йорты аның өчен, бәлки, күңеллерәк булыр», — дип уйланып торырга кирәкме?

Моңгарга төрлечә җавап бирергә мөмкин булса да, тормышта моның әүвәлгесен «яхшы эшләде» диләр. Икенчесен «шул җинаятьтә иштиракь итте» дип мөхакәмәгә тарталар.

Озакка бармыйк. Мөфтилек мәсьәләсендә бәгъзе бер милли даирәләремез: «Әле ашыгырга юк, уйлашырга кирәк, төшенергә кирәк, әле бит мөселманга зарарлы кеше мөфти ителә дигән сүз — сүз генә, факт түгел», — диделәр. Вә шул хакта мөфтилек мәсьәләсендә әфкяре гомумиямездәге берлекне бетерделәр.

Нәтиҗә ни булды?

Күз алдымызда.

Шуның өчен «Ислам вә мәгариф»нең тууы хәбәрен халкымыз тәһлекәле бер дошман тууы дип каршы алуы табигыйдер вә шулай каршы алырга тиештер.

Чөнки «Сыйрател-мөстәкыйм»нең соңгы итәк асты һөҗүменә мәгъруз булган милли ноктамыз — иң газиз, иң кадерле телемез, милли телемездер.

Чөнки «Ислам вә мәгариф»нең ирешергә теләгән максаты — әфкяре гомумияне сугарып тора торган пакь милли матбугат чишмәседер. Аның артына яшергән зәһәре — шул чишмәне агулар өчен хәзерләнгән агусыдыр.

Бәлки, боларга мәгънәви ярдәмдә булына торган әфәнделәрнең дә үзләренчә яхшы ниятләре бардыр. Бәлки, шул пычрак эшкә алар авыр ният берлә керә торганнардыр.

Ләкин боларның бу хәрәкәтләре нәтиҗәи игътибары белән дуңгыз итен бисмилла әйтеп кабул гына булачактыр.

Тирә-янындагы шуның хәрамлыгыннан шөбһәләре бар мөселманнарны алдар өчен әйтелгән бисмилла булып калачактыр.

## ФРАКЦИЯ ЯНЫНДАГЫ «БЮРО» МӨНӘСӘБӘТЕ БЕРЛӘН

Фракция янында булган киңәш мәҗлесенең беравыздан бюро ясарга, мотлакан, лязем табуы һәммә гәзитәләр тарафыннан язылып үтте. Бу фикергә Идел буе матбугаты һәммәсе дә беравыздан лязем дип каршы алган шикелле, Кырымның «Тәрҗеман»ы, Кавказның «Ачык сүз»е[1] дә шул фикерне тәкрарлады. Боларның һәммәсе дә үзенең укучыларына «Мөселман фракциясе алдында мәсьәләләр бик мөһим, андагы депутатлар шул милли, дини вазифаларны үзләре генә үтәрләр дип көтеп тору хаксыз. Аларга шул милли бурычны үтәшер өчен матди, мәгънәви ярдәм лязем. Ул да — «бюро тәэсис берлән була» дигән фикерне аңлатырга тырыштылар.

«Вакыт» гәзитәсе мөхәррирләре арасында киңәшкә чакырылган ике зат булып та, берсе дә килә алмаса да, алар да шул фикердә, шул матбугат берлән бергә булдылар. Киңәш вакытында «Вакыт»ның бер номерында «Оренбурглар бара алмадылар инде, гафу ителсен. Ләкин Оренбург үз өстенә төшкән вазифасын тәмамы берлән үтәячәктер» диелгән иде.

Мин хәзер фракция янындагы бюроны төзүдә Оренбургның шул вазифасын ничек үтәвен белмим. Шул сүзләрне язган «Вакыт» рәфикымыз шул мәсьәләдә никадәр ярдәм итүеннән хәбәрем юк. Иншалла, бу сүзләр матурлык өчен генә язылмагандыр. Иншалла, Оренбург мөселманнары үзләренең дини, милли вазифаларын үтәүдә башкалар эшләгәнне алыр өчен кулларын сузып тормый торганнардыр. Моңганчы

һәрвакыт милли, дини мәсьәләләремездә алдан йөргән Оренбург зыялылары да үзләренең урыннарын белә торганнардыр дип хис зан итәм.

Ләкин «Вакыт» рәфикымызның 8 мартта чыккан номерасындагы «Фракция янында бюро тәшкиле» дигән мәкалә[2] ни өчен язылганын белмәенчә аптырап калам. Идарәдән язылган бу мәкалә иң әүвәл бюро ясауның лөзүме хакында ихтиляф юклыгын әйтеп үтә дә киңәш мәҗлесендәге фракциянең платформа мәсьәләсене мөзакәрә итүгә килеп төртелә вә шул хактагы платформа дигән сүзне программа сүзе берлән чуалтып, түбәндәгечә фикер йөртә: «Фракция янында шул киңәш мәҗлесе ун елдан бирле дәвам итеп хак хәят казанган Русия мөселманнарының берничә съездлары тарафыннан кабул ителгән «Иттифак» программасының[3] уң стенасын урынында калдырып, сул стенасын алып ташларга карар биргән, бу исә мөселман халкының дикъкатен җәлеп итсә кирәк. Бу хәлнең мөселман әфкяре гомумиясе тарафыннан кабул күрелүе бинаән галәйһи, фракция янында бюро тәшкиленә вә халык илә фракция арасында берлек артуга хезмәт итүе шөбһәледер».

Иң әүвәл киңәштә булган бер кеше сыйфаты берлән һәм дә киңәштә шул платформа мәсьәләсен мөзакәрәгә куючыларның берсе булуым[4] игътибары берлән шул аңлашылмауны җавапсыз калдыра алмыйм.

Бөтен гәзитәләрнең хисабына караганда, киңәш мәҗлесендә һичбер төрле программа мәсьәләсе күтәрелмәгәне, хосусән «Мөселман иттифакы» программасы тикшерелмәгәне, үзгәртелмәгәне мәгълүмдер. Бу мәсьәләне минем кадәр үк, әлбәттә, «Вакыт» рәфикымыз белергә тиештер.

Мәсьәләдә фәкать платформа — хаттел-хәрәкәтне тәгаенләү хакында гына сүз булды. Киңәш мәҗлесендәге бөтен хазирун бердән: «Бу мәҗлес «Мөселман иттифакы»ның программасын карамый, бу фәкать Думадагы мөселман депутатларның хаттелхәрәкәтләренең уңнан, сулдан чикләрен генә күрсәтергә тырыша», — диде.

Бу фикер бөтен хазирун тарафыннан платформаны карау иттереп кабул ителде. «Мөселман иттифакы»ның программасының уң стенасы да, сул стенасы да булса, урта стенасы да, идәне дә, түшәме дә (булса) — һәммәсе дә элгәреге халәтендә калдырылды.

Киңәш мәҗлесе уң тарафтан килә торган һөҗүмне күзгә алып, шул якка элгәреге, моннан ун ел элек кагылган мәшрутиять баганасын — соңгы елларда бик какшаган, хәтта ауган мәшрутиять баганасын утыртты.

Русия мөселманнарының эчләрен пошыра, шөбһә калдырачак монда ни бар ди.

Шул мәшрутиять сызыгы сызылгач, мәшрутиять байрагы күтәргән «Мөселман иттифакы»н сөючеләрнең ни дип кәефе китәдер, ди.

Билгакес, шул сызык сызылгач, «Мөселман иттифакы»ның эченә таба уңнан ага торган пычрак хәрәкәтләргә генә буа корылды. Итәк асты хәрәкәтләре берлән мөселманнарга зарар итә торган даирәләргә, үземезнең карагруһларымызга: «Алар бездән түгел, «Мөселман иттифакы»ннан читтә», — дигән сүз генә ачык иттереп әйтелде.

«Дин вә мәгыйшәтче»ләр[5], Ишми ишаннар[6], Байрашовлар «Мөселман иттифакы» берлән буталып йөри алмаудан мөселман өчен файдага башка һичнәрсә булмаячак дип ышанылып шулай эшләнелде.

Сулдан стенаны алып ташлау дигән фикер дә хата. Мин, докладчы булып, үз тарафымнан уңнан һәм сулдан чик сызылуы тәкъдим иткән идем. Ләкин мәҗлес бер тавыш берлән генә түгел, бөтенләй бергә ул тарафтан куркыныч юк дип мөзакәрә итмәде, ул якка сызык та сызылмады.

Иң әүвәл: платформаның сул тарафында чик сызыгы бар идеме? Юк иде. Беренче, Икенче Думаның мөселман трудовиклары, шул чикне үтеп, мөселман фракциясенә керәләр иде.

Өченче Думада социалист Ибраһим бәк Хәйдәревкә[7]: «Шул сызыкны үтмә», — диелмәгән иде.

Дүртенче Думада сәяси радикал Ибнеәмин әфәндегә[8]: «Читкә чык», — дигән боерык бирелмәгән иде.

Өченче Думада Ибраһим Хәйдәревнең мөселман фракциясе платформасында эшләвеннән мөселманнарга файдадан башка ни зарар булды? Ибнеәмин әфәнденең Дүртенче Думада мөселман фракциясенең платформасында торуыннан нинди уңгайсызлык туды?

Чыккан нәтиҗә: аз гына көч кырыкка бүленмәенчә берләште, бергә хәрәкәт итте. Шулай булса, сулдан чик куймауда ни зарар булачак?

Оренбург мөселманнары, хосусән «Вакыт» гәзитәсе шуның кай йиреннән куркыначак? Белмим.

Оренбург депутаты Гайса мирза Еникиевнең сул якта чик беткәнне күреп, табган суллыгы берлән социал демократ булырга ашкынуыннан куркылса, шуның өчен «Вакыт» рәфикымызның бюроны тудырыр хәзерге мәсьәләләрнең иң әһәмиятлесе булган бер чакта язган мәкаләсендә кылны кырыкка ярып ятуын вакытсыз бер хәрәкәт дип табамыз.

Әгәр бу фикер Оренбург мөселманнарының уе булса, «намаз укыр идем дә, тәсбихым юк шул» дигән осталык кына дип кабул итәмез.

Иншалла, безнең бу юшичәләремез һәммәсе хата булыр да, «Вакыт» рәфикымыз элгәреге әйткән сүзендә сәбатлы калыр. Оренбург мөселманнары үзләренең унъеллык ганганәләре буенча барып, бюрога кеше җибәрерләр.

## ТАТАРЧА ТЕАТР ВӘ КОНЦЕРТ

Әндиҗандагы кебек, әһел түгел кешеләрнең сәхнәгә чыгып, милли театрны тәхкыйрь итүләре яңгы гына вакыйга түгелдер. Мондый күңелсезлекләр бөтен Русия буенда эшләнәдер. Шул мәсьәләгә эче пошкан Мирсәяф әфәнде кадәр үк минем дә саруымны кайнатадыр. Ләкин моның сәбәпләрен без мөхәррирләрдән эзләү тугры түгелдер. Мин «Мөгаллимә»не язсам[1], аны мәгълүм бер тарызда аңлап, мәгълүм төсле типларны эшләргә тырышып язганмын. Минем муллаларым арасында сакалын кызылга буяган имам юк. Нә имамнарның тәгърифендә, нә сөйләгән сүзләрендә андый уй чыгарырга мөмкин түгел.

Карт хәзрәтне[2] мин динле кешеләрнең дини хисләрен тәхкыйрь итәрлек иттереп бер сүз язмадым. Бер сызык сызмадым. Ул кадимче иске хәзрәт.

Әсәрнең язылуы муаффәкыятьле чыккандыр, юктыр. Ул икенче мәсьәлә, ләкин шуларны бозып, әллә нәрсәләр оештырып уйнасалар, без мөхәррирләр гаепле түгелмез. Бу вакыйгада Әндиҗан халкының миңа рәнҗергә һичбер төрле хакы юктыр.

Мин «Мөгаллимә»не яздым. Үзем яздым. Шуны бастырдым. Үзем бастырдым. Шул «Мөгаллимә»гә үзем театральный цензурадан рөхсәт алдым, үзем алдым.

Шуннан соң сәхнәгә беренче куелуында үз күземнән үткәрер өчен «Мөгаллимә»не «Сәйяр» труппага биреп[3], Мәкәрҗәдәге беренче куелуының репетицияләренә килдем. Ләкин, тәәссефкә каршы, беренче репетициясеннән башкасында булына алмадым. Әллә нинди бер хаин минем өстемнән әллә ниләр ялганлап донос ясаганга, бүлмәмә килеп тентү үткәрелде, үземне тотарга, эзләргә тотындылар. «Мөгаллимә»нең репетициясен тәмамән бер мәртәбә дә күземнән кичерә алмаенча, Петроградка китәргә мәҗбүр булдым.

Аннан соң «сәйяр»ләр Мәкәрҗәдә ике мәртәбә куйдылар. Казанда да кую да аларга гына бирелгән булса да, әллә кайдан килеп чыккан Кудаш дигән бер хәриф[4] миннән сорамаенча-нитмәенчә шул көнне Казанда куярга инша чыгарган, мин Кудаш дигән шәхеснең труппасы юклыгын белгәнгә, аннан элек «Мөгаллимә»не «Сәйяр»гә генә биргәнгә, Кудашка куярга ризалыгым юклыгын белдердем. Ләкин ул аңгарга карамады. Полициядән әллә нинди кәгазьләр алып куйды. Законча әйткәндә, минем хокукымны талады. Әдәби кагыйдәләргә караганда, минем мөхәррирлек хокукымны аяк астына таптады. Шуларның икесе өчен дә, әлбәттә, мин шул хәрифне судка бирү хакында маликмын. (Пьесаны сорамаенча, урлап куйган өчен алты айга кадәр төрмәгә ябалар һәм дә мөхәррир алдында гражданский яктан да мәсьүл булалар.)

Ләкин мин үзем өчен шулай итеп судлашып йөрүне ваклык таптым. Үземнең пьесамны үзем ышанган артистларга бирү хакымны гасыблаган, минем судлашып йөрерлек дәрәҗәдә вак түгеллегемне белеп, сәхнә алдында да җинаять ясаган шул әдәби кара халыкны матбугат, татарның аңлылары үзләренең мәгънәви мөхакәмәләре берлән генә җәза итәрләр дип уйладым.

Бу мәсьәләдә минем фикерем хата чыкты. «Йолдыз»да бер кеше Кудашевның шул театр хулиганлыгын яклап, «Гаяз әфәнде ул ничек Кудашевка бирми» дип һөҗүм ясады вә, бөтен дөньяның театр кануннары, бөтен дөньяның гражданский законнары алдында мөкатдәс саналган минем театрны сайлап, үз теләгәнемә бирү хакым минем өстемә гаеп күрсәтелергә тырышылды.

Бу әхлакый хулиганлык берлән дә мин тагы тартышырга керешүне үземә муафикъ тапмадым, татарның театрының үсүенә, тәрәккъкый итүенә бер зарар килмәсен дип аңлап эшләмәдем. Хәзер Әндиҗанда әллә нинди шарлатаннар минем «Мөгаллимә»не бозып әллә нәрсәләр кылынганда, миңа Әндиҗан халкы рәнҗегән икән.

Шул рәнҗү хаклымы?

Мин пьеса язганмын, шуны бастырганмын, шуңгарга рөхсәт алганмын, шуңгарга әллә никадәр матди-мәгънәви көч сарыф иткәнмен. Шуннан соң тагы инде мин, Әндиҗанга барып, начар кешеләр уйнамасын дип сугышып йөрим диме!

Бу көн Әндиҗанда минем «Мөгаллимә»не шулай иттереп миңа халык рәнҗерлек иттереп куйганнар икән, шул ук көнне, бәлки, Хабаровскида минем «Мөгаллимә»мне шуннан да начар куйганнардыр. Архангельда, бәлки, «Кыямәт»не исламнан көлүемне ясый торганнардыр[5]. Әстерханда минем «Җәмгыять»не мөселманнарның «Җәмгыяте хәйрия»ләреннән, тәрәккъые мәгариф җәмгыятьләреннән көлү иттереп чыгара торганнардыр[6].

Әллә кайда минем «Ике гыйшык»ымны, «Өч хатын берлән тормыш»ымны йә әхлаксыз бернәрсә иттереп уйный торганнардыр. Боларның һәммәсенең артыннан йөрергә минем имкяным юк. Мин дә кешеләр төсле кеше, минем дә тәүлегем

егерме дүрт сәгать кенә. Теләгән вакытта чыгып китеп, теләсә кая барырга, теләгән кадәр мәсъраф тотарга минем ихтыярымда әндери казнасы юк. Мин — каләм берлән көн кичерә торган бер язучы. Минем бөтен хаклы-хаксыз теләкләремне эшләп торучы Яхъя пәриләрем юк.

Мәскәүдә торып, кайда ничек уйнауларын күреп, кайда начарлык барын белеп торырлык әүлиялыгым юк. Татар дөньясындагы шул начарлык берлән ялгыз гына тартышырлык миндә кәрамәт тә, сихер дә юк вә һичбер вакытта да «Татар дөньясындагы бөтен начарлык берлән тартышуны үз өстемә генә алдым» дигәнем юк...

Бар каләм берлән язам. Үзем ышанганча, үзем халкыма файдалы дип уйлаганча язам. Шул язуларымны этләнеп, мең бәла берлән бастырып таратам. Шул бастырганнарымны, кирәк, китап булсын, кирәк, гәзитә-журнал булсын, әллә никадәр матди зарар итеп, ярым бушлай таратам.

Инде шуларны укыйсы килгәннәргә барып укып йөртүгә, аңламаганнарына аңлатырга да, театр уйнаучыларына да дөрест иттереп уйнатырга да минем бурычыммы?

Шуларны үти алмавым өчен миңа андагы-мондагы милләттәшләрем рәнҗесәләр, рәнҗергә хаклары бар дип белсәләр, шул рәнҗүләрендә хаклылармы?

Минем дә үзләре кебек кеше генә икәнлегемне, минем дә көчем кешенеке кебек кенә — мәхдүд икәнлеге, минем өчен дә дөньядагы төрле-төрле тыгызлыклар шулай ук тыгыз икәнен уйлап гафу итсеннәр. Минем театр китапларым сәхнәгә куела башлаганга озакламаенча ун ел тула[7]. Шул ун ел эчендә шулардан теләгәнчә гонорар алу үземнең хакым булса да, театр үсүенә зарар булмасын дип, бу көнгә кадәр бер тиен гонорар алмаганымны белеп, шуннан һичбер төрле матди мәнфәгать күрмәгәнемне белеп гафу итсеннәр. Ләкин үзләренең вазифаларын да онытмасыннар. Минем алдымда гына түгел, татар сәхнәсе алдында булган вазифалары — авылда чабатасы берлән сәхнәгә чыккан әдәпсезләргә әсәрне таптарга, сәхнәне былчыратырга ирек бирмәү. Моны үтәмәсәләр, минем әсәрләремне былчыратсалар, сәхнәне тәхкыйрь иттерсәләр, минем рәнҗергә хакым алардан күбрәк булачагын белсеннәр.

Шуның өчен Әндиҗандагы аңлы мөселманнар, миңа рәнҗү урынында, үзләренең аңнары берлән, үзләренең матди вә мәгънәви көчләре берлән шул шарлатаннарны куып чыгарган булсалар, азмы-күпме татар театрына хезмәт иткән бер мөхәррир гә рәнҗүгә караганда, күбрәк иттереп милли вазифаларын үтәгән булыр иделәр. Сәхнәне пакьләүне читтәге көчләрдән көтмәенчә үзләре эшләсәләр, милли вазифалары милли әдәбият, милли театр тудыруда хезмәт иткән кешеләрне сүгү генә түгел икәнен эш берлән исбат иткән булырлар иде.

Татарның театры, әдәбияты, матбугаты, җәмәгать эшләре читтә сыкрап тора торган, эшләгән кешеләрне хаксыз тәнкыйть итә торган егълавыкларга мохтаҗ түгел. Аңлы хезмәтнең кадерен белә торган, шул хезмәтләр өчен матди, мәгънәви әллә никадәр көч сарыф ителгәнне аз гына да булса да аңлый торган, җәмәгать эшләренең һәммәсендә үзләренең тәнкыйть хакы гына түгел, вазифасы, бурычы да барлыгын белә торган затларга мохтаҗ.

Югыйсә бу рәнҗүләр, бу тәнкыйтьләр елына ике мәртәбә була торган гаеттә[8] рус авылына качып кала торган мужикның мулланы, ишрак намазын көтеп чыкмавын, һәр төннең уртасында сәхәр намазын укымавын тәнкыйть итү берлән бер булачактыр. Иң әүвәл үзеңнең өстеңә төшкән фарызларны үтәргә кирәк. Аннан соң башка кешеләрнең нәфел гыйбадәтләрен эшләгәндәге бөтен нәфелләре эшләп бетермәвен тикшерергә керешергә кирәк.

Мантыйк шуны тели, хаклык шуны куша.

## ТАГЫ «БЮРО»

Мөселман фракциясе янында киңәшләр булып үткәнгә инде ай тулып узды. Шул ай эчендә Дума, җыелып, үзенең иң кызу урак өсте булган бюджет карау мәсьәләсенә тотынды. Инде бюджетның бик күбесе каралып үтте дә. Мөселманнарның эчке тормышларына, идарәи руханияләренә, мөселманнарның мәдәни эшләренә, шәһәр вә земстволардан ала торган ярдәмнәренә, мөселманнарның сәяси хокукларына иң зур тәэсир ясый торган дахилия нәзарәтенең сметасы каралды. Вә шуның аерым департаментларыннан чит диннәр департаментының сметасы җентекләнде. Бу департамент — соңгы елларда безнең мөселманнарның рухани тормышларына иң зур тәэсир ясый торган дивандыр.

Шул департаментның директоры Минкин[1] булган чакта директор әфәнденең дустлыгы берлән Баязидовлар, Байрашовлар вә башка ресторанчылар тарафыннан «Сыйрател-мөстәкыйм» дигән союз да төзелергә булган иде.

Шул ук департаментның катышы берлән Мәскәүдәге цензор астында чыга торган «Ил» гәзитәсе ябылган иде.

Шул Минкинның тәэсире берлән, Идел буе мөселманнарының мөфтилек хакындагы фикере читтә калдырылып, үзенең якын танышы, «Сыйрател-мөстәкыйм» ясашучысы Сафа Баязидовны мөфтилек урынына куйдырган иде.

Шул департамент ничектер, нинди хак беләндер катышып, Мәскәүдәге «Нәшере мәгариф җәмгыяте»нең уставына рөхсәт бирдермәгән иде вә шуның хакында мәрхүм Әсәдуллаев мәктәбенең мәсьәләсе күк берлән йир арасында калдырылган иде.

Шул департамент, соңгы елларда үзенең даирәсен киңәйтә-киңәйтә, безнең мөселманнарга каршы бер «фәтваиханә», шәйхелисламлык дәрәҗәсенә генә муафикъ хәрәкәтләрдә булынган, ислам фикъһесе хакында китаплар нәшер иткән иде[2], итәргә керешкән иде.

Бәлки, департаментның башка хезмәтләре дә бардыр. Бәлки, ул Русиядә утыз миллионлы мөселманнарның бөтен идарәи руханияләренең иң башы иттереп үзен куйгач, мөселманнарның бер-бер дини эшләре мөселманнар теләгәнчә, аларга файдалы иттереп тә эшләгәндер.

Мәгаттәэссеф, без аны белмимез.

Менә шул департаментның сметасы каралганда, әлбәттә, мөселман депутатлары мөселман халкының фикерен әйтми булмадылар. Ибнеәмин әфәнде шул хакта озын нотык сөйләде[3]. (Тәфсиле бу номерымызда бар.)

Кавказ идарәсенең сметасы каралганда, Карс, Батум вилаятьләрендә сугыш башланганнан бирле мөселманнарга никадәр авырлыклар төшүе гәзитәләрдә бик күп язылган иде. Шундагы җәберләгән мөселман халкы өчен Русия мөселманнарының бөтен почмакларыннан бик күп иганә дә йибәрелгән иде.

Думадагы мөселман фракциясенең әгъзалары, әлбәттә, бу мәсьәлә хакында да авызларын йомып калмадылар. Кавказ депутаты Йосыф бәк Җәгъфәрев[4] озын бер нотык белән Кавказдагы мөселман фаҗигасенең өстеннән пәрдәсен ачты (нотыкның тәмамы «Сүз»нең 33–34 нче номерларында басылды).

Мәгариф нәзарәтенең сметасы каралганда, мөселманнарның тагы авырта торган мәктәп-мәдрәсә мәсьәләләре, мөгаллим, мөгаллимәләрнең хокуклары хакында фракция тик кала алмады. Гайса мирза Еникиев 15 марттагы Дума мәҗлесендә озын бер нотык берлән мөселманнарның Мәгариф нәзарәтеннән нинди мәдәни теләүләре барлыгын аңлатты. Мәгариф нәзарәте мөселман укытучыларга нинди хокуклар бирелергә ярдәм итүе ляземлеген сөйләде. (Бу нотык тиздән гәзитәмездә басылачактыр[5].)

Моннан соң да, әлбәттә, мөселманнарга очы төртелә торган бер мәсьәлә чыкты исә сөйләнелер. Шул мәсьәләләрнең мөселманнарга сугылулары, чыбык очы төртелүләре җавапсыз калдырылмаслар.

Ләкин Думадагы мөселман фракциясенең хезмәте бу гына түгелдер. Аның алдында берничә ляихә әллә кайчаннан бирле кизү көтеп тора. Боларны эшләп, ляихә сурәтенә кертеп, Думага тәкъдим итү лязем.

Боларның берсе дә авылдагы мәктәпкә программа ясау кебек кенә эшләрлек түгел, иң күбесе — Русиядә бөтен мөселманның йә дине, йә милли, йә сәяси хокукын законландырыр өчен эшләнәчәк эшләр.

Боларны тәмамән закон булыр дәрәҗәгә йиткереп эшләп бетерергә бик күп хәзерлек, бик күп хезмәт лязем.

Мондагы кечкенә генә эшләнеп бетмәү яисә аз гына уйланып бетмәүдән килгән хаталар, бөтен мөселманнарга тәэсир итеп, әллә никадәр зарар итү ихтималы бардыр. Шуның өчен җентекләп, дикъкать берлән эшләү ляземдер, фарыздыр.

Киңәш мәҗлесе шул милли бурычны тутыруны, милләт өстенә йөкләнгән шул фарызны тутыруның хәзер вакыты икәнен, моннан да кичектерергә ярамавын кычкырып игълан итте. Бөтен аңлы мөселманнарга, милли азан тавышын ишетергә өйрәнгән мөселманнарга нида итте. Вакыт үткәрергә ярамауны, дини, милли мәсьәләләремездә «бүген, иртәгә» дип салындырып барырга ярамавын белдерде.

Һәммә мөселманның өстенә йөкләнгән бурычын төшерер өчен фракция янында бюро төзергә лязем дигәне карар чыгарды. Шуның ничек төзелүе, кирәклеге хакында махсус низамнамә эшләде.

Шул фикергә катышып, бюроны тудырышырга Казан, Троицк вәгъдә итте. Оренбургтан шул фикергә иштиракь итү хакында хәбәр алынды. Шул мәсьәләне зуррак шәһәрләргә аңлатыр өчен бюро ясауны фәгалиятькә чыгарыр өчен киңәш мәҗлесе рәисе Котлыкай мирза[6] мөрәҗәгатьләр күндерде.

Иншалла, һәммәсе урынлы-урынында мөзакәрә ителә торгандыр. Үткән номерымызда Мәскәү мөселманнарының бюрога әгъза җибәрергә карарлары басылды[7].

Иншалла, үзләренең милли, дини вазифаларын үти белүчеләр Мәскәү мөселманнары гына булып калмас.

Иншалла, Мәскәү мөселманнарының шул аңлы хәрәкәтләре бик күп йиргә үрнәк булыр, иярченнәр табар.

Троицкиларда да, әлбәттә, шул уйны фәгалиятькә чыгару юлында эшләнә торгандыр.

Казан да, үзенең Казанлыгын күрсәтү өчен, үз ихтыяры берлән барган күңелле әгъзасы берлән генә канәгатьләнми торгандыр.

Ул да хәрәкәт итә торгандыр.

Оренбург та үз вазифасының башындадыр.

«Вакыт» гәзитәсендә ике номердан бирле языла торган киңәш мәҗлесе хакындагы кирәксез казынулар Оренбургның үзенең бурычын үти алмавын каплар өчен ясаган маневрасы түгелдер.

Әстерханы, Семисы, Сибирияссе, Төркестаны, Кавказы, әлбәттә, шул мәсьәләдәге бурычын үти торгандыр.

Иншалла, шулайдыр. Без шулай хөсне зан итәмез.

Ләкин шул әфәнделәрдән, шул шәһәрләрнең аңлыларыннан тагы бернәрсә көтәмез.

Ул да:

Ашыга төшү, үзләренең бюрога итәчәк ярдәмнәрен фәгалияткә чыгаруны тизрәк эшләү.

Вакыт әһәмиятле. Дума мәҗлесләренең иң кызу чаклары.

Фракциямезнең эшенең иң күп вакыты. Мөселман эшләренең рус галәменә Дума минбәренә чыгарылуы өчен иң мәслихәт чагы.

Шуның өчен бюроның бер көн элек төзелеп бетүе әллә никадәр уйланылмаган файдалар китерәчәктер.

Шуңгарга күрә ашыгу лязем.

Эшне сузылдыра-сузылдыра әле дә бик күп форсатлар качырдык. Бик күп хаталар ителде. Бер генә мәртәбә ашыктырыйк әле.

Ашыктырыңыз әле!

Җәмәгать эшләре эшләгәндә бездә эшләнү һәрвакыт ике дәвергә бүленә. Берсе — шул фикернең мәйданга куелу дәвере. Икенчесе — шул фикерне фәгалияткә чыгару дәвере.

Фикер мәйданга куелганда, саф булгангамы, халкымызның бөтен пакь кыйсеме күтәреп ала да шуны сөйли, яза, халык арасында тарата. Фикер көннән-көн киңәеп китеп, үзенә арка таяначак тарафдарлар таба. Эшләнә-эшләнә теория ягыннан ышкылана, пычкылана, тормышка, татбикъка ярарлык хәлгә куела.

Татарның табигате практик эш яратучы булганга, ул аңладымы: «Кая, шуны эшлик, ни кирәк соң? Матди көчме, мәгънәви көчме, сәяси куәтме?» — дип сөаль бирә. Шул сөальләрдә мөзакәрә мәйданына куела да тудырылачак көчнең түбәләре, нигезләре үлчәнә, ташлары, такталары, тимер-томырлары хисаптан чыгарыла. Шуннан соң, күңелдән генә шул кирәк-ярак хәзер булгач та, «Йә инде, эшлик!» дигән фикер керә. Җәмәгать эше үзенең икенчесе баскычына баса, ясалуның икенче дәверенә керә.

Эш шунда җиттеме, шул икенче адымның капкасы кагылдымы, моңгача бергә хәрәкәт иткән күп даирәләр пыр киләләр. «Тукта әле, без уйлыйк!» дигән фикердә яңгыдан туктыйлар. Искедән эшләнеп килгән ганганәмез булмаганга, һәр даирә үзенчә төшенә. Һәр төркем халык үз үлчәве берлән үлчи. Иң кызганычы шул: һәрбер кыйсем халык шул эшнең башыннан алып ахырына кадәр үз уе, үз фикере берлән генә эшләнүенә исрар итә. Шул үз рецептының суы гына азрак булса да, вазгыятенә карап, йә битарафлык игълан итә яисә шул фикернең дошманы киселә. Мәгаттәәссеф, икесендә дә ачыктан-ачык хәрәкәт итеп, үзе ни уйлаган — шуны язмаенча, үзе ничек файдалы тапкан — шуны сөйләмәенчә сәясәт уйната, итәк асты сәясәтен йөртә.

Үзеннән чыкмаган фикерне ямьсезләтер өчен шул вакытта нәрсә куркыныч итеп күрсәтергә мөмкин булса, шуңгарга сарыла.

Элгәрерәк шул куркыныч ителеп динсезлек йөртелә иде. Хәзер инде ул искерде. Аңгарга төрелгән даирәләрнең үзләренең кара йөзләре халык алдында тәмам ачылды.

Хәзер халык алдында әйтеп аңлатырлык бер гаеп күтәрелде. Һәрнәрсә мәйданга, һәммә эш ачык эшләнә, матбугат бар, әфкяре гомумия бар. Тегеләр аптырамадылар. Искедән казынып, тагы иске булса да, бер корал чыгардылар.

Ул да — интрига.

Ләкин аны идарә итәр өчен осталык кирәк. Алар шуны тәдкыйкатка тотындылар.

«Гакыллы баш» булып «бик һәйбәт эш, ләкин ашыгычрак булмас микән? Уйлана төшергә кирәк, обмозговать итәргә кирәк. Җиде үлчә, бер кис, дигәннәр. Һәйбәт, ләкин, минемчә, менә монысы артыграк, монысы кимрәк, монысы кызылрак, фәлән...» дип, үзләренең фикерләрен, хәйлә тозакларын да яшерделәр. Җөзьият юлына кереп хәрәкәт итә башладылар.

Мөфтилек мәсьәләсендә шулай булды.

Бюро мәсьәләсе шулай булырга тора. Аның янында да итәк асты сәясәте йөртелә, оста интрига эшләнә.

Хосусән мөселманнарның зур урыннары булган бер-ике шәһәрдә бу интрига бөтен көче-куәте берлән, Дума таралып киткәнче бюрога әгъза йибәртмәс өчен, беренче, икенче, өченче үлчәү берлән шөгыльләнә, әфкяре гомумияне шөгыльләндерә.

Җиденче үлчәүгә кадәр ерак әле. Алла боерса, бәлки, барып та җитә алмамыз, шулай итеп эш юлда калыр...

Бюро мәсьәләсе хәзер менә шул дәвердә.

Безнең халкымызның тугрыдан-тугры уйлый торган, әллә нинди җөзьият хәйләләренә өйрәнмәгән башы шунда хәйлә бар, бунда ау бар икәнен күрми. Үзенең беркатлылыгы, үзенең саф дәрунлыгы берлән алдана. Үзе аңламаенча, «файда итәм» дип, җәмәгать эшенә зарар итә вә шул иезуит тозакларыннан арынып чыгарлык көч күрсәтә алмаенча буталып кала. Форсат кача, вакыт үтә.

Җәмәгать эше халыкның иң зур күпчелеге теләмәгән төстә нәтиҗә бирә.

Мөфтилек мәсьәләсендә ресторан, вагон кухняларында эшләнгән сәясәткә әфкяре гомумиямез мәгълүб булды.

Хәзер бюро мәсьәләсе дә француз кухнясының гүзәл рецептлары алдында чуалып аптырап ята...

Күзне бераз ачыбрак карап, үзенең шәхси мәнфәгатьләре ноктасыннан гына карый торган хәрифләрнең карталарын ачарга вакыт түгелме?

Шуларның тозаклары арасыннан ычкынып, җәмәгать эшен җәмәгать фикере берлән эшләргә вакыт түгелме?

Бюро мәсьәләсе янында никадәр итәк асты сәясәте йөртелсен, ләкин бюро безгә лязем. Бюроның бу тарызда ясалуына кәефе киткән кешеләр булса булсын, аны ясау — бу көнге көннең бурычы. Бу бурычны бу көн үтәмәсәк, иртәгә вакыт үтә. Милли, дини, мәдәни эшләремезнең хәле тагы мөшкелләшә.

Зуррак шәһәрләрнең аңлырак кыйсемнәре, шул мәсьәләдә халыкны кырыкка ярдыручыларның максатларын аңлаңыз әле!

Үзеңезнең сафлыгыңызны, мөселманлыгыңызны әллә кемнәрнең мәнфәгате шәхсияләренә корал иттермәңез әле!

Шуны белеңез: бюро ясау мәсьәләсе хәзер бөтен халыкның мәдәни, милли, дини мәнфәгатьләрен саклар өчен бер генә юл булганга, татарның истигъдады булса, ул мәйданга чыкмаенча калмаячактыр.

Бер шәһәрнең, ике шәһәрнең аршынын кулына тотып, үлчәп торган булып форсат качыруыннан гына эш бозылмаячактыр.

Татар дөньясы киң.

Татар зур.

## МӨФТИЛЕК ТИРӘСЕНДӘ

«Дин вә мәгыйшәт» безнең Казан мөхбиремезнең «Йолдыз» шагыйре Садыйк мулла Иманколыйның Одессага Духовное собрание тарафыннан 450 сум мәгаш берлән гаскәри имамлыкка җибәрелүе хакындагы хәбәрен тәмамән күчерә дә[1], үзеннән «Садыйк мулла Одессага хәрби мулла түгел, мәхәллә имамы итеп тәгаен ителгән» дип тәфсир итә.

Мөхбирнең «Депутатларымыз шул «Мөфти Баязидов булып калсын!» дигән Казан имамнары вә могтәбәр картларының гаризаларын караганда, шул маддәне хәтердән чыгармасыннар иде» дигән җөмләләре хакында мантыйк йөртеп, [«Дин вә мәгыйшәт»], «Сүз» берлән моназарә кылышып, хуш, бәс... депутат хәзрәти хәтерләрендә тоттылар!.. Ни булды вә яхуд ни булачак... Болай булганда безнең Оренбург имамнарын, Оренбург губернаторының да губернатор булып калуын депутатларымызга хат язып үтенеп куйсыннар. Депутатлар да губернаторның, бер урынга исправникның тәгаен кылуын хәтердә тотсыннар» дип, көлү берлән сүзен тәмам итә.

Иске мәҗүсләр, яңгы мөртәтләр берлән эш иткән «Дин вә мәгыйшәт» тирәсенә Русиянең Идел буенда мөселманнар, чын мөселманнар барлыгы вә аларның ун мең мәхәллә тәшкил итүе мәҗһүл булырга кирәк. Шулай булмаганда ун мең мәхәллә, җиде-сигез миллион мөселманның дини башын губернатор, исправник, урядник берлән чагыштырып, аларны бер дәрәҗәгә куеп йөртмәсләр иде.

Әнә шул чын мөселманнарның фикеренчә, ун мең мөселманның рухани башы урядник та, стражник та, исправник та түгел. Аның кылычы да юк, аның җилкәсенә тегелгән путаллы йолдызлары, тасмалар да юк. Хезмәте өчен алган, муенына таккан кресты дә юк. Шуның өчен бу чын мөселманнар, бу халык: «Ун мәхәлләнең дин башы булачак мөфти халыкның үз арасыннан, үзе сайлаган мөфтисе булырга кирәк. Аның тәгаене Бәләбәйгә исправник йибәрелүе кебек юлда йөртелмәскә кирәк», — ди.

Бөтен дөньядагы халык тарафыннан теләсә генә нинди динне тотсыннар, бөтен тарихи заманнарда эшләгән бәни бәшәрнең хөрмәт итә торган иҗтимагый кануны бар. Ул да — һәр дин халкы үзенең дин эшләрен идарә итәр өчен имамнарын үзләре сайласыннар дигән кагыйдәдер.

Менә бу кагыйдәгә дөньяның дүрт почмагына христиан, ислам, мәҗүс мәмләкәтләрендә шул кагыйдәне бозмыйлар, ихтирам итәләр.

Ислам мәмләкәтләренең иң шәүкәтле вакытларында, иң көчле чакларында христиан вә яһүдләрнең дин эшләрен эшләргә тәмам хөррият бирелде, дин башлыкларын үзләренә сайларга тәмамән тапшырылды.

Бабаларымыз татарлар үзләренә табигъ иткән русларның[2] диннәренә һич тукынмадылар. Диннәргә тәмам хөррият бирделәр, попларын, архиерейларын, патриархларын сайлауларны үз ихтыярына тапшырдылар.

Бу көнге көндә Төркиядә греклар, әрмәннәр шул мохтарият берлән файдаланалар.

Бу көнге көндә безнең Русиядә иң түбән дәрәҗәдә йөртелә торган яһүдләрнең шул хакларын беркем дә гасыб итми. Ул гына да түгел, бу көнге көндә бөтен саннары сигез меңнән артмаган, җыенысын җыйсак, Казанның Яңгы бистәсе мөселманы кадәр була алмаган караимнәр шул хактан файдаланалар. Үзләренең монах башларын үзләре сайлыйлар.

Исламияттә мәхәллә тәшкиләтендә, бөтен дини, дөньяви оешуларда шура әсас ителгән.

Исламияттә имам тәгаен итүдә пәйгамбәрләремез Мөхәммәд гам, үзеннән соң булачак хәлифәсен дә үзе тәгаен итеп калдырмаенча, шураи өммәткә тапшырган.

Ислам галәмендә рухани башын сайлау — исламиятнең рухи әсасыдыр.

Хәзерге заман да шул юлдан барырга тиештер.

Русиянең законнары да исламиятнең шул әсасына хөрмәт итеп, бөтен руханиларны сайлау ысулына куйган иде. Хәзерге заманда да имамнар сайлау — мәхәлләнең хакыдыр.

Ике йөз йортлы бер авылның башында тора торган имамны тәгаен итү шунда стражник җибәрү юлы берлән эшләмәгәндә, ун мең мәхәлләнең башына куелган кешенең дә чын мөфти, чын рухани башы булыр өчен исправник җибәрелү ысулы берлән әллә нинди бер чиновникка яраудан, бер миссионер берлән бер фикердә булудан, мөселманнарның тәрәккъкыйсенә дошманлыктан, русларның карагруһлары белән бер уйда булудан гына килгән имтияз берлән эшләнмәскә кирәк, диләр.

Мөфти дигән зат мөселманнарның үз араларыннан сайланган, үз күпчелекләре мәслихәт тапкан зат булырга тиеш, диләр.

Боларча, шул идарәи рухания башындагы мөфти, ул мөфти ул идарәи руханиянең башы, мөселманнарның дини, мәдәни омтылуларының бер әгъзасы мөфти, сәяси һичбер фикернең коралы булмаенча, Идел буендагы мөселманнарның ак-пакь теләкләренең гәүдәләнгән символыдыр.

Шуның өчен бу кыйсем халык, үзенең мөфтисенә дин башы дип караганга, әхлакый кагыйдәләрнең бик күбен тутырган затны шул урында күрергә тели.

Шуның өчен ул мөселманнар хакында ялган донослар ясап имтияз казанган, Русия мөселманнарының тәрәккъкыйләренә киртә салуны үзенә карьера иткән писләрне шул урынга лияекатьсез таба.

Шуның өчен бу халык, зур жалунияләргә кызыктырып, сатлык муллаларны үз тарафына аударыр өчен әле зур жалуния берлән Одессага җибәрүен, әле «Петроградка, имам итәм» дип командировать итүләрен, әле «фронтка күндерәм», әле «ахунлык бирәм» дип собраниедән элгәреге Ирандагы кебек, «рөтбә сату» биржасы ясауга җирәнеп карыйлар.

Аракы, дуңгыз ите сатарга өйрәнгән буфетчының бабасыннан калган дини, милли байлыкларын сату — рус базарына сату дип сыкранып карыйлар.

Менә шул ноктада без «Дин вә мәгыйшәт» тирәсеннән аерыламыз. Шушы күңелле, без үземез генә, бер кечкенә генә халык түгел, Идел буе мөселманнарының бөтен пакь кыйсеме, бөтен сатылмый торган, сатылып тамагын туйдырырга теләмәгән, дини фәхешне кәсеп итмәгән бөтен затлар аерыламыз.

Сез: «Мөфти — исправник кебек полиция чиновнигы», — дисез. Без: «Мөфти — дин башлыгы», — димез. Сез, үз фикереңезне тоттырыр өчен, «мөфти — полиция чиновнигы» дигән әсасны йирләштерер өчен сагыяләр ясап, шул фикернең каршылары берлән тартышасыз.

Үзеңезнең тарафдарыңызны арттырыр өчен ахунлык, военный муллалык өләшәсез.

Без, үз фикеремезне аңлатыр өчен, бөтен Русия халыкларының вәкилләре җыелган Думага мөрәҗәгать итәмез.

Шул бөек мәмләкәт диванында закон эшләнеп, «мөселманнарның мөфтисе үз араларыннан сайланган мөселман булсын» дигән теләвемезне закон иттереп чыгартырга тырышамыз.

Халык җиңәрме, шәйтан җиңәрме? Анысы — Алладан...

## (* * * ГӘЗИТӘМЕЗНЕҢ МӘКТҮБЛӘР КЫЙСЕМЕНДӘ...)

Гәзитәмезнең мәктүбләр кыйсемендә Фатыйма ханым Шакулова җәнабларының каләм тимәенчә китмәслек мәктүбе бар. Мәктүб халкымыз арасында төпләнеп җитмәгән яңгы бер агымга кагылганга, фикер йөртүне лязем таптым.

Аурупаның фикер тарихында тәрәккыйпәрвәргә каршы консерваторлар-мөхафәзәкярләр дигән бер фирка барлыгы мәгълүм.

Тәрәккыйпәрвәрләр фиркасен тәнәзыге бәка гамиле казып чыгарган кебек, мөхафәзәкярләр фиркасен дә тәрәккыйпәрвәрләрнең искелекне җимерүләреннән курку хисе казып чыгаргандыр. Болар арасында гасырларча тартышу дәвам иткәндер.

Хосусән Англиядәге тәрәккыйпәрвәрләр белән мөхафәзәкярләрнең тартышулары бик күптәннәндер. Бу ике фирканең эш күрәчәк мәйданнары инглиз халкын ачыктан-ачык тартышуларга өйрәткәнгә, боларның һәммәсеннән дә ап-ачык хисап сорап, ап-ачык иттереп программаларын сөйләштергәндер, язгандыр. Хаттел-хәрәкәтләренең маякларын утырттыргандыр.

Эшлекле инглиз милләтенең консерваторларының, бәлки, максатлары иске инглиз хәятын бары-югы берлән саклау, бигрәк борын хәзрәтләренең имтиязларын мөхафәзә итү булса да, халыкка ярар өчен болар бик күп ислях маддәләре керткәннәрдер.

Инглиз консерваторларының бу көнге программалары, безнең сул кадетларымыздан бик күп маддәдә сул булган кебек, аларның хаттел-хәрәкәтләре дә Русиядәге мәгънә берлән бик сулдыр. Боларның тартышу ысуллары да безнең Русиядә чын руслар (рус консерваторлары) партиясе тарафыннан кабул ителгән полиция көченә таянуга бөтенләй башкадыр. Болар ачыктан-ачык хәрәкәт итәләр, сайлау вакытларында парламентта үз фикерләрен үткәрергә тырышалар. Үзләре арасыннан министрлар чыгарып, үз фиркаләренең программасын татбикъка маташалар. Болар арасында донос, сагыя, авантюрлык кебек ялганнар партиянең коралы иттерелеп кабул ителмәгән, бәлки, билгакес, болар арасында да шул золымнар мөртәт, мәнфүр сыйфатлардыр.

Әгъзаларының иң күбесе консерваторлык байрагы берлән үзенең имтиязын сакларга, үзенең сайлау вакытындагы хокукының күплеген кулга тотарга тырышучы бароннар булса да, болар арасында консерваторлыкның Англия өчен иң тугры юл икәнлегенә ышанганнары да бик күптер.

Анда эш шулай. Һәр мәсьәлә ап-ачык итеп мәйданга куела. Шул мәсьәлә ап-ачык итеп мәҗлесләрдә сөйләнә, гәзитәләрдә языла. Теләгән кеше шул хакта дәрес укый, китап тарата. Халык яратса, кабул итә, яратмаса, бу кешенең яисә бу гөруһның зәхмәте бушка чыгып кала.

Анда хөкүмәт эчке тартышуга, фикер, фәлсәфә, идея тартышуына дорфача катышмый. Үтерү, кыйнау, вату, сындыру булмадымы, аның эше юк, рәхим ит, нинди партия корасың, кор.

Шуның өчен Англиядә «бу кызылрак», «бу яшелрәк» дип барып әйтә торган бер даирә юк. Шул сүзне тыңлап, «ә ник ул ахмак алай иткән» дип килеп бәйләнүче юк.

Инглиз мәэмүре бер кеше хакында яисә гөруһ халык хакында «ул яшел» дигән кәгазьне алса яисә «кызыл» дигән хәбәрне алса, ул кәгазьне чүпкә ташлый. Чөнки ул зур халык арасында яшел дә, кызыл да, сары да, кара да төсләрне сөючеләр булу табигатьнең яратылышыннан килгән бер хасият дип ышана.

Безнең Русиядә халык бөтенләй башкача. Шуның өчен Хикмәтнең «Сүз»дәге мәкаләсе Русиянең хәле-әхвале күзгә тотылып язылган. Татарның милләте мәкхүмә булуы, татарның мәдәни хәрәкәтләренә рус халкының күзе өйрәнеп йитмәгәнлеге дикъкатькә алынып каләм йөртелгән.

Менә шул ноктадан караганда, безнең тәрәккыйпәрвәрләрнең дошманнары хакында «алар мөхафәзәкярләр, аларның иманнары бар» дип буламы?

Аларның шул фикерен татарның күпчелеге өчен файдалы дип ышанганга, чын калебтән эшлиләр дип уйларга мөмкинме? Әллә болар чыннан карагруһлармы?

Мондый сөальләргә җавап биргәндә, иң тугры юл — шул халыкның эшләгән эшенә карау, шуннан чыккан нәтиҗәне күз алдына китерү, шул халыкның үзенең максатына ирешер өчен тоткан юлын тикшерү, үзенең дошманнары берлән тартышырга истигъмаль иткән коралын күздән кичерүдер.

Менә шул үлчәү берлән хәзер безнең тәрәккыйпәрвәрлеккә дошман даирәләргә барыйк.

Аларның беренче хәрәкәтләре ни булды?

Бөтен яңгылыкны, бөтен фәнни әдәбиятны, матбугатны хәрам итеп игълан итү булды. Ләкин боларның хәрам диюләре фәкать академически бер хәрәкәт кенә түгел. Халыкны шул яңгылыкка һөҗүм иттерер өчен иде. Һәм дә Русиянең бөтен почмагында шул һөҗүм булды.

Икенче хәрәкәтләре: халыкның үз тарафларына авып йитмәгәнен күргәч, хөкүмәткә мөрәҗәгать итеп, полиция көче берлән тәрәккыйпәрвәрләрне бетерү булды.

Бу юлда аларның «шәригатькә сыймый» дигән сүзләре колакка алынмаганга, болар ялган доноска тотындылар. Бу юлда указы алынган имамнар, мәктәптән куылган мөгаллимнәр, мөгаллимәләрнең исәбе-хисабы юк. Бу донослар, бу сагыяләрнең һәммәсе ялганча ителеп һәм дә бөтен мөселманга начар исем ягар өчен эшләнде. Аларның бервакытлары донос кораллары «патша хәзрәтен тәхкыйрь итте» булды. Соңрак ул искерде, түрәләр буңар илтифат итми башладылар.

Соңыннан «Иттихаде исламчы» дигән яңгы донос табып алдылар. Хәзер «пантюркизм» доносы башлады. Ишми ишан ялган донос белән әллә никадәр имамның указын алдырды. Бубилар мәсьәләсендә мөхакәмәгә барып, ялган шәһадәт белән «бөтен Русия мөселманнарында иттихаде ислам фикере бар» дигән уйны хөкүмәт даирәләрендә урынлаштырырга тырышты.

Буби кебек зур бер гыйлем йортын тар-мар китерергә сәбәп булды.

Казанның «Мәдрәсәи Мөхәммәдия»сенең хәле шул юлдан барды.

Авыллар, шәһәрләрдәге ябылулар, тентүләр — һәммәсе бер ялган доноска барып төртелде.

Мөселманнарның төрле почмакларында төрле донос оялары корылды. Шуларны берләштерер өчен бер кнопка төртү берлән Уфасы, Түнтәре.

Мөфтилек, фәләнлек...

Бу көнге арестлар...

Хәзерге донослар...

Менә боларны күз алдыннан үткәрү генә дә саф кешегә «юк, боларда ислам аңлаганча иман да юк, боларда игътикад та юк, болар мөселман дөньясына кергән мясниклар, Русия мөселманнарының йөрәген, бавырын, эчен, башын сату өчен мөселман ите кибете ачкан мясниклар, шуны оптом да сата, кисәкләп-кисәкләп тә сата!» дигән нәтиҗәне тудырадыр.

Шуның өчен «Сүз»дәге мәкалә Англиягә каратып язылса, никадәр хата булачак булса, безгә караганда шулкадәр дөрестер.

Бездә тәрәккыйпәрвәрлеккә каршы тору — хәятка каршы торудыр.

Бездә тәрәккыйпәрвәрлеккә каршы тору — татарның мәктәбе, мәдрәсәсе булуына, татарның идарәи руханиясе үз кулында булуына, татарның әдәбияты, матбугаты булуына, татарның хатыны-кызы кеше булуына каршы булган хәрәкәттер.

Бу карагруһлык кына түгелдер, Англия кебек адәмнең хокукына игътибар ителгән мәмләкәтләрдә җәза ителә торган җинаятьтер, халыкка каршы, мәмләкәткә каршы җинаятьтер.

Безнең хәятта әле мөхафәзәкярләр чыгарлык дию пәрие адымнары белән алга китү юктыр.

Шуның өчен «мөхафәзәкяр» дигән даирәләр булса, ул үзеннән-үзе килеп чыккан булмаенча, читләргә тәкълидтән ясалган бер маймыллык кынадыр.

Бәгъзе бер даирәләрдә тәрәккыйпәрвәр булдың исә, мәктәп карау, мөгаллим, мөгаллимәгә вазифа бирү, матбугатка иштиракь итү кебек бурычлар туганга, тәрәккыйпәрвәрлекнең оешуы дәверендәге матди чыгышларына ярдәм итәр өчен налог түләү лязем булганга, «мин тәрәккыйпәрвәр түгел, мин мөхафәзәкяр» диючеләр булды. Ләкин болар мөселман мөхафәзәкяренең программасының үзәге булуы тиешле булган зәкят, гошерне дә катгыяны инкяр итәләр вә шул мәсьәләдә кысылсалар, муллаларны сүгәргә тотыналар.

Болар мөхафәзәкярләр түгел, болар төя кошлары, безнең татарның үз эченнән чыккан, үзенең милли төя кошлары, үзенең «гакыллы башлары».

## МӘРХҮМ ТУКАЙ

Кичә Тукай мәрхүмнең вафатына өч ел тулды. Шул өч ел эчендә татарның әдәбият, шигырь галәме моңа кадәр беренче сафында барган Тукайсыз — халык шагыйрьләренең беренчесе булган Тукайсыз яшәде. Татарның мәдәни хәрәкәтләре үзенең һичбер селкенүендә Тукайның сизгеч каләменең очы тимичә китми торган адымнарында, үсүендә, киңәюендә Тукайсыз дәвам итте.

Халыкның рухы — татар халкының рухы, йоклаудан торып, күзен ачкан чагындагы Тукайның рәхмәтле нисан шигырьләреннән сугарылмаенча, сусаган хәлендә дәвам итте.

Татарның дорфа йөрәге, татарның һәрнәрсәгә аршын белән килә торган, бер тиен белән үлчи торган карашы тарих бабайның үткәрергә, чарларга куйган вакытында мәрхүм Тукайның ышкысы-пычкысыннан мәхрүм хәлендә яшәде.

Татар дөньясының өстендә калын болытлар күтәрелә башлап, татар тормышының өстеннән үткән таң җиле, иске пырныган исләрне алып китеп, татар борынына нәфасәт сизгечлеге керә башлаган дәвердә

татар шигыре Тукайсыз, милли Тукайсыз калды. Ниһаять, татарның мәдәни, иҗтимагый хәрәкәтләрендәге мәтәлүләр, асты өскә килүләр Тукайның кискеч сатирасы, пакь көлүләреннән ятим булып барды.

Шагыйрьнең хыялындагы дулкыннар, кайнаулар, галәяннәр, тормышыбыздагы үзгәрешләр, милли мәйдандагы өмидләр, көтмәгән фаҗигаләр остасы юкка хамлыктан чыга алмаенча эшләнә алмады. Мәңгегә кадәр китап сәхифәләрендә фотографлы сакланачак мәнзарәләр югалды, әрәм булды.

Өч ел инде Тукай юк. Тукай үлде. Тукай арамыздан китте. Тукай — тормышымыздагы һәр хәрәкәтнең шигъри тарафын тотып алып мәйданга сала торган Тукай вафат итте.

Тукай — хәзерге үсү дәверемездәге һәр пакь йөрәк тибүен сизеп алып, киләчәк буынга бүләк биреп бара торган Тукай мәрхүм булды.

Инде аңарга өч ел вакыт үтте.

Шул өч елда Тукайның юклыгын без күземез белән күреп, колагымыз белән ишетеп, бөтен тойгыларымыз белән тойдык.

Аның вафат иткән көнендә аның әдәбият мәйданымызда баскан урынына күземезне ташласак, шул буш урынны күреп, Тукай юклыгы тойгысы тагы да көчәядер, зураядыр. Сигез ел бербуйдан рәхмәт чишмәсе агып торган Тукайдан, тазә бер кабер, бер бушлык күрсәк, шул тойгы, күңел сыкравы белән бизәкләнеп, өмидсезлек белән чәчәкләнәдер. Күз алдында ямьсез мәнзарәләр тудырадыр.

Әйе, Тукай үлде. Тукай арабыздан югалды. Тукайны арабыздан көчләп югалттык. Меңнәр-меңнәр фахишәләрне үстерә, киендерә, җылыта торган Идел буе бер шагыйремез — Тукайны матдәтән, мәгънән ашатырлык, туйдырырлык азык таба алмады. Меңнәр-меңнәр җаныйларны җылыта, симертә торган Идел буе беренче шагыйремезгә картлар җылысы кадәр дә җылы бирә алмады.

Ачлыктан, ялангачлыктан, мохтаҗлыктан, фәкыйрьлектән шагыйремезне үтердек, татарның иң зур мәркәзендә меңнәр, йөз меңнәр, миллионнар мохлисе булган Тукайны ачлыкта, суыклыкта үтердек.

Шул фаҗигадә үземез хәзер яши торган халкымыз каршында, киләчәктәге үсәчәк буынымыз алдында без нинди җинаять эшләдек! Без аларны нинди милли байлыклардан мәхрүм иттек.

Тукай белән бергә тазә кабергә күмелгән милли шигырьләрнең кыйммәтләрен кем тәкъдир итәчәк? Чәчәк вакытында җир астына күмелеп, киләчәк буынның байлыгын талауда кем мәсьүл булачак?..

Өч ел эчендә өстенә кабер ташы да куела алмаган Тукайның суык каберенә караганда, күңел сыкрануларының аһы, йөрәк рәнҗүләренең зары кемгә язылачак?..

Тукайның гасырдашлары, Тукайның дәвердәшләре, Тукайның яшәгән даирәсе, Тукайның иле, Тукайның шигыре белән бала-чагасын тәрбия итә торган бөтен Идел буе[на язылачак].

Тукай үлде. Әнә ул шул җимерек кабер астында (ауган тактага Габдулла Тукай дип язылган), коры агач күршесендә Габдулла Тукай ятмаса, бүгенге көндә аның үлгәненә өч ел үтмәгән булса, ничек булыр иде икән?

Ямьсезлек, дорфалык, өмидсезлек белән тулган татар тормышының хакыйкатеннән «Татар тормышы ничек булырга кирәк?» дигән хыял дөньясына күчик әле.

Әнә Тукай, сау, сәламәт, яшь. Аның 27 гә кадәр эшләтелгән, чарлатылган каләме үзенең урынын тапкан. Сигез ел эчендә үсә-үсә бөреләнеп яфрак ярган, аның шагыйрьлек агачы чәчәк аткан.

Аның күз алдында сигез ел бербуйдан бертөсле булып, суык кына, соры гына, җансыз гына, сансыз гына татар тормышы төрләләнә, хәрәкәтләнә башлаган. Анда-монда җанлылык галәмәте күренгән.

Таң вакытында анда карасаң, ыржайган тештән башка көлемсу йөзләр күренгәлиләр.

Көн уртасында зәмһәрир суыгы чыга торган шул җирдән кан җылысы гына килә башлаган...

Сигез еллык шагыйрьлек хәятында эчке җылысы белән генә тора алган, көннең-көнендә Алла биргән шагыйрьлек сәрмаясын кимереп кенә көнен кичерә алган Тукай пакь, тук, ак бер урынга утыртылган.

Менә шул Тукайның алдында өч еллык хәят — татар хәяты үткән... Үзенең тартышы, үзенең табигый үсүе, үзенең бер артка, бер алга чигүләре белән татар тормышының мәнзарәләре үткән...

Сигез ел фәүкылгадә авырлыкта кичергән вакытында, шагыйрьлегенең сабыйлык дәверендә татарның гамәл дәфтәренә шулкадәр зур милли байлыгын мирас калдырган Тукай ниләр язган булыр иде. Нинди әсәрләр белән, нинди шигырьләр белән татар әдәбиятын, татар шигырь дөньясын бизәкләгән булыр иде?

Кем белсен, бәлки, шул өч елда аның «Шүрәле»се унлап иптәш тапкан булыр иде.

Кем белсен, бәлки, безнең иске әкиятләремез, Тукайның шигырь чишмәсендә коенып, бизәнеп, аллыгөлле булып, алдымызда чын кеше кебек килеп басар иде.

Кем белсен, бөтен шагыйрьлек дәверендәге Тукайның фаразы вөҗүдкә чыккан булыр иде дә, татарның үз «Евгений Онегин»ы[1] мәйданга килгән булыр иде.

Кем белсен, бәлки, татарның тарихы, каһарман хатыны Сөембикәсе, хәзер энҗе кебек шигырьләр белән тезелеп, һәммәбезнең телендә йөрер иде.

Кем белсен, бәлки, белегвар Җәгъфәрнең[2] төсе, эше, идеясе гәүдәләнеп, бөтен татар дөньясының алдына утыртылган булыр иде.

Кем белсен, Сакмар суы буйлары, Урал тауларының моңнары, бәлки, шагыйрьнең хыялында әллә никадәр милли поэмалар вөҗүдкә китерткән булыр иде.

Бүген боларның барысы да хыял. Фәкать Тукайны, шагыйрь Тукайны ачтан, суыктан үтергән дорфа татар тормышы гына — хакыйкать.

## КЫРЫМДА ЗЫНҖЫРЛЫ МӘДРӘСӘСЕ ВӘ ИДАРӘИ РУХАНИЯ ЭШЛӘРЕ

Кырымда Зынҗырлы мәдрәсәсе мәсьәләсе ятышмады, идарәи руханиянең мәдрәсәләр исляхы өчен җыйган мәҗлесе килеп катышты. Ул мәсьәлә бертөрле эшкә килерлек хәлгә керергә өлгерә алмады, Кырым мөфтисе Гадил мирза Корашайский истигъфа итә[1] дигән хәбәр таралды. Шуның берлән өченче мәсьәлә килеп туды.

Боларның һәр берәм-берәме генә Кырым өчен бик зур мәдәни мәсьәләләр булганга, кырымлы кардәшләремезнең мәдәни, дини хәятлары белән бик күптөрле йепләр белән багланганга, Кырым әфкяре гомумиясене хәрәкәткә китермәве мөмкин түгел иде. Кырым кардәшләремез җанлы булсалар, бабаларымызның иске иле — Кырымда, Русия татарларының биләгән йирләренең иң матур, иң бай йире — Кырымда. Кырымның тарихи хуҗалары — Кырым татарлары үлмәгән, вафат итмәгән булсалар, матур, кояшлы Кырым яланнары элгәре хуҗалары өчен зиярәткә әверелмәгән булса, тавышларын чыгарырга, теләкләрен сөйләргә тиеш иде.

Озын еллар йокыда ятуына өйрәнеп беткәнгә, без Кырым кардәшләремезнең өстенә килгән шул мәдәни бурычлар алдында уянып, «мин дә бар, минем фикерем шул» дип әйтә алуына курка-курка, шөбһәләнеп кенә карый идек.

Әлхәмделилля, безнең Кырымга каршы биләгән сүи занымыз хата чыкты. Аллага шөкер, кырымлы кардәшләремез арасындагы сонганча килгән тынлык, каберстан тынлыгы булмаенча, ятак тынычлыгы гына булды.

Әлхәмделилля, таң ату белән Кырым агайлары да күзләрен ачып, уйлашырга керештеләр. Зынҗырлы мәдрәсәсе мәсьәләсе аларның уянып, фикерләрен сөйләргә беренче сәбәп булды.

Зынҗырлы мәдрәсәсе... Безнең Идел буенда бу мәдрәсәнең исемен ишетмәгән кеше бармы? Безнең Идел буенда Зынҗырлы мәдрәсәсе хакында Казан университеты, Мәскәү дарелфөнүне кебек эче-тышы тәртипле бер мәдрәсә дип уйламаган кеше бармы?

Мәрхүм Исмәгыйль бабаның егерме биш, утыз еллык «Тәрҗе-ман»ындагы тугрылык белән безгә, Идел буе мөселманнарына үз булган, үзләнеп беткән Зынҗырлы мәдрәсәсе мәсьәләсе Кырымда бу ел яңгы мәйданга чыкты.

Зынҗырлы мәдрәсәсе мәсьәләсе, мөдәррис вафат булу сәбәпле, мөдәррис сайлау мәсьәләсе белән туды.

Иң әүвәл шуны белдерү лязем: Зынҗырлы мәдрәсәсе — Кырымның иң иске мәдрәсәләреннән бер мәдрәсәдер. Моннан өч-дүрт йөз ел элек Кырым ханнарыннан Миңлегәрәй хан тарафыннан Бакчасарайда бина ителгән вә Кырым мөселманнарының гыйльми ихтыяҗларын тутырыр өчен эшләнелгән шул мәдрәсә иләл-әбәд дәвам итсен өчен, зур бер вәкыф калдырылган. Хәзерге көндә шул вәкыфның еллык килере кырык биш-илле мең сумнар чамасында.

Менә шул мәдрәсәнең, әлбәттә, бер низамы, вәкыфның бер шартлары булгандыр. Ләкин ни булса да булган, Кырымның вәкыфы хакында, Кырым Русиягә кушылганда, аерым бер маддә кертелгән булса да, Зынҗырлының вәкыфы да, Кырымның башка вәкыфлары кебек бәрбад бер хәлгә килгән. Кырым мөселманнарының бөтенләенә Миңлегәрәй хан тарафыннан мәңгелек һәдия ителгән Зынҗырлы мәдрәсәсе шул ук аңлатылмау хакында Бакчасарайның читендә, Бакчасарайның Тегәрҗеп урамында чәнәкәләр белән тулган Салаҗык мәхәлләсенең милке булып калган.

Шул олуг вәкыфлар, олуг мәдрәсә хакында Кырымның голямасы, идарәи руханиясе иске ганганәсен генә дә саклый алмаганга, шул Зынҗырлы мәдрәсәсенә мөдәррис сайлау дигән гыйльми бер эштә чегәннәр* мәхәлләсенә имам сайлауның итәгенә генә тегелгән бер мәсьәлә булып киткән.

Менә Зынҗырлы мәдрәсәсенең — елына кырык-илле мең сумнар вәкыфлы мәдрәсәсенең бу көнге аяныч хәлдә булуының төп фаҗигасе.

Кырым халкы, Кырым мөселманнары шул мәдрәсәгә Миңлегәрәй ханның бөтен Кырым мөселманнарына калдырган һәдиясе дип карый. Шуны ислях итәргә бөтен көче берлән тырыша, тырмаша. Бөтен Кырымның голямасы, зыялысы, мирзасы, агасының фикере берлән булдыклы мөдәррис ясар өчен, бөтен законлы юллар берлән хәрәкәт итәргә тотына. «Ислях» ди, программа төзи, мөдәррис эзли, могавиннәр таба...

Вәкыфның килерен-чыгышын рәткә куймакчы була.

Икенче тарафтан Кырымда үз сүзен генә йөртергә теләгән Кырым куштаннары, мәдрәсәләр хакындагы законның ачык йирләреннән файдаланып, «Зынҗырлы мәдрәсәсе Салаҗык мәхәлләсенең мәхәллә мәктәбе, андагы укыту эше имам әфәнденең бурычы» дигән ноктадан килә дә, Салаҗыктагы чегәннәр алай итеп, болай итеп күндереп, үз тарафыннан хәзерләнгән мөдәррисне имам иттереп сайлата. Шул имам түрәләр тарафыннан тасдыйк ителә. Зынҗырлының мөдәррисе Зынҗырлы вәкыфының механически хуҗасы була да керә дә утыра.

Менә бу юлы да шулай булды. Үлгән мөдәррис Хәбибулла әфәнде Зынҗырлы мәдрәсәсенең вәкыфының хисабын бирер өчен җинан Алла тарафына киткәч тә, Кырымның яшь зыялылары, агалары, голямасы арасында, форсаттан файдаланып, муафикъ бер мөдәррис куяр өчен тәшәббескә керешелде. Шуны дустча бетерер өчен, Кырымның голямасы, мирзалары, агалары берлән киңәшләр ясады.

Бакчасарай городской главасы, Кырым мөселманнары арасында үзе теләгәнчә эш йөртүне сөюче Сөләйман мирза Кырымтаев[2] берлән аерым күрешеп сөйләштеләр. Мөдәррислек урынына кеше сайлар өчен киңәш мәҗлесе ясарга карар бирделәр. Шуның көнен тәгаен иттерделәр. Ләкин киңәш мәҗлесенә өч көн калгач, Сөләйман мирза Кырымтаев, Салаҗык мәхәлләсенең халкыннан приговор алып, Мостафа әфәнде исемендәге, зарары да юк, файдасы да юк бер мөдәррисне Салаҗыкка имам иттереп сайлатты. Үзенең түрәләр арасындагы сүз үтүе берлән файдаланып, тасдыйк та иттерде. Шулай итеп, Мостафа әфәнде бөтен Кырымның күзе теккән Зынҗырлы мәдрәсәсенең мөдәррисе булды да механически керде.

Зынҗырлы мәдрәсәсенең кырык биш-илле мең килерле вәкыфының да Аллаһы Тәгалә алдында гына мәсьүле булып барып басты.

Сөләйман мирза Кырымтаевның Мостафа әфәнденең сайлануында, шуны тасдыйк иттерергә ашкынуында, шул мәсьәләдә яшь көчләргә «бергә хәрәкәт итәмез» дигән вәгъдәсенә хилаф хәрәкәт итүендә нинди бер максат эшләнелде, әлбәттә, моннан күреп булмый. Ләкин ерактан карап та, Кырым мөселманнарының голямасы, мирзасы, яшь көчләренә каршы килеп, итәк асты хәрәкәте берлән эшләнелгән бу эштә милләт мәнфәгате, халык файдасы күзәтелмәгәнен ап-ачык күреп буладыр.

Бу хәрәкәттә дә, безнең Идел буенда ресторанчыларның мөфти кую мәсьәләсендәге кебек, итәк асты хәрәкәтләре берлән бер тугма икәне күренеп торадыр.

Бездәге мөфти урынына утырган кеше, күз буявы ясар өчен әллә ниләр тавышланган шикелле, Кырымдагы Кырымтаев мирзаның да «мөдәррисе» дә «Зынҗырлыны ничек ислях итәмез» дип бер мәҗлес ясадылар. Ләкин мәҗлескә нә Кырымның кулга тотарлык голямасы, нә мирзалары, нә яшь гыйльми көчләре килмәде.

Мөдәррис Мостафа әфәнде берлән Кырымтаев Зынҗырлы мәдрәсәсенең хәрабәсе алдында икәү ултырып калдылар.

Яшь көчләр, голяма әфкяре гомумия тагы үзенең өмиде, үзенең мәдәни бер эш эшләргә теләгән өмиде шөбһәле итәк асты хәрәкәтләренә бәрелеп ватылганын күреп калды.

Зынҗырлы мәдрәсәсенә мөдәррис сайлау, мәдрәсәгә программа эшләү мәсьәләсе Кырым әфкяре гомумиясендә, гомумән, мәдрәсә-мәктәп ислахы фикерен тудырды. Шул хакта «Тәрҗеман» гәзитәсендә мәкалә өзелмәгән кебек, «Җәмгыяте хәйрия»ләр, земство идарәләренә докладлар, проектлар йибәрелә башланды.

Кырымның оешкан каны хәрәкәткә килде. Яшь мөдәррисләр, яшь галимнәр, аңлы мирзалар «мәдрәсә-мәктәп ислях ителмәсә, милли тормышымыз харап була» дигән мәсьәлә алдына басканын сизде. Гыйльми, мәдәни мөбахәсәләр китте.

Кырымның идарәи руханиясе, үзенә йоклап ятар өчен генә Аллаһы Тәгалә тарафыннан багышланган дип хыял иткән мәдрәсә-мәктәпнең аяк астыннан тайганын күргәч, «мәдрәсә ислахы» дигән бер тавыш күтәреп, рәсми мәҗлес ясады. Ләкин мәҗлескә нә яшь галимнәр, нә яшь гыйльми көчләр, нә мөхәррирләр чакырылмады. Җыелган мирзалар, мөдәррисләр, муллалар, «суга алмаган зур күтәргән» дигәнчә, мәдрәсәләрне башыннан ахырына кадәр бөтен әсасларын үзгәртеп ислях итәргә дигән карарны кабул иттеләр.

Читтән караганда, бу вакытка кадәр тик йоклап яткан бу мөдәррисләрнең шулкадәр үзгәреп китүләренә Кырымдагы, Идел буендагы, Кавказдагы мәдрәсә хакында иң соң фикердәге яшьләремездән мәсафә-мәсафә сулга китүләре ул вакытта да безне гаҗәпкә калдырган иде.

Дини мәдрәсәләрдә гимназия программасы берлән русча укытылсын дигән теләүгә бераз хәйранга да калган идек.

Хәзер 17 мартта шул мәҗлеснең карары берлән мәктәп-мәдрәсә ислахы хакындагы комиссиянең җыелышыннан мондагы «кызыллык»ның да пәрдәсе ачылды.

17 март комиссия мәҗлесендәге идарәи рухания тарафыннан вәкил булыпмы, яшь булыпмы, господин «М.» дигән рус китерелгән. Бу господинның кемлеген, мәгаттәәссеф, без белмимез. Ләкин киңәш

мәҗлесенең мәдрәсә-мәктәп исляхы комиссиясендә сайланган затлар арасында господин «М.»ның булмавын хәтеремездә тотканга, бераз хәйрат берлән: «Бу писарьнең анда ни эше бар икән? Мөселманнар Коръәнне мәгънәсен аңламаенча укуны мәслихәт табалармы, әллә Чәләбизадә[3] тәкълиф иткәнчә, мәгънәсе дөрестләнеп укырлык булгач кына, балаларның кулларына бирүне муафикъ табалармы? Болар бит господин «М.»ның вазифасы түгел», — дигән идек.

Мәҗлестә Чыңгыз әфәнде, Сәедәхмәт[4] һәм дә Чәләбизадә әфәнделәрнең мәктәп исляхы хакындагы ляихәләре каралганда идарәи руханиянең рус әгъзасы да һәм дә мөселман әгъзасы да «монда мәктәп-мәдрәсә исляхы каралмый, мондагы сүзләр гәзитәдә язарга ярамый» дип йөдәп чыктылар вә шуның берлән әүвәлге мәҗлестәге карарлар эшләр өчен түгел, халыкны бераз тынычландырыр өчен, йокыдан уянып килә торган Кырым мөселманнарын тагы «әлли-бәлли итәр бу» дип йоклату өчен тирбәтү генә икәнлеген изһар иттеләр.

Шулай булмаса, шул беренче мәҗлестәге карарны фагыйлияткә чыгарыр өчен җыелган комиссия сүзләрен бетерер-бетермәс ябылмас иде вә шундагы сүзләр кирәкмәгән бернәрсә дип тыңланмас иде.

Әгәр карарларын тудырырга дигән тәшәббес дөрест булса, вөҗүдкә чыгарырлык бер эшкә керешелер иде. Бу хәрәкәтләренә караганда, идарәи рухания яшь көчләрнең казып чыгарган мәсьәләләрен оныттырыр өчен мәсьәләне салландырып озатырга хөкем итүе кебек күренәдер.

Ләкин Кырымның әфкяре гомумиясе үзенең мәкъдәрәте белән уйнаудан артык туйды булырга кирәк. Шул көннәрдә алынган хосусый хәбәрләремезгә караганда, Кырымда идарәи рухания ислях ителмәгәндә нә мәдрәсәсенә ислях ителәчәк, нә мөдәррис тәгаеннәре әлеге интригалар юлыннан чыгачак, нә вәкыф мәсьәләсе, вәкыфларның теләгәнчә сарыф ителәчәк дигән фикер туганлыгы белдереләдер.

Соңгы көндә шул мәсьәлә янында фикер алышу башланып киткән булырга кирәк. «Тәрҗеман»да Кырым мөфтисе Корашайский истигъфа итә икән дигән хәбәр күрелде.

Әлбәттә, бер мөфтинең истигъфасы берлән генә мәсьәлә хәл ителмәячәктер. Бәлки, кырымлылар алдында тагы зур, тагы әһәмиятле булган мөфти сайлау мәсьәләсе туачактыр.

Мөфтилек урыны Зынҗырлы мәдрәсәсенә мөдәррис булуга караганда тагы олуг, тагы зур булганга, әлбәттә, монда да интригалар, итәк асты хәрәкәтләре булачактыр. Бу табигыйдер. Безнең иҗтимагый эшкә өйрәнмәвемездән килгән гөнаһымызның җәзасыдыр. Ләкин кырымлы кардәшләремезнең рухани идарәләрендә мохтарият закон берлән дә тасдыйк ителгәнгә, анда мөфтилек мәнсуби сайлана торган урын булганга, әлбәттә, алар бер ресторанчыларның үзләренең нәмайндәләрен үткәрүләреннән курку юктыр. Ләкин Кырымның үзенең махсус «Сыйрател-мөстәкыйм»е, Кырымның үзенә махсус интрига базарлары барга, әлбәттә, анда да бик каты тартышу башланаячактыр. Ләкин Кырым кардәшләремезнең бу елгы елда халыкка таба омтылуларындагы фагыйлиятьне күргәнгә, без бу мәсьәләдә чын мөфти сайлаучылар тарафы җиңәр дип ышанып, өмидләнеп каламыз.

## БЮРО БУЛДЫ

Оренбург тарафыннан бюро әгъзасы булып эшләшер өчен яшь юристымыз Нәҗип әфәнде Корбангалиев Петроградка китте[1]. Бүген-иртәгә Мәскәү мөселманнарының бюрога әгъза итеп сайланган затлары да китәчәк.

Уфаның йибәргән әгъзасы[2] күптән хезмәт итеп тора. Димәк, өч-дүрт көндә бюро бөтенләй ясалып бетәчәк, атна-ун көндә бюроның өч шәһәрдән килгән өч әгъзасы элгәредән дә фракциягә бергә хезмәт итә торган Сәлимгәрәй мирза Җантурин берлән дүртәүләшеп эшкә керешәчәк.

Русия мөселманнарының хокукый ихтыяҗлары бик күп булганга, әлбәттә, өч-дүрт кешелек бюро гына бөтен эшләрне алып бара алмаячактыр.

Фракция янындагы эшләрнең Мәкәрҗә өстендә шул халык бик азлык итәчәктер. Ләкин әле болай булуы да бик зур сөенечле эштер вә киләчәктә милләт булып тора белүемезгә өмидне уята торган күңелле фалдыр. Бабайларның «башланган эш — беткән эш» дигән мәкальләре бар. Бюро эше дә никадәр әле башлану дәверендә генә булса да, моның тәмамлыгын да күрү бик еракта түгелдер. Иншалла, Русиянең буена җәелгән мөселманнар шул башланган эшне ярты юлда калдырмаслар, иншалла, халкыбызның хокукый, сәяси ихтыяҗларына чит кеше булып карамый торган аңлыларымыз матди вә мәгънәви ярдәмнән кире тормаслар.

Бюро булды. Бөтенләй шартлары китерелеп үк булмаса да, эшне алып барырлык бюро хәзер булды. Инде шуны ныгыту, шул бюроны милли ихтыяҗымызга нисбәтән зурайту гына калды. Хәзерге көндә бюроның әгъзалары әле Уфа мөселманнарының, Мәскәү сәүдәгәрләренең, Оренбург мөселманнарының

вәкилләреннән генә гыйбарәт. Хәзергә кадәр әле өч ай мөддәтендә шул өч шәһәрнең мөселманнарына башка мөселманнар үз вазифаларын үти алмадылар.

Элгәреге заманнарымызда милли хәрәкәтләремездә беренче сафта торган Казан, беренчелекне Уфага биргән кебек, икенчелекне дә Мәскәүгә оттырды, өченчелекне Оренбургтан ярышып ала алмады. Дүртенчелекне, белмим инде, кемгә бирергә тора торгандыр. Казанның бу кадәр артка калуының, Идел буе мөселманнары арасында зурлык, байлык, халыкның күплеге берлән беренче урында торган Казанның зиярәт өсте кебек тып-тын торуының хариҗи сәбәпләре дә юк түгелдер. Казан түрәләренең лөзүменнән артык шөбһәләнүләре дә манигъ була торгандыр. Моның иң зур сәбәбе, шөбһәсез, Казан татарларының хәзердә кичерә торган әхвале иҗтимагыяләрендәдер.

Казан соңгы елларда көтүчесез калган көтү кебек торды да китте. Шул тору аркасында үзенең берлеген югалтып, мәгънәви яктан көчсезләнде.

Аның һәр урамында үзенә бер «олуг» чыгып, үз хәлкасына таба халыкны борырга кереште. Эш берлән, халыкка файда итү берлән түгел, халыкка файда иткән булып уйнау берлән, милләткә хезмәте берлән түгел, «милләткә хезмәт итәм» дигән сүз берлән, спекуляция ясау берлән халыкны үзенә бормакчы булды. Шул максатка ирешер өчен һичбер васитадан чиркәнмәде. Кара көч, мал көче, гайбәт, интрига, сагыя — һәммәсе ходка йибәрелде.

Шуның аркасында нинди генә мәсьәлә чыкмасын, милли булсынмы, дини булсынмы, берничә даирәнең интригасына корал булудан котыла алмады.

Бюро мәсьәләсе дә шулай булды. Монда партияләр сугышырга, гизле сугышырга кереште. Мәсләк өчен, максат өчен түгел, сугышу-кычкырышуга башка эш юк дип ышанганга тотынды.

Әлбәттә, монда «фәләннең бюрога баруы миңа муафикъ, йә миңа уңгайсыз»лыкларның да, шәхси мәнфәгать яклары да зур роль уйнады, ләкин күбесе бу кычкырышу, бу итәк асты тарткалашуына картага азартланып киткән кеше кебек кенә керде.

Менә шуның аркасында Казан үзенең әүвәлге урынын югалтты. Шуның аркасында алтмыш мең мөселманлы Казан утыз-кырык мең кешедән мөрәккәб Мәскәү сәүдәгәрләре кадәр милли тойгы барлыгын исбат итә алмады. Йөзәр елдан бирле мәркәз булып килгән Казандагы көчләр бу көннәр генә Мәскәүгә җыелган утыз-кырык мең мөселман кадәре генә дә һиммәт, гайрәт күрсәтә алмады.

Инде Казаннан бер генә үтенеч калды. Ул да — шул ясалып килә торган бюроның эшләнеп бетүенә манигъ булмау, бюроның эшләргә дип куйган программасын тутыруына аяк чалмау. Моның өчен Казан өстенә йөкләтелгән актыккы бер милли бурыч бар. Ул да — бюроның хәзерге һәйәтенә интрига кертеп, аларны эшләүдән мәхрүм итәрлек бер хәлгә китерердәй кешене вәкил иттереп йибәрмәү.

Хәзерге бюроның әгъзалары, иттифакый уларак, сүздән битәр эш сөючеләрдән мөрәккәб. Боларның барысының да артында шәхси гайрәт берлән үткән авыр юлларда биек таулар күренеп тора. Боларның берсенең дә гамәл дәфтәрендә сәясәткә осталык, интрига ясый белүгә маһирлык дигән сыйфатлар юк. Боларның берсенең дә эшләргә дигән уйларында, милли файдага дигән омтылуларында милли мәнфәгатьне спекуляциягә чыгару дигән карта юк.

Боларның барысының да башында җыйган саф мәгълүматлы, күңелендә халкының хокуклы булуына иман, йөрәгендә шул милли омтылуларны алып барырлык көче генә тулы.

Болар тормышның кара юлларыннан керергә өйрәнмәгәннәр. Болар итәк асты тартышуларга чыныкмаганнар. Болар интрига берлән эш итәргә алышмаганнар.

Шуның өчен Казан кеше йибәрәчәк булып та, интригант кешене күндерсә, аның бюрога вә шуның аркасында бөтен халкыбызга иткән хезмәте бәүлиснең иткән хезмәте белән бер булачактыр.

Казанда шул хакта куркынычлар күз алдына басып торса да, башка шәһәрләрдә дә мондый куркулар юк түгелдер. Шуның өчен алардан да кеше йибәрелгәндә, эшли белүенә башка, оешып эшли алырлык саф милли өмидле сахибе булу кебек сыйфатларны шарт итәргә тиештер.

Бюроның эшләячәк эше, әлбәттә, фәүкылгадә күптер. Ләкин хәзерге көндә безнең Идел буе мөселманнарының гына түгел, Кырым, Кавказ, Төркестан, Кыргыз даласы мөселманнарының һәммәсенең иң авырткан йирләре — рухани эшләремездер.

Әби патша заманындагы эшләнгән законның — 150 елдан бирле рухани тормышымыз хакындагы төзәтелмәгән законның — дини ихтыяҗларымызны үтәргә йитмәвендәдер. Идарәи руханияләремезнең исляхы, мәхәллә тәшкилаты, рухани мәдрәсәләремезнең мәгълүм закон астына алынуы, вәкыфларымызның идарәсе закон берлән тәгаен ителүе беренче дәрәҗәдәге эшләремездәндер.

Шуның өчен «бюро», фракция берлән бергәләшеп, шул хактагы закон ляихәсене ашыгычлык берлән хәзерләргә тиештер.

Икенче дәрәҗәдә, шөбһәсез, һәр йирнең мөселманнарының хокукының тигезләнүе мәсьәләсе.

Земстволар, шәһәрләргә сайлаулар, Төркестанда йир ала алмаулар, кыргыз даласына мөһаҗәрәт итә белмәүләр, Төркестан, Казакъстанның Думага әгъза сайлаулары, [Государственный] советта мөселманнарымыздан әгъза булындырулар... вә һәказә, вә һәказә...

Болар, әлбәттә, бик күптер. Моңгарга башка фракциянең үзенең ясалуы хакында да бик күп эше бар. Ун елдан бирле, мәсәлән, хисабы бирелмәгән. Ун ел эчендә, мәсәлән, фракциянең җыелган материаллары бер хәлгә китерелмәгән. Ун елдан бирле мәсьәлә бер мәртәбә депутатларымызның мәҗмуг речьләре берлән халкымыз таныштырылмаган. Ун елдан бирле фракциягә килгән төрле йир мөселманнарының теләкләре-үтенечләре бер йиргә җыелып, бер фикер чыгарылмаган.

Эш күп, эшче генә аз.

Файдаланырга торучылар күп. Бу көнге көндә бурычны үтәүчеләр генә аз. Ашлык өлгергәч, ашарга торучылар күп. Бу көнге көндә орлык чәчкәндә, кечкенә генә түтәлгә җитәрлек тә орлык бирүчеләр аз.

Алай да эшләргә кирәк. Саныңызның азлыгына да карамаенча, эшегезнең күплегеннән дә курыкмаенча эшкә башлаңыз.

Иманыңыз юлдашыңыз булсын. Алла могниеңез булсын.

Милләт сүз көтми, эш көтә.

Милләт спекуляциядән туйды, эшкә сусады.

## МУСА ӘФӘНДЕНЕҢ «СЫЙРАТЕЛ-МӨСТӘКЫЙМЧЕ»ЛӘР БЕРЛӘН МӨНӘСӘБӘТЕ

Апрельнең 5, 6 нчы көннәрендә чыккан «Вакыт» гәзитәсендәге Муса әфәнде Бигиевнең мәкаләләре моңганчыга кадәр тиелмәенчә үткән бик күп мәсьәләләрне ачарга мәҗбүр итә. Болар арасында, әлбәттә, иң зурысы — Муса әфәнде Бигиевнең 14 нче елдан 16 нчы елга кадәр булган мөддәттә «сыйрател-мөстәкыймче»ләргә мөнәсәбәтенең үзгәрүедер. 14 нче елда «сыйрател-мөстәкыймче»ләрнең алган юллары мөселманнар өчен катгыян зарарлы дип ышанган Муса әфәнденең 15 нче елларда зарарлыгына шөбһәгә керүе, 16 нчы елда аларның мәсләкләрендә курку күрмәү, ахыргарак тугрыдан-тугры аларга таба маил итү, кул сузуда тәдриҗи үзгәрүдер.

Муса әфәнденең әхвале рухиясендәге бу үзгәреш Муса әфәнденең мәсләгендәге уңга таба авышу гына булса, суллардан, уртачалардан саф күңелләре булган кебек, ник уңнардан пакь теләүчеләр булмасын диеп китәргә, бәлки, мөмкин булыр иде. Ләкин Муса әфәндедәге фикер авышу һичбер төрле уңлану, урталану кебек, вөҗдан кушуы берлән эшләнгән хәрәкәткә охшамаганга, Муса әфәнденең сәяси дөньядагы шул сикерүе башыннан ахырына кадәр пакьлектән былчырак дөньясына, саф хезмәттән сату-сатылу базарына омтылу-атылуына охшаганга, табигый, без аңгарга сәерче булып кала алмыймыз.

Табигый, без аңгарга, Муса әфәнде үзе әйткәнчә, «сез үз фикереңездә хөр булсаңыз, мин дә үз уемда хөр» дигән сүз берлән, «Дин вә мәгыйшәт»нең «сез безнең хөрриятемезне тәхдид итеп, үзеңезнең байрагыңызга язылган фикергә хилаф итәсез» дигән сүзләренә моназарә өчен китерелгән могарәзәләренә генә разый була алмыймыз. Шул мәсьәләгә үземезнең нәзарымны ап-ачык әйтеп бирергә мәҗбүр буламыз.

Шул сүз вакытларында, бәлки, кирәге бик үк булмаган мәнзарәләр ачылыр. Бәлки, әфкяре гомумия алдында ябык булуы хис-нәфасәт буенча теләнелгән милли чирләремездән пәрдәләр алыныр. Бәлки, нечкәргән кешеләрнең хисләрен тәхкыйрь итәр?

Ләкин хәзерге көндә Муса әфәнде, үзенә зимнаи нисбәт ителгән гөнаһлар, гаепләрне «юк, мин эшләмәдем» дип бетерер йирдә, бөтен «сыйрател-мөстәкыймче»ләргә каршы хәрәкәткә югарыдан торган булып, былчырак ыргытырга теләве шул пәрдә ачудагы бөтен мәсьүлиятне аның өстенә йөклидер. Безнең шул мәҗбүри бәятнатымызда ачылачак серләрнең мәсьүле Муса әфәнде булып каладыр.

Баштан башлыйк:

13 нче елның ахырында «Ил» гәзитәсе идарәсендә Баязидовлар, Байрашовлар «Сыйрател-мөстәкыйм» дигән исем берлә «Союз русского народа»ны татар тормышына татбикъ итәргә телиләр» дигән хәбәр алынды.

Идарә шул вакытта ук шуны җентекләргә кереште. Баязидов, Байрашов, Ялышев, Җаубаш Гариф мулла вә башка берничә кешенең имза ителгән уставы кулына төште.

Шул союзны татарчаландыруга ярдәмчеләрнең берсе мөселманнарга дошман даирәләр һәм дә «Союз русского народа»дан бер марҗа икәнлеге беленде.

Шул «Союз русского народа»ның гайре рус милләтләргә дошманлык фикерен таратыр өчен, «Нур» гәзитәсен көндәлек иттереп зурайту ниятендә икәнлекләре аңлашылды.

Русия мөселманнарының теләкләрен, өметләрен, милли гаяләрен «Союз русского народа» теләгәнчә генә борыр өчен Петроградта Баязидов, Байрашов, ресторанчы Ялышев, Акчурин, тагы берничә вак-төяктән бер мәркәзи комитет ясарга карарлары мәгълүм булды.

Шул материал берлән «Ил» идарәсе мөселман фракциясенең әгъзаларына һәм дә Петроградның могтәбәранына мөрәҗәгать итте.

14 нче елның башында шул материал өстеннән ике-өч мәҗлестә мөзакәрә булды. Мөзакәрәләр сер тотылу лязем булганга, мәҗлестә «Ил»дә имзалары чыккан (Муса әфәнде шулар арасында) затлар берлән бәгъзе бер сәбәпләрдән имза куелулары матлуб булмаган тагы ике кеше бар иде.

Озын тәхлилдән соң мәҗлес «Сыйрател-мөстәкыйм»нең, мотлакан, мөселманнарны алдар өчен ясалган бер тозак икәнлеге фикеренә килде вә, шул фикерне әфкяре гомумиягә ачып биреп, хәтәр барлыгын игълан итүне милли, мәдәни вә вөҗдани бурычы дип хисап итте һәм игълан итте.

Муса әфәнде Бигиев шул мәҗлестә «Сыйрател-мөстәкыйм»не һичбер төрле якламады. Аларның алдакчылыкларына һичбер шөбһәсе юк икәнен кат-кат әйтте. Мәҗлес кабул иткән резолюцияне йомшаграк табып, тагы катырак гыйбарәләр куллану ляземлеген алга сөрде.

Мәҗлеснең әфкяре гомумиягә мөрәҗәгатенең нәтиҗәсе һәммә кешегә мәгълүм.

«Сыйрател-мөстәкыймче»ләргә эшләрен йөртә белмәгәннәре өчен таяначак даирәләре акча бирмәделәр. Мөселман дөньясы да аларга ләгънәт укыды.

Карагруһ партиясе мөселманнар арасында «Сыйрател-мөстәкыйм» исеме берлән мәйданга чыга алмаенча калды. Шул вакытта «сыйрател-мөстәкыймче»нең Байрашовы мәгънәви ярдәм теләп, ягъни мөселман әфкяре гомумиясен булыштырырга ният итеп, иттифакый Петроградта тугры килгән Фатих әфәнде Кәрими һәм дә Исмәгыйль бәк Гаспринскийларны зыяфәт итте.

«Сыйрател-мөстәкыймче»нең икенчесе Сафа Баязидов, миңа мөрәҗәгать итеп, «Сыйрател-мөстәкыйм»гә каршы компанияне бетерергә үтенде. Ләкин боларның икесенең дә планнары җимерелде. Кирәк, Исмәгыйль баба, кирәк, Фатих әфәнде, кирәк, мин, хәйләләренә алынмадык. Җыланның куенымызга керергә теләвенә, туңган булып, мескинләнеп маташуына инанмадык.

Безнең шул инанмавымыз тугры булып чыкты. Шау-шу басылгач та, Баязидов, Байрашов компаниясе үз юлларында хәрәкәт иттеләр. Баштан бер комитет ясап, зур союз оештырырга имкян юклыгын белгәч, үзләренең карагруһларына таянып, мәмләкәт эчендә оячыклар ясадылар. Үзләренең агентлары белән итәк асты мөнәсәбәткә керештеләр. Мөселманнарның зуррак урыннарында дәрәҗә, малга кызыга торган, дин, мәсләккә өстән карый торган ярты фасикъ, ярты муллаларны үзләренә багладылар. Уфада, Казанда, Оренбургта, Касыймда төпле нигезләр кордылар. Анда-бунда кечкенә-кечкенә агентлар хәзерләделәр.

Менә шул вакытта Петроградта яңгы бер мәсьәлә туды. Зариф хәзрәт Йунысов вафат итте. Шунының урынына Муса әфәнде Бигиев имам булу юлына керде. Монда, әлбәттә, искиткеч бер эш юк. Егерме ел мәдрәсәдә укыган бер дин галиме, урын чыккач, мәхәллә халкы сайлагач, ник мулла булмасын? Ләкин Муса әфәнде шул эшендә әлеге Баязидларның арка терәкләре «Сыйрател-мөстәкыйм»гә җан өрүче Минкинга мөрәҗәгать итте. Аңгарга үзе барып, ярдәм теләде.

Минкинның мөселманнарга ничек каравы Муса әфәндегә мәгълүм булганга, аны үзенә ышандырыр өчен Муса әфәнде ниләр сөйләгәндер, әлбәттә, без белмимез, ләкин Муса әфәнденең шул юл берлән дә михраб иясе булырга тырышып ятканын онытмыймыз.

Ләкин ул ялыну да файдалы чыкмады булырга кирәк, Муса әфәндене имамлыкка тасдыйк итмәделәр.

Шул арада мөфти Солтанов үлү белән мөфтилек мәсьәләсе туды. Баязид, Байрашлар, үзләренең агентлары берлән Минкинга таянып, мөфтилек түренә кичтеләр.

Әфкяре гомумия шау-шу килде. Протест китте. Матбугат протест итте. Әфкяре гомумия протест ясады. Дума әгъзалары протест ясады.

Муса әфәнде дә протестчылар арасында иде. Ул «Баязидов мөфти булса, мин имам булмыйм, отказать итәм» дип сөйләнде. (Ләкин Муса әфәндене тасдыйк итмәү Баязидов мөфти булганчы ук беткәнгә, бу отказ, әлбәттә, туйдан соң ителгән дөмбер генә иде.)

Баязидның мөфти ителүен протест итеп, мөселман фракциясенә «Дума мөнбәреннән укылсын» дигән мөрәҗәгатькә Муса әфәнде беренчеләр арасында имза атты. Шул фикергә күбрәк затларның иштираке өчен хезмәт итте. (Бу хакта «Дин вә мәгыйшәт»тә озын мәкалә булганга, монда без матбугатка мәгълүм түгел нәрсәне ачмыймыз.)

Шуннан соң? Шуннан соң ни булды? Мәгълүм түгел. Теге кәгазь фракциягә барып җиттеме? Әллә ул бәгъзе бер кешеләрнең Баязидларга көчләрен күрсәтер өчен корал гына булып калдымы?

Ләкин көз көнендә Баязидов Петроградка жалуния арттырырга кайткач, Муса әфәнде, мөфтилегенә протест иткән имзасының карасы да кипмәс борын, Сафа мулланы зыярәт итте.

Ни сөйләгәнлекләре, әлбәттә, безгә мәгълүм түгел, ләкин шуннан соң теге протест кәгазе әллә нишләде...

Халык арасында «Баязидлар «Ислам вә мәгариф» дигән гәзитә чыгаралар икән, Муса әфәнденең дә катышы бар икән» дигән сүз чыкты.

Мин үзем шул сүзләргә һичбер төрле әминият итмәгәнгә, Муса әфәнде берлән бер күрешкәндә (октябрь-ноябрьдә булырга кирәк), «Ислам вә мәгариф» хакында сорадым. «Миңа киңәшкә килгәннәр иде, бик һәйбәт киңәш бирдем, Шаһтәхтинскийны, Вәгыйз Нәүрузины күрсәттем. Маташып йөриләр», — диде. Үзе дә көлде. Мин: «Хаҗи Теләшине дә күрсәтү кирәк иде», — дидем дә мәсьәләне көлеп бетердек.

Шуннан соң Петроградтан «Муса әфәнде «сыйрател-мөстәкыймче»ләр белән чуалып йөри» дигән хатлар, хәбәрләр алдым. Бераз арттыру бардыр дип артык әһәмият бирмәдем. Гәзитәгә бер хәбәр дә кертмәдем. Беркөнне яшьләр мәҗлесендәге Муса әфәнденең «Ислам вә мәгариф» хакындагы бәянате хакында озын бер хат килде. Үз кашымда инабәте бар кешенең мәктүбен икенче бер танышым тәэкид итте. Мин һаман әле: «Болай гына бетмәсме, Муса әфәнденең шул маташуы бер аңлашылмау гына түгелме?» — дип, гәзитәдә бер хәреф кертмәдем.

Шул арада Муса әфәндегә хәерхаһлыгында һичбер шөбһә булмаган бер заттан килгән хатта: «Хәл-әхвальнең асты-өсткә килде: «Ислам вә мәгариф»кә матбага бирү хакында Муса әфәнде берлән бик озак сөйләштем. Үз фикереннән кайтара алмадым. Ниһаять, фәлән әфәнделәр, фәлән әфәнделәр ташларга киңәш бирделәр. Тәэсиремез булмады. Гәзитәдә шул хакта бернәрсә биреңез әле. Муса әфәнде гәзитә сәхифәләрендә үзенең кылырга теләгән эшен күрсә, ни икәнен белеп фикереннән кайтмасмы!» — диелгән иде.

Шул арада Петроград мөхбиремездән «Муса әфәнде, «сыйрател-мөстәкыймче»ләр» дип бер мәкалә килде.[1]

Бу мәкалә басылу берлән Муса әфәнде катгыян рәд итәр дә шул сүзләргә урын калмас дип, «Сүз»дә бастык.

Мәкаләнең башына үз тарафымнан Муса әфәнденең рәдден көтеп калганымызны аңлаттым. Шуңгарга каршы Муса әфәнде, хосусый мәктүб берлән: «Хәтерем калды, кәефем китте», — дип, теге мәкалә өчен үпкәсен белгертте. (Муса әфәнде бу хат ахырында: «Теләсәгез, гәзитәгә языңыз», — дигән иде.)

Мин, Муса әфәнденең шул зур милли мәсьәләне хәтер калу, кәеф китү берлән үлчәвенә гаҗәпкә калып, мондый мәсләки мәсьәләләрдә атамның да хәтере калуына илтифат итәргә ярамаганын язарга уйладым. Ләкин шул арада Петроградка киңәш мәҗлесенә чакырылганга, анда сөйләргә калдырдым.

Муса әфәнденең «Сыйрател-мөстәкыйм» берлән маташып йөрүе үзе өчен дә зарарлы, халык ноктаи нәзарыннан ямьсез икәненә ышанганга, Мәскәүдәге дустларына барып, Муса әфәндегә мәктүб язуларын, аларның да Муса әфәндене шул фикердән кайтарырга димләүләрен үтендем, һәм дә алар яздылар да.

Петроградка баргач та, Муса әфәндене тискәре күреп, шул хакта сөйләдем. Ләкин Муса әфәнденең сөйләгән сүзләре һаман «һидаять теләгән кешегә мин [каршы] тормыйм»нан гыйбарәт булганга, үзенең ничек каравын ап-ачык әйтеп бирмәгәнгә, канәгать хасил итә алмадым.

Элгәреге елдагы «Сыйрател-мөстәкыйм»гә каршы чыккан затларны күбесен аерым-аерым күреп, шул хакта сөйләштем. Алар барысы да: «Муса әфәнденең «сыйрател-мөстәкыймче»ләр берлән чуалып йөрүе болай да мәсләкендә ныклыкка өйрәнмәгән халык арасында чуалуны, авуны тудырачак, иҗтимагыятемезгә сәбатсызлык кертәчәк һәм дә карагруһларымызның теләге булган безнең белән бергә барган, бергә хәрәкәт иткән куәтләремезне бүлү булачак», — диделәр вә шуңардан мөмкин кадәр асатча чыгар өчен, Муса әфәндене чакырып, бер мәҗлес ясарга карар бирделәр.

Фракция рәисе Котлыкай мирзаның өендә мәҗлес ясалды. 14 нче елда имза иткән затлар гына җыелган иде.

Сүз башланды. «Ислам вә мәгариф»кә матбага бирү хакында Муса әфәнде тугрысында чыккан хәбәрләрнең дөрестме-түгелме, теге вакыттагыга караганда Муса әфәнденең «Сыйрател-мөстәкыйм»гә каравы үзгәргәнме, юкмы?» — дип сөаль бирдек.

Муса әфәнде озын бәянаттә булынды. Аныңча, сүзенең хөласасы моннан гыйбарәт: Госман Галикәев дигән Байрашовның мөгаллиме һәм старший официанты, Муса әфәндегә килеп, Муса әфәнде уйлаган «Мөнбәр» гәзитәсен чыгарса, Фатих Байрашов нашир булачагын сөйләгән. Муса әфәнде аңгарга разый булмагач, үзләре — Госман әфәнде, Фатих Байрашов «Ислам вә мәгариф» исемендә гәзитә чыгарырга карар бирүләрен белдергән һәм дә Муса әфәндене баш мөхәррир булырга чакырган. Муса әфәнде, үзе гәзитә башында торырга разый булмаса да, һәйәте тәхририя төзеп бирергә өстенә алган. Шуның өчен

Габдулла Гыйсьмәтине[2] күрсәткән, Вәгыйз Нәүрузины[3] тәкъдим иткән. Габдулла Сакмари берлән Хәлим Искәндәревләрне[4] чакырырга мәслихәт тапкан. (Боларга үзе хатлар язганмы, башкалардан яздырганмы — Муса әфәнде ачык җавап бирмәде.)

Шуннан соң Фатих Байрашов, Госман Галикәев берлән һәм дә «Петроградский листок» дигән урам гәзитәсенең бер язучысы берлән Муса әфәндегә килгәннәр. Теге русны «Ислам вә мәгариф»нең русча мөхәррире иттереп күрсәткәннәр. Муса әфәнденең матбагасында бастыруны рәсми сораганнар. Муса әфәнде ачык җавап бирмәсә дә, рус урынына Шаһтәхтинскийны чакырырга кушкан. Байрашов чакырган.

Сөйләгән вакытта Байрашов гәзитәнең басылуы өчен матбага бәһасе дип һәр айга мең дә ике йөз сумны тәэмин итәргә булган. (Уникe номер гәзитәнең матбага эше дүрт йөз, биш йөз сумнар чамасында.)

Байрашов Муса әфәндегә «мәсләке хакында наширының катышы юк» дип, һәр номерында язарга да вәгъдә иткән. Муса әфәнде алырга разый булуга якын бер сүз биргән. (Муса әфәнде әйтеп бетермәенчә, очын яшереп сөйләгәнгә, ике арадагы мокавәләгә кул куелып-куелмавы мәгълүм булмады.)

Шуннан соң гәзитәләрдә («Сүз»дә) мәкалә чыккан. Муса әфәнденең хәтере калган, кәефе киткән...

Шунда Муса әфәнденең бәяны тәмам.

Мәсьәлә өстендә сүз китте. Иң әүвәл, Муса әфәндене матбага бирмәсен дип кенә димләргә килгән затлар алдында Муса әфәнденең һәйәте тәхририя ясашуы да килеп баскач: «Муса әфәнденең «Сыйрател-мөстәкыйм»гә карашы да үзгәрмәдеме?» — дигән сөаль яңгыдан зураеп туды. Озын сүзләрдән соң Муса әфәнде: «Мин аларны һидаятькә киләләр дип ышанам. Мин Фатих әфәнденең шул эше гөнаһын йолар өчен эшләү дип беләм», — диде.

Озын сүзләрдән соң Муса әфәнденең яки алдануы, яки алданырга теләве ап-ачык күрсәтелде. Җәмәгать эшендә йөргән кешенең шундый мәсләки эштә юк-бар берлән уйнарга ярамавы, мондый аву-түнүләр сәяси фәхешне таратырга сәбәп булуы төрлечә сөйләнелде. Муса әфәнде: «Алай булса, мин боларга матбага бирмим», — диде. «Бик һәйбәт. Алай булса, теге чакырган кешеләреңезгә, инде килүеңез мәслихәт түгел, дип әйтеңез, хата булганлыгын аңлатыңыз, халыкка да: «Безнең «Сыйрател-мөстәкыйм»гә каравымыз һаман әле бертөсле икәне мәгълүм булсын», — диелде.

Муса әфәнде тагы: «Юк, һаман әле «Ислам вә мәгариф»нең зарарлы түгеллегенә ышанам. Ләкин бу эшне сезнең хәтер өчен генә кылам», — диде.

Алты сәгать мәҗлестә сөйләнелгән сүз, ителгән карарлар тагы хәтер саклауга килеп төшкәч, мәҗлес аптырап китте. Вакыт бик соң булганга, тагы бер мәҗлестә мөзакәрә итешергә булып таралды.

Шул вакытларда Петроградның укучылары арасында «Ислам вә мәгариф»кә секретарь булып керергә йөрүче Габдулла Гыйсьмәтигә мөнәсәбәтләре хакында киңәшләре булды. Укучылар, үзләренең иптәшләре булып йөргән бу кешенең «Ислам вә мәгариф»кә секретарь булуы дөрест чыкса, бу эшкә милли җинаять дип карап, галякаләрен кисүләре хакында карар кабул иттеләр вә шул карарны казыя мәшрута сурәтендә язып, Габдулла Гыйсьмәтинең үзенә дә кул куярга имкян бирделәр. (Мөзакәрәләр ничек булуы мәгълүм булмаса да, Габдулла Гыйсьмәтинең имзасы булмады.)

Шул каршы хәрәкәт Байрашлар лагеренда курку уятты. Матбугатка мәсьәләнең чыгуы тагы йомгак очларын чуалтачаклыгыннан куркып, төрле хәбәрләр тараттылар. Мөмкин кадәр протестларның чыкмаенча торуына иҗтиһад иттеләр. «Ислам вә мәгариф» берлән мөнәсәбәтләре бар дип шөбһәгә төшелгән әфәнделәрнең һичберсе һичбер гәзитәдә рәддия ясамадылар. Һичбер төрле «минем катышуым юк» дигән сүзне кычкырып сөйләмәделәр.

Муса әфәнденең матбагасын бирүе-бирмәве, Муса әфәнденең Байрашовларга, Баязидовларга «һидаять табар өчен маллары берлән ярдәм итәргә йөрүчеләр» дип, карашы үзгәрүе-үзгәрмәве мәгълүм булмады.

Петроградтан алынган хәбәрләрдә «сыйрател-мөстәкыймче»ләрнең протестлары чыкмас борын, гәзитәләрен чыгарып, татар әфкяре гомумиясен мөфтилек мәсьәләсендәге кебек «әмре вакыйг» алдында калдырырга теләүләре мәгълүм булды. Шул юл берлән алар «мосыйбәт хәерле улсын!» дип, «Сыйрател-мөстәкыйм»нең яңгы бизәкләр берлән бизәнеп, милли мәйданымызга чыгып утыруына ышандылар.

Шул арада Петроград укучылары, яшьләре, үзләренең ноктаи нәзарларын ап-ачык итеп, «Ислам вә мәгариф» хакындагы бәяннарын гәзитәгә басарга җибәрделәр. Бәяннамәдә утыз-кырык имза булса да, бу халык, Петроградта торып, кирәк, Муса әфәнде, кирәк, аның ярдәмчеләре вә кирәк, Байрашлар компаниясен бик якыннан торып белсәләр дә, Муса әфәнденең йә башка берсенең катгый рәдде чыгып, мәсьәлә капланмасмы өмиде берлән бәянны портфельдә тоттык. Ахырдан, тегеләрнең һаман «Сыйрател-мөстәкыйм» берлән чуалып йөрүләре хакында берничә даирәдән катгый хәбәрләр алгач, бәяннамәләрен җибәрдек.

«Сүз»дән «Йолдыз», «Кояш», «Тормыш», «Тәрҗеман» алды. Кавказның «Ачык сүз», «Яңгы икъбаль» мәсьәләгә катышты[5]. Бу гәзитәләр һәммәсе мәкаләләр яздылар, фикерләрен бәян итте.

Үзенең урыс кафтанын ертык чапаннары берлән яшерен чыгарга теләгән «Сыйрател-мөстәкыйм»гә каршы әфкяре гомумиядә хәрәкәт китте.

Протестлар язулар... игълане нәфрәтләр...

Шулар мөнәсәбәте берлән Петроградның җәмәгать хезмәтчеләре, үзләренең карашларын әйтер өчен, Петроградта баш күтәрә торган «Ислам вә мәгариф»не ничек тануларын мөхакәмә итәр өчен теге вакыттагы кебек яңгы мәҗлес ясадылар. Котлыкай мирзаның чакыруы буенча тагы җыелдылар. 14 нче елдагы «Сыйрател-мөстәкыйм» уставын тикшергән мәҗлестәге бөтен әгъзалар булган кебек, Муса әфәнде дә шулар арасында иде. Мәҗлес мөзакәрәгә керешкәч, Муса әфәнде үзенең мәҗлестә битараф калачагын, мөзакәрәгә катнашмаячагын игълан итте. Мондый мәҗлесләрдә битарафлык уңгай булмаса да, мәҗлес дәвам итте. Озын сүздән соң шундагы затлар, хәзер чыгарга хәзерләнә торган «Ислам вә мәгариф» «Сыйрател-мөстәкыйм»нең киемен үзгәртүе генә, моннан элек «сыйрател-мөстәкыймче»ләргә ничек әминият итәргә ярамаса, хәзер дә шулай ук икәнлеге хакында резолюция кабул иттеләр. Шуны имзалап, чыгуы рәсмән игълан ителү берлән матбугатка чыгарырга булдылар.

Рәсми мәҗлеснең ахырына кадәр битарафлыкны саклаган Муса әфәнде мәҗлес бетеп, чәйгә керешелгәч, фракцияне тәнкыйть итәргә кереште. Фракция фәләнне эшләмәде, моны эшләмәде, фракция үз вазифасыны үти алмады, чит эшләр берлән шөгыльләнә башлады, дип, киңәш мәҗлесенә күчте. Киңәш мәҗлесе фәлән итте, төгән итте, дип, аны тәнкыйть итәргә кереште. Котлыкай мирза: «Муса әфәнде, мин киңәш мәҗлесенең рәисе идем. Андагы чакырылган кешеләрне мин үзем ышанып, иптәшләрем белән киңәш итешеп чакырган идем. Сез шул дәгъвәтлеләр арасында идеңез, мәҗлестә һәркемгә үз фикерен сөйләргә рөхсәт булды. Бу сүзләрне сез шул вакытта сөйләү кирәк иде, әгъзалары таралып беткән бер мәҗлесне хәзер тәнкыйть итү иҗтимагыять әдәбенә мохалиф эш», — диде. Муса әфәнде, шул тәнбиһләргә колак салмаенча, киңәш мәҗлесендәге сүзләрне, шундагы затларны тәхкыйрь итәргә тотынгач, мәҗлес Муса әфәнде өчен күңелсез вакыйга берлән тәмам булды. (Болар «Дин вә мәгыйшәт»нең 14 нче номерында ачык язылганга[6], бу мәсьәләдә сер ачу мәсьүлияте миңа гаид түгелдер.) Муса әфәнденең ноктаи нәзары тагы мәгълүм түгел бер хәлдә калды. Шулар хакында дүрт-биш төрле урыннан аерым-аерым мәгълүматлар алсам да, моның хакында мин бер сүз язмадым. Бер сүзне гәзитәмездә йибәртмәдем. Вакыты берлән Муса әфәнде үз тарафыннан рәддия язар дип көтеп калдым.

Шул арада яңгы вакыйга булды. «Сыйрател-мөстәкыймче»ләр, татар матбугатының саф башындалыгын күреп, вазгыятьнең үзләре өчен уңгайсызлыгын сизделәр. Гәзитәләрен чыгарудан ваз кичтеләр. Язучылар, матбагалар берлән бөтен мөзакәрәләрен кистеләр.

Шуннан соң өч-дүрт ай ел элек үк үзләренең катышлары юклыгын игълан итүләре гыйззәте нәфсе өчен тиеш булган әфәнделәр берсе артлы берсе рәддия язарга керештеләр.

«Сыйрател-мөстәкыйм» берлән мөнәсәбәттә исеме зикер кылынган Вәгыйз әфәнде Нәүрузи «Сүз»гә рәддия китерде. Рәддиясенең ахырында максаттан чыгып китүләр булса да, «Сүз»гә керер өчен тулмаган урыннары күренеп торса да, битарафлык итәр өчен генә бастырдык.

Кизү Муса әфәндегә килеп җитте. Ул шул хакта ачык мәгълүмат бирү урынына «Вакыт» гәзитәсендә «Әүвәлге сүзләрем» дип, матбугатка каршы хаким сыйфаты берлә әллә ниләр сөйләмәкче булды. Әдәп дәресе сатты. Нәсыйхәт укыды.

Ләкин «Сыйрател-мөстәкыйм» берлән мөнәсәбәте хакында ап-ачык иттереп «юк» дигән сүзне әйтмәде. Укучылар алдында «Тагы ни булды?» дигән төтенне калдырды. Шуның өчен шул фактларны бирү изһаре хакыйкать өчен лязем күрелде.

Хәзер әфкяре гомумия шундагы фактлар берлән Муса әфәнденең шапырынуындагы буш сүзләрен үзе үлчәсен!

Яхшы берлән яманны, әдәпле-әдәпсезне аеру — әфкяре гомумиянең вазифасы.

Кайда мәсләк бар, кайда авышып йөрүне күрү — аңлы татарның үз бурычы.

## МӘСКӘҮДӘ ИКЕНЧЕ АДЫМ

Мәскәүдә мөселман каракүлчеләренең оешып, мал алыр өчен яңгы тиҗарәтханә ачулары гәзитәмездә язылып үткән иде*[1]. Яңгы тиҗарәтханә Мәскәүнең каракүлче сәүдәгәрләреннән абруйлы утызлап фирманы бер эш янында җыя алганга, бу тиҗарәтханә тәэсисе анда-монда бер кибет яисә бер магазин ачу кебек кечкенә генә эш түгелдер. Мондый зур оешулар әле безнең мөселман сәүдәгәрләренең арасында яңгы булганга, бәлки, шул тиҗарәтханә — зурлыгы, эшенең киңлеге, катышкан фирмаларның күплеге берлән Идел буе татарлары арасында беренче эштер.

Тиҗарәтхәнәнең максаты, аның сату-алу юлында итәргә теләгән эше, тиҗарәтханәне тәэсистә куелган әсаслар — милли хәятымызда зур роль уйнаган сәүдә эшенең икенче адым атларга хәзер торганын күрсәтә торган хәерле фалдыр.

Мәгълүм ки, безнең халык никадәр сәүдәгәр булса да, искедән бирле килгән тире-яры, җәнлек сатулары безнең халык кулында гына булса да, кызыл мал, кырыктартма сатуында безнең халык шактый зур урын тотса да, бу сатулар күбесе кечкенәлектән үтә алмыйлар иде. Боларның һәммәсе, бер юлдан барып, кечкенә генә сумалы, зур гайрәтле кешеләр кечкенә кибеттән башлыйлар да, үзләренең тырышлыклары аркасында үзләренең ашау-эчүләрен, мәдәни ихтыяҗларын кысу аркасында сумаланып алалар иде дә, акыртын гына үсеп баралар иде. Ләкин боларның үсүләре мәгълүм дәрәҗәгә җиткәнчә генә бара да аннан соң туктый яисә бөтенләй бетеп китә иде. Болардан үсә-үсә зур фирмаларга әйләнеп китүчеләре, болардан фабрикантлар чыгулары яисә бер-бер сатудан иң зур сәүдәгәр булып базарга тәэсир итәрлек булучылары күптән инде күренгәне юк иде. Болар кечкенә генә сәүдәгәр булып баралар. Акыртын гына тәрәкъкый итәләр. Кризислар вакытында ыгыр-шыгыр гына үзләрен саклыйлар иде.

Боларга сата торган руслар, яһүдләр, немесләр бик тиз йә банкир, йә фабрикант, йә зур кулдагы сәүдәгәргә әйләнеп китәләр дә, безнең агай-эне һаман шул үз үлчәвеннән үсә алмый иде. Ул һаман торгашлыктан чыга алмый иде.

Моның сәбәпләре, әлбәттә, күп. Иң зурысы — бу сәүдәгәр халкының тырышлыгы тага кисәргә җитсә дә, сатучылык хисе һаман иске, бабалардан калганча торып, шуның гыйлем, заман берлән шомармавыннан иде.

Бу сәүдәгәрләрнең күзләре бик кыска булганга, алар бүген килгән биш тиен файдага бер елдан соң киләчәк ун сумны һәба итәргә хәзер торалар. Чыгышны азайтыр өчен, хезмәтчеләргә бер шакмак шикәр ким биреп, экономия ясыйлар. Магазинның рухы булган приказчикның бер, ике, өч сум жалуниясен кысалар, биш-ун тиен файда итәр өчен, күрше сәүдәгәренә зарар итәм дип, базар бозалар, малның бәһасен төшерәләр иде. Шулай итеп, башларын кечкенә мәсьәләләр берлән мәшгуль итеп, зур файдалардан мәхрүм калалар. Баскан йирләрендә, тоткан базарларында, бер-берсенә аяк чалышып, алга атларга көчләре калмый иде. Тиҗарәт дөньясының киң базарына чыга алмаенча, һаман шул үзенең тирә-юнендә туалар, үләләр иде. Иске заманнарда, тормыш очсыз булганда, сәүдә базарында татар сатучысына үзе кебек акыртын хәрәкәт итә торган рус сәүдәгәре генә каршы чыкканда, болай бару мөмкин дә булгандыр.

Ләкин соңгы елларда сәүдә базарына кискен зиһенле яһүд, әрмән килеп кергәч, зур сумаларга таянып нимес аяк баскач, бу төрле сату итү мөмкин түгелләнгән иде. Шуның аркасында соңгы егерме ел эчендә бик күп базарлар безнең мөселман сәүдәгәрләренең кулыннан ычкынган, бик абруйлы фирмаларның көле күккә очкан, бик күп оста, уңган сәүдәгәрләр яһүд, әрмән, нимес, рус сәүдәгәрләренең приказчигы булып калган иде. Шулай түбәнәю елдан-ел алга бара, елдан-ел мөселманнарның зур фирмалары бетә, кечкенәләре капитал боендырыгы астына керә бара иде. Сәүдәгәр егълый, сыкрый, муенын бөгә, яһүд сатучы банк алдында буен сона иде. Хезмәтче булып калып, сәүдәсенең каймагын аларга ташый иде.

Мәскәү каракүлчеләре алдында шул мәнзарә көннән-көн ачыла барды. Элгәре приказчикның кулда тотып сатып йөрүдән үскән бу фирмалар, элгәре вакытта расходны кысып, тәүлегенә унсигез сәгать эшләп сумаланып алган булсалар да, зурая төшкәч, болар алдында теге гомуми куркыныч килеп баскан иде. Банклар, комиссия конторалары, спекулянтлары боларны йотарга, боларны да үзләренә хезмәтче итәргә кармаклар салалар, аулар коралар иде. Тик кенә торып, боларның маңгай тирләре берлән тапкан малларының каймагын ашарга хәзерләнәләр иде.

Шуның өчен сугышка кадәр нимес фирмалары, каракүл чыга торган Төркестанга мөселман приказчигы җибәреп, беренче кулдан каракүлне җыеп алалар иде дә сатучы булган мөселман ага-энегә борычлап-тозлап сатып торалар иде. Сугыш башлангач, нимес фирмалары урынын яһүдләр тотмакчы булды. Үткән елны каракүл базарына барып, шактый мал алдылар. Бу ел китереп, мөселманнарга зур файдалар берлән саттылар. Шуңгардан гыйбрәт алып, бу ел зур бер тиҗарәтханә ясап, каракүлнең зур кыйсемен үз кулларына кертеп, мөселман сәүдәгәренә үз бәһасен диктовать итәргә хәзерләнделәр.

Мәскәү каракүлчеләренең алдында йә яһүдләргә приказчик булып калу, яисә үзара юктан тартышып йөрүне ташлап, алу өчен генә булса да, берләшү уе туды. Мәскәү мөселманнары шул мәсьәләдә сәүдәгәрлек күрсәттеләр. Аларның бик күп фирмалары бу көндә ителәчәк аз-маз файданы да гомумгә корбан итеп, Төркестаннан каракүл алыр өчен берләштеләр. Утыз фирма акционерный товарищество ачарга карар иттеләр.

Хәзергә әле, бу елгы базарны үткәрмәс өчен, Бурнашев, Карамышев фирмасында торговый дом ачып, зур гына капитал куеп эшкә керештеләр. Яһүдләргә хезмәт итә торган егетләремезне үзләренә куштылар. Үзара аерым алып йөри торганнарны бергә җыеп, каракүл алырга йибәрделәр.

Шулай итеп, мөселман арасыннан чыгып, мөселманнар ашасыннан гына сатыла торган каракүл базарына үзләрен имеп торырга теләгән паразит көчләргә ирек бирмәделәр. Мәскәү каракүлчеләре үзләренең шул хәрәкәтләре берлән торганлыктан, вак сатучылыктан чыгып, сәүдәнең икенче дәрәҗәсе булган промышленникка, зур сатучылыкка таба омтылулык күзләре ачылганны күрсәттеләр.

Сәүдә эшемез тәрәкъкый итсә, табигый уларак, аңларга тиеш булган оешып эш итүдә беренче адымны атладылар, беренче уларак, сәүдәгәрлекнең икенче сыйныфына күчтеләр.

Ләкин икенче сыйныфка күчү әле икенче сыйныфны бетерү түгелдер. Анда бик озын-озын дәресләр бар. Анда бик күп өйрәнергә кирәкле яңгы мәгълүматлар бар. Беренче сыйныфтагы бала сәүдәгәргә гафу ителсә, икенче сыйныфка күчкәннәргә кичерелми торган гадәтләр, кануннар бар. Ул гына да түгел, икенче сыйныф сәүдә эшендә зур-зур каршы чыга торган көчләр бар.

Алар үз арадагы Сәгыйть берлән Шәһитнең, Әхмәтша берлән Мөхәммәтшаның тартылулары кебек кенә түгел, алар көчле яһүд фирмалары, банклар, конторалары. Сәүдәгәрләр шул якта дустларыннан битәр дошманнары күбрәк булу табигый икәнлеген аңлап, кул-кулга хәрәкәтне ташламасалар, читтән кергән интригаларга колак салмасалар, каракүл базары аларныкы. Икенче сыйныфка күчтеңез, өченчегә күчүне күздә тотып, авыр имтиханнарга хәзерләнеңез. Сезнең шул юлдан муаффәкыять берлән эш итә алуыңыз башка сәүдә юлларында да оешу — кушылышуга үрнәк булачак. Сезнең шул юлда тәрәкъкый итүеңез, татар сәүдәгәренең эчендә көя булып ашый торган ваклыкны бетереп, аны рухи үстерәчәк.

## БЕЗНЕҢ ЮЛЫМЫЗ

Киң Русиянең өлкәләренә җәелгән төрек-татар баласын без киләчәктә мәдәни бер милләт булып яшәвен күрәсемез килә. Күп миллионнарга саны ирешкән бу халыкны мөселман динендә улдыгы хәлдә, каумиятен югалтмадыгы хәлдә, Аурупа мәдәниятен кабул итеп, шул мәдәниятне үз рухына сугарыр, шул мәдәнияттән үзенең хәятына кирәкле көчләрне сайлап ала белер дип ышанамыз.

Киләчәктәге тормыш тартышлары элгәреге замандагыга караганда йөз мәртәбә, мең мәртәбә авыр буласын күземез берлән күреп торганда, иске замандагы кебек, үземезнең иске-москы мәгълүматымыз, иске-москы мәдәниятемез, чери башлаган йоламыз, черегән гадәтемез берлән генә күрше милләтләр алдында үземезне сакларга көчемез йитешүенә инанмыймыз.

Күрше халыклар эчендә эреп бетмәс өчен, тирә-юнемездән дөбердәп килә торган Аурупаның мәдәнияте, гыйлеме, тиҗарәте, һөнәре, әдәбияты, музыкасы, фәхеше, ялганы, шарлатанлыгы алдында күмелеп калмас өчен, без күршеләремез коралланган корал берлән кораллануны лязем табамыз. Эремәс өчен, бетмәс өчен, үземезне үз милли гөруһ эченә тыгарга, милли күбә тимерен кияргә фарыз дип ышанамыз вә шул күбә тимерене элгәреге замандагы тутыгуларыннан арчу лязем, шуның черекләрен яңгы корыч, яңгы милли тимер берлән сипләү фарыз дип беләмез.

Шуның өчен безнең хәзерге матбугатымыз, әдәбиятымыз, мәктәбемез, мәдрәсәмез, җәмгыятьләремез, театрымыз, музыкамыз, тиҗарәтемез вә бөтен иҗтимагыятемез шул милли күбә тимерен ныгытырга корал булырга тиеш дип иман итәмез. Шуларның һәммәсен Русиядә төрек-татар баласының хәят тартышуында, мәдәни ныгуында көчләнүенә хезмәт итәргә тиеш, дип катгый итеп әйтәмез.

Менә шул юлга хезмәтне милли хезмәт итеп таныймыз, шул юлда тырышып көч сарыф итүне җәмгыятькә хезмәт дип аңлыймыз, шул юлда сарыф иткән көчләрне, түгелгән гайрәтләрне тәкъдир итәмез.

Шул юлда хезмәт иткән затны, кирәк, ул бер мөгаллим булсын, кирәк, ул бер мөдәррис булсын, кирәк, ул малы берлән халкына хезмәт итә торган аңлы мөселман булсын, кирәк, милли сәхнәсен тудырырга тырышучы бер артист булсын, кирәк, милли моңны бүләк иттереп калдырырга тырышучы музыкант булсын, кирәк, халыкның рухында исламиятнең нигезләрен ныгытучы имам булсын, безнең сафдашларымыз, безнең иптәшләремез, безнең берлән бергә баручы юлдашларымыз дип беләмез. Кулымыздан килгән мәгънәви көчне аларга бирергә тырышамыз, эчемездән генә булса да аларга рәхмәт тавышларын әйтеп торамыз.

Ләкин шул милли гаягә омтылганда, шул милли киемне төзәтергә тырышканда, ямауга куелачак материалларны без бик нык күздән кичерү, милли күздән кичерүне лязем табамыз.

Шуның өчен бара торган юлымыздагы һәммә борылгычларда, юлның һәммә аерылышларында туктап торып, кайсысы безнең максатка илтә, кайсы кара урманга кертә, кайсы караклар, качкыннар оясына төртелә дип тукталып торамыз, торырга мәҗбүрият хис итәмез.

Шуннан соң юлның матураеп ком сибелүенә карамаенча, юлның буендагы утыртылган агачларның матураеп, күләгә биреп торуларына гына кызыкмаенча, бабайлар кайдан йөрделәр икән, ничек хәрәкәт иттеләр икән дигән уйга төшәмез. Аларның исләрен иснимез, аларның тарихи вакыйгаларын хәтерлимез.

Күз алдымыздагы Касыйм ханнары, мирзаларының рус князьләренең бармак ишарәләре берлән хәрәкәт итүләре[1], Казан халкының җиңгелгәннән соң, керпе кебек бөтәрләнеп ятып, үз эчендәге куәт берлән генә күршеләргә һичбер төрле таянмаенча, үзен-үзе саклавын хәтерлимез. Шуннан соң чыккан нәтиҗәләрне күздән кичерәмез.

Касыйм мирзаларының халыкларына иткән хезмәтләре — Казан, Әстерханны руска алып бирүе[2]...

Казанның иткән хезмәте — үз эчендә үзен-үзе динендә, үз милләтендә саклап килүе.

Тарихның башка сәхифәләрен ачамыз. Күз алдымызга төрек йилкәсенә арка таянган Багдад хәлифәте[3], чит мәмләкәтләргә арка таянган төрекләрнең әхраре фиркасе, дахили идарәсендә күрше кавемнәрнең ишарәсе берлә йөрүче милләтләр килә.

Нәтиҗә һәммәсендә дә бер.

Шуннан үземез өчен бер фикер чыгарамыз: безгә үземезнең мәдәни яшәвемездә үз көчемезгә генә ышанырга кирәк, үз халкымызның гына матди-мәгънәви көче берлән барырга тырышырга кирәк.

Менә шул ноктадан карап, без күршеләремезнең карагруһларына арка таянып эшләргә теләгән бүлекне, халыкны иң әүвәл хата итә дип, юлыннан чәвермәкче буламыз. Шул юлда гыйнад итсә, тискәрелек күрсәтсә, халкыбызга хыянәт итә дип ышанамыз.

Казан тирәсендәге муллаларның, үрәдник-фәлән берлән танышып, доносны юлга кертеп йибәрүләрен, сагыяләрен без милли җинаять итеп хисаплыймыз.

Безнең бер милләт булып яшәвемезгә дошман даирәләргә арка таянып, иптәш булып мәйданга чыгарга теләгән фиркаләргә, бүлекләргә сатлык-хаин дип ышанамыз, иман итәмез.

Шундый бозыклыклар халык арасында җәелмәсен өчен, аларны мөмкин кадәр баштан ук бетерергә тырышамыз, чит көчкә таянып түгел, халкыбызның милли аңына таянып, шуларның дошман көчләре, иң тугрысы, безгә дошман көчләрнең кораллары икәнен күрсәтергә, аңлатырга тырышамыз, шуны аңлатуны үземезнең милли бурычымыз дип ышанып эшлимез. Безнең фикеремезчә, әле безнең милли могадәләмез савыгып йитмәгәнгә, милли күземез үткерләнеп өлгермәгәнгә, һәрбер хәрам эшне кычкырып әйтеп, халыкның дикъкатен җәлеп иттерүне лязем табамыз.

Без, әле халык үзенең аңы берлән кайсысы яхшы, кайсы ярыйсысын, кайсысы начар икәнен аерып бетерерлек хәлгә килмәгәнгә, халыкның шул аңын бутый торган һәрбер хәрәкәтне тәнкыйть итәмез.

Белгәнемезне әйтәмез, гыйнад иткән кешеләрнең алган юллары милли юлга зарарлы икәнен кычкырып әйтүдән һичбер тартынмыймыз.

Шуның өчен милли агачымызның тамырын кисәргә җыелган берничә хаинның балтасына, кемгә генә сап булырга теләсә дә, аның былчырак максатка хезмәт итүен белдерәмез, игълан итәмез, халыкны агяһландырыр өчен шулай итүне үземезгә лязем табамыз.

Шул эшләрне һичбер кешегә шәхси дошманлыктан яисә бер-бер төрле зурмы, кечкенәме матди мәнфәгать артыннан эшләмимез, милли идеалымызны саклау өчен лязем дип ышанганга, вөҗданы миллиямезнең кушуы буенча эшлимез. Милләтемезнең киләчәге алдында өстемезгә фарыз булган бурычны үтимез.

Киләчәк буынның ләгънәтеннән котылыр өчен, хәзерге буынның саңгырау колагына азан кычкырамыз.

Әлхәмделиллаһ, моңганчы караңгы көндә дә, карлы-бозлы ягъмур яуганда да без азан вакыты йиткәнен онытмадык.

Аллага шөкер, нинди авыр көннәрдә дә дошман көчләре алдында тибелеп-сыгылып, милли рәзаләт япмадык.

Халкымызга иманымыз — алган юлымызның тугрылыгына иманымыз безне киләчәктә дә шул сәфаләт, рәзаләттән саклаячактыр.

## ГӘЗИТӘ НӘРСӘ?

### I

Кулыңызга тотып укырга тотынган гәзитәнең ничек итеп шул кыяфәтенә кереп, сезгә барып җитүе хакында берәр нәрсә уйлаганыңыз бармы? Һәр укыганда монысының мәкаләсе шәп түгел икән, монысы шәхсыять белән уграша икән, монысының кәгазе начар икән дип, тәнкыйть күзе берлән генә караган гәзитәне сезнең кулга итеп тоттырыр өчен гайрәтләр сарыф кылынуны уеңызга гына китергәнеңез бармы?

Һәр көнне чәй эчкәндә, чәйне тәмлеләндерү өчен акрынлап-акрынлап кына карап, бер сәгатьтә укып бетергән шул гәзитәне шул хәлгә китерер өчен матди көчләр, мәгънәви куәтләрнең күпме чәчелгәнен төшенгәнеңез бармы?

Дөрестен әйтик, юк...

Гәзитә — ул гәзитә! Ул чыга... Казанда, Оренбургта, Уфада, Мәскәүдә чыга...

Менә шулай чыга... Шулай чыгар өчен ул гәзитә инде...

Ләкин ничек чыга, нидән чыга, нинди көчләр эшләп чыгара, нинди максатлар аны төртеп йөртә? Аннан хәбәреңез юк.

Гәзитә чыгарыр өчен нинди матди хәзерлекләр кирәк, нинди мәгънәви көчләр лязем, тугрысын әйтеңез, анысын уйлап та караганыңыз юк.

Гәзитә чыга, әллә нинди бертөрле кешеләр бар да шулар гәзитәне чыгаралар... Шуннан соң ул ничектер сезгә килеп төшә...

Шундый эш бармы, әллә ул юкны бушка бушатып кына буламы?

Әллә аңгарга Яхъя мулла пәриләре хезмәт итәләрме, әллә Җәбраил фәрештә ярдәмгә киләме, әллә Газазил галәйһи әл-ләгънәтә[1] бик тырышып эшлиме? Анысын башыңызга да керткәнеңез юк...

Шулай бит, менә шулай булса, тагы бер мәртәбә тәмлеләндереп чәй эчкәндә, менә шул мәкаләләрне төшенебрәк укыңыз әле.

Безнең Русиядә гәзитә чыгарыр өчен элек, иң әүвәл Дахилия нәзарәтеннән рөхсәт алу лязем булган. Ул вакытта гәзитәгә рөхсәт бирер өчен нашире, мөхәррире хакында бик күп тикшерүләр лязем булган. Ул вакытта шул рөхсәт алу ягы тәэсис итүнең иң авыр адымы булганга, безнең кебек гайрәте, көче аз халыклар гәзитә чыгара да алмаганнар.

Сиксәненче елларның ахырында Казанда мәрхүм Габдрахман Ильясов һәм дә Габделкаюмән-Насыйри, ахырга таба Шаһбазгәрәй мирза Әхмәрев берничә мәртәбә министрга мөрәҗәгать итсәләр дә[2], һәммәсенә дә рөхсәт бирелми килгән.

Шул вакытта ничектер Кырымда гына Исмәгыйль бәк Гаспринскийга «Тәрҗеман»га рөхсәт бирелгән[3]. Кавказның идарәсе аерымча булганга, Кавказ наместнигы азәрбайҗанча гәзитә чыгарырга рөхсәт иткәләгән. Бу вакытта бөтен гәзитәләр үзләренең бөтен мәкаләләрен алдан цензорга күрсәтеп, рөхсәт алырга лязем булган. Алдан цензорга күрсәтмәү хакын алыр өчен бик зур залоглар лязем булганга, аның берлән берничә зур гәзитәләр генә файдалана алган.

Ләкин безнең Идел буенда 1905 елга кадәр катгыян бер гәзитәгә рөхсәт булмаган, һәм дә бер гәзитә дә чыкмаган.

1905 елда 17 октябрь Манифесты берлән мәмләкәттә хөрриятләр игълан ителгәч, әлбәттә, сүздә язудагы элгәреге кысынкылыклар да бетәргә тиеш булды. Шуның өчен матбугат хакында бердән яңгы закон чыгарып өлгертергә мөмкин булмаганга, 1905 елның ахырында «Матбугат хакында вакытлы кагыйдәләр» гонванында хөкүмәт тарафыннан вакытлы законнар игълан ителде.

Бу вакытлы закон буенча, гәзитәләрнең чыгуы өчен, министрдан рөхсәт алынуының лөзүме бетерелде. «Рөхсәт» дигән сүз үзе үк матбугаттан бөтенләй чыгарылды.

Икенчедән, гәзитә чыкканча цензорга күрсәтүнең тиешлеге ләгу ителде. Цензор дигән нәрсә матбугат өчен тәмамән бетерелде.

Матбугатка хөррият бирелде. Ләкин шул «матбугат хөррияте» үзе берникадәр тәфсирләр берлән бәян ителде. Баягы гәзитә-журнал чыгару өчен «рөхсәт лязем түгел» дигән сүз урынына икенче мәгънә утыртылды. Гәзитә йә журнал чыгартырга теләүче зат үзенең шул теләве хакында үзе тора торган вилаятьнең губернаторына, градоначальниклы шәһәрдә булса, градоначальникка прошение түгел, заявление бирергә кирәк. Шул заявлениесендә «мин фәлән шәһәрдә, фәлән телдә, фәлән мөддәттә, фәлән бәһагә гәзитә чыгармакчы булам» диярргә тиеш вә шул заявлениесендә гәзитәнең нашире кем, редакторы, мәсьүл мөхәррире кемлеген, нинди типографиядә басылуын, атнага ничә чыгуын, бәһасен ачык иттереп белдерергә тиеш.

Рус тәбәгасы булган, яше егерме бишкә йиткән, хокуклары хөкем берлән киметелмәгән, банкрот булмаган һәркем мәсьүл мөхәррир була ала.

Менә шул заявление бирелгәннән соң, ике атна эчендә губернатор яисә градоначальникның канцеляриясеннән, гәзитәсе, журналы рус телендә булса, ике шәһадәтнамә бирелергә тиеш. Берсе — редакциядә сакланыр өчен, икенчесе — матбагага бирелер өчен. Шул ике атнада әгәр шәһадәтнамәләр бирелеп өлгермәсә, теге кеше гәзитә алдында мәсьүл булмыйдыр.

Рус түгел телләрдә — татарча, әрмәнчә, грузинча, яһүдчә чыгарырга теләгәннәр өчен заявление биргән көннән шәһадәтнамә алу көне ике айга кадәр сузыла.

Петроград кебек зуррак шәһәрләрдә шул мөддәт үткәнне көтеп тормаенча бирсәләр дә, Казан, Уфа, Оренбург кебек кечкенәрәк шәһәрләрдә күбрәк ике айны тутыралар.

Шуннан соң гәзитә-журналның хуҗасы хисапланып, наширенә шул ике шәһадәтнамә бирелә.

Нашир булган кеше хөкүмәт алдында кибет хуҗасы кебек хисап ителә. Аңгарга мали мәсьүлиятләр генә төшә, ягъни промысловой шәһадәтнамә алу, йибәргән гәзитәләр өчен почта берлән хисап йөртү вә һакәза...

Язылган мәкаләләр, гәзитәнең мөндәриҗәсе өчен хөкүмәт мәсьүл итеп редакторны таный. Гәзитәдә зарарлы табылган мәкалә чыкса, редакторны хөкемгә тарта, гәзитәдә бер кешене мыскыл итү-фәлән булса, ул кеше алдында редактор җавапка кала.

Наширнең мәсьүлияте кечкенә булганга, хөкүмәт аның өчен бер шарт та куймый. Балигъ булмаган бала да, хокукы киметелгән кеше дә, торговый дом, акционерный обществолар да нашир була алалар. Ләкин редакторлык өчен, мотлакан, югарыда күрсәтелгән шартлар лязем ителә.

Шул ике шәһадәтнамәне алгач, наширнең гәзитә яки журнал чыгара башларга хакы була.

Ләкин әле бу коры хак кына. Һәр мөселманның хаҗга барырга, зәкят бирергә хакы булган кебек, бер хак кына. Шуннан соң гәзитәнең, журналның нашире, ул хакыннан файдаланып, шул эшне вөҗүдкә чыгарырга кала.

Гәзитәнең башында торучы* алдында ике мәсьәлә килеп баса. Берсе — гәзитәнең тышкы ягын юлга кую, ягъни типография табу, булмаса, ачу, контора алу, анда кирәкле кешеләрне утырту, кәгазь хәзерләү, йибәрер өчен почта берлән эш йөртү, чит шәһәрләрдә агентлар табулар.

Икенчесе — гәзитәнең эчке ягын мәгълүм мәсләктә юлга кую.

Моның өчен гәзитәнең башкаручысы алдында һәйәте тәхририя оештыру лязем була, ягъни гәзитәнең эчен мәкаләләр, хәбәрләр белән тутырып, язучылар хәзерләү, шуның өчен редакция тоту лязем була. Язучы, мөхәррирләрне җәлеп итү тиеш була. Чит шәһәрләрдә мөхбирләр табу һәм дә читтә тора торган мөхәррирләрдән язуга иштиракь иттерүнең юлларын кору.

Иң әүвәл һәйәте тәхририясеннән тотыныйк. Бер гәзитә яки журнал редакциягә урын тотты ди. Үзенең матди көченә карап фатирмы, бүлмәләрме алды.

Хәзер инде гәзитәнең башында торыр өчен, гәзитәнең мәсләкен саклап барыр өчен, шунда бер баш мөхәррир утырып торырга кирәк. Ул баш мөхәррир халык арасында игътибарлы, каләме белән танылган булуы, башка гәзитәләрнең баш мөхәррирләреннән йә мәсләке, йә фикер йөртүе яисә кан тибүе белән аерылган булуы шарттыр.

Укучы алдында мәгънәви тарафыннан мәсьүл була торган бу зат гәзитәнең мәгънәви эшләренең бөтен вакларына кадәр күрергә тиештер.

Матбугат галәмендәге зур, кечкенә, карт, яшь язучыларны бөтен хосусый хәятлары белән таныырга тиештер.

Гәзитә-журналда ачылачак бөтен мәсьәләләрне аңларлык куәи гыйльмиясе булырга, укучыларның нинди нәрсәләрне сөйгәннәрен аңларлык табигый тойгысы булырга тиештер.

Бу затның мәсләк иясе булуы, гәзитә-журнални идарә куйган юлдан алып барганда вак-төяк җилләрдән курыкмаслык батырлыгы булуы хакында, әлбәттә, әйтеп тә торасы юк.

Менә хәзер шундый бер кешене табып утыртты ди. Ләкин бу зат фәкать мәгънәви ягын идарә итүче генә булганга, моңгарга ярдәмчеләр, хезмәтчеләр, язучылар ляземдер. Болар гәзитә яки журналның максатына карап төрлечә бүленә. Мәсәлән, бер гәзитәне алдык: анда мотлак дахили эшләр, хариҗи эшләр, вилаять эшләре, фән, әдәбият, матбугат дигән кыйсемнәре булырга тиеш бит. Менә шуларның һәммәсенең башында үзенең мөтәхассыйсы утырырга тиеш.

Димәк, безнең редакциямезгә тагы дахили эшләр хакында язуларны бер башкаручы, харижигә бер, вилаять эшләренә бер, матбугат эшләренә бер зур шәһәр булса, шәһәрнең үз вакыйга вә хәлләре хакында бер икенче дәрәҗә мөхәррирләре утыртылырга тиештер. Бу затлар һәммәсе дә үз даирәләрендә хезмәт берлән ихтисас иткән булырга тиеш.

Болар булды ди. Ләкин бу кешеләр әле үзләре һаман кара хезмәтче түгел. Болар шул хакта озын мәкаләләр яза алалар. Килгән мәкаләләрне төзәтә алалар, рәткә суга алалар. Ләкин боларга да материал язучылар кирәк. Болары гәзитә-журналның даими язышучылары, сотрудниклары була.

Бер сотрудник дахили эшләр хакында казына, мәгълүмат җыя, вакыйгалар чүпли. Берсе хариҗи эшләр хакында хариҗи гәзитәләрдән парламентларның мәҗлесләрен тәгъкыйб итә. Берсе, матбугатта ни булганны күздән качырмас өчен, мөмкин кадәр күп гәзитәләрне укый. Ләкин дахили эшләр бик күп булганга, харижиләр монда да киң булганга, матбугат, әдәбият тагы бик тирән мәсьәлә булганга, әлбәттә, бундагы язучылар да берәр генә булса җитми. Алар һәр гәзитәдә берничә булалар, булырга тиешләр.

Боларга башка — тагы чит шәһәрләрдәге мөхбирләр. Боларны да гәзитәнең зурлыгы, таралуына карап мөмкин кадәр һәммә йирдә булдырырга тиештер. Мөмкин кадәр һәр йирнең вакыйгасы гәзитәдә чыгарга тиештер. Гәзитә чыга торган шәһәрдәге вакыйгалар, хадисәләрне, әлбәттә, читтән китерергә ярамый бит, шуның өчен хәбәр җыючылар-хроникерлар ляземдер.

Менә шулар берлән редакция тула яза. Ләкин редакция җәмәгать оешмасы булганга, аның башка гәзитәләр, журналлар, җәмгыятьләр, хосусый кешеләр берлән эше, мөнәсәбәте бардыр. Килүчесен, китүчесен кабул итү, алар белән редакция исеменнән сүз сөйләү. Моның өчен редакциянең эчендә сәркатиб дигән бер зат торырга тиештер.

Бу кешегә идарәнең сәясәтен йөртү йөкләтелгәнгә, нәзакәтле, тәрбияле булу беренче шарттыр.

Хәзер шуларга берничә тел белә торган тәрҗемәчеләрне тыксак, кыңгырау кагуга килә торган малае берлән ишек төбендә килгән кешеләрне каршы алучы капучыны кушсак, идарә тәмам булып йитәдер.

Хәзер фараз кылыңыз: шул идарәнең бер бүлмәсенә баш мөхәррир кереп мәкаләләргә чумды. Өч бүлмәсендә өч мөдир утырды, дүртенче бүлмәдә сәркатиб үз урынын тотты, зур бүлмәдә җиде-сигез өченче дәрәҗә язучылар язарга тотындылар. Почта берлән чит шәһәрләрдән, авыллардан хатлар, хәбәрләр килде. Шәһәр буенда йөрүче хәбәрчеләр кайда янгын барлыгын, кайда өй җимерелүен, кайда ат таптавын, кичке театрда ни куелуын, бу көн шәһәремезгә кемнең килүен, кемнең китүен, кемнең үлү хәбәрләрен китерделәр ди.

Шулар һәммәсе язылды, кәгазьгә күчте ди. Берәм-берәм язучылардан мөдирләргә, мөдирләрдән баш мөхәрриргә барып җитеп кабул ителде ди.

Боларны бит әле гәзитә хәленә кертү бар... Бу мәкаләләр, хәбәрләр, вакыйгалар әле бит бер кәгазьгә генә язылган нәрсәләр. Аларны меңнәргә йиткерергә кирәк. Аның өчен инде янә идарә конторага, гәзитәнең тышкы эшләрен караучыга мөрәҗәгать итәргә мәҗбүрдер.

Аның ничек итеп шул кәгазьләрне гәзитә ясап чыгаруын киләчәктә сөйләрмез[4].

**II**

Ярый, хәзер гәзитәнең бөтен мәкаләләре, бөтен хәбәрләре, мәктүбләре, шигырьләре — һәммәсе язылып бетеп, конторага чыкты ди. Хәзер шуларны контора ничек иттереп инде гәзитә хәленә кертә?

Гәзитә-журнал конторaларының ике ягы бар. Бер ягы — мөхәррирләр эшләп бетергән мәкаләләрне гәзитә төсенә кертү, икенче ягы — шул эшләнеп беткән гәзитәләрен алучыларга ирештерү.

Хәзер менә контора шул мәкаләләрне алып, гәзитәнең басыла торган матбагасына бирәдер. Анда ул материалларны гәзитәне карап җыйдыручы, гәзитәне шул кыяфәткә китерүче баш мөрәттибкә (метранпажга) тапшырадыр. Баш мөрәттиб үзенең кул астындагы хәреф тезүчеләргә бүлеп бирә дә, хәреф тезүчеләр, үзләренең кассалары янына килеп, эшкә тотыналар.

Матбаганы күрмәгән кешеләргә болар һәммәсе сүз генә булганга, моны иҗекли төшик әле. Бер язган язуны күбәйтү ысулы төрлечә була. Боларның бертөрлесе мәгълүм бер кара (кытай карасы) берлән аерым бер кәгазьгә языла, шуны мәгълүм ысул берлән хосусый хәзерләнгән ташларга төшерәләр дә, шул ташлар берлән басыла. Буңгарга таш басма диләр. Һиндстанда хәзергә кадәр бу басма бик мәгъруф. Моны эшли торган басмаханәгә литография диләр.

Икенчесе — хәреф басма. Бусының ысулы бөтенләй башкача. Монысында һәр хәреф өчен аерым-аерым шәкелләр ясалган. Шул шәкелләр һәммәсе аерым-аерым ителеп кургашыннан коелган. Шул ук карага манып, печать баскан кебек кәгазьгә суксаң, хәреф төшерәдер.

Һәр телдәге хәрефләрнең төсләре, шәкелләре төрле-төрле булганга, болар һәр телдә боларның саннары шул халыкның әлифбасындагы хәрефе берлән бердәй буладыр. Ләкин безнең төрек-татар кавемнәре, элгәреге заманнарда бик мөселман булган булып, үзләренең уйгур, уйхун язуларын ташлап, гарәп хәрефенә күчкәннәр. Ул хәрефләр гарәпләрнең үзләренә, аларның сөйләүләренә күрә эшләнгән булганга, әлбәттә, Азиянең икенче башыннан килгән фән-лисан ягыннан бөтенләй башка телләргә мәнсуб булган төрек-татар теленә аз гына да килмәгән. Шул язулар әллә ничә гасырлар дәвам иткәнгә, хәзер инде безнең әдәбиятымызга тәмам кереп китеп, шул гарәп хәрефләре безнеке булып киткәннәр.

Менә шул гарәп хәрефләренең язулары башка халык хәрефләренең язуына караганда аермалыдыр. Мәсәлән, безнең белгән русчамызда гына да һәр хәреф үзенә аерым-аерым языла. Шуларның җыелуларыннан сүз хасил була. Хәрефнең сүз уртасында да, башында, ахырында да шәкеле югалмый, һаман бертөсле языла. Шуның өчен русчада никадәр хәреф булса, шуларны басар өчен дә шулкадәр генә шәкел ясарга ихтыяҗ туа. Русчада хәрефнең бер төрлесе утыз дүрт шәкелгә сыя. Шуларны таратып куяр өчен ясалган кечкенә-кечкенә тартмалар баш хәрефләр, знаклар, цифрлар берлән бергә кассада йөз дә ун буладыр.

Әмма бездә мәсьәлә бөтенләй башкача. Гарәпчәдә хәреф баш, урта, ахыр, ялгыз хәрефләргә бүленеп, төрле төстә языла. Шуның өчен бер хәрефкә әллә ничә шәкел ясау лязем була.

Мәсәлән, бертөрле үлчәүдәге «х» хәрефе өчен русчада бер генә шәкел бар. Бездә шул «х» өчен дүрт төсле шәкел ясау тиеш була. Бу бер генә «х» да түгел, башка хәрефләремездә дә шулай. Шуның өчен бездә

китапмы, гәзитәме басар өчен истигъмаль иткән гарәп хәрефләремезнең йөз дә алтмыш сигез шәкелләрен кулда итәргә тиеш буладыр. Шул кургашын хәрефләр бергә өелеп куелса, табарга авыр булганга, аларның һәрберсенә аерым-аерым, кечкенә-кечкенә бүлмәләр ясыйлар. Шулар һәммәсе бергә торсын өчен, шул бүлмәчекләрне бергә җыештырып куялар. Менә шул хәрефләрне салыр өчен җыештырылган бүлмәләргә касса диләр. Дүрт почмаклы иттереп куелган кассаларга шул кургашын хәрефләр аерым-аерым тутырыла.

Менә кулына мәкалә тоткан мөрәттиб үзенең кассасы алдына килә дә туктый. Мәсәлән, «Сугыш башлануга инде унсигез ай булды» дигән җөмлә тора. Ул язудагы шул җөмләне басарга яраклы итәр өчен, хәреф җыярга уңгай булсын өчен ясалган верстак дигән тимер тоткычны ала да кассадан куллары берлән хәреф җыярга тотына.

Иң әүвәл баш «», аннан соң аңгарга ахыр «», аннан соң баш «», аннан соң ахыр «»,* «башланган» дигән сүз һакәза — иттерелеп, һәммә хәреф аерым-аерым алынып тезелә. Сүз булдымы, ике сүз бергә катышып китмәсен өчен, ике арага кургашын шакмак куела.

Менә шулай итеп, һәр хәрефне аерым-аерым алып, мөрәттиб юлны тутыра. Ике юл аерылсын өчен, юлның киңлеге кадәресендә кургашын бер чыбык (шпон) салып, икенче юлны җыярга керешә.

Шулай итеп, һәр хәрефне аерым-аерым җыйнап, сүзләр, юллар битләрне тутыра.

Ләкин шулай казынып хәреф табу бик мәшәкатьле булганга, аны өйрәнмәенчә булдырып булмый. Нинди милләтне тәрәкъкый иттерергә теләгән зат та, өйрәнмәсә, хәреф җыя алмый. Нинди гакыллы баш та үзенең исемен генә оештырып та чыгара алмый. Бәлки, хәреф җыяр өчен махсус өйрәнгән кешеләр лязем була. Урамнан теләсә кемне анда кертеп булмый. Шуңгарга күрә мөрәттибнең хезмәте башка эшчеләргә караганда бәһале түләнә.

Мөрәттиб никадәр кызу җыйса да, сәгатенә егерме юлдан артык җыя алмаганга, гәзитә-журнал өчен, әлбәттә, болар бик күп кирәк була.

Хәзер инде шул язылган мәкаләләр җыелып бетте ди. Ләкин боларны бит әле кәгазьгә чыгарасы бар. Менә инде шул җыелган мәкаләләрне гәзитәдәге багана-багана көенчә бәйлиләр дә махсус машинага куеп басып алалар. Шуннан соң «яңлыш җыелмадымы» дигән сөаль туа. Шуны чагыштырыр өчен, махсус бер кешегә бирелә. Ул басылган шул кәгазьләрне язмалары берлән чагыштырырга тотына. Мөрәттиб никадәр оста булса да, аның яңлышмау ихтималы юкка, бик күп яңлыш чыга. Мосаххих әфәнде шул яңлышларны кырыена язып, төзәтеп чыга. Мөрәттиб тагы шул кәгазьне алып, үзенең җыйнап, багана иттереп куйган хәрефләренә килә дә махсус без белән яңлыш куелган хәрефләрне кадап ала. Аның урынына дөрестен куя. Тагы мосаххихка карарга бирә. Мосаххих тагы хаталар таба. Мөрәттиб тагы төзәтә. Тагы да кала.

Шундый баганалар күбәйгәч, шул баганаларны оештырып, мәкаләләрне рәткә сугып, кайсысы беренче мәкаләне, кайсысы икенчене, кайсысы фельетонны урынлаштырырга тотына.

Боларны башкарыр өчен идарәдән тагы бер кеше килә. Ул үзенең идарәдән бирелгән кәгазе буенча мәкаләләрне тездерә, хәбәрләрне урынлаштыра. Гәзитә бөтенләй тәмам бит төсенә кертелә. Тагы бер мәртәбә басып карыйлар. Тагы тасхих итәләр. Һәммәсе урынында. Хата беткән. Басарга да ярый.

Хәзер инде шул кургашын хәрефләрдән җыйналган битләрне машинага илтеп куялар, анда бик яхшы итеп урынга ныгыталар.

Машина янына печатник — махсус бер мастер килә. Машина өстенә кәгазь салып торучы махсус өйрәнгән бер кеше менә.

— Бисмилла! Йибәр!

Кәгазь салучы кәгазь сала. Печатник машинаны ходка йибәрә, машина шаулый, гөрли. Икенче ягыннан гәзитәнең бер ягын басып чыгара. (Зур машина ике гәзитәнең аерым-аерым якларын бергә баса.)

Тагы мосаххих, тагы теге мөрәттибләр. Тагы теге мәкаләләрне тезешүче. Бер сүз бик тонык чыккан... Бер сүзнең бер хәрефе бик ыржаеп тора. Бер юл бөтенләй чыкмаенча калган. Бер бик бәйләнгеч кешенең исемендәге йомшак «гайн» урынына каты «гайн» куелган![5]

Тагы төзәтү. Баткан хәрефне «өстерәп» чыгаралар, чыгып торганын «кыйнап» кертәләр. Түбәнрәк төшкән юлларның астына кәгазь куялар.

«Йә, тагы бас». Тагы басалар. Тагы хаталар, тагы төзәтәләр.

Инде тәмам ярый, баса башлаңыз!

Хәзер контораның кешесе, ничә мең номерда басылачак булса, печатникка кирәк кадәр санап кәгазь бирә.

Машина гөрли башлый. Машина янына менгән кеше берәм-берәм кәгазьләрне төшерә бара. Машинаның теге ягыннан гәзитәнең бер ягы басылып чыга баралар.

Менә гәзитәнең бер ягы басылып тәмам булды. Теге кургашын хәрефләрдән җыелган битләрне машинадан алалар. Икенче якларын китереп куялар. Тагы төзәтәләр. Тагы рәтлиләр. Тагы басыла башлый. (Машинаның уртачасы сәгатенә мең номерга кадәр гәзитә басып бетерә.)

Хәзер инде дүрт ягы да басылган гәзитә чыга башлый.

Ләкин алар аннан җәелгән, ачылган көенчә чыгалар. Шул вакытта контораның махсус бөгүчеләре килә. Алар чыккан бер гәзитәне аерым ясалган өстәлләрдә бөгә башлыйлар вә шуларны, почтага йибәрер өчен, бандерольгә киендерәләр. Бу да бетте. Инде гәзитәләрне адреслары берлән йибәрер өчен конторадан махсус экспедиция хезмәтчеләре киләләр. Боларның өстендә экспедиция башы тора.

Буның ничек йибәрүе киләчәктә язылыр[6].

**III**

Экспедиция — гәзитәне йибәрү — үзенә аерым бер фән дәрәҗәсенә килгән. Гәзитә йибәрү ул хат йибәрү кебек кенә түгел. Анда иң әүвәл адресның иң тугры язылуы лязем. Икенчедән, аның нинди юлдан, трактан китүе ачык күрсәтелгән булырга тиеш. Аннан соң аның мәгълүм сәгатьтә китә торган поездга өлгерер өчен, мәгълүм вакытта почтага хәзерләнеп бирелгән булуы шарт.

Моңга башка, гәзитә бик күп киткәнгә, аны тикшереп торырга, төзәтешеп торырга почта мәэмүрләренең вакыты юк. Шуның өчен идарә һәммә эшен бетереп, ваклыкларына кадәр эшләп бетергән көенчә тапшырырга кирәк.

Ул соң ничек эшләнә? Мәсәлән, Казан губернасыннан Спас өязеннән Мораса волостеннан Алпар авылыннан Мөхәммәтҗан Әхмәтҗан углыннан бер еллык гәзитә сорап перевод килә.

Конторага кереп, Хабаровскиның сәүдәгәре Галим Хәкимов берьеллык яздырып, квитанция алып чыга.

Нәмәнганнан агент Гали әфәнде «Мирзаколый Хуҗа, Миргали Хуҗа, Хаҗи Хәсәнгә» дип ордер йибәргән.

Болар берәр генә булса да яисә атнага бер генә килсә, рәтләргә мөмкин булыр иде. Ләкин болар бер дә түгел, ун да түгел, йөз дә түгел, мең дә түгел, берничә мең. Болар иртәге көнгә дә килә, аннан арыга да килә.

Боларның адресында берсенең исемендәге бер хәреф йә бер ноктасы яңлыш төшсә, гәзитә бармый яисә әллә кая йөреп китә, яисә шуңгарга охшаганрак икенче берәүгә бирелә. Идарәгә: «Акча йибәрдем, гәзитә килми, акчамны ашадыңыз, гәзитә йибәрмәдеңез. Милләт, милләт дигән булып мине талыйсыз. Алай, әфәндем, алдашып алганчы, юл буена чыгып, кесә басучылык итү кирәк иде, инде бу милләт ничек тәрәккъый итсен!» — дигән хатлар, жалобалар килә башлый.

Менә шулардан котылыр өчен (болардан бөтенләй котылу имкян харижында) зур гәзитәләр бик мәшәкатьле юллар эзләп чыгарганнар вә шуның берлән мөмкин кадәр гәзитәнең тапшырылуын тәртипкә куя алганнар.

Шуның өчен менә эш ничектән башлана. Баягы әфәнделәрнең язылган кәгазьләре алындымы, кирәк, перевод булсын, кирәк, ордер, контораның башы шуларны гомуми бер дәфтәргә яза. Кемнән ни өчен, никадәр акча алынган, ул әфәнде нинди адреслы?

Шуннан соң аны кассаны идарә итүчегә тапшыра. Ул, үзенең кассасының номерын шул кәгазьгә сугып, тагы кемнән, ни өченлеге хакындагы акчаның суммасын дәфтәренә кайд итә.

Аннан соң кәгазьләр экспедиция башына күчә, экспедиция башы дәфтәренә күчерә. Шул кәгазьгә дәфтәреннән номерын суга.

Шуннан соң ул әлифба битле дәфтәргә адресын язып куя. Шуннан соң гәзитә барырга дигән шәһәр, авыл, стансаның кай тракт берлән йибәрелерлеген эзләргә тотына. Почтада саклана торган зур, җуан книганы актарып, стансаны таба. Аннан өязен, губернасын чагыштыра, табылган кебек була. Ләкин күп вакытта переводта яңлыш язылганга, андый станса книгада чыкмый, экспедиция башы күзенә зурайта торган пыяланы тотып, переводның почта штемпелен укырга тотына. Анда да көчкә табыла.

Бунысы хәзер бетте.

Инде хәзер нинди тракт берлән йибәрерлекне табарга калды.

Почтовый трактлар җыенысы алтмыш биш. Менә экспедиция башы шул, мәсәлән, Хабаровск ничәнче икәнен эзләп тапты. Мәсәлән, кырык өченче икән. Шул цифрны куйды. Ләкин бер трактта әллә никадәр почта стансалары бар. Аларның да махсус номерлары бар. Аны да ачык язарга кирәк. Аларның хисабы биниһая, һәрбер трактта биш йөзгә кадәр җитә. Инде шул йибәреләчәк йирнең ничәнче номерда икәнен казынырга кала.

Адрес бик начар язылганга, Алексеев Алексеевский берлән, Александровский берлән чуаланып язылганга, тагы тикшерергә тиеш була.

Бу да табылды. 127 икән ди. Хәзер менә экспедиция башы шул цифрны теге кәгазьгә куя да адрес хәзерләүчегә тапшыра. Адрес хәзерләүче шуны махсус бер кәгазьгә, формага яза. Шундагы тракт урынын, цифрларын ачык куя. Бастырылачак булган адресның нинди формада икәнен тагы цифр берлән куя.

Инде исемнәр, фамилияләргә тотына. Бик дикъкать берлән яза.

Ләкин күп вакытта монда да шөбһәгә төшә, чөнки адрес язучы күп вакытта переводның артына «милләткә хезмәт итүеңезгә рәхмәт», фәлән-төгән дигән чит мәсьәләләр язып, исемен, фамилиясен куярга урынын бетергән була да, исемен хәреф берлән генә куя да фамилиясен әллә нинди борып-борып язган була. Тагы казынып аералар.

Инде тәмам. Менә хәзер шул язылган адрес тагы берничә кәгазьгә күчерелә дә матбагага басарга бирелә. Ләкин анда бер адресны гына басарга мөмкин түгел. Дөнья кадәр машинаны бер-ике адрес өчен биләргә ярамый. Анда аларны, йөзләп-фәләнләп бергә җыеп, формага оештыралар. Шул тулганча, басмаенча көттерәләр. Шуннан җыялар. Хаталары чыга, төзәтәләр.

Хәзер инде басылды ди. Шул басылган адресны гәзитә бер айлык кына алынса да, өч айлык кына булса да, бер елга йитәрлек иттерелеп басыла. Шуннан соң тагы кайтарылып экспедиция башына тапшырыла. Ул шул кәгазьләрне ала да махсус машина берлән һәр адресны аерым иттереп кисәләр. Бер кешенең бөтен елга йитәрлек адресын резина берлән бергә эләктерә дә, шулардан берсен махсус ясалган карточкага ябыштырып, номерының рәте буенча сакланыр өчен махсус шкафның тартмасына куя.

Икенчесен әлифба рәте берлән мөштәриләрнең фамилиясе саклана торган шкафка, карточкасына ябыштырып куя.

Өченчесен тагы карточкага ябыштырып, мөддәтләр күрсәтелгән шкафны ача да, вакыты кай айда чыга торган булса, шул айга аерылган бүлмәгә рәте берлән куя. Шуннан калган әллә ничә йөзен барын бергә ала да, хәреф кассасы кебек иттереп кечкенә тартмалар берлән бүлеп-бүлеп ясаган махсус шкафның тартмасын ача да: «Нинди тракт иде әле?» — дип, шул трактка китә торган адресларның күршесенә үзенә аерым бүлмәчеккә куя.

Менә хәзер инде теге матбагадагы басылып беткән хәзер гәзитәгә китик. Менә шул басылган гәзитәләрне санатып, печатник экспедиция башына тапшыра. Ул кулындагы кәгазь буенча тимер юл берлән йибәрә торганнарын бүлеп, кайсы вокзалдан китә, шуларга берәр хезмәтчесен йибәртә. Болар һәммәсе төнлә эшләгәнгә, трамвай йөрми торган булганга, гәзитәне извозчикта салып китәләр. Үзе калганнар берлән эшләргә тотына.

Матбагага килер алдыннан ул, баягы күп адреслар саклана торган шкафтан тракт-тракты берлән аерып[7], һәр тартмачыклардан берәр адрес алып куя да аны махсус бер кәгазьгә төрә.

Аннан соң икенче тракт тора торган кассаларны ача да алардан да һәр мөштәринең бүлмәчегеннән берәрне ала. Аны да төрә, шулай итеп, ул алтмыш биш төенчекләрне хәзер берәм-берәм сүтәргә тотына, берсенә беренче трактның баскан адресларын ябыштырырга куша. Икенчесенә икенче, өченче, дүртенче тракт вә һакәза...

Менә хәзер берничәсе ябыштырылып бетте ди. Ул шуларны саный, үзенең кәгазендәге хисабына дөрест чыкса, тота да махсус хәзерләнгән накладнойга язарга тотына.

Беренче трактның, мәсәлән, беренчесенә бер номер, икенчесенә өч, дүртенчесенә биш, алтынчысына да иллә гайре әл-ниһая...

Шуларны һәммәсен язып бетергәннең соңында шуларның итогын чыгарып яза да дөрестлеге хакында имзасын куя һәм дә шул накладной берлән шул трактка китә торган гәзитәләрне бергә төрдереп бәйләтә, икенче тракт хакында һәм шулай.

Шулай итеп, алтмыш биш трактка гәзитәләрне бүлеп, алтмыш биш накладной язып, алтмыш бишендәге төрле урыннарга күпме китүен күрсәтеп язып бетерә дә, почтага соңга калмас өчен, кызуланып чаба.

Кайсыбер трактлар сәгать биштә өлгерергә кирәк булса, аларны алдан йибәртә.

Шулай итеп, гәзитә чыгачак көннең иртәнге сәгать алтысына кадәр шәһәр мөштәриләрнекен, сәгать җидегә кадәр чит мөштәриләрнекен биреп бетерә.

Шуларны фәлән трактка фәлән кадәр бирү, фәлән трактка фәлән кадәр мәҗмугасен җыеп, тагы ике данә накладной яза да шуларның икесенә дә почта мәэмүре ничә сәгать, ничә минутта никадәр гәзитә алынуы хакында кул куя да берсен почтада калдыра, берсен экспедиция башына тапшыра. Ул шуны конторага кайтарып бирә.

Менә хәзер инде теге адреслар буенча гәзитәләр китәләр. Алар, үзләренең трактлары буенча барып, мәркәз ноктасына туктыйлар да шуннан урыны-урыны берлән таратырга почта идарәләренә вә волостьларга йибәрелә.

Контора: «Аллага шөкер, бу номер тәмам булды», — дип, икенче номерны хәзерләргә тотына. Ул тагы шул рәвештә языла, шул рәвештә басыла. Шул рәвештә йибәрелә.

Ләкин эш әле алай гына бетми.

Гәзитәдә язылган мәкалә берәүгә ярамый. Берәүгә дип йибәрелгән гәзитә икенче йиргә эләгә.

Берсенең адресы ялгыш булып кире кайтып килә. Идарәгә жалобалар килә башлый.
Аннан соң ничек булуы киләчәктә[8].

## ИМТИХАННАР МӨНӘСӘБӘТЕ ИЛӘ

Хәзер имтиханнар вакыты. Идел буеның җиде-сигез мең татар мәктәбендә имтиханнар эшләнеп яткан кебек, Кавказ, Кырым кардәшләремезнең тәртипле мәктәпләрендә дә имтиханнар бара. Ул гына түгел, Төркестан кардәшләремез арасында да татар мөгаллимәсе, татар мөгаллиме аяк баскан йирләрдә шигырь укынып, мөнәҗәт көйләнеп, нотыклар сөйләнеп, имтиханнар дәвам итә.

Шәһәр вә авылларның баласы бар. Бөтен гаиләләре хәзер имтихан уе берлән мәшгуль. Ирләре генә түгел, хатыннары да имтихан кирәк-ярагы белән, имтиханга хәзерләнү белән маташалар.

Бу имтиханнар хәзер безнең тормышымызга кереп киткән сабан туе берлән театр арасында урта бернәрсә булып китте. Балаларның имтиханнарын күрергә чит авыллардан, шәһәрләрдән киләләр. Кибетен ябып, сәүдәгәр бара. Кызлар имтиханына өен калдырып абызтайлар, туташлар җыела. Имтиханга дип балаларга матур киемнәр хәзерләнә, имтиханга җыелган халыкка ярар өчен мөгаллим, мөгаллимә кыш буе хәзерләнә, язга таба эштән чыга, имтиханга килгән кешеләрнең гыйльми үлчәүләре юк икәнен белгәнгә, аларның сүи гыйрфанияләренә карап, күзгә бәрелә торган мәнзарәләр тудырырга, аларның «гыйлем» дигән нәрсәләрен белгән иттереп күрсәтергә зур көч сарыф кыла. Һәр йирдән халыкның нинди нәрсәне күрергә теләвен сизеп ала да, шул якны кабартып, күпертеп күрсәтергә ижтиһад итә. Шуның өчен йончылдырып, балалардан әлләниләр бикләтә, абызтайлар, абзыйларның «теле телгә йокмый, су кебек эчә» диюләрен ишетер өчен кечкенә балаларны муштировать итә. Балага чын, кирәкле белемне бирүгә вакыты җитмәенчә, күстәреш ягына зур дикъкатен йибәрә, шулай йибәрергә мәҗбүр, чөнки имтиханга килгән халык, шул имтиханнан кәмиттән көткән шаккатыруларны күрмәсәләр, мөгаллим-мөгаллимәдән разый булмыйлар. Икенчене эзләргә тотыналар. Аны да табып алып, аңгардан шул балаларны җыйдырып, кәмит ясатырга маташтыралар. Андый-мондый теләгәне чыкмаса, яисә бөтенләй мәктәптән ихласлары кайтса, яисә тагы яңгы мөгаллим эзләргә керешәләр...

Менә бу имтиханны карарга халык җыюларның күңелсез ягы – имтиханнарны халык җыеп ясау ысулының зарарлы икәнен күрсәтә торган аяклы дәлиле.

Кирәк, әле йирле мәгарифпәрвәрләр, кирәк, мөгаллим вә мөгаллимәләр унбиш елдан бирле килгән шул гадәттән, халык эченә кереп, сеңеп бара торган зарарлы юлдан котыла алмыйлар. Болар халыкка күрсәтергә аңлашылсын өчен күрсәтергә, ысуле җәдидтә Коръән укытылганны исбат итәргә, бу мәктәптә теге мәхәлләнекеннән гыйльме хальнең шәплеген белдерергә, бу мөгаллим-мөгаллимәнең үткәннәреннән хисапта осталыгын күрсәтергә мәҗбүрият хисе итәрләрме, әллә бер киткән буенча китеп барамы?..

Ләкин хәзер инде мәктәбемезнең яши башлавына егерме ел тулып килгәндә, әүвәлге елларда кирәкле булган, хәзер искереп бетеп, зарардан башка файдасы калмаган имтихан кәмитләрен бетерергә вакыт иде. Әгәр шуларны бетерсәк, мөгаллим-мөгаллимәләрнең укыту юлларын тикшерүне урам халкының тамгасыннан коткарсак, мәктәп исляхымызның икенче адымын атлаган булыр идек. Һәм дә балаларымызны кәмиткә чыгар өчен хәзерләнгән акробатлар кебек, кирәге бик аз яисә алай кирәк түгел нәрсәләрне уку-ятлаудан коткарып, саваплы, файдалы эш эшләгән булыр идек. Ул гына да түгел, хәзерлекләре бик мәхдүд булган мөгаллим-мөгаллимәләремезне үз эшләре берлән генә мәшгуль булырга имкян бирер идек.

Хәзер бит алар, мескиннәр, сәясәт йөртергә мәҗбүрләр. Бер йирдә алар «Без гыйльме хальгә әһәмият бирәмез», бер йирдә «Без татар теленә нык тотынамыз», бер йирдә «Без Коръән вә тәҗвид укытамыз» дигән лозунглар берлән сәясәт йөртәләр... Шуның аркасында үзенең иптәш мөгаллимне, мөгаллимәне уздырыр өчен «гыйльме хальгә әһәмият бирми», «тәҗвид белми»-фәлән кебек күңелсезлекләргә сәбәп була. Мулла вә мөәзиннең талашуыннан туеп беткән халык арасына яңгыдан иске мөгаллим берлән яңгы мөгаллимнең сәяси талашына зәмин ачалар.

Имтиханнарга киткән, күргән кешеләрнең хәтерләрендәдер, күп йирдә мөгаллим-мөгаллимәләр һәрвакыт балаларга тыңлаучыларны шаккатырырлык сөальләр бирергә тырышалар. Балаларга тыңлаучылар алдында зур күренгән нәрсәләр кечкенә булса да, белдергән кебек күрсәтергә маташалар. Шуның өчен аларның махсус юллары бар. Җиде яшьлек бер баладан: «Тәяммем нәрсә?» — дип сорыйлар. Бала шарт-шорт җавап бирә. Дөнья кайгысы берлән бөтенләй бирелгән абзый базарда ишетелмәгән бу яңгы нәрсә — тәяммемне нәни бер баланың белүенә гаҗәпкә кала.

«Госел нәрсә?»
Абзый, абыстай аны беләләр...
«Әйе, ул кирәкле нәрсә?»
Нәни генә чәчәк кебек сигез яшьлек кызчык госел нәрсәлеген сөйләп бирә.
Абзыйның кәефе тагы килә.
«Йә, госелнениләр фарыз итә?»
Аңлый башлаганның соңында гомерендә бер мәртәбә халык алдында әйтергә ярамаган сүзләрне балачык тезеп китә...
Абзыйның йөзенә көлү чыга... Авызы ерыла. Икенчеләр берлән күз-күзгә карашып алышалар...
«Мөгаллимнәр шәп укыткан икән... Киләсе елга да алыйк! Алыйк!»
Мөгаллим-мөгаллимә, Аллага шөкер, бу ел урын эзләүдән котылдылар...
Бу елны сәясәтләре инглизләрнең соңгы елгы сәясәтләреннән файдалы чыкты.
Имтиханда аңлаганрак, матбугат укыганнар бармы?
Ярый, алар да өлешсез калмасын.
«Йә әле, Әхмәт! Җәнүби Америкада нинди елгалар бар?»
Бала, күзне ярты йомып: «Миссисипи, Миссури, Амазонка... шәһәрләре; Рио-де-Жанейро, Гватемала...»
Менә тагы шаккатырдылар... Тагы әллә никадәр кеше аңламаган сүзләрне балалар әйттеләр.
Шул балаларга чынлап имтиханчы булып, аларның өч елда, дүрт елда аңнары никадәр артуын белер өчен кыска гына бер җөмләне укытып, гыйльме тәхлил ясаса, табигатьтән кечкенә-кечкенә нәрсәләр сораса, бала кызара-бүртенә, мөгаллим-мөгаллимә аптырап кала.
Балалар алай укытылмаган, дәресләр балага хәят өчен кирәкле аңны бирү ысулына куелмаган.
Балалар имтихан дигәндәге кәмит көнендә роль уйнаучы нәни артистлар иттерелгән.
Мөгаллимнәр шуларны өйрәтүче режиссерлар итеп чакырылган...
Болар бер мәктәпкә, бер имтиханга карап кына язылмый. Алдымда егермеләп имтиханны язган мәктүбләр тора.
Һәммәсендә: «Балалар гыйльме хальдән, җәгърафиядән гаять гүзәл җавап бирделәр Тукаев мәрхүмнең шигырен укыдылар».
«Баш мөгаллимемез Габдулла әфәнде милләтне тәрәккый иттерү хакында нотык сөйләде».
«Милләт атамыз Габдрахман әфәнде гаять мәэсүр нотыгында мөгаллимнәргә рәхмәт укыды, яшәсен милләт, диде».
«Милләт анамыз хөрмәтле, шәфкатьле, сәгадәтле, фазыйлиятьле Миңлесафа абыстай балаларга бүләк өләште».
Һәммәсен тәхлил итсәк, шул чыга: 15–20 ел эчендә үткәргән имтиханнарны күздән кичерәсең дә, шул хиссият яңара: бу ел мәктәп мәсьәләсе, программа мәсьәләсе җитдирәк мөзакәрәгә куелырга тора.
Оренбург земствосында киңәш булачак, Уфа земствосы зурча бер киңәш мәҗлесе ясамакчы була. Гәзитәләремездә дә шул хакта язгалыйлар.
Мөгаллим-мөгаллимәләр җитмәгәнгә, анда-монда мөгаллимәләр, мөгаллимнәр курсы ачыладыр.
Димәк, без шул уку-укытуның кәмит мәсьәләсеннән ашып, хәят эше икәнен чынлап аңлар дәрәҗәгә килеп барамыз.
Димәк, бу көн-иртәгә безнең моңганчы килгән мәктәп гадәтләремез, юлларымыз тәнкыйтькә, фәнни тәнкыйтькә уграячак. Шуның өчен хәзерге мөгаллим-мөгаллимәләр алдында иң беренче вазифа мәктәпне вак сәясәттән пакьләү булырга тиештер. Шуның өчен мөгаллим-мөгаллимәләр өчен ясалган курсларда да мөгаллим-мөгаллимәләрнең тәрбиягә, гыйльми тәрбиягә өйрәтелүләрен әллә нинди шау-шулы, тантаналы программаларга корбан ителмәскә, мәктәп вак сәясәттән әрчелергә тиештер.

## УНЪЕЛЛЫК ДУМА ВӘ МӨСЕЛМАННАР

27 апрельдә Думаның җыелуына ун ел тулып үтте. 27 апрельдә безнең мөселман депутатларымызның Русия мәмләкәтенең закон төзү диванына закон эшләшүче сыйфаты белән керүләренә ун ел үтте.
Бу ун ел эчендә дүрт мәртәбә мөселман халкы үзенең вәкилләрен Дәүләт Думасына закон эшләшергә, мәмләкәтнең эшләрен халык файдасына таба эшләшергә дип йибәрде, шул ун ел эчендә Русия мәмләкәтенең төрле тарафларына җәелгән мөселманнары сиксән биш кадәр вәкил сайладылар[1].
Шул ун ел эчендә Русиядә рус милләтеннән кала күплеге берлән беренчелекне тоткан мөселманнарның вәкилләре әүвәлге Думадагы утыз өчтән Дүртенче Думада йидегә килеп төште, шул ун ел эчендә Думага

сайлауның праволарын үзгәрткән «Өченче июнь законы» буенча бөтен Төркестан, бөтен Кыргызстан вәкилсез калдырылды[2]. Кавказ, Идел буе мөселманнарының сайлау хокуклары сизелерлек дәрәҗәдә киметелде.

Ләкин шулай булса да Дәүләт Думасында — Русиянең закон төзүче диванында — мөселман депутатлары булмаенча тормады. Аларның тавышларын, мөселманнарның күплегенә нисбәттә бик аз булса да, аларның мәгънәви, матди көчләре Русия мөселманының мәдәни ихтыяҗын үтәр өчен зәгыйфьлек күрсәтсә дә, һәрвакытта мөселман тавышы ишетелә килде.

Зуррак мәҗлесләрдә мөселман депутатлары үз фикерләрен чыгып сөйләделәр. Мәсләклерәк адымнарда үзләренең ноктаи нәзарларын аңлаттылар. Мөселманнарның мәдәни-икътисади, сәяси хәлләренә гаид законнар каралганда, мөселман мәнфәгатен сакларга тырыштылар.

Думаның үз мәҗлесләрендә генә түгел, комиссияләрендә дә фикерләрен бәян иттеләр. Депутатларымыз бик аз булганга, араларында зур, көчле затлар да тугры килмәгәнгә, мөселман фракциясенең бер нотыгы да, бер заявлениясе дә Русия әфкяре гомумиясенең дикъкатен җәлеп итә алмады. Ун ел эчендә бер генә мәртәбә дә Думада «мөселман көне» була алмады.

Моның, әлбәттә, иң зур сәбәбе фракциянең ялгызлыгында, фракциянең ярдәмсезлегендә иде. Фракция бөтен эшне үз көче берлән эшләргә мәҗбүр иде. Фракциягә материал бирүче ил тик тора торган җансыз бер гәүдә иде.

Фракциягә арка таяначак вилаятьләрдә организацияләр, оешмалар юк иде. Фракциянең фикердәше, мәсләктәше бик күп булса да, аның шәп эшләвен, Тимер батыр[3] кебек хәрәкәт итүен күрәсе килүче бөтен Русия мөселманы булса да, бу көчләр таркау хәлендә иде. Бу көчләр фәкать күңел көчләре, бәгырь теләүләре генә иде. Бу көчләр һичбер төрле матди вә мәгънәви ярдәмгә кул сузарлык дәрәҗәдә гәүдәләшкән куәтләр түгел иде.

Шуның өчен, бу көн әйтергә оят, ун елдан соң әйткән кешегә ялганчы диеләчәк милли вакыйга хакыйкать булып килде.

Ун ел эчендә Русиянең утыз миллионлы мөселманы фракция янында бер бюро, бер эш бюросы ясап бирә алмады.

Ун ел эчендә утыз миллионлы мөселман елына утыз мең сумлык мәсъраф чыга торган милли үсеш өчен мәктәптән, мәсҗедтән кирәкле бер фарызны үти алмады.

Ун ел эчендә утыз миллионлы мөселман, үзенең сәяси хәрәкәтләрендә кыйблагяһ булсын өчен, бердәнбер легальный, законлы булган фракция янында үзенең инанган җәмәгать хадимнәрен җыеп, сәяси бер оешма ясый алмады.

Шул хакта милли үсүемезгә, мәдәни алга китүемезгә, сәяси тәрбия күрүемезгә никадәр зарар ителгәнлеге, әлбәттә, санап бетергесез.

Милли тормышымыздагы мөфти мәсьәләләре, мәктәп-мәдрәсәмезнең төпсезлеге, тормышымыздагы гражданлык хакын алып бара торган доносчылык, хулиганлык, соңгы замирләре берлән, шөбһәсез, шул оешманың юклыгына, халык алдында игътибарлы фикер кыйбланамәсенең юклыгына барып төртеләләр. Ләкин болар арасында иң зарарлысы — халкымызның сәяси тәрбиядән гафил булуы вә шул хакта бер эш тә эшләнмәведер.

Беренче Дума, Икенче Дума сайлауларында халкымызның ничек сайлаулары күз алдымызда булса, Өченче, Дүртенче Думадагы сайлануларның иттифакыйлыгы да, әлбәттә, һәммәмезгә мәгълүм.

Анда бер кеше иттифакый цензалы булды да сайланды[4]. Монда берәү иттифакый күпчелек тарафыннан кабул ителде дә Думага үтте. Мәгълүм программаны күздә тоту, мәгълүм бер хаттел-хәрәкәткә ригая итү, мәгълүм мәсләктән читкә чыкмау кебек шартлар, әлбәттә, бер йирдә бер исем тарафыннан да куелмады, күрсәтелмәде. (Бу мәсьәләдә Уфа гына бераз мөстәсна.)[5]

Аннан — Миңлегалиев, моннан — Байбурин, тегеннән —Мөфтизадә, моннан Тәлгат сайландылар да килделәр[6].

Менә шул иттифакыйлык мөселман фракциясенең мәгънәви көчен бетерде. Аны һичбер вакытта бергә бәйләнгән, ныгыган бер тән, бер җан кебек итә алмады. Шуның хакында халкымыз берлән фракция арасында аңлашу, берсен-берсе танышу булмады. Киләчәктә дә бу куркыныч әле бетмәгән. Киләчәк Думада әле йирле куштаннарның, земский сөйгән старшиналарның мөселман вәкиле булып килүе ихтималы бетерелмәгән.

Чөнки халык әле сәяси тәрбия күрмәгән. Халык әле Думаның нәрсәлеген аңламаган. Халык әле мөселман фракциясе нишләргәлеген белмәгән.

Менә Думаның торышына ун ел тулгач кына булса да, безнең халыкка шуларны аңлата башларга вакыт түгелме?

Мөселман фракциясе нәрсә? Нинди булырга тиеш? Мөселман вәкилләре кемнәр? Киләчәктә ниндиләр булырга тиеш дигән дәрес бирелә башларга тиеш түгелме?

Тиеш, күптән тиеш.

Хәзер калдырмаенча эшли башлауның чигенә йителгән булырга тиеш.

Шуның өчен, әлбәттә, бик күп рисалә, китаплар язарга кирәктер. Бик күп кешеләр, хатиблар халыкка Думаның нәрсәлеген, мөселманнар аннан ни көтә алуларын аңлатырга тиештер.

Ләкин болар әле хәзергә дахили сәясәт һавасында мөмкин түгел дәрәҗәдә. Шуның өчен иң уңгай юлны алырга тиештер.

Ул да — депутатларымызның Беренче, Икенче, Өченче, Дүртенче Думаларда сөйләгән бөтен нотыкларын татарчаландырып нәшер итү[7], шуларны халкымыз арасында күпләп-күпләп таратудыр.

Хәзер, Аллага шөкер, Дума янындагы бюро, шундагы унъеллык таркау материалдан җыеп, мал хәленә китерә.

Хәзер, Аллага шөкер, бюро, фракциянең закон төзү эшләрен йиңеләйтер өчен, ляихәләр хәзерли, эшли, эшләячәк. Киләчәктәге эшләргә нигез салачак.

Ләкин шул бюро янына тагы бер кечкенә генә бюрочык ясап, шул бюрога яңгы әгъзалар кушып, яңгы бурыч йөкләтеп, бер тәрҗемә бүлмәсе ачып, бөтен мөселман депутатларның речьләрен эшләп чыгарсалар, бик зур хезмәт булмас идеме?

Булыр иде. Халык үз вәкилләренең ни сөйләгәнлекләрен укыр иде. Халык, укый-укый, төшенә-төшенә, үзенең сәяси тәрбиясен киңәйтер иде.

Халык үз аңы берлән нинди депутатларның үзенең йөрәгенә ята торган сүз сөйләвен, ниндиенең гакылына сыйганны эшләвен күрер иде.

Шуның өчен хәзер бюроның ныгып йитүе мәгълүм булды исә, фракция икенче мәсьәлә итеп шуңгарга керешсә иде.

Халкымызның аңлы кыйсеме, сәяси тәрбия бирүне лязем дип ышанган блогы шул кечкенә китапларны нәшер итәргә матди тәэминат ясаса иде.

Русиянең кичерә торган вакыты — тарихи вакытлар. Бу көн булмаса, иртәгә, иртәгә булмаса, берсекөнгә сәяси тәрбиягә ихтыяҗымыз зур булачак.

Думаның мөддәте дә узып бара, озакламаячак, тагы сайлаулар да булачак, тагы халыкның фикеренә, сәяси тәрбиясенә мөрәҗәгать ителәчәк. Менә шул вакытларда, уңны — сулдан, акны карадан аерыр өчен, шул депутатларымызның Думада сөйләгән нотыклары бик зур ярдәм итәчәктер вә бик күп кешегә кыйбланамәлек вазифасын үтәячәктер.

Без әфкяре гомумиянең шул мәсьәләгә дикъкать итүен күрәсемез килә. Без шул мәсьәләнең озын түгел көннәрдән соң фәгалиятькә чыга башлавын ишетәсемез килә.

## «ТАҢ» ГӘЗИТӘСЕ ЧЫГУЫНА УН ЕЛ ТУЛУ МӨНӘСӘБӘТЕ БЕРЛӘН

Бүген татарның фикер тарихында зур бер роль уйнаган «Таң» гәзитәсенең тууына нәкъ ун ел буладыр. Бер фикере иҗтимагыйны тәхлил итәргә, аны тудырып чыгарган гамәлләрне иҗекләргә унъеллык мөддәт йитәрлек вакыт булса да, хәзерге көндәге сәяси һавалар[1] «Таң» хакында ачыктан-ачык сөйләүдән безне тыядыр.

«Таңчы»лык мәсләге Идел буе төрек-татарның фикер тарихында каһарманча сәхифәләрне язучы беренче хәрәкәт булганга, соңгы гасыр эчендә Идел буе төрек-татарының черемәгән икәнен күрсәтә торган яшь йөрәкнең беренче тибүе булганда, әлбәттә, җаның хакында ярым-йорты мәгълүмат бирү тарихе әфкяремезгә каршы җинаять булачактыр. Шуның өчен «таңчы»лыкның тууы, үсүе, киңәюе дәверләрен без хәзер күз алдымызда кебек күреп торсак та, «таңчы»лык мәсләгенең, «таңчы»лар хаттел-хәрәкәтенең Идел буена иткән мәгънәви тәэсирләрен берәм-берәм санарлык булсак та, мәгаттәэсеф, шуларын ачып сала алмыймыз. Татар тарихе сәясиясенә зур материал булачак шул мәгълүматларны чыгаруны мөнасиб вакытына кичектерергә мәҗбүр буламыз.

Шуның өчен үк, «таңчы»лык мәсләге вә «таңчы»ларның хезмәтләре арасын да җиде-сигез еллык реакция каплап торганга, вә шул җиде-сигез ел эчендә милли ганганәсез, иҗтимагый тойгысыз, вак-төяк мөхәррирчекләрнең, «таңчы»лыкның үзенә сугылган печатьтан файдаланып, буяган ялган төсләрен юарга, «таңчы»лыкның чын төсен күрсәтергә дә имкян таба алмыймыз вә шул хакта сөйләргә тиеш булган сүзләрне, күрсәтергә кирәк булган дәлилләрне дә коралланырга сәяси даирә мөсагыйд түгел дип, тик каламыз. Киләчәктә хакыйкатьне ап-ачык итеп сөйләячәгемезгә ышанып, сөйләргә мәгънәви көчемез барлыгына инанып, аны да кичектерәмез.

Шулай булса да, «таңчы»лык хәрәкәтендәге бәгъзе бер нокталарны ачуны, «Таң» гәзитәсенең бәгъзе бер якларын күрсәтүне лязем табамыз.

Иң әүвәл шуны әйтик, «Таң» гәзитәсе нинди гәзитә иде? Шул гәзитәне нинди гамәлләр тудырды? Ул татар тормышында табигый буларак мәйданга чыктымы, әллә сонгыйлык бар идеме?

«Таң» гәзитәсе, «таңчы»лык фикере янында оешкан бер гөруһ халыкның тәрҗемане әфкяре булганга, әлбәттә, аның хакында гәзитә буларак аерым сөйләп торуның лөзүме юк. «Таңчы»лык мәсләген тудырган гамәлләр аны тудырган буладыр, ләкин «таңчы»лык мәсләген, тугрырак әйткәндә, халыкчылык мәсләген нинди гамәлләр мәйданга чыгаруны өстеннән генә күздән кичерү зарар итмәячәктер. Тарихи вакыйгаларны тудыручы гамәлләр арасында бик күптөрле матди, мәгънәви, психологический факторлар буладыр. Боларны берәм-берәм тәхлил ясап тору, бая әйткәнчә, мөмкин булмаганга, моның психологический сәбәпләрен генә күзгә китермәкче буламыз.

Егерменче гасырларда татар тормышындагы иң сизелгән нәрсә — фәүкылгадә бер кысынкылыгы иде. Татар тормышы бөтен даирәләрендә тыгызлык сизә иде. Аны әллә нәрсә тыштан кыса иде, әллә нинди көч эчтән изә иде. Шул изү аркасында аның тудыра торган көче гаять зәгыйфьләнгән, үзенә киртә куелмаган сату-алуда гына беркадәр җанлылык күрсәткән иде. Башка тарафлар да, кирәк, гыйлем юлында, кирәк, уку-укытуда, кирәк, иҗтимагый оешуларда, тәмамы берлән эшсезлектә иде. Ул рухан фалиҗ суккан хәлдә иде.

Шул тик тору хәле озын дәвам иткәнгә, бер яктан, тудыру, эшләү куәтенең маясен киметкән иде. Икенче яктан, шул эшсезлек, тудырмаенча тору «барына канәгать» фикерен тудырган, шуны татар тормышының эченә ныгыткан иде.

Шуның өчен татар, бөтенләен алганда, һәрбер төрле мәдәни, сәяси эшләрендә кыл кыймылдатмый торган бер хәяте иҗтимагыя булып яши иде. Үзенең хәят мәсьәләләрендә дә «уф» дип кенә җавап итеп, һаман буйсына бара торган бер халык иде. Һәрбер уңайсызлыкка «Казан илаһи» дип карау, «язмыш» дип ышану бөтен рухында хәят өчен, хокук өчен тартышуны — хәятның иң нык тамыры булган тартышуны бетергән иде. Бөтен татар халкыннан боламык кебек хәрәкәтсез-җансыз, пассив бер элемент ясап куйган иде. Менә шул пассивлык бөтен татарны кыскан кебек, борылырга тора торган яшь көчләрне дә кыса, изә иде.

«Монысы гадәткә сыймый, монысы шәригатькә тулмый, монысы — йолага хилаф!» — менә егерменче гасырның башындагы хәрәкәтләр, татар яшьләрен җанландырган хәрәкәтләр вакытында алар алларыннан да, артларыннан да шул мыгырдау, шул эшсезлекне күрделәр. Татар үзен-үзе эченнән, тышыннан шул тик тору, шул язмышка ышану белән чолганганын күрде.

Аларның алдында ике төрле генә мәсьәлә чишеләчәк иде. Берсе — үзе дә күпчелеккә катышып: «Тәкъдир язмаган эш булмас», — дип «тиклек»кә батып китү; икенчесе — шул эшсезлектән туеп: «Бактым, кит шуннан, явыз көч! Бет, явыз көч, мин сине бетерергә тырышам», — дип тартышырга керешү иде.

Халыкның, яшьләрнең күпчелеге йонны яткан ягына сыйпау фикере белән гакылны башлык итте. «Иренмә, тартыш!» — дип кычкырды вә шул тартышуны юл итеп мәйданга чыкты. Үзенең бөтен хаттел-хәрәкәтен тартышу белән тәгаенләде. Менә бу «таңчы»лык хаттел-хәрәкәте иде.

Шуның өчен «таңчы»лык, психологический яктан караганда оешкан, мәгънән фалиҗ хастасына эләккән татар тормышына каршы реакция иде. Бу реакциянең куәтлелеге, көчлелеге дә, теге фалиҗ зәхмәтенең көчлеге берлән мөтәнасиб иде.

Фалиҗ зәхмәте дин, шәригать мәсьәләләрен каплаган иде. «Таңчы»лык шуларга каршы хатын-кыз мәсьәләсендә тартышу күтәргән иде.

Фалиҗ зәхмәте халыкның сәяси хокуклары тарафын фалиҗ белән каплаган иде. «Таңчы»лык хокуклы булу, халык тәмам хокуклы булсын дип тартышу ачкан иде.

Фалиҗ зәхмәте, миллиятен тәмам телсез, авызсыз калдырган, аның җәберен, моңын, көен кимергән иде. «Таңчы»лык театр, музыка, әдәбият тусын дип, аңгарга каршы тартышу ачкан иде.

Татар тормышы фикерлек, мескинлеккә баткан иде. Аның икътисади хәяты, җире, суы фалиҗ хастасы берлән кипкән иде. «Таңчы»лык җир, ирек тартышуын ачкан иде, ачкан гына түгел, хәятның дәвамы өчен шул тартышуда гына булачак икәнен аңлаган иде, шул тартышуда гына киләчәк икәнен, шул халыкка аңлатуны гая итеп алган иде. Шуның өчен «таңчы»лык фалиҗ хасталыгына, эшсезлеккә, язмышка каршы ачылган мәгънәви бер хәрәкәт иде.

«Таңчы»лык фикер, рухны таза бер матдә берлән тулуы өчен ачылган низаг иде. Низагы бәка иде. Шуның өчен «таңчы»лык үлүгә, тик торырга, пассив яшәүгә каршы булган бер хәрәкәт иде. Тормыш өчен, хәят өчен тартышу иде. Милли, дини хокуклар, икътисади, иҗтимагый киңлекләр өчен тартышу иде. Татарның киләчәктә бер хәяте иҗтимагыя булып, җанлы, рухлы хәяты иҗтимагыя булып яшәү өчен

тырышу-тырмашу иде. Ягъни «таңчы»лык татарның хәяты миллиясенең бәкасе өчен кычкырыш алды. Аның низагысы — бәка низагысы иде.

Шулай булгач, «Таң» гәзитәсе ябылса, «таңчы»лар Себергә җибәрелсә, «таңчы»лар эчтән-тыштан дошманнар белән чормалып алынса, «таңчы»лык рухы бетәчәк идеме?

Татарның хәятында киләчәккә омтылу бетмәсә, татарның тормышында мәдәниянү гаясе бетмәсә, «таңчы»лык рухы бетмәячәк иде. «Таңчы»лык яшәячәк иде. Ул вакыт без, «таңчы»лар, шуның яшәвенә иман иткән идек.

Бу көн, «Таң» гәзитәсе туганга 10 ел үткәч, «таңчы»лык фикеренең никадәр зур тәрәкъкый иткәнен күреп, татар тормышындагы фалиҗның әле бер әгъзадан, әле бер әгъзадан китүен-кимүен күреп, үземезнең ул вакытта хак юлда икәнемезне белеп сөенәмез. Киләчәктә дә татар фикеренең тәрәкъкыйсы безнең тартышу юлыннан барачагын еравктан күреп торып шатланабыз.

Татар инде авыруыннан терелү дәверенә кучте. Татар инде «язмыш шулай» дигән хастадан котылды. Татар мәдәнияте өчен, милли мәдәнияте өчен тартышырга тотынды.

Моннан ун ел элек «хәят өчен тартышу» дигән безгә махсус лозунг гомум өчен лозунг булды.

«Таңчы»лык татарның канына сеңде.

## * * * (БУ КӨНГЕ КӨННЕҢ ИҢ МӨҺИМ МИЛЛИ МӘСЬӘЛӘСЕ...)

Бу көнге көннең иң мөһим милли мәсьәләсе — шөбһәсез, Уфа земствосы тарафыннан чакырылган киңәш мәҗлеседер. Матбугатымыз шул хакта мәкаләләр язды, яза, язачак. Гыйлем ияләремез шул киңәш мәҗлесенә докладлар яза, хәзерли, укый, казына, хәзерләнә.

Әфкяре гомумиямез дә үзенең тавышын ишеттерер өчен мөзакәрәләр ясый, карарлар кабул итә.

Казанда шул хакта берничә мәҗлес булып үтте вә тагы ясалырга тора. Оренбургта шул хакта киңәш өчен бер оешма ясарга карар бирелде, мәҗлесләр ясалды. Троицк та үзенең фикерен, мөляхәзәсен бер җепкә тезде.

Гәзитәләрдә уку-укыту мәсьәләсенә мөнәсәбәте булган затлар, мөнәсәбәте бар дип ышанган кешеләр мәкаләләр яздылар, фикерләрен, төшенмәләрен мәйданга сөрделәр.

Кыскасы гына, Идел буе төрек-татарының хәят, мәмләкәт мәсьәләсе җитди бер сүз, бер карар алдында икәнлеген хис иттерә торган бөтен эшләр, хәрәкәтләр күз алдыннан үтте. Моннан соң да, табигый уларак, көне якынлашкан саен, мәсьәлә җитдиләшә барачактыр. Табигый уларак, хәзергә караганда да күбрәк затлар мәсьәләнең хәленә катышачактыр.

Ләкин монда кечкенә генә ике куркынычлы тыкрыкка китү ихтималы да юк түгелдер.

Боларның берсе һәм дә иң куркынычлысы — гәзитәләр, журналларда мәктәп мәсьәләсе берлән аяк өстендә генә таныш кешеләрнең күпләп катнашып китүләре, үзләре артыннан әфкяре гомумияне бутап йибәрүләредер. Әгәр бу була калса, безнең һәр эшемездә булган кебек һәр кеше «бәнем нәзарым» дип мәйданга чыга башласа, шөбһәсез, мәсьәлә буталачак кынадыр. Милләт катгый бер сүз, күплек тарафыннан кабул ителгән фәнни бер карарны кабул итүдән бик еракта калачактыр.

Шулай була калса, фәнни тәрбия мөтәхассыйслары, уку вә укыту осталары читтә калдырылачактыр. Аларның фән берлән ныгытылган фикерләре, асыл хакыйкатьләре сүз, моназарә, могарәзә, сафсаталар астында күмелеп калачактыр.

Икенче тапкыр тыкрык тагы да күңелле юл түгелдер.

Ул да — шул киңәш мәҗлесе мөнәсәбәте белән вә шул хакта әйтеләчәк сүзләр, кабул ителәчәк фикерләрдә йирле хәмиятнең роль уйнавыдыр. Әгәр чынлап та гомуммилли булган мәктәп мәсьәләсендә безнең урам, ары як урамы дигән балалыктан алып калган урам хәмиятемездән өстә тора алмаслык, тагы күңелсез нәтиҗәләр туачактыр.

Шәһәрләр һәм авыллар арасында «минем фикерем үтте, теге фикер үтмәде, безнең җиңде, тегеләрнеке җиңелде, безнең шәһәр теге шәһәрнең борынына чиертте» дигән бытбылдык сугыштыруы башланачактыр. Земстволарның шулкадәр яхшы ният белән башлаган шул мәдәни хезмәтләреннән без оятлы гына булып калачакмыз.

Шуның өчен мәсьәләгә катнашачак затлар, кирәк, сүз сөйләгәндә, кирәк, фикер йөрткәндә, иң әүвәл үзләренең фән җәһәтеннән хәзерлекләре барлыгына дикъкать итсәләр иде. Фәнни тәрбиядән хәбәрсез булса, мәктәп программасы хакында мәгълүматлары өстән-өстән генә булса, бу эшкә катышып тузан күтәрмәсәләр иде.

Укучылар да фән күргән, тәҗрибә белән хәзерләнгән укытучы мөгаллимнәремезнең сүзләрен, фикерләрен, бик үк шома итеп әйтелмәсә дә, тавышсыз-тынсыз гына кабул итсәләр иде.

Шәһәрләр арасында бу көнге көндә туып килә торган йирле хәмият бу мәсьәләдә роль уйнамаенча, киң күзлелек күрсәтә алсак иде. Шуның өчен борын чиртүләрне ташлап торып, бу мөкатдәс мәсьәләдә фәкать

милли, мәдәни мәнфәгатемез берлән генә ашлансак иде вә шул милли, мәдәни мәнфәгатьне күздә тотып кына хәрәкәт итсәк иде.

Без шуны көтәмез.

Гыйлем әһленең, фәнни тәрбия күргән затларының чынлап эшкә керешеп, йөземезне агартырлык хәзерлекләр күрсәтүләрен Алладан теләп каламыз.

## * * * (ҮТКӘН НОМЕР ГӘЗИТӘМЕЗДӘ...)

Үткән номер гәзитәмездә Русиядә яши торган гайре рус милләтләр исеменнән Америка президенты Вильсон җәнабларына ителгән мөрәҗәгать хакында язылган иде.

«Новое время»нең язуы буенча, мәсьәлә моннан гыйбарәт: май числосының башларында «Русия тарафыннан кысыла торган милләтләрнең союзы» исемендәге чит мәмләкәтләрдә яши торган җәмгыять Вильсон җәнабларына бер докладной записка-мәгъruзат күндергән. Докладның эчендә мөфассал иттереп гүя Русия хөкүмәтенең гайре рус милләтләрне җәберләүләре саналган вә президент җәнабларыннан Русиядәге гайре рус милләтләренең мәдәниятләрен бетүдән саклар өчен Русия хөкүмәтенә тәэсир итәргә үтенелгән. Докладның ахырына финнар, эстоннар, латышлар, литвиецлар, поляклар, малоруслар, яһүдләр, грузиннар, мөселманнар тарафыннан имзалар атылган, ягъни шул кысылуда бу халыкларның һәммәсе дә Вильсон җәнабларына зарлануларында иштиракь иткәннәр кебек күрсәтелгән.

Нинди милләтләрнең әгъзаларыннан кемнәрнең имза атканлыклары мәгълүм булмаса да, поляклар исеменнән Дүртенче Думаның әгъзасы поляк Лемпицкийның кулы барлыгы мәгълүм булган. Бер яктан, Русиянең дәүләт диваны әгъзасы үз халкының хәлен яхшыртыр өчен чит мәмләкәтнең башлыгына мөрәҗәгать иткәнгә, икенчедән, милләтләр мәсьәләсе Русиядә бик әһәмиятле мәсьәлә булганга, Думаның аксакаллары мәҗлесендә шул эш каралды һәм дә бик күп сүзгә сәбәп булды. Мәсьәләне мәҗлескә керткән националистларның шул мәсьәләне алга сөрүдән максатлары, бәлки, үзләренең гайре рус милләтләргә эминият кирәкмәүне исбат итү өчен аларга дошманлыкларын гына күрсәтү өчен булгандыр. Ләкин аксакаллар мәҗлесендә мөзакәрә бөтенләй башка төс алды. Күпчелек милләтләрнең вәкилләре булган булып, Вильсон җәнабларына мөрәҗәгать итүгә сәлби яктан карасалар да, докладта күрсәтелгән кысынкылыкларның барлыгын икърар иттеләр.

Депутатларның күбесе гайре русларның хәлен үзгәртү вакыты бик йиткәнен, гайре рус милләтләрен хокукта тигезләү тиешлеген алга сөрделәр.

Чит мәмләкәтләрдә яши торган «союз» белән Русия мөселманнарының катышы юк икәне хөкүмәткә бездән яхшы мәгълүмдер. Русия мөселманнарының үзләре тарафыннан Вильсон җәнабларына хокукларын мөхафәзә итәр өчен мөрәҗәгать итәргә вәкил күндермәүләре дә билгеледер.

Ләкин моннан да Родзянко җәнаблары аңлаганча, Русия мөселманнарының хәлләре ал да гөл дип әйтергә урын юктыр.

Русия мөселманнарының хәлләре хакыйкатән бик күп үзгәрергә мохтаҗдыр. Русия мөселманнары мәдәни яшәешләренә аркылы салынган бик күп киртәләрне алып ташлаулары күптән тиештер. Русия мөселманнарының хәзерге хәлләре аларны икътисади, сәяси мөсавәтне бик зур дәрт берлән көтәргә мәҗбүр итәдер.

Ләкин Русия мөселманнары, кирәк, сугыш вакытында, кирәк, солых вакытында үзләрен Русиянең гражданнары итеп хисап иткәнгә, алар үзләренең хокуклы булуларын чит мәмләкәтләрнең тикшерүләренә биргәннәре юктыр. Русия мөселманнары үзләренең тулы хокуклы булуларын бик теләсәләр дә, бу мәсьәләне Русиянең үзенең дахили эше дип ышанганга, Дәүләт Думаларыннан, рус халкының үзенең сәяси тәҗрибәсеннән көтәдер.

Моңганчыга кадәр үзенең зарын, аһын, җәберләнүен мәмләкәтнең канунлы даирәләренә генә мөрәҗәгать итеп аңлатырга, ислях иттерергә тырышкан Русия мөселманнары моннан соң да шул юлдан күчәр дип уйламыймыз.

Ләкин Русия мөселманнарының чит матбугатта шау-шу кубармавы, Төркия әрмәннәре кебек, кечкенә генә бер мәсьәләдән берничә кешедән җыеп, Аурупа, Америкага делегатлар йибәреп шапырынмаулары аларның хәлләре бик яхшы икәнлектән булмаенча, бөтенләй башка сәбәпләрдәндер.

Без, Русия мөселманнары, үземезнең хәзерге хәлемезнең бик кысынкы икәнен беләмез. Без, Русия мөселманнары, хәзерге кысынкылыкларның безнең мәдәниятемезгә, милләтемезгә, динемезгә дә зарарлы тәэсир иткәнен күрәмез. Ләкин без һаман әле шул кысынкылыклар бетәр, законлы юлда бетәр дип, рус халкына ышанып көтеп торамыз.

Тарих буенча бергә авырлыкларны күтәреп барган Русиянең төрек-татарларына рус милләте золым итмәс, аның милли хәят берлән яшәвенә манигъ булмас дип өмидләнеп торамыз.

Моңганчыга кадәр килгән кысынкылыклар һәммәсе дә аңламаудан гынадыр. Безнең үземезнең хәлемезне аңлата белмәвебездән генәдер дип, үземезне җуатамыз вә шулай гына булуына ышанып каламыз.

Шуның өчен Думадагы милләтләрнең хәлен ислях итү кизүе бетте дигән фикергә без тәмамән катышып, үз тарафымыздан нинди исляхларның кичектерелмәве тиешлеген әйтеп китмәкче буламыз.

Беренче, Русиядә яши торган төрек-татар баласы — сан җәһәтеннән һәм дә тазалыгы җәһәтеннән руслардан кала беренче милләттер.

Санымыз хакында никадәр ихтиляф булса да, иң аз иттереп әйткәндә дә, безнең санымыз егерме биш миллионнан ким түгелдер. Менә без Русия дәүләтендә бөтен авырлыкларны бергә күтәрә торган шул төрек-татар милләтенең бер милләт булып яшәргә хакы барлыгын, кирәк, хөкүмәтемез, кирәк, рус милләте тасдыйк итсен вә безнең милли хәрәкәтемезгә һичбер төрле аяк чалынмасын.

Икенче, без, Русиядәге төрек-татар балалары, әллә кайчаннан бирле ислам динендә булып килгәнгә, исламият безнең канымызга сеңгән. Исламият барлыгымызның бер нигезе булып әверелгән.

Мөселманлык белән төрек-татарлыкны Русиядә аеру мөмкин түгелдер. Шуның өчен безнең динемез һичбер яктан кысылу күрмәскә тиештер.

Хөкүмәт даирәләрендә, русларның идарәгә якын мохитләрендә безне христиан итү фикере, безгә каршы миссионерлар көче белән хәзинә акчасы белән тартышу тәмамән бетерелергә тиештер.

Менә бу ике әсас кабул ителмәгәндә, безнең арамыздан аңлашуны көтү бик авырдыр. Шул ике әсас фәгалиятькә чыгарылмаганда, читкә чыгып, милләтнең мәнфәгате дип аңлаган кешеләрнең чит матбугат, чит хөкүмәтләрнең ярдәменә сыгынуын бетерергә мөмкин түгелдер. Билгакес, Русия мөселманнарының үзләренең съездларында, матбугатында, әфкяре гомумиясендә лязем дип кабул ителгән маддәләр канун даирәсендә тормышымызга татбикъ ителсә, Вильсонга бирелгән бер доклад кына түгел, мең доклад та Русиянең халыклары арасындагы берлекне бетерәчәк түгелдер. Русия мөселманнарының күңеленә тәшвиш төшерәчәк түгелдер.

Ләкин Русия мөселманнарына ителгән сәясәт моңганчы килгән юлдан барса, аларның сәяси, мәдәни, милли, дини хокукларына игътибар ителмәсә, аларның ихтыяҗларына колак салынмаса, табигый, Русия мөселманнарында үзләренең хокуклы булуларында башка җәберләнгән милләтләр алган юлдан китәчәктер.

## УФА КИҢӘШ МӘҖЛЕСЕ

Гәзитәләрдә язылуына күрә, киңәш мәҗлесендә кузгатылачак мәсьәләләр хакында зуррак шәһәрләрдә мөзакәрә йөргәнлеге мәгълүмдер. Хосусый мәктүбләргә караганда, әһле тәрбия дә, киңәшкә хәзерләнеп, материал хәзерләп яталар. Уфа земствосының гайре руслар арасында мәгариф тарату шөгъбәсенең мөдире Гомәр әфәнде Терегулов җәнабларының да киңәштә кузгатылачак мәсьәләләрнең бик күбесе хакында докладлар хәзерләве язылады[1].

Оренбург земствосының мөселманны агарту хадимнәренең дә докладлар хәзерләү, материаллар туплаулары күптән билгеледер. Киңәш мәҗлесендә рәсми хезмәтче булып хәзер булачак бу затларымызның докладлары, мәгърузатлары, әлбәттә, бик мәгънәле булачактыр.

Хосусән Уфа земствосында гайре русларны агарту эшен өч ел эчендә бик югары дәрәҗәдә күтәргән, ике елда туксан алты кадәр мөселман китапханәсе ачтыра алган Гомәр әфәнденең тәҗрибәдән алган мәгълүматы бик файдалы булачактыр.

Ләкин болар никадәр файдалы булса да, боларда шул хосуста тәҗрибәгә таянылган мәгълүмат күп булса да, алар гына мәсьәләне хәл итәчәк түгелләрдер, бәлки, мәктәп, тәрбия мәсьәләсен киңәш мәҗлесенең алдында ачып куячаклар гынадыр.

Шуның өчен чакырылган затлар һәммәсе дә киңәштә хәл итәчәк мәсьәләләрнең әһәмиятен аңлап, мотлакан, хәзерләнергә тиештер. «Тегеләр эшләр әле, тегеләр хәзерләр әле» дип, буш кул берлән барудан өстә булырга, хосусән гыйлем, тәрбия вә педагогия мөтәхассыйслары, тәҗрибәле мөгаллим, мөгаллимәләр, бу маддә хакында төшенеп, фәнни докладлар хәзерләргә тиештер.

Безнеңчә, киңәш мәҗлесендә хәл ителәчәк мәсьәлә — милли хәятымызның иң зур бер мәсьәләседер.

Хәзерге заманда милли хәят белән тору мәктәп-мәдрәсә тәрбиясенең милли рухта булуына бәйләнгәнлеге исбатка мохтаҗ түгел бер хакыйкатьтер. Мәктәбе, халкының рухы, тәрбиясе, милли даирәсе булмаган, баласы-чагасы милли рухы белән сугарылмаган халыкларның читтән килә торган куәтле мәдәнияттә эреп китүләре дә ап-ачык күренгән эштер.

Шуның өчен безгә, безнең буынга хәзер бик авыр бер бурыч йөкләтеләдер. Ул да, эшләнеп, ислях ителеп килә торган мәктәпләремезне, зурларымызны ачуны-агартуны хәл-әхвальгә муафикъ, замананың теләвенә яраклы итеп куеп, үземезнең киләчәктә бер милләт булып яшәвемез гаясенә ирештерә торган юлга салудыр.

Бу юлда безнең матбугатымыз, җәмәгать хезмәтләремез, хосусән мөгаллим-мөгаллимәләремез, мәктәп-мәдрәсә караучы әрбабе һимматемез бик зур хезмәтләр сарыф иттеләр. Ләкин боларның һәммәсе дә, аерым йирдә аерымча барып, бер юлга куелмаган иде. Төрле шәһәрдә төрле юллардан кителеп, алгы юлга барысы бергә барып чыга алмаган иде. Соңгы елларда программаның төрлелеге, фәүкылгадә көчле булуы һәр йирдә сизелә иде.

Мәктәпләрнең икътисади ягының тәэмин ителмәгән булуы бик күп мөгаллимнәрне сөйгән урыннарыннан читкә китәргә, үзләре тудырган мәктәпләрне ташларга мәҗбүр итә иде.

Хәзер земстволар, үзләренең вазифаларын аңлап, мөселман халкын агарту юлына кергәч тә, мәктәпнең һәм дә халыкны агартуның икътисади ягына нык нигез куелды.

Земстволар халыкны агартуның мәсърафын, хезмәтчеләренең саннарын тәэмин иттеләр. Ләкин земство әрбабы үзе мәктәпләрнең программасы хакында вә шул эшнең ничек эшләнүе хакында тәҗрибәсе, мәгълүматы булмаганга аптырап калды вә шул эштә бергәләп эшләр өчен мөселман халкының игътибарлыларына мөрәҗәгать итте. «Мәктәпләреңезне һәм дә халык агартуны нинди юлдан алып барырга телисез? Фикереңезне аңлатыгыз», — диде. Без хәзер менә шул сөальгә җавап алдында торамыз. Бу сөальне безгә земство әрбабы гына бирми, безгә бу сөальне тормыш үзе куя. Бу сөальнең тугры хәл кылынуына безнең мәктәбемез, безнең кыйраәтханәләремезнең истикъбале баглы. Бу мәсьәләне тугры юлга куя белүемезгә безнең бер милләт булып яшәешемез баглы. Шуның өчен бу мәсьәлә — хәзерге вакытта бөтен иҗтимагый мәсьәләләремезнең иң мөһимедер.

Моннан киләчәк файда санап бетерә алмаслык булган кебек, үземез теләгәнчә хәл итә алмасак, үземез теләгәнчә хәл итәрлек көч күрсәтә алмасак, моннан киләчәк зарар[ны] да үлчәүне кабил түгелдер. Моның тормышымызга итәчәк тәэсире хәзерге бөтен мөәссәсәләремезнең тәэсиреннән зурдыр.

Бу киңәш мәҗлесендә кабул ителәчәк карарлар үземез теләгәнчә чыкса, шул карар тормышка татбикъ ителсә, моның сәмәрәсе идарәи рухания исляхыннан яисә фракция янына көчле бюро ясаудан ун мәртәбә, йөз мәртәбә артык булачактыр.

Чөнки монда милли хәятның нигезе салынадыр. Чөнки монда гасырлар буена китәчәк милли бинаның рухы корыладыр.

Чөнки монда хәзерге гасырда һава кебек, су кебек кирәкле мәгарифнең чишмәсе ачыладыр.

Чөнки монда халкымыз арасында еллардан бирле чуалып агып йөргән әмәлемез, саглям бер сәясәтемез бер юлга куеладыр.

Әһәмиятен аңлап, җитди хәзерләнә алсак, өстемезгә төшкән бурычны үти алган буламыз.

Ваклык күрсәтеп, бар көчемезне җыя алмаенча, кирәгенчә карар ясый алмасак, киләчәк буын алдында җинаять ясаган буламыз.

Вакыт йитте, мәсьәлә әһәмиятле.

## БЛОК ВӘ МӨСЕЛМАННАР

Думаның мәҗлесләрендә ниндәен ляихәләр таралганны, аларның ничек хәл ителүләре хакында мөмкин кадәре гәзитәмездә мәгълүмат бирә килдек. Шул Дума хисапларын укыган затларга Думада зур бер күпчелек тәшкил иткән «тәрәккъкыйпәрвәр блок»[1], исемендә бер оешма барлыгы мәгълүм булса кирәк. Бу «тәрәкъ-кыйпәрвәр блок» Думадагы кадетлардан алып националистларга кадәр сузылган кебек, сәясәт мәйданында таралган алты фракцияне бергә җыя, бер көч итәргә тырыша иде. Шул оешмада һәрвакытта күпчелек булып торганга, «тәрәккъкыйпәрвәр блок» Думада ни эшләргә теләсә — шуны эшли, нинди ляихәне үткәрергә теләсә — шуны үткәрә, нинди законны ясарга каршы килсә — шуңгарга ирек бирми иде. Ул гына да түгел, Думаның сулыннан килгән бөтен ляихәләр, запросларны Думаның минбәрен дә чыгартмый иде.

Гайре рус милләтләрнең хокукларын тигезләү хакындагы трудовикларның ляихәләре, бик озакка кадәр утыз өч имза таба алмаенча, Думага кертелә алмаган иде. (Чөнки трудовиклар, с.-демократлар, мөселманнар үзләре генә утыз өчкә йитә алмыйлар.) Сулларның берничә запрослары да шул хәлдә калган иде. Чөнки «тәрәккъкыйпәрвәр блок» әгъзалары ляихәгә һәм дә запроска үз әгъзаларының имзаларын бирмиләр иде. Уңнар сулларның теләкләренә каршы булганга, әлбәттә, алардан имза көтеп тә булмый иде.

Шуңгарга күрә Думада «тәрәкъкыйпәрвәр блок»ның падишаһлыгы хөкем сөрә иде. Алар теләгән карарлар, алар теләгәнчә маддәләр үтә, алар теләмәгән ляихәгә юл бирелми, алар теләмәгән запрос Дума минбәрен күрми иде.

Думаның фагыйль мохтары булган шул «тәрәкъкыйпәрвәр блок»ның исемендә никадәр «тәрәкъкыйпәрвәр» дигән сүз булса да, үзенең эчендәге бик күп әгъзалары карагруһларга бик якын депутатлар булганга, тәрәкъкыйпәрвәрлекне блокның флагыннан башка да күрү авыр иде.

Шул оешма ясалганда, безнең мөселман фракциясен читтә калдырганнар иде. Мөселман фракциясенең, безнең дә милли, дини ихтыяҗларымыздан иң кирәген генә үзеңезнең программаңызга кертеңез, дигән сүзләренә программага инородец мәсьәләсен кертү — блокны парчалый торган мәсьәләдер. Шуның өчен сезне, үзеңезне дә блокка булган программа даирәсендә генә (ягъни мөселман мәнфәгате хакында бер сүз кертмәенчә) кабул итә аламыз... дигәннәр иде. Һәм дә үзләренең шул сүзләрен Думаның мәҗлесләрендә дә татбикъ кылып киләләр иде.

Ул гына да түгел, мөселманнар белән элгәре бергә йөргән бик күп депутатлар мөселман тавышы белән депутат була алган (хосусән Беренче, Икенче Думаларда) кадетлар да, блокка җинаять итмәс өчен, бөтен гайре русларга, шулар арасында мөселманнарга да, арка биргәннәр иде.

Хосусән кадетларның шулай тәртә борулары, крестьян законы каралганда ап-ачык мәгълүм булды. Кадет Маклаков үзенең ляихәсендә Өченче Думада шул хакта ясалган проекттагы, яһүдләргә бу маддә гам булмасын дигән урынга, гомумән, инородецлар бу хокуктан файдалана алмаслар дип, кыргызлар, казакълар, төрекмәннәрдән мөрәккәб мөселманнарны хокуксыз иттерергә теләве вә караларның ярдәме белән шуны булдыруы үзе йитәрлек дәлил булса кирәк.

Менә хәзер шул «тәрәкъкыйпәрвәр блок» Думада тын алырга ирек бирмәгәнгәме, аның белән суллар һәм уңнар арасында тартышу башланды.

Бу ике бүлекнең, әлбәттә, алган юллары, блокның яратмауларының сәбәпләре аеры-аеры. Суллар, блок халык файдасын аз күрсәтә, тугры бармый, диләр. Уңнар, блок, астыртын иттереп барып, Русиядә парламент ысулын кертергә тели, диләр. Ләкин икесе дә блоктан разый түгел.

Менә крестьян законы каралганда, трудовиклар блокка каршы бик каты сугыш ачтылар. Блокны йиңә алмасалар да, үзләренең сүзләрен үткәрә алмасалар да, блокның бик күп гизле серләрен ачтылар.

Трудовиклар, үзләре генә Думада мөстәкыйль фракция булганда, һичбер төрле кабул итми калу ихтималы булмаган поправкалар керттеләр. (Шулар арасыннан берсе — бөтен гайре русларның, мөселманнарның да хокукын тигезләү.) Кадетлар, блок эчендә булганга, шул поправкаларның зарарына тавыш бирделәр. Берничә карт кадетлар, рәнҗешеп, мәҗлестән чыктылар.

Ул да ярар иде, крестьяннарны оҗмахка кертәмез, дип башлаган Маклаковның ляихәсенә Думадагы крестьяннар группасы «Думага сайлау вакытларында крестьяннарның хокукларын кыса торган сайлау законының 62 нче маддәсе бетерелсен» дигән төзәтүне керттеләр.

Блок аптырады. Маклаковның хәле начарланды. Блокның депутатлары бик матур сүзләр белән крестьяннарны шул хокукларын сорамаска димләделәр. Маклаков үзе барысыннан да күп тырышты. Тавышка куелса, бәлки, шул крестьяннарның теләве дә өстәл астына киткән булыр иде. Ләкин крестьяннар исемле тавыш бирүне сорадылар вә шуны Думадан кабул иттерделәр. Шуннан соң октябристлар, үзләренең партияләренең исеме чыкмасын өчен, крестьяннарга дошман дигән хәбәр таралмасын өчен, 62 нче маддәне үзгәртүне кабул иттеләр. Блок эченнән чатнады.

Соңгы мәҗлесләрнең берсендә кадет князь Мансуров (чукынган татарлардан): «10 июньдә Дума тарала дип хәбәр чыкты. Шуның өчен Дума немес йирләрен алу хакындагы ляихәне карый алмаенча калса, мәсьүлият хөкүмәткә төшә», — диде.

Шуны гына көтеп торган кебек, уңнар тоттылар да, блок тарафыннан кабул ителгән эш программасын бозар өчен, икенче көннәрдә земстволар сайлавындагы реформаны карау урынына немес йирләрен алу хакындагы ляихәгә, каралса иде, дигән теләү керттеләр.

Мәҗлес кич булганга, уңнар берлән суллар бергә тавыш биргәнгә һәм дә блок эченнән берничә октябрист шул якта булганга, уңнарның теләүләре кабул ителде.

Блок аптырауда калды. Шул карарны үзгәртер өчен, 16 июнь мәҗлесендә тагы төрле юллар берлән мәсьәләне тавышка куйды. Ләкин бунысында блокка кергән прогрессистлар барысы да октябристларның бәгъзесе белән тагы блокка каршы тавыш бирелде.

Блок элгәреге берлеген югалтты. Шуның аркасында элгәреге көчен — фагыйль мохтарлыгын бетерде.

Хәзер менә мәсьәлә шулай. Без мөселманнарга бу блокның файдалы булу ихтималы бик азга, Думадагы шул көчле оешманың йимерелүен үземезгә файдалы эш дип каршы аламыз һәм дә блок эченә кергән сул фракцияләр үзләренең иткән хаталарын аңлап, октябристлар, националистларга иярчәнлек итүдән кайтып, Русия халкын тигез хокуклы ясау астында чын тәрәкъкыйпәрвәр блок ясалыр дип көтеп каламыз.

## АУРУПА КАРАШЫНДА ИСЛАМ ДӨНЬЯСЫ

Гасырымызда тормышның иң зур тамыры — хәят тартышы булганга, дөньяда ике зур мәдәниятнең төрле төстә бәрелешүе табигыйдер. Бу мәдәниятнең берсе — иске ислам мәдәнияте, икенчесе — яңгы Аурупа мәдәниятедер.

Боларның әүвәлгесе үзенең бәкасен саклар өчен тырыша- тартышадыр. Икенчесе, ягъни Аурупа мәдәнияте, иске мәдәниятне үзенең кул астына алырга тырыша-тырмашадыр. Тормыш тартышу булганга, әлбәттә, монда искиткеч бернәрсә юктыр. Тартышуның әсасы «замана — көчленеке» дигән кагыйдәгә бина ителгәнгә, боларның бер йирдә берсенең, бер йирдә икенчесенең җиңү-җиңелүендә гаепләү була торган эш түгелдер.

Тартышуның кан тамыры капйотлык булганга, җиңгән мәдәнияткә әхлаксызлык вә вөҗдансызлык дип каршы тору — көлке генә була торган эштер. Ләкин тартышуның үзенең дә махсус кагыйдәләре, әдәпләре бардыр. Сабан туендагы көрәшү, Испаниядә үгез сугыштыру, Бохараи шәрифтә бытбылдык талаштыру да, Англиядә ат узыштыру да махсус кагыйдәләр, әдәпләр берлән тәртипләнгәндер.

Шуның өчен иске ислам мәдәнияте белән яңгы Аурупа мәдәнияте тартышканда да әхлакый гонсыр эшкә алынмаса да, мәгълүм әдәп даирәсендә эш йөртелсә, һәр ике тараф бер-беренә «минем берлән тартышучы» дип ихтирам белән караса, күңеллерәк, морадчарак булыр иде.

Мәгаттәәссеф, ислам дөньясына каршы Аурупаның бер халкы да шуны эшли алмады һәм дә хәзер дә, сугыш вакытында, ислам дөньясы, ике тарафка бүленеп, күп вакытта үзенең мәнфәгатенә каршы килеп, аурупалылар берлән бер сафта булып сугышса да, кан түгелсә дә, ноктаи нәзар үзгәрмәде, үзгәрми.

Французларның Африкадан китергән кара гарәп мөселман гаскәре немесләргә каршы бик зур баһадирлыклар күрсәткәч, французларның утыз-кырык миллионлы Африкадагы мөселман колонияләрен шул хезмәтләре өчен нинди бүләк бирүләре хәтереңездәдер. Французлар –дөньяның хөррияте өчен бик күп кан түккән, хәзерге сугышны да «кечкенә милләтләрнең хөррияте өчен ителәчәк мохәрәбә» дип атаган французлар, әл-Җәзаир, Тунис, Фаста, хәзерге хәрби идарәләрен үзгәртеп, шул халыкларның мәдәни яшәүләренә имкян тудырырлык мәдәни мөәссәсият ясарга тиеш түгел идеме? Мәктәп-мәдрәсә, гимназия, дарелфөнүн тәәссис итеп, матбугатларына, җәмгыятьләренә хөррият биреп, мөселманнарның хезмәтләрен иң яхшы тәкъдир итү тиеш иде түгелме?

Ләкин француз милләте, француз хөкүмәте меңәр, бәлки, йөз меңәр түгелгән мөселман гарәп гаскәренең фидаилыгы бәрабәренә аларга Мәккә шәһәрендә мәсҗед бина итәргә, әллә кайда ханәкә ачарга фәрман чыгарды.

Зур сугышның бик күп мәйданнарына җәелгән әллә ничә йөз мең һинд мөселманы гаскәренә — үзләренең диндәшләре төрекләр белән Дарданеллда, Багдад, Мисырда сугыша торган немесләрне үзләренең баһадирлыклары белән исләрен китерә торган һинд мөселман гаскәренә каршы инглиз милләте нинди мөгамәләдә булынды?

Әйе, аларга үзләренең намазларын укырга уңгайлык ясады. Аларга үзләре теләгәнчә ашарга ихтыяр бирде. Аларга үзләренең зәбихәләрен истигъмаль өчен аерым казан тәгаен ителде. Ләкин Ирландия фетнәсеннән соң, инглиз әрбабе хөкүмәте алдында Англия колонияләренең идарәләрен үзгәртү лөзүмлеге тасдыйк ителгәч вә шул яңгы идарәне төзер өчен бөтен колониядән вәкилләр чакырырга карар бирелгәндә, алтмыш-җитмеш миллион мөселманлы инглизләрнең Африка колониясе һәм дә йөз миллион мөселманлы Һиндстан колониясе онытылыпмы калдырылды — алардан вәкил чакырылмады. Аларның хәлләре бик шәп саналдымы — аларның идарәләре ислях кизүенә куелмады. Алар инглиз милләте алдында башка колонияләре белән бер хокукта итеп тәгаен ителмәде.

Аларга үз зәбихәләрен ашарга имкян бирелде. Аларга намазларын укырга камыш намазлыклар өләшелде, аларга, үзләре теләгәнчә, бисмилла дип пешерергә махсус казан асылды. Ләкин хокук киңәйтү, мәдәни мөәссәсәләргә хөррият бирү хакында алар читтә калдырылды.

Безнең парламент әгъзаларымыз, иттифакчы дәүләтләрдә сәясәттә йөреп, әрбабе дәүләт белән күрештеләр, сөйләштеләр. Нинди исляхат лөзүмлеге хакында бер-берсе белән фикер алыштылар.

Бик күп җыеп кайткан гакыллар арасында бу затлар гайре руслар хакында да рус милләтенә «аманәт»ләр алып кайтканнар. Берсенә «Русиядә яһүдләргә мөсавәт бирелсен, югыйсә без Русиягә бурычка да бирмәмез» дигәннәр, берсенә «әрмәннәргә Әрманстан ясап бирү өчен тырышылсын», берсенә «Ләһстанның мөстәкыйль идарәле булуына иҗтиһад ителсен» дигәннәр.

Шуларның һәммәсендә дошманны җиңгән өчен лязем-фарыз табуларын сөйләгәннәр, ләкин анда да безнең хакта — Русиядәге утыз миллион мөселман хакында — сугыш сафындагы Идел буе мөселманы

гаскәре генә дә төрек солтанының төрек гаскәреннән сан җәһәтеннән артык Идел буе мөселманы хакында бер сүз дә әйтмәгәннәр. Бөтен сугышучы, иттифакчы дәүләтләрнең гаскәрендәге саннары Бәләбәй өязеннән чыккан мөселман гаскәре кадәре була алмаган яһүдләр хакында бик каты сүзләр колакка тукыганнар.

Рус гаскәрендәге саннары Оренбург Каргалысыннан чыккан мөселман солдаты кадәре була алмаган әрмәннәр хакында әллә никадәр хокуклар алып бирүне үтенгәннәр, сораганнар, кушканнар.

Безнең хакта алар да бер сүз әйтмәгән, болары да безнең мәдәни, милли хокукымызның булуы хакында уйлап та карамаган.

Безгә ни кирәк булсын?

Безгә ник кирәк булсын?

Без бит мөселман!

Ул гына түгел әле, менә Голландия мөселманнары — Җавадагы мөселманнар үзара, имеш, җыелганнар да Төркиянең шәйхелисламын халегъ иткәннәр. Үзләренә генә түгел, бөтен мөселман дөньясына ярарлык шәйхелислам сайларга булганнар. Ләкин үзләре шундый кешене белә алмаганга, Амстердамга мөрәҗәгать итеп, шунда колбаса эшләүче, дуңгыз ите тозлаучы немесләргә мөрәҗәгать итеп: «Безгә кем шәйхелислам булырга муафикъ булыр икән?» — дип сораганнар.

Бу хәбәр, әлбәттә, имеш. Хәтта имеш тә түгел, бу хәбәр — чи ялган. Ләкин шул чи ялган хәбәрләр гәзитәләрдә язылалар, укылалар, мөзакәрә ителәләр.

«Болай булмас ла, папаны тәгаен ит!» дип, «Иран шаһына бервакытта да католиклар мөрәҗәгать иткәннәре юк» дип беркемнең дә башына керми. Берсе дә уйламый, төшенми!

Ник?

Чөнки болар мөселманнар.

Чөнки мөселманнарга һәртөрле ахмаклыкларны кылу да мәгафу!

Чөнки мөселманнар — гражданский мәгънәдә сабыйлар.

Чөнки мөселманнар — дөнья кешеләре түгел, ахирәт кошлары.

Шуның өчен аларга аерым казан булса, аерым зәбех, мең мәсҗед урынына тагы мең дә беренче мәсҗед салынса, буш йөргәннәргә ханәкәләр арттырылса, аларга җитә. Алар шуның белән канәгатьләнәләр.

Чөнки алар шуның белән ахирәткә якынлашалар. Чөнки алар шуның берлән фани дөньядан ерагаялар.

Чөнки алар мөселманнар...

Чөнки алар оҗмах кошлары...

Аурупада ислам галәменә каршы ителгән бөтен мөсаһәләләрнең төбе шул әхваль рухына!

Бөтен дөньядагы мөселман хокукына каршы ителгән инсаниятсезчә мөгамәләнең сәбәбе — шул караш...

Бөтен мөселман дөньясының иң зур дошманы да, эчтән ашый торган микробы да — шул аңлашылмау...

Шуның өчен бөтен мөселман дөньясына гасырымызның йөкләткән вазифасы да, киләчәк ислам галәме алдындагы бурычны да — безнең дә йир угыллары, дөнья балалары икәнлегемезне исбат итү, сүз белән түгел, уй белән, эш белән исбат итү.

## КИҢӘШ МӘҖЛЕСЕ

Кирәк, хосусый мәктүбләр, кирәк, мөхбирләрнең язуына, гәзитәләрнең хәбәрләренә караганда, Идел буе мөселманнарының күп даирәләре Уфадагы киңәш мәҗлесенә хәзерләнеп ятуы белдереләдер. Шул мәсьәлә буенча Самар губернский земствосында киңәш булган. Уфа киңәшенә кушылырга вә мөселманнарның агаруына әһәмият бирергә карар кабул ителгән.

Мөхбиремезнең язуына күрә, Саратау вилаять земствосы да, йирле зыялы мөселманнарны җыеп, шул хакта берничә киңәш мәҗлесләре ясаган вә мөселманнарны агарту хакында безнең өчен күңелле карарлар кабул иткән.

Казан, Оренбург, Уфаның шул эшенә бик зур гайрәт белән иҗтиһад итүе күптән мәгълүм. Соңгы «Тәрҗеман»ның язуына күрә, Кырым да шул киңәшкә кушылу хакында эшкә керешкән.

Димәк, бөтен Русия мөселманнары үзләренең Русиянең чын гражданы икәнлекләрен һәр йирдә бертигез хис итә башлаганнар. Һәр йирдә шул гражданлык вазифасын тәмамы белән тотар өчен уку-укыту эшенә күршеләре рус милләте белән бергә барырга тиешлекне аңлаганнар.

Моңганчыга кадәр земстволардан куркып, моңганчыга кадәр земстволарның мөселман мәктәп-мәдрәсәләренә иткән ярдәмнәреннән чиркәнеп йөргән мөселманнар земствоның үзләренеке икәнен төшенеп йиткәннәр. Димәк, мөселманнар белән йирле земстволар даирәсендә аңлашу башланган. Рус

зыялысы үзенең эшлекле күрше татар халкын агартуны үз бурычы икәнен аңлаган. Йирле мөселманнарның зыялылары земство даирәләре белән мәгариф эшен бергә алып баруда милләтнең истикъбале икәнен сизенгән.

Бу шатлыклы факт — безнең алга китүемез өчен тугры адым булачагы кебек, Русиянең таза дәүләт булып ныгуы өчен дә бик зур хезмәт итәчәк эштер.

Шуның өчен без төрле земстволарның, соңга калып булса да, үзләренең бурычы мөселманнарны агартуда икәненә килеп йитүләрен бик шатланып каршы аламыз вә булачак Уфа киңәшмәсеннән ике арада аңлашмаулар тәмамән бетәрлек булсын иде дип көтеп каламыз.

Ул гына түгел, тарихлары, язмышлары белән бергә барырга бәйләнгән Русиянең шул зур ике гонсыры — Русиянең руслары берлән Русиянең мөселманнары арасында танышу-аңлашу беренче баскычында гына калмаса иде.

Шул земстволар тарафыннан мөселманнарның агаруга хаклары бар икәнлеге тасдыйк ителгән кебек, Русиянең зуррак даирәләрендә дә безнең милли, мәдәни хәрәкәтемезнең законлы бер хәрәкәт икәне тасдыйк ителсә икән. Безнең халкымызны укытырга, агартырга, баетырга тырышкан, иҗтиһад иткән милли даирәләремезнең каһарманча хезмәтләре Русия дәүләте өчен кирәкмәс, Русия хөкүмәте яратмый торган бер эш кебек иттереп каралу бетерелсә икән, без, Русия мөселманнары, хәзер үземезнең милли, дини мәнфәгатьләремезне аңлау өстенә, үземезнең алдагы бурычны да тәмамы берлән түләр дәрәҗәгә җиткәнемез — исбатка мохтаҗ түгел бер хакыйкатьтер.

Без хәзер Ватанның балигъ угланнарымыз инде. Милләт хакимиятемез дә безгә карап килгән иске карашларын алыштырса, безне үлчи торган иске аршыннарын үзгәртсә, Ватан өчен дә, дәүләт өчен дә, инсаният өчен дә иң тугры адымны атлаган булачактыр.

Иншалла, шул тугры адымны атлар.

## ЛАШМАН ХЕЗМӘТЕ

Бу номер гәзитәмездә моңганчы солдат хезмәтенә алынудан мәгаф булып килгән инородецларны лашман хезмәтенә җыю хакында патша хәзрәтнең фәрманы галисе басыладыр. Бу фәрман буенча, Сибириянең күчмә халыклары, кыргызларның бөтенләе, Төркестанның (Хива ханлыгы, Бохара әмирлегенә башка) сарт, таҗик, төрекмән вә башка бөтен әһлиясе, Кавказ мөселманнары — һәммәсенең сугыш кирәк-ярагы өчен кырык өч яшенә кадәр дәүләт хезмәтенә алыначаклары игълан ителәдер.

Бу халык Русиядә шактый күп миллионнарга тулганга, әлбәттә, боларны җыю берьюлы гына булмас. Ләкин бу яңгы төрле дәүләт хезмәтенең иң зур йөге безнең мөселман халкына төшкәнгә, әлбәттә, иң зур дикъкать белән бу мәсьәләне без тәгъкыйб итәргә мәҗбүрмез.

Бөек Петр заманыннан бирле Идел буе мөселманнарының күбесе, гаскәргә алынмаенча, лашманга алыналар иде, ягъни алар дәүләт өчен кирәкле хезмәтләрне эшләргә мәҗбүри җыелалар иде. Көймәләр ясар өчен алардан урманнар кистерәләр, алардан сал агыздыралар. Алардан көймәләргә төялгән гаскәр йөген, бурлак иттереп, су буйлап тарттыралар иде. Ләкин Русиядә бөтен халык өчен солдат хезмәте гам иттерелгәч, Идел буе мөселманнары, руслар вә башка халыклар белән бергә, алай (полк) хезмәтенә кертелгәннәр иде.

Кыргызлар, Төркестан мөселманнары, Кавказ мөселманнарының иң зурысы Русиягә кушылганда, махсус могаһәдәләр белән кушылганга, алар шул мокавәләләр буенча гаскәрлектән мәгаф иделәр. Бу күп халыкның мөселман мәмләкәтләре чигендә яшәүләре аркасында гаскәрлеккә алынып өйрәтелүләре дә дәүләт ноктаи нәзарыннан шөбһәле эш иттереп уйланылган иде. Хәзер менә инде сугыш озаеп киткәч, шул халыкларны лашман хезмәтенә алып, гаскәремезнең юлын җиңеләйтү лязем табылды, күрәсең.

Лашман хезмәтенә ничек алу хакында әле кагыйдәләр, кануннар, правилалар игълан ителмәгән. Шуның өчен ничек алулары, җыелган халыкны ничек эшкә йибәрүләре, ничек сайлаулар хакында бернәрсә дә мәгълүм түгел. Ничек кенә булса да, моңганчыга кадәр казармаларда түгел, өйдә торырга да өйрәнмәгән кыргызлар өчен, үзләренең Төркестаннарыннан башка дөнья юк дип белгән сартлар өчен бик авыр булачагы табигыйдер.

Кирәк, кыргыз даласы, кирәк, Төркестанның идарәсе бик иске ысулда булганга, мондагы йирле халыкның үзенең зарын, аһын аңлата торган һичбер төрле вәсиләсе булмаганга, бу халыкны лашманга җыю да, алу да, хезмәткә йибәрү дә дәүләт өчен кирәксез, халык өчен зарарлы юлларга кертелмәве, әлбәттә, бик матлубтыр.

Лашман хезмәтен башкару эше әле нинди кулларга биреләчәге мәгълүм түгел. Ләкин хөкүмәт өчен яңгы бер эш булганга, йирле түрәләр өчен моңганчы эшләнеп, тәҗрибә күрелмәгән бер хәрәкәт булганга,

йирле халык өчен башына да килмәгән бер яңгылык булганга, шул фәрманны фәгалиятькә чыгаруда йирле мәнфәгать тә күздән ерак тотылмаска тиеш иде.

Бу ике өлкәдә нә земство, нә шәһәр идарәләре, нә башкача өлкәләр идарәләренә халык катыштырылмаганга, бу эш тә түрәләр кулына гына тапшырылуы ихтималы бик якындыр. Йирле түрәләр күп вакытта халыкның үзеннән бик ерак торганга, халыкның гадәтен, телен белмәгәнгә, аларга гына ышанып эш итү, аларның белеме белән генә хәрәкәт итү йирле халыкның бөтен тормышы фәүкылгадә зарарлы булуы ихтималы юк түгелдер.

Йирле халыкның шул дәүләт хезмәтен «казаи илаһи» дип аңлау ихтималы бик якындыр. Шундый күңелсез эшләр килеп чыкмасын өчен, кыргыз, Төркестан, Кавказ мөселманнарына иң якын торган мөселман фракциясе һәм дә сугыштан зарарланганнарга хезмәт итәр өчен ачылган Мәүкыйть мөселман комитеты шул мәсьәләдә хезмәткә катыштырылса иде вә, шул ике мәркәземездән фикер-киңәш алынып, эшкә тотынылса иде.

Ләкин безнең түрәләр даирәсе безгә киңәш итеп килергә өйрәнмәгәнгә, бу мәсьәләдә дә чакыруны көтмәенчә, мөселман фракциясе белән комитеты бергә җыелып, мәгълүм бер карар чыгарып, үзләре хөкүмәткә мөрәҗәгать итсә яхшырак булыр иде.

Шуның өчен бу ике даирәмез шундый зур мәсьүлиятле вакытында, кирәк, дәүләт өчен, кирәк, күп миллионлы мөселманнарның рәфаһе хәле өчен катгый бер хәрәкәт ясап, мәгълүм план коруы ляземдер вә шул лашман хезмәтен тәртипкә салышканда, үз тарафыннан планнар кирәк булса, кешеләр күрсәтеп, хөкүмәткә кул сузарга тиештер.

Фракциямез, Вакытлы комитетымыз үзенең мәгълүматы, тәҗрибәсе белән берсен-берсе белми торган мөселман халкы белән түрәләр арасында васитачылык, тәрҗеманлык итмәсә, итә алмаса, ике тараф өчен дә кирәкмәгән мәшәкатьләр тууы табигый эштер.

Без фракция әгъзаларының Петроградтагылары белән Мәүкыйть комитет әгъзаларының тиздән җыелышып, лөзүме булса, мәгълүматтан файдаланырлык кешеләр чакырып, кыска гына киңәш ясавын һәм дә шул эшне җиңеләйтүдә тәшәббескә керешүен хәзерге көннең фарызы,ваҗибы дип табамыз вә шул хезмәтне көтеп каламыз.

## РАМАЗАН ШӘРИФ ГАЕТЕ

Инде өченче Рамазан гаетен дөньяның иң мәгъмүр мәмләкәтләре өстенә ут, тимер яуган вакытта үткәрәмез.

Инде өченче Рамазан бәйрәмен Ватанымызның бөтен халкы өстендә сугыш казасы, бәласе уйнаган вакытында кичерәмез.

Инде өченче Рамазан гаете Русиянең утыз миллионлы мөселман халкының өендә, йортында, илендә сугыш кайгысы, хәсрәте белән аһ-фәган белән янган көннәрендә каршы аламыз.

Инде өченче гаете Рамазанны бөтен ислам дөньясыннан өзелеп бетеп, ислам дөньясының хәл-әхваленнән хәбәрсез көенчә бәйрәм итәмез.

Инде өченче гаете Рамазанны бөтен ислам дөньясы өмид берлә, кайгыдан мөрәккәб бер хис белән каршы ала.

Инде ислам дөньясы — йир өстенең бөтен тарафына таралган ислам дөньясы, киләчәк гаете мөбарәкне тыныч кына фәраванлыкта күрсәк иде дип, дога белән каршы ала.

Ләкин Аурупа өстендә чыккан ут уены һаман басылмый, Аурупаның уртасында кабарган янгын һаман киңәйгәннән-киңәя бара.

Ул берсе артлы берсе ислам илләренә чаткыларын чәчә, ялкыннарын тарата бара.

Русия-Австрия сугышы[1] башлангач та, ике мәмләкәтнең дә мөселман гаскәрләре ватаннарын саклау байрагы астында бер-беренә һөҗүм иттеләр. Идел буе мөселманы Босна, Һәрсак мөселманына хәмлә итте[2]. Икесе дә күңелендәге иманына таянып, икесе дә бер булган кәгъбәсенә йөзен юнәлдереп, икесе дә «Алла!» дип кан-җан сугышына ашкынды.

Төркия нимесләр тарафыннан сугышка катышкач, ислам дөньясы тагы парча-парчага килде.

Төркия чигендә Идел буе мөселманы, Кавказ төреге үзенең мөселман кардәшенә каршы кылыч күтәрде[3].

Һинд, Бәлүҗестан мөселманы[4], алай-болай булып, Төркиянең мәкаме хәлифәтен инглизләр, французларга алып бирер өчен, Дарданелл сахилләрендә утка керде. Төрек гаскәре белән баһадирлыкта, батырлыкта ярышып, Айя-Суфия җәмигысының башына күтәреләчәк тәрене асар өчен[5] кан түкте, җан бирде.

Африканың гарәп мөселман гаскәре Мисырга таба кул сузарга, ике мөселман мәмләкәтен бергә кушарга тырышкан төрек гаскәренә каршы чыкты. Мисыр да, бөтен Африкадагы инглиз, француз идарәсен саклар өчен, ул үзенең мөселман кардәшенә ук атты, кылыч чапты[6].

Иранның төрле кабиләләре, Иранның төрле фикер иярченнәре әле руслар, инглизләр ягына чыгып, әле төрекләр арасына кушылып, бер-берсе белән кырылышты, сугышты[7]. Бер-берсенең илен-йортын йимерде, канын түкте.

Бөтен ислам дөньясы, шул ике сугыша торган дәүләтләр арасында кысылып, әле ул тарафтан, әле бу тарафтан кыйналды, кысылды, изелде.

Шул ике ел дәвам иткән сугышта әллә никадәр җан, мал корбан итте, әллә никадәр гайрәт, көч сарыф итте.

Ләкин шул ике ел эчендә ислам галәменең артыннан-тарихыннан ияреп килгән бер генә кайгысы да кимемәде. Шул ике ел эчендә ислам галәменең үзен саклар өчен атларга теләгән бер генә адымына да мәйдан ачылмады.

Шул ике еллык түгелгән каннар бәрабәренә ислам галәме үзенең мең өмиденнән берсенең генә дә якынайганын күрә алмады.

Шул ике ел эчендә ислам галәме үзенең иксез-чиксез иткән корбаннарының миллионнан берсенең генә дә кабул булачак өмиден тудыра алмады.

Чөнки ислам галәме, бик аз бер истисна берлә, үзенең гаясын, үзенең идеалын аңламаенча, мәйдане мөбарәзәгә катышты.

Чөнки ислам галәме үзенең максатын булдырыр өчен, үзенең теләген тудырыр өчен тартышуга керешмәде.

Чөнки ислам галәме ике тарафтан да чакырылган өмәгә килде. Икенчеләренең дөньядан көткән максатларын-гаяләрен тутырышыр өчен сугышка катышты.

Менә инде сугыш эчендә өченче Рамазан гаетен үткәрәмез. Шул өч гает арасында сугыш дөньясында фәүкылгадә үзгәрешләр булды, мәмләкәтләр йир өстеннән себерелде, бәгъзе милләтләрнең исемнәре генә калды. Шәһәрләр, авыллар йир белән иксан ителде. Дөнья кан исенә исерде. Шул исереклектә бөтен дөньяның ерткычлары сугышкан вә сугышмаган халыкларның канын эчәргә керештеләр. Бөтен дөньяның гакыллы башлары киләчәктәге дөньяның торышын-йөрешен рәтләргә планнар корырга керештеләр.

Сугышмый торган мәмләкәтләр бер-берсе белән могаһәдә ясаштылар. Киләчәктә дөньяда тору хакында киңәшләр ясашты, карар беркеттеләр. Сугышучыларга сыгынган кечкенә милләтләр үзләренең милли теләкләрен булдырыр өчен оештылар, берләштеләр, берсенә мохтарият кирәк икән, берсенә истикъляль кирәк икән, берсенә өлкәсен зурайтырга кирәк икән, берсенә күршесен бетерергә лязем икән!

Барысы да «Минем мәнфәгатем шул!» дип мәйданга чыкты, чыгарга тора.

Сугыша торган зур милләтләр арып мосаләхәгә утыргач, бу халыклар, үзләренең планнарын, уйларын күтәреп, солых өстәленә барырга хәзерләнәләр һәм баралар.

Арыган, көчсезләнгән зур дәүләтләрнең зәгыйфьлегеннән файдаланып, аны-моны алырга, тартырга, суырырга торалар. Ләкин ислам галәме нишләде?

Дүрт йөз миллионлы ислам галәме нишләде, нишли? Нинди теләкләр хәзерләде, нинди планнар кора?

Ул читләрнең боерыгы белән сугышка катнаштырылган ислам галәме үз ихтыяры белә солыхка катнашырга торамы, үзенең каны белән сугышның бик күп битләрен язган ислам галәме солых мәҗлесендә дә каләм белән, кара белән үзе хакында бер генә сүз язарга хәзер торамы?

Безгә каршы сугыша торган төрекләрне истисна иткәндә:

— Юк!

— Ник?

Чөнки солыхны оешылган көчләр ясаячаклар. Чөнки солыхка оешкан милләтләр үзләренең тарихи юлларында [*бер сүз бозылган*] милләтләр генә мөшарәкәт итәчәкләр.

Чөнки солыхтан үзләренең «үзлекләрен» белгән, үзләренең үзлекләренә таба омтыла алган милләтләр генә файда чыгарачаклар. Алар гына сугышның гамилләре булган кебек, солыхның нәтиҗәләреннән алар гына файдаланачаклар.

Өмәчеләргә өмә өйрәсе генә биреләчәктер!

Хәзер инде сугыш башланганнан бирле ислам дөньясы өченче Рамазан гаетен үткәрә[8].

Сугыш башланганнан бирле өченче елны ислам дөньясы үзенең мәнфәгатенә йобанчы булып тора, хәзер инде дөньяның рәззакы өләшенгән көннәрдә ислам дөньясы яисә авызын күтәреп тик тора, яисә әле бер тарафка өмәгә йөри.

Ике еллык канлы мөхәрәбәләр ике еллык коточкыч вакыйгалар ислам дөньясын тирән йокысыннан уятмады.

Инде өченче елгы мохәрәбәләр, өченче елгы вакыйгалар ислам дөньясының күзен ачсын иде.

Инде дүртенче гаетне укыганда[9], ислам дөньясы балигъ-мөкәлләф булып, гает намазына хәзер булсын иде.

## СУГЫШ ХЕЗМӘТЕ КҮПМЕГӘ ТӨШӘ?

Ике ел инде сугыш дәвам итә. Бу ике ел эчендә адәм баласының түккән каны, күз яшенең исәбе-хисабы юк. Аны үлчәп тә бетерер хәл юк. Ватылган шәһәрләр, яндырылган авыллар, җимерелгән юлларның микъдары да әле бер Аллага гына мәгълүм. Бөтен вату-сынуның, үлү-үтерүнең чамасын алыр өчен бик күп хезмәт җентекләү кирәк булганга, әлбәттә, хәзер катгый бер цифр бирергә мөмкин түгелдер. Ләкин сугышка тотылган чыгымнарны тәхминән билгеләргә имкян бардыр. Хөкүмәтләрнең күпме тотканнары, ничек тотканнары, төрле дәүләтләрнең күпме бурыч алулары, әлбәттә, яшерен түгелдер.

Шул хисапларга караганда, сугыш өчен тотылган акча расходы түбәндәгечә тәхмин ителәдер.

Англиянең әүвәлге көннәрдә һәр көнлек чыгыш унике миллион сум булган, 16 нчы елның башыннан бирле инглизләрнең көндәлек чыгышлары илле биш миллион сумдыр.

Русия әүвәлге айларда көндәлек расходы сигез миллион сум булган, хәзерге көннәрдәге чыгышы тәүлегенә 38 миллион сумдыр.

Французларның да расходлары, әлбәттә, көннән-көн артадыр. Гомумән, хәзергә кадәр инглизләрнең тоткан сугыш расходлары 23 миллиард сумнан ким түгелдер. Русиянең — 19 миллиард, Франциянең — 18 миллиард, калган иттифакчыларымыз Сербия, Белгия вә Японияләрнең 2 миллиард чамасыдыр. Безнең иттифакчыларның ике елда тоткан бөтен расходы 66 миллиард сумнан аз түгелдер.

Безнең дошманнарыбызның чыгышларына килсәк, анда мәнзарә бераз үзгәрә төшәдер. Германия, Австрия, Төркия, чит мәмләкәтләрдән корал кирәк-ярак сатып ала алмаганга, бөтен кирәк-яракны үзләреннән чыгарырга мәҗбүрләрдер. Шуның өчен, бер яктан, корал, кирәк-ярак табуда алар кысынкылык сизенсәләр дә, акчалары үз базарлары эчендә калырга мәҗбүр булганга, бердән, акча читкә күпләп акмыйдыр, икенчедән, чыгышлары азрак булып барадыр.

Бу көнгә кадәр Германиянең ике елда иткән чыгышы 23 миллиард сумдыр.

Австриянең иткән расходы — 12 миллиард, Төркия, Болгариянең ике миллиард сум булып, мәҗмугсы 37 миллиард сум гынадыр. Ягъни безнең иттифакчыларымызның расходына караганда бермә-бер дәрәҗәсендә аздыр.

Бу азлыкның сәбәпләре, әлбәттә, бик күптер. Моның берсе — бу мәмләкәтләрнең элгәредән сугышчы дәүләт булып, алдан хәзерлек күрүләрендәдер, икенчедән, бу мәмләкәтләрнең, халыкларының икътисадка ригая итүчән булуларында, бик үк кадерләтергә яратмауларындадыр. Һәм дә сан ягыннан да гаскәрләрнең азлыгындадыр.

Бу сугыш әле беткәне юкка, әлбәттә, расходларның артуы табигыйдер.

Бүгенге көнгә кадәр ике тарафның түккән суммасы йөз миллиард сумнан ким түгелдер. Бу йөз миллиард сумның күпмелеген белер өчен, башка цифрлар берлән чагыштыру ляземдер. Мәсәлән, бөтен җир йөзенең өстендә тимер юлларның бәһасе йөз миллион сумлыкка җитмидер.

Мәсәлән, сугышка кадәр сугышчы дәүләтләрнең бөтен бурычы, бөтен гомере буена ясаган бурычы 58 миллиард сум гына иде.

Сугышка кадәр шул сугышучы мәмләкәтләрнең барысының бергә һәр елны итә торган мәмләкәт расходы 16 миллиард сум гына иде.

Бу йөз миллиард сумны алтынга әйләндерсәк, мәнзарә тагы коточкычланадыр. Түгелгән алтынның пот хисабы гына да биш миллион потка җитәдер (кәгазь акча төшмәгән иттереп хисап йөртелде). Шуны төяр өчен вагонга салганда, һәрбер вагонга меңәр пот тутырганда да, биш мең вагон лязем буладыр.

Җан, кан хисабы, әлбәттә, әле мәгълүм түгел. Ләкин, хисапларга караганда, ике тарафта сугышчыларның саны кырык миллион кешедән ким түгелдер. Боларның аз гына дигәндә дә егерме миллионы йә яраланып, йә үлеп сугыштан зарар күргәндер. Шуларның дүрттән бересе, ягъни биш миллионы үлгәндер. Калган 15 миллионның яртысы, үзенең кулын, аягын, әгъзасын ватып, эшкә ярамаслык дәрәҗәгә килгәндер, калган сигез миллионы эш эшли алу куәтен яртылыга киметкәндер. Боларның иткән зарарларын акчага бору, әлбәттә, мөмкин түгел.

Моңгарга башка, сугыш вакытында беткән мал-туарның исәбен-хисабын һич белеп булмыйдыр. Әллә никадәр миллион хайван суелып, үлеп, һәлак булып беткәндер.

Менә сугыштан ителгән адәм баласы зарары әлегә генә шулкадәр. Киләсе елда никадәр булачагын Алла үзе генә белә[1].

## * * *(ЛАШМАН ХЕЗМӘТЕ ХАКЫНДАГЫ ФӘРМАН...)

Лашман хезмәте хакындагы фәрманның мөселманнар өчен күңелсез вакыйгалар, хөкүмәт өчен кирәксез катылыклар тудырмавы өчен үземнең фракциямезнең эшкә дикъкать итүен тиешле табып язган идек[1]. Җирле мәэмүрләрнең халыкның мәгыйшәте, фикере берлән таныш булмавыннан, халык өчен зарарлы, хөкүмәт өчен кирәксез канлы вакыйгалар булуыннан куркуымызны аңлаткан идек. Безнең шөбһәмез дә дөрес чыкты. Өметемез дә бушка китмәде.

Лашман хезмәте хакындагы фәрман игълан ителгәч тә, фракциямезнең рәисе Котлымөхәммәд мирза берлән Йосыф бәк Җәгъфәрев, шул фәрманны тормышка татбикъ хакында үзләре тарафыннан лязем күргән матдәләрне күрсәтеп, баш министр Штрюмер[2] җәнабларына хат яздылар. (Хатлары «Сүз»нең 74 нче номерында басылды[3].)

Штрюмер җәнабларыннан берничә мәртәбә күрешеп сөйләшер өчен вакыт сорадылар. Ләкин баш министр атна-ун көн эчендә депутатларымызны кабул итәргә вакыт таба алмады. Депутатларымыз Хәрбия нәзарәтенә мөрәҗәгать иттеләр. Анда да үзләренең фикерләрен бәян иттеләр. Халык өчен уңгайсызлыклар туу ихтималы барлыгын белдерделәр. Хөкүмәт даирәләре шул сүзләргә никадәр әһәмият бирүе, әлбәттә, безгә мәгълүм түгел.

Ләкин җирле халыкның шул фәрман тирәсендә бик зур куркуга төшүләре, һаман шул фәрман тирәсендә зур канлы вакыйгалар[4] булуы хәзер беркемгә дә яшерен түгелдер. Фракция шул эшләр берлән үзеннән-үзе мәшгуль булып торганда, Төркестаннан, кыргыз[5] даласыннан делегатлар килә башлады. Әстерхан кыргызларының балыкчыларыннан, Бүкәй хан илләреннән[6], Урал кыргызларыннан, Урал-рус казакларыннан, Тургай кыргызларыннан, Төркестан мөселманнарыннан аерым-аерым вәкилләр килде.

Боларның һәркайсы үзләренең илләренең бу фәрманга карашларын һәм дә фәрманның ничек итеп тәгъбир ителүе кирәклелеген белдергән докладлар китерделәр. Фракция бюродан шул хакта киңәш-ярдәм сорадылар һәм андагы хәлләр берлән таныштырдылар.

Диңгез буе кыргызлары хәзерге вакыт балык тоту, балык тозлау чагы булганга, җыелуны октябрьгә кадәр кичектерүне һәм дә өйдә бер генә ире бар өйләрдән лашманга алынмауны телиләр.

Урал-рус казакларының вәкилләре җәй көне мал-туар кырда йөргәндә ирләремез гаскәргә алынып беткәнгә күрә, мал-туарымызны карауны көтүчеләр кыргызлар гына булуны сәбәп күрсәтеп, көз җитеп мал-туар кырдан кермәс борын, кыргызлардан лашманга җыюны кичектерүне үтенәләр.

Төркестанлылар, хәзерге вакыт пахта эшенең иң кызу чагы, бездә ирләр эшләмәсә, хатыннарымыз эшкә өйрәнмәгәнгә, Төркестанның бөтен пахтасы һәлак булачак, җирле халыкның тормышы бөтенләй җимереләчәк, Русиянең заводлары, фабрикалары пахтасыз калачак, диләр. Шуның өчен, бердән, пахта (мамык) эше беткәнче кичектерүне сорыйлар. Икенчедән, шул фәрманны татбикъны муафигърак юлга үтенәләр. Иң ахырдан хәзерге көннәрдә Төркестанның бик күп шәһәрләрендә шул фәрман мөнәсәбәте берлән уянган шау-шуны бетерер өчен ясалган каты кысынкылыкларны бетерүне сорыйлар.

Бу вәкилләр хөкүмәт даирәләренә гаризалар җибәрделәр, нәзарәтләргә бардылар. Петроградтагы депутатлар берлән сөйләштеләр, фикерләрен аңлаштылар. Хосусән Төркестандагы фәрманның татбигы вакытындагы җирле мәэмүрнең каты мөгамәләләре Петроград даирәләренә зур тәэсир ясады. Мөселман депутатларының тырышлыгы аркасында рус депутатларыннан Некрасов, Виноградов, мөселманнардан Котлыкай мирза Тәфкилевнең имзалары берлән Верховный ставкага[7] Төркестаннан лашманга җыюны кичектерүне сорап телеграмма җибәрделәр. Мондагы хөкүмәт даирәләре берлән сөйләшеп, Төркестандагы мәэмүрләрнең җирле халык берлән мөгамәләсен үзгәртү хакында мөрәҗәгатьләр ясадылар. Фракция берлән бюроның берничә җәмәгать хезмәтчеләре берлән һәм дә читтән килгән вәкилләр берлән киңәшләре булды. Төркестандагы хәл берлән тәмам танышылган Төркестанга бер-ике депутатның ярдәме лязем табылды. Мөселман фракциясе исеменнән Йосыф бәк Җәгъфәров барырга булды. Рус депутатларыннан трудовик Керенский һәм дә прогрессист Караулов бергә барырга сүз бирделәр[8].

Фракция бюроның мәҗлесләрендә бу депутатларның китүләре каралганда, Дума рәисе Родзянконың[9] Петроградка кайтуы мәгълүм булды. Котлыкай мирза берлән Йосыф бәк Җәгъфәрев кулларындагы материаллар берлән Родзянко җәнабларын таныштырдылар. Думаның рәисе мөселман депутатларына ярдәм итәргә вәгъдә итте. Үз исеменнән хөкүмәт даирәләренә мөрәҗәгать итәргә сүз бирде. Икенче көнне Петроградтагы бөтен депутатларның[10] Родзянконың кабинетында шул хакта киңәшләре булды. Котлыкай мирза берлән Йосыф бәк үзләренең иптәшләрен яңадан Төркестан хәлләре берлән таныштырдылар вә ярдәм итешергә үтенделәр. Шул арада Төркестанга генерал-губернатор иттереп генерал Куропаткинның[11] тәгаен ителүе мәгълүм булды.

Родзянко һәм дә безнең депутатларымыз Куропаткин җәнабларын күреп сөйләшергә теләсәләр дә, Куропаткинның поезды бик тиз китәчәк булганга, Родзянко генерал берлән телефонда гына сөйләшә алды, вә безнең депутатларымыз Төркестанның яңа генерал губернаторы берлән күрешүне Куропаткинның утарыннан килүенә — 30 июльгә калдырырга мәҗбүр булдылар.

Ләкин Родзянко җәнабларына генерал сөйләвеннән, кирәк, депутатларымыз вә, кирәк, Төркестан вәкилләре зур өмидләнделәр. Бердән, Куропаткин җәнаблары, үзе барганчы бөтен эшен туктатып торырга кушып телеграмма җибәргәне беленде. Икенчедән, яңа генерал-губернаторның Төркестанның мәэмүрләренең иткән катылыкларыннан һич разый түгеллеге, җирле халыктан лашман алуның ысулларын Төркестанның бер файдасы өчен үзгәртүнең тиеш икәнен икърар итүе мәгълүм булды.

Шул яңа өметләр тугач, Төркестандагы вакыйгаларны барып күрү өчен депутатларның җибәрелүе лөзүмлеге үзгәртелмәсә дә, Куропаткин белән киңәш җитешүгә кадәр кичектерелде.

Хәзерендә мөселман депутатлары үзләренә төрле җирдән депутатларның теләкләрен берләштереп, Куропаткинга лашманга җыю ысулының ни тарызда булуы тиешлеген аңлатырга хәзерләнәләр.

Докладларга караганда, бу үзгәрешләр түбәндәге әсасларга бинаән ителәчәк.

Беренче — кирәк, кыргыз даласында, кирәк, Төркестанда, Кавказда, бүтән җирләрдә лашманга җыю көзгә кадәр кичектерелсен. Икенче — өй хезмәтенә кирәк булган кешеләр лашман эшеннән мәгаф булсын. Өченче — теләгән кешегә гаскәргә китәргә, теләгән кешегә үзе урынына кеше яллап җибәрергә ихтыяр булсын. Мондагы депутатлар яңа генерал-губернаторның шул теләкләрене кабул итүне бик якын күрәләр.Генерал Куропаткин Төркестанны белгән зат булганга, үзенә могавин итеп чакырган затлары үзе киң затлар булыр дип уйлаганга, Төркестанда кирәк булмаган катылыклар бетәр дип өмид итәләр.

## ФРАКЦИЯ ВӘ БЮРО

Безнең бөтен җәмәгать эшләремез бик авырлык белән эшләнгәне һәркемгә мәгълүмдер. Бездә җәмәгать өчен, халыкның алга китүе өчен бер төрле мөәссәсә ясау лөзүмлеге ике төштә ике дүрт дәрәҗәсендә мәгълүм булгач, шул мөәссәсәне мәйданга чыгару өчен кирәк булган бер матди, мәгънәви көчемезнең эшләргә урыны юкка тик ятуы билгеле булгач, мөәссәсә вөҗүдкә чыкканчы тагы озын бер дәвер кичәдер. Шәрекълектән килгән канымыздагы акрын хәрәкәттәнме, әллә үземезгә ышанмавымызданмы, матбугатымыз, әфкяре гомумиямез бәдиһи дәрәҗәсенә йиткән шул мәсьәләне туксан тугызынчы мәртәбә мөзакәрәгә тотына. Шул мөәссәсә янында зарар яки файда итә алуы ихтимал булган затлар, гакылчылар фәлсәфә саталар. Шуның вөҗүденнән курыккан кешеләр интрига коралар, йил тегермәннәре үрәләр. Матди тарафын тәэмин итәчәк даирәләр — байларымыз, йөз мәртәбә акчаларын санап, файдасы күпме булуы, савабы, шәйхеморадка җитүе хакында төшенәләр, уйлыйлар... Бюро мәсьәләсе дә шулай булганлыгы мәгълүм.

1906 елны 27 апрельдә Государственный Дума ачылгач та[1], Думадагы мөселман депутатлар үзләренең милли, дини, сәяси теләкләре тирәсендә аерым бер фирка булып бүленгәч тә, бюро дигән ярдәм хезмәт мөәссәсәсе үзеннән-үзе килеп чыгарга, үзеннән-үзе туарга тиеш иде. Ләкин бөтен кагыйдә, кануннарга хилаф уларак, безнең фракциямезнең бюросы фракциянең мөстәкыйль яшәвенә ун ел тулганда гына мәйданга килә алды. Ун ел тулганда гына шуның өчен кирәкле булган матди-мәгънәви көчләрен бергә укмаштыра алдык. Аны да үземезнең олуглыгымызга мөнасиб, үземезнең халкымызның сәясәт ихтыяҗына йитәрлек итеп эшли алдыкмы? Хәер!

Русиянең эчендәге утыз миллионлы мөселманнарның мәнфәгатьләрен, хокукларын мөхафәзә итәр дәрәҗәдә көчле итә алдыкмы? Хәер!

Русиядәге мөселманнарның яшәешләре мәгълүм бер сәяси юлга кереп бетмәгәнгә, рус түрәләренең мөселманнарга карашлары бер урынга утырып бетмәгәнгә, халкымыз берлән хөкүмәт арасында һәрвакыт мөзакәрәләр булуы табигый түгелме?

Идел буе мөселманнарның идарәи руханияләре, мәктәп-мәдрәсә эшләре, земство, шәһәрләрдәге сайлау хаклары йирле-йиренә куелмаган. Казакъ, кыргыз кардәшләремезнең йирләре, сулары, үзләренең истикъбальләрен тәэмин итәр дәрәҗәдә закон берлән артларына беркетелмәгән. Төркестан кардәшләремезнең идарәләре әле һаман вакытлы хареб кагыйдәләре астыннан чыгарылмаган. Андагы сәяси, икътисади тормыш нәмәгълүм бер юлга төшерелмәгән, Кырым, Кавказ кардәшләремезнең вәкыф мәсьәләләре, мәктәп-мәдрәсә, тәрбия мәсьәләләре һичберсе хәл ителмәгән. Шуның өчен йирле түрәләр берлән халкымыз арасында туктамаенча аңлашылмау булып торуы табигый түгелме? Әлбәттә, табигый.

Шуның өчен мөселман халкы, кайда гына яшәмәсен, үзенең кайгысыны аңлата торган, үзе берлән хөкүмәт арасында үзенә бер васита эзләргә мәҗбүрдер. Ул да — мөселман депутатлары, мөселман фракциясеңдер.

Моңганчыга кадәр мөселман фракциясенең әгъзалары гаять аз булганга, мөселман фракциясенең ярдәмчесе — бюро тәэсис ителмәгән булганга, бу мөрәҗәгатьләр күбесенчә файдасыз кала иде. Депутатларның вакыты йитми, хәзерләргә тиеш докладлар өлгерми. Күреләчәк министрлар, директорлар күрелми кала иде. Шуның аркасында бик күп җәмәгать эшемез йә эшләнми яисә безгә зарарлы төстә хәл ителә иде.

Бу ел менә, Аллага шөкер, бюро ясап өлгерттек. Үземезнең ихтыяҗымызга йитәрлек булмаса да, кечкенә генә бер оячык ясадык. Милли, дини, сәяси ихтыяҗларымызны сөйләр өчен бер адрес, бер милли адрес тудырдык. Нәтиҗә ни булыр, әле әйтергә иртә.

Ләкин шуны да әйтмичә китәргә ярамый: фракциянең ун еллык хәятында бу елгы ел кебек күп эшләнгәнлеге күрелмәде. Фракциянең унъеллык хәятында бу елгы кебек монтазам бер хәрәкәт күрелмәде.

Бюроның вә фракциянең ни эшләүләрен язып торасы юк. Гәзитә укыган, милли матбугатны тәгъкыйб иткән затларга монда ниләр булганы мәгълүм. Ләкин соңгы көннәрдә бюро вә фракциянең халкы алдында никадәр хезмәт итүе вә шул хезмәтендә муафикъ булуы, бәлки, әле ачык мәгълүм түгелдер.

Соңгы лашман хезмәте хакындагы фәрман гали чыккач та, бюро вә фракциянең нинди теләкләрне кулда итә алганы, бәлки, мәгълүм түгелдер.

Төркестанда вә Кыргызстанда башланган дәһшәтле хәрәкәтләрне хөкүмәт өчен лөзүмсез, йирле халык өчен зарарлы тәшәббесләрне бетерер өчен, йиңгелчәгә борыр өчен фракция вә бюро фәүкылгадә эшләр эшләде. Атна, ун көнлек мөддәтендә шул мәсьәлә хакында министрлар, директор вә депутатлар берлән бертуктамаенча мөзакәрәдә булынды. Төркестан, казакъ даласыннан килгән вәкилләр, җәмәгать хадимнәре берлән ун мәртәбә киңәш ясады. Аларның теләкләрен урынына йибәрде. Шуларны тәгъкыйб итте. Атна, ун көнлек тырышу аркасында Төркестан, казак даласындагы дәһшәтле вакыйгаларны йомшак тарафка борырга муафикъ була алды. Төркестанның иске мәэмүрләре төшерелеп, Төркестанны белә торган генерал Куропаткинның тәгаен ителүе фракция, бюроның тырышлыгы тәэсиреннән читтә булмады. Төркестан вә Кыргызстанда лашман хезмәтен яңгы юлга куйганда, фракция вә бюроның зур тәэсире булды.

Иншалла, Төркестанда вә Кыргызстандагы бәгъзе бер аңлашылмаулар аркасында чыккан шау-шу берлән кулга алынганнар, җәбер ителгәннәренең язмышлары карар ителүгә дә фракциямезнең зур ярдәме булачактыр.

Ләкин шулкадәр зур хезмәтне фракция үзе генә эшли алачак идеме?

Атна, ун көн эчендә биш-ун йирдән килгән вәкилләрне кабул итеп, аларның бөтен теләкләрен бер йиргә җыя беләчәк идеме?

Шөбһәсез, бюроның шул вакытта зур хезмәте тиде. Бюро әгъзалары фракциягә рух керттеләр. Киңәш, мөзакәрә, хезмәт берлән эшнең иң зур йөген тарттылар.

Хәзерге көндә лашман хезмәте хакында халкымызның теләге үзе уйлаганча хәл ителүе — безнең сәяси хәятымызда беренче вакыйгадыр. Шул беренче уңуның бөтен савабы, шөбһәсез, бюроның гамәл дәфтәренә язылачактыр.

Менә шул лашман хакында төркестанлы, кыргыз кардәшләремез үземезнең бюро вә фракциямезнең булуы никадәр файдалы икәнен аңладылар. Баш төртәчәк йирләре булгач, үз теләкләренең азын булса да хөкүмәткә аңлатуның юлы барлыгын күзләре берлән күрделәр.

Шуның өчен, иншалла, болар кайгылары беткәч тә, бюро вә фракцияне онытмаслар. Ауга барыр алдыннан ашатылган эт берлән төлке тотып булмаган кебек, башка бәла төшкәч кенә корылган даирәләрдән дә файда итү бик авырдыр.

Мондый мөәссәсәләр даими яшәргә тиештер. Мондый мөәссәсәләр туктаса да, халыкның хокукы, мәнфәгате хакында уйлашып торырга тиештер. Ләкин аларны яшәтүче дә халык үзедер.

Бюро хәзер, Аллага шөкер, яши. Бюро хәзер, Аллага шөкер, төркестанлыларга, казакъларга хезмәт итте. Ләкин бит бюро Төркестан көче, Кавказ көче берлән яшәми, фәкать Идел буе мөселманнарының матди, мәгънәви көчләре берлән генә яши. Кирәк, бюрога вә, кирәк, фракциягә Кавказдан бер кеше йибәрелгәне, бер тиен акча бирелгәне юк.

Төркестаннан нә бюрога вә нә фракциягә нә бер кеше вә нә бер тиен акча бирелгәне юк.

Алай дигәч тә, сез бюро, фракция расходсыз тора, андагы әгъзаларымыз фәрештәләр дип уйламаңыз, фракция, бюроның еллык утыз-кырык мең расходы бар. Фракция, бюроның уннан артык әгъзасы, хезмәтчесе бар. Боларның берсенә дә Яхъя мулла пәриләре матди, мәгънәви ярдәм итми. Боларның берсенә дә әндери казнасы ачылганы юк. Боларның һәммәсен Идел буе мөселманнары идарә итәләр. Идел буе мөселманнары хәзерлеге йиткән кирәкле әгъзалар таптылар. Аларны вәкил иттереп йибәрделәр. Идел буе

мөселманнары үз вәкилләренең тормышларын, канцелярия расходларын тәэмин иттеләр. Хәзер дә итәләр һәм итәчәкләр.

Ләкин үткәрә торган вакытымыз бик әһәмиятле булганга, бу көнге Төркестан, Казакъстан башына килгән хәсрәтле кайгылар Кырым, Кавказга килмәс дип уйларга, күз алдымызда дәлилемез булмаганга, шул тарафның мөселманнары да бюро, фракциягә ярдәмгә килсәләр яхшырак булмас идеме?

Төркестан, мәсәлән, үзеннән бер әгъза күндерә алса, Кырым, мәсәлән, фракциянең сәркатибен — бюроның әгъзасы итеп кабул ителгән кырымлы затны үзенең вәкиле итеп танып, шуның хәятын тәэмин итсә генә булмас идеме? Кавказ һакәза.

Дөрест, бюро бар. Бюро булачак. Безнең Идел буе мөселманнары үземез генә дә бюро, фракцияне алып барачакмыз.

Чөнки безнең Идел буе мөселманнары шул милли даирәне күтәрү фарыз икәнен белер дәрәҗәсендә сәяси тәрбия күргәннәр.

Ләкин Кавказ зыялылары гына, безнекенә караганда меңләп артык Кавказ зыялылары шул мәсьәләдә безнең Чиләбедән, араларында бер гимназия бетергән әгъзалар булмаган Чиләбе мөселманнарыннан да артта булмаса, нинди күңелле булыр иде.

Баку — миллионерлары берлән мәшһүр Баку, яңгы борынлап килә торган егерме-утыз гаиләле Мәскәү мөселманнарыннан милли аңсыз булмаса, Мәскәү мөселманнарыннан милли тәрбиядә дүн түбән булмаса, нинди яхшы булыр иде.

Вакыт мөһим.

Әллә никадәр мәсьәләләр мәйданга куелачак. Бюро вә фракциянең алдында йөз еллык эш тупланылачак. Бюро вә фракциянең алдында милли, дини, сәяси хәятымызның иң төп мәсьәләләре кизүгә куелачак. Тарих тарафыннан куелачак.

Шул көндә көчле булсак, шул көндә үз хокукымыз, үз мәнфәгатемезне аңлый белсәк, безнең истикъбалемез нурлы. Әгәр шул көндә укышмаган канымыз белән авызымызны җәеп иснәп утырудан котыла алмасак, вәйля безнең хәлемезгә!

Кырым, Төркестан вә Кавказның зыялылары! Хәзерге тарихи көннәремезне аңлап, өстеңезгә төшкән бурычларны үтәңез әле!

Тарихымызда бер генә мәртәбә күплегемезгә мөнасиб дәрәҗәдә матди, мәгънәви көчле дә булыйк әле.

## ЯШЬ КӨЧЛӘРНЕҢ БУРЫЧЫ

### I

Казан гәзитәләре фәүкылгадә бер зур милли хәбәр китерделәр. Уфаның һимматле байларыннан Габделлатыйф хаҗи Хәкимов, Казандагы Харитонов матбагасын йөз мең сумга сатып алып, шул матбаганы «Өмид» берлән берләштереп, дини китаплар нәшер итәр өчен бер ширкәт мәйданга китергән[1].

Габделлатыйф хаҗи Уфа «Җәмгыяте хәйрия»сенә күптән түгел генә йөз мең сум иганә иткән заттыр. Габделлатыйф хаҗи — Уфадагы үз мәхәлләсенең мәсҗеден, мәдрәсәсен бина иткән, бу көнге көндә үз хәраҗаты берлән тәрбия итә торган заттыр.

Габделлатыйф хаҗи — Русиядә булган һәртөрле изгелек мөәссәсәләренә ярдәм итә килгән, үзе ышанган урыннарга малын кызганмый торган юмарт бер карт байдыр. Моның юмартлыгы белән бик күп йирдә мәктәп-мәдрәсә тәрбия ителде. Бик күп йирдә яңгы мәсҗедләр салынды, бик күп йирдә иске мәсҗедләр төзәтелде.

Габделлатыйф хаҗиның юмартлыгыннан, аның үзе ышанган һәр эшкә акчасын кызганмавыннан файдаланып, бик күп фасикъ муллалар аның акчасына донос кантурлары да ачтылар, халкына хезмәт итә торган яхшы муллаларны, оста мөгаллимнәрне төрмәгә яптырттылар, Себергә йибәрттеләр. Бик күп балаларның гөнаһсыз яшьләрен түктерделәр. Бик күп гаиләгә Габделлатыйф хаҗиның акчасы берлән гомергә онытылмаслык золымнар ясадылар.

Бу көнге көндә Идел буе мөселманнарының бәүлисләр шайкасы Габделлатыйф хаҗи акчасына гөнаһсыз милләт хезмәтчеләрен төрмәләрдә черетәләр. Ләкин бу начар эшләр дә Алла тарафыннан да гафу ителмәячәк. Бу золымнарда Габделлатыйф хаҗиның акчасы ялган шаһитлар ялларга, доносчылар ашатырга сарыф ителсә дә, Габделлатыйф хаҗи бу һимматен чын иманыннан эшләп килде. Янындагы иблис ялчыларын чын дин хезмәтчесе дип белеп, аларга матди ярдәмнән кулын тартмады.

Менә хәзер шул Габделлатыйф хаҗи, «дин, дин» дип сөйләп кенә эш бетмәгәнне белгәнгә, акчасын кызганмаенча, йөз мең сум сарыф итеп, дини китаплар нәшер итәр өчен матбага ала. Шулай итеп, хезмәт итү лязем, фарыз дип ышанганга, газиз малын да кызганмый. Мең сум, ун мең сум, йөз мең сумнан тукталып тормый.

Ник? Чөнки аның ышанган эшен эшләү тиешлегенә иманы камил.

Чөнки аның аңлаган юлында изгелек итәргә ихласы там.

Ләкин шул карт хаҗи бабайның шулкадәр һиммәт итүендә, мохите бик тар бер бабаның шулкадәр баһадирлык итүендә гыйлем, фазыйль ягыннан аңгардан бик күп дәрәҗәдә өстә торган яшьләргә гыйбрәт алачак бер нокта юкмы?

Бар. Ул да хаҗи бабаның үзе ышанган, үзенчә динлелек дип белгән һәрбер эшен эшләвендәдер.

Тәрбия, уку ягыннан хаҗи бабадан бик күп дәрәҗә югары торган яшьләр сыйныфын аерган нокта да менә шулдыр. Хаҗи баба ышандымы, иман иттеме — эшли, акча кызганмый, малдан тормый.

Яшьләр ышандымы, бернәрсәнең җәмәгать өчен кирәклеген белдеме, аңладымы — шуның белән тәмам итә, шул үз теләгәнен булдырыр өчен кыл кыймылдатмый. Бөтен милли, дини теләге мәйданга чыгарлык булса, өч тиен бакыр акча сарыф итми. Ул гына түгел, шул юлда хезмәт итә торганнарны ямьсез күрсәтер өчен гайбәт сата, һәрбер төрле чын хезмәтченең эшеннән әллә ниләр казынып, чокчынып гаеп эзли, яшь буын арасында җәмәгать эшләренә битарафлык фикерен урынлаштыра, хулиганлык тарата.

Шуның аркасында үзенең зыялылыгына бик ышанып йөргән ак якалылар арасында да чын җәмәгать хезмәтен карт, дорфа байлар гына итә, җәмәгать эшләрендә мохите тар, аңы аз байлар гына беренчелек шәрәфен казана.

Тегеләр... тегеләр тик тора... яисә әллә кайдан бер ахмак килеп, моның шөһрәте өчен акчасын сарыф кылганын көтеп ята...

Идел буе татарлары арасында кичерә торган дәверемез үзгәрү, алышыну дәвере булганга, безнең мәдәни ихтыяҗларымыз Коръән бастыру белән генә бетмидер.

Егерменче гасырда мөселман булып торыр өчен Коръәннең бик дөрест иттереп, яхшы кәгазьгә басылуы, матур төптә төпләнүе генә кифая итмидер. Хәят бик төрлеләнгәнгә, мөселманлыкны саклау өчен мәктәбе, мәдрәсәсе, мәсҗеде, җәмгыяте, әдәбияты, матбугаты, музыкасы, театрына да ихтыяҗ шулкадәр үк зурдыр.

Бер карт бай үзенең бинаи исламиятнең баганасы дип ышанганын үз мәсърафына эшлидер. Мәктәпнең кирәклегенә, Коръәннең дөрест басылуы дәрәҗәсендә икәнен аңлаганнар, матбаганың кирәклелеге Коръәннең катыргысының пөхтә булуыннан әһәмиятлерәк икәнен аңлаганнар, әдәбият, музыканың милли тәрбия өчен һава белән су кебек лязем икәнен аңлаганнар нишлиләр?

Алар да шул хаҗи бабадан гыйбрәт алалармы? Алар да шул юлда — үзләре ышанган юлда бер хәрәкәт эшли алалармы? Аларның байлары — саннары йөзләп түгел, меңләп саналачак байлары — шул юлда бер эш эшлиләрме?

Казанда, мәсәлән, милли әдәбиятны тәрәкъкый иттерер өчен идеяле бер ширкәт ясалдымы? Башка бер шәһәрдә матбугатны милли юлдан тугры иттереп алып барырлык бер оешма мәйданга китерелдеме?

Идел буеның күп шәһәрләренең берсендә генә булса да милли театрымызга нигез салынырлык бер генә матди хәрәкәт эшләнелдеме?

Юк! Ул гына да түгел, башланган бер идеягә торгызылган эшләр йимерелделәр, харап булдылар, матди көч юклыгыннан чәчәк ата алмаенча корыдылар, беттеләр.

Татар балаларының милли тәрбиядә булуы тиешлеге хакында беркемнең дә шөбһәсе юктыр. Шул ният белән чыгарылган матур «Тәрбиятел-этфаль», «Ак юл» журналлары акчасызлык юлында корбан булдылар[2]. Мөгаллимнәр вә мөгаллимәләрнең фән, тәрбия юлын күрсәтүгә ихтыяҗларында бит беркемнең дә шөбһәсе юктыр. Шул бурычны үтәр өчен фән, тәрбия журналларыннан «Мөгаллим», «Мәктәп» берсе артыннан берсе үлде, харап булды[3], култыклаячак көчләр булмаганга, бик кечкенә генә матди ярдәмнәр дә булмаганга баттылар, югалдылар.

Ул гына да түгел, бу көнге көндә милли тәрбиямез өчен иң кирәкле нәрсә мәктәп, дәрес китапларымыз икәнендә сүз булу ихтималы юктыр бит. Менә хәзерге көндә шул фәндә тәхассыс иткән, исмасам, егерме мөгаллимнең генә әллә никадәр яхшы китаплары наширләре юкка, үзләренең акчалары юкка басылмаенча яталар.

Иң ахырдан, татар әдәбиятын мәйданга китерүдә исемнәре танылган мөхәррирләрнең язган бер әсәрләре белән милли байлыкның кирпечен салулары* тасдыйк ителгән әдәбиләремезнең генә әсәрләре басылыр өчен, исмасам, бернәрсә тудырылганмы?

Юк.

Ник?

Әллә боларның тарафдарлары азмы? Әллә әдәбиятның кирәклеген аңлаучылар юкмы? Әллә матбугатның су кебек лязем икәнен белүчеләр йитәрлек түгелме? Әллә мәктәп-мәдрәсәнең, матбугатның лөзүмен аңлаучыларның саны бик кыскамы?

Хәер!

Ник соң?

Буларның берсенең дә иманы — үзенең ышанган матбугатына, әдәбиятына, мәктәбенә иманы Габделлатыйф хаҗиның Коръән катыргысына иткән иманы кадәр юктыр.

Чөнки буларның берсенең дә сөйләгән сүзе эчтән кайнап чыккан хакыйкать түгел, модага иярүдән килгән балалык кына.

Ләкин балалык та үз вакытында үтәргә тиештер. Егетлек яшенә йиткәч тә, балигълыктан чыга алмаган гөруһлар һичбер вакыт егет була алмаячаклардыр. Егет була белмәгән кешеләрнең вакыты йиткәннең соңында карт була белмәве дә мәгълүмдер.

Шуның өчен, шул зур вакыйгадан гыйбрәт алып, безнең аңлы дигән сыйныфымыз да бераз хәрәкәткә килергә тиештер. Ул да сүз берлән түгел, иман берлән эшкә керешергә тиештер.

Хосусый эшне эшләүдә матди көч беренче дәрәҗә булганны бик белгән бу затлар җәмәгать эшләрендә дә матди көчләрне сарыф итә башларга, үзләренең теләкләрен мәйданга чыгарыр өчен, матди көчләрне бергә җыеп, милли бер ширкәт мәйданга китерү тиештер.

Безнең игътикадымызча, бу көнге көндә иң беренче кирәк булган ширкәт — үземезнең милли әдәбиятымыз, үземезнең фәнни әдәбиятымыз, үземезнең чын матбугатымызны алып бару өчен төзеләчәк ширкәттер.

Хәзер халыкның кулында акча барда шундый бер милли ширкәт тәэсис итү бик йиңгел булачактыр. Ләкин берничә шарты бар. Аларның беренчесе — акчалы кешеләрнең акчасына табынмаулары. Икенчесе — зыялы дигән затларның, әллә кемнәрнең бирүен көтеп тормаенча, иң әүвәл үзеннән башлаулары. Өченчесе — кылны кырыкка ярып, бик гакыллы булган булып маташа-маташа форсатны качырмаулары.

Менә хәзер, мал куәте белән милләтенә хезмәт итәргә теләгән яшь көчләр, кизү сезнеке! Милләтеңезнең истикъбаленә иманыңыз булса, балаңыз-чагаңызны шул милләт иттереп күрәсеңез килсә, шул юлда өстеңезгә төшкән бурычны үтәргә тиешсез.

Үзеңезнең алдыңызда үзеңезнең шәрәфеңез булса, үзеңезнең балаңыз-чагаңыз алдында үзеңезнең бурычыңызны аңлый алсаңыз, шул милли адымны эшләргә тиештерсез.

Бу көнгә кадәр килдек, матбугатымыз берничә каһарманнарның йилкәсендә өстерәлеп бара алды, әдәбиятымыз җаныннан газиз берничә әгъзасын корбан итеп кечкенә-кечкенә адымнар ясый алды.

Ләкин каһарманнар дәвере һәр милләттә бер генә була. Ул хәзер үтте. Үтмәсә — үтә.

Бөтен милләт өстенә төшкән һәрбер милли фарзе кифаяне эшләп, милләт өстеннән фарызны төшерүче кимеде, кими бара, бетәчәк. Ләкин фарыз бетми. Милли фарыз, милли ихтыяҗ арта гына бара. Бу көн эшләнмәсә, иртәгә тагы зурая, иртәгә эшләнмәсә, кәффарәте тагы олуглаячактыр, вә милли яшәешемез авырайганнан-авырая барачактыр. Никадәр гакыллы башлы булып, әллә кемнәр эшләгәнне көтсәңез дә, форсат качырудан башка файда чыкмаячактыр.

Дини китаплар нәшер итүдә бурычын үти белгән карт Латыйф хаҗи сезнең өстеңезгә милли фарыз булган йөкне төшерер өчен килмәячәктер.

**II**

Элгәреге заманда бабаларымызның үзләренең милләтләрен саклар өчен тоткан юллары бер генә булган. Ул да — милләте хакимә берлән мөмкин кадәр аз мөнәсәбәттә булыну. Шуның өчен ул заманның алдагылары, голямасы күршеләремез русларның бөтен тормышын хәрам итеп игълан иткәннәр.

Русларның зәбихәсе хәрам, рус белән никях, русларның ашамак-эчмәке хәрам, русларның телләре, көйләре хәрам, русларның гадәтләре, йолалары хәрам, русларның кием-салымы, бүрке, папкасы, каләнсуәи мәҗүсисе хәрам. Алар белән алыш-биреш итү, алар белән мөгамәлә итү, хәләл даирәдә булса да, куркынычтан хали түгел.

Менә шул юллар белән иске бабайлар үземезнең хәятымызны үз хәятымыз даирәсеннән чыгармаска тырышканнар. Читләрдән килә торган һәртөрле мәдәни, гыйльми, дини, гадәти хәрәкәтләрнең һәммәсен дингә хилаф дип сеңештергәннәр. Шуның аркасында безнең Русиянең эчендә калган бер уч Идел буе татарларын руслашудан саклап алып кала алганнар. Бабаларымызның бу хәрәкәте ул вакытта иң табигый бер хәрәкәт булган. Милләтне саклар өчен, тәназыгы бәка өчен ул вакытта ялгыз шул юл гына тугры булган.

Шул хәрамнар аркасында бабайларымыз гаиләмезгә рус хатыны керүдән саклый алганнар. Гаиләмезне тәмам милли иттереп калдыра алганнар. Шул хәрамнар аркасында бабайларымыз үземезнең йоламыз,

гадәтемезне саклый алганнар. Тормышымызны русларның көе, музыкасы, гадәте, йоласының тәэсиреннән азат итә алганнар. Шул хәрамнар хакында халкымызның рухына «чын тормыш — безнең тормыш, башкаларның тормышы — хәрам тормыш» дигән казыяне сугып, үзенең тормышына, хәятына каршы зур бер мәхәббәт баглата алганнар.

Ул вакытларда бабайларның шул калканнары тәмамы берлән читтән килә торган үзлекне бетерүгә каршы тора алган, ул замананың кыска гакыллы миссионерларының дорфача христиан итәргә тырышуларына каршы кальга була белгән.

Ләкин ул вакытта безнең халкымызның тормышы тәдафегый хәлендә булган. Ул үзенең иленә кергән дә керпе кебек бөгәрләнгән дә яткан. Читтән ни генә килсен, ул сөтме, балмы, дегетме, катыкмы — зәһәре белән агу дигән дә куйган, һичберсеннән авызына алмаган.

Ләкин вакыт үткән саен, замана үзгәргән. Русиянең хокукый тормышында үзгәрешләр булган кебек, аның сәүдәсендә, гыйлем-һөнәрендә әллә никадәр яңгылык пәйда булган. Безнең халык та, табигый уларак, шул зур агымга каршы тора алмаган. Аның сәүдәгәре сәүдәгә керешкән. Рус белән, яһүд белән, башкалар белән мөгамәләгә тотынган. Аның сүзен дә, көен дә ишеткән. Холкын, тормышын да күргән. Кием-салымын да күздән кичергән.

Озын-озак мөнәсәбәттән соң теге бабаларның «русның һәрнәрсәсе — хәрам» дигән казыясы да йимерелгән, татар тормышында Аурупа мәдәниятенә каршы корылган шул крепость ватылгач та, Аурупа мәдәнияте татар тормышының эченә йимерелеп керә. Аның әдәбияты, аның музыкасы, аның йоласы, гадәте, аның кииеме-салымы татар тормышын каплый. Иске бабайларның гадәте буенча, бәгъзе бер кешеләремез «хәрам, хәрам» дип кычкырса да, буа ерылгач, суга каршы «рөхсәт юк» дигән бу әмерләрнең тавышка башка һичбер нәтиҗәсе булмый.

Хәзер бу көнге көндә моннан илле ел элгәре татар дөньясы — ислам диненнән күбәи тимер кигән татар дөньясы тәмамы белән үзгәргән. Аның йоласы, гадәте элгәреге саф татар йоласы түгел, аның кииеме-салымы Алтай тауларыннан алып чыккан печемдә түгел, аның тормышының үзәге, элгәреге кебек, күршеләренең басып китүеннән курку түгел, аның утырган йире дә, элгәреге кебек, Идел буе татар иле генә түгел, ул бөтен Русиягә җәелгән, җәелә. Русиянең шәһәрләренә, авылларына кәсеп өчен китә, тарала.

Аның әхвале рухиясе дә башка, ул хәзер рус хәятына каршы «бу — хәрам» дигән үлчәүне югалткан. Элгәреге бабайлар заманасындагы бик күп хәрам булган нәрсәләр хәзер аның тормышына кереп киткән, «кирәкле» булып киткән. Ул алар белән хәзер тартыша да алмый, чыгарып ыргыта да алмый, дөресте — шул ыргытуны кирәк тә тапмый.

Ул хәзер русның тормышыннан ул кадәр җирәнми, рус хатыны дип, күзне йомып китми, рус зәбихәсе хәрам дип ашамаенча тормый, рус белән алыш-биреш итү шөбһәле дип үзенең табышын югалтмый, югалта алмый.

Чөнки тормыш аны мәҗбүри иттереп сарбысыз булырга куша. Шуның өчен аның үзлеге, аның миллияте элгәреге дин калканы белән генә саклана алмый. Аның үзлеге, элгәреге кебек, йола, гадәттә руска иярмәү белән генә мөхафәзә ителә алмый.

Ул хәзер «иярмәү»не булдыра алмый, иң тугрысы, булдырырга тиеш тә тапмый. Ул хәзер элгәреге кебек дорфа миссионерның килеп, үзен христиан итүеннән курыкмый. Анлык кына аның үзенә ышанычы бар. Анлык кына үзенең хокукын саклый белерлегенә аның иманы бар. Ләкин аның миллияте, аның үзлеге һаман читтән һөҗүмгә мәгъруз.

Ул хәзер иленнән чыккан. Аның иң фәгъгал бүлеге шәһәрләрдә яши, сәүдәсен, һөнәрен үзенә башка халыклар белән эшли. Шуларның телен өйрәнә, гадәтен белә. Алар белән төрле мөгамәләдә була. Ашавында, эчүендә, киемендә, салымында ул гомум модага табигъ. Ул монда Алтай тауларыннан чыкмый, Петербургта, Мәскәүдә чыга.

Эш эшләп бетердеме, ул тын җыяр өчен урамга чыкса, анда аны кинематограф каршы ала. Ул зур көзгеле залда музыка астында үзенең утыз тиененә күңел җуата, театр, музыкасы аның арыган нервларын хәл җыйдыра! Ләкин «Тәфкилев», «Сакмар» уйнап түгел, «Во саду-ли, в огороде» көйләп! Ул, аз гына үсә төшеп, зуррак сәүдәгәр булса, рәхим ит, аның ихтыярында рус театрлары, рус опералары, рус концертлары. Менә болар барысы да, акрын гына моның эченә сеңә-сеңә, элгәреге татар баласының үзлеген читкә куа бара. Аның миллиятен чит мәдәният эчендә тоз кебек эретә бара.

Бу да әле бер хәл. Бу кыйсем халык үзләре мәдрәсәсен, мәктәбен, мулла-мөдәррисен күргәнгә, аларның эчләренә үзлелек ныгытылган. Аларның тәмамән миллиятләрен югалтудан страховать иткән. Ләкин яшь буынның хәле ничек? Болар балалары ничек?

Архангельда, Тверьда, Киевта, Харьковта, Владивостокта, Харбинда, Костромада яши торган бу татарларның балаларының хәле ничек?

Балалык вакытларын болар үзләре кебек яшьтәш рус балалары Вася, Маня, Федя белән үткәрергә мәҗбүрләр. Шул Вася, Федялар арасында азлык хасил иткәнгә, уенда, гадәттә, алардан үрнәк алырга мәҗбүрләр. Мәктәп вакыты йитеп укый башласалар, тагы Вася, Паша, Федя өчен хәзерләнгән мәктәпләргә китми хәлләре бармы?

Юк!

Соңгы елларда ибтидаи мәктәпләремез артса да, игъдади тәрбия өчен рус гимназияләренә керми хәл юк бит.

Шул балаларның авызлары ачылып, әдәбият укый башласа, рус телендәге йөз еллар эшләнгән рус әдәбияты белән татар әдәбиятын чагыштырып карамый хәле бармы?

Зур рус милләтенең күп еллар эшләнгән әдәбияты алдында татарның кечкенә, яшь әдәбияты тез чүкми хәле бармы?

Музыкага китсә, әллә никадәр дөньяга мәшһүр композиторлары эшләгән рус музыкасы белән безнең милли кубызымызның череллдәве ярышуны күтәрәчәкме?

Һич!

Шуның өчен бу балаларның үскән вакытларында үзләренең тәкаммелләре өчен читтән фән, гыйлем, тәрбия алган чакларында бөтен мәгънәви азыклары чит халыкның азыгы булачактыр вә шул татар балаларында милли ныклыкны саклый торган һичбер көч калмаячактыр .

Шуның өчен бу көнге килешемездә барсак, тормышымызның үзгәрешенә каршы үземезнең үзлегемезне саклый торган яңгы коралларга ябышмасак, егерме биш-утыз ел үткәннән соң, безнең хәлемез ни булачактыр?

Без, бераз татарча сөйли белә торган паспортларымызга «Әхмәтҗан Мөхәммәтҗан углы», «Әсма Миңлешәриф кызы» дип язылган кешеләр булып, атамыз, анамыз үлгәндә мулладан ясин «прочитать» иттерә торган рәсми мөселманнар, рухан башыннан алып ахырына кадәр руслар, марҗалар булып калачакмыз.

Без ул вакытта яисә Касыйм татарлары кебек әллә ниндәен иске фикерләрдә мөтәгассыйб булып, милли эшләрдә тәмам рус булып, үзлегемезнең тамырына балта чабучан милли кяферләр булачакмыз.

Яисә Литва татарлары кебек буен бөтиле, шәмаил шәрифле, теле юк, әдәбияты юк, музыкасы юк, гадәте-йоласы юк байгышлар булып калачакмыз.

Ләкин шул хәлдән чыгар өчен, киләчәк егерме биш-утыз ел эчендә бөтен Идел буе мөселманнары арасында Ильминский да уйлый алмаган шул миллиятсезлек, руслашу падишаһлык сөрмәсен өчен юллар бармы соң?

Бар!

Ул да — хәзерге көннән үк яшь буынымызны милли зәррә белән зирәһләү, ул да — балаларымызны миллиятнең бөтен төрлеләре белән ашлау!

Ләкин безнең өчен Коръәнне дөрест иттереп бастырып, шәп иттереп төпләтү генә йитәчәк түгелдер.

Аның өчен милләтнең аңлылары, киләчәктәге шул куркынычны күреп, бу көннән үз вазифасын үти башларга тиештер.

Бу көннән яшь буын өчен милли азык хәзерләтергә тиештер.

Аның өчен ни лязем?..

**III**

Аның өчен ни ляземме?

Үзлегемезне саклар өчен, үземезнең аерым бер милләт булып яшәвемезне саклар өчен ни ляземме?

Үземезнең күрше милләтләр арасында эреп бетеп, бөтен бар-лыгымызны, бөтен мәдәниятемезне, бөтен байлыгымызны читләрне үстерер өчен тирес, чүп булудан саклар өчен ни ляземме?

Моның җавабы бик кыска.

Без көчле булырга тиеш. Чит милләтләрнең көчләре тарафыннан йотылмаслык дәрәҗәдә, милли авызларына сыймаслык дәрәҗәдә зур булырга тиеш.

Чит халыкларның тешләре арасында кысылып, изелер дәрәҗәдә тешсез, тырнаксыз булмаска, күрше халыкларның мигъдәләренә керү белән каймак кебек эреп китәр дәрәҗәдә йомшак, зәгыйфь булмаска тиеш.

Әгәр без шулай көчле була алсак, безнең бер милләт булып торуымыз хәл ителгән! Әгәр без үзлегемезне саклар дәрәҗәдә көчлелек күрсәтә алмасак, безнең башка халыкларның үсүләре өчен тирес булуымыз катгый!

Замана — көчленеке!

Хәят хакы, кирәк, аерым кешеләрдә булсын, кирәк, иҗтимагый сыйныфларда булсын, кирәк, аерым милләтләрдә булсын — көчленеке.

Бу — табигатьнең кануны!

Ләкин бер милли оешма ни белән вә ни дәрәҗәдә көчле була беләчәк?

Моның өчен биреләчәк җавап та бик кыска һәм катгый. Бер адәмнең таза, көчле, нык булуы өчен аның бөтен әгъзалары исән булып, аңар ашамак-эчмәк, пакь һава саф булуы өстенә, ул адәмнең әгъзаларының бөтен хәрәкәте киләчәген саклар өчен хезмәт итүе кирәк, ягъни ул бу көнге көндә мохитеннән алган көчне иртәгә, өченче көнгә тормышын дәвам иттерер өчен кирәкле эшләрне эшләргә боруы, бар көчен шул юлда татбикъ итүе кирәк. Шуның кебек үк бер милләтнең дә бер милләт булып, аерым бер мәдәни оешма булып, үзенең телен, үзенең гадәтен, йоласын, үзенең динен саклар өчен лязем булган шартлары да шул милләтнең бөтен әгъзаларының үзенең бәкасе өчен кирәкле булган хезмәтләрне итүен — милләтнең башы шул фикер хакында уйларга тиеш. Милләтнең кулы шул хакта лязем күрелгән эшләрне татбикъка таба борылырга тиеш. Милләтнең аягы, гәүдәсе шул башның борган тарафына хәрәкәт итәргә, адым атларга тиеш. Милләтнең үрчү куәте, халыкның саны артуга гына түгел, халыкның ганганәсе, милли әхвале рухиясенең өзелмәенчә атадан — бабага, бабадан балага бирелүенең тәсбих теземе булырга тиештер.

Ләкин бу «тиешләр» һәммәсе дә нәзарият бит! Моның татбикы ни тарызда?

Моның татбикымы? Аның өчен иң әүвәл милли хәятымыздагы иҗтимагый гонсырларымызның кайсысы киләчәк өчен кирәкле, милли бәкамыз өчен кайсысы лязем икәнен тәгаен итү шарттыр.

Бу гонсырларны хәзерге кебек «карт» [һәм] «яшь» истиляхлары белән бүлгәндә дә бик зур яңлышмаячакмыз. Киләчәк тормыш, моннан егерме-утыз ел, илле ел соңгы тормыш кемнәр өчен кирәк? Бу көнге көндә гүр якасына аяк баскан картлар өчен моның кайгысы — хәсрәт түгел, рәхәте шатлык түгел икәне мәгълүмдер. Киләчәктә бетү, руслашуга да кемнәр мәгъруз? Бу көнге көннең картлары, ир урталары түгел, хәзерге көннең яшьләре, балалары, киләчәк буындыр. Шуның өчен шул киләчәк хәзерлеген корганда, уйлаганда, хәзерге картларның уйлары, фикерләре, аларның искедән калган мөстәхас фикерләре белән катгыян хисаплашмаска тиештер. Бөтен нигезне — киләчәк өчен корылачак нигезне яшьләргә каратып, киләчәк буынның баласына каратып эшләргә тиештер. Шуның өчен зиярәт тирәсен тотуларын мөхтәрәм картларга калдырып, яшьләр, балаларның истикъбале белән мәшгуль булырга, аларны руслаштырудан, бетүдән саклар өчен юллар табарга тиештер.

Моның өчен иң беренче шарт — мәктәпләремезнең милли булуы түгелме? Шөбһәсез, шулайдыр. Ләкин бу көнге көндә ибтидаи мәктәпләремездә «милли» дигән сүз никадәр истигъмаль ителсә дә, эч ягыннан болар бик зәгыйфь, моның төбенә куелган тәрбия һичбер төрле рәтләнеп эшләнмәгән, мәктәпләрнең нигезләренә чын милли тәрбия берләштерелмәгән.

Моның сәбәпләре, әлбәттә, күп. Мөгаллим-мөгаллимәнең лөзүме кадәре мәгълүматы йитмәве, мәктәп китапларымызның бик начар булып, мәгълүм бер мәсләккә хезмәт итәр өчен эшләнгән булмаулары. Шул кимчелекләр аркасындадыр, мәктәп күргән балаларымыз мәгълүм бер милли тәрбияне алып чыга алмыйлар. Мәктәптән чыккач, мәгълүм милли юлдан барырлык итеп йибәрелә алмыйлар.

Шуның өчен милли бинаны төзүдә беренче лязем булган нәрсә — мәктәпләремезнең мәгънәви көчләрен зурайту, юксәләтүдер.

Бу — беренче.

Икенче — мәктәптә вакытында баланың алганы никадәр күп кебек күренсә дә, алар бик сай мәгълүматлы булалар. Тәрбия хосусында мәктәпләр никадәр яхшы булса да, алар гына юлга төшерә алмыйлар. Шуның өчен, мәктәпләрдән дәрт алып чыккан балаларның омтылуларын тудырыр өчен, аларның мәктәп тышындагы тәрбияләрен мәгълүм юлдан алып бару лямемдер. Шуның өчен яшь буынның уку китапларына дикъкать итү лямемдер. Милли хәятның төрле мәсьәләләре хакында баланың башындагы сөальләргә милли рухта җавап табар өчен милли әдәбият иң ышанычлы иптәштер. Шуның өчен яшь буынга үзенең телендә язылган әдәбият та аның күңеле омтылган бөтен мәсьәләләргә җавап табар дәрәҗәдә бай булырга тиештер. Аның күңелен җуатыр, башындагы, йөрәгендәге дәртләрен таратыр өчен милли музыкасы яисә кулына алып уйнаган көе аның саф хисләрен былчыратмас дәрәҗәдә эшләнгән булырга кирәктер.

Аның эче пошыпмы, мәйдандагы бер-бер иҗтимагыймы, гаиләвиме мәсьәләне хәл итәргә юл эзләпме барган театрында аның алган хиссияте, тәмамы белән миллияткә манчылган булу өстенә, сәнгать җәһәтеннән дә чын театр булырга тиештер.

Шуның өстенә яшь буынның һәр көн иртә белән хәбәрләр, вакыйгалар хакында укый торган гәзитәсе, фәнни мәсьәләләр хакында моталәгә итә торган журналы, китаплары ана телендә булуы һәм дә эченең байлыгы ягыннан күршеләренекеннән ким булмавы шарттыр.

Менә шул мәгънәви көчне милли иттереп организовать итә белсәк, менә шул яшь буын өчен бөтен мәгънәви кирәкләр ана телендә табылырлык булса, күршеләр эчендә эрүгә вә киләчәктә бер милләт булып яшәүдән мәхрүм булуга каршы зур бер кальга корылган буладыр.

Ләкин сүздә йиңгел бу эшләрне билфигыль эшләү фәүкылгадә бер гайрәткә мохтаҗдыр. Ул да — татарның бөтен мәгънәви көчләрен берләштереп, аларның бөтен куәтләреннән, талантларыннан мөмкин кадәр күп иттереп милли байлык тудыруга истигъмаль итү, аларны остача иттереп эксплуатировать итүдер. Моның өчен хәзерге көндә мәктәп-мәдрәсәләремез дәрес китаплары яза алырлык әһле тәрбияне бергә оештырып, мәгълүм программада дәрес китаплары хәзерләтүдер.

Моның өчен әдәбиятымызның үсүенә хезмәт итүе күздә тотылган бөтен әдипләремезнең хәятларын мөмкин кадәр зур милли әсәрләр мәйданга китерердәй юлга борудыр. Моның өчен милли матбугатымызның күрше яһүд, рус, әрмән матбугатыннан мәгънәви яктан фәкыйрь булмасын өчен, әһле гыйлем, әһле фәнни матбугат мәйданына чакырыр дәрәҗәдә матди җәһәттән ныкландырудыр. Боларның барысы да матди көчкә мохтаҗдыр, һәм дә хәзерге көндә төрле йиргә таралган татарның мәгънәви көчләре шул кизүдәге мәсьәләләрне хәл итәр дәрәҗәдә хәзерлеге булганда, бөтен терәлү матди көчтә генәдер. Ул матди көч, һичбер халыкта да күктән иңмәгәнгә, читтән китерелмәгәнгә, халыкның үз эченнән табылырга тиештер. Бәхетле халыкларда күп вакытта бай бер сыйныф шуны эшлидер. Безнең кебек йолкыш милләтләрдә шул зур милли бурычны тутырыр өчен иманыннан башка каләме генә яисә авызы гына бар, йирсез-сусыз пролетариат эшли, көрәшә. Матди көч йитмәү аркасында әллә никадәр гайрәт сарыф ителеп, әллә никадәр кыйммәте юк затлар югалтып кына дәвам итә аладыр. Фәкать үләр-үлмәс дәрәҗәдә генә дәвам итә аладыр вә алгандыр.

Ләкин моның соңында шул дәрәҗәдә дәвам итсә, бу көчләр халыкны руслашудан сакларлык калкан хәзерли алмаячактыр. Бу кечкенә генә көч киләчәк буынның милли рухын туйдырырлык милли-мәгънәви азык йиткереп тора алмаячактыр.

Шуның өчен хәзерге көндә шул ихтыяҗны аңлаган даирәләр шуның чарасына төшенергә тиештер. Моның эчендә иң фарыз булган нәрсә — бу көчләрнең терәлеп тора торган матди манигъларны бетерүдер. Икенчедән, яңгы көчләр хәзерләр өчен өмидле яшьләрне хәзерләүдер. Боларны фәгалияткә чыгарыр өчен, милләт тарафыннан әминият казанган кешеләрнең идарәсенә бирер өчен милли бер фонд та хәзерләүдер. Шул милли фондтан үземезнең матбугатымыз, әдәбиятымыз, театрымыз, музыкамыз ярдәм алырга тиештер. Шул милли фондтан рус мәктәпләрендә укучыларыбызны милли даирәдә тәрбия ителәчәк юлга сарыф ителергә тиештер. Татбикатькә килгәндә, иң беренче милли фондтан зур бер нәшере китап ширкәте ясап, мәктәп, китап, әдәбият, театр, музыкамызны үз кулына алырга тырышырга тиештер.

Икенчедән, шул кирәкле тарызда нәшер иткән китапларны мөмкин кадәр бөтен авыл почмакларына кадәр таратырга тиештер. Менә шул эшләнә алса, егерме-утыз ел эчендә Идел буе татары суда батмый, утта янмый торган, кая барса да эреми-нитми торган бер милли оешма була беләчәктер. Шул бурычны эшли алмасак, киләчәктәге буынның руслашуына бу көннән разыйлык имзасы аткан буламыз. Ләкин бездә сәүдәгәрләр, байлар арасында шул фикерне аңлаганнар йитәрлек бармы? Бөтен Идел буенда шундый бер ширкәт ясарлык йөз, йөз егерме мең сумлык акча табып буламы?

Аңлаган яшьләр арасында тарих буенча онытылмаячак шул милли хезмәттә беренче урында торырга теләүчеләр бармы?

Монысын киләчәк күрсәтер.

**«НӘШЕРЕ КОРЪӘН ШИРКӘТЕ»**

Габделлатыйф хаҗи Хәкимовның Харитонов матбагасын алуы Уфаның һиммәтле байлары тарафыннан оештырылган «Нәшере Коръән ширкәте»нең мәйданга килүенең беренче адымы кебек тәфсир ителгән иде[1]. Ләкин шул гомуммилләт өчен әһәмиятле зур бер эштә гомуммилләтнең барысының мөкатдәс булган Коръән вә башка шәргый китапларны нәшер өчен эшләнгән шул эш итәк асты гына йөртелеп, аңлашылмаган бер мәсьәлә булып калган иде.

Кирәк, мәгънәви яктан вә, кирәк, матди яктан, сату-алу җәһәтеннән шулкадәр киң эшнең китап галәмендә бибәһрә бер Коръән сәүдәгәре белән бетерелүе вә шул эштә капраллык таягы «Сабах» ширкәтенә бирелүе исне китәргән иде[2].

Ләкин соңгы вакытларда алынган хосусый мәктүбләргә караганда, мәсьәлә бөтенләй башкача, имеш. Казанда Харитонов матбагасын алучы һәм дә шул эшне «Сабах»ларга тапшыручы Уфаның Садри Нәзиров, Сабирҗан Шәмигулов вә башка байлар тарафыннан җыелган Казан сәрмәясенә эшләнгән эш булмаенча, Хәкимов фирмасының хосусый бер эше генә, имеш. Ләкин монда да әле һаман «имеш»тән котылып булмый. Ләкин шул имешләр бөтен Русия мөселман галәме өчен кирәкмәгән аңлашылмауларны

тудыралар. Шул мәсьәлә хакында шөбһә уяталар. Татар матбугатында һаман шул мәсьәлә хакында аерымачык фикер бәян итүдән туктатып торалар.

Матбугатымыздан «Вакыт», «Тормыш», «Кояш» бу мәсьәләнең аңлашылмаган бер уен икәнен язып үттеләр. «Йолдыз» зур бер милли оешма кебек тәлкыйн итте. «Дин вә мәгыйшәт» Сафа Баязидовның яңгы бер кармагы кебек иттереп бәянда булынды[3]. Ни генә булса булсын, аңлашылмау бетмәде вә шул изге эшнең башына куелган гизлелек бөтен эшкә шөбһәле бер буяу бирүдән саклый алмады.

Русия мөселманнарының Коръән вә башка мөкатдәс китапларны нәшер итү хакында башлары ватылганлыгы күбемездә мәгълүм. Мәкәрҗәнең беренче съездында[4] дин китапларының милләтнең монополиясенә алынуы яшьләр тарафыннан тәкъдим ителгән бер мәсьәлә иде. Аннан соң да әллә никадәр сөйләнгән, язылган бер эш иде. Хосусән Казанда әлеге Харитонов матбагасында басылган Коръәннәрдә, Казанның мөтәгассыйб муллаларыннан Сафа мулланың мәгънәви мәсъүлияте астында чыгарылган Коръәннәрдә Казан яшьләре тарафыннан тәхрифләр табылгач[5], бу мәсьәлә бик кызып киткән иде. Шул вакытта әллә никадәр планнар корылганның соңында гомуммилләт тарафыннан Коръәнне сату-алу базарыннан чыгару, аны капйот сәүдәгәренең сату малы итүдән алу мәсьәләсендә фикердә иттифак хасил булган иде. Ләкин бездә бер мәсьәләне аңлап бетү белән эшләп чыгару арасында берничә ел вакыт үтү кирәк булганга, Коръән Шәрифне инхисарга алу да шулай торып калган иде. Харитонов үзенең яңлыш Коръәннәрен сата биргән, башка көтепханәләр үзләреннән тагы яңлыш Коръәннәр баса биргәннәр иде.

Шул чуалчык дәвам итеп килгәндә, Уфа зыялыларының юл күрсәтүе буенча Уфаның байлары шул изге эшкә акча бирергә булдылар, булдылар гына түгел, бер ике-өч көн эчендә бер-ике йөз мең сум сума да җыеп алдылар. Хәзер инде шул эшне юлга кую гына калды. Акча биргән затларның һәммәсе дә шул сумаларын лиллаһ бирүләрен сөйләделәр. Шул сума белән ниятләрен Коръәне газим нәшерен кирәкле юлга кую гына икәнен аңлаттылар. Максатлары хәзерге үзләренең кызыл мал, ашлык, йомырка, чүпрәк сатулары кебек, Коръән сатуын, алуын да бер тиҗарәт итеп алырга теләмәүләрен ап-ачык сөйләделәр. Шуның өчен уфалыларның шул юмартлыгы гомум тарафтан рәхмәт әйтелеп кабул ителде. Һичбер төрле могарәзә эшләмәенчә, эшнең эш булуы гына көтелде.

Ләкин бездә бик күп эшемездә булган кебек, монда да әллә нәрсә булуы да хактыр. Гомумән, әллә ни туды. Ләкин кирәгенчә уйланып, төшенеп түгел, әллә кемнең әллә нинди алдавы, әллә кемнең әллә нинди алдануы белән чуалчык эш булды да чыкты.

Моңгардан чыгачак нәтиҗә дә шуның өчен бик томанлы күренми хәле юктыр. Моңгардан чыгачак нәтиҗә дә, бөтен халыкның теләгәне кебек, Коръән басу, сату эшендә чуалчыкны бетерәчәк түгелдер. Чөнки яңгы «Сабах», Хәкимов фирмасының Коръән нәшер итәргә хакы булган кебек, шундый ук мөселман фирмасы Кәримовның вә Хөсәенов вирасәтенең, Кадыйровның да, галим Максудовның да, шул ук Харитоновның да ихтыяры үз кулларында калды. Аларга каршы «сез басмаңыз» дигән бер канун эшләнмәгән кебек, аларга каршы «басмаңыз» дигән мәгънәви бер көч тә куелмады, куела алмыйдыр. Соң, ни генә булды? Коръән нәшер эшенә тагы яңгы Хәкимов дигән бер кеше генә кереште. Шуның өчен Коръән вә мөкатдәс китапларны басу, тарату эше һаман әле милли, дини юлда ителмәде. Хәкимовның юмартлыгы мәгълүм булып калса да, аның акчасын милли, дини юлга сарыф итүдә мәгълүм бер планы булмаенча, күп вакытта үз балтасын үзе утырган ботакны кисәргә сарыф иттереп торуы гына беленеп калды. Коръәнне нәшер итүне милләтнең инхисарына алу мәсьәләсе һаман ачык көенчә калды, мәсьәләне баштан башларга булып калды.

Ләкин шунда тагы яңгы бер сөаль туды. Ул да Уфаның һиммәтле байларыннан Садри әфәнде Нәзиров, Сабирҗан әфәнде Шәмигулов вә башкаларның Коръән нәшере ширкәте ясар өчен биргән сумалары кайда калачак? Вә алар хәзер кем кулында? Шул сумалар халыкның милли, дини теләге булган Коръән эшен инхисарга алу өчен биреләчәкме, юкмы?

## УКУ ЕЛЫ КЕРДЕ

Бу елгы уку елы фәүкылгадә авырлыклар эчендә башланадыр. Мөгаллимнәремезнең бик күбесе гаскәри хезмәткә алынганга, бик күп мәктәпләремез мөгаллимсездер. Мөгаллимнәремез йитешерлек дәрәҗәдә булмаганга, алар да мөгаллимнәр урынын тутырырлык түгелдер.

Аның өстенә мөгаллим вә мөгаллимәләрнең мәгаше һаман әле әүвәлге елларның тормышына каратып куелганга, хәзерге кыйммәтчелек заманында көн кичерергә йитәрлек түгелдер. Шуның өчен мәктәп тирәсенә яңгы мөгаллимнәр җыю түгел, искеләрне — мәктәп исе белән чыныгып беткән мөгаллимнәрне

тотып тору да фәүкылгадә авырдыр. Шуның өстенә әле тагы китабы, кәгазе, карандашы, каләме дә йитмәгән кебек, дәрес китапларымыз да азлык итәчәктер.

Сугыш башланганнан бирле кәгазь дүрт йөз процент кыйммәтләнгәч, матбага эшчесенең саны җитмеш биш-сиксән процент азаю бәрабәренә хакы йөз илле процент үскәч, татар китабы дөньясы тәмамы белән эшеннән тукталды. Елына меңгә кадәр яңгы төрле китаплар нәшер итә торган Идел буе китап базары, 15нче елдагы кебек, күп булса ун-унбиш китап мәйданга куя алды. Елына өч-дүрт йөз төрле мәктәп китаплары бастыра торган Идел буе матбугаты 16 нчы елның эчендә бик күп булса биш-ун яңгы китап бастыра алды.

Шуның өчен, дәрес башланыр-башланмас, китап ачлыгы күзгә ташланачактыр, бу елгы уку елында үзенең каты хөкеме астында шул татар мәктәбен кысып киләчәктер.

Мәктәпнең, бер тарафтан, мөгаллимгә ачлыгы, икенче тарафтан, китапка туймавы мәктәпләрнең эчке тормышына, балаларымызның тәрбиясенә бик зур тәэсир ясаячактыр.

Балаларымызның тәрбиясе бу елгы ел эчендә элгәрегегә караганда күп ким булачактыр. Алган мәгълүматлары элгәрегегә караганда бик күп мәртәбә аз булачактыр. Ул гына да түгел, китап базарында әүвәлдәгечә ярарлык, фән, тәрбия ягыннан бик үк начар табылмаган китаплар бик тиз алынып беткәнгә, ун ел эчендә начарлыклары катгый булып, мәктәптән сөрелгән ташландык китаплар мәктәпкә барып керәчәктер. Мәктәпнең тәдриҗи сурәттә эчке ягыннан үсеп барган бер вакытында мәктәпне артка таба чигәчәктер. Менә бу фәүкылгадә авырлыклар бетмәсә, уку елында үзенең авыр хөкеме астында берничә йөз мең татар баласын изәчәктер.

Нишлисең, сугыш вакыты, фәүкылгадә сугыш вакыты, безнең мәктәпләрнең дә болай начар баруы фәүкылгадәлек эчендәге бер фәүкылгадә генәдер дип үзеңне-үзең җуатырга, әлбәттә, мөмкин. Ләкин бу фәүкылгадәлекнең сәбәбе сугыштан түгелдер. Безнең халкымызның, безнең аңлы дигән кыйсемемезнең үзенең киләчәген аңламавында, үзенең газиз баласының кадерен, кыйммәтен белмәвендәдер.

Безнең бөтен тарихымыз эчендәге фаҗигамез булса, ул да —балаларымызның гаилә эчендәге кыйммәте юклыгы, балаларымызга киләчәкнең агалары дип карый белмәвемездер. Хосусән баласына әһәмият бирмәү — сәүдәгәр сыйныфында искиткеч дәрәҗәдә таралган бер авырудыр. Сәүдәгәр сыйныфы үзе белән бергә углын кибеткә алып чыгарлык дәрәҗәгә йиткәнчә, кызы, тәрәзә төбенә утырып, үзеннән-үзе, мөстәкыйлән сагыз чәйнәрлек, гайбәт сатарлык булганча, берәр мәктәпкә йибәреп укытадыр. Баланың күз алдыннан китеп торуына бераз дикъкать итәдер. Ләкин шунда баланың ни дәрәҗәдә укытылуын, баланың нинди тәрбия алуын, нинди юлга таба борылуын хәтеренә китереп тә карамыйдыр.

Укыймы? Укый. Ни укый? Ничек тәрбия ителә? Нинди тормышка хәзерләнә? Аның анда эше юк. Фәкать артык расход чыкмасын...

Анысы да саранлыгыннан да түгел. Ләкин ул баласын укытуны эш дип карамаганга, аның сәүдәгәр башы андый-мондый «юк-бар эшкә» акча түгәргә, әрәм итәргә яратмый, шуның өчен иң бай гаиләләрдә — фамилиясенең сәгадәте өчен унар меңен кызганмаган өйләрдә дә иң газиз бер баланың тәрбиясенә сарыф ителәчәк сума абыстайның бер мәртәбә кунак мәҗлесенә тоткан расходы кадәре була алмыйдыр. Абыстайның бер мәртәбә «күңел ачкан» вакытында ычкындырган акчасына йитә алмыйдыр.

Шуның өчен дә безнең сәүдәгәр сыйныфындагы байлык, бездәге тиҗарәт йортлары, бу көн бар, иртәгә юк булып, бабадан — балага, атадан анага калу кебек озын гомерлелек катгыян юктыр.

Шуның өчен бездә сәүдәгәр сыйныфы, баерак кыйсем бүлегемез халкына хезмәт итә торган нә мулла, нә мөдәррис, нә мөгаллим, нә мөгаллимә, нә тәрәккъкыйпәрвәр бер хезмәтче мәйданга китерә алмагандыр. Бала тәрбиясенең кыйммәтле сәүдәгәр алдында зиярәт тирәсе тотудан да түбән булганда мәктәп-мәдрәсәнең җаны булган, милли тәрбиянең нигезе булган китап базарына ул бер тиенлек тәэсир ясый алмагандыр. Китап базарына сатучы-алучы, табыш эзләүче булып керерлек сәүдәгәрлек тойгысы югары күтәрелмәгән, милли бер хезмәтне бергәләп эшләшим дип аяк басарга үзенең милли бурычын аңларлык балигъ булмаганга, китап базары баштан алып ахырына кадәр ярлы шәкертләр кулында калгандыр, ярлы шәкертләрнең тырышуы, тырмашуы белән тәрәккъкый итә алгандыр, ярлы шәкертләрнең гайрәте, энергиясе аркасында фәүкылгадә авырлыклар, фәүкылгадә кысынкылыклар белән олуг юлга чыгарга хәзерләнгәндер.

Сугыш ун ел кичеккән булса, бәлки, безнең китап базарымыз хәзерге кәгазь кысынкылыгын, эшче юклыгын бик салкын канлылык белән генә каршы алган булыр иде. Ул, бәлки, татар баласын, татар мәктәбен китапсыз калдырмас дәрәҗәдә ныгыткан да булыр иде.

Ләкин бу көн ул аны эшли алмады. Бу көн китап базарының шәкерт капиталы ун, унбиш миллион халыкның мәгънәви азыгын хәзерләп торырга йитмәде, йитмәячәк.

Инде ни булачак?

Китап базарында — кытлык, мәктәп эшемездә — артка чигенү... Сугыш дәвам итсә, китапларымыз беткән кебек, журналларымыз, гәзитәләремезнең дә берәм-сәрәм ябылуы, югалуы мәгълүм. Хәзер милли хәрәкәтемезнең кергән юлы шул. Шуннан тагы ничек килеп чыгачакмыз? Керсә чыга алмаслык шул тар тыкрыктан кем өстерәп чыгарачак?..

— Аны Алла белә.

Ләкин катгый иттереп әйтеп була: бу юлы милли кризисны хәл итәр өчен ярлы шәкертнең капиталы гына, гайрәте генә йитмәячәктер.

Милләтнең икътисадән нык сыйныфы, сәүдәгәре табыш итүдә фәүкылгадә шул елларда үзенең милли бурычын аңласа, үзенең газиз баласының кадере кесәсендәге каралып, майланып беткән керле маркалардан ким түгел икәнен сизсә генә, китап базарына кулын сузса гына, мәсьәлә хәл ителәчәктер. Шул вакытта гына татарның мәгънәви азыгы кирәк вакытында хәзер булып торачактыр. Шул вакытта гына мәмләкәтнең эчендәге, тышындагы кечкенә-кечкенә үзгәрүләр татар баласының тәрбиясез, мәктәбе китапсыз калуына тәэсир итмәячәктер.

Шуның өчен шул сабактан дәрес алып, сәүдәгәр галәме, татарның аңлы дигән байлары үзенең бала-чагасының киләчәктә ни татар, ни рус булып йөрүен күрәсе килмәсә, үзенең бала-чагасының тәрбиясезлегеннән килгән авырлыкларының һәрбер ыңгырашуындагы ләгънәтләре ләхетенә кадәр барып торуын теләмәсә, ул үзенең аталык бурычын үтәргә тиештер.

Шул аталар бергәләп берләшеп үзләренең балаларының укуы өчен, мәгълүм юлда тәрбияле булуы өчен китап базарындагы акчасызлыкны бетерергә тиештер.

Теләсә, табыш итү әсасында, теләсә, мәгънәви азык хәзерләп, киләчәк буын алдында рәхмәт ишетү, дога алу нигезендә булсын, көчле бер китап организациясе, бер нәшере китап ширкәте ясау лязем дер, фарыздыр. Мәсҗед салудан мең мәртәбә артык, руза тотудан, намаз укудан йөз, мең мәртәбә артык саваплы фарыздыр.

Шуның өчен уку елы башланганда, матбугатымызның ун елы тулган бер елында Идел буеның кайсы гына бер йирендә булса да, шундый бер милли организациянең тууын үземезнең эчемездән, үземезнең хәләл малымыздан тууын яһүдләрнең Мәсихен көткәннән көчле бер хис белән көтәмез.

Шул булганда гына, милли тәрбиямез юлга куелачак дип ышанганга, шул милли бурыч эшләнелмәгәндә, Идел буе татарын руслардан алып калу мөмкин түгел дип иман китергәнгә, курку белән өмидтән мөрәккәб бер хис белән көтәмез.

## МӘРХҮМ ИСМӘГЫЙЛЬ БӘК ГАСПРИНСКИЙ

11 сентябрьдә милләтнең бабасы Исмәгыйль бәк Гаспринский җәнабларының вафатына ике ел тулды. Дөньяның тарихында күрелмәгән зур сугыш заманасында татар хәяты мәгънәвисенең иң зур гамиле булган Исмәгыйль бабаның юклыгы гүя сизелмәгән кебек үтте. Сугыш бөтен көчләрне үз тарафына борып алганга, милли-мәдәни хәрәкәтләр гомумән диярлек дәрәҗәдә тукталып киткәнгә, бабаның тавышын, авазын ишетмәенчә яшәүгә эверелде. Бөтен татар гаиләсендә әллә никадәр канлы кайгылар булганга, һәр гаилә йә атасын, йә углын югалтканга, милли бабайның юклыгы шул хосусый кайгылар астында күмелеп калды. Аның исеме әле һаман кыйбланамә булып торса да, аның исеменә муафикъ дәрәҗәдә бер ядкяр әле эшләнмәде. Нә бабаның ядкяре өчен бер-бер зур вәкыф калдырылды, нә бабаның исеме югалмасын өчен әсаслы бер мәктәп салынды, нә бабаның үзе үлсә дә, рухы үлмәсен өчен укучы яшьләргә стипендия ачылды!

Шулай итеп, бабаны олуглавымыз, хөрмәтләвемез әле һаман күңелдә генә калды. Исмәгыйль бәкне баба итеп хисаплавымызның күзгә күренгән шаһиты булырдай бер мөәссәсә дә мәйданга китерелмәде.

Иншалла, Исмәгыйль бәкнең зиярәт шәрифе мәрхүм шагыйремез Габдулла Тукайныкы кебек вәйран булып ятмый торгандыр.

Иншалла, аның рухи шәрифе үзенә ителгән шул илтифатсызлыктан рәнҗеми торгандыр.

Ләкин бабаның иҗтимагый рухы, шөбһәсез, аның мәгънәви угылларының, аның шәкертләренең шулкадәр эшсез, көчсез ятуыннан сыкрый торгандыр. Милли хәрәкәтләремездәге аннан соң туган шул торгынлыкка кашын чытып, чыраен сытып карый торгандыр.

Гафу ит, хөрмәтле баба! Хәзергедәге көндә милли хезмәтчеләремезнең яртысыннан артыгы гаскәрлеккә алынганда, бик күбесе спекуляция белән мәшгуль булганда, синең рухыңны сөендерерлек эш эшли алмыймыз.

Синең утыз ел өстерәгән милли йөгеңне юлы белән тәгәрәтеп алып бара алмыймыз. Анлык көчемез юк. Анлык халкымызның киләчәктәге дәһшәтләрне күрерлек күзе юк. Анлык халкымызның иманы юк.

Тугры, син киткәннән бирле әллә никадәр мәдрәсә, мәктәп ябылды. Әллә никадәр милләт балалары тәрбиясез, мөгаллимсез калды. Ике елда, син киткәннән бирле, синең тудырган матбугат галәменең урыны буш калды. Яңгы бер китап чыкмады. Яңгы бер эш мәйданга килмәде. Яңгы бер гәзитә, яңгы бер журнал тумады. Юлбашчысына халыкның ихтыяҗы мең мәртәбә артса да, мәгънәви азыкның кирәклеге берничә мең мәртәбә үссә дә, «Солдат бәете»нә[1] башка һичбер нәрсә чыкмады.

Рухың тыныч булсын. Бу торгынлык, иншалла, вакытлы гынадыр. Бу торганлык, иншалла, сугыш вакытында гына туган хасталыктыр.

Иншалла, шулайдыр.

Иншалла, синең газиз рухыңа өченче ел дога кылганда, коры фатиха гына кылмамыз. Иншалла, синең кыйммәтеңне белүемезне, сине тануымызны фәгалән исбат итәрмез. Хезмәткә муафикъ ядкярләр тудырган булырмыз.

Иншалла!

Ләкин син, мөкатдәс баба, үзең дә Алладан сора. Агач йөрәкле татар угылларына бабаларының канын бир, дип, шәфәгатьче бул! Мөәллифәтел-колүб, татар зыялыларына иман бир, бабаларындагы кебек таза иманны бир, дип дога кыл!

Бәлки, синең догаң мәкъбүл улыр.

Югыйсә, баба, ун ел, егерме ел үтмәс, синең эшләгән эшләреңне тирес, чүп басар.

Синең кадерле кабереңнең исеме, җисеме югалыр.

Милләт бабасы, шәфәгатьче бул!

«Терек вакытында эшләдем, бурычым бетте» дип, анда, оҗмахта тыныч ятма!

Үлгән йиреңдә эшләп ят.

Син бит җисмәни үлсәң дә, җаның үлмәде. Арма-талма, эшлә!

Мондагы йир йөзендә аяк белән йөри, кул белән тота, күз белән күрә, авыз белән ашый торган рухан үлек татар егетләре өчен эшлә!

Оятлары качкан татар егетләренең оятсызлыгыннан оялып, анда да эшлә!

Үлгән булсаң да эшлә, баба! Синдә генә өмид, эшлә!

## «СҮЗ» ГӘЗИТӘСЕ КОНТОРАСЫННАН

«Сүз» гәзитәсенең хөкүмәт әмере белән ябылуы агентларымыз белән мөгаләмәнең табигый юлында баруын туктатты. Бик күп агентларымыз берлән хисабымыз, алыш-бирешемез бетмәенчә калды. Шуның өчен агентларымызның иске хисапларын тәмамлауларын үтенәмез.

Перевод өчен һәм дә мәктүп өчен адрес:

Гәзитәмезнең конторасы:

Москва, Мещеринское подв., 84.

«Сүз»нең мөштәриләрен яңгы гәзитә белән тәэмин итү мәсьәләсе тиз вакытта хәл ителәчәктер.

«Сүз» гәзитәсенең вәкиле Мөхәммәдгаяз әл-Исхакый.

## ЛАШМАН ХЕЗМӘТЕНӘ КЕРЕРГӘ ТЕЛӘҮЧЕЛӘР

Лашман хезмәтенә алыначак кыргыз, сарт кардәшләремезнең берничә меңе земгор идарәсенә йибәрәләчәге мәгълүм булгач та, земгорның баш идарәсе миңа мөрәҗәгать итеп, мең башлары, ике йөз илле башлары күрсәтергә сораган иде. Мин дә, халыкка хезмәт итәрдәй егетләрне табар өчен, үземезнең җәмәгать хадимнәремезгә мөрәҗәгать итеп, әминиятле, шул халыкның тел-гадәтен белә торган егетләрне тәкъдим итәргә үтенгән идем.

Шуларның ярдәмнәре аркасында земгор дружиналарына егерме-егерме биш кадәр башчылар йибәрттем. Ләкин шул хәбәр гәзитәләргә кергәч, кирәк, хосусый исемемә, кирәк, земгор комитетына[1] гаризалар, телеграмнар килде. Боларның бик күбесенә җаваплар да бирелде, ләкин бәгъзе берәүләре, җавапны көтмәенчә, үзләре Мәскәүгә килә башладылар. Земгорның дружиналарына кирәк кадәр башчылар алынып беткәнгә, бу килгән әфәнделәр вакыт, мал сарыф итеп буш кайтып китәргә мәҗбүр булдылар. Моннан соң да чакырылмаган затлар ышанып килеп йөрмәсеннәр иде һәм дә үзләренең форсатларын югалтмасыннар иде. Чөнки земгорда вакытлы гына башчылар алу тукталды.

Гаризалар, телеграмнар йибәрелгән затларның гаризаларының алынуы хисабы буенча, эшкә яраклы булуы күзгә тотылып, кандидат ителеп языла баралар.

Бу затларның кирәкләре булгач та, йә мәктүб, йә телеграф белән дәгъвәт ителәчәкләрдер.

## ХӘЙРИЯТ ӘҺЛЕНЕҢ ДИКЪКАТЕНӘ

Земгор комитетының вәкилләре белән эшкә алынган сарт, кыргыз кардәшләремезнең торышларын-йөрешләрен карап кайттык. Земгорның әгъзаларыннан инсаниятчә мөгамәләләрен күреп шатланып калдык.

Безнең үтенүемез буенча, кыргыз, сартларга һәр йирдә аерым ашханәләр ясадылар, аларның гадәтләренә муафикъ иттереп ашау-эчүләренә әһәмият бирергә булдылар. Аларның гыйбадәте диния-ләренә һичбер төрле манигъ булмаячакларына вәгъдә бирделәр.

Булган бүлекләрнең һәммәсендә имамнар тәгаен иттердек һәм дә җомга бәйрәмен итәргә рөхсәт бирдердек.

Кыргыз, сарт кардәшләремез рухан тынычланып калдылар. Ләкин дини гадәтләрне үтәр өчен кирәкле булган китап, Коръән һәм дә тәһарәт өчен комганнар юктыр. Земгор даирәсендә боларны алыр өчен махсус акча да юктыр. Шуның өчен хәйрият ияләре шул гарип мөселманнарны хәтерләренә алып, китап, Коръән, намазлык, комган йибәрсәләр, мохтаҗларга тапшырылачактыр.

Әйбер йибәрү өчен адрес:

Москва, Никольская, д. 17. Иногородческое бюро.

Садретдин Максудов, Мөхәммәдгаяз Исхаков.

Башка гәзитәләрнең дә басуын үтенәмез.

## ИСКӘРМӘЛӘР ҺӘМ АҢЛАТМАЛАР

*1915*

5 бит.

**Казыйлык.** «Ил» газетасының 1915 елгы 7 гыйнвар (58 нче) санында «Гаяз» имзасы белән, ахыры (якынча өчтән бер өлеше) кыскартылып (ак урын калдырылып) басылган. Текст шуннан алынды.

«Ил» газетасы 1913 елның 22 октябреннән — Петербургта, 1914 елның ноябреннән 1915 елның мартына кадәр Мәскәүдә чыккан; нашире һәм мөхәррире — Гаяз Исхакый үзе.

Мәкалә Хәсәнгата Габәшинең (1863–1933) Диния нәзарәтендәге (Уфада урнашкан Оренбург Мәхкәмәи шәргыядәге) казыйлык вазифасыннан китүе уңае белән язылган. «Вакыт» газетасы фикеренчә, Х.Габәши яхшы казый булган, гаиләдә рәсемгә, музыкага да каршы түгел, хиҗаб (мөселман хатын-кызларының йөзләрен каплап йөрүе) мәсьәләсе белән шөгыльләнмәгән. Ул казыйлык вазифасын 1912 елдан бирле үтәгән була. Бераздан аның урынына казый булып Благовещенск имамы Салихҗан Урманов сайлап куела.

6 бит.

**Мәүлед бәйрәме**. «Ил» газетасының 1915 елгы 9 гыйнвар (59 нчы) санында «Гаяз» имзасы белән басылган. Текст шуннан алынды.

1915 елда Мәүлед (Мөхәммәд пәйгамбәрнең туган көне) 13 гыйнварга туры килгән. 14 гыйнварда исә Мәскәүнең Татарский мәсҗедендә ястү намазыннан соң мәүлед укылган, имам Габдулла Шәмсетдинов сөйләгән, Әсәдуллаев мәктәбе шәкертләре гарәпчә мәдехләр, санәләр әйткәннәр.

Хатимә Нәзифә язуына караганда («Ил», 1915 ел, 18 гыйнвар), Мәскәүдә беренче мәртәбә уздырылган балалар кичәсендә 250 бала булып, анда, аерым алганда, ир һәм кыз балалар Г.Тукайның «Бәйрәм бүген!», «Фатима берлә Сандугач», «Бала белән Күбәләк», «Аучы белән Куян», «Эт белән Шәкерт» исемле әсәрләрен укыганнар, мөгаллим Миргаяз әфәнде скрипкада уйнаган.

[1] *...балалар кичәсе ясый башладылар...* — шундый балалар кичәсе, мәсәлән, Мәүлед уңае белән Казанда «Шәрекъ клубы» залында 1914 елның 25 һәм 27 гыйнварларында (ике көн) үткәрелгән. 1915 елдагысы 14 гыйнварда булган.

[2] *«Хатын-кыз җәмгыяте хәйриясе» ... әдәби кичә ясарга тотынды.* — «Ил» газетасында (8 гыйнвар, 58 нче сан) Илһамиянең «Балалар кичәсенә дәгъвәт» исемле язмасы басылган. Анда балалар кичәләренең әһәмияте ассызыклап әйтелә. Аерым алганда: «Һәркем бу кичәгә үзенең баласын җибәреп, бердән, үземезнең шундый зур булган бәйрәмемез берлән таныштырырга, икенчедән, баласының күңелен ачып гомерендә онытылмаслык бер күңелле хатирә калдырырга тырышса иде», — диелә.

8 бит.

**«Сәйяр» труппасы хакында.** «Ил» газетасының 1915 елгы 9 гыйнвар (59 нчы) санында имзасыз басылган. Текст шуннан алынды.

Беренче бөтендөнья сугышы башлангач, Казанның «Шәрекъ клубы»нда эшләп килгән «Сәйяр» труппасы бинасыз кала: бина хәрби лазаретка әйләндерелә. Тамак авыруы көчәюе сәбәпле, Габдулла Кариев да труппада уйнауны киметә, репертуар мәсьәләсе дә читенләшә, кайбер артистлар труппадан китә башлыйлар. Труппа яшәешендә килеп туган мондый авыр хәлләр турында вакытлы матбугат битләрендә дә хәбәрләр күренә. Әмма «Сәйяр» барыбер таркалмый, аның Габдулла Кариев җитәкчелегендәге изге эшчәнлеге 1918 елга кадәр дәвам итә.

[1] *Җәлал Байкин* (1886–1954 елларда яшәгән) — соңыннан да артист, режиссер буларак сәхнә эшчәнлеген дәвам итте, Әстерханда татар театрын оештыручыларның берсе булды.

[2] *Сара ханым* — Сара Байкина (1895–1972), актриса, РСФСРның атказанган артисткасы.

[3] *...әллә никадәр исемнәрдә «труппалар» тәэсис ителделәр.* — Мәсәлән, 1912 елда Уфада беренче татар артисткасы Сәхипҗамал Гыйззәтуллина-Волжская — «Нур» труппасын, 1914 елда Әстерханда Зәйни Солтанов «Татар артистларының драма ширкәте» дип аталган труппа төзи. Бу елларда татарлар яшәгән күп төбәкләрдә драма әсәрләрен сәхнәгә кую ешаеп китә.

9 бит.

**Безнең хәлләр (Сугыш Русиянең бөтен...).** «Ил» газетасының 1915 елгы 11 гыйнвар (60 нчы) санында «Гаяз» имзасы белән басылган. Текст шуннан алынды.

[1] *Сугыш* — сүз 1914 елның 1 августында (яңа стиль белән) башланып киткән Беренче бөтендөнья сугышы турында бара. Надир Дәүләт язуына караганда (Русия татарларының милли көрәш тарихы (1905–1917). — Казан: «Милли китап», 1998. — 192 б.), сугыш елларында бер миллионнан артык русияле мөселман сугышка алынган, аларның яртысы исә татар һәм башкортлардан булган.

[2] *...булмавы да табигыйдер*. — Моннан соң шактый урын буш калдырылган.

[3] *Башка шундый вазифамызга...* — моннан соң газетада 20 юл чамасы урын ак калган (текст кыскартылган).

[4] *Дума ачылыр көннәр җитә*. — Россиянең IV Дәүләт Думасы үз эшен 1915 елның 27 гыйнварында яңарткан.

[5] *...төшенергә вакыты килмәдеме*? — Газетада моннан соң 10 юл чамасы урын буш калган (текст кыскартылган).

10 бит.

*** **(Мәскәү кебек мөселманы**...). «Ил» газетасының 1915 елгы 16 гыйнвар (62 нче) санында имзасыз гына басылган. Текст шуннан алынды.

Бу мәкалә «Мәскәүле Гъ.Къ» имзасы белән шул ук санда чыккан түбәндәге хатка (мөрәҗәгатькә) «Ил»нең (газета редакциясенең) җавабы рәвешендә язылган:

«Хөрмәтле Гаяз әфәнде!

Түбәндәге сәальләремә могтәбәр «Ил» гәзитәсенең бер почмагында җавап бирүеңезне үтенәм.

Безнең Мәскәүдә шактый күп кенә мөселман агай-эне торадыр. Боларның шактый зур кыйсеме гаилә белән торучы булсалар да, арада өйләнмәгән егетләремез күбрәктер. Менә шул гаилә берлән торганнарында бер-берсенә барып килеп йөрү гадәте бик аз булса да, егетләр өчен барачак-киләчәк һичбер урын юктыр. Безнең мөселманнарда чакырмаенча килү-китү гадәте юк. Берсе-берсе барса, өй хуҗасы куркып киткән төсле була. Кәефе бозыла, эч пошканнан күңел ачарга барган булсаң, тагы кәефең китеп тиз-тиз качасың. Хосусән яшьләремез — өйләнмәгән егетләремезнең хәле бик мөшкел була. Үземезнең мөселман арасында борын төртәчәк бер урын таба алмыйлар. Көн буе сату итеп, өйгә кайтып аш ашагач та, бер-ике сәгать буш вакыт кала. Шуларны егетләр ничек үткәрсеннәр, картлар «намазда зикер тәсбихтә торсыннар» диләр. Ләкин егетләр ни өчендер шуны булдыра алмыйлар. Һәм дә бик күп вакытта эч пошканнан буш вакытларын ресторанларда үткәрәләр, биллиардлар, карталар уйнап, башларын зәһәрлиләр.

Безнең шул тормышымыз яхшымы? Шулай баруымыз табигыйме? Әллә моны төзәтергә тиешме? Һәм дә ничек?»

[1] *Мәскәүдәге «Шәрекъ клубы»ның...* — андый исемдәге клубның Мәскәүдә ачылуы турында мәгълүматлар табылмады. 1907 елдан Казанда «Шәрекъ клубы» эшли.

12 бит.

**Мәскәү, 18 гыйнвар.** «Ил» газетасының 1915 елгы 19 гыйнвар (63 нче) санында «Гаяз» имзасы белән басылган. Текст шуннан алынды.

[1] *Ерзиннар мәктәбе* — Мәскәү сәүдәгәре һәм эшмәкәре Салих Йосыф улы Ерзинның (1833–1911) уллары белән берлектәге фирмасы ефәк тукыма һәм мамык белән сәүдә иткән, алар мәдәни эшләргә дә актив катнашканнар.

[2] *Әсәдуллаев мәктәбе* — Мәскәү эшмәкәре Әсәдуллаев акчасына салынган мәктәп.

14 бит.

**Дума ачылды.** «Ил» газетасының 1915 елгы 28 гыйнвар (67 нче) санында «Гаяз « имзасы белән басылган. Текст шуннан алынды.

«Ил» газетасының өч көн алда — 25 гыйнварда чыккан 66 нчы санында «Гаяз»ның «Отпавшийлар» исемле мәкаләсе басыласы булган (газетаның «эчтәлеге»ндә мәкаләнең исеме аталса да, ул урнаштырыласы урын цензура таләбе белән ак килеш калган, әмма имзасы сакланган).

[1] *...июль числосында...* — 1914 елның июле турында сүз бара.

[2] *...юллар өчен тикшерү...* — моннан соң 3 юл чамасы урында текст басылмаган (ак килеш калдырылган).

[3] *...депутатларымыз, саннары никадәр аз булса да...* — IV Дәүләт Думасына мөселманнардан 7 кеше сайланган була.

[4] *Садыйк Галикәев, Сөләйман Аитов, Мөхәммәтҗан Кәримовларда... Исмәгыйль Үтәмишевтә ясалган тентүләр...* — биредә сүз завод хуҗасы, сәүдәгәр һәм җәмәгать эшлеклесе Мөхәммәтсадыйк Галикәев (1847–1919), сәүдәгәр һәм эшмәкәр Сөләйман Аитов (1862–1922), Казанда китап сату фирмасы һәм кинематографы хуҗаларыннан Мөхәммәтҗан Кәримов һәм сәүдәгәр Исмәгыйль Үтәмишевләр турында бара.

16 бит.

**Карс мөселманнары.** «Ил» газетасының 1915 елгы 4 февраль (69 нчы) санында «Гаяз» имзасы белән басылган. Текст шуннан алынды.

Язмада Кавказ таулары артындагы Карс төбәге мөселманнары турында сүз бара. XVI гасырдан башлап — Госманлы дәүләте (Төркия), 1878 елдан Россия составында була. Беренче бөтендөнья сугышы вакытындагы Төркия һәм Россия арасындагы канлы бәрелешләрдән монда яшәүче халыклар, аеруча мөселманнар, күп җәфа күрәләр. Мөселманнар яшәгән урынчылыкның губернаторы, ярдәм итүне үтенеп, Россия мөселманнарына мөрәҗәгать иткән дә була. (Газетада Карс губернаторының Мәскәү мөселманнарыннан («Баку мөселман җәмгыяте хәйриясе» рәисе дә) Мирза Әсәдуллаевка сугыштан зарар күргән, мохтаҗ мөселманнарга ярдәм күрсәтергә өндәгән телеграмма җибәрүе язылган.)

Карс өлкәсе 1918 елда Төркиягә кайтарыла.

18 бит.

**Безнең хәлләр (Тарих көпчәгенең әйләнүе...).** «Ил» газетасының 1915 елгы 6 февраль (70 нче) санында «Гаяз» имзасы белән басылган. Текст шуннан алынды.

[1] *...казыйлык мәсьәләсенең бер нәтиҗәгә ирешмәенчә туктавы...* — казый булып Благовещенск имамы Салихҗан Урманов сайлап куелуны Гаяз Исхакый хупламаган булса кирәк. («Казыйлык мәсьәләсе» исемле мәкаләгә язылган аңлатма һәм искәрмәләрне карагыз.)

[2] *...Карс мөселманнары хәленең бертөрле адәм гакыллы юлга куела алмавы...* — Россиянең төрле җирләрендә халыктан, аерым алганда мөселманнардан, акча җыю, җибәрү кебек гамәлләр ясалса да (берара «Ил» газетасының үзендә дә кемнең, кайда күпме акча тапшыруы турында хәбәрләр дә басылган[1]) , бу эш киң масштабта алып барылмаган, билгеле.

20 бит.

**Мәскәү, 8 февраль.** «Ил» газетасының 1915 елгы 8 февраль (71 нче) санында «Гаяз» имзасы белән басылган. Текст шуннан алынды.

23 бит.

**Мөселманнарның хәле вә депутатларымыз.** «Ил» газетасының 1915 елгы 11 февраль (72 нче) санында «Гаяз» имзасы белән басылган. Текст шуннан алынды.

[1] *Чихәнкили* — Аркадий Иванович Чкенкели (1874–1959), Карс, Батуми төбәкләреннән, Сухуми округыннан IV Дәүләт Думасы депутаты, социалист, грузиннарның демократик хәрәкәте лидерларыннан, 1921 елдан соң эмиграциядә яшәгән.

[2] *Хәрбия министры* — 1915 елда Россиянең хәрбия министры вазифасын В.А.Сухомлинов үтәгән.

[3] *Горемыкин* — Иван Логинович Горемыкин (1839–1917), Россиянең дәүләт эшлеклесе, 1906 елның апрелендә Министрлар Советы Рәисе.

[4] *...тәүсыя иткәне гәзитәмезнең хәбәр кыйсемендә бар.* — «Ил» газетасының шул ук санында басылган «Кавказда мөселманнарның хәле» исемле хәбәрдә «Дума әгъзасы Чихәнкили Министрлар башлыгы Горемыкинны зиярәт итеп, аның белән Кавказдагы зарарланган мөселманнар турысында күп сөйләшеп утырды. Горемыкин Чихәнкилинең заявлениесен тыңлаганның соңында, аңа Кавказ мөселманнары хакында олуг гаскәри мәэмүрләргә доклад ясавын тәүсыя кылган» диелә.

[5] *Гәзитәбезнең 71 нче номерында хәбәр кыйсемендә бар.* — «Ил» газетасының бу санында Батумидан китерелгән хәбәрдә мондагы бөтен мөселманнар исеменнән Грузия экзархына (баш рухани) вәкилләр килеп, үзләренең дин ягыннан кардәшләре — мөселман аҗарлар һәм көрдләрнең кылган эшләренә ачынып, аңардан Россиягә тугрылыклы булуларын олы чиновникларга ирештерүен үтенүләре әйтелә. Экзарх, мөселманнарны бик мәрхәмәтле сурәттә гафу итеп, аларның бу сүзләрен Россияне Кавказдагы наместнигына белдерәчәген вәгъдә итә. Әлеге вәкилләр солдатларга өләшү өчен экзархка күп бүләкләр дә тапшырганнар.

[6] *Дагъстан мөселманнары националист Ковалевскийга мөрәҗәгать иткәннәр...* — сүз ике томлы «Кавказ» һәм «Русский национализм и национальное воспитание в России» кебек китаплар авторы профессор П.И.Ковалевский турында бара булса кирәк.

[7] *«Вольный экономический общество»* — 1765 елда императрица Екатерина II хуплавы белән оештырылган «Вольное экономическое общество» («Ирекле икътисади җәмгыять») турында сүз бара. Соңгы елларда ул Россиядә яңадан эшли башлады.

24 бит.

**Бу көннең бурычлары**. «Ил» газетасының 1915 елгы 13 февраль (73 нче) санында «Гаяз» имзасы белән басылган. Текст шуннан алынды.

[1] *...утызар, кырыгар миллионлы капиталистларымыз...* — утызар, кырыгар миллион сум акча белән эш итә торган капиталистлар турында сүз бара.

[2] *...меңнәр, йөз меңнәр урта дәрәҗәдәге сәүдәгәрләремез...* — мәкаләдә меңәр, йөз меңәр сум акча белән эш иткән сәүдәгәрләрнең дә Карс мөселманнарына ярдәм итәргә тиешлеге искәртелә.

[3] *...мохтаҗлыкта калды.* — Моннан соң газетаның сигез-тугыз юлы ак килеш чыккан (цензура таләбе белән текст кыскартылган).

[4] *Петербургтагы җәмгыятьләр съездының...* — 1909 елда иганәчелек белән махсус шөгыльләнә торган оешмаларның Бөтенроссия берлеге (Всероссийский союз учредителей обществ и деятелей по общественному призрению) оештырыла, 1914 елда исә аның чираттагы съезды уздырыла. Биредә сүз шуның турыда бара булса кирәк.

26 бит.

**Җавапларым.** «Ил» газетасының 1915 елгы 15 февраль (74 нче) санында «Гаяз» имзасы белән басылган. Текст шуннан алынды.

[1] *«Исмәгыйль бәк вә Зөһрә Гаспринскийлар» диген фельетоннарыма ...* — Г.Исхакыйның «Исмәгыйль бәк, Зөһрә ханым Гаспринскийлар» исемле мәкаләсе «Ил» газетасының 1914 елгы 14, 17, 21, 24 ноябрь һәм 5 декабрь (41, 42, 43, 44 һәм 47 нче) саннарында «Гаяз» имзасы белән басылган (тексты Г.Исхакый «Әсәрләр»енең 6 нчы томына урнаштырылды).

[2] *Ибраһим абзый Акчурин җәнабларының ... ачык хатын ...* — Ибраһим Акчуринның (1859–1933) «Идарәгә мәктүб»е «Вакыт» газетасының 1914 елгы 20 декабрь (1660 нчы) санында урнаштырылган. Бу мәктүп уңае белән «Дин вә мәгыйшәт» журналы (1915 ел, 1 нче сан) болай дип язды: «... Гаяз Исхаков тарафыннан бер фельетон языла килде. Занларынча, әдип саналган бер кешенең каләменнән аккан сүзләрне вә «Ил» газетасы кебек зур кешеләр (!) тарафыннан чыккан бер гәзитәдәге сәтырларны безем татар яшьләре тарихи бернәрсә дип укыдылар.

Шул фельетонда язылган сүзләр арасында Гаспринский вә хатыны хакында байтак ялган вә ялалар барын фельетонда мәүзуг мәсьәлә булган Акчуриннар фамилиясеннән Ибраһим Акчурин Исхакыйга уфкәли-уфкәли бәян итә; үлгәннәр хакында бундый ифтира вә терек булганым хәлдә минем өсткә бундый гайбәтләр өймәскә кирәк иде, дип тәнбиһ итә. Гаяз кеби бер сыйныф халыкның югары санаган кешеләре ул кадәр яла вә уйдырмалар язарга тиеш түгел иде дия вә «Вакыт»жа озын мәкалә язып Гаязны вә «Ил» идарәсен каләм сабы берлән борынга кыйный».

[3] *«Сөембикә»нең 7 нче номерында ... Мәхбүбҗамал ханым Акчурина кузгатканга...* — язучы, мәкаләләр, очерклар авторы Мәхбүбжамал Акчуринаның (1869–1948) «Зөһрә ханым турысыннан» исемле мәкаләсе «Сөембикә» журналының 1915 елгы 7 нче (1

февраль) санында басылган. М.Акчурина бераз соңрак «Вакыт» газетасының 1915 елгы 5 март (1718 нче ) санына «Мөхәммәтгаяз әфәнденең җавапларына җавап» та урнаштыра. (Газета «Кирәк, бу мәкалә вә, кирәк, моннан элек басылган Ибраһим Акчурин мәкаләләре хакында бу мәсьәләгә идарә битарафтыр» дигән искәрмә дә ясаган.)

[4] *Зөябашы* — Сембер губернасындагы авыл (хәзерге исеме Иске Тимошкино). Атаклы сәүдәгәр һәм эшмәкәр Акчуриннарның сукно фабрикалары беренче башлап шушы авылда барлыкка килгән.

[5] *«фәзаилешшөһүр»че* — Җамалетдин Бикташи тарафыннан язылган «Фәзаилешшөһүр» китабы мәктәп-мәдрәсәләрдә дәреслек булып йөргән. (Беренче тапкыр Казанда 1854 елда басыла.)

[6] *Мәсләк низагы да ясадым.* — Бу урында Г.Исхакый «Таң йолдызы» газетасында эшләгән (берара редактор да булып торган), язышкан вакытларын истә тота. Әлеге газетасының 1906 елгы 3 август (24 нче) санында басылган «Тәрҗеман» вә «Вакыт» гэзитәләренә җавап» исемле, «Чыңгыз» имзалы мәкаләсендә Гаяз Исхакый (ул вакыттагы «таңчы») Исмәгыйль Гаспринский турысында: «Фатих (ягъни Фатих Кәрими) социализмнан никадәр хәбәрсез булса, «Тәрҗеман» бабай да шулкадәр белемсез икән. Безнең карт мөхәрриmeз булып торган илле-алтмыш яшьлек бер язучыга шулкадәр наданлык, шулкадәр өстән карау ниһаять дәрәҗәдә оят, соң дәрәҗәдә көлке вә бөтен матбугатымыз өчен хурлыктыр. Фатихның «Ислам вә социализм» дигән мәкаләсе белән берлә «Тәрҗеман»ның шулкадәр Аурупа лисаннарының берсенә тәрҗемә кылынса, аларның ибтидаи мәктәп шәкертләре дә бу мәкаләләрнең мәгънәсезлегенә гаҗәпкә калырлар иде», — дип язган иде.

[7] *Хәсән абзый Акчурин* — 1866–1916 елларда яшәгән эшмәкәр, җәмәгать эшлеклесе, меценат (мәгариф эшенә матди ярдәмнәр күрсәткән, бай китапханәсе булган). Аның турында Риза Фәхретдин истәлеге бар.

[8] *Фатыйма ханым Шакулова* — Хәсән Акчурин хатыны, 1868–1939 елларда яшәгән. Вакытлы матбугат битләрендә язмалары да күренә. Шуларның «Хатага дикъкать» исемле берсе «Сүз» газетасының 1916 елгы 1 апрель (40 нчы) санында басылган. Түбәндә аның тексты тулысынча китерелә:

«31 нче номер «Сүз»дә «Ислам вә мәгарифчеләр» дигән фельетонда халыкны ике кыйсемгә аерып, берсенә — тәрәкъкыйпәрвәрләр, икенчесенә карагруһлар исемен бирә. Ләкин бу соңгы исем бирүе яңлыш, һәм бондый яңлышны матбугатта тикшермәенчә вә пешерелмәенчә калдыру тиеш түгел. Чөнки тәрәкъкыйпәрвәрләргә каршы мөхафәзәкәрләр була. Һәм бу ике кыйсем — икәве дә игътикадлы кешеләр. Адәмдә игътикад мөхтәрәм хәл һәм аларны карагруһлар дип әйтеп булмый. Карагруһларда игътикад булу ихтималы юк.

Хикмәт ага әйтә:

«Русия татарларының тәрәкъкыйпәрвәрләр яшь буыны хәят байрагын кулына тотып мәдәният дөньясына аяк басканга әле гасырларча вакыт үткәне юк. Аның тарихы бик кыска, ул дөньяга килүе берлән, хәят байрагын күрсәтүе берлән татар эчендә тәназыгы бәка мәйданга килде. Бу көрәшү, бу тартышуда халык табигый сурәттә икегә аерылып китте. Берсе «мәгърифәт, мәдәният, хәят» диде. Шуның өчен тырышырга тотынды. Китапка, әдәбиятка ябышты. Ысуле җәдидне уйлап чыгарды. Шуны бөтен милләткә кабул иттерергә тырышты. Болар тәрәкъкыйпәрвәрләр иде. Икенче кыйсем, искелек, кабер-ахирәткә башка һәммәсе дә хәрам, дөнья кяферләр өчен генә яратылган, дип фәтва чыгарды. Бу кыйсем карагруһлар кыйсеме иде, ди.

Яңлыш шунда: кешеләр кабергә ышана, ахирәт көненә, кемнең хәрамы бар, искесе бар, димәк, аның игътикады бар. Игътикадлы кешеләрдән карагруһ булу ихтималы булмаган шикелле үк, карагруһларда игътикад булу ихтималы юк».

*Фатыйма Шакулова*

[9] *Вильһельм* — 1888–1918 елларда Германия императоры, Пруссия короле булган Вильһельм II (1859–1941).

31 бит.

**Истанбул вә бугазлар**. «Ил» газетасының 1915 елгы 20 февраль (76 нчы) санында имзасыз басылган (икенче яртысы кыскартылган). Текст шуннан алынды.

Газетаның 22 февраль (77 нче) санында «Истанбул һәм Чанак кальга бугазларын ачу вә ябу тарихы» исемле имзасыз язма урнаштырылган. Чанак кальга — Европаны Кече Азиядән аерып тора торган Дарданелл бугазы, Мәрмәрә (Мрамор) диңгезен Эгей диңгезе белән тоташтыра. 1915 елның 19 февралендә инглиз һәм француз эскадрасы Чанак кальганы кулга төшерү, Төркияне сугыштан чыгару, Кара диңгез аша Россия белән бәйләнешләрне торгызу максатында Төркия фортларына һөҗүм итә. Газетада «Дарданеллның тупка тотылуы хакында» исемле хәбәр дә басылган.

[1] *Харисҗия министры Сазонов* — Россиянең дәүләт эшлеклесе һәм дипломаты С.Д.Сазонов 1910–1916 елларда Тышкы эшләр министры була, бу вакытларда Россиянең тышкы сәясәтендә Англия (Бөекбритания) белән якынлашу идеясе ачык чагылган.

[2] *54 нче елда башланган Кырым сугышы* — 1853–1856 еллардагы сугыш истә тотыла. Башта Россия белән Төркия арасында барып, 1854 елда аңа Төркия ягыннан Бөекбритания һәм Франция килеп кушыла. 1856 елда Парижда ясалган килешү белән тәмамлана.

[3] *77 нче елның сугышы* — Босния һәм Герцеговина халыкларының Төркия хакимлегенә каршы күтәрелешеннән файдаланып, Балкан ярымутравында йогынтысын көчәйтү максатында Төркия белән Россия арасында 1876 елда башланган бу сугыш 1878 елның февралендә Сан-Стефанода кул куелган солых килешүе белән тәмамлана.

[4] *Бәхре сәфид* — Урта диңгез (Ак диңгез дип тә йөртелгән).

32 бит.

**Милли уку йортларымыз.** «Ил» газетасының 1915 елгы 20 февраль (76 нчы) санында «Гаяз» имзасы белән, бераз кыскартылып (газетада якынча биштән бер өлеше ак калдырылып) басылган. Текст шуннан алынды.

[1] *«Кунут» догасы берлән «Колһуаллаһ» өйрәнеп ...* — «Кунут» догасы — намаздан соң укыла торган дога («Иман шарты»ннан), «Колһуаллаһ» — Коръәннең 112 нче сүрәсе («әл-Ислах»).

[2] *...әт-тәхыятьтән аерып, күмер казырга ...* — намазга тезләнеп утырып укый торган догадан аерып, ташкүмер казып чыгара торган шахталарга китү турында сүз бара.

[3] *...тиештер, ляземдер...* — моннан соң 27 юллык текст басылмаган, урыны ак калдырылган.

[4] *Казанда ... кызлар гимназиясе* — Фатиха Аитова (1899–1942) тарафыннан Казанда 1909 елда ачылган кызлар мәктәбе 1916 елда Татар кызлары гимназиясе итеп үзгәртелә (гимназия ачуга рөхсәт 1915 елда бирелгән була).

[5] *...каршы алыныр иде.* — Моннан соң 4 юллык текст басылмаган, урыны ак калдырылган.

[6] *...яңгы мәгариф назыйре алышынгач...* — 1915 елда Россиянең мәгариф министры итеп билгеләнгән Павел Николаевич Игнатьев (1870–1926), либераль буржуазия таләпләренә юл куеп, Россиядә урта мәктәпләргә реформа ясарга, мәҗбүри башлангыч белем бирүне кертергә омтыла, ләкин патша хөкүмәте боларга каршы килә, шунлыктан 1916 елда аңа отставкага китәргә туры килә.

36 бит.

**Сәясәт йөреше**. «Ил» газетасының 1915 елгы 25 февраль (78 нче) санында имзасыз басылган. Текст шуннан алынды.

[1] *...яңгыдан Бизанс мәмләкәтен тудыру ... көтәләр иде.* — Византия империясе (Көнчыгыш Рим империясе), Рим империясенең таркалуы нәтиҗәсендә IV гасырда барлыкка килеп, XV гасырга кадәр яши. Башкаласы Константинополь 1453 елда төрекләр тарафыннан яулап алына, һәм Византия яшәүдән туктый.

[2] *Баш министр Винизилус* — Грециядә 1909 елда хакимияткә килгән либераль партия җитәкчесе Элефтериос Венизелос (1864–1936) турында сүз бара. Ул Грециянең биш мәртәбә премьер-министры вазифасын үти, Беренче бөтендөнья сугышы вакытында сугышка Антанта ягыннан торып катнашу ягында була.

[3] *...Беренче сугышны хәзерләгән, Икенче Балкан сугышын очлап чыгарган...* — Балкан союзы (Болгария, Сербия, Греция, Черногория) белән Төркия арасындагы Беренче Балкан сугышы 1912 елның 9 октябреннән 1913 елның 30 маена кадәр барган һәм, 1913 елгы Лондон килешүе нәтиҗәсендә Төркия үзенең Европадагы биләмәләрен (Стамбул һәм Көнчыгыш Фракиянең зур булмаган өлешен генә үзендә калдырып) югалткан. 1913 елның 29 июненнән 18 августына кадәр дәвам иткән Икенче Балкан сугышы исә Болгария белән Греция, Сербия, Черногория (соңыннан боларга Румыния һәм Төркия дә кушылып китә) арасында була. Нәтиҗәдә Болгария җиңелә. Үз җирләренең бер өлешен Румыниягә, Төркиягә, Сербиягә бирергә мәҗбүр була. Бу сугышлар халыкара каршылыкларны кискенләштерә, Беренче бөтендөнья сугышы башланып китүне тизләтә.

[4] *Аталар диңгезе* — Эгей диңгезе.

[5] *Дәдәагач лиманы* — Эгей диңгезенең төньягындагы култык, анда Александруполис (элекке исеме — Дедеагач) порты урнашкан. Хәзер бу тирә — Греция территориясе.

40 бит.

**Карс мөселманнары (Карс мөселманнарына ярдәм...).** «Ил» газетасының 1915 елгы 1 март (80 нче) санында «Гаяз» имзасы белән басылган. Текст шуннан алынды.

Мәкаләдә чагылыш тапкан мәсьәлә Г.Исхакыйның «Карс мөселманнары» («Карс тирәләрендә сугыш...») дигән язмасында очрады (аның искәрмә һәм аңлатмаларын карагыз).

[1] *...Идел буе мөселманы хәлле-хәленчә катышты.* — Карс мөселманнарына ярдәмгә хәтта Финляндия мөселманнары да 50 сум 50 тиен җыеп тапшырганнар.

42 бит.

**Бабайлар туфрагы**. «Ил» газетасының 1915 елгы 27 февраль һәм 6 март (79 нчы һәм 82 нче) саннарында (соңгысында кыскартылып, өч урын ак калдырылган; алар якынча текстның уннан бер өлешен тәшкил итә) «Гаяз» имзасы белән басылган. Текст шуннан алынды.

Газетаның 25 апрель (79 нчы) санында Симферопольдән алынган хәбәрдә немецларның җирләрен сата башлаулары әйтелә. Немец колонистлары җирләрен татарларга дисәтинәсен 140 сумнан саткан**.**

[1] *...форсаттан файдалансалар иде.* — Бу урында текстның 27 февральдә чыккан өлеше тәмамлана.

[2] *...бер-бер банк ярдәм итәме?..* — Моннан соң ике юллык урын буш калдырылган.

[3] *...укмашыңыз да алыңыз.* — Газетаның беркадәр өлеше кисеп алынган (дефектлы).

[4] *...сез аңгарга мохтаҗ түгелсез.* — Беркадәр урын буш калдырылган.

46 бит.

**Икенче адым.** «Ил» газетасының 1915 елгы 11 март (84 нче) санында «Гаяз» имзасы белән басылган. Текст шуннан алынды.

[1] *Гәзитәмездәге хәбәрләр кыйсемендә.* — Газетаның «Дахили хәбәрләр» өлешендә «Ил» газетасы исеменнән «Хосусый сурәттә алган мәгълүматымызга күрә, Баку мөселман «Җәмгыяте хәйрия»се Карс областенда сугыштан зарарланган мөселманнарга ярдәм өчен үзеннән махсус бер һәйәт йибәрәчәк. Бу һәйәттә мөселман докторлар да булып, алар һәйәтнең сәхия җәһәтен идарә итәчәктер...» диелгән.

[2] *...«Икъбал» гәзитәсеннән күчерелеп бер мәктүб басыладыр.* — 1913 елның мартыннан 1915 елның апреленә кадәр Бакуда чыккан бу газетада әлеге мәктүб «Сугыштан зарарланган мөселманнар» исеме белән урнаштырылган.

49 бит.

**Габдулла Кариев.** «Ил» газетасының 1915 елгы 13 март (85 нче) санында имзасыз басылган. Текст шуннан алынды.

Газета чыккан көн (13 март) Казанның Зур театры бинасында Габдулла Кариевның бенефисы булып, сәхнәдә Фатих Сәйфи-Казанлының «Ямьсез тормыш» драмасы (3 пәрдәле) һәм Галиәсгар Камалның «Бүләк өчен» комедиясе уйнала. Соңгы вакытларда тамак авыруы көчәеп китүе сәбәпле, театрда артист булып уйнавы кыенлашып киткән Габдулла Кариев Саттар ролендә чыгыш ясаган. Бу турыда Шәһит Әхмәдиев: «...Чын мәһарәт белән уйнады, тик тавышының карлыгуы, шуның аркасында артистның газаплануы гына кызганыч рәвештә тәэсир итте», — дип язган («Йолдыз», 1915, 15 март). Шул көнне «Ил» газетасында «Ил» идарәсе» исеменнән:

«Габдулла әфәнде!

Сезнең артистлык талантыңызны, милли театрга иткән онытылмас хезмәтләреңезне тәкъдир итеп, Сезне бу көнге көнеңез белән тәбрик итәмез вә Сезнең күп елларга сәламәт булуыңызны телимез!» дигән котлавы да басылган (86 нчы санда).

Габдулла Кариев Кырымга дәваланырга 21 мартта китә, аннан кайткач, «Сәйяр» труппасын җитәкләүне, режиссерлык һәм артистлык эшчәнлеген дәвам иттерде.

«Артист Габдулла Кари» исемле истәлек язмасында Гаяз Исхакый: «1915 елның башлары иде. Г.Каринең авырып китүе һәм бугаз чахуткасын алуы хәбәре йөри иде. Габдулла берлә язышкан мәктүбләребездә аның дәвалануына ихтыяҗ зурлыгы, Кырымга китәргә кирәк булуы, ләкин акча юклыгы тотып торуы мәгълүм булып кала иде. Мин дә Кырымга китәргә димлим, акча табуда берәр төрле ярдәм итешүнең чараларын эзләүне белдерә идем», — дип язды ( Габдулла Кариев. «Яңа милли юл», 1936 ел, 12 нче

сан). Габдулла Кариев 21 мартта Кырымга китә. («Йолдыз» газетасы 22 март санында «Аңарда туберкулез авыруы тапканнар һәм Кырымга барырга киңәш иткәннәр» дип язган.)

51 бит.

**Өч мәсьәлә.** «Ил» газетасының 1915 елгы 18 март (87 нче) санында «Гаяз» имзасы белән, кыскартылып (якынча 22 юллык бер өлеше ак калдырылып) басылган. Текст шуннан алынды.

[1] *Боларның берсе Петроградтагы җәмгыятьләр съездының карары ...* — Бөтенроссия мөселман җәмгыятьләре съезды 1914 елның 6–10 декабрьләрендә булып, аның мөһим бер карары «Кавказ чигендә Төркия белән сугышып ята торган гаскәремезнең яралыларыны багар өчен күчмә хастаханә җибәрү»дән гыйбарәт була.

[2] *Баку «Җәмгыяте хәйрия»се рәисенең Мәскәү укучыларына телеграмын... язган идек*. — Газетаның 11 март (84 нче) санында Мирза Әсәдуллаевның «төрле шәһәрләрдәге тыйб факультетында укучы мөселман студентларга мөрәҗәгать иткән кебек, Мәскәү дарелфөнүнендә укучы студентлар түгәрәгенә дә мөрәҗәгать иткән. Мәскәү дарелфөнүненең тыйб факультетыннан 6 мөселман студенты Карс мөселманнарына ярдәмгә барырга риза булган»лыгы языла.

[3] *Казандагы мөселман театры ... сум бирде*. — Бу ярдәмне «Сәйяр» труппасы ясаган булса кирәк.

54 бит.

**Тукай мәрхүм.** «Ил» газетасының 1915 елгы 27 март (89 нчы — соңгы) санында «Гаяз» имзасы белән басылган. Текст шуннан алынды. (Һәнүз Мәхмүтов тарафыннан әзерләнгән тексты «Мирас» журналының 1996 елгы 4 нче санына да урнаштырылган иде.)

«Дин вә мәгыйшәт» журналы (1915 ел, №13, 3 апрель) «Ил» гәзите начар мәсләк тәгъкыйб иткәне өчен Мәскәү градоначальнигы тарафыннан туктатылганын яза. «Гәзитәчелек эшендә 25 ел» дигән мәкаләсендә Г.Исхакый «Кавказның вәли гомумисе граф Воронцов-Дашков дахилия министрына «Ил» өстеннән зарланып кәгазь күндерде. Министр Мәскәү шәһәре башлыгына «Ил» хакында тәдбир алырга кушты һәм 1915 елның 27 мартында 89 нчы номердан «Ил» гәзите туктатылды» дип яза.

[1] *...сигез еллык хәятында...* — монда сүз Тукайның әдәби иҗат гомере якынча сигез ел дәвам итүе турында бара. Аның «Мужик йокысы» исемле беренче басма шигыре (тәрҗемә) «Фикер» газетасының 1915 елның 26 ноябрь санында укучыларга тәкъдим ителгән.

[2] *...кадерне, ихтирамны Тукай мәрхүм үзенең мәрхүм булуы берлән бердән алды.* — Бу урында Тукай исән чагында кадер-хөрмәтне алмаган икән дип аңлашылмасын. Чынында ул вафатына кадәр үк олы шагыйрь булып танылды, аның иҗаты Г.Камал, Ф.Әмирханнар тарафыннан югары бәяләнде, шигырьләре, китаплары мәктәп-мәдрәсәләргә үтеп керде. 1910 елда Г.Ибраһимов: «Хәзер шигырь мәйданында иң шәүкәтле һәм галибәле рольне мөхтәрәм Тукаев уйный. Шул дәрәҗә ки, татар шагыйре диелүгәчә, укучы зиһенендә Тукаев мәүҗүд була», — дип язды.

56 бит.

**Русия мөселманнары.** «Национальные проблемы» журналының 1915 елгы 1 нче (май) санында «Мухаммед-Гаяз Исхаков» имзасы белән (рус телендә) басылган. Текст шуннан татарчага тәрҗемә итеп алынды.

Журналның тиздән басылып чыгачагы турында «Ил» газетасының 1915 елгы 15 март (86 нчы) санында «Национальные проблемы» исеме белән түбәндәге хәбәр урнаштырылган:

«Национальные проблемы» («Милли мәсьәләләр») исемендә Мәскәүдә рус телендә бер журнал чыгарырга хәзерләде. Журналның максаты — Русиядә яши торган төрле милләтләрнең милли вә мәдәни тормышлары берлән рус матбугат галәмен таныштыру, Русиядә төрле милләтләрнең мәдәни, милли мәсьәләләрен хәл итәргә мөсагыйд зәмин хәзерләүдер.

Журналда мөмкин кадәр Русиядәге бөтен милләтләр катыштырылырга карар бирелгән. Моңа кадәр поляклар, яһүдиләр, белоруслар, малоруслар үзләренә аерым баблар алып барырга разый булганнар. Грузиннар, әрмәннәр берлән дә мөзакәрәләр бара икән.

Мөселманнарны да арага катнаштырыр өчен Мәскәүнең матбугат әһеле берлән дә мөзакәрәләр булып үтте.

Мәскәү мөселман зыялылары берничә мәҗлестә мәсьәләне төрле яктан мөзакәрә иткәннең соңында катнашырга карар бирделәр. Вә шул эшне алып барыр өчен Русия мөселман халкының төрле ботагыннан вәкилләр сайлап язучылар түгәрәге ясадылар. Шул түгәрәк, шул милли мәсьәләне алып баруда үзенең генә көче җитә алмаганын хисаплап, русча яза алырлык мөхәррирләремезгә, җәмәгать хадимнәребезгә мөрәҗәгать итәргә карар бирде.

«Милли мәсьәләләр» журналы апрельнең әүвәлге яртысында чыгачактыр».

Бу хәбәр «Ил» газетасыннан алынганы күрсәтелеп, «Кояш» газетасының 1915 елгы 18 март (657 нче) санында да («Дахили хәбәрләр» бүлегендә) басылган.

Түбәндә мәкаләнең русчасы (оригиналы) китерелә:

«Мусульмане России!

Странное положение занимаем мы, мусульмане многоплеменной России, на девять десятых своего состава принадлежащие к одному тюрко-татарскому племени и непонятными историческими причинами разбросанные по всему необъятному простору Империи от Татарского пролива до Мурмана.

Неблагосклонная к нам судьба воспитала, однако, в нас национальное самосознание и, что удивительнее всего, на пространстве веков развивала в нас неимоверной крепости силу самосохранения. Благодаря этому живем ли мы среди народа, культура которого стоит выше нашей, входим ли в соприкосновение с племенами, стоящими на более низкой ступени культурного развития, везде и всюду мы остаемся верными себе, сохраняя отличительные черты своего национально-культурного характера с его своеобразными методами мышления и своенравными психологическими особенностями восприятия и выражения своих чувств. Наша музыка, наша песня выдержали многовековой натиск иранской поэзии, наш язык никогда не капитулировал перед богатым, красивым арабским языком, несмотря на громадное культурное и религиозное значение последнего в мусульманском мире, наш характер остался неизменным под влиянием эластично ассимилирующего славянского творчества. Из незаметной, но упорной вековой борьбы народов мы вышли непобежденными: борьба сковала нас в одно целое, сплоченность рождала веру в будущее, она же питала творческое созидательное начало, и на пороге XX века мы выступаем как компактная национально-культурная единица, а на арене общественных разрушительно-созидательных стремлений начала века явились уже как нация, со всеми моральными и материальными атрибутами таковой и с глубоким национальным самосознанием.

Те реформы, какие пришлось нам совершить в течение последних пятнадцати лет в области педагогики, преобразуя наши мектебе с допотопными методами обучения в начальные светские училища, схоластические медресе в духовные семинарии и учительские институты, являются поистине историческим подвигом. Наши успехи в области литературы, как беллетристической, так и научно-педагогической, возросшей количественно и качественно и приобретшей такое же значение в жизни нации, как и у большинства европейских народов, являются не менее важным национальным творческим делом.

Создание национального театра, выработка национальных типов, воспитание крупных артистических талантов, развитие музыки, до национальной оперы включительно, являются дополнительным проявлением национально-культурной созидательной работы. Если принять во внимание, что при том громадном напряжении сил, которое потребовалось при этой работе, не было ни малейшей поддержки извне, ни материальной, ни моральной, если принять во внимание, что для создания новых начал пришлось разрушить старые крепкие основы, что холодно-мертвящая бюрократическая рука неизменно действовала в союзе с нашим ретроградным духовенством, то станет ясно, какие неисчерпаемые силы таились в недрах всегда молчаливого, серьезного тюрко-татарского народа.

Эта культурная работа совершается и сейчас и ведется так же интенсивно, как и прежде. Без устали, без колебаний, без внутренней реакции жизнь мусульманских масс течет могучим потоком, и все на пути его так ново, жизненно, красиво. Русское общество, как это не раз случалось в его истории, проглядело то, что совершается вокруг него, проглядело ту внутреннюю перемену, какая произошла у его векового соседа, у его самого крупного соучастника государственной жизни. К сожалению, и по сей час в ходу старые представления о мусульманах, до сих пор еще не перестали мерить нас старым екатерининским аршином, расценивать вышедшими из употребления ассигнациями. Глубоко несправедливое отношение к нашим ценностям, способное вызвать неожиданные крупные недоразумения, покоится, по нашему мнению, на тех ненормальных проявлениях внимания к нам, какими дарит нас русская печать: нами преимущественно интересуются миссионеры и востоковеды; но первые из них по своей профессии не могут относиться объективно ко всему, что мы делаем и что творим, и потому, отражая нашу жизнь на страницах специальной миссионерской и правой печати, отдаляются от истины на расстояние их объективной совести. Вторая категория, способная мыслить только археологически, не может оценить по достоинству результатов культурного творчества ранее чем через 300 лет, а русская интеллигенция, нормально мыслящая, с объективными мерилами, никогда к нам не приходила, не проявляла к нам ни дружбы, ни вражды. Наша же малочисленная интеллигенция, поглощенная работой среди своего народа, не могла первая прийти к русскому обществу. Она предпочитала молчать, отчасти преднамеренно, отчасти под давлением внешних причин; но теперь, когда перед русской общественной мыслью ставятся на очередь национальные проблемы, мусульманская интеллигенция, как органическая часть своего народа, не может остаться посторонним зрителем и, мобилизовав свои слабые силы, должна принять посильное участие в ознакомлении русского общества со своими национально-культурными чаяниями и стремлениями, а также способствовать развитию добрососедских отношений между различными народностями Империи на почве взаимного понимания и взаимного уважения».

58 бит.

**Мөфтилек мәсьәләсе әтрафында.** «Кояш» газетасының 1915 елгы 19 август (777 нче) санында «Гаяз Исхакый» имзасы белән басылган. Текст шуннан алынды.

1915 елның 12 июнендә Диния нәзарәте мөфтие Мөхәммәдъяр Солтанов (1827–1915) вафат булып, аның урынына яңа мөфти кую мәсьәләсе туа. Татар вакытлы матбугаты битләрендә бу турыда төрле-төрле фикерләр әйтелә. Мәсәлән, «Дин вә мәгыйшәт» журналында имам вә мөдәррис Мөхәммәтгали Диния нәзарәтендә күп еллар казыйлык вазифасын башкарган, күпләргә мәгълүм Гыйният казыйны (Капкаевны) мактап яза, шул кеше мөфти була калса, мөселманнар өчен файдалы эшләр эшләячәген әйтә. Аныңча, бу урынга ахун Сафа Баязидов та (1887–1937(?) лаек. Журнал редакциясе исә икесен дә яхшы кешеләргә чыгара, ләкин мөфти куюның хөкүмәт вазифасы булуына басым ясый.

Фатих Әмирхан да «Кояш» газетасында мөфти сайлау мәсьәләсенә кагылышлы өч мәкалә бастыра. Ул аларда үз кандидатурасын яклауны үтенеп авторга мөрәҗәгать иткән, «Вакыт» газетасының 14 июль санындагы «Мин мөфти булырга тиеш!» исемле мәкалә авторы Камил Мотыйгыйны Сафа Баязидов һәм Кронштадтның хәрби ахуны Алтынбаевлардан югарырак куя.

Әмма патша хөкүмәте үзенчә эшли: 27 июльдә игълан ителгән фәрман белән Сафа Баязидовны мөфти итеп билгели. Бу хәбәр килү белән, бер төркем Казан зыялылары Думадагы мөселман фракциясенә, кайбер сәяси партияләрнең җитәкчеләренә протест телеграммасы җибәрәләр. Аңа кул куючылар арасында Фатих Әмирхан, аның энесе Ибраһим, Гафур Коләхмәтев, Шәһит Әхмәдиевләр дә булган.

1917 елгы Февраль инкыйлабы булгач, Сафа Баязидов мөфтилектән төшерелә.

Гаяз Исхакыйның бу «Мөфтилек мәсьәләсе әтрафында» исемле мәкаләсе «Йолдыз» газетасының 1915 елгы 21 август (1495 нче) санында кабат басылып, текст алдыннан «Мөфтилек әтрафында» дигән язма да китерелгән. Аның тексты:

«Уфаның 3 нче мәхәлләсендә имам Сабир мулла Хәсәнов Баязидовның мөфтилеккә тәгаен кылыну мөнәсәбәте илә «Уфимская жизнь» гәзитәсендә түбәндәге мәкаләне бастырган:

«Оренбург мөфтисе Мөхәммәдъяр Солтановның вафатыннан соң аның урынына куелачак мөфти хакында мөселманнарның фикерләре икегә аерылды, руханиларның күбрәге илә могтәдил мәсләктәге мөселманнар, мөфти руханидан булырга тиеш, закон (11 том, 1417 матдә) буенча мөфти мөселманнарның рухани башлыклары санала, диләр. Икенче бер кыйсем — үзләрен тәрәкъкыйпәрвәр санап йөргән мөселманнар моның хилафына киттеләр. Алар мөфтинең дөньяви мәгълүмат алган кешеләр арасыннан тәгаен кылыну фикеренә керделәр. Гәзитәләрдә Петроград агентствосы тарафыннан Петроград ахунды Мөхәммәтсафа Баязидовны мөфти тәгаен ителү хәбәре белдерелде. Бу хактагы указ «Правительственный вестник»та да игълан кылынды. Мәсьәлә закон буенча хәл кылынган була, шулай булса, хәзер бу хакта мөзакәрә бетәргә тиеш. Ягъни бу яки теге кеше мөфти булсын фикерләре булырга тиеш түгел иде. Фәкать, тәсадеф ки, «Тормыш» газетасы үзенең бишенче августта чыккан 294 нче номерында яза: «Уфа мөселманнары Баязидовның мөфти тәгаен ителүеннән риза түгелләр, Уфа мөселманнары исеменнән Петроградка мөселман фракциясе илә кадетлар исеменә Уфа мөселманнарының Баязидовның мөфти тәгаен ителүенә нәразыйлыкларын Дахилия министрына белдерергә үтенеп телеграм йибәрелде, ләкин аларга Уфа мөселманнары исеменнән андый телеграм йибәрергә кем вәкаләт биргән? Кем соң ул Уфа мөселманнарының әксариятен тәшкил итүчеләр? Берсе дә мәгълүм түгел.

Минемчә, Уфа мөселманнарының күбесе хөкүмәтнең Сафа Баязидовны мөфти тәгаен итүен муафикъ күрделәр. Аның исеменә тәбрик телеграмнары йибәреп, үзләренең мәмнүниятьләрен изһар кылдылар. Уфадагы мөселман руханилар да, билә истисна, бар да хөкүмәтнең бу эшен муафикъ күрделәр. Аерым-аерым һәм бергәләшеп тәбрик телеграмм йибәрделәр.

Уфада өченче мәхәлләдә имам С.Хәсәнов».

**Гаяз әфәнде мәкаләсе**

«Мөхәррир Гаяз әфәнде Исхакый мәзкүр «Уф.ж.» гәзитәсенә һәм пайтәхет гәзитәләренә ушбу мәкаләне йибәргән. Бу мәкалә Уфа гәзитәсендә басылып та чыккан инде. Гаяз әфәнде яза...»

[1] *Сабир мулла Хәсәнов* (1866–1917дән соң) — Уфада имам-хатиб һәм мөдәррис, II Дәүләт Думасы депутаты.

[2] *«Нур» гәзитәсен чыгару белән ачык күрсәтте.* — Атасы Гатаулла Баязидов вафат булгач та (1911–1914 елларда), Сафа Баязидов газетаның нашир һәм редакторы вазифасын үтәүне дәвам итә, әмма газета консерватив позициягә күчә.

[3] *«Сыйрател-мөстәкыйм» исемле бер партия тәэсис итеп...* — 1914 елда Петроградта уставын патша хөкүмәтенең Эчке эшләр министры раслаган бу җәмгыятькә (союзга) алдынгы татар яшьләре протест белдереп чыгалар. Шуның нәтиҗәсе буларак, патша департаментының провокациясе фаш ителә.

[4] *Мәхкәмәи шәргыя* — Диния нәзарәте турында сүз бара.

60 бит.

**Бер изах.** «Кояш» газетасының 1915 елгы 13 октябрь (819 нчы) санында «Мөхәммәтгаяз әл-Исхакый» имзасы белән басылган. Текст шуннан алынды.

1917 елга кадәрге татар поэзиясе үсешенә сизелерлек өлеш керткән, «Гыйффәт туташ» псевдонимы белән китап-җыентыклар, татар вакытлы матбугаты битләрендә (мәсәлән, «Ил», «Сүз» газеталарында) шигырьләр бастырган Заһидә Бурнашева (1895–1977, совет чорында җәмәгать эшлеклесе) тумышы белән хәзерге Рязань өлкәсендәге Әҗе авылыннан. «Вакыт» газетасының 1915 елгы 6 сентябрь санында аның «Мәрхәмәт намена бер үтенеч»е (идарәгә мәктүбе) басылып чыга. Анда, аерым алганда, Бөтен татар дөньясын каплап алган аңсызлык, наданлыклардан хасил булган тәгассыб вә кара көч белән тартышырга көрәштегем вакыттан игътибарән мин бик авыр дәверләр кичерә килдем. […] Яшерен имза илән матбугатка чыккан шигырь кисәкләрем аларга мәгълүм булгач, мин анам тарафыннан тәмам өйгә ябылдым. […] Минем бар нәрсәләрем бикләнде, китапханәмдәге китапларым яндырылды. Ахырда […] йортларын ташлап чыгарга мәҗбүр булдым. Читкә укырга барырга волостной старшина паспорт бирми. Үземнең рәнҗетелгән йөрәгемне, мазлуманә түгелгән яшьләремне матбугат аркылы милләткә аңлатып, үзенең хаксызга җәберләнгән вә уку юлында бу кадәр газаплар, җәһәннәм күргән бер кызын химаягә милләтне чакырам» диелә. Г.Исхакыйның бу изахы шушы хат белән танышу уңае белән язылган. Татар вакытлы матбугаты битләрендә Заһидә Бурнашеваны яклаган башка мәкаләләр дә күренә. «Бу фаҗига Әҗе авылындагы Бурнашларның гаилә фаҗигасе генә түгел, бәлки бөтен Шәркый Аурупага вә Азиягә таралган татарларның милләт фаҗигаседер» дип яза, мәсәлән, Борһан Шәрәф («Вакыт», 1915, 11 сентябрь).

Гыйффәт туташ хаты уңае белән «Йолдыз» газетасының 1915 елгы 23 сентябрь (1517 нче) санында басылган язма исә 14 имзалы (Мөхәммәдзаһид Шамил, Исмәгыйль Леманов, Мәрьям Базаревская, Галимҗан Шәрәф, Мәрьям Ягъкубова, Солтанбәк Мәмлиев, Госман Тукумбәтов, Кәрим Сәгыйди, Лотфи Исхакый, Габдулла Гыйсьмәти, Мостафа Чокаев, Мәхфүзә Максудова, Какаҗан Бирдиев, Ч.Еникиев). Бу язмада, аерым алганда, болай диелә:

«Гыйффәт туташ башыннан үткән бәлаларендә юлдашлык вә аңа бөтен куәте берлә ярдәм иткән гали кызлар мәктәбе мөгаллимәләреннән Сәлимә туташ Ягъкубованың Петроградка кайтуыннан соң, безгә күңелемезне парчалаган бу вакыйганең һәммә тәфсилләре берлә танышырга мөмкин булды.

Җәйне Әҗедә үткәргән Сәлимә туташ Гыйффәт туташның укуга тырышуы вә шигырьләр язуы өчен ана һәм атасыннан күргән бәлаләрене, алган ифтира вә бөһтаннарыны вә бөтен Әҗенең кара халкы тарафыннан күтәргән хаксыз тәхкыйрьләрене бер-бер сөйләде. Әҗенең яшь вә карт зыялы вә зыялы исемендә йөрүчеләренә тел вә фигыльләре берлә аларга ярдәм итәргә теләүләре, бары укырга теләгән өчен генә анасы йортыны ташларга мәҗбүрә кызга сыенып торырга бер бүлмә дә бирергә теләмәгәнлекләре күренде.

Бертуктаусыз яктылык вә югарыга омтылган шагыйранә күңеленең кара көчкә бирелеп, аның тырнагында калмаганыны без аңлыймыз, шагыйрәмезнең бу көчтән котылу юлындагы батырлыгы алдында тез чүгәмез вә аны бөтен күңелемез илә алкышлыймыз.

Шуның белән бергә кара көч бердәнбер татар шагыйрәсенең каләмене сындырырга теләгәндә, татар дөньясы өстендә ялтырап күтәрелмәктә булган якты йолдызны кара көч сүндерергә теләп һөҗүм иткәндә, ярдәм кулларыны үзләре белеп сузмау гына түгел, Гыйффәт туташны вә аның берлә бергә мең төрле ифтира вә ялганлар күтәргән вә намусларына кадәр һич хаксыз тәхкыйрь ителгән Сәлимә туташны алларына бик кечкенә үтенеч берлә килгәч тә кайтарып йибәрүләре вә ярдәмсез калдырулары өчен, эшне берникадәр дә аңламаган Әҗе зыялыларына вә үзләрене зыялыга санап йөрүчеләренә, шулар арасында укучыларга ярдәм җәмгыяте әгъзаларына да дулкынланган күңелемезнең иң тирән ноктасыннан наразыйлык вә нәфрәт белән итәмез.

Гыйффәт туташ башына тугры килгән вә матбугатка чыккан бу вакыйга — милләтемезнең тәрәккъкыят юлында үзләре лябед булган бер мәсьәләне уртага салу. Бу мәсьәлә, инде күптән хәл ителергә вә, нинди юл берлә генә булмасын, гыйлем алуның нә милләткә, нә дингә, вә нә дә ватанга һичбер вакытта зарар итмәгәнен вә итмәячәген күптән аңларга тиеш иде.

Югарыдагы вакыйга мөнәсәбәте берлә шул хәлне аңламаган вә аңларга теләмәгән һәммә ата-ана вә кардәшләргә дә милли истикъбалемез намена нәфрәт белән әйтеп, кара көчкә каршы сугыш ачканнарга, нинди юл берлә генә булса да гыйлемгә омтылуларга вә анларга ярдәм итүчеләргә хөрмәт вә тәшәккер изһар итәмез».

62 бит.

***** (Идел буе матбугатының...).** «Сүз» газетасының 1915 елгы 13 декабрь (1 нче) санында «Мөхәммәтгаяз әл-Исхакый» имзасы белән басылган. Текст шуннан алынды.

«Сүз» газетасы «Ил» газетасы дәвамы рәвешендә Мәскәүдә 1915 елның 13 декабреннән 1916 елның 22 сентябренә кадәр нәшер ителгән. Редакторы — Габдулла Сәгыйтов, нашире — Әхмәд бәк Салихов.

[1] *Унҗиденче ай дәвам иттереп киленгән канлы зур сугыш...* — 1914 елның 1 августында башланган Беренче бөтендөнья сугышы турында сүз бара.

63 бит.

**Кизүдәге мәсьәләләремез**. «Сүз» газетасының 1915 елгы 16, 18, 22, 25 декабрь (2, 3, 4, 5 нче), 1916 елгы 2, 16, 24, 31 гыйнвар (7, 11, 14, 17 нче), 2, 6 март (28, 30 нчы) саннарында «Гаяз» имзасы белән басылган («Әле дә шул мөселман җәмгыятенең мәдрәсәләр мәсьәләсенә күчик әле» диелгән булса да, дәвамы күренмәде). Текст шуннан алынды.

Мәкалә турында «Вакыт» газетасында (1916 ел, 31 гыйнвар; үзгәртелмичә «Йолдыз» газетасының 5 февраль санында басылган) «Ш.К.» имзалы берәү болай дип язган:

«Кизүдәге мәсьәләләр» дигәч тә, мин Гаяз әфәнденең мәкаләләрен башта гади обывательләргә хас бер кызулык белән укырга керешкән идем.

Ләкин бераз соңрак мин аларны почтенный гражданнарга гына хас бер салкын канлылык вә җиддият белән укый башладым, чөнки бу мәкаләләрдә һәммә нәрсә табылырга мөмкин, тик обыватель өчен кирәк булган кизүдәге мәсьәләләр юк. Мәсәлән: кыйммәтчелек, спекуляция, утын кахтлыгы, азык кахтлыгы вә гайреләр.

Бәс, шулай булгач, табигый салкын канлылык настроениесенә бирелеп укый башларга туры килде.

Ләкин бу настроение дә озакка бармады. Чөнки Гаяз әфәнденең баштагы берничә мәкаләсен укыган чакта, аның җитди тонда язылуына бер дә шөбһә итмәдәгем хәлдә, алтынчы мәкаләгә йиткәч, күңел базарына шөбһә төште. Монда ул «юмор»га бирелгән төсле күренә башлады.

Бу мәкалә бер вакытлар Русия мөселманларының милли-сәяси бер партиясе сыйфаты белән оешып тамыр җәяргә теләгән «Мөселман иттифакы» белән интернациональ яшьләр фракциясенең сыйфаты сөбүтия вә сәлбияләрен яд итүгә багышланган.

Ләкин боны укыганда әлеге ир уртасы гражданларга хас җитди настроение югала да китә. Ихтыярсыз рәвештә елмаерга мәҗбүр буласың.

Мәсәлән, фараз итеп караңыз: Тупчыбашев, мәрхүм Исмәгыйль бәй Гаспринский Мәдинәи Мөнәвәрәдән голүме исламия тәхсил кылып кайтканнар. Башларында кечкенә генә гарәп чалмалары, өстләрендә буйлы ефәк җәлләбияләр өстеннән киң җиңле гарәп җөббәләре, аякларында кызыл сәхтияннан эшләнгән үткен борынлы чарыклар. Шушы мөбарәк Мәдинәи Мөнәвәрә шәкертләре «Русия мөселманнары иттифакы» оештыру эше белән әвәрә булалар. Шәрекънең мәдрәсә күшәләрендә нихәтле хыялпәрәстлек мәүҗүд булса, болар һәммәсен диярлек үзләре белән алып кайтканнар.

Алар, әлбәттә, үзләре генә түгел. Байтак кына иптәшләре дә бар.

Мәсәлән, Бохараның Күкелташ мәдрәсәсендә тәхсил кылып кайткан Сыртланов, Акчурин, Тәфкилев кеби зур чалмалы, көнһ муллалар да әлеге эш артыннан йөриләр, ләкин, Гаяз әфәнде әйтмешли, бу Шәрекъ шәкертләренең төшенчәләре бик киң булса да, мәсьәләләрнең һичберсендә мәгълүм әсаслар куелмаган, аларның уйлары Шәрекънең матур күгe, зөмред кебек диңгезе арасында уйланганга, бик күбесе хыял дәрәҗәсеннән индерелмәгән вә тормышка татбикънең ысулы уйланылмаган.

Менә инде шушы «Шәрекънең мәдәнияте черегән вакытындагы моральне сеңдереп кайткан» кешеләр «Мөселман иттифакы» партиясе оештырып йөргәндә, икенче бер фирка «яшь» халык хөррият фиркасе флагы астында йөриләр.

Менә болар инде тегеләргә караганда бөтенләй башка халык! Болар, Гаяз әфәнде әйтмешли: «Русиядәге үзгәреш алдындагы сәяси тәрбияне күргәнгә (ә тегеләр әле ул чакта кайсы Мәдинәдә, кайсы Бохарада дини мәсьәләләр хакында ду күчереп моназарә кылышып яталар икән), рус әдәбияты аша шул вакыттагы икътисади уйлауны, вакыйгаларны мадди нoктаи нәзарыннан карауны кабул иткәннәр иде».

Болар һәммәсе диярлек зур тәҗрибәле, киң белемле, аек нәзарлы булып, теге Шәрекъ шәкертләре шикелле хыялга бирелмиләр, ни эшләсә дә белеп эшлиләр һәм дә тоткан юлларында сөбат күрсәтәләр.

Менә шунлыктан да, үткән ун ел эчендә теге хыялпәрәст иттифакчылар кайсы социалист, кайсы анархист булып беткән хәлдә, хөрриятче «яшьләр» үзләренең мәсләкләреннән зәррә кадәр дә читкә авышканлары юк. Алар һаман да «Берләшеңез, бөтендөнья эшчеләре!» шигаренә самими сәдакать саклыйлар. Әллә шушы яшьләр фиркасенә мәнсуб II Государственный Думага сайланган депутат хәзрәтләре һаман да Маркс, Каутский, Бебель вә Лассальләрдән башка һичбер авторитет игътираф кыйлмыйлар. Анысы шулай. Ләкин эшнең тагын икенче ягы да бар.

Гаяз әфәнденең бәянына күрә, мәзкүр ике фирканең берләшеп эш күрүләре дә мөмкин булган. Ләкин моңар һәм әлеге Шәрекъ шәкертләре — «иттифакчы»ларның хыялпәрәстлеге юл бирмәгән.

Мәсәлән, алар гомуми програмга: 1) Мисырда дини исляхат ясау; 2) Габделхәмиднең золымларына каршы тору; 3) Японияне мөселман ясау маддәләрен кертергә тырышканнар.

Яшьләр аны кабул итәргә тиеш тапмаганнар, әлбәттә.

Аерылышу шуннан соң булган дисезме? Юк шул, соңыннан маддәләргә дә күнмәкче булганнар.

Ләкин теге Шәрекъ шәкертләре во что бы не стало яшьләрдән аерылырга карар биргәннәр: иртәдән сәгать 10 да китәргә тәгъйин кылынган, «съезд» пароходына сәгать 9 да килгәннәр дә айда, бакалым!

Ләкин яшьләр дә «яр якасында» авыз ачып калмаганнар, бәләкәй генә бер пароход алганнар да, әйдә тегеләрне куарга...

Пароходта тегеләр яшьләргә хуш кабул күрсәтсәләр, эшләрнең тагын да җайланып китүе бик мөмкин икән.

Ләкин Шәрекъ шәкертләреннән азмы-күпме нәзакәтле мөгамәлә көтәргә мөмкинме соң? Монда яшьләргә күрсәткән әллә нихәтле золымнар, әллә ничә төрле куркытулар ни Ходай үзенең дошманнарына да күрсәтмәсен, вәссәлам.

— Тыныңыз чыкты исә, шәһәрдән утыз-кырык чакрым йиргә китеп, далага ташлыймыз, — диләр икән.

Гаяз әфәнде әле монда барын да әйтеп бетерми, чөнки ул вакыйга хакында миңа байтак нәрсәләр ишетергә туры килде. Җөмләдән бере — нәкъ шушы сәгать 9 белән 10 арасында бер буксир пароходы болар яныннан үткән, менә шушы буксирның капитаны әйтә: «Карыйм-карыйм да, ул кенәзләр тулган пароходта эшләр яхшы күренми, шау-шу, кычкырыш бара», — ди. Шулай дигәнчә булмады ди. Ике кеше бер яшь егетне берсе — аякларыннан, берсе башыннан тоттылар да, селтәп торып, суга ыргытып та йибәрделәр ди! Мескинне чак-чак кына коткарып калдык ди.

Капитанның тәгърифенә күрә, мәзкүр троеның икесе, ягъни ыргытучылары Тупчыбашев белән мәрхүм Гаспринскийга тугры килә. Өченчесен исеме, фамилиясе белән үк атап әйтсә дә, мин бу урында белдерүне уңайсыз табам. Чөнки Гаяз әфәнде бу вакыйга хакында бөтенләй сөкүт кылырга тиеш тапкан...

Эшләр бу дәрәҗәгә йиткәч, табигый, аерылмаска хәл калмаган була. Ләкин монда бик кызык бер хәл бар ки, ул да «иттифакчы»лар белән «хөрриятче»ләрнең аерылуы түгел, бәлки, «Берләшеңез, бөтендөнья эшчеләре!» лозунгына ябышкан яшьләрнең милләтчелек шигарен тоткан «иттифакчы»лар арасында чуалып йөрүләре! Гаяз әфәнде «таңчы»лык, «уралчы»лыкның мәйданга чыгуына фәкать «иттифакчы»ларның сүә мөгамәләләрен сәбәп итеп күрсәтә икән, анысы, әлбәттә, үз файдасына булып чыкмый, һәрхәлдә, добродушный «иттифакчы»:

— Мин үзем сине элеккеге гөнаһларың өчен азрак кыздырып аласы иде, ә син үзең үк өлгерден, хәерле булсын, — дисә, урыны бар».

[1] *Хәзрәти Гайсә галәйһиссәламнең хәвариюны* — Гайсә пәйгамбәрнең (Иисус Христосның) унике ярдәмчесе (апостоллары). Ислам диненең башлангыч елларында Мөхәммәт пәйгамбәрнең дә иң якын 12 ярдәмче-юлдашларын хәвариюннар дип атаганнар.

[2] *Лютер* — Мартин Лютер (1483–1546), Германиядә Реформация эшлеклесе, католиклык диненең төп догматларына каршы чыккан кеше.

[3] *Жан Жак Руссо* (1712–1778) — француз язучысы, философ, рәсми чиркәүне, динне башка диннәргә карата чыдамсызлыгы өчен тәнкыйтьләгән.

[4] *Монтескье* — Шарль Луи Монтескье (1689–1755), француз мәгърифәтчесе, философ, язучы.

[5] *Юнанстан* — Грециянең зур өлеше; 1453–1821 елларда Госманлы империясе (Төркия) составында булып, 1814 елда барлыкка килгән оешма 1921 елда грекларның милли азатлыгы өчен восстание күтәргәч, империядән аерылып чыга.

[6] *Болгар кәмитәчеләре* — Дунайдагы Болгария XV гасырдан XIX гасырның икенче яртысына кадәр Госманлы империясе составында була; 1869 елда илдә Болгария инкыйлабы Үзәк Комитеты җитәкчелегендә милли-азатлык восстаниесе күтәрелсә дә, Болгария 1908 елга кадәр Төркиягә вассал дәүләт булып яши.

[7] *Насыйрилар, Мәрҗаниләр, Исмәгыйль бәкләр* — Каюм Насыйри, Шиһабетдин Мәрҗани, Исмәгыйль Гаспринскийлар турында сүз бара.

[8] *...киләсе мәкаләдә озайта төшәрмез.* — Моннан соң мәкаләнең «Сүз» газетасында 1915 елгы 22 декабрьдә басылган өлеше башлана.

[9] *Мәкәрҗәнең беренче съезды* — «Иттифакы мөслимин» («Мөселман иттифакы») партиясенең I съезды Мәкәрҗә ярминкәсе вакытында 1905 елның 15 августында үткәрелә.

[10] *«Иттифакчы»лар таифәсе* — Исмәгыйль Гаспринский, Галимәрдан Тупчыбашев, Әбүсогуд Әхтәмов, Габдерәшид Ибраһимов кебек җәмәгать эшлеклеләре күз алдында тотыла.

[11] *«Хөрриятче»ләр* — 1904–1905 елларда Казанда башлап йөрүчеләре Г.Исхакый, Ф.Туктаров булган татар яшьләренең яшерен оешмасы «Хөррият» исемле җилем басмада газета чыгарган.

[12] *Рәшид казый* — Габдерәшид (Рәшид) Ибраһимов.

[13] *Исмәгыйль бәк* — Исмәгыйль Гаспринский.

[14] *Галимәрдан бә*к — Галимәрдан Тупчыбашев.

[15] *Идел буе мөфтилеге* — Оренбург мөселман Диния нәзарәте (Мәхкәмәи шәргыя, Диния нәзарәте) турында сүз бара.

[16] *Мисырның дини исляхияте* — Мисырда ул елларда дини реформалар үткәрүгә омтылышлар ясала.

[17] *Габделхәмит золымы* — Госманлы империясенең 1876–1909 елллардагы солтаны Габделхәмит башта Конституция кертә, ләкин тиздән аның нигезендә оештырылган парламентны тарата, илдә деспотик режим (золым) урнаштыра. 1908 елда яшь төрекләр инкыйлабы басымы астында Конституцияне яңадан торгызырга мәҗбүр була. Төркиядәге хәлләр татар вакытлы матбугатында да чагылыш тапкан (мәсәлән, Габдулла Тукай иҗатында).

[18] *Җамалетдин әл-Әфгани* — 1839–1897 елларда яшәгән дин галиме, җәмәгать эшлеклесе, мөселман исляхчысы. 1869 елга кадәр Әфганстанда яши, аннары чит илләрдә (Һиндстан, Мисыр, Иран, Россия, Франция, Англия, Төркия) эмиграциядә була, Төркиядә үлә (1944 елда аның сөякләре Кабулга күчерелгән).

[19] *«Бөтенрусия мөселман иттифакы»* — «Иттифакы мөслимин» партиясе турында сүз бара.

[20] *«уралчы»лар* — 1907 елның 4 гыйнварыннан 27 апреленә кадәр Оренбургта социал-демократик позициядәге «Урал» газетасы чыгарылган. Нашире — Тимерша Соловьев (соңрак Гомәр Терегулов), мөхәррире — Хөсәен Ямашев. Газетаның фактик җитәкчеләре — Хөсәен Ямашев, Галимҗан Сәйфетдинов; газета хакимият тарафыннан туктатыла.

[21] *Мамай заманында, Туктамыш вакытында* — Мамай (?–1380), әмир, Алтын Урданың Көнбатыш олысы идарәчесе, рус тарих фәнендә Куликово янындагы сугышны китереп чыгарган дигән фикер урнашкан; Алтын Урданы бүлгәләп, аерым өлешен үз кулына алырга омтылган.

[22] *Пәйгамбәр заманасында* — Мөхәммәт пәйгамбәр заманасы — VI гасыр азагы һәм VII гасыр башлары истә тотыла.

[23] *Сәхабә кирам чагында* — Мөхәммәт пәйгамбәрнең замандашы булып, аны күргән хөрмәтле кешеләр яшәгән вакытлар турында сүз бара.

[24] *17 октябрь Манифесты* — эшчеләрнең сәяси күтәрелешеннән куркып калган патша Николай II 1905 елның 17 октябрендә Манифест игълан итәргә мәҗбүр була. Анда кайбер гражданлык иркенлекләре, Дәүләт Думасы чакыру вәгъдә ителә.

[25] *«таңчы»лар* — рус социалист-революционерлары йогынтысында булган, «Таң йолдызы» газетасы (1906) тирәсендә тупланган төркем (башлап йөрүчеләре — Гаяз Исхакый, Фуад Туктаров, Сәгыйть Рәмиев, Шакир Мөхәммәдьяров), 1907 елда төркем таркала.

[26] *«Дин вә мәгыйшәт»* — 1906–1918 елларда Оренбургта чыккан атналык дини, фәнни, әдәби һәм сәяси журнал (башта «Дөнья вә мәгыйшәт» исемендә була). Редакторлары — Заһидулла Хәйруллин һәм Фәезхан Даутов, нашире — Мөхәммәтвәли Хөсәенов.

[27] *«Шәкертлек» исемендә махсус бер җәмгыять* — 1901–1904 елларда Казанда яшерен эш алып барган татар яшьләре түгәрәге.

[28] *«Тәрәккый» журналлары* — Казан Татар укытучылар мәктәбе укучыларының кульязма газетасы (1895–1900; башлап йөрүчеләре — Г.Исхакый, Ф.Туктаров, С.Максуди, Г.Терегулов).

[29] *озын күзле Йосыфлары* — сүз Йосыф Акчура турында бара.

[30] *6 нчы елда Мәкәрҗә съездына* — «Иттифакы мөслимин»нең өченче съезды Мәкәрҗә ярминкәсендә 1906 елның 15–21 августында уздырылган.

[31] *«Таң» таралган бер гәзитә* — газетаның төгәл исеме — «Таң йолдызы»; ул 1906 елның 18 маеннан 16 ноябренә кадәр нәшер ителгән.

[32] *Өченче Дума ... мөселманнар аз кертелде.* — Думага сайлаулар турында 1907 елның 3 июлендә чыгарылган яңа закон нигезендә III Дәүләт Думасына нибары 10 мөселман депутаты үткән.

[33] *Икенче Мәкәрҗә съездында* — «Иттифакы мөслимин»нең икенче съезды 1906 елның 13–23 гыйнварында Петербургта уздырыла. Анда партиянең Уставы һәм 23 пункттан торган Программасы кабул ителә, съезд Дәүләт Думасына сайлауларда кадетларга кушылуны яхшы дип таба.

[34] *Габдулла Бубый берлән Садри әфәнде Максудига башкаларын...* — күренекле педагог һәм җәмәгать эшлеклесе Габдулла Буби (1871–1922), 1906 елның язында хаҗдан кайткач та, милли азатлык хәрәкәтенә катнаша башлый. Ул «Мөселман иттифакы» партиясенең III съездында (1906 ел, август) мәктәпләр һәм партиянең программасын эшләү комиссияләрендә эшли, берничә мәртәбә съезд утырышларында чыгыш ясый, партиянең Үзәк Комитетына әгъза булып сайлана. Съездан соңгы елларда да партия программасында урын алган карашларга тугрылыклы булып кала.

Адвокат, атаклы җәмәгать эшлеклесе, «Мөселман иттифакы» партиясенең лидерларыннан Садри (Садретдин) Максуди (1878–1957) партиянең III съездында Үзәк Комитет составына сайлана, II һәм III Дәүләт Думалары депутаты буларак та татарларның иҗтимагый тормышында зур роль уйный.

105 бит.

**Милли йитешсезлекемез.** «Сүз» газетасының 1915 елгы 30 декабрь (6 нчы) саннарында «Мөхәммәтгаяз әл-Исхакый» имзасы белән басылган. Текст шуннан алынды.

Мәкалә, тексттан ук аңлашылганча, 1915 елның 27 декабрендә Мәскәүдә халык театрлары эшлеклеләренең Бөтенроссия съезды ачылу уңае белән язылган.

[1] *Көфер почмагы* — Казанда Мәскәү һәм Париж коммунасы урамнары кисешкән почмак (Нурулла мәчете — Печән базары мәчете чаты). Монда иске фикерле сәүдәгәрләр, фанатик динчеләр җыелып, яңа фикерле затлардан көлеп, аларны хурлап кала торган булганнар. Г.Тукай, Ф.Әмирхан, Г.Камал әсәрләрендә сатира объекты булып хезмәт иткән.

[2] *Час чатының* — бу елларда Казан административ яктан «часть»ларга бүленгән.

[3] *Камалы, Әмирханы, Исхакые* — бу урында сүз драматург Галиәсгар Камал, прозаик һәм драматург Фатих Әмирхан һәм авторның үзе (Гаяз Исхакый) турында бара.

## *1916*

107 бит.

**Милли матбугат бәйрәме.** «Сүз» газетасының 1916 елгы 5 гыйнвар (8 нче) санында «Гаяз» имзасы белән басылган. Текст шуннан алынды.

[1] *Октябрь көннәре* — 1905 елның 7–25 октябрьләрендә Россиядә 2 миллион кеше катнашында самодержавиене бәреп төшерүне һәм демократик ирекләрне таләп иткән сәяси стачка үткәрелә. Моңардан куркып калган патша Николай II 17 октябрь Манифестын игълан итәргә мәҗбүр була (ләкин анда вәгъдә ителгән иркенлекләрнең күбесе кәгазьдә генә калган). Бу сәяси күтәрелеш 1905–1907 елгы революциянең иң мөһим этапларыннан берсе булып тора.

[2] *Йосыф әфәнде* — Йосыф Акчура (Акчурин, 1876–1935) — җәмәгать эшлеклесе, журналист, публицист. Сембер шәһәрендә туып, 7 яшеннән Төркиядә яшәгән, анда белем алган, берара Парижда да яшәгән. Йосыф Акчура 1904 елда Россиягә кайта, «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә укыта, 1905 елның 29 октябрендә чыга башлаган «Казан мөхбире» газетасының редакторы була. 1908 елдан соң Төркиядә яшәгән.

[3] *Һади Максуди* (1868–1941) — педагог, тел галиме, нашир, 1906–1918 елларда чыккан «Йолдыз» газетасының нашире һәм редакторы; күпсанлы дәреслекләр авторы.

[4] *Фуад Туктаров* — 1880–1938 елларда яшәгән журналист, публицист, җәмәгать эшлеклесе, сәясәтче.

[5] *Борһан Шәрәф* (1883–1942) — педагог, әдип, журналист. 1905 елдан башлап журналистикада эшли. «Казан мөхбире» газетасында сәркатиб, «Әхбар»да мөхәррир, аннан Оренбургта «Вакыт» газетасында эшли. «Вакыт»ның мөхбире сыйфатында Урта Азиядә, Иранда булып кайта.

[6] *Фәсих учитель Мөхетдинов* — Фәсхетдин Мөхетдинов, 1893–1903 елларда Казан Татар укытучылар мәктәбе янындагы башлангыч татар мәктәбе мөгаллиме (учитель), 1910–1917 елларда Казан Татар укытучылар мәктәбендә ислам дине укытучысы.

[7] *Шакир абзый Таһиров* — Шакирҗан Таһиров (Шакирҗан Таһири, 1858–1918), педагог, рәсем укытучысы.

[8] *Сәедгәрәй мирза Алкин* (1867–1919) — юрист, «Мөселман иттифакы» партиясен оештыручы һәм җитәкләүчеләрдән. «Казан мөхбире» газетасының рәсми нашире һәм редакторы; I Дәүләт Думасы депутаты.

[9] *...русчада «Казанск. вестник» исемендә гәзитә* — 1905 елның 5 ноябренә кадәр генә чыккан (3 сан) «Казанский вестник» газетасы («Казан мөхбире» газетасының русчасы).

[10] *...Мөхәммәтҗан Сәйдәшевкә гәзитәне тапшырды.* — 1865–1914 елларда яшәгән сәүдәгәр, эшкуар, нашир, җәмәгать эшлеклесе М.Сәйдәшев турында сүз бара. Газета реакция елларында Сәйдәшевләр наширлегенә күчкәч, аның эшчәнлеге сүлпәнләнә, мәсләге үзгәрә, сирәк чыга һәм 1911 елның мартында бөтенләй туктала.

[11] *«Төрек йорты» мөәссисе* — 1911–1931 елларда Истамбул шәһәрендә госманлы төркисендә чыккан фәнни-әдәби һәм иҗтимагый журналны («Төрек йорды» дип тә йөртелә) нигезләүче һәм күп еллар буе мөхәррире булып торган Йосыф Акчура турында бара.

[12] *...берничә гәзитәләр, журналлар булып үтте.* — 1905–1918 елларда Россиядә татар телендә 125 исемдә газета, 45 журнал нәшер ителгән (Раиф Мәрданов фикере).

[13] *...«кәшфез-зөнүн шәкерт»* — мәдрәсәләрдә «Кәшфез-зөнүн» исемле китапны укучы (өйрәнүче) шәкерт турында сүз бара.

[14] *Исмәгыйль баба* — Исмәгыйль Гаспринский.

112 бит.

**Петроград татар гәзитәләре.** «Сүз» газетасының 1916 елгы 10 гыйнвар (9 нчы) санында имзасыз басылган. Текст шуннан алынды.

[1] *...матбаганы Кырым татарларыннан Ильяс мирза Бораганский тәэссис итте.* — Ильяс Бораганскийның (1852–1920 еллар ахыры) Петербургтагы типо-литографиясе 1894 елда ачыла һәм 1911 елга кадәр эшли. Анда казакъ, кырым-татар, фарсы, гарәп телләрендә 120 ләп китап нәшер ителгән.

[2] *«Мишкят»* — мәдрәсәләрдә укылган китап исеме.

[3] *...Рәшид казый Петроградта «Мирьат»лар нәшер итә башлады.* — Габдерәшид Ибраһимов (1857–1944) 1900–1903 һәм 1907–1909 елларда «Мирьат» (көзге) исемле китап-брошюралар бастырган (16 сы — Петербургта, 6 сы — Казанда).

[4] *...мөфти сүгү хакындагы мәкаләләре* — мәсәлән, андый мәкалә «Мәхкәмәи шәргыя» исеме белән «Мирьат»ның 19 нчы һәм 22 нче (1907, 1909) саннарында басылган (10–11 б.; 2–4 б.). Аларда миллион мөселманга баш булган бу «Мәхкәмә...»дән хәзерге хәлендә хезмәт көтү мәгънәсез дип әйтелә, рәис (мөфти) Мөхәммәдьяр Солтановның кая гына барып чыкса да, акча туплау белән шөгыльләнүе тәнкыйтьләнә. Язмада аның «һичбер эш кыйлганы юк»лыгына басым ясала.

[5] *«Нур» гәзитәсе* — бу газета 1905 елның 2 сентябрендә Петербургта атнага бер тапкыр чыга башлый. Нашире һәм мөхәррире — Гатаулла Баязидов, аның вафатыннан соң — Сафа Баязидов; нәшер ителүенең әүвәлге елларында шактый авторитетлы басма булып саналган. Чынлыкта татар вакытлы матбугатының тарихы шушы «Нур» газетасыннан башлана...

[6] *Хәзер «Нур» гәзитәсе бар да түгел, юк та түгел.* — Газетаның соңгы 310 нчы саны 1914 елның 22 июнендә чыккан.

[7] *Петроградта икенче гәзитә «Өлфәт» булды*. — «Өлфәт» газетасы Петербургта 1905 елның 11 декабреннән 1907 елның 9 июненә кадәр чыккан (85 сан). Нашир һәм редакторы — Габдерәшид Ибраһимов (берара бу вазифаларны Әхмәт Мөнир дә үтәгән). Газетада шәкертләрне мәдрәсәләрдән куу.

[8] *Муса әфәнденең гыйльми тәдкыйкатьләре* — «Өлфәт» газетасында Муса Бигиев язмалары еш басылуга ишарә ителә. Мәсәлән, аның 1905 елгы 29 декабрь (3 нче) санында «Казан мөселманнары», 1906 елгы 12 гыйнвар (5 нче) санында «Әфьюн мәсьәләсе», 16 февраль (11 нче) санында «Тарихе һиҗринең ибтидасы» исемле язмалары чыккан.

[9] *«Дума» гәзитәсе* — 1907 елның 21 апреленнән 30 маена кадәр Петербургта чыккан (6 сан). Нашир һәм редакторы Кәлимулла Хәсәнов (1881–1949), 1911 елның мартында хакимият тарафыннан хөкемгә тартылып, бер ел төрмәдә (Казанда) утырып чыга.

[10] *«Милләт» исемле гәзитә* — 1913 елның 28 декабреннән 1915 елның 7 февраленә кадәр Петербургта чыккан газета (19 сан). Редакторы — Исмәгыйль Леманов, наширләре — Сәлимгәрәй Җантурин һәм Ибнеәмин Әхтәмов.

[11] *Петербург Петроград улганнан бирле...* — бу шәһәрнең исеме Беренче бөтендөнья сугышы башлангач, төгәлрәк әйтсәк, 1914 елның 18 августында үзгәртелгән.

116 бит.

**Матбугат бәйрәме мөнәсәбәте берлә.** «Сүз» газетасының 1916 елгы 14 гыйнвар (10 нчы) санында «Гаяз» имзасы белән басылган. Текст шуннан алынды.

[1] *...безнең язучыларымыз да татар матбугатының ... эшләп килгәнгә...* — «Сүз» дә, мәсәлән, Мәхмүтфуад Туктаров, Әхмәд Зәки Алиев, Г.Сөләйман, Ибнеәмин Әхтәмов, Нәҗип Гасрый, Шакир Мөхәммәдъяров, Кәрим Сәгыйть, Әхмәдбәк Салихов, Шакир Мостаев, Исмәгыйль Леманов, Гомәр Терегулов кебек язучы һәм журналистлар язышкан.

[2] *«Вакыт» гәзитәсендә ... кыска бер хәбәр генә кертелгән...* — Матбугат юбилеена караган хәбәрләр «Вакыт» газетасының 1916 елгы 5 һәм 9 гыйнвар саннарында «Дахили хәбәрләр» рубрикасында басылган, 9 гыйнвардагысында «Матбугат көне. Дахили Русиядә татарча гәзитә чыга башлавына 10 ел тулу мөнәсәбәте илә бәйрәм ясалырга тиеш булса да, фәүкылгадә әхваль сәбәпле бу бәйрәмне кичектерергә мәҗбүрият күрелгән...» дип әйтелгән. Газетаның 8 гыйнвар санында исә бер фирка (төркем, партия) Мәскәү мөселманнарыннан килгән телеграмма урнаштырылган. Телеграммада «Халкымызда аң вә миллият фикере уйлануда беренче гамәл булган милли матбугатымызның унъеллык дәвамы безне дә туган тел вә үз халкымызны сөяргә өйрәтте» диелгән була.

[3] *«Тәрҗеман»да ... бу хакта мәкалә вә хәбәрләр күренде.* — «Тәрҗеман» газетасының 1916 елгы 9 гыйнвар (6 нчы) санында «Х.С.» имзасы белән «Шималь төрекләре матбугаты илә ун сәнәлеге хатирәсенә япынмыш яуме махсус мөнәсәбәте илә исеме белән баш мәкалә 10 гыйнвар (7 нче) санында исә «Милли мәгыйшәт» рубрикасында «Йолдыз»ның 10 сәнәлеге» исемле кыска хәбәр басылган.

[4] *Казан гәзитәләре вә «Тормыш» кына, махсус ук булмаса да, бернечә мәкаләне шул мәсьәләгә багышлаганнар*. — Мәсәлән, «Тормыш» газетасының 1916 елгы 5 гыйнвар санында З.К.ның «Вакытлы матбугатымыз» исемле баш мәкаләсе һәм Фатих Сәйфи-Казанлының «Яз башы», Галиәсгар Гафуровның «Ун яшьлек матбугат» дигән мәкаләләре басылган.

119 бит.

**[Халык театры съездында мөхтәрәм Гаяз әфәнде тарафыннан бирелгән доклад]** «Сүз» газетасының 1916 елгы 14 гыйнвар (10 нчы) санында басылган. Текст шуннан алынды.

Газетаның 1915 елгы 22 декабрь (4 нче) санындагы «Халык театрының съезды» исемле имзасыз хәбәрдә «Мәскәүдә 27 декабрьдән 5 гыйнварга кадәр халыкка театр ясарга тырышучыларның киңәш мәҗлесе булачактыр. Бу мәҗлескә 400 гә якын вәкилләр чакырылганнар. Рус халкы театр хезмәтчеләреннән башка, башка милләтләрнең дә театр хезмәтчеләре чакырылган. Безнең татарлардан да бернечә театр язучы мөхаррирләргә, мәгълүм труппаларга чакырылулар җибәрелгән икән, ишетүебезгә күрә, Кавказ труппасыннан бернечә артист, бернечә драматург киләчәк икән. Безнең Идел буе сәхнәчеләреннән дә, «Сәйяр» труппа артистларыннан Габдулла әфәнде Кариев, Өммегөлсем ханым Болгарская, драматурглардан Галиәсгар Камал, Фатих Әмирхан, Гаяз әфәнде Исхакый, артистка Сәхипҗамал туташ Гыйззәтуллина, Мохтар Мутин әфәнделәр вә башка бернечә кеше чакырылган икән.

Съездга хәзергә кадәр туксанлап доклад хәзерләнгән. Кавказ сәхнәчеләре дә махсус докладлар белән киләчәкләр икән. Идел буе сәхнәчеләре дә үзләренең иптәшләре белән булачак киңәш мәҗлесләрендә үзләренең хәлләре хакында доклад хәзерләп килсәләр яхшы булыр иде» диелә.

Съезд узганнан соң, газетаның 14 гыйнвар (10 нчы) санында «Мәскәүдә халык театры съезды» исеме белән түбәндәге хәбәр дә басылган: «27 декабрьдә Мәскәүдә ачылган театр хезмәткәрләренең съездында Г.Исхакый «Идел буе татарларының театры тарихы» дигән темага доклад ясады. Русиядә, театр эшлеклеләрен берләштереп, бер мөстәкыйль җәмгыять төзүне максат итеп куйган бу съезд 1916 елның 5 январена кадәр дәвам итте». Бу хәбәрдән аңлашылганча, әлеге съезд халык (эшче, крестьяннар) театрлары булдыруга күп хезмәт куйган академик В.Д.Поленов рәислегендә барган.

[1] *Татар театры ... уеннардан башланды.* — «Милли театрның беренче яралгылары халык уеннарында, җыен, сабан туе кебек бәйрәмнәрдә, туй йолаларында күренә» (Һәнүз Мәхмүтов).

[2] ... *әдәби рәткә салу тәҗрибәсе...* — бу урында Габдрахман Ильясиның «Бичара кыз» (1887), Фатих Халидинең «Рәдде бичара кыз» (1888) драмалары, билгесез авторның «Комедия Чистайда» әсәре (1895) басылып чыгулар турында сүз бара. Беренче тәҗрибәләр буларак, аларның сәнгати дәрәҗәләре әллә ни югары булмады.

[3] *... Казан һәм Уфада ... татар спектакльләре куела башлады.* — Уфа яшьләре 1906 елның 21 апрелендә Приказчиклар клубында Г.Исхакыйның «Өч хатын берлән тормыш» драмасын куялар. «Бу — татар театры тарихында зур сәхнәгә чыгарылган беренче рәсми спектакль» (Һәнүз Мәхмүтов). Казан яшьләре 1906 елның 5 маенда Приказчиклар клубында төрек драматургы Нәмекъ Камалның «Кызганыч бала» драмасын (Галиәсгар Камал тәрҗемәсендә) һәм «Гыйшык бәласе» комедиясен (төрекчәдән Габдрахман Камал тәрҗемәсендә) куялар.

[4] *Гаяз әфәнденең «Өч хатын берлән тормыш» исемле әсәре* — Г.Исхакыйның бу беренче драматик әсәре Казанда 1900 елда басылып чыга (икенче басмасы — 1912 елда). Беренче мәртәбә сәхнәдә 1906 елның 21 апрелендә Уфада уйнала.

[5] *... театрга каршы кара көч...* — иске фикерле дин әһелләре, консерватив фикерлеләр, патша чиновниклары татар театрын булдырмаска тырышалар; пьесаларны сәхнәгә куюга һәрчак рөхсәт алу кирәк булды, кайбер газета һәм журналларда театр әхлакый бозыклыкка илтә торган нәрсә сыйфатында бәяләнде.

[6] *... артисткаларны урамда озатуга...* — моңа («Озату»га) мисал итеп Сәхипҗамал Гыйззәтуллина-Волжскаяның «Сәхнә дусты» исемле истәлегендә китерелгән бер вакыйганы күрсәтергә була: «Бервакыт мин театрдан эшемне бетереп кайтып килә идем,

юлда бер төркем билгесез кешеләр очрадылар. Кыяфәтләренә караганда, алар Тукайның «Яңа Кисекбаш...»ында язган «көфер почмагы» әһелләре иде. Болар минем арттан киләләр һәм әллә нинди ямьсез сүзләр сөйлиләр:

— Менә ул театр марҗасы, аны бәреп үтерәсе бар, аны үтерү савап кына булачак.

Шунда ук алар мине куа башладылар. Мин куркып йөгерә башладым һәм көчкә өйгә кайтып кердем. Төне буена аларның сүзләре колагымнан китмәде, йоклый алмадым» (Тукай турында замандашлары. Казан, 1960, 93–94 б.).

[7] *... драматический цензор* — Василий Дмитриевич Смирнов (1846–1922), матбугат эшләре буенча баш идарәдә драмалар цензоры, Шәрекъ әдәбияты белгече, профессор; «мәшһүр төрек-татар дошманы» (Гаяз Исхакый), «кара һәм ахмак психопат» (Фатих Әмирхан).

[8] *... «Сәйяр» труппасы* — бу профессиональ татар труппасы 1907 елда Оренбургта оеша; 1908 елдан аның җитәкчесе — Габдулла Кариев. Труппа 1918 елга кадәр эшли.

[9] *... җәмгыятьләр хакындагы 4 март правиласына...* — бу урында патша хөкүмәте эшләп чыгарган «Җәмгыятьләр һәм союзлар турында вакытлы кагыйдәләр» («Временные правила об обществах и союзах») искә алына. Бу законны патша 1906 елның 4 мартында раслаган.

123 бит.

**Мәскәү, 20 гыйнвар**. «Сүз» газетасының 1916 елгы 20 гыйнвар (12 нче) санында имзасыз гына басылган. Текст шуннан алынды.

[1] *... студент Сәгыйд әфәнденең «милли оешу» хакындагы фикере...* — Мөхәммәдсәгыйд (Сәгыйд) Янгалычевнең мондый фикерләре «Фракциягә ярдәмме милли оешма?» исемле мәкаләсендә чагылыш тапкан. Анда Думаның мөселман фракциясенә ярдәм өчен төзелергә тиешле милли оешма турында сүз бара. Бу хакта күп тапкырлар сөйләнелсә, язылса да, эш шуннан узмый кала. Баштарак матбугатта әлеге эш өчен һәр шәһәрдән берәр кеше бирергә кирәк дигән тәкъдимнәр күренсә дә, мәкалә авторы бу фикер белән килешеп бетми. Болай эшләгәндә кечкенә шәһәрләр һәм зуррак авыллар читтә калачагын белдерә. Бүгенге көндә Русия мөселманнары арасында элемтә юк, «Русиянең бер очындагы мөселманнар эшләгән эшләр икенче очында беленми калалар. Эчке Русиядә торганнар, без Себердә торганнарыбызның уку эше ничек, көн күрүләре ничек, сәүдә эшләре ничек икәнлеген һәм нинди ихтыяҗлары кизүдәлеген белмибез...» дигән фикер белдерә.

Мәкалә авторы фракциягә ярдәм өчен оешма төзүне төрле авылларда, шәһәрләрдә эшләп килүче җәмгыятьләрдән көтә. Петроград җәмгыяте яки Думадагы мөселман фракциясе әлеге җәмгыятьләрнең съездын үткәрү инициативасын үз кулына алырга тиеш. Әлеге съезд нәтиҗәсендә милли мәсьәләләр тикшерелеп фракциягә ярдәм өчен тиешле сандагы кеше дә калдырылыр дигән фикердә тора.

126 бит.

**«Йолдыз» юбилейсы.** «Сүз» газетасының 1916 елгы 20 гыйнвар (12 нче) санында «Гаяз» имзасы белән басылган. Текст шуннан алынды.

Мәкалә шул ук имза белән һәм үзгәртелмичә «Дин вә мәгыйшәт» журналының 1916 елгы 5 нче санында да басыла һәм идарә (редакция) исеменнән түбәндәге искәрмә бирелә:

«Мәдәният гасырында мондаен вәхшәтләр булмаска тиешле иде. Бер кеше, яхшымы, яманмы, үз хисабында яхшы дип милләткә күрсәткән хезмәтенең 10 нчы елында бәйрәмен ясый, мәдәният дөньясында боңа иштиракь итмәгән кеше зарарына да сүз сөйләмәскә тиешле иде.

Гәзитәдә тәнкыйть ителәчәк урыннар бар икән, аны башка бер вакытка, башка бер мөнәсәбәт илә тәнкыйть итәргә тиешледер. Юкса, хосусый берәүнең шатлык көнен бу рәвештә былчырату мәдәният галәмендә бер хезмәт түгел, язучының үзен вәхшиләр зөмрәсендә күрсәтәчәк бер эштер. Дөрест, андаен эшләргә бәйрәмнәр ясау үзе ноктаи шәргътән караганда тиешле түгел. Шуның өчен гомуми матбугатның милләткә иткән җинаятьләрене күрсәтүдә зарар юктыр».

[1] *16 гыйнварда ... махсус номер...* — чынында, «Сүз» газетасының бу (1591 нче) саны 1916 елның 15 гыйнварында чыккан һәм ул «Йолдыз» газетасының нәшер ителә башлавына ун ел тулуга багышланган.

[2] *Садыйк хәзрәт әл-Иманколый җәнаблары ... «Йолдыз»га багышлап шигырь дә язды.* — Шагыйрь С.Иманколыйның (1870–1932) «Йолдыз»га» исемле шигыре бу газетаның 15 гыйнвар (1591 нче) санында басылган.

[3] *«Вакыт» берлән «Тәрҗеман»нан башка...* — «Вакыт» газетасының 1916 елгы 5 гыйнвар (1955), 8 гыйнвар (1957), 9 гыйнвар (1958) саннарындагы «Дахили хәбәрләр» бүлегендә искә алуларны, «Тәрҗеман» газетасының 1916 елгы 9 гыйнвар (6 нчы) санында «Х.С.»имзасы астында «Шималь төрекләре матбугаты илә ун сәнәлеге хатирәсенә япылмыш яуме махсус мөнәсәбәте илә» исемле баш мәкаләне, «Сүз» газетасыннан килгән котлау телеграммасы, 10 гыйнвар (7 нче) санында «Милли мәгыйшәт» рубрикасында Йолдыз»ның 10 сәнәлеге» исеме астында кыска гына хәбәрне, 15 гыйнвар (11 нче) санында ««Йолдыз»ның ун сәнәлек яуме махсусы» исемле имзасыз мәкаләне моңа мисаллар итеп күрсәтергә мөмкин.

[4] *Һади әфәнде, мәдрәсә шәкерте генә булса да...* — Һади Максудины татар вакытлы матбугат битләрендә кайчак әнә шулай кимсетеп телгә алганнар.

[5] *Сәет Баттал, Салсал хикәясе...* — биредә госманлы төрекләренең румнарга каршы сугышларын тасвирлаган «Сәет Баттал Газый» әсәре (авторы мәгълүм түгел, VIII гасыр халык иҗаты әсәре дип фараз ителә); баш герое Сәет Баттал халык арасында хәйләкәрлек символы булып киткән. Дин хакына сугышларда катнашкан легендар геройның тормышы һәм каһарманлыклары тасвирлана.

«Кыйссаи Салсал» — татар шагыйре Мәүлекәй Юмачиковның (1840–1910) дини сугышлар турында борынгы халык экиятләренә нигезләнеп язылган китабы. Салсал — фантастик образ, халык арасында гадәттән тыш батырлык символы булып йөри.

[6] *... шуларны махсус бер имляда язып тора.* — Гарәп алфавитындагы татар язуында өч кенә сузык аваз хәрефе (а, у, и) булу дөрес укуны кыенлаштырганга, Һади Максуди тагы өч сузык аваз билгеләре (о,ө,ә) өсти һәм шуны Уфадагы гыйльми мәҗлестә рәсми рәвештә кабул иттерүгә ирешә. Бу хәрефләрне ул, беренче буларак, «Йолдыз» газетасы имлясына кертә.

132 бит.

**Мәдәни эшләремез.** «Сүз» газетасының 1916 елгы 22 гыйнвар (13 нче) санында «Гаяз» имзасы белән басылган. Текст шуннан алынды.

[1] *Шул көннәрдә … мөтәвәллиләренең еллык мәҗлесләре була.* — Оренбург сәүдәгәре, җәмәгать эшлеклесе Әхмәт Хөсәенов (Әхмәт бай, 1837–1906) үлгәндә «Русия мөселманнары файдасы өчен» ярты миллион сумлык вәкыф калдыра, васыятьнамәсендә исә аның нинди эшләргә тотылачагын санап чыгып, аны бүлү өчен җаваплы кешеләрне (мөтәвәллиләрне) атый. Алар, һәр елда җыелышлар уздырып, иганәләрне кемнәргә бирү турында карар чыгара торган булганнар.

Хәер, Г.Исхакыйның бу язмасы чыкканчы ук мөтәвәллиләрнең еллык мәҗлесе булган да инде. Бу «Вакыт» газетасының 1916 елгы 22 гыйнвар санында басылган түбәндәге хәбәр белән раслана:

«18–19 гыйнварда мөтәвәлләләр мәҗлесе булып, 1915 елның гомуми хисабы каралды. 1916 елның сметасы тасдыйк ителде. Соңра аның 1916 ел өчен правление әгъзалары сайланды. Рәислеккә Закиров, рәис могавинлегенә Харис Фәйзуллин, хәзинәдарлыкка Габделхәмит Хөсәенов, секретарьлеккә Камил Кәримов вә махсус хезмәтсез ике әгъзалыкка Нигъмәтулла хәзрәт Тимушев илә Хөсәен хаҗи Хөсәенов сайландылар. Правлениедә алты кеше, отчет газетада басылачак». Бу җыелышта мөселманнар арасында мәгариф тарату мәсьәләләре хакында киңәшер өчен мөтәхәссыйслар һәм мөселман зыялылары, учительләр чакырып киңәш мәҗлесе ясарга тиеш табыла.

[2] *...«Хөсәения» мәдрәсәсе тәрбия ителә.* — Оренбургтагы бу мәдрәсәне бертуган Әхмәт (1837–1906), Мәхмүт (1839–1910) һәм Гани (Гани бай, 1839/1840–1902) Хөсәеновлар 1889 елда ачканнар. Аларның мәгърифәтчелек өлкәсендә башкарган эшләренең иң мөһиме «Хөсәения» мәдрәсәсе белән бәйле. Мәсәлән, аны тәртиптә тоту, ут, су кертү, шәкертләрне киендерү, тукландыру, хәлфәләргә хезмәт хакы түләү һәм торак белән тәэмин итүгә 1915 елда гына да 24 мең сум сарыф ителгән.

[3] *... Сабирҗан әфәнде Шәмигуловның магазиныннан чыккан артистларымыздан…* — бу урында артист һәм режиссер Гыйлаҗ Казанскийның (Ибраһимов, 1891–1938) сәхнә эшчәнлеген башлаганчы Сабирҗан Шәмигуловның кибетләрендә приказчик булып йөргәненә ишарә ясала булса кирәк.

136 бит.

**«Ил» наширенең мөрәҗәгате.** «Сүз» газетасының 1916 елгы 27 гыйнвар (15 нче) санында имзасыз гына басылган. Текст шуннан алынды.

«Ил» газетасы, 1913 елның 22 октябрендә «йорт-җир файдасын күзәтүче төрек-татар газетасы» булып, Г.Исхакый редакторлыгында Петербургта чыга башлый. Аның баш мәкаләсендә: «Халкыбызның өсте-башы бөтен, аш-суы иркен, йөзе-күзе күркәм, көе-җыры көчле, сүзе-сазы татлы, кыйланышы килешле, җайлы; йөреше-барышы тугры иттереп күрәсебез килү безне зур мәсьүлиятле «Ил» эшен җилкәмезгә алырга мәҗбүр итте ... Шул авыр эшне бүлешергә безнең дустыбыз, юлбашчыбыз — иманыбыз бар һәм шул иманны без «Ил»нең нигезенә салып, бөтен иманлыларны йөкне күтәрешергә, кайгы-шатлыкларны бүлешергә өндибез», — диелгән була. Әмма юлында каршылыклар беренче адымнарыннан ук башлана. Мәсәлән, газетаның 7 нче санында М.Мәннаф имзасы белән басылган «Татарга» шигыре өчен 6 декабрь номеры конфискацияләнеп, Гаяз Исхакый судка бирелә. Тикшерү барышында мөхәррир, бар җаваплылыкны үз өстенә алып, шигырь авторының кемлеген әйтүдән баш тарта. 1914 елның 12 май утырышында хөкем палатасы шигырьдә законга каршы әйбер тапмый, эшне ябып, 7 нче саныннан конфискацияне ала; Гаяз Исхакыйны хөкем итмәскә карар бирелә*. Соңрак бу шигырьнең авторы Мәннаф исемле Троицкиның мәгълүм сәүдәгәре икәнлеге «Йолдыз» газетасында язылган. Газетаның кайбер саннары конфискацияләнгән, күп мәкаләләр ак таплар белән, хәтта буш урыннар калдырылып басылган.

Газетаның 12 нче сандагы «Ял итү мәсьәләсе» дигән имзасыз мәкаләсе өчен «Ил»гә штраф салына. Бу мәкалә Казанда рус бәйрәмнәрен мәҗбүри ял иттерү, татар бәйрәмнәреннән татарлар өчен эш көне итеп игълан итү карарына каршы язылган. Моның русларның сәүдә эшләренә уңайлык тудыру максатыннан чыгып эшләнгәнлеге әйтелә. Мәхмүтфуадның шул ук мәсьәләгә караган «Бу да мөмкинме?» исемле мәкаләсе 16 нчы санда урын алган. Петербург шәһәр башлыгы язманы законга каршы табып баш мөхәрриргә 350 сум штраф сала, түли алмаса, тугыз атнага төрмәгә ябылырга тиешлеген белдерә. Бары 16 саны чыгып өлгергән «Ил» өчен бу түләү, әлбәттә, авыр булуын исәпләп, Исхакый тоткынлыкка ризалык бирә. Ә газетаны шул юнәлештә дәвам иттерү өчен вакытлы мөхәррир билгеләнә. 31 нче саныннан ул Нәҗип Гасрый мөхәррирлегендә чыга башлый. Бу хәбәрне ишетү белән казанлылар мәкаләдә язылган фикерләргә үзләренең кушылганлыкларын белдерәләр. Штраф суммасын түләүне үз өсләренә алып, телеграмма белән 350 сум акча җибәрәләр. Петербург мөселманнары да читтә калмый, Исхакый инде төрмәгә китәргә киенеп яткан минутта акча китерәләр. Фин татарлары да, Петербург мөселманнары кебек, бу мәсьәлә Казанга гына түгел, ә барыбызга да кагыла дип, штраф суммасына кушарга 50 сум акча җибәрәләр. Ахыр чиктә Исхакый тоткынлыктан котылып кала.

Беренче бөтендөнья сугышы башланганнан соң, барлык газеталар да хәрби цензурага буйсындырыла. «Ил»гә цензор итеп А.Д.Смирнов билгеләнә, һәм газета өчен авыр көннәр башлана. Үз вакытында чыга алмый, үз йөзен, шактый дәрәҗәдә мөстәкыйльлеген югалта. Мөхәррир, эшләр болай дәвам итә алмаячагын аңлап, 41 нче саныннан газетаны зур авырлыклар белән Мәскәүгә күчерә. Баштарак Мәскәү шәһәр башлыгы «Ил»не Петербургта Гаяз Исхакый дигән кеше чыгара дип, Мәскәүдә яңадан газета чыгарырга рөхсәт бирми. Исхакый үзенең кемлеген аңлатканчы ике-өч ай вакыт үтә, бары тик 1914 елның 14 ноябрендә генә беренче саны дөнья күрә. Монда цензор итеп Шәрекъне сөюче, йомшак табигатьле бер әрмән билгеләнә. Әмма кискен, үткен телле «Ил» озак яши алмый. Кавказда аҗар мөселманнарына каршы рус хөкүмәте, рус гаскәренең кылган золымнарын язуы өчен 1915 елның 27 мартында 89 нчы номердан «Ил» туктатыла.

136 бит.

**Мәскәү, 27 гыйнвар**. «Сүз» газетасының 1916 елгы 27 гыйнвар (15 нче) санында имзасыз гына басылган. Текст шуннан алынды.

[1] *Совет* — Россия империясенең Дәүләт Советы турында сүз бара.

[2] *... баш министрлык урыныннан Горемыкинның истигъфа итеп...* — Министрлар Советы рәисе И.Л.Горемыкин.

[3] *Штрюмер* — Борис Владимирович Штрюмер — патша хатыны һәм Григорий Распутинның тәкъдиме белән 1916 елның февралендә Россиянең Министрлар Советы Рәисе итеп куела. Әмма шул ук елның ноябрендә аны патша отставкага җибәрергә мәҗбүр була.

[4] *«Кара блок»* — Думадагы уңнар (65 депутат) һәм өлешчә октябристлар (барлык октябрист депутатлар — 98) блогы.

[5] *Котлыкай мирза мәктүбенә...* — Котлымөхәммәд Тәфкилев турында сүз бара.

138 бит.

**Матбугат, яһүдләр вә без.** «Сүз» газетасының 1916 елгы 29 гыйнвар (16 нчы) санында «Гаяз» имзасы белән басылган. Текст шуннан алынды.

Мәкалә шул вакытларда «Новое время» газетасының ияләре арасында килеп чыккан каршылыклар турында рус матбугатында күренгән хәбәрләрне уку тәэсирендә язылган. Г.Исхакый бу газетаның характерын, наширенең эшчәнлеген шактый дөрес яктырткан.

«Новое время» газетасы Петербургта (Петроградта) 1868 елдан 1917 елгача нәшер ителеп, 1976–1912 елларда ул атаклы рус журналисты, публицисты, нашир һәм язучы Алексей Сергеевич Суворин (1834–1912) наширлегендә чыгып килә.

[1] *«Новое время» гәзитәсен тәэсис итүче, үстерүче ярлы бер мөхәррир Алексей Суворин иде.* — Гади бер авылда крестьян гаиләсендә туып үскән, әллә ни зур уку йортларында укымаган А.С.Суворин газетаны башлап оештыручы түгел, чынында, үстерүче, тиражы артуга күп көч куеп, аны шул чор рус матбугаты мәйданында иң беренче урыннарга урнашуын тәэмин итүче.

[2] *Алексей Суворин («Русь» гәзитәсене ... алып барган иде)* ... — Алексей Алексеевич Суворин (1862–?), язучы, 1896 елдан башлап беркадәр вакыт «Новое Время»ның икенче җаваплы редакторы булып торган.

[3] *... яһүднең хокуксызлыгына* — яңа эрага кадәр 63 нче елда яһүд дәүләте Рим империясе тарафыннан җимерелгәч, яһүдләр бик күп илләргә күчеп утыралар. Әмма аларның хокуклары чикләнгән була. Россиядә чикләнгән торак урыны хокукый һәм икътисади яктан чикләгән 19 гасыр ахыры — 20 гасыр башында еврей погромнары оештырыла.

[4] *Бейлис мәсьәләсе* — патша хөкүмәте тарафыннан 1913 елда Киев шәһәрендә кирпеч заводы приказчигы еврей М.Г.Бейлиска каршы оештырылган суд процессы. 1911 елда аңа, христиан малае Ющинскийны ритуаль максат белән үтергән дип, ялган гаеп ташлана. Җәмәгатьчелекнең басымы астында суд Бейлисны акларга мәҗбүр булган.

143 бит.

**«Йолдыз»ның «миллилеге».** «Сүз» газетасының 1916 елгы 5 февраль (18 нче) санында «Гаяз» имзасы белән басылган. Текст шуннан алынды.

[1] *«Йолдыз»ның ун еллык юбилейсы мөнәсәбәте берлән язган мәкаләмә...* — «Сүз» газетасының 1916 елгы 20 гыйнвар (12 нче) санында «Гаяз» имзасы белән басылган «Йолдыз» юбилейсы» исемле мәкалә истә тотыла.

[2] *...«Таңчы»га җавап» гонванында мәкалә язган.* — Гаяз Исхакыйның «Йолдыз юбилейсы» исемле мәкаләсенә җавап рәвешендә Һади Максуди «Йолдыз»ның 1916 елның 26 гыйнвар (1597 нче) санында «Таңчы»га җавап» исемле түбәндәге мәкалә бастыра:

«Йолдыз»ны чыгарганчы, миңа унбиш еллар кадими җаһилләр белә көрәшергә тугры килгән иде. Инде ун елдан бирле җәдитнең арьягына чыккан «Таңчы» дигән бер таифә белә көрәшү лязем булды. Халык белә торгандыр, «Таң», «Тавыш» вә гайре гәзитәләр васитасы белән болар «Йолдыз»га вә аның мөәссисе вә сахибе булган миңа төрле рәвештә һөҗүм кылдылар. «Йолдыз» алар өчен гүя мәркәзи бер хөкүмәт булды. Башка тарафларга оппозициялекне кыла алмаганлыкларыннанмы, башка сәбәптәнме, алар һаман «Йолдыз»га игътираз кылу белә мәшгуль булдылар. «Йолдыз», боларга күп вакытта сөкүт вә илтифатсызлык белә генә җавап биреп барса да, үзенең галәбәсен сизә бара.

«Таң» вә «Тавыш» заманнарында болар «Йолдыз»га милли дип бәйләнә иделәр. Ул вакытта мода йиле белә искәнлекләреннән миллияткә бик каршы иделәр. «Йолдыз» миллияттә дәвам итте, ахырда аларга галиб булды. Хәзер аларның һәммәсе үзләре дә милли булып киттеләр. Болар әле бер шәһәргә, әле икенче шәһәргә барып, гәзитәләр чыгарып карыйлар. Ләкин һич муафикъ була алмыйлар. Бу муаффәкыятьсезлектән «Йолдыз»ның вә башка бер гәзитәнең рәваҗ вә дәвамыннан күрәләр булырга кирәк. Чөнки һәрвакыт әдәпсез рәвештә бер-ике гәзитәгә бәйләнә торалар. Бу бичаралар ничә ширкәт вә ничә кешенең акчаларын сарыф кылып бетерделәр инде, ул ширкәт вә ул кешеләргә хисапны алар «Йолдыз»га бәйләнү белән бирәләр.

Шөбһә юк, бу әдәпсезлеккә аларны, үзләре әйткәнчә, корсак мәҗбүр итә торгандыр, ләкин башкаларга бәйләнү белә генә корсак туйдырырга мөмкин булыр микән?

«Йолдыз»ның имля кагыйдәләреннән көлүчеләр дә шулар иде. Ләкин милләт аларның көлүләренә карамады. Имля өчен кагыйдәләр эзләргә мәҗбүр булды.

Бу таифә өч мәсьәләдә үзләрен «Йолдыз»га мәгълуб саныйлар: миллият мәсьәләсе, имля мәсьәләсе һәм гәзитә чыгару мәсьәләсе. «Йолдыз» нашир вә мөхәрриренә матди файда биргәне юк әле, әмма башкаларга гәзитә белә көн күрергә манигъ булса була торгандыр шул.

«Сүз» газетасының 12 нче номерында Гаяз әфәнденең «Йолдыз» хакында язган озын бер мәкаләсе фәүкылгадә көлке вә бик түбәнлектер. Ул, бичара, «Йолдыз» хакында ни әйтергә дә белми, белмәсә дә, эчендәге укларның барын да чыгара, аңлата.

Даимән милли фикер нәшер итеп, тәрәкъкый вә тәгаллемгә тырышу илә «Йолдыз» ун сәнә дәвам итеп, милли хезмәттә, сәдакатьтә беренчелек шәрәфен алган. Әгәр дә «Йолдыз» хакында җитди игътираз кылачак булганда, аның юбилее көненнән бер ай элек йә бераз соң кылырга кирәк иде. Юк, Гаяз әфәнденең «Йолдыз» хакындагы шеше нәкъ шул «Йолдыз»ның юбилей шәрәфенә ирешкән көнендә тула. Шул мөнәсәбәт илә йөрәгенә чыдый алмыйча әллә ниләр яза.

«Йолдыз»ның мәсләген кабул итмәскә мөмкин. «Йолдыз»да косурлар табарга җаиз, ләкин Гаяз әфәнде «Йолдыз»ның мәсләге мәкъбүл түгел, дип әйтә алмый.

Чөнки аның бу көндәге үзенең мәсләге «Йолдыз» мәсләгенә башка түгел. Ул «Йолдыз» мәсләген үзе мәсләк итеп иттихад кылган инде. Әмма ни ди? «Йолдыз»ның мәсләге юк аның, ди. Хәлбуки бөтен галәм чыга башлаганнан бирле «Йолдыз» һаман бер мәсләктә дәвам итте дип шәһадәт бирә.

Аптырагач, ул: «Йолдыз» мәсләген вә әйтәчәк сүзләрен әйтеп бетерми ул», — ди. Ун ел язылып та мәсләк вә фикерләр әйтелмәскә мөмкин микән?

Дөрест, «Йолдыз»ның әйтәчәк вә язачак сүзләре күп әле. «Йолдыз» милләтне әлифбадан укыта башлады. Ул татар милләтен мәдәни бер милләт хәленә китергәнче тәдриҗән иршадында дәвам итәчәк ул. Гаяз әфәнде буны сизә булырга кирәк. «Йолдыз» әйтәсе сүзен әйтеп бетерми ул», — ди.

«Йолдыз»ның өстенә алган миссиясе бик күп вә мөкатдәсдер. Бу миссияне муаффәкыять илә әда вә иҗраэ кылачагында «Йолдыз» иминдер. Бу хосуста «Йолдыз»ның тәдриҗ сәясәтен тотуы исә косур түгел, кәмаль булса кирәк.

Гаяз әфәнде: «Йолдыз» халыкны хулиганлыкка өйрәтте», — ди. Буңа ни дип җавап бирергә кирәк? Милләтне тәрәкъкый вә тәгаллемгә өндәү «таңчы»ларча хулиганлык булса гаҗәп түгел, ләкин буны алар милли «Ил» вә «Сүз»дә түгел, «Таң» вә «Тавыш»та язып калырга кирәк иделәр. Әле яхшы, шарлатанлыкка өйрәтте, дип әйтми. Ахрысы, Гаяз әфәнде «шарлатан» кәлимәсен язарга да курка булырга кирәк. Чөнки аның кемнәргә вә нинди кешеләргә итлак кылынганлыгы һәркемнән артык аңа мәгълүмдер. Һәркем телендә булган сүз, әлбәттә, аның үз колагына да керә торгандыр.

Гаяз әфәнде: «Йолдыз» вак интрига вә вак доносляр белә мәшгуль булды», — ди. Буңа дәлил ни икән? «Йолдыз» хакында һәрнәрсәне язарга уйламаган кеше бунның мисалларын язарга да уйламаска кирәк иде. Язган сүзенең бер әсасы булса, Гаяз әфәндедән язуын үтенәм.

Сүз сүзне тарта бит. Донос дигәч, минем күңелгә донос белән шөһрәт тапкан кешеләрнең һәммәсе килделәр. Гаяз әфәнде читтә торганда ниләр генә сөйләмәделәр? Петроградта торган вакытында әллә кемнәрне Хаҗи Теләшиләр белә бергә хисапладылар.

Иң соңында Гаяз әфәнде «Йолдыз»ның почта хакын процентлы тариф белән түләгәненә эче поша. Ул тарифны почта тәнзыйматыннан гына карарга кирәк, һәфтәдә ничә мәртәбә чыккан гәзитәләргә никадәр түләргә тиешлеге бар да шунда язылган. Һәрвакыт сул яза торган «Маленький Петроград» вә «Биржевые ведомости» гәзитәләре нинди тариф белә түләсәләр, «Йолдыз» да шул тариф белә түли».

[3] «*Таң» вә «Тавыш» заманнарында...* — «Таң» («Таң йолдызы»), «Таң мәҗмугасы», «Тавыш» — татар социалист-революционерлары карашын чагылдырган гәзитәләр. 1906 елның 18 май — 16 ноябрьләрендә нәшер ителгән «Таң йолдызы» газетасының (65 саны чыга) фиктив редакторы һәм нашире Гали Путиляков була. Аның дәвамы буларак ике генә саны (1906 елның 18 декабрендә, 1907 елның 1июнендә) дөнья күргән «Таң мәҗмугасы» Хөсәен Әбүзәров редакторлыгында һәм наширлегендә чыккан. 1907 елның 23 апрель — 5 июньнәрендә басылган (барлыгы 6 сан) «Тавыш» газетасының редакторы булып Гариф Биккинин саналган. Чынлыкта бу өч басманың мөхәррир һәм наширләре — Гаяз Исхакый, Сәгыйть Рәмиев, Фуад Туктаров.

[4] *«Вакыт»* — 1906 елның 21 февралендә Оренбургта чыга башлап, барысы 2309 сан чыкканнан соң, 1918 елның 26 гыйнварында туктатыла. Баш мөхәррире — Фатих Кәрими, наширләре — Шакир Рәмиев һәм Закир Рәмиев (Дәрдемәнд). «Йолдыз» газетасының «Вакыт» белән талашуына мисал булырдай бер генә фактны күрсәтергә мөмкин: «Вакыт» газетасының 1915 елгы 13 июнь (1796 нчы) санында Фәтхелбәян Исламов «Тәнкыйтьләр дикъкатенә» исемле язмасында тәнкыйтьченең нинди булырга тиешлеге турында сүз алып барып, «Йолдыз» газетасының тәнкыйтьтән бигрәк башкаларга һөҗүм рухындагы чыгышлар ясавын әйтә. «Йолдыз» газетасының шул ук елгы 18 июнь санындагы имзасыз «Тәнкыйтьчеләр» исемле мәкалә шуңа җавап рәвешендә язылган.

[5] «*Идел*» — 1907 елның сентябрендә Әстерханда чыга башлап (барысы 623 сан), 1914 елның гыйнварында Әстерхан губернаторы боерыгы белән туктатыла. Мөхәррире һәм нашире — Габдрахман Гомәрев (1867–1933).

Толстой вафат булгач, татар вакытлы матбугатында төрле мәкаләләр басылган. Шуларның берсендә «Йолдыз», Толстойның атаклы «Живой труп» әсәрен Толстой иҗат итмәве турында чыккан имеш-мимешләргә ышануын белдерә. «Идел» газетасының 1911 елгы 18 ноябрь (403 нче) санында Сәгыйть Рәмиев, моңа каршы чыгып, әсәрнең Толстойныкы булуын дәлилли.

[6] *«Тәрҗеман»* — Русиядә төрки-татар телендә нәшер ителгән беренче газета. 1883 елның апрель аеннан Бакчасарай шәһәрендә (Кырымда) чыга башлый һәм утыз биш ел дәвам итеп, 1918 елда туктатыла. Нигезләүчесе, нашире һәм мөхәррире — Исмәгыйль Гаспринский (1851–1914). Аның вафатыннан соң мөхәррире — Хәсән Сабри Айвазов, нашире Рәфгать Гаспринский. Бу газетага карата татар газеталары битләрендә тәнкыйди фикерләр чыгып торган.

[7] *«Тормыш»* — 1913 елның 18 октябрендә Уфада 1912–1913 елларда Том шәһәрендә нәшер ителгән «Сибирия» газетасының дәвамы рәвешендә чыга башлый. Беренче мөхәррире — Вәгыйз Нәүрузов, 1914 ел башыннан — Закир Кадыйри, нашире — Гыйбадулла Усманов. Газета «пролетариат революциясенә каршы фикер тарату»да гаепләнеп, 1918 елның 29 апрелендә Уфа Мөселман комиссариаты карары белән туктатыла.

[8] *...«Йолдыз» гәзитәсендә... номерасы фәлән көнне чыкты» дип язып чыгарды.* — 1907 елның 23 апрелендә Казанда «Тавыш» исемле газета чыга башлый. Нашире — Хөсәен Әбүзәров, редакторы — Гариф Биккинин, фактик редакторы Г.Исхакый була. Редактор Гариф Биккинин авырып китеп, редакторны алыштыру хакындагы кәгазьгә кул куелганчы ук, 18 майда (җомга көн) үлеп китә. Хөсәен Әбүзәров үзе өйдә булмаганга, идарәдәгеләр, редактор вафат булганны белмәстән, «Тавыш»ның 21 май (5 нче) санын әүвәлге редактор имзасы белән чыгаралар.

«Йолдыз» 1907 елның 23 май (123 нче) санында «Казан хәбәрләре» бүлегендә Гариф Биккининның вафат булуы турында түбәндәге хәбәр басыла:

«Ишетелдегенә күрә, «Тавыш» газетасының мөхәррире Гариф Биккинин вафат улмыш. Вә 18 май җомга көн икенде вакытында дәфен кылынмыштыр.

Гариф әфәнде бундан берничә ел мокаддәм бәдәл илә хаҗга вармыш вә шул сәфәрендә йиде сәнә кадәр Мәккә мөкәррәмәдә тормыш иде.

Русиядә ихтилял хәрәкәтләре башлангач, «таңчы»лар илә бер мәсләккә килмеш вә хәзердә «Тавыш» газетасында мөхәррирлек итмәктә иде.

Аллаһы иптәшләренә сабыры җәмил виреп, урыны җәннәттә кылсын». Шуннан соң «Тавыш» газетасы яптырыла.

[9] *Кәримовлар типографиясенең мөдире вафат булып...* — Бу вакытта Кәримовлар матбагасының җаваплы мөдире Габделмәннан Әхмәтҗан улы Рәхманкулов була. Кәримовлар Рәхманкуловның җаваплы мөдир булуын раслату өчен губернаторга 1906 елның 20 декабрендә үк мөрәҗәгать иткән булалар. Әмма әлеге вазифага ул 1907 елның 9 мартында гына раслана.

[10] *«Русские ведомости»* — 1863–1918 елларда Мәскәүдә чыккан иҗтимагый-сәяси газета. 1905 елдан кадетлар партиясе органы.

[11] *«Русское слово»* — 1895 елдан 1917 елның 26 ноябренә (9 декабрь) кадәр чыккан көндәлек газета. Либераль позициядә торган. 1897 елдан нашире — И.Д.Сытин.

[12] «*Речь*» — Петроградта чыккан газета.

[13] «*Дон*» — Петроградта чыккан газета.

[14] «*Земщина*» — бу газета С.К.Глинка редакторлыгында 1909 елдан башлап чыккан.

[15] «*Русское Знамя*» — С.-Петербургта А.И.Дубровин редакторлыгында 1905–1917 елларда «Рус халык союзы» органы буларак чыккан газета.

[16] *Миссионер Җузи әфәнде* — гарәп һәм төрек телләрен белгән (ләкин татар телен белмәгән) бу кеше Казанда 1912 елдан цензор булып эшли. Ул татарларның чит илләргә барып укуларына, хаҗ кылуларына, гомумән, татар матбугатына, мәдәниятенә, әдәбиятына каршы чыккан. «Колокол» газетасының 1917 елгы 1500–1502 нче саннарында басылган «Мусульманская печать в России» дигән мәкаләсен хәтта Казандагы миссионер вакытлы матбугаты да бастырмауны мәгъкуль тапканнар.

146 бит.

**Мөселман фракциясендә киңәш мәҗлесе**. «Сүз» газетасының 1916 елгы 14 февраль (22 нче) санында «Гаяз. Петербург, 10 февраль» имзасы белән басылган. Текст шуннан алынды.

IV Дәүләт Думасы каникуллардан соң эшен башлап җибәргәч, мөселман фракциясенең дә эшчәнлегендә җанлану сизелә. Аерым алганда, 3–20 февральләрдә Петроградта мөселман җәмәгать эшлекләренең рәсми булмаган җыелышы — киңәш мәҗлесе булып, анда Думадагы мөселман фракциясенең тактикасы мәсьәләсе карала.

[1] *Думадагы мөселман фракциямез...* — IV Дәүләт Думасына мөселманнардан 7 депутат кына үтә алган. Аларның өчесе — Уфа губернасыннан, берәресе — Оренбург, Баку, Дагъстан һәм Самарадан сайланган була. Дагъстан вәкиле Мөхәммәд Далгат фракциягә кермәгән.

[2] *Котлыкай мирза* — дүрт чакырылыш Дәүләт Думасына да Уфадан сайланган Котлымөхәммәд Тәфкилев (1850–1917 дән соң) турында сүз бара.

[3] *Закир әфәнде Кадыйри* — 1878–1954 елларда яшәгән журналист, җәмәгать эшлеклесе; 1914–1918 елларда «Тормыш» газетасы редакторы.

148 бит.

**Мөселман фракциясендә киңәш мәҗлесләре**. «Сүз» газетасының 1916 елгы 18 һәм 20 февраль (23 һәм 24 нче) саннарында «Гаяз. Петроград. 12 февраль; 13 февраль» имзасы белән басылган. Текст шуннан алынды.

Нинди киңәш мәҗлесе икәнлеге алдагы мәкаләгә язылган аңлатма һәм искәрмәләрдә әйтелде.

[1] *хөкүмәтнең декларациясе* — бу вакытта Россия хөкүмәтенең башлыгы вазифасын И.Л.Горемыкин башкарган.

[2] *Баязидов* — сүз 1915 елда мөфти итеп куелган Сафа Баязидов турында бара. «Компаниясенең эшләгән эшләре» дигәндә, С.Баязидовның Петербургта бер төркем мөселман эшлекләләре тарафыннан оештырылган җәмгыять — «Сыйрател-мөстәкыйм» эшендә катнашуына ишарә ителә булса кирәк.

[3] *Епископ Андрей* — епископ Андрей (Ухтомский), Казанда архимандрит булып торганда, мөселманнарга христиан бәйрәмнәрен бәйрәм иттерергә тырышкан. Дәрәҗәсе үстерелеп, Уфага епископ итеп җибәрелгәч тә, ул мөселманнарга дошманлыгын дәвам иттергән. Аның турында Фатих Әмирханның «Епископ Андрейның каралыгы» исемле мәкаләсе дә бар («Кояш», 1917 ел, 27 март).

[4] *«Тәрәкъкыйпәрвәр блок»* — Беренче бөтендөнья сугышы барышында Россиянең уңышсызлыкларга очравына борчылган IV Дәүләт Думасы депутатларыннан 1915 елның 9 августында оешкан блок. Аның составына Думаның алты фракциясе (барлык 422 депутатның 236 сы) кергән. Блок вәкилләре патша хөкүмәтен тәнкыйтьләп чыкканнар, «ышаныч хөкүмәте» («правительство доверия») булдыруны таләп иткәннәр. Мөселман фракциясендә бәхәсләр булып, сәяси берләшмәләр арасыннан «тәрәкъкыйпәрвәр блок»ка керү теләге белдерелсә дә, әлеге блок моны игътибарга алмый. Блокны оештыручылар, барыннан да бигрәк кадетлар, мөселман депутатларның хокукый, дини, милли чикләүләрне бетерү омтылышын якласалар, октябристлар фракциясенең блоктан чыгуыннан куркалар. Хәер, мөселман вакытлы матбугатында мөселман фракциясенең Думадагы прогрессив көчләр белән сәяси блоклар төзү эшендә пассивлыгын гаепләп язганнар.

[5] *3 нче июнь правиласы* — 1907 елның 3 июнендә II Дәүләт Думасы таратыла һәм сайлаулар турында яңа закон кабул ителә. Аның буенча эшчеләр һәм крестьяннардан выборщиклар саны 2,5 мәртәбә киметелә, җирбиләүчеләр һәм буржуазиянеке 2 мәртәбә арттырыла, рус булмаган халыклар вәкилләрне бик аз санда салмый алалар.

[6] *Байтирәков* — Габделлатыйф Байтирәков (1873–1951), IV Дәүләт Думасында Уфа губернасыннан депутат.

[7] *Миңлегалиев* — Минһаҗетдин Миңлегалиев (1857–?), IV Дәүләт Думасында Самара губернасыннан депутат.

[8] *Далгат* — Мөхәммәд Далгат (Тәлгат, 1849–1922), IV Дәүләт Думасында Кавказдан (Дагъстаннан) депутат.

[9] *Садри әфәнденең фракцияне блокка кермәүдә гаепләп язулары…* — IV Дәүләт Думасындагы мөселман фракциясе шулай да «тәрәкъкыйпәрвәр блок»ка якынрак позициядә торган.

[10] *Йосыф бәк Җәгъфәревнең … бәяннамәләре …* — IV Думада Баку, Елисаветополь һәм Эриван губернаторларыннан депутат Мөхәммәд Йосыф Җәгъфәрев (1885–?) Дума утырышларында шактый еш чыгыш ясаган.

[11] *Гайса мирза* — Гайса Еникеев (1864–1931), II, III, IV Дәүләт Думалары депутаты.

[12] *...әлгәреге Дума рәисе Родзянко* — М.Б.Родзянко (1859–1924), Россия сәяси эшлеклесе, октябристлар партиясе җитәкчеләреннән, III һәм IV Дәүләт Думалары рәисе.

[13] *…совет әгъзасы профессор Максим Ковалевский* — Максим Максимович Ковалевский (1851–1916), социолог, хокук белгече, тарихчы, җәмәгать эшлеклесе, Россиянең Дәүләт Советы әгъзасы. Аның «Закон и обычай на Кавказе» исемле ике томлы хезмәте дә басылган (1890). Үлеме уңае белән «Вакыт» газетасының 1916 елгы 25 март (2006 нчы) санына бер мәкалә урнаштырылган.

[14] *Закир әл-Кадыйри әфәнде* — Закир Кадыйри (1878–1954), журналист, җәмәгать эшлеклесе, 1914–1918 елларда «Тормыш» газетасы редакторы.

[15] *...департаментлар* — бу елларда Россия министрлыклары, башка дәүләт органнарының аерым бүлекләре (мәсәлән, Рухани эшләр департаменты — Департамент духовных дел).

156 бит.

**Мөселман фракциясендә өченче киңәш мәҗлесе.** «Сүз» газетасының 1916 елгы 24 февраль (25 нче) санында «Гаяз» имзасы белән басылган. Текст шуннан алынды.

[1] *комитет* — сүз «Мөселман иттифакы» партиясенең Үзәк Комитеты турында бара.

[2] *Ләкин аерым-аерым депутатлары уңлашканнар.* — Мәсәлән, III Дәүләт Думасы депутаты И.Мөфтизадә уңнарга кушыла.

[3] *Гайса мирзаны үткәрергә тырышулары…* — Гайса Еникеев III Думага депутат булып Казан губернасыннан, IV Думага Оренбург губернасыннан сайлана. («Вакыт» газетасы позициясе йогынтысында.) Казаннан бу Думага бер генә мөселман депутаты үтә алмаган.

[4] *«Исламе мәгариф» гәзитәсе* — «Ислам вә мәгариф» исемле әлеге газетаны 1915 елда Петроградта Фатих Байрашев (1913 елның ноябрендә Дин эшләре департаментына — «Сыйрател-мөстәкыйм» исемле уң партияне төзүгә гариза (прошение) биргән дүрт кешенең берсе (буфет тотучы) чыгарырга омтылган.

[5] *Муса әфәнде* — Муса Бигиев.

[6] *... Садри әфәнде* — Садри Максуди.

[7] *Исмәгыйль әфәнде Леманов* — Бакчасарайдан килгән сәяси эшлекле, I һәм II Дәүләт Думаларында мөселман фракцияләре секретаре, кырым татар журналисты, җәмәгать эшлеклесе.

[8] *Миңлегалиев* — IV Дәүләт Дума депутаты Минһаҗетдин Миңлегалиев (1857–?), Самара губернасыннан сайланган.

[9] *Сәлимгәрәй мирза Җантурин* — җәмәгать эшлеклесе, мәгърифәтче, I Дәүләт Думасы депутаты; 1864–1926 елларда яшәгән.

[10] *Ибнәмин әфәнде Әхтәмов* (1877–1941) — юрист, IV Дәүләт Думасы депутаты, Уфа губернасыннан сайланган.

[11] *Шакир әфәнде Мөхәммәдъяров* (1883–1967) — сәяси эшлекле, хокук белгече, публицист, эсер, педагог.
[12] *Кәрим Сәгыйть әфәнде* — Кәрим Сәгыйтев (1888–1939), журналист, публицист, Петербургта торып Казан газеталарында язышкан, Тукай белән аралашкан (истәлеге бар).

160 бит.

**Киңәш мәҗлесе.** «Сүз» газетасының 1916 елгы 26 февраль (26 нчы) санында «Гаяз» имзасы белән басылган. Текст шуннан алынды.

[1] *Габдерахман әфәнде Рәхманкулов* — Троицк шәһәре мулласы.
[2] *Бүкәйханов* — Алихан Букәйханов (1870 яисә 1866 — 1937), Семипалат өлкәсеннән I Дәүләт Думасы депутаты, казакъ публицисты.
[3] *Байтурсунов* — Әхмәт Байтурсунов (1873–?), шагыйрь, тәрҗемәче, дәреслекләр авторы, 1913–1918 елларда казакъ телендә чыккан «Казакъ» газетасы нашире.
[4] *...урта казакълыктан бер әфәнде...* — XV гасыр ахырында оешкан Казакъ ханлыгы өч җүздән торган: Олы җүз, Кече җүз, Урта җүз. Г.Исхакый телгә алган кеше традицион рәвештә чыгышы белән Урта җүзгә караган.
[5] *Шакир әфәнде* — Шакир Мөхәммәдъяров.
[6] *«тәрәккъыйпәрвәр блок»* — IV Дәүләт Думасының алты фракциясе катнашында төзелгән блок («прогрессивный блок»).
[7] *Сидловский* — Сергей Илиодорович Шидловский (1861–1922), рус сәяси эшлеклесе, эре җир биләүче; IV Дәүләт Думасында октябристлар лидеры, «тәрәккъыйпәрвәр блок» бюросы рәисе.
[8] *Җәгъфәрев* — Мөхәммәд Йосыф Җәгъфәрев.
[9] *Караулов группасы* — Михаил Александрович Караулов (1878–1917), II һәм IV Дәүләт Думалары депутаты, IV Думада «тәрәккъыйпәрвәр блок»ка якын позицияне биләгән.
[10] *Садри әфәнде* — Садри Максуди.
[11] *...мөфти ителеп куелуы.* — Сүз 1915 елда Диния нәзарәтенә мөфти итеп куелган Сафа Баязидов турында бара.

166 бит.

**Мәскәү, 26 февраль.** «Сүз» газетасының 1916 елгы 26 февраль (26 нчы) санында «Гаяз» имзасы белән басылган. Текст шуннан алынды.

[1] *Якшәмбе көн* — 1916 елның 21 феврале.
[2] *Шәмси ага* — Шәмси Әсәдуллаев (1841–1913), азәрбайҗан мультимиллионеры, нефть сәнәгатьчесе, фән һәм мәдәният үсешенә бик күп матди ярдәм иткән, Мәскәүдәге Татар мәдәни үзәгенә (Татар йортына) махсус бина бүләк иткән. Ул Әсәдуллаев йорты буларак та билгеле.
[3] *Мәрхүм Ерзин* — Салих Йосыф улы Ерзин (1833–1911), танылган Мәскәү сәүдәгәре, эшмәкәр, миллионер, иганәче, Мәскәүдәге Җамигъ мәчетен (икенче мәчетне) тулысынча үз акчасына төзеткән (1903–1904).
[4] *Яхъя мулла пәриләре* — Татарстан Республикасы Арча районы Шекә авылында Яхъя бине Сәфәр бине Арслан (1758–1838) исемле бер мулла яшәгән. Имеш, үзенә буйсынган пәриләр аның бөтен теләкләрен үтәгәннәр. Ул Яхъя ишан исеме белән дә халык арасында мәшһүр булган.

169 бит.

**«Йолдыз»га соңгы җавап.** «Сүз» газетасының 1916 елгы 2 март (28 март) санында «Гаяз»имзасы белән басылган. Текст шуннан алынды.

Исхакый белән Һади Максуди арасында татар вакытлы матбугатының унъеллыгы уңае белән килеп чыккан бәхәс күп кенә татар газеталары һәм журналлары битләрендә дә чагылыш таба, мәсәлән, «Дин вә мәгыйшәт» журналының 1916 елгы 5 нче (29 гыйнвар) санындагы мәкаләдә, «Кармак» журналының 1916 елгы 7 нче (1 апрель) санындагы «Мәгъҗүнче шәкерт» вә ике «Батырлар» хикәясе («Сүз» вә «Йолдыз» кычкырышуы мөнәсәбәте белән») дигән язмада.

[1] *...язган фельетоныма...* — «Сүз» газетасының 1916 елгы 5 февраль (18 нче) санында чыккан Гаяз Исхакыйның ««Йолдыз»ның «миллилеге» исемле үз мәкаләсе истә тотыла.
[2] *...минем өстемә ташланды.* — «Йолдыз» газетасының 1916 елгы 26 гыйнвар (1597 нче) санында Һади Максудиның «Таңчы»га җавап», 31 гыйнвар (1601 нче) санында «Йолдызчы» имзасы белән «Таңчы» тагын сүгенә башлады» («Сүктек», «Сүгәбез», «Сүгәчәкбез»)»; 10 февраль (1606 нчы) санында имзасыз «Таңчы»га икенче җавап» исемле мәкаләләр басыла.

«Таңчы» тагын сүгенә башлады» мәкаләсе Г.Исхакыйның «Йолдыз юбилей»сы исемле мәкаләсенә җавап рәвешендә язылган. Автор 1906 елда Казанда чыккан «Таң» һәм «Тавыш» газеталарның аерым саннарында «Сүктек, сүгәбез, сүгәчәкбез» сүзләренең еш очравын, аларның хәтта газета девизына әйләнүен әйтә. «Таңчы»лар, «йолдызчы» фикеренчә, «Милли эшләрнең башында йөргән затларны мәрхәмәтсез рәвештә сүгә, тәхкыйрь итә, мөселманның һәрбер мөкатдәс нәрсәсеннән көлә, һичбер авторитетны тасдыйк итми иде. «Мөселман иттифакы»н хыял, алдакчылар корган тозак дип, гыйлем вә дингә таянып сөйләнгән сүзләрне «буш фәлсәфә» дип, имля төзәтүне «чепуха» дип атый иде». «Таңчы»ларның «Тәрҗеман»нан башлап һәммә татар гәзитәләрен сүгүләрен искәртеп, моңа дәлилләр рәвешендә «Таң йолдызы»ның 1906 елгы 27 июнь (12 нче) санында чыккан «Татар гәзитәләре» исемле редакцион мәкаләне һәм шул ук елгы 9 июнь (7 нче) санындагы «Чыңгыз» имзалы «Вакыт»ка җавап»ны китерә. Алга таба «йолдызчы» Исхакый чыгарган «Таң йолдызы», «Тавыш», «Ил», «Сүз» газеталары турында сүз алып барып, 1913 ел ахырында Петроградта нәшер ителә башлаган «Ил» газетасының мәсләге бөтенләй башка булуын искәртә: «Ул хәзер эшче халык өчен дә янмый, байлар (буржуазия), муллаларга да һөҗүм кылмый, биш-алты ел элек юан-юан «матур» сүзләр белән сүктегә татар гәзитәләре вә мөхәррирләренә дә тими, башка гәзитәләр ни язса, ул да шуны яза... Хәзер Гаяз әфәнде каршында эшче дә юк, алпавыт та, буржуй да, залим дә, мәзлум да юк. Алдаучы да, алданмыш та, «таңчы» да, тарилкәче дә юк, тик бер татар милләте генә, мөселман мәнфәгате генә бар». Гаяз Исхакыйның «Ил»че ясарга теләгән затларыннан Йосыф Акчура, Муса Бигиев, Шакир Мөхәммәдъяров, Сәгыйть Рәмиев, Зәки Вәлидиләр читләшүләренә төртеп күрсәтә. «Ил» газетасы тирәсендә бер-ике «таңчы» гына калган, имеш. «Ил» газетасы Петроградтан Мәскәүгә күчерелгәч, редакция Мәскәүгә килүче татар байлары төшә торган «Мещерское подворье»га (кунакханәгә) урнаштырылу фактына нигезләнеп, Гаяз Исхакыйның буржуазиягә «залимнәр», «кан

эчүчеләр» дип кычкырмый гына үзенә «җылы оя» ясавы әйтелә, ул «эшчеләрнең җилек майларын эчүче, аларның көчләрен эксплуатировать итүче купецларның ярдәмнәре белән бер ширкәт төзеп, «Ил»не матди яктан тәэмин итә...»

«Ил» туктатылгач, «Сүз» газетасы чыга башлый. «Сүз» наширлеге Әхмәдбәк Салиховка тапшырыла. Гаяз әфәнденең янә «таңчы»лык тамырлары тибә башлап, «Сүз»дә үзенең «таңчы»лык тарихларын яза башлый. «Бу мәкаләләрнең һәммәсендә «таңчы»лык тенденциясе кызыл җеп булып сузылып бара», — диелә «Йолдызчы» язмасында.

Гаяз Исхакый мәкаләсен укучылар: «Чынлап та, әллә «Йолдыз» шулаймы икән?» — дип уйламасын өчен, «Йолдызчы» әдип-журналистның «гәзитәчелек вә публицистлык тарихын бераз тикшереп, аның сүзләренең кыйммәте ни дәрәҗәдә икәнлеген күрсәтүне» тиешле таба. Аныңча, Исхакыйның хәзер «Йолдыз» өстенә пычраклар ыргытуы бер дә гаҗәп түгел: «490 юллык мәкаләдәге сүзләр катгыян бер хакыйкатьне ачу, бер явызлыкның өстеннән пәрдә күтәрү нияте белән язылган сүзләр түгел, бәлки пароходтан төртеп төшерелгәндә сүгенә-сүгенә калган «сүгешнамә»ләр чыгарып, берничә ай вовсю сүгенгән, милләтче булып карап та, муаффәкыять таба алмаган бер «таңчы»ның яңадан сүгенә башлавы гынадыр».

Өченче «ташланучы» — «Таңчы»га икенче җавап» исемле имзасыз мәкаләне язучы (авторы Һади Максуди булырга тиешле) Г.Исхакыйның «Йолдыз»ның миллилеге» дигән язмасында каршылыклы урын таба: анда автор (Исхакый) бер җирдә газетаның мәсләксезлегеннән көлүен әйтә дә язмасының ике юлын биләгән сүзләреннән соң бу көлүнең мәсләкләр аерымлыгы аркасында булуын «үзе дә сизмичә аңлатып куя». Димәк, «Йолдыз»ның мәсләге бар булып чыга. Аны мәсләксезлектә гаепләү дөрес түгел, имеш, имзасыз мәкаләдә Исхакыйның «Йолдыз»га бәйләнүен инкяр итүе дә «күзгә карап ялганлау» дип бәяләнә. Гыйффәт туташның «Сүз» газетасында «мөхтәрәмә мөхәррирә» Фәхрелбәнат Сөләйманияне тупас хурлап чыгыш ясавы да Г.Исхакыйның «Сүз»нең һичбер номерында һичбер гәзитә вә журналга бәйләнү булмады» диюе белән каршылыкка керә. Бу мәкаләдә шулай ук «Йолдыз»ны «Тавыш» һәм «Ил» газеталары өстеннән донослар ясауда гаепләү дә кире кагыла.

«Йолдыз»да басылган әлеге өч мәкалә уңае белән Мәхмүтфуад (бу имзаның иясе — Фуад Туктаров) «Сүз» газетасының үзендә өч санга (1916 елгы 10, 12, 14 февраль) сузылган «Мәҗбүри бер җавап» бастырып, бәхәстә Г.Исхакый ягына баса, «Йолдыз»дагыларны тупаслыкта гаепли, мәкаләләрендә сүгенүләр урын алуын әйтә.

«Йолдыз» газетасы моннан соң да сүзен бирми: аның 1916 елгы 24 февраль (1612 нче) санында «Йолдызчы» имзасы белән «Йолдызчы»ның җавабы» дигән репликасын урнаштырган.

[3] *Кечкенә фельетон белән астан керде.* — Югарыда искә алынган мәкаләләр укучыларга ул еллардагы исемләнеш белән кечкенә фельетон итеп тәкъдим ителгәннәр.

[4] *... соңгы елларда нәшерләрен үз өстемә алуым...* — мәсәлән, Гаяз Исхакыйның «Мөгаллимә» исемле 3 пәрдәле драмасы (Петербург, 1913) һәм «Остазбикә» хикәясе (Мәскәү: М.О.Актай и К⁰ типографиясе, 1915) Мөхәммәдгаяз әл-Исхакый наширлегендә басылган.

[5] *... ике йөз егерме «Йолдыз» мөхәррирен ярдәмгә чакырды.* — «Йолдыз» газетасы үзенең унъеллык юбилеена багышлап чыгарган 15 гыйнвар (1591 нче) санында «Ун ел эчендә «Йолдыз»га каләмнәре белән иштиракь иткән затлар» исеме астында «Йолдыз»га язышкан 220 ләп кешенең исемен, кем булуларын һәм кайда эшләүләре турында белешмә китерә. Болар арасында Г.Тукай, Г.Ибраһимов, Г.Камал, Ф.Әмирхан кебек татар әдәбияты классиклары, шулай ук Җ.Вәлиди, Г.Газиз, Һ.Атласи, М.Бигиев, Г.Баттал, Г.Ибраһимов һ.б.ларның исемнәре атала...

[6] *...сигезенчесе, тугызынчысы иттерелеп күрсәтелгән мөәррих Зәки Вәлиди берлән мөнәкъкыйд Нәҗип Гасрый ...* — әлеге исемлектә Һади Максуди үзе беренче, Садри Максуди икенче («II һәм III Дума әгъзалары, дәгъва вәкиле, «Йолдыз»да хәзер дә яза»), Гаяз Исхакый өченче («мәгъруф әдип, мөхәррир, «Сүз» гәзитәсенең мөәссисе вә мөхәррирләреннән») итеп китерелә. Теksттагы исемлектә Әхмәдзәки Вәлиди («мөәррих»), чынлыкта, уналтынчы, Нәҗип Гасрый («сабык «Ил» мөхәррире») егерме икенче итеп бирелә.

[7] *Себергә җибәрелүләремә ...* — Казан төрмәсендә алты ай утырган Гаяз Исхакый 1907 елның октябрендә Архангельск губернасына сөргенгә җибәрелә.

[8] *«Йолдызчы» әфәнделәрнең өчесеннән гыйбарәт...* — 2 нче искәрмәдә телгә алынган мәкаләләрнең авторларына ишарә ясала.

[9] *«Тавыш» мөхәррире Габдулла түгел, Гариф Биккинин иде, диде.* — Г.Исхакый «Сүз» газетасының 1916 елгы 20 гыйнвар (12 нче) һәм 5 февраль (18 нче) саннарында басылган «Йолдыз» юбилейсы», «Йолдыз»ның «миллилеге» исемле мәкаләләрендә Һади Максудины доносчылыкта гаепли. «Тавыш» газетасының редакторы Гариф Биккинин үлүе турында «Йолдыз»да хәбәр бастыруны («Йолдыз»ның «миллилеге» исемле мәкаләгә язылган 8 нче искәрмәне карагыз) Г.Исхакый донос дип атый. Һ.Максудины доноslыкта гаепләп язган «Йолдыз»ның миллилеге» мәкаләсендә Г.Исхакый ялгыш Гариф Биккининның исемен Габдулла дип яза. Әлеге язмага җавап рәвешендә «Йолдыз»да (имзасыз) басылган «Таңчы»га икенче җавап» исемле мәкаләдә исә: «Тавыш» редакторы Габдулла Биккинин түгел, Гариф Биккинин иде. Бер гәзитәнең мөхәррире үлгән, аның вафат хәбәре фәүкылгадә бер корректность белән икенче бер гәзитәдә (ягъни «Сүз» дә. — *Төзүчеләр*) язылган. Безнең ул хәбәремездә нинди донос бар», — диелә.

[10] *Хөсәен Әбүзәров һәм дә Кәримов типографиясенең мөдире учитель Габделмәннан әфәнде хакында судка бирелгәнлекләрен...* — «Тавыш» газетасы яптырылганнан соң, газетаның нашире Хөсәен Әбүзәров белән газета басыла торган Кәримовлар басмаханәсе мөдире, учитель Габделмәннан Әхмәтҗан улы Рәхманкуловлар судка бирелә. Әмма суд эшләре ахырына кадәр җиткерелми, чөнки Габделмәннан Рәхманкулов кинәт үлеп китә, ә Хөсәен Әбүзәров үзенең ул вакытта Казанда булмаганлыгын исбат итә ала.

[11] *Тагы «Йолдыз»ның 1601 номерындагы ... жирный хәреф берлән әллә кемнең дикъкатен җәлеп итәргә маташуы...* — чыннан да, «Йолдыз»чы мәкаләсендәге «без татарлар хөкүмәт каршында беренче ышанычлы кешеләрмез, тагын да итагатьле булырга кирәк [...]. Үзенең дә башы чыкмады, безнең башымызны да черетеп бетерде [...]. Нихәл, бабай, тел тикшерәмсез? Башка эшеңез юк бит, җирең, иркең мул, праваң кямил, корсак тулган, башка ни кирәк? [...] татар гәзитәләре безнең мәсләккә хилаф, шуның өчен дә һәммә татар гәзитәләрен сүгәбез» дигән урыннар калын хәрефләр белән басылган.

[12] *Тарифа* — монда сүз газеталарны мөштәриләргә (әбүнәчеләргә) җибәргәндә алына торган почта чыгымнары турында бара. «Йолдыз» газетасы өчен мондый чыгымнар кайбер рус газеталары кебек азрак билгеләнгән булса кирәк.

[13] *Ул ... мөхтәрәм Молчанов берлән сөйләшеп...* — «1901–1916 елларда С.-Петербургта чыккан «Петербургская газета»ның нашире һәм редакторы Молчанов турында сүз бара.

[14] *Дубровинның чыгарган «Русское Знамя»сы вә башка карагруһлар гәзитәләре...* — «Рус халкы союзы» партиясенең органы булган «Русское Знамя» газетасын доктор (табиб) Александр Иванович Дубровин (1855–1921) чыгарган (1991 елда кабат нәшер ителә башлый).

**Кырым рухани идарәсендә мәктәп-мәдрәсә мәсьәләсе.** «Сүз» газетасының 1916 елгы 4 март (29 нчы) санында «Гаяз» имзасы белән басылган. Текст шуннан алынды.

[1] *«Гавамил» укыла торган пустханәләре* — һөнәрчелек белән шөгыльләнә торган остаханәләр турында сүз бара булса кирәк.

[2] *Красный Крест* — авыруларга һәм сугышларда җәрәхәт алучыларга ярдәм итү максатында барлыкка килгән оешмалар. Россиядә XIX гасыр урталарында төзелә.

177 бит.

***** (Тагы «Сыйрател-мөстәкыйм» баш күтәрде...**). «Сүз» газетасының 1916 елгы 9 март (31нче) санында «Гаяз» имзасы белән басылган. Текст шуннан алынды.

181 бит.

**Тагы «Сыйрател-мөстәкыйм».** «Сүз» газетасының 1916 елгы 11 март (32 нче) санында «Гаяз» имзасы белән басылган. Текст шуннан алынды.

Фатих Байрашов 1915 елда «Ислам һәм мәгариф» дигән газета чыгаруны планлаштырган.

[1] *Сафа мулла* — Мөхәммәдсафа Баязидов.

[2] *Фатих Байрашов* — «Мөселман фракциясендә өченче киңәш мәҗлесе» исемле мәкаләгә язылган искәрмәне карагыз.

[3] *Хаҗи Теләши* —Мөхәммәт Хаҗи Теләши (1868/1870–1929, журналист һәм публицист; Нальчик тикшеренүчесе Р.Х.Хашхожева бу псевдонимның кабарда язучысы Кази-Бек (Юрий) Ахметуковныкы дип язды) — Парижда рус телендә чыгарылган «Мусульманин» журналының нашире һәм Петербургта чыгарылган «В мире мусульманства» газетасы редакторы («ниндидер бер кара аферист шәхес икәне мәгълүм булу белән журналны укымадылар». — *И.Рәмиев*). Бу басмаларны ул Столыпин биргән 15 мең сум акчага чыгарган, патша полициясе белән хезмәттәшлек иткән.

[4] *...әллә нинди Гыйсьмәтиләр, Нәүрузилар «Ислам вә мәгариф»кә кергәннәр, керәләр...* — Сүз журналист, сәясәтче бу елларда Петроградта яшәгән Габдулла Гыйсьмәти (1883–1938) турында бара.

[5] *Галиәсгар Гафури «Кояш»ка кергән иде.* — Язучы, публицист һәм журналист Галиәсгар Гафури-Чыгтай 1915 елда «Кояш» газетасында эшли.

[6] *Галимҗан Ибраһимов «Аң»га кергән иде.* — Галимҗан Ибраһимов «Аң» журналы редакциясендә җаваплы секретарь булып 1913 елның 18 октябреннән 1914 елның 13 февраленә кадәр эшли.

183 бит.

**Фракция янындагы «бюро» мөнәсәбәте берлән.** «Сүз» газетасының 1916 елгы 13 март (33 нче) санында «Гаяз» имзасы белән басылган. Текст шуннан алынды.

[1] *Кавказның «Ачык сүз»е* — Мөсаүвәт партиясенең лидеры, күренекле азәрбайҗан сәяси эшлеклесе, әдәбият галиме, язучы, тәрҗемәче Мәмәд Әмин Рәсүлзадә (1884–1955) 1915 елда чыгара башлаган «Ачык сүз» газетасы турында сүз бара.

[2] *«Вакыт» рәфикымызның ... «Фракция янында бюро тәшкиле» дигән мәкалә* — «Вакыт» газетасының 1916 ел, 8 март (1996 нчы) санында имзасыз басылган.

[3] *«Иттифак» программасы* — «Иттифакы мөслимин» («Мөселман иттифакы») партиясенең программасы, 1905 елның көзендә Рәшид Ибраһимов, Галимәрдан Тупчыбашев, Әхмәт Агаевлар тарафыннан язылып, партиянең 1906 елның 16–21 августында булган өченче съездында беркадәр үзгәртелеп кабул ителә.

[4] *...платформа мәсьәләсен мөзакәрәгә куючыларның берсе булуым...* — Гаяз Исхакый бу съезд утырышларында берничә мәртәбә чыгыш ясый, аерым алганда 20 августтагы утырышта «Программ маддәләрне берәр-берәр мөзакәрә кылаек, тәнкыйть кылаек, соңра, яраса, кабул итәрмез» дип сөйләгән (бу турыда басманың 6 нчы томындагы мәкаләләрне укыгыз).

[5] *«Дин вә мәгыйшәт»челәр* — Оренбургта 1906–1918 елларда чыккан журналда (нашире — Мөхәммәтвәли Хөсәенов) чыгыш ясаучылар, журнал тоткан позицияне яклаучылар.

[6] *Ишми ишаннар* — Ишмөхәммәд Динмөхәммәдев (1849–1919), дин эшлеклесе; демократик татар зыялылары тарафыннан еш кына тәнкыйть ителгән.

[7] *Өченче Думада социалист Ибраһим бәк Хәйдәрев* — Кавказдан, Дагъстаннан сайланган депутат, Думада башта социал-демократлар фракциясендә булса да, 1909 елда мөселманнар фракциясенә кушыла.

[8] *сәяси радикал Ибнеәмин әфәнде* — 337 нче биттәге искәрмәне карагыз.

186 бит.

**Татарча театр вә концерт.** «Сүз» газетасының 1916 елгы 13 март (33 нче) санында «Гаяз» имзасы белән басылган. Текст шуннан алынды.

Г.Исхакыйның бу мәкаләсе «Татарча театр вә концерт» исеме белән газетаның шул ук санында Мирсәяф Атласов бастырган язмага җавап рәвешендә басылган. Г.Исхакый фикерләре аңлашыла төшсен өчен, түбәндә М.Атласовның ул язмасы тулысында китерелә:

«Әндиҗан, 19 февраль, дүшәнбе көн кулыннан һичбер эш килмәгән, һөнәрсез, театрдан хәбәре юк вә бернәрсәгә дә мөстәхикъ булмаган ярым-йорты кешеләр (җыентык: татар вә урыс) тарафыннан татарча театр уйналды.

Сәхнәгә Гаяз әфәнде Исхакыйның «Мөгаллимә»се куелды. Афишаны бер һәфтә элгәре бастырып чыгардыкларыннан кемнәр уйнаячагы мәгълүм иде. Ләкин тамашага килгән халыкка, уйнаучылар афишадагы кешеләр булмаенча, башка бер кыйсем әдәпсезрәк татар вә урыс яшьләренең маска астында сәхнәгә чыгачаклары аңлашылды. Соңра афишада исеме күренгән затлар, боларның җинаятьләреннән разый түгеллекләрен аңлатып протест кыла башлагач, алар да үзләренең җинаятьләре халыкка фаш булмасын өчен, беренче пәрдә күтәрелер алдында теге әфәнделәрнең ризалыкларын үтенделәр. Халык аз булса да, пәрдә ачылып, уен башланды. Суфлер үзенең кулыннан килгән кадәр тырышып-тырмашып кычкырса да, милли татар театрының йөрәгенә хәнҗәр тыгып, мөкатдәс сәхнәгә чыгарга җөрьәт итә алган каһарманнар суфлерның агызыннан чыккан сүзләргә төшенә алмаенча, уйларына ни килсә, шуны сөйләп, тамашачылар алдында сәхнәне мәсхәрә иттеләр.

Беренче пәрдәдәге хәзрәт ролене уйнаучы сакалыны кызыл хынага буяган персиянга охшап сәхнәгә чыкканнан ук, тамашачылар нәфрәтләнә башладылар. Остазбикә ролене уйнаучы Фатих Байбиков өстенә хатыннар күлмәге, башына калфак киеп өстәлнең бер башында утырса да, аның Фатих икәнлеге ап-ачык беленеп тора иде.

Икенче пәрдәдә мөгаллим Габдулланың атасы эчке Русиядән ерак Сибириягә углыны күрергә барган карт ролене кыяфәте белән дә, сүз вә кыланышлары белән дә пьесада язылган гакыллы вә инсафлы хәзрәткә якын да килмәгән, тупас вә мәгънәсез бер кыяфәттә күрсәтелде. Уйнаучы хәзрәт булып, авыл йирендә теләнеп йөрегән хәерчеләр киемендә чыгып, алпан-тилпән селкенеп сәхнәгә чыкты. Тамашага килгән халык: «Безнең динне вә рухани муллаларымызны театр китапларында шушы кадәр мыскыл итеп язмаенча, яхшырак бер кыяфәттә күрсәтсәләр булмасмы», — дия, әдибебез Гаяз әфәндедән рәнҗи башладылар. (Сәхнәгә киенеп чыгу өчен башка йирдән кием сорап таба алмауларын белеп, каһарманнар бары да үз киемнәреннән чыкканнар иде.)

Килгән халык арасында наразыйлык, шау-шу була башлагач, Газиз Әлмөхәммәдевне теләп сәхнәгә чыгардылар. Газиз Әлмөхәммәдевнең яхшы ачык тавышы илән җырлавы бераз рух бирде.

Ләкин театр китабы язучы мөхтәрәм мөхәррирләремез уйнаучыларның кем вә нинди адәм икәнен белеп кенә рөхсәт бирсәләр, Әндиҗандагы тамагын туйдыра алмаган ач козгыннарның иске чабаталары белән мөкатдәс сәхнәгә чыгып, милли татар театрын аяк астына салып таптасалар, әдип вә мөхәррирләремез мондый бәхетсезлекләргә очрамаган булырлар иде».

[1] *Мин «Мөгаллимә»не язсам...* — бу драма Финляндиядә 1913 елның 6–8 декабрьләрендә иҗат ителгән.

[2] *Карт хәзрәт* — «Мөгаллимә» драмасының баш каһарманнарыннан мөгаллим Габдулланың авылдан килгән этисе турында сүз бара.

[3] *«Мөгаллимә»не «Сәйяр» труппага биреп...* — Гаяз Исхакыйның өч пәрдәле «Мөгаллимә» драмасы «Сәйяр» труппасы тарафыннан Мәкәрҗә ярминкәсе вакытында 1914 елның 16 августында уйнала. 1915 елда Уфада куела.

[4] *Кудаш дигән бер хәриф* — сүз Ильяс Кудашев-Ашказарский турында бара. Ул, 1914–1915 елгы сезонда Казанда «Музыка вә фаҗигаи исламия» исемле труппа оештырып, «Сәйяр» труппасында сәхнәләштерелгән пьесаларны үз труппасында да куйган. Бу турыда Г.Кәрам «Аң» журналында: «... «Сәйяр» труппасына аяк чалырга тырышкан кеби, «Сәйяр» артистлары тарафыннан игълан ителгән уеннарны шул ук кичәдә башка урыннарда уйнап, һәр ике тарафка һәм матди, һәм дә мәгънәви бик зур уңайсызлыклар китерде. [...] ләкин аны «труппа» дип атау бик мөнасиб булып бетәр микән? Кудашев үзе, бәлки, оста артист булса булыр. Әмма бер тарыдан ботка булмаган кеби, бер артисттан да труппа тәшкил итеп булмый.

Кудашев сезон башыннан башлап шәһәребезнең төрле урыннарында унлап спектакль куйды. Әмма нинди спектакльләр? Берсендән-бере начар, берсендән-бере адәм көлкесе!..

Театр галәменә асла тәгаллекы булмаган, театр нидән гыйбарәт икәнлеген дә белмәгән бер такым асламчы хатыннар, кибетче малайлар вә илхләрдән җыелган бер җыентык белән генә театр уйнауның мөмкин булмаганлыгын, гаҗәбә, Кудашев белми микәнни? Әгәр белсә, бу кадәр гөстадан халыкка ничек батырчылык кыла икән?» — дип язган (15 нче ел, 11/12 сан). И.Кудашев-Ашказарскийның бу еллардагы театраль эшчәнлеге Габделгазиз Монасыйповның «Артист кисәкләре» исемле язмасында да кискен тәнкыйть ителә («Йолдыз», 1914 ел, 25 ноябрь).

[5] *«Кыямәт»не исламнан көлүемне ясый торганнардыр.* — Бу комедия Петербургта 1909 елда язылган һәм 1911 елның 24 гыйнварында (?) Оренбургта «Сәйяр» труппасы тарафыннан сәхнәдә уйналган.

[6] *«Җәмгыять»не мөселманнарның «Җәмгыяте хәйрия»ләреннән, тәрәкъкые мәгариф җәмгыятьләреннән көлү иттереп чыгара торганнардыр.* — «Җәмгыять» комедиясе китап булып 1911 елда Казанда басыла һәм шул ук елның 14 октябрендә Казанда «Сәйяр» труппасы тарафыннан сәхнәгә куела. Н.Нәриманов режиссерлыгында 1911 елның 19 ноябрендә Әстерханда уйналган.

[7] *...озакламаенча ун ел тула.* — Татар театры тарихында зур сәхнәдә беренче рәсми спектакль Гаяз Исхакыйның «Өч хатын берлән тормыш» драмасы буенча 1906 елның 21 апрелендә Уфада Приказчиклар клубында куелган.

[8] *...елына ике мәртәбә була торган гаеттә...* — Рамазан һәм Корбан гаетләре турында сүз бара.

189 бит.

**Тагы «бюро» (Мөселман фракциясе...).** «Сүз» газетасының 1916 елгы 18 һәм 30 март (35 һәм 39 нчы) саннарында «Гаяз» имзасы белән басылган. Текст шуннан алынды.

[1] *Шул департаментның директоры Минкин* — Россия империясенең Эчке эшләр министрлыгының чит диннәр буенча рухани эшләр департаменты җитәкчесе турында сүз бара.

[2] *Шул департамент ... мөселманнарга каршы бер «фәтваиханә», шәйхелисламлык дәрәҗәсенә генә муафикъ хәрәкәтләрдә булынган, ислам фикъһесе хакында китаплар нәшер иткән иде.* — Бу урында Г.Исхакый әлеге департаментның үзенә карамаган эшләр белән шөгыльләнүен тәнкыйтьли, департаментның дини күрсәтмәләр бирүенә каршы төшә, ислам дине эшлекләләре үзләре хәл итәргә тиешлегенә басым ясый булса кирәк.

[3] *Ибнеәмин әфәнде шул хакта озын нотык сөйләде...* — Әлеге нотык «Сүз» газетасының 1916 елгы 18 март санында басылган.

[4] *Кавказ депутаты Йосыф бәк Җәгъфәрев* — аның нотыгы «Сүз» газетасының 1916 елгы 13 март (33 нче), 16 март (34 нче) саннарында басылган.

[5] *Бу нотык тиздән гәзитәмездә басылачактыр.* — Гайса Еникеев нотыгы «Сүз» газетасының 1916 елгы 26 март ( 38 нче) санында басылган.

[6] *Котлыкай мирза* — Котлымөхәммәд Тәфкилев.

[7] *Мәскәү мөселманнарының бюрога әгъза җибәрергә карарлары басылды.* — «Сүз» газетасының 1916 елгы 16 март (34 нче) санындагы «Мәскәү» мөселманнарыннан фракциягә ярдәмгә вәкил җибәрү» исемле хәбәрдә Мәскәү имамы Габдулла әфәнде, Гариф Бурнашев һәм башкаларның уртак фикергә килүләре, Думадагы мөселман фракциясе янында бюро ясавын хуплап, аңа Мәскәүдән әгъза итеп Әхмәдбәк Салиховны җибәрергә, аның хәятын (бюро әгъзасы буларак эшчәнлеген матди яктан) тәэмин итү мәсьәләсен дә хәл итәргә карар биргәннәре әйтелә.

195 бит.

**Мөфтилек тирәсендә.** «Сүз» газетасының 1916 елгы 20 март (36 нчы) санында «Гаяз» имзасы белән басылган. Текст шуннан алынды.

[1] *«Дин вә мәгыйшәт» безнең Казан мөхбиремезнең ... хәбәрен тәмамән күчерә дә ...* — әлеге журналның 1916 елгы 10 нчы (11 март) санындагы бу хәбәр «Сүз» газетасыннан (1916 ел, 2 март, 28 нче сан) күчереп бастырылган. Аның тексты:

«Садыйк мулла Иманколый

Мөхбиремез яза: сөйләнгән сүзләргә караганда, Казанның могтәбәр имамы. «Йолдыз»ның шагыйре дә» булган Садыйк мулла кайсы фронткадыр гаскәри имам тәгъйин ителгән. 450 сум мәгашлек биреләчәктер. Садыйк мулла шул көннәрдә Казаннан Одессага

китәчәк икән. Менә шул эшләр — Казан имамнарыннан әгъзалар җыеп депутатларга йибәргән хатларның башлыча сәбәбедер, диенеләдер. Шуның өчен депутатларымыз шул «Баязидов мөфти булып калсын» дигән Казан имамнары вә могтәбәр картларының гаризаларын караганда, шул маддәне хәтердән чыгармасыннар иде. Мәһди («Сүз», №28)».

Хәбәргә өстәмә рәвешендә журнал мондый аңлатманы бирүне дә кирәк тапкан:

«Безнең сөйләгән сүзләргә генә түгел, һич шөбһәсез белүемезгә күрә, Садыйк хәзрәт Одессага мәхәллә имамы ителеп тәгъйин кылынган. Гаскәри имам булып та тәгъйин кылына икән, бик яхшы, нур галә нур. Азган-тузган, диннән бизгән социалист шайтаннар тәгъйин кылынмаганы — муҗибе шөкран бер эштер. Фәкать Казан имамнарының депутатларга «Баязидов мөфти булып калсын» дип хат язганлыклары безгә мәгълүм түгел, һәм Казан хәзрәтләре депутатларга ул тарика мөрәҗәгать кылуларына күңел бер дә ышанасы килми. Ихтимал, алар, Тәфкилевнең Дума мөнбәреннән ваклануын күреп, «андаен вак эшләр илә маташмаңыз, хосусән шәхси интересларга бирелмәңез» дип язган булсалар, мөмкин. Әгәр дә ул эш дөрест булса, Казан имамнарының ул эшләре ниһаять дәрәҗә дөньядан хәбәрсезлекләренә, вә ниһаять дәрәҗә садәдиллекләренә, вә ниһая дәрәҗә тагы да әллә нилекләренә шаһиде гадел булачактыр. Бинаән галәйһи аларның ул эшләре үзләренә дә йөз аклыгы түгелдер.

Чөнки мөфти хәзрәтнең мөфти булып калуы, депутатлар эше, язган хатлары (әлбәттә, дөрест булса) һичбер мөнәсәбәтсез көлке генә бер эш булып каладыр. Алар ул гаризаларын Казанның Мещанский старостасына биргән булсалар, ни файда чыгар иде? Депутатларга биргән гаризаларының хөкеме дә, шуннан ким булмаса, бер дә артык түгелдер.

Инде «Сүз»нең бармак янавына яхуд бу эштә ике тиенлек әһәмияткә малик булмаган депутатларга биргән тәгълиматына килсәк, бөтенләй бер наданлык, бөтенләй бер адәм көлкеседер. Имеш, хөкүмәт тарафыннан тәгъйин вә падишаһымыз хәзрәтләре тарафыннан тасдыйк иделмеш бер хөкүмәт мәэмүренең урынында калдырылуыны үтенеп садәдилан тарафыннан [язылган, бирелгән] мөнәсәбәтсез гаризаларны караганда, ул эшкә мөнәсәбәтләре булмаган депутатлар мөфти хәзрәтенең әһлиятле, лиякатьле, мөтәдәйин галим бер затны бер урынга тәгъйин кылуыны артык җаһиллек, ахмаклык булырмы? Хуш, депутат хәзрәте хәтерләрендә тоттылар! Ни булды вә яхуд булачак? Болай булганда безнең Оренбург имамнары Оренбург губернаторларының да губернатор булып калуын депутатларымызга хат язып үтенеп куйсыннар, депутатлар да губернаторның бер урынга исправник тәгъйин кылуыны хәтерләрендә тотсыннар».

[2] *...татарлар үзләренә табигъ иткән русларның ...* — сүз XIII–XV гасырларда рус кенәзлекләренең Алтын Урдага буйсынып яшәүләре турында бара.

198 бит.

***** (Гәзитәмезнең мәктүбләр кыйсемендә...).** «Сүз» газетасының 1916 елгы 1 апрель (40 нчы) санында «Гаяз» имзасы белән басылган. Текст шуннан алынды.

Г.Исхакыйны бу репликаны язуга Фатыйма Шакулованың газетаның шул ук санында урнаштырылган «Хатага дикъкать» исемле мәктүбе этәргән. Әлеге хат исә үз нәүбәтендә «Хикмәт» имзалы берәүнең (Петроградтан) «Сүз» газетасының 1916 елгы 9 март (31 нче) санында урнаштырылган «Ислам вә мәгарифчеләр» дигән мәкаләсен уку тәэсирендә язылган.

«Хикмәт» мәкаләсендә сүз 1914 елда бер төркем кешеләрнең «Сыйрател-мөстәкыйм» исемле союз оештырырга йөрүләре искә төшерелә, ләкин, аныңча, «милли матбугатымыз, бөтен җәмәгать хадимнәремез каһәрләп, ләгънәтләр укып, аның бөтен әшәкелекләрен халык алдында ачып бирделәр, бөтен серләрен фаш итеп, зарарлы якларын күрсәтеп аңлаттылар. Шуның белән элекке козгыннар оясы пыр туздысы». Ахыр чиктә карагруһлар мәнфәгатен алга тоткан бу «ислам вә мәгарифчеләр» элгәреге «Сыйрател-мөстәкыймче»ләр союзы низагысында «дәрес алып, [...] сәясәт берлән халык эченә керү өчен, [...] «Ислам» байрагын күтәрергә булдылар», — ди ул. «Хикмәт», боларның яшьләр арасыннан «арка таяначак бер гөруһ халык эзләргә» тотынуларын, хәйләле эш йөртүләрен әйтеп, «эшнең төбе, нигезе — мөселман халкына зарар итү, милли мәдәниятебезнең нигезен җимерү булачактыр» дип белдерә. Мәкалә «мөселманнарның милли, аңлылары милли намусларын сатмаганнары «Сыйрател-мөстәкыйм»не ничек каршы алса, аның баласын да шулай каршы алырга тиеш»леген искәртеп тәмамлана.

Түбәндә Фатыйма Шакулова мәктүбен исә тулысынча китерәбез:

«31 нче номер «Сүз»дә «Ислам вә мәгарифчеләр» дигән фельетонда халыкны ике кыйсемгә аерып, берсенә — тәрәккъкыйпәрвәрләр, икенчесенә карагруһлар исемен бирә. Ләкин бу соңгы исем бирүе яңлыш һәм бондый яңлышны матбугатта тикшермәенчә вә пешерелмәенчә калдыру тиеш түгел. Чөнки тәрәккъкыйпәрвәрләргә каршы мөхафәзәкәрләр (яклау) була. Һәм бу ике кыйсем — икәве дә игътикадлы кешеләр. Адәмдә игътикад мөхтәрәм хәл һәм аларны карагруһлар дип әйтеп булмый. Карагруһларда игътикад булу ихтималы юк.

Хикмәт ага әйтә:

«Русия татарларының тәрәккъкыйпәрвәрләр яшь буыны хәят байрагын кулына тотып мәдәният дөньясына аяк басканга әле гасырларча вакыт үткәне юк. Аның тарихы бик кыска, ул дөньяга килүе берлән, хәят байрагын күрсәтүе берлән татар эчендә тәназыгы бәка мәйданга килде. Бу көрәшү, бу тартышуда халык табигый сурәттә икегә аерылып китте. Берсе «мәгърифәт, мәдәният, хәят» диде. Шуның өчен тырышырга тотынды. Китапка, әдәбиятка ябышты. Ысуле җәдидне уйлап чыгарды. Шуны бөтен милләткә кабул иттерергә тырышты. Болар тәрәккъкыйпәрвәрләр иде. Икенче кыйсем «искелек, кабер-ахирәткә башка һәммәсе дә хәрам, дөнья кяферләр өчен генә яратылган» дип фәтва чыгарды. Бу кыйсем карагруһлар кыйсеме иде, ди.

Яңлыш шунда: кешеләр кабергә ышана, ахирәт көненә, кемнең хәрамы бар, искесе бар, димәк, аның игътикады бар. Игътикадлы кешеләрдән карагруһ булу ихтималы булмаган шикелле үк, карагруһларда игътикад булу ихтималы юк».

Г.Исхакый фикеренчә, татарларда әле консерваторлар (Англиядәге мәгънәсендә) дип исемләнерлек агым формалашмаган.

201 бит.

**Мәрхүм Тукай.** «Сүз» газетасының 1916 елгы 3 апрель (41 нче) санында «Гаяз» имзасы белән басылган. Текст шуннан алынды (Э.Ханнанова тарафыннан әзерләнеп, «Мәдәни җомга» газетасының 1996 елгы 23 май санында кабат бастырылды).

Мәкалә Габдулла Тукайның вафатына өч ел тулу көннәрендә язылган. Исхакый, шагыйрьнең вафаты көннәре җиткәч, һәр ел саен газетасында аның турындагы мәкалә һәм истәлекләргә урын бирә, үзе дә аңа багышланган язмаларын урнаштыра. «Мәрхүм Тукай» — шуларның өченчесе. Анда Тукайның мирасына һәрвакыттагыча югары бәя бирелә. Тукай исән булса, татар дөньясына әллә никадәр бөек әсәрләр бирер иде, дигән үкенеч белдерә. Язманың буеннан-буена ул Тукай үлеменә гаеплеләрне һәм гаепне эзли.

[1] *...татарның үз «Евгений Онегин»ы ...* — бу очракта Г.Исхакыйның «Евгений Онегин» поэмасын рус поэзиясенең олы казанышы итеп санаганлыгы сизелә. Тукай үзе дә «Пушкин вә мин» шигырендә бу әсәрне телгә ала, 1912 елның язында

Петербургка баргач, Сафа Баязидов фатирында «Евгений Онегин» операсыннан (грампластинкага язылган) Онегин арияләрен тыңлый.

[2] *Белегвар Җәгъфәр* — Алмыш (Алмас) хан (Җәгъфәр бине Абдуллаһ, IX йөз ахыры — X йөз башы), Бөек Болгар дәүләте идарәчесе. Г.Исхакыйның «Ике йөз елдан соң инкыйраз» әсәрендәге төп геройның Җәгъфәр исемен йөртүе дә беркадәр шушы фактка да бәйле булса кирәк.

204 бит.

**Кырымда Зынҗырлы мәдрәсәсе вә идарәи рухания эшләре.** «Сүз» газетасының 1916 елгы 6 апрель (42 нче) санында «Гаяз» имзасы белән басылган. Текст шуннан алынды.

Мәкаләдә сүз Бакчасарайның Салачык мәхәлләсендә XV йөз ахырларыннан — Кырым ханы Миңлегәрәй заманнарыннан бирле эшләп килгән Зынҗырлы мәдрәсәсе турында бара.

[1] *Кырым мөфтисе Гадил мирза Корашайский истигъфа итә...* — Кырым татарлары милли хәрәкәте җитәкчесе Ногман Чәләби Җиһан (Чәләби Чәләбиев) 1917 елның мартында Кырым мөфтие итеп сайлана.

[2] *Сөләйман мирза Кырымтаев* — «Сүз» газетасының 1916 елгы 1 июнь (60 нчы) санында бу кешенең «Зынҗырлы мәдрәсәсе әтрафында» исемле язмасы урнаштырылган. Редакциянең искәрмәсендә «Зынҗырлы мәдрәсәсе хакында ачык мәгълүм булсын өчен, идарә, битарафлык вазифасын тәмамән үтәп, Сөләйман мирза Кырымтаев җәнабларының мәкаләсен гайнән басадыр» диелгән. Бу мәкаләнең соңарып басылуына сәбәп аның Г.Исхакый Мәскәүдә юк чагында килүе, Исхакыйның үзенә адреслануы, шунлыктан әдип Мәскәүгә кайтканчыга кадәр газетага урнаштырылмый торуы күрсәтелә.

[3] *Чәләбизадә...* — Ногман Чәләби Җиһан турында сүз бара булса кирәк.

[4] *Сәедәхмәт* — Җафәр Сәедәхмәт (1889–1960), юрист, Кырым татар милли хәрәкәте җитәкчеләреннән.

209 бит.

**Бюро булды.** «Сүз» газетасының 1916 елгы 8 апрель (43 нче) санында «Гаяз» имзасы белән басылган. Текст шуннан алынды.

Фракцияләр башкарасы эшләрне координацияләү һәм депутатларның җәмгыять белән бәйләнешен көчәйтү максатында IV Дәүләт Думасындагы фракцияләр каршында махсус бюролар булдырылган. Мөселман фракциясенең дә шундый бюросы оештырыла һәм ул 1916 елның мартында эшли башлый. Башта аңа Казан, Уфа, Оренбург һәм Троицк вәкилләре генә кергән.

[1] *Нәҗип әфәнде Корбангалиев Петроградка китте.* — Әлеге бюро әгъзасы, адвокат (Харьков университетында укыган; Троицкидан) Мөхәммәтнәҗип (Нәҗип) Корбангалиев (1866–1918 дән соң) турында сүз бара, 1917 елда Милләт мәҗлесе делегаты.

[2] *Уфаның йибәргән әгъзасы...* — Шакир Мөхәммәдъяров (1883–1967), юрист, публицист, әдәби әсәрләре бар; 1916 елда мөселман фракциясе янындагы бюро әгъзасы.

213 бит.

**Муса әфәнденең «сыйрател-мөстәкыймче»ләр берлән мөнәсәбәте.** «Сүз» газетасының 1916 елгы 20 һәм 22 апрель (45 һәм 46 нчы) саннарында «Гаяз» имзасы белән басылган. Текст шуннан алынды.

Мәкалә «Вакыт» газетасының 1916 елгы 5 һәм 6 апрель (2012 һәм 2013) саннарында Муса Бигиевнең «Муса Җарулла» псевдонимлы, «Әүвәлге сүзләрем» исемле, Гаяз Исхакый телгә алган күләмле мәкаләсе басылу уңае белән язылган.

Мәкаләдә Г.Исхакыйның «сыйрател-мөстәкыймче»ләргә кискен каршы позициядә торуы, күренекле дин галиме, җәмәгатьчелек алдында зур абруй казанган Муса Бигиевне тегеләр ягына авышуын һич тә булдырмаска омтылуы ачык күренә.

[1] *«Муса әфәнде, «сыйрател-мөстәкыймче»ләр» дип бер мәкалә килде.* — «Сүз» газетасының 1916 елгы 17 апрель (44 нче) санындагы бу мәкаләнең төгәл исеме — «Муса әфәнде вә «Сыйрател-мөстәкыйм». Ул «Сыйрател-мөстәкыйм»нең яңгы мәйданга атылу, шундагы максадлары, йөзләре тәмамән ачылсын өчен аларның [...] булган фикерләре тикшерүдә әфкяре гомумиягә битарафча ярдәм итешер өчен, «Сыйрател-мөстәкыйм»нең ике тарафдарының язуларын гайнән дәреҗ итәмез» дигән искәрмә белән басылган. Мәкалә ике өлештән тора.

Беренчесе — «Шайтаннар кайгыра» исемле*, авторы — Һатиф. Анда, аерым алганда, болай диелә:

«[...] моннан бер ел кадәр әүвәл Петроградта бер «Сыйрател-мөстәкыйм» җәмгыяте оешу хәбәре тасдыйк өчен мәрамнамәсе хөкүмәткә тәкъдим ителү хәбәре чыгу илә, шайтаннар кеби кызыллы-яшелле яшь-йилкенчәкләр**, котлары очып, каравыл кычкырдылар, хәрап буламыз, милләт хәрап була. Бу «Сыйрател-мөстәкыйм» дигән сүз бит, безнең милләт («тугры юл» дигән исеменнән үк күренеп тора, «тугры юл» дигән сүз бит) тугры юлдан китәләр дә,безем һаваларда да иярмәсләр дия, «сыйрател-мөстәкыймче»ләрне пычратырга керештеләр. Ул вакытта әле җан кермәгән иде, менә инде бу ел, имеш, «сыйрател-мөстәкыйм-че»ләр җанланадыр. Менә аларның җанлануына галәмәт Фатих Байрашев «Ислам вә мәгариф» исемендә гәзитә чыгара, имеш, бу инде — шул «Сыйрател-мөстәкыйм» партиясенең органыдыр. Аңа, исеменнән үк билгеле, мәгариф кенә дип исем бирми, «Ислам вә мәгариф» дия дә, әлбәттә, бер сер бар. [...] Юк, болай ярамый! Хәзер бу бит тәрәкъкыйпәрвәр аталган безгә хәзер халыкны үземезгә аударырга мөмкин. Вакыт үтмәс борын, халык ул «Сыйрател-мөстәкыйм»нән һәм «Ислам вә мәгариф»тән хәбәрсез вакытта, без аны пычратыйк, халыкның ихласы кайтсын, шулай итеп, ул рәваҗ тапмас, юкса без: «Тукта әле, нинди булыр?» — дип торсак, алар халыкка йогышлы, файдалы нәрсәләр язып эш күрсәтсәләр, халыкны үзләренә җәлеп итәрләр дә соңра безнең бушбугаздан кычкыруымызга халык илтифат итми башлар, дия киңәшкәннәр. Менә хәзер «йолдызчы»лар, «сүзче»ләр бар көчләрен шул изге эш артыннан йөрүчеләрне пычратырга керештеләр. Без әүвәлдән үк аларга тирес яктан карыйдыр идек, моннан ары һәм шулай карармыз идек, моннан ары һәм шулай карармыз һәм карарга тиешбез. Аларның кара ягын һаман чүкчеп, фаш итә торамыз, диләр. «Йолдыз»чылар илә «сүзче»ләр бит алар күптән түгел генә берен-бере бик макташканнар иде. Аларның үзләре тәгъбиренчә, бер тарафы монафикъ мәраи алдакчы, доносчы, хулиган булып, икенче тарафы җил тегермәне илә сугышкан Дон Кихот, идиот иде бит, шулай булгач инде, алар донос та итәрләр, җил тегермәне илә көрәшкән кеби һәртөрле нахальный юл илә сугышырга да керешерләр. Бу инде аларга гадәт булган нәрсәдер. Алардан һәртөрле әдәптән куркып иген икмәй калу ярамаган кеби, андый Дон Кихотлар тавышына карап, изге эштән тукталырга тиеш түгелдер».

«Сыйрател-мөстәкыйм» дип исемләнгән икенче өлешендә («Сүз» газетасы редакциясе исеменнән булса кирәк) «Сыйрател-мөстәкыйм» үзенең рухы вә максады берлән тугрыдан-тугры русларның карагруһ партияләренең копиясыдер. Бу җәмгыять мөселманнар исеменнән йөртелсә дә, моңардан мөселманнарга зарарга башка һичбер файда чыкмаячактыр. Моның артында йөрүче кешеләрнең бөтен мөселманнар исеменә яшеренеп тәгъкыйб иткән эшләре үзләренең фәкать шәхси мәнфәгатьләре өчен генә икәнлегенә канәгате вөҗданиямез хасил улды. Шуның өчен дә бөтен мөселманнарга шул куркынычлы, ямьсез җәмгыятьнең чын

төсен ачып бирүне үзебезнең милли, мәдәни бурычымыз дип санап матбугатка чыкты» дип язылa (Ил, 1914, 5 нче сан). Аннан соң Муса Бигиев «Вакыт» газетасының 1916 елгы 6 апрелендә бастырган язмадан өзекләр китерелә. М.Бигиев үз позициясен аңлата, үз-үзен тотышында хыянәт, мәкер юклыгын әйтә.

[2] *Габдулла Гыйсьмәти* — 1883–1938 елларда яшәгән җәмәгать эшлеклесе, журналист; мәкалә язылган елларда Петербург психоневрология институты хокук бүлеге студенты.

[3] *Вәгыйз Нәүрузи* — журналист, Октябрь инкыйлабыннан соң чит илдә яши.

[4] *Хәлим Искәндәрев* — 1888–1958 елларда яшәгән журналист, әдәбият тәнкыйтьчесе, педагог.

[5] *Кавказның «Ачык сүз», «Яңгы икъбаль» мәсьәләгә катышты.* — «Ачык сүз» исемле көндәлек газетаны 1915 елның октябреннән башлап Мөхәммәдәмин Рәсүлзадә, «Яңа икъбаль» газетасын исә 1915 елның апреленнән башлап Газиз Хаҗибәков чыгарган.

[6] *Болар «Дин вә мәгыйшәт»нең 14 нче номерында ачык язылганга...* — бу урында автор журналның 1916 елгы 14 нче санындагы имам вә мөдәррис Мөхәммәт Габделхәй Корбангалиевнең «***(Фракциямез хозурында...)» исемле мәкаләсенә журнал идарәсе (редакциясе) биргән искәрмәгә (чынлыкта, күләмле мәкалә) ишарә итә булса кирәк.

222 бит.

**Мәскәүдә икенче адым.** «Сүз» газетасының 1916 елгы 22 апрель (46 нчы) санында «Гаяз» имзасы белән басылган. Текст шуннан алынды.

[1] *...тиҗарәтханә ачулары гәзитәмездә язылып үткән иде.* — «Сүз» газетасының 1916 елгы 8 апрель (43 нче) санындагы «Мәскәүдә яңа тиҗарәт ширкәте» дигән, авторы күрсәтелмәгән язмада 5 апрельдә Мәскәү мөселманнары арасында «Торговый дом Бурнашев, Карамышев һәм компанияләре» исемле яңа сәүдә ширкәте ачылуы, аның максаты «Урта Азия белән Сибириядә каракүл һәм пушной мал тиҗарәтен арттыру» булуы әйтелә. Ширкәт «Торговый дом...» рәвешендә төзелсә дә, асыл максат ширкәтне акционер компания итүдән гыйбарәт була. Ширкәткә Мәскәүнең барлык могтәбәр сәүдәгәрләре дә катнаша. Аның әгъзалары башта 30 кадәр булып, әмма тиз арада тагы да артуына ышаныч белдерелә.

225 бит.

**Безнең юлымыз.** «Сүз» газетасының 1916 елгы 24 апрель (47 нче) санында «Гаяз» имзасы белән басылган. Текст шуннан алынды.

[1] *Касыйм ханнары, мирзаларының рус князьләренең бармак ишарәләре берлән хәрәкәт итүләре* — 1450 елларда Мәскәүнең бөек кенәзе Василий II тарафыннан Казан ханлыгына каршы көрәштә татарларның үзләреннән файдалану өчен оештырылган Касыйм ханлыгы (үзәге — хәзерге Рязань өлкәсенең Касыйм шәһәре). Идарәчеләрен Мәскәү кенәзләре һәм патшалары билгеләп куйганнар, нәсел буенча варислык булмый. Касыйм ханнары еш кына Казанга каршы Мәскәү оештырган яуларга үз гаскәрләре белән катнашканнар.

[2] *Казан, Әстерханны руска алып бирүе...* — 1552 һәм 1556 елларда рус гаскәрләренең Казан һәм Әстерхан ханлыкларын басып алганда Касыйм ханнары диндәшләренә ярдәмгә килмәгәннәр, киресенчә, беркадәр булышканнар гына. Мәсәлән, Казанны яулап алучылар арасында Шаһгали хан җитәкчелегендәге гаскәрләр дә булган.

[3] *... төрек йилкәсенә арка таянган Багдад хәлифәте...* — Габбасилар хәлифәлеге (Багдад хәлифәлеге) 1055 елда мөстәкыйльлеген югалта, тумышы белән Габбасилар династиясеннән булган хәлифәнең роле рухани сферада гына саклана. Багдадны, Мисырны яулап алгач, төрек солтаны хәлифә дип игълан ителә.

228 бит.

**Гәзитә нәрсә?** «Сүз» газетасының 1916 елгы 27, 29 апрель һәм 1 май (48, 49 һәм 50 нче) саннарында «Гаяз» имзасы белән басылган. Текст шуннан алынды.

[1] *Газазил галәйһи әл-ләгънәтә* — бу урында Газазил исемле фәрештә искә алына. Коръәндә аның Аллаһының әмерен тыңламавы өчен ләгънәтләнүе әйтелә. Иблис, шайтан дип тә йөртелә.

[2] *Габдрахман Ильясов һәм дә Габделкаюм әл-Насыйри, ахырга таба Шаһбазгәрәй мирза Әхмәрев бернична мәртәбә министрга мөрәҗәгать итсәләр дә...* — татар телендә газета чыгарырга омтылыш XIX гасыр башлангач та байлыкка килә (1808 елда — профессор И.И.Запольский, 1834 елда — М.Г.Никольский, 1864 елда — П.И.Пашино, И.Нафаль, 1865 елда В.С.Курочкин омтылып карыйлар). Гасыр ахырына таба татарлар үзләре дә активлаша. 1863 елда Каюм Насыйри Казан хәрби губернаторы исеменә гариза (прошение) белән мөрәҗәгать итсә, әмма цензура турында яңа устав әле кабул ителмәгән булу сәбәп ителеп, татарча матбугат органына рөхсәт бирелми. К.Насыйри аннан соң да теләгеннән кайтмый, «Таң йолдызы» исемле газетаны чыгару уе белән йөри. Драматург Габдрахман Ильясиның «Казан» исемле газета чыгарырга омтылышы да (1887) игътибарсыз калдырыла. 1894–1895 елларда шул исемдәге газета булдырырга Шаһбазгәрәй Әхмәрев омтылышы да чынга ашмый. XIX гасыр дәвамында татар телендә газета чыгаруны сорап хакимият органнарына 20 дән артык гариза кергән.

[3] *...Гаспринскийга «Тәрҗеман»га рөхсәт бирелгән.* — Гомумтөрки телле беренче газета — «Тәрҗеман»ның беренче саны 1883 елның 10 апрелендә Кырымдагы Бакчасарай шәһәрендә дөнья күрә. Исмәгыйль Гаспринский аның нашире һәм мөхәррире вазифасын 1914 елга кадәр (вафатынача) үтәп килгән.

[4] *...кәгазьләрне гәзитә ясап чыгаруын киләчәктә сөйләрмез.* — Бу урында мәкалә текстының «Сүз» газетасының 27 апрель санында чыккан өлеше тәмамлана.

[5] *Бер бик бәйләнгеч кешенең исемендәге йомшак «гайн» урынына каты «гайн» куелган!* — Мәкаләдә йомшак «гайн» дип аталган хәреф — чынлыкта нечкә әйтелешле «e» («гайн») хәрефе. «Бәйләнгеч кеше» дип Гаяз Исхакый исә үзенә ишарә ясый. Аның исеме гарәп графикасындагы татар язуында әлеге «e» («гайн») хәрефе белән башлап языла.

[6] *Буның ничек йибәрүе киләчәктә язылыр.* — Моннан соң мәкаләнең «Сүз» газетасының 29 апрель санында басылган өлеше китерелә.

[7] *...тракты-тракты белән аерып...* — ул елларда Россиядә почта элемтәсенең юнәлешләре трактлар буенча билгеләнгән.

[8] *Аннан соң ничек булуы киләчәктә.* — «Сүз» газетасының моннан соңгы саннарындагы мәкаләнең ахыры очрамады.

240 бит.

**Имтиханнар мөнәсәбәте илә.** «Сүз» газетасының 1916 елгы 1 май (50 нче) санында «Гаяз» имзасы белән басылган. Текст шуннан алынды.

Бу елларда татар вакытлы матбугаты битләрендә язга чыккач, укулар тәмамлангач та, мәктәп-мәдрәсәләрдә имтиханнар уздырылу турында куанычлы мәкаләләр, хәбәрләр басылып тора.

244 бит.

**Унъеллык Дума вә мөселманнар.** «Сүз» газетасының 1916 елгы 5 май (51 нче) санында «Гаяз» имзасы белән басылган. Текст шуннан алынды.

I Дәүләт Думасы 1906 елның 27 апреленнән 8 июльгәчә кадәр генә эшләп кала. Мәкалә шул Думаның эшли башлавына 10 ел тулу уңае белән язылган.

[1] *…мөселманнары сиксән биш кадәр вәкил сайладылар.* — Мөселманнардан I Дәүләт Думасына — 25, II Дәүләт Думасына — 37, III Дәүләт Думасына — 10, IV Дәүләт Думасына 6 депутат сайлаган була (барысы 78 депутат).

[2] *«Өченче июнь законы» буенча ... вәкилсез калдырылды.* — Россиянең Министрлар Советы Рәисе П.А.Столыпин (1862–1911) 1907 елның 3 июнендә сайлаулар турында яңа закон чыгара. Аның буенча сайлауларга зур үзгәрешләр кертелә (аерым алганда, рус булмаган халыклардан бик аз кеше генә депутатлыкка үтә алган).

[3] *Тимер батыр* — әкият герое (мәсәлән, «Камыр батыр» исемле татар әкиятендә).

[4] *... цензалы булды да сайланды.* — 1907 елгы сайлаулар турындагы закон рус булмаган халыклардан, бигрәк тә мөселманнардан, вәкилләрнең Думага депутат булып үтү ихтималын гаять киметте. Җирле властьлар административ ресурсны еш кулландылар.

[5] *Бу мәсьәләдә Уфа гына бераз мөстәсна.* — IV Дәүләт Думасына Уфа губернасыннан Санкт-Петербург университетын тәмамлап юрист булган (югары белемле) Ибнеәмин Әхтәмов (1877–1941) сайлану истә тотыла булса кирәк. IV Дәүләт Думасына да депутат булып сайланган Котлымөхәммәд мирза Тәфкилев (1850–1917) урта белемле генә булган (Пажеский корпус тәмамлаган).

[6] *Аннан Миңлегалиев, моннан Байбурин, тегеннән Мөфтизадә, моннан Тәлгат сайландылар да килделәр.* — IV Дәүләт Думасына Самара губернасыннан, Минһаҗетдин Миңлегалиев, III Дәүләт Думасына Оренбург губернасыннан, Җиһангир Байбурин, Кырымнан, Исмәгыйль мирза Мөфтизадә, IV Дәүләт Думасына Дагъстаннан Мөхәммәд Далгат сайланган була.

[7] *депутатларымыз речьләрен ... бөтен нотыкларын татарчаландырып нәшер итү...* — II һәм III Дәүләт Думалары депутаты Садри Максудиның чыгышлары гына «Йолдыз» газетасында еш басылган.

247 бит.

**«Таң» гәзитәсе чыгуына ун ел тулу мөнәсәбәте берлән.** «Сүз» газетасының 1916 елгы 18 май (56 нчы) санында «Гаяз» имзасы белән басылган. Текст шуннан алынды.

«Таң», дөресрәге, «Таң йолдызы» газетасы 1906 елның 18 маенда чыга башлый, фактик редакторы — Гаяз Исхакый. Газетада аның күпсанлы мәкалә һәм фельетоннары дөнья күргән. 65 саны чыккач, 1906 елның ноябрендә газета патша властьлары тарафыннан тыела. Аның тирәсенә тупланган Гаяз Исхакый, Фуад Туктаров, Сәгыйть Рәмиев һәм Шакир Мөхәммәдъяровлар составындагы төркемне «таңчы»лар дип йөрткәннәр.

«Сүз» газетасының моннан алдагы санында (1916 ел, 15 май) «Дахили хәбәрләр» рубрикасында түбәндәге хәбәрне урнаштырган:

«Оренбургта Гаяз әфәнде шәрәфенә зыяфәт.

Мөхтәрәм әдибемез Гаяз әфәнде Исхакыйның шәһәремездә мосафир булыну мөнәсәбәте илә мөхлисләре тарафыннан аның шәрәфенә «Биржевый гостиница» залында 8 майда якшәмбе көн зыяфәт бирелде.

Зыяфәттә 30–40 кеше бар иде. Мәҗлес мөнәсәбәтле нотыклар сөйләнеп вә мөсәхабә ителеп зыяфәт бик гүзәл үтте».

Хәбәр «Вакыт» газетасының 1916 елгы 6 май саныннан күчерелеп басылган.

[1] *...хәзерге көндәге сәяси һавалар...* — бу вакытларда Беренче бөтендөнья сугышы бара, илдә цензураның көчәю сәбәпле, вакытлы матбугатта хакыйкый фикерне әйтү мөмкинлеге чикләнә.

251 бит.

***** (Бу көнге көннең иң мөһим милли мәсьәләсе...).** «Сүз» газетасының 1916 елгы 28 май (59 нчы) санында «Гаяз» имзасы белән басылган. Текст шуннан алынды.

Газетаның 1916 елгы 13 май (54 нче) санында имзасыз «Мәктәп вә школа тирәсендә» дигән бер язма урнаштырылган. Анда IV Дәүләт Думасы эшчәнлегендә, съездларда, төрле киңәш мәҗлесләрендә урын алган иң беренче мәсьәләнең уку-укыту мәсьәләсе булуы, мәсәлән, школаның «татарча да, русча да белмәгән, дөнья кирәкләрен кайгыртуга бераз гына да булсын хәзерләнмәгән чиле-пешле үсмерләр чыгара торуы» әйтелә. Язмада Уфада булачак киңәш мәҗлесе турында да сүз бара: «Бу ел җәй Уфада мәктәп вә школаларга гаид мәсьәләләрне тикшерер өчен мөселман вәкилләренең катнашы белән киңәш мәҗлесе булачагы мәгълүмдер. Менә шушы тәшәббесләрнең барысын да бергә җыйганда, уку-укыту мәсьәләләре тагы да шактый зур эш башлаганлыгын күрәбез. Ләкин бу тәшәббесләр хакыйкатән зур эш булып чыксын өчен, иң элек матбугатта вә җәмәгать хадимнәренең үзләре арасында мөселманнарның мәгарифенә гаид әсаси мәсьәләдә фикер берлеге булырга тиештер.

Уфада булачак киңәш мәҗлесенә хәзерләнү мөнәсәбәте белән милли матбугатта әлегәчә басылган мәкаләләр барысы да мәзкүр фикер берлегенең юклыгын күрсәтәдер». Бу язманың авторы Г.Исхакый үзе үк булырга мөмкин.

252 бит.

***** (Үткән номер гәзитәмездә...).** «Сүз» газетасының 1916 елгы 5 июнь (61 нче) санында «Гаяз» имзасы белән басылган. Текст шуннан алынды.

«Сүз» газетасының 1916 елгы 3 июнь (58 нче) санында: «Бу көн иртә белән Гаяз әфәнде Оренбург, Казан шәһәреннән Мәскәүгә кайтып җитте», — диелә.

Г.Исхакый репликасында «Сүз» газетасының 1916 елгы 1 июнь (60 нчы) санында чыккан имзасыз «Милләтләр мөрәҗәгате хакында» исемле язма турында сүз алып бара. Анда:

«Бервакыт Русиядә яшәүче төрле инородец исеменнән Америка президенты Вильсонга бер язу бирелгән. Бу язуда бу милләтләрнең Русиядә бик кысынкы хәлдә яшәүләреннән, хөкүмәтнең аларның бөтен мәдәниятләрен җимерү сәясәтендән шикаять

ителгән. Бу язуга мөселман берничә зыялыларының да имзалары бар дигән хәбәрләр рус матбугатында таралган иде. Г.Думадагы уңнар, шул язу мөнәсәбәте илә Дума рәисе Родзянкога заявление биреп, мәсьәләнең тикшерелүен сораганнар иде.

Инде май 28 ендә Г.Думаның старшиналар советы мәҗлесендә Родзянко тәхет риясәтендә шул мәсьәлә тикшерелде.

Родзянко мәҗлесне ачу белән уңнарның заявлениясен зикер итә һәм әйтә: «Вильсонга милләтләр исемендән бирелгән язуда Г.Думаның Польский Коло әгъзасы Лемпицкийның имзасы булганлыктан уңнар һәм националистлар, Лемпицкийның бу эшен аерып, Г.Думаның идарә һәйәте комиссиясендә тикшерелүне сорадылар».

Граф Путкамер әйтә: «Польский Коло Лимпецкийны үткән ел сентябрь аенда ук Коло әгъзалыгыннан сөреп чыгарды вә шул вакытдан бирле аның белән һич мөнәсәбәттә булганы юк».

Родзянко буйлә тәнбиһ ясый: «Г.Дума рәисе булучылыгым сыйфаты илә Америка президенты Вильсонга бирелгән мәзкүр язу хакында минем катгый бер сүз сөйләр хәлем юк. Бу гына аз: бу язу бирелү хакындагы хәбәр, кирәк, миңа, кирәк, башкаларга булсын, гәзитәләрдән генә мәгълүм булды. Мондый хәбәр рәсми дә була алмый, катгый рәвештә дөрест булып бетмәве ихтималы бар. Әгәр мондый бер язу Вильсонга чынлап йибәрелгән булса да, аз гына да Русиядә яшәүче милләтләрнең тәрҗемане әфкяре була алмыйдыр.

Русия инородецларының чын әфкяре Дума минбәрендән аерым милләтләрнең рәсми вәкилләре тарафыннан, аларның гомуми ватанга садыйк калуларында вә итагатьлелегендә һич шөбһә калдырмаслык рәвештә ителеп әллә ничә кат әйтелде», — ди.

Мөселман фракциясе вәкиле Котлымөхәммәд мирза Тәфкилев урыныннан кабаланып торып игълан итә: «Вильсонга бирелгән язу мөселман тарафыннан имзаланган булса да, ләкин бу язуны, кирәк, төзешүгә вә, хосусән тапшыруга бер генә мөселман фракциясе катнашмады», — ди.

Трудовик Керенский язу тапшырылу фактына нәтиҗәсе кайчан булса да бер килеп чыга торган серле эш дип мәгънә бирә: «Бу фактка күз йомарга һич ярамый, бу Русия туфрагында яшәүче аерым милләтләрнең хәлләре начарлыгын ярып саладыр. Менә шуның өчен дә Дума мәйдане мөзакәрәгә милли мәсьәләне куярга тиеш, чөнки бу мәсьәләләрдә шәһәр вә земство идарәләре ислях мәсьәләләре кебек үк мөһимдер», — ди.

Чкенкели Вильсонга бирелгән язуны мөндәриҗат вә форма ягындан карый. Ул, грузин сыйфаты илә, берәр мәмләкәт кул астында торучы милләтләрнең чит бер мәмләкәт химаясенә сыгынуларына, үз хокукларын химая итү хакында чит мәмләкәткә мөрәҗәгать итүләренә протест ясый. «Грузиннар бөтен Русия халкы белән бергә хокуклы булырмыз дип ышанып, өмидләнеп торалар. Ләкин Вильсонга язылган мөрәҗәгатькә Дума бик нык илтифат итәргә тиештер. Чөнки бу факттан әллә ниләр чыгып китү ихтималы бар», — ди.

«Баскаков Лемпицкий мәсьәләсен Дума идарәсе һәйәтенә тапшыруны мәгъкуль тапмый. Мәҗлес бу мәсьәлә хакында Баскаков фикеренә катнашып, уңнар вә социалистларның Лемпицкий хакында булган тәкәллефе рәд ителәдер», — диелгән.

Америка президенты Вильсон дигәндә, 1912–1921 елларда Америка Кушма Штатлары Президенты булып сайланган Уилсон Вильсон (1856–1924) күз алдында тотыла.

255 бит.

**Уфа киңәш мәҗлесе.** «Сүз» газетасының 1916 елгы 12 июнь (63 нче) санында «Гаяз» имзасы белән басылган. Текст шуннан алынды.

[1] *Гомәр әфәнде Терегуловның ... докладлар хәзерләве язылады.* — Меньшевик, 1913–1917 елларда Уфа губернасы земствосының мәгариф бүлегендә мөселманнар бүлекчәсе мөдире, педагог Гомәр Терегулов (1883–1938) турында сүз бара; 1919 елдан соң эмиграциядә яши.

257 бит.

**Блок вә мөселманнар.** «Сүз» газетасының 1916 елгы 19 июнь (65 нче) санында «Гаяз» имзасы белән басылган. Текст шуннан алынды.

[1] *Шул Дума да... купчелек тәшкил иткән «тәрәкъкыйпәрвәр блок»...* — бу блокка Думадагы алты фракция кергән. Мөселманнар фракциясе әлеге блокның программасын кабул итү ягында торса да, блок мөселманнарның бу теләкләренә колак салмый. Аны оештыручылар (барыннан да бигрәк кадетлар) Думадагы күпчелекне традицион властьны алмаштыру максаты тирәсендә тупларга омтылалар. Мөселман депутатлары өчен исә хокукый, дини, милли чикләүләрне бетерү иң мөһим нәрсә булып торган. Хәер, мөселман газеталарында мөселман депутатларының блокка кермәвенә сәбәпләр итеп аларның йомшаклыгы, пассивлыгы да күрсәтелә.

260 бит.

**Аурупа карашында ислам дөньясы.** «Сүз» газетасының 1916 елгы 26 июнь (67 нче) санында «Гаяз» имзасы белән басылган. Текст шуннан алынды.

Мәкалә Беренче бөтендөнья сугышы барган вакытта язылган.

263 бит.

**Киңәш мәҗлесе (Кирәк, хосусый мәктүбләр...).** «Сүз» газетасының 1916 елгы 30 июнь (68 нче) санында «Гаяз» имзасы белән басылган. Текст шуннан алынды.

265 бит.

**Лашман хезмәте.** «Сүз» газетасының 1916 елгы 10 июль (71 нче) санында «Гаяз» имзасы белән басылган. Текст шуннан алынды.

Беренче бөтендөнья сугышының беренче елларында (1914–1915) Дала генерал-губернаторлыгыннан (хәзерге Казакъстан, Кыргызстан җирләре) һәм Төркестан генерал-губернаторлыгыннан (хәзерге Төрекмәнстан, Таҗикстан һәм Үзбәкстан җирләре) беркем дә, шул исәптән монда туган яки 15 яшенә җиткәнче күчеп килгән руслар да, сугышка алынмаган. Әмма 1916 елга чыккач, патша хөкүмәте моңа кадәр мобилизацияләнмәгән «инородец»ларны, нигездә, бу җирләрдә яшәүче төрек-мөселманнарны оборона төзелеше, окоп казу кебек эшләр өчен солдатка алырга кирәк дигән карар кабул итә һәм 1916 елның 25 июнендә бу турыда патша фәрманы игълан ителә.

Бу сандагы патша әмере — лашман хезмәтенә инородецларны җыю турындагы фәрманы — патша Николай II нең 1916 ел 25 июнендә чыккан указы (фәрманы) нигезендә 19–43 яшьлек инородец ирләр оборона сызыгы һәм хәрби элемтә юллары эшләренә алынырга тиеш була.

Бу мәсьәләдә мөселман фракциясенең эше, вакытлы комитет җыю эше 1916 елның 17 июлендә Россия Министрлар Советы Рәисе Б.В.Штрюмерга К.Тәфкилев һәм Й.Җәгъфәрев имзалары белән хат тапшыралар. Бераз соңрак, 1916 елның 19 ноябрендә, мөселман депутатлары инициативасы, 35 депутат имзасы белән заявление игълан ителә.

267 бит.

**Рамазан Шәриф гаете.** «Сүз» газетасының 1916 елгы 18 июль (73 нче) санында «Гаяз» имзасы белән басылган. Текст шуннан алынды.

Мәкалә Рамазан гаете — бәйрәм көнендә чыккан, әмма Г.Исхакый дөньядагы шатланырлык хәлләр турында сөйләми: Аурупа һәм Азиядә Беренче бөтендөнья сугышы бара. Аның башланганына инде өченче ел киткән.

[1] *Русия-Австрия сугышы* — Беренче бөтендөнья сугышы кабынып китүгә беренчел сәбәп (сылтау) — 1914 елның 15 июлендә Австро-Венгрия тәхете варисы үтерелә. Германиянең басымы астында Австро-Венгрия — Сербиягә каршы, ә дүрт көннән соң Германия Россиягә каршы сугыш игълан итә. Бу зур сугыш җәмәгатьчелектә ( матбугатта) Русия-Австрия арасында барган бәрелеш рәвешендә дә аңланган.

[2] *Идел буе мөселманы Босна, Һәрсак мөселманына хәмлә итте.* — Мөселман-славяннар яши торган Босния һәм Герцеговинаны 1878 елларда Австро-Венгрия империясе үз составына кертә. Беренче бөтендөнья сугышы вакытында Россия Австро-Венгрия белән дә бәрелешкәндә, билгеле инде, аның гаскәрләрендәге Россия мөселманнары да каршы як мөселманнары белән сугышырга тиеш булганнар.

[3] *Төркия чигендә Идел буе мөселманы, Кавказ төреге ... кылыч күтәрде.* — Беренче бөтендөнья сугышына Төркия Германия яклы булып катнашырга мәҗбүр була, коры җирдә Россия белән Төркия арасындагы сугыш хәрәкәтләре башлыча Кавказ артында барган.

[4] *Һинд, Бәлуҗестан мөселманы...* — ул вакытларда Англиянең колониаль идарәсендәге Һиндстан да Төркиягә каршы сугыш хәрәкәтләренә катышырга тиеш булган. Белуджистан — хәзерге Пакыстанның бер өлкәсе. Бу елларда аның көнчыгыш өлеше — Англия кул астында, көнбатыш ягы Иран составында була.

[5] *Айя-Суфия җәмигысының башына күтәреләчәк тәрене асар өчен...* — Беренче бөтендөнья сугышы вакытында Россия үзенең күптәнге хыялын — (Петр I васыятендә үк әйтелгән) тормышка ашырырга — Дарданелл һәм Босфор бугазларын кулга төшерергә, шул исәптән Истанбулдагы әлеге атаклы мәчетне дә христиан гыйбадәтханәсе итәргә тырышты.

[6] *Мисыр да ... мөселман кардәшенә ук атты, кылыч чапты.* — 1511 елда Госманлы империясе составына керсә дә, шактый дәрәҗәдә мөстәкыйльлеген саклап килгән Мисыр 1882 елда Бөекбритания тарафыннан оккупацияләнә, ә 1914 елда аның протекторатына әверелә. Шунлыктан ул сугышка инглизләр ягыннан торып катнаша (шулай итеп, Төркиягә каршы позициядә була).

[7] *Иранныц төрле кабиләләре ... кырылышты, сугышты.* — Бу сугыш барышында Иранның төньягы — рус гаскәрләре, көньягы инглиз гаскәрләре тарафыннан басып алына. 1915 елның мартында Англия белән Россиянең үзара яшерен килешү төзүләре халыкта ризасызлык тудыра, каршылык хәрәкәтләре барлыкка килә.

[8] *...өченче Рамазан гаетен үткәрә.* — Рамазан гаете 1914 елда — 9 августка, 1915 елда 29 июльгә туры килгән.

[9] *Инде дүртенче гаетне укыганда...* — 1917 елда Рамазан гаете 7 июльгә туры килә; кызганычка каршы, Г.Исхакыйның өмете акланмый — Беренче бөтендөнья сугышы дәвам итә әле.

270 бит.

**Сугыш хезмәте күпмегә төшә?** «Сүз» газетасының 1916 елгы 24 июль (74 нче) санында «Гаяз» имзасы белән басылган. Текст шуннан алынды.

Мәкаләдә сүз 1914 елның 1 августында башланып киткән Беренче бөтендөнья сугышы вакытындагы финанс чыгымнары турында бара.

[1] *Киләсе елда никадәр булачагын Алла үзе генә белә.* — 38 дәүләт катнашкан Беренче бөтендөнья сугышы 1918 елның ноябрендә Германиянең капитуляциясе белән тәмамланды. Дүрт ел эчендә сугыш хәрәкәтләренә тартылганнарның гомуми саны — 29 миллионга, мобилизацияләнгәннәр саны — 74 миллионга җиткән; яу кырында һәлак булучылар — 10 миллион, җәрәхәтләнүчеләр — 20 миллион.

272 бит.

***** (Лашман хезмәте хакындагы фәрман...).** «Сүз» газетасының 1916 елгы 29 июль (75 нче) санында «Петроград, 25 июль, Гаяз» имзасы белән басылган. Текст шуннан алынды.

[1] *... тиешле табып язган идек.* — «Сүз» газетасының 1916 елгы 10 июль (71 нче) санында «Гаяз» имзасы белән басылган «Лашман хезмәте» исемле мәкалә искә алына.

[2] *Штрюмер җәнаблары* — «Мәскәү, 27 гыйнвар» исемле мәкалә искәрмәсен карагыз.

[3] *Хатлары «Сүз»нең 74 нче номерында басылды* — Ул язма «Котлымөхәммәд мирза Тәфкилев вә Җәгъфәревтән баш министр Штрюмерга хат» дип исемләнгән.

[4] *Зур канлы вакыйгалар* — лашман хезмәте турындагы патша фәрманы Төркестанда, хәзерге Казакъстан җирләрендә зур ризасызлык тудыра. 1916 елның 4 июлендә башланып киткән халык күтәрелеше 1917 елның башына кадәр дәвам итә. Гаскәр көчен куллану белән генә властьлар күтәрелешне бастыра алганнар.

[5] *Кыргыз* — хәзерге вакытта казакъ исеме белән аталып йөртелә торган төрки милләт күз алдында тотыла.

[6] *Бүкәй хан илләре* — 1801–1876 елларда яшәгән Казакъ ханлыгын Бүкәй Нургалимов дигән кеше төзегәнгә, ул Бүкәй Урдасы дип тә йөртелгән. Мәкалә язылган вакытта әлеге Урда Әстерхан губернасы составында була.

[7] *Верховный ставка* — бу елларда Россия дәүләтенең хәрби көчләре белән идарә итә торган органы.

[8] *Рус депутатларыннан трудовик Керенский һәм дә прогрессист Караулов бергә барырга сүз бирделәр.* — Бу урында рус сәяси эшлеклесе, 1917 елда Вакытлы хөкүмәт башлыгы Александр Федорович Керенский (1881–1970) һәм II һәм IV Дума депутаты Михаил Александрович Караулов (1878–1917) турында сүз бара.

[9] *Дума рәисе Родзянко* — М.В.Родзянко (1859–1924) октябристлар партиясе лидерларыннан, III һәм IV Дәүләт Думаларының рәисе булган.

[10] *Петроградтагы бөтен депутатлар* — Россия империясенең даими урыны Петроградта булган IV Дәүләт Думасы депутатлары турында сүз бара.

[11] *Куропаткин* — патша генералы А.Н.Куропаткин (1848–1925), 1898–1904 елларда Россиянең хәрби министры, рус-япон сугышы вакытында булдыксызлыгы белән танылa.

275 бит.

**Фракция вә бюро.** «Сүз» газетасының 1916 елгы 10 август (77 нче) санында «Гаяз» имзасы белән басылган. Текст шуннан алынды.

[1] *1906 елны 27 апрельдә Государственный Дума ачылгач та...* — I Дәүләт Думасы 1906 елның 27 апрелендә эшли башласа да, 8 июльдә патша Манифесты белән куып таратыла.

279 бит.

**Яшь көчләрнең бурычы.** «Сүз» газетасының 1916 елгы 14, 19 һәм 23 август (78, 79 һәм 80 нче) саннарында «Гаяз» имзасы белән басылган. Текст шуннан алынды.

Г.Исхакый язмасы һәм «Тормыш» газетасының 1916 елгы 10 август (499 нчы) санындагы «Уфада кызлар мәдрәсәсе» исемле хәбәр Г.Гаделморад имзалы берәүне «Дин вә мәгыйшәт» журналында «Тормыш» вә «Сүз» гәзитәләренә» дигән күләмле мәкалә белән чыгыш ясарга этәргән (1916 ел, 32, 33, 35 нче саннар). Аның соңгы (35 нче) санында сүз Г.Исхакый мәкаләсе турында бара. Автор, татарның киләчәге мәсьәләсен Г.Исхакый «дәһшәтле мәсьәлә итеп табуын», «бөтен татар зыялыларына җитди бер сөаль ташлавын» әйтеп, Исхакый мәкаләсеннән II өлешенең «Шуның өчен бу бабаларның үскән...» дип башланган соңын аз гына үзгәртүләр белән тулысынча күчереп бастыра һәм мәкаләсен түбәндәгечә дәвам итә:

«Гаяз бу сөальне бик җиңел итеп кенә ташламый, ул үзе сүзе башында борынгы голямаларның «динсезләр берлән аралашмагыз, тар кием кимәгез, фәләнчә уку хәрам, дуңгыз ите хәрам, фәләнчә йөрү мәкърүһ, музыка дөрест түгел» кеби сүзләр илә иң әүвәл зыялыларның канын кыздыра. Шуннан соң милли кяферләр дип аларга мәзкүр сөальне кадый. Бу сөальгә җавап бирү, әлбәттә, безнең кеби фикере кара, халык, дин-диянәт дип, Гаяз таифәсе артыннан йитәрлек дәрәҗәдә түгел, артта калган таифәләргә лязем түгел. Шуның өчен бу сөальгә Гаяз мәсьәләсенә җавап бирүне түбәндәге таифәләргә хәвалә кыйлам (дикъкать идәрсез!).

Ике сүзнең берендә ят тел катыштырып сөйли торган, кирәк-кирәкмәс фәннәр укып, романнар карап (?), тәүсигы мәгълүмат хәйләсе илә яшәгән (үз зәгымларынча) зыялылар, эшкә иренеп, иленнән бизеп, милләтнең азаккы копейкасын да үз кесәләренә калдырмаенча, корсак туйдыру фикеренә кереп, милләтне хур вә мәсхәрә кыйла торган нәсел вә нәсәб заегъ итәргә сәбәп булган театр вә концерт биреп йөрүче татар артистлары, каты якалар куеп, кулларына капельмейстер кеби нечкә вә юан таяк тотып, үзләренең нә милләттән икәнене түшләренә карап белемми, озын мыеклы-сакалын атнасына ике мәртәбә кыра торган мөгаллимнәр бөтен дөньяга һәртөрле бидгать ишага кыйлып яза. Тугры килгән урында очраган халыкка татлыландырып сүз сөйләүче тел бистәсе, хатыннарга һәр нәүгъ хөрриятне бирә вә аларны җитәкли, имамнарны «муллалар» дип язып, эшсезлек илә гаеп кыла торган, үзләрен бөтен дөньядагы милләттәшләргә дәрес бирүче санаган вә бәгъзеләре гәзитәләре саен мөфти хакында халык арасына ифтиракка сәбәп булган төрле хәбәрләр язып, үзләре мөфти була алмый калган ачуын алучы гәзитә мөхәррирләре, мөгаллимәләрне, уку яшендәге кызларны һәр нәүгъ дәсисә илә тәдсис итеп, артларыннан телохранитель булып йөрүче татар начальниклары, өйләрендә ят милләттән гувернантка, кухарка тота торган суфи мәхәллә картлары, очраган кешегә сәлам бирергә дә саранлык кыйла торган, кирәкле урынга иганә сораганда, вакытым юк әле, дип кенә җавап бирүче, кызларны рояль-пианино вә әллә нәрсәләр уйнарга өйрәтүче яһүди хатынына сәгатенә ике сум биреп, хәлфә вә мулласына килгәндә, бер сум да бирергә авырсынучы байлар, әүвәлге вакытта бишбилле казакидан, мәсҗедкә барганда чалмадан йөреп, хәзерендә ул сыйфатын җуеп, европейский тар вә юка костюм киеп, ботинкалардан гына йөри торган сәүдәгәрләр, граммофон мөсабәкасе ясый торган, хатыннарын томанныйларга, базарларга, якын станцияләргә вә вокзалларга йөртүче, мәхәлләсен аздыра торган яшь имамнар, мәктәп-мәдрәсәләрен төрле программаларга авыштырып, төрле йирдән мөгаллимнәр китереп тә һаман да эш чыкмаенча, шәкертләре берәм-берәм сызган, тәрәккъкый итә торган мәдрәсәдә шәкертләре калмагач, (от нечего делать) сызганып кызлар мәдрәсәсе ачып, шунда мөдир булырга, яхуд пәрдә артында гына булса да, имтихан кылырга фикерләүче имамнар, мөгаллимнәрне төрле шәһәрләрдән, чит мәмләкәтләрдән игъланнар илә җәлеп итүче вә һәр сәнәдә моктәдир мөгаллимнәр хезмәте аркасында галидән ибтидаигә төшкән, ярты миллион суммага хуҗа мөдир вә мөтәвәллиләр, мәхәллә халкы арбасына утырып, мәдрәсәләрен сыйныфлап мөгаллимнәргә тапшырып, зур шәкертләрдән колак каккан мөдәрисләр, йә, авыл йә шәһәр халкы тормышын тәнкыйть итеп, үзе намаз укымый, дин тотмый, рузасыз гомер кичерүче мөхбирләр, хатыннар ихтилятыннан, хәрәкәт вә сәкәнатларыннан ләззәт алучы тәрәккъкыйпәрвәр татарлар, җәмгысы нә бер Алласын, пәйгамбәрен зикер итми торган, дин юлында булган ишан вә муллаларга дошман булган, фәхеш вә отыштан башы чыкмый торган шарлатаннар! Пәйгамбәр сөннәтенә, сәләф юлына аркылы төшеп, исем вә шөһрәт таратуга хезмәт итүче, мәсҗедләренә хатыннар кертүче хатынпәрәстләр, җае килсә, дин вә вөҗданын бер тиенгә сатарга хәзер булган, халыктан көлү өчен көлке журналлары чыгарган адәм хурлары, халык акчасыны исраф итәр өчен намәшрүг юллар ихдас идәргә тәэсис иделеп тә, бар акчаны бетерүче «Җәмгыяте исламия» дип аталган җәмгыять әгъзалары, мохитенә карап, мәсләк алыштырган остазлар юлыннан чыккан ишан вә мөридләр, Гаязның идәреб, мәбһүт уларак гарыз иткән сөаленә — аның өчен нә лязем? Нә җавап бирсен инде?

[...] хәзерге хәлемезне назар игътибарә алып, барыш-килеш, алмашыну, милли кяферлек мәсьәләләре мөляхәзә итәргә, чарасына керешергә тиештер. Сүзегез бетәсендәге язылган нәрсәдән дә азрак гыйбрәтләнергә кирәккә, шул мәсләкне тәрвиҗ вә тәкъвия итүче баш мөәссис Гаяз бу көнгә көн кидешләрнең уңгайсызга таба барганын сизә вә төзәтергә ни лязем икәнен халыкка гарыз кыла.

Фәгътәбиру йа ули-л- әбсар».

[1] *Уфаның һиммәтле байларыннан Габделлатыйф хаҗи Хәкимов ... бер ширкәт мәйданга китергән.* — 1916 елда И.Н.Харитонов типографиясе бертуган Әхмәдуллиннарның «Өмид» типографиясе белән берләшә һәм «Сабах» фирмасы каршында эшләвен дәвам итә.

[2] *«Тәрбиятел-әтфаль», «Ак юл» журналлары акчасызлык юлында корбан булдылар.* — «Тәрбиятел-әтфаль» журналы 1907 елның гыйнвар — март айларында Мәскәүдә Заһид Шамил наширлегендә һәм редакторлыгында чыккан (сәркатибе — Фатих Әмирхан). «Ак юл» журналы 1913 елдан 1916 елның гыйнварынача Казанда Фәхрелислам Агиев наширлегендә һәм редакторлыгында чыккан.

[3] *«Мөгаллим», «Мәктәп» берсе артыннан берсе үлде, харап булды...* — «Мөгаллим» журналы 1913–1914 елларда Оренбургта Хәсән Гали наширлегендә һәм редакторлыгында чыккан. «Мәктәп» журналы 1913–1914 елларда Казанда Шиһаб Әхмәров редакторлыгында чыккан (нашире — «Сабах» ширкәте).

292 бит.

**«Нәшере Коръән ширкәте».** «Сүз» газетасының 1916 елгы 31август (82 нче) санында «Гаяз» имзасы белән басылган. Текст шуннан алынды.

[1] *...беренче адымы кебек тәфсир ителгән иде.* — Бу урында Г.Исхакый «Яшь көчләрнең бурычы» мәкаләсенә ишарәли.

[2] *...бибәһрә бер Коръән сәүдәгәре белән бетерелүе вә шул эштә капраллык таягы «Сабах» ширкәтенә бирелүе исне китәргән иде.* — Ис китәрүнең сәбәбе Кәбир Бәкернең «Коръән табгы вә ислам матбагасы» исемле язмасында («Вакыт», 1916, 19 август, 2079 нчы сан) ачыла. Ул анда: «Уфа байлары [...] милләтнең иң зур ихтыяҗларыннан бере Коръән табгы вә дини китаплар нәшер итү өчен Духовный Собрание хозурында гомуми бер матбага тәэсис итү дип карар бирделәр. Габделлатыйф хаҗи, зур бер микъдарда иганә кылып, ошбу эшнең мәйданга килүенә өмид тә тудырган иде. Менә шул арада халис тиҗарәт уе белән генә матбага тотып килгән «сабахчы»ларның бу эшкә катышып, Харитонов матбагасыны үз матбагаларына кушулары, халис изге бер ният белән генә башланган бу эшнең барышын икенче бер тарафка суырып, милләтне зур бер вакыфтан мәхрүм итмәдеме?» дип яза, Габделлатыйф хаҗи биргән акчаның хосусый нәшриятка тапшырылу ихтималына каршы чыга. К.Бәкер уенча, «Бөек ислам матбагасы» исеме белән тәэсис ителгән Хәкимов вә «сабахчы»лар матбагасының нинди әсасларга корылганлыгы хәзергә ачык мәгълүм түгел. Эш башына куелган кешеләрнең бөтен гомере матбага хезмәтендә үтеп тә, сәнгатьчә имтияз кәсеб итәрлек җитди бер эш күрсәткәне беленмәде, шунлыктан хәзерге бу яңа матбагага яңа өмидләр баглап булмыйдыр. Билгакес, Харитонов мәйданнан китү илә Казандагы мөселман матбагаларының бөтен рәкабәтләре бер-беренә аяк чалудан гыйбарәт булып, сәнагать вә нәфасәт ягы үз-үзеннән сүнәргә мөмкин, чөнки бездә рәкабәт шул юлдан чыгалмый».

[3] *«Дин вә мәгыйшәт» Сафа Баязидовның яңгы бер кармагы кебек иттереп бәянда булынды.* — Бу турыда журналның 1916 елгы 31 нче санындагы «Бөек эш вә мөһим тәшәббес» (имзасыз) һәм 33 нче санындагы «Габделлатыйф хаҗи» (авторы — Һатиф) исемле мәкаләләрдә әйтелә.

[4] *Мәкәрҗәнең беренче съездында...* — «Иттифакы мөслимин» («Мөселманнар иттифакы») партиясенең I съезды Мәкәрҗә ярминкәсе вакытында 1905 елның 15 августында үткәрелә.

[5] *Коръәннәрдә Казан яшьләре тарафыннан тәхрифләр табылгач...* — И.Н.Харитонов матбагасында Коръән хаталы басылуына беренче булып Фатих Әмирхан игътибар итә һәм «Кояш» газетасының 1913 елгы 14 ноябрь (264 нче) санында «Коръән бозу» исемле мәкалә бастыра. Казан татар вакытлы матбугатында бу турыда берничә тапкыр язылган.

294 бит.

**Уку елы керде.** «Сүз» газетасының 1916 елгы 4 сентябрь (83 нче) санында «Гаяз» имзасы белән басылган. Текст шуннан алынды.

297 бит.

**Мәрхүм Исмәгыйль бәк Гаспринский.** «Сүз» газетасының 1916 елгы 18 сентябрь (86 нчы) санында* «Гаяз» имзасы белән басылган. Текст шуннан алынды.

Газетаның бу санында «Мәскәү хәбәрләре» рубрикасы астында «Гаяз әфәндегә бүләк» исеме белән басылган хәбәрдә Бакуның бер заводында эшли торган татар эшчеләренең Гаяз Исхакыйга бүләк — кыйммәтле язу әсбабы җибәрүләре турында әйтелә: «Кара савытының мрамор тактасына көмеш белән бик нәфис язуда «Биби Һибәт эшчеләреннән әдибебез мөхтәрәм Гаяз Исхакый җәнабларына тәкъдим» дип язылган. Күндергән мәктүбләрендә Биби Һибәт эшчеләре, Гаяз әфәнденең Рамазан гаете мөнәсәбәте белән язган мәкаләсен бер мәҗлестә укыгач та, шул мәкаләне тәкъдир итеп, шул карарга килүен һәм дә акча җыеп алуларын язалар. Эшче сыйныфымызның шул сизгерлеге дикъкать ителмәслек түгелдер». «Рамазан гаете мөнәсәбәте белән язган мәкалә» дигәндә, Исхакыйның «Рамазан Шәриф гаете» мәкаләсе истә тотыла.

[1] *«Солдат бәете»* — «Рәсемле солдат бәете» исемле китапчык 1915 елда Казанда «Сабах» көтепханәсендә басылган (бу турында хәбәр «Йолдыз» газетасының 1915 елгы 4 март санында бар).

299 бит.

**«Сүз» гәзитәсе конторасыннан.** «Безнең ил» газетасының 1916 елгы 4 декабрь (4 нче) санында «Сүз» газетасының вәкиле «Мөхәммәдгаяз әл-Исхакый» имзасы белән басылган. Текст шуннан алынды.

Бу газетаның соңгы саны 1916 елның 22 сентябрендә басыла, ә шул ук елның 10 ноябрендә чыга башлаган «Безнең ил» газетасы аның дәвамы булып тора.

«Вакыт» газетасы (1916 ел, 4 октябрь) аның туктатылуы турындагы хәбәрдә газетаның «зарарлы мәсләге өчен хөкүмәт тарафыннан сугыш беткәнгә кадәр дип ябылу»ы, редактор Габдулла Сәгыйтовның «Земский союз тарафыннан лашманчыларга меңбаш итеп тәгаен кылынуы, капитан дәрәҗәсе бирелеп тиешле урынына җибәреләчәге» әйтелгән.

«Дин вә мәгыйшәт» журналы (1916 ел, 39 нчы сан, 343 б.) «Сүз» газетасы» дигән хәбәрдә: «Мәскәүдә Г.Исхакый тарафыннан чыгарыла торган «Сүз» гәзитәсе начар мәсләк тәгъкыйб иткәне өчен хөкүмәт тарафыннан туктатылды. Шундыйрак татар галәмене төһмәткә сәбәп була торган икенче бер гәзитә чыгарырга рөхсәт алынган, соңгы гәзитәгә мәсьул мөхәррирлеккә икенче бер кешене «яллаганнар», — дип язган. «Безнең ил» газетасы Шакир Мостаев һәм Гаяз Исхакый редакторлыгында чыккан.

300 бит.

**Лашман хезмәтенә кирәргә теләүчеләр.** «Безнең ил» газетасының 1916 елгы 18 декабрь (6 нчы) санында «Земгор — лашман эшен карау бюросының әгъзасы Мөхәммәдгаяз Исхаков» имзасы белән басылган. Текст шуннан алынды.

[1] *Земгор комитеты* — земство һәм шәһәр союзларының берләштерелгән комитеты; Беренче бөтендөнья сугышы вакытында Россия армиясен тәэмин итүдә патша хөкүмәтенә ярдәм итү максаты белән 1915 елның июлендә оештырылган. 1918 елда Халык Комиссарлары Советы карары белән таратылган.

300 бит.

**Хәйрият әһленең дикъкатенә.** «Безнең ил» газетасының 1916 елгы 18 декабрь (6 нчы) санында «Садретдин Максудов, Мөхәммәдгаяз Исхаков» имзалары белән басылган. Текст шуннан алынды.

*1915*
Казыйлык ..................................
Мәүлед бәйрәме ...............................
«Сәйяр» труппасы хакында .........................
Безнең хәлләр (Сугыш Русиянең бөтен…) .................
*** (Мәскәү кебек мөселманы...) ......................
Мәскәү, 18 гыйнвар .............................
Дума ачылды .................................
Карс мөселманнары .............................
Безнең хәлләр (Тарих көпчәгенең әйләнүе...) ................
Мәскәү, 8 февраль ..............................
Мөселманнарның хәле вә депутатларымыз ................
Бу көннең бурычлары ............................
Җавапларым .................................
Истанбул вә бугазлар .............................
Милли уку йортларымыз ..........................
Сәясәт йөреше ...............................
Карс мөселманнары (Карс мөселманнарына ярдәм…) ...........
Бабайлар тупрагы ..............................
Икенче адым .................................
Габдулла Кариев ...............................
Өч мәсьәлә .................................
Тукай мәрхүм .................................
Русия мөселманнары .............................
Мөфтилек мәсьәләсе әтрафында ......................
Бер изах ...................................
*** (Идел буе матбугатының…) .......................
Кизүдәге мәсьәләләремез ..........................
Милли йитешсезлекемез ...........................

*1916*
Милли матбугат бәйрәме ..........................
Петроград татар гәзитәләре .........................
Матбугат бәйрәме мөнәсәбәте берлә ....................
[Халык театры съездында мөхтәрәм Гаяз әфәнде тарафыннан бирелгән доклад] ..............................
Мәскәү, 20 гыйнвар .............................
«Йолдыз» юбилейсы ............................
Мәдәни эшләремез .............................
«Ил» наширенең мөрәҗәгате ........................
Мәскәү, 27 гыйнвар .............................
Матбугат, яһүдләр вә без ..........................
«Йолдыз»ның «миллилеге» .........................
Мөселман фракциясендә киңәш мәҗлесе .................
Мөселман фракциясендә киңәш мәҗлесләре ................
Мөселман фракциясендә өченче киңәш мәҗлесе .............
Киңәш мәҗлесе ...............................
Мәскәү, 26 февраль .............................
«Йолдыз»га соңгы җавап ..........................
Кырым рухани идарәсендә мәктәп-мәдрәсә мәсьәләсе ..........
***(Тагы «Сыйрател-мөстәкыйм» баш күтәрде…) ............
Тагы «Сыйрател-мөстәкыйм» .......................
Фракция янындагы «бюро» мөнәсәбәте берлән ..............
Татарча театр вә концерт ..........................
Тагы «бюро» (Мөселман фракциясе...) ...................
Мөфтилек тирәсендә ............................

*** (Гәзитәмезнең мәктүбләр кыйсемендә…) ................
Мәрхүм Тукай ................................
Кырымда Зынҗырлы мәдрәсәсе вә идарәи рухания эшләре .......
Бюро булды .................................
Муса әфәнденең «сыйрател-мөстәкыймче»ләр берлән мөнәсәбәте ....
Мәскәүдә икенче адым ..........................
Безнең юлымыз ...............................
Гәзитә нәрсә? ................................
Имтиханнар мөнәсәбәте илә ........................
Унъеллык Дума вә мөселманнар ......................
«Таң» гәзитәсе чыгуына ун ел тулу мөнәсәбәте берлән ..........
***(Бу көнге көннең иң мөһим милли мәсьәләсе) .............
*** (Үткән номер гәзитәмездә…) ......................
Уфа киңәш мәҗлесе .............................
Блок вә мөселманнар ............................
Аурупа карашында ислам дөньясы .....................
Киңәш мәҗлесе (Кирәк, хосусый мәктүбләр…) .............
Лашман хезмәте ...............................
Рамазан Шәриф гаете ............................
Сугыш хезмәте күпмегә төшә? .......................
*** (Лашман хезмәте хакындагы фәрман...) ................
Фракция вә бюро ..............................
Яшь көчләрнең бурычы ...........................
«Нәшере Коръән ширкәте» .........................
Уку елы керде ................................
Мәрхүм Исмәгыйль бәк Гаспринский ...................
«Сүз» гәзитәсе конторасыннан .......................
Лашман хезмәтенә керергә теләүчеләр ..................
Хәйрият әһленең дикъкатенә ........................
Искәрмәләр һәм аңлатмалар .................

Литературно-художественное издание

**Исхаки** Гаяз
(**Исхаков** Мухамедгаяз Гилязетдинович)

**СОЧИНЕНИЯ**
**В ПЯТНАДЦАТИ ТОМАХ**

**Том 7**

Казань. Татарское книжное издательство. 2007

На татарском языке

Әдәби-нәфис басма

**Исхакый** Гаяз
(**Исхаков** Мөхәммәтгаяз Гыйләҗетдин улы)

**ӘСӘРЛӘР**
**УНБИШ ТОМДА**

**7 том**

Мөхәррире *В.Р.Камалиева*
Рәссамы *В.В.Булатов*
Бизәлеш мөхәррире *Р.Х.Хәсәншин*
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучысы *С.Н.Нуриева*
Корректорлары *Г.Г.Гарифуллина, Г.М.Хәбибуллина, С.Н.Галимуллина*

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 13.12.2007.
Форматы 84r108 $^{1}/_{32}$. Офсет кәгазе. «Times» гарнитурасы.
Офсет басма. Шартлы басма табагы 19,32 + форз. 0,21.
Шартлы буяу-оттиск 19,64. Нәшер-хисап табагы 21,49 + форз. 0,36.
Тиражы 3000 д. Заказ С-1565.

Татарстан китап нәшрияты ДУП. 420111. Казан, Бауман урамы, 19.
**http://tatkniga.ru**
**e-mail: tki@tatkniga.ru**

Оригинал-макет Jahat™ программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде.

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы ААҖ.
420066. Казан, Декабристлар урамы, 2.